ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

11. 1991



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:
ТАТАРСТАН
ССРның
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ,
ГАЗЕТА-
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ,
РЕДАКЦИЯНЕҢ
ХЕЗМӘТ
КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

**11**

**1991**

КАЗАН

*Бу санда*

ШИГЪРИЯТ һӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Г. МОРАТ. Аран. Шигырьләр ........ 3
Н. ӘХМӘДИЕВ. Шәрык мизгелләре. Шигырьләр ........ 7
Ф. ЛАТЫЙФИ. Хыянәт. Роман ........ 10
Х. МӨДӘРРИСОВА. Урман. Шигырьләр ........ 82
Р. ГАЗИЗОВ. Каеньлыкта үләм... Шигырьләр ........ 85
Г. ТАВЛИН. Афәт. Роман ........ 88

ӘДӘБИ МИРАС

Б. КИЛӘЧИ. Диңгез. Шигырь ........ 147
К. КӘРИБОВ. Ялындыра. Шигырьләр ........ 147
Б. МИРЗАНОВ. Гашыйк. Шигырьләр ........ 148
К. ПАТИИ. ..гә. Шигырьләр ........ 150
Г. РАМАЗАНОВ. Минем фәһмем. Шигырьләр ........ 151
Ә. СӘГЫЙДИ. Бәхтемә. Шигырьләр ........ 152
Җ. ЮМАЕВ. Вөждан. Шигырьләр ........ 153

ПУБЛИЦИСТИКА

Т. ГАЛИУЛЛИН. Замана балалары ........ 155

СӘНГАТЬ

Л. ХӘМИДУЛЛИН. Мирхәйдәр Фәйзи эзләреннән ........ 170

Коръән сүрәләре ........ 175

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ГАЙНЕТДИНОВ. Бабич һәм аның китабы ........ 186

Котлыйбыз ........ 146
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 189
Тышлыктагы сурәтләр ........ 192

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркатип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа Ф. ЛАТЫЙФИ «Измена», окончание романа Г. ТАВЛИНА «Рок», стихи Г. МОРАТА, Н. АХМАДИЕВА, Х. МУДАРИСОВОЙ, Р. ГАЗИЗОВА.

«Литературное наследие»: татарские поэты начало века.

«Публицистика»: Т. ГАЛИУЛЛИН. «Дети своего времени».

«Искусство»: Л. ХАМИДУЛЛИН. «По следам Мирхайдара Файзи».

Суры из Корана.

«Книжное обозрение»: М. ГАЙНЕТДИНОВ рецензирует книгу Бабича «Синие песни».

Поздравляем юбиляра.

Дневник общественно-политической жизни.

На наших обложках: железные узоры; портрет писателя и ученого М. Госманова.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 16.09.1991 ел. Басарга кул куелды 01.11.1991 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 38544. Заказ И-447. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Газинур Морат

### Аран

Бәйсезлегең бәйдә бәргәләнә,
Бәйсезлегең бәйле әлегә.
Бәйгеләрдә бәйге тоткан кавем,
Бәйсезлегең тоткын хәлендә.

Бәйгеләрдә бәйге тоткан Атың
Тышауланган килеш аранда
Сугымчыны көтә...
Араннарда
Атлар бетеп барган заманда

Сугымчылар арта: суга алар,
Күсәк белән суга Атыңа.
Атсыз йорттан мал-бәрәкәт китә,
Дәүләт китә...
Арба ватыла.

Атсыз да һәм Ватансыз да калгач,
Үзең җигеләсең арбага...
Бүген әнә тышауланган Атың
Сугымчыны көтә аранда.

Күзендә — яшь, юатырга теләп,
Җиләс җилләр ялмый ялларын.
— Коткар, Хуҗам, — диеп, Атың бүген
Шәкүр картка гүя ялвара.

— Коткар, Хуҗам, — диеп Атың бүген
Аран баганасын кимерә.
Йортың, җирең, телең таланганда
Ат карагы булсын илеңдә.

Ат карагы булсын — йолып алсын
Арандагы тоткын Атыңны...
Бу җиһанда Аты — малы качкан
Күп араннар инде ватылды.

---

*Газинур МОРАТ (1959) — шагыйрь, «Җир хәтере», «Мин дөньяны тыңлыйм», «Оча җырлар» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Кемнәр анда Атлар аранын да
Хөр биләмә диеп атады.
Юк, араннар бәйсез була алмый,
Бәйдә яшәгәндә Атлары.

Атны бүген урлап чыгу кирәк,
Урлап чыгу — башка чара юк.
Артта — Ил-йорт.
Алда — имперфронт —
Чигенергә инде чама юк.

* * *

Тарихларны кичә-кичә
Хәлдән тайдык. Сусадык.
Юл сорадык чишмәләргә —
Юл күрсәтте... Сусанин.

Эзләп киттек чишмәләрне —
Чишмәләрне тапмадык...
Дәверләр куйган капкынга
Кемнәр генә капмадык та,
Кемнәр генә капмадык.
Капкында да Тәңре хакын,
Алла хакын хакладык.

Без дә чыгарбыз хак юлга —
Гасырларны кичәрбез.

Ирек дигән чишмәләрнең
Ятып суын эчәрбез.

Без дә чыгарбыз хак юлга.
Юллар уң булсын!
Амин!
Каршыда — җиде юл чаты,
Юл чатында — Сусанин (!)

Килбәте шул ук. Искечә.
Нияте, бәлки, үзгә?
Белмибез — әллә адашкан,
Әллә юл сайлый безгә.

## Сабак

Уртак малны эт тә җыймас,
Эт тә җуймас чаманы.
Адәм башын адәм ашар,
Килсә этләр заманы.

Эт көненә калыр халык,
Эт көненә калыр ил.

Эт ялаган сөякне дә
Тарткалаучы табылыр.

Табынына ыргытырлар
Калдык сынык-санакны.
...Уртак малны этләр ашый —
Дүрт гасырлык сабактыр.

* * *

Р. К.

Булмаса халыкның
Әгәр дә үз Иле,
Илбасар телендә
Җыр язар шагыйре.

## Карт Отелло

Ул иреккә чыккан бүген генә,
Кичә генә тоткын булган ул.
Яшьлегендә — ят атакка яткан
Үз хатынын тотып буган ул.

Ул иреккә чыккан бүген генә,
Бүген генә килгән мунчага.
Минем гөнаһларны юарга, ди,
Җитмәс хәтта бер пот мунчалаң.

Парлы ләүкә аңа тәхет бүген —
Тәхетләрең торсын бер читтә.
Хатын-кызлар белән сак кылан, ди,
Хатын-кыздан саклан ничек тә.

Хатын-кызга суксаң, беттем, диген,
Зинданда да көн юк андыйга.
«Пахан»нардан серең яшермә дә —
Кемлегеңне шундук таныйлар.

Кешегә дә чутламыйлар анда,
Хупламыйлар безнең ишене.
Хатын кыйнап, таш капчыкта яту,
Әйт, энекәш, ирләр эшеме?!

Беләсеңме, ничә ел утырдым
Хатын хыянәте өчен мин.
Дөньясы да зиндан кебек аның —
Мин зинданда шуңа төшендем.

Зинданы да зина кебек аның —
Дөньяда мин шуны аңладым.
Һәрбер хыянәтнең — хыянәткә,
Кыяматка илтә барганын.

Һәр хыянәт кыяматкә илтә, —
Хаксызмы мин, йә, әйт, хаклымы?..
...Ышкый-ышкый юды карт Отелло
Тәнендәге шәрә хатынны.

Ул иреккә чыккан бүген генә,
Бүген генә килгән мунчага...
Минем гөнаһларны юарга, ди,
Җитмәс хәтта бер пот мунчалаң.

## Төнге Ригада латыш кызы белән сәяси сөйләшү

Бездә Ирек мәйданы бар,
Сездә — Ирек һәйкәле.
Һәйкәлгә ничек барасы,
Латыш кызы, әйт әле.

Сәҗдә кылыймчы сезнең дә
Азатлык алласына.
Һәйкәлгә ничек барасы
Мин — татар баласына?

Ә син юллар ябык, дисең,
Анда, дисең, атышлар —
Латыш җирендә кан коя
Урыслар һәм латышлар.

Латышлар илендә, дисең,
Интерфронт, ОМОНнар...
Җантимер итеп урысны
Яши бирә Гапоннар.

Без дә, дисең, күп татыдык
Кимлекне вә тарлыкны.
Тик җиңеп булмый — Иреккә
Һәйкәл куйган халыкны.

Сездә бар Роза Турайдас,
Бездә бар Сөембикә...
Тарихлар сере — йозакта,
Тарихлар сере — биктә.

Син дә юллар ябык, дисең,
Азатлык алласына.
Әйт, алайса, нишләргә соң
Мин — татар баласына?!

# Нур Әхмәдиев

## ШӘРЫК МИЗГЕЛЛӘРЕ

### Мисыр

Килгән дә дошман кол иткән,
Җимергән, ваткан, көл иткән,
Җир — вәйран, кысыр калган...
Бүгенгә — ерак тарихтан
Шул хәрабә хәлендә дә —
Күр: Бөек Мисыр калган...

### Сфинкс янында

Эссе иде көндез,
Тынга капты...
Салкыная төште — иңде кич.
Җыеп утыртты да каршысына
Тарих сөйли безгә Сфинкс.

Биш мең еллык тарих...
Әл-Гизәдә —
Каршысында пирамиданың —
Фиргавеннәр хакында сөйләвен
Тын да алмый тыңлыйм мин аның.

Кояш йоклый офык артларында,
Нил туктаган — тели тыңларга.
Пирамидаларга кат-кат карыйм —
Сыймас төсле хәтта уйларга.

Уйга сыймый...
Ә Имхатип[1] аны
Менә шушы ташка сыйдырган.
Үлемсезлек булып күчкән ташлар
Күпме колның муенын сындырган.

Болытларны тишкән түбәләрдә
Без белмәгән серләр бардыр ла...
Әнә шуннан карап тормый микән
Кояш алла — мәшһүр Амон-Ра?

Шушы Сфинксның катында да
Кемнәр генә туктап калмаган.
Гай Антоний,

---

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) — *шагыйрь, прозаик, «Аһәң», «Бал яңгыры» һ. б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

[1] Имхатип — пирамидаларны төзүгә революцион үзгәреш керткән Мисыр архитекторы.

Юлий Цезарь булган...
Наполеон да, аргач, хәл алган.

Клеопатра патша кебекләр дә
Сфинксны «тыңлап» үскәннәр.
Җиңү, саулык көтеп сугышларда,
Дога сорап киткән Искәндәр[1].

«Һәр карыш җир — катлы-катлы Тарих,
Ничә катлам? — Кемнәр санасын.
Колы иткән язмыш, фиргавен дә
Аямаган адәм баласын.

Кылычларга нигезләнгән Тарих,
Пирамидаларның һәр ташы —
Иртәгесе көнгә өмет өзгән,
Бүгенгегә түзгән кол башы.

Кызган комда кеше Тарих язган, —
Ливиянең Бөек чүлендә.
Шушы чүлдә гөлләр үстерүе
Батырлыкка тиңдер бүген дә.

Күз алдына баса иштеккәннәр,
Тыныч йоклап булмас бүген кич...
Телен белсәң, күпме гыйбрәтләрне
Сөйләр иде безгә Сфинкс!

## Помпей колоннасы

Тираннарның бармы изгеләре,
Кансызлыкта әллә тиңнәрме?
Бөек Помпей ни уйлады икән
Канга батырганда илләрне?

Баш кистергән чакта ни уйлаган?
Хөкемдарның үсен кем белә?..
Кызыксынганнарның башкайлары
Үзләре дә менгән сөңгегә.

Үз башы да җиргә тәгәрәсен
Белмәгәндер Помпей, белмәгән.
Патшалардан бер ул гынамыни —
Үз үлеме белән үлмәгән?

Күмгәннәр дә башын,
Нәкъ шул төшкә
Төзегәннәр мәрмәр колонна:
Комсыз нәфес өчен, әйт, хөкемдар,
Нәрсә булсын биек — шуннан да?

## Чүлдә уйлану

*Мисырның 96 процент җире чүлдән тора.*

Белешмәләрдән.

Бар җире чүл,
Ә чүл «кысыр».
Чүлдә гөрләп
Яши Мисыр.

Бездә җирләр
Кара туфрак.
Гомер үтә
Икмәк сорап

[1] Искәндәр — Александр Македонский.

Аргентина,
Канададан...
Без ялкаумы,
Әллә надан?

Ялкау дисәң,—
Көн-төн эштә.
Надан да дип
Булмый һич тә...

Басу тулы
Тракторлар.
Авыр заман,
Гаҗәп чорлар...
Чүлме?— Без ул,
Без — кысырлар!

## Хеопс белән әңгәмә

Без киләсен белмәгәндер,
Уйламаган фиргавен.
Онытмам кысан юлларда
Бөгелә-сыгыла йөргәнем.

Миллионлаган таш тезелгән,
Тонна-тонна һәммәсе.
Җиде могҗизаның берсе —
Болытларда шәүләсе.

Эчкә керсәң, титак-титак
Үтелә һәрбер карыш.
«Күтәрә күрмә башыңны —
Бәреп куярсың ялгыш!»

Кисәттеләр — оныткანмын,
Мин дә бит бары бәндә.
Күзләремнән ут күренде
«Күккә омтылган» мәлдә.

Ыңгырашып куйды Тарих,
Зеңгелдәде таш дивар..
Саксыз булсаң, язмыш агай
Мисырга килеп кыйнар.

Колагымда ят бер тавыш,
Кайдан килә мондый өн?
Вәкарь белән тамак кырып,
Сүз башлады фиргавен:

— Кеше түгел, бөҗәкләр сез,
Нәҗес сез, кизәкләр сез!
Шушы йортка сырышасыз,
Белмим, ник тырышасыз?

Хуфу кирәк булса сезгә,
Гәүдәм күптән урланган.
Ташлар сезгә ни сөйләсен
Безнең данлы чорлардан.

Мин үлгәнче туган булсаң,
Бер колым булыр идең.
Бимазалап йөрмәс идең,
Калтырап торыр идең!

Калдырыгыз тынычлыкта,
Үтенәм, калдырыгыз:
Бүген булмаса, иртәгә
Үләсе һәрберегез!

Ничәнче кат ризасызлык
Белдергәндер, ни чара...
Үлгәч кол да, фиргавен дә —
Барысы да бичара.

Ходай каршында тигезләр,
Барыбыз кардәш, туган.
Ләкин колдан туфрак калган,
Пирамида — Хуфудан.

Бездән исә нәрсә калыр?
Хуфу дәшми бу юлы.
Каян белсен,
Без бөтенләй
Башка тираннар колы.

Хуфудан безнең көннәргә
Илле гасырлап ара...
Уйланырсың.. Гыйбрәт өчен
Пирамида ташларына
Башыңны бәреп кара!

---

[1] Хуфу — Хеопсның борынгы мисырча әйтелеше. Аның пирамида эчендәге гәүдәсенең кая китүен хәзергә кадәр белүче юк.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Флүс Латыйфи

# ХЫЯНӘТ

РОМАН

## Серле тамга

Шәһре Кашан — җиһан күрке,
Халкы оста вә, һөнәрле,
Кем корыччы, кем көмешче,—
Шикләнмә, ышан, бел инде.

Болгар дәүләте заманындагы
билгесез шагыйрь



Иртәнге тынлыктан уянып кына килүче шәһәрне сискәндереп, Нугай юлы ягындагы капкалар өстендә олы дум-думбакларның дәртле тавышлары яңгырап үтте. Көйчеләр, әйтерсең лә, бер-берсен уздырырга тырышкандай, агач кысага тарттырылган үгез тиресенә ярсып-ярсып бәрәләр, тонык, әмма куе авазлар биек-биек манаралар арасыннан тирә-якка тарала да Казан суы, Болак һәм Кабан өстенә кайтаваз булып ишелеп төшә, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр яши торган урамнарда, тар тыкрыкларда, читлеккә эләккән коштай, бәргәләнә:

— Даң-даң-даң!..

— Доң-доң-доң...

Баштарак тукран тукылдагандай ешлык белән кабатланган авазлар кинәт туктап калды һәм берничә мизгел тынлыктан соң салмак кына тагын кабатланды. Әйтерсең, дум-думбаклар бер-берсе белән нәрсә турындадыр сөйләшә, серләшә иде.

Төпе буе йокысызлыктан газапланган Сәетнең колагына бу авазлардан да якын нәрсә юк иде. Гүяки корылыктан әлсерәгән, яргаланып каткан җир өстенә шифалы яңгыр тамчылары төште, Сәетнең йөзе яктырып китте, күзләренә нур иңде. Бармаклары кабалана-кабалана дисбе төймәләрен тартырга кереште.

— Ниһаять! Йокымсыраулы озын кышлардан соң җиргә яшәү-яшәрү килә, тормышның яме кайта...

Флүс ЛАТЫЙФИ (1943) — *прозаик, публицист. «Кырагай» һәм «Вөҗданыңнан сора» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Бүленгән намаз — күктә асылынып калган кош мисалында. Ул җиргә дә төшә алмый, күккә дә ашмый. Иреннәреннән ычкынгач, тәңре колагына барып ирешергә тиешле сүзләрне ашыкмый-кабаланмый, дөнья ваклыкларына игътибар итми, бүленми әйтү фарыз. Моны да бик яхшы белә иде Сәет. Әмма дум-думбакларның дәртле сөйләшүе аның күңеленә вәсвәсә салды, башланган догасы әйтелеп бетмәгән көйгә иреннәренә ябышып калды, колаклары шәһәр капкасы өстендәге көйчеләрнең үзара сөйләшүен сеңдерә башлады, акылы исә башкалар өчен сер булган, яшерен булган шул табышмакны чишәргә керешә.

Базар дөньясы серләреннән бихәбәр меңләгән казанлылар өчен гадәти бер көй булып яңгыраган бу авазларның яшерен мәгънәсен белә иде шул Сәет. Һәр уен коралы аңа хәбәр китерә, һәр көйнең үз сүзе бар.

Дум-думбакларның еш-еш бәргәләнүе офыкта Хәрәзем, Сәмәрканд сәүдәгәрләре күренде, алар инде шәһәргә якынлашып килә дигәнне аңлатса, аларның сирәк-сирәк дәшкәләве нинди мал төяп килүеннән хәбәр ирештерә. Әле яңа гына шәһәр сакчылары шул турыда сөйләште.

— Даң-даң... — Бусы — Сәмәрканд сәүдәгәрләре ни-нәрсә төягән дип сорау иде. Алдагы күзәтченең җавабы гадәти булды.

— Чин[1] ефәге!

Ефәк асыл мал! Мондый тавар белән хан сараена да, Казаннан көнбатыштагы башка мәмләкәтләргә дә үтеп кереп була! Кирәкле мал! Сәетнең намазын бүлеп каударлануы да шуннан иде. Хәер, озакламый башланачак Ташаяк ярминкәсендә үзенең коры кул белән калмаячагына да бик яхшы ышана иде ул. Бөтен Казанда, Казанда гына түгел, бөтен ханлыкта бер-ике дистә генә кеше аңлый торган яшерен сергә ия булу ул инде сәүдә дөньясында иң биек үргә ирешү дигәнне дә белдерә иде.

Мондый дәрәҗәгә быел кыш кына ирешә Сәет. Ул әле күп нәрсәне белми, төшенми, базар алыш-бирешләре дөньялар иминлегенә, малның күпме килүенә генә бәйле, дип фикер йөртә, сәүдәгәрләрнең үзара астыртын сүз берләшеп эш итүен күз алдына да китерми иде. Баксаң, Казан сәүдәгәрләренең үз кануннары, кагыйдәләре, бөтен дөнья малтабарларыннан аерым үз берлекләре бар икән.

Мал табу, сәүдә эшендә, юл йөрүдә өзеклек булып торган кыш айлары тәмамланып килә, нәүрүз бәйрәменә дә күп калмаган көннәр иде ул. Сәер хәбәр иртән килә дигәндәй, шундый көннәрнең берендә таң атар-атмас Сәетнең ишеген шакыдылар.

Килүче — балаларча кабарынкы ирене өстендә каралҗымланып мыек төртеп кенә килүче яшь егет — иплән кенә өйгә узды һәм яшенә хас булмаган салмаклык белән утырып дога кылгач, Сәеткә йомышын әйтте:

— Базарбаш бүген иртәнге чәйдә сине үз хозурында күрергә тели. Соңламавың хәерле булыр. Нургали ага ике сөйли торган кеше түгел.

Чин дәүләте чикләреннән салкын диңгез буйларынача исеме билгеле, дан-шөһрәтле, каты куллы һәм гадел базарбашының чакыруы Сәетне сөендерде дә, шомландырды да. Нургали ага юкка дәшмәс, бер-бер хәл булгандыр. Тик нинди хәл-хәбәр ул? Куаныч китерә торганымы, әллә көенечлесеме?

Йомышчы егетне озаткач, мәрткә киткәндәй, күзен йомып, озак уйланып утырды Сәет. Үзенең кылган гамәлләрен кат-кат хәтереннән уздырды, кемгәдер зыян салмаганмы, гаделсез эше белән кемне дә булса рәнҗетмәгәнме?.. Күпме генә уйланмасын, үзеннән гонаһ таба алмады һәм җиңел сулап әзерләнергә кереште.

Озатырга чыккан җәмәгате Гөлйөземне маңгаеннан үпкәндә җаны тынычланган, күңеле үз урынына утырган иде инде.

— Озакламам, Гөлем,— диде ул. Хатынының йомшак, ак кулын алып, үзенең маңгаена куеп торды, яраткан, аңлашып-сөешеп гомер кичергән, җанына тиң күргән затның бармакларыннан, әйтерсең, аңа рухи тынычлык

---

1 Чин — Кытай.

күңел бөтенлеге саркыды.— Озакламам,— дип янә кабатлады ул һәм чыгып китәр алдыннан борылып, шаярып күз кысты.— Базарбаш чакыра, иреңнең дәрәҗәсе үсүен күр!

Гөлйөземнең бите алланып китте, таң белән килеп кергән хәбәрдән каушап калган хатын сүз дәшмичә генә күз сирпеде, керфекләре арасыннан Сәеткә нур коелгандай булды.

«Борчылма! Ни булса да мин синең белән. Язганын бергә күрербез» дигәнне аңлата иде аның бу карашы.

Никадәр генә тыныч күренергә тырышмасын, барыбер Сәетнең йөрәген шик корты кимерә иде. Уен эшмени!? Базарбаш хозурына махсус чакырулы кешегә ике генә юл барлыгын белми түгел ул. Берсе аның — дәүләткүләм эшләрдә катнаштыру кебек дәрәҗәле юл булса, икенчесе — хурлыклы куылу, сәүдә эшеннән, малтабарлыктан читләштерелү. Бусы — үлем җәзасына тиң! Андый хөкем алган адәмгә хезмәтчелеккә төшүдән гайре чара калмый. Тамгачылар[1] килеп малын язып алыр, ясавыллар[2] аны төяп хан казнасына озатыр. Әнә шундый хөкемгә тарыганнар да булмады түгел, булды. Андый хәлләрне дә белә Сәет. Шик-шөбһәгә төшәрлек чакыру иде бу.

Нургали аганың ак таштан салынган зур йорты, морзалар яши торган аксөякләр мәхәлләсендә матурлыгы, байлыгы белән аерылып тора иде. Төсле пыяла куелган якты тәрәзәләре, зифа чыршылар белән ярышып дүрт почмагыннан күтәрелгән нечкә, төз, алтын уклы манаралары, калын имән ишекләре аны тагын да мәһабәтрәк, саллырак итеп күрсәтә. Хан карачыларына[3] тиң дәрәҗәле бу кешенең өенә юл ачылу югары катламга күтәрелү белән бер. Моны Казандагы ярлы-ябагай да яхшы белә.

Ишектән алып түр башына кадәр келәмнәр җәелгән, ачык яшел төстәге бизәкле ефәк белән эчләнгән кунак бүлмәсендә Казанның атаклы уңлап малтабары, кәрваннары белән дөньяны аркылыга-буйга гизгән сәүдәгәрләр җыелган иде. Аларны күрүгә Сәетнең бөтен тәне буйлап эчке бер калтырану йөгереп узды. Шанлы кешеләр арасына тиң итеп чакырылудан туган горурлану хисенә инде дистә елдан артык күңел чоңгылында яшәгән икенче бер тойгы — шикләнү һәм икеләнү килеп уралды. Дөрес, атларына мал төяп юл йөргәндә, Идел буйлап көймәләрдә, салларда акканда, аякларына чаңгы тагып төн ягында яшәүче кабиләләр янына чапканда ул хисләр югала, онытыла. Әмма Казанга кайтып төшүгә шул тойгы баш калкыта, әкрен генә, сиздерми генә җанын кимерә. Гөлйөзем янында, балалары арасында узган кадерле сәгатьләрнең тәмен агулый иде. Юкса, ул хиснең күптән үләргә, бетәргә тиешлеген дә белә. Сәбәпләре юк ителгән, андый борчулар өчен тамырлар калмаган да кебек. Һай, юк бит, шик үзе белән каберенә дә керер, ахрысы. Һич югы, балаларына күчмәсен иде алар.

Эче тулы шөбһә, сорауларына җавап эзләп бәргәләнү булса да йөзенә сабырлык чыгарып сәлам бирде. Бу йортта, бу кешеләр арасында сабырлыктан да югары бәяләнүче нәрсә юк.

— Хуш киләсең, Сәет туган! Әйдә, түрдән уз!

Базарбашның ягымлы эндәшүеннән Сәетнең эченә җылы йөгерде. Юк! Шик-шөбһәләрем урынсыз. Барысы да яхшы булыр, алла боерса!

Нургали ага өстәлдән кечкенә көмеш кыңгырау алды. Аның кул тибрәтүеннән кыңгырау телгә килде, гөмбәзләнеп өскә күтәрелгән биек түшәм астында көмеш чыңнар биеште. Диварлар белән бер иш ефәк чаршаулар корылган ян-як ишекләр ачылып китте, аларның берсеннән көмеш савытлар тотып яшь егетләр, икенче яктан иң талымчан кешенең дә авыз суларын китерерлек хуш исләр таратучы тәгамнәр күтәреп, яшь, чибәр кызлар килеп керде.

«Өнемме бу, төшемме?» Сәет, үзенең базарбаш өендә икәнлегенә әле һаман ышанып җитмәгән кебек, як-ягына каранып алды. Әмма бу төш түгел, чынбарлык иде. Нургали аганың ишарәсенә буйсынып, кунаклар тезләрен

---

[1] Тамгачы — таможня чиновнигы.

[2] Ясавыл — атлы каравыл, карар үтәүче.

[3] Карачы — министр.

бөкләп бүлмә уртасындагы тәбәнәк өстәл янына утырыштылар. Угланнар каяндыр чәмчәле бизәкләр салынган кызыл күн тышлы мендәрләр алып чыкты, һәр кешегә, таяныр урынына мендәр салынды.

Өстәлдәге көмеш савытларда — телемләп туралган казылык, ысланган ит, яңа гына мичтән чыккан кабартма, татлы ризыклар, чынаякларда — юкә балы, нечкә билле озын савытларда куе кызгылт ширбәт күбекләнә. Шактый ил гизәргә, дөнья күрергә өлгергән Сәет барлык сыйларның исемен дә белеп бетермәвен абайлап алды. «Базарбаш яши белә икән!» — дип уйлап куйды ул. «Дөрес, безнең дә өстәлдән кунак сыеның өзелгәне юк. Әмма, барыбер бу кадәре үк түгел инде. Их, Гөлйөземне алып килеп күрсәтәсе иде!..»

Кергәннән бирле ишек төбендә таптанудан узмаган Сәетне Нургали ага үзе өстәл янына чакырды:

— Йә, һаман бусага төбен саклау килешмәс. Уз, табын янына утыр, — диде ул кулы белән өстәлнең бирге башында буш калган мендәргә күрсәтеп. — Таяныл ал!

Сәет кабат әйттермәде. Тыйнаклыкның да бер чиге була торгандыр бит. Казанлыларның кунак сыйларга, назланып, ялындырып кына сыйлатырга яратуы мәгъриптә дә, мәшрикътә дә билгеле анысы. Тик бүген андый көн түгелдер. Базарбашы өендә хуҗаның һәр сүзе, ымы, күз карашы фәрман булып кабул ителә.

Сәетнең урыны Әҗем карт белән янәшә туры килгән иде. Казанда гына түгел, Кырымда, Әстерханда, нугай далаларында, Мәскәүдә һәм Новгородта, Хәрәземдә һәм Сәмәркандта, әрмән тауларында, кыскасы, сәүдә кәрваннары сукмагы кайда илтсә, шунда ихтирам казанган, тырышлыгы, үткенлеге, мал таба белүе белән шөһрәт алган, дөньяга таш ярып чыккан бу кеше инде җиденче дистәне ваклаган булса да, һаман яшь күренә, үткен телле, зиһенле иде әле. Ул Сәеткә таба иелә төшеп пышылдады:

— Шым бул! Монда ишеткән колагыңнан керсен, авызыңнан чыкмасын. Йөрәгең тибүдән туктаганда да иреннәрең кыймылдамасын...

Ләкин Әҗем карт әйтеп бетерә алмады, тынлыкны Нургали аганың тавышы бүлде:

— Җәмәгать! Әһле базар... Мәҗлеснең сәбәбе күпләрегезгә мәгълүмдер. Шулай да кабат әйтүдән зыян юк. «Сүзең көмеш булса, дәшмәвең алтын» тәгъбире бүгенге табынга туры килми. Шулай бит, Әҗем ага?

Базарбашның пышылдап кына әйтелгәнне дә ишетеп утыруын белеп, Сәетнең күз аллары караңгыланып китте. Күзе генә түгел, колагы да үткен икән Нургали аганың. Әнә ич, Әҗем хәтле Әҗемгә ничек төрттерә.

Әҗем картның исә керфеге дә селкенмәде. Ул базарбашка борылып, әйткәнеңне хуплыйм дигәндәй, кулларын кушырып башын иде, әйтә башлаганы исә телендә эленеп калды.

Башка сүзләрне дә, мәҗлесне дә томанлы хәтерли Сәет. Кем ни әйткән, нәрсә белән сыйлаганнар, кем ничек котлаган — болары әһәмияткә ия булмаган вак нәрсәләр шикелле артка чигенгән, күңелдән юылган. Ә иң мөһиме — анысы йөрәккә уелган, ак кәгазьгә алтын хәрефләр белән беркетелгән ярлык шикелле баш миендә мәңгелеккә урын алган.

Бу — беркайчан да Сәеттән чыгарга тиеш булмаган сер, яшерен вәгъдә. Ул аны теле белән генә түгел, каны белән беркетте.

Нургали аганың һәр сүзе әле хәзер дә колагында яңгырый, үзенә күрсәтелгән ышанычтан, олылаудан җаны татлы бер рәхәтлек кичерә, шул ләззәттән исерә. Бүгеннән башлап базар булган һәрбер илдә, һәр шәһәрдә Сәеткә юллар ачык, аның ул һәм базарбаш кына белә торган яшерен көче, бөек сере бар.

— Без синең кем икәнеңне дә, Казан-йортка ничек килеп төпләнүеңне дә яхшы беләбез. Без сине бик озак күзәттек, сынадык, — дигән иде Нургали ага. — Күңелеңдә хосетлек, калебеңдә комсызлык, саранлык юкмы, кулың кәкре түгелме, телең йозактамы, күзеңне нәфес пәрдәсе капламаганмы, йөрәгеңне май басмаганмы, эчке хасиятләрең тышкысына туры киләме?.. Ни рәвешле сынавыбыз сер булып калсын. Анысын өлкән кәсептәшләрең

үзләре белә. Әйткән сүзләрең, кылган гамәлләрең безгә килеп җитә торды, син сынауны үттең. Без сиңа ышандык...

Сәет базарбашның сүзләрен хәйран калып тыңлады. Йөрәге еш-еш тибә, бите ут булып кызыша башлады. Тыны кысылгандай булды. Чит мәмләкәтләрдә йөргәндә дә, шушы Казанда да ул үзен кемдер күзәткәнне, кирәк чакта гына ярдәм кулы сузылганны тоеп яши иде, моны еш кына үзенең шикләнүчәнлегенә сылтый, ә эше яхшы баруны юл уңудан күрә иде.

Хәер, аңа истәлекләргә бирелеп торырга ара да калмады. Базарбашның тавышы серле бер төсмер алды, ул кулы белән ишарәләп нидер күрсәтүгә, бүлмәдәге хезмәтче егетләр һәм кызлар юкка чыкты. Нургали ага үзе торып ишекләрне тикшерде, бары тик шуннан соң гына сүзен дәвам итте.

— Бүгеннән башлап син, Сәет Сәлим углы, Казан-йортның асыл сәүдәгәрләре арасына кабул кылынасың, безгә мәгълүм серләр һәм хәбәрләр синең өчен дә уртакка әйләнер... Мәгърибтән мәшрикъкәчә, көн ягыннан төн ягынача безгә мәгълүм базарларның ишекләре ачылыр, сәүдәң уң, юлың җиңел булыр. Инде безгә хыянәт кылсаң, серебезне ятларга чишсәң, аны үз мәнфәгатең өчен генә файдалансаң, башың чапкылыкта[1] бетәр. Кирәккәндә без мәрхәмәтсез дә була беләбез. Чигенер юлың юк.

Базарбашның тавышы кырысланды, күзләрендә ут чаткысы булып хыянәтчеләргә, хаиннәргә нәфрәт кабынды. Тик бу хәл озакка бармады, акрын гына, салмак тавыш белән ул Сәет алдына бүгеннән куелачак таләпләрне, хәзергә белергә мөмкин дип саналган серләрне бәян итәргә кереште. Күп нәрсәләрне сөйләде, моңарчы белмәгән, хәтта сизенмәгән нәрсәләргә Сәетнең күзен ачты Нургали ага. Серләр күп иде, катлаулы иде.

— Вәгъдәңне, сәүдәгәр сүзенә, Казан-йортка тугрылыгыңны кан белән беркетү фарыз. Бирегә кил, Сәет Сәлим углы!

Нургали ага, башы белән ымлап, Сәетне үз артыннан иярергә чакырды. Саллы чаршауны күтәреп, түр башында яшерелгән ишектән тәрәзәләренә тимер челтәр тотылган ярымкараңгы бүлмәгә үттеләр. Базарбаш авыз эченнән генә ниндидер дога укыгач, куеныннан олы ачкыч чыгарды, идәндәге бакыр сандыкның йозагын борып җибәрде. Капкач шыңгырдап ачылды. Ниндидер асыл маллар, алтын-көмеш, кыйммәтле ташлар көтеп торган Сәет сандык төбендә бары берничә төргәк язу гына күрде. Шуларның иң зурысын, вакыт үтү белән саргайганын, баш-башы мөһерләнгәнен саклап кына алды Нургали ага һәм төргәкне тәрәзәдән төшкән яктыга куеп, Сәеткә дәште:

— Мене монда тамгаңны салырсың...

Әҗем карт билендәге кыныннан сүзсез генә үткен хәнҗәрен суырып чыгарды, аны Сәеткә сузды һәм күзләре белән тәрәзә төбендәге каурый каләмгә ымлады.

Кан белән вәгъдә беркетүнең ни икәнен Сәет белә иде. Тантаналы тынлыкны бозарга җөрьәт итмичә, тавышсыз гына хәнҗәрне алды һәм җиңен сызганып, ялтырап торган очлы тимерне беләгенә кадап алды. Ярадан сирпелеп куе кызыл кан чыкты. Аның һәр хәрәкәтен тын да алмый күзәтеп торган өлкән сәүдәгәрләр бер-берсенә караштылар. Сәет үзенең тормышында ниндидер мөһим бер борылыш буласын күптән аңлаган иде инде. Бу мизгелдә ул берниндн авырту да, икеләнү дә тоймады. Барысы да, аның үз язмышы да, Гөлйөзем һәм балалары язмышы да шушы кешеләр кулында икәнен, ул гына түгел, бүгенге һәм киләчәк тормышының ничек үтәчәге дә шушы язуга, антка бәйле икәнен дә акылы, зиһене белән, бөтен җаны-тәне белән сизенгән иде. Икеләнергә, куркырга, шик-шөбһәңне күрсәтергә ярамый. Ул, каурыйны канына манчып, Нургали ага күрсәткән урынга үзенең имзасын салды. Хәрефләр тезгән арада күзләре төргәк кәгазьнең сүтелеп, алдына таралып төшкән өлешендәге язмаларны барлап чыгарга өлгерде. Арада гарәп һәм чин язуы да, уйгур тамгалары да, тагын ниндидер аңлаешсыз телдә салынганнары да бар иде. Казан сәүдәгәрләренең көчен, алар сүзенең үтемлелеген, серен тагын бер кат шунда аңлады Сәет. Шушы бөек

[1] Чапкылык — баш чабу урыны.

сергә кушылуыннан, сүзләре теләсә-кайсы йортка үтеп керердәй кешеләр арасына алынуыннан, бу мизгелләрнең җаваплылыгыннан һәм яшерен тантанасыннан башы әйләнеп китте.

Нургали ага кәгазьне яңадан төреп сандыкка салды һәм изге бер йола башкарганлыгын тагын бер кат аңлатырга теләгәндәй, аның күзләренә текәлеп, туп-туры итеп карап торды, тавыш чыгармаска тырышып тамак кырды. Куллары салмак кына Сәетнең муенына таба сузыла башлады. Әллә куркудан, әллә аның бу аңлаешсыз хәрәкәтеннән сискәнеп китте яшь сәүдәгәр, әмма башын алмады. Караңгылыкка ияләшеп өлгергән үткен күзләре базарбашның кулында ефәк җепкә тагылган көмеш тәңкәне күреп алган иде инде.

— Бу тамганы күз карасыдай гына түгел, җаныңнан да кадерләбрәк сакларсың,— диде базарбашы аның муенына тәңкәне асып.— Ул сиңа дөньядагы бөтен базарларның бикен ачар, хәтта хан сараена юл ачык булыр.— Нургали аганың тавышы көчәйгәннән-көчәя барды, аның һәр хәрәкәтен тылсымлангандай күзәтеп торган Сәеткә, үзе белән базарбаш түгел, ниндидер илаһи зат сөйләшәдер кебек тоела башлады.— Тик онытма, күргән файдаңның, тапкан малыңның уннан бере Казан-йорт казнасына, тагын да бер өлешенең яртысы уртак маяга күчә барыр. Казан-йортыбыз бай, таза, нык булсын өчен алтын-көмеш, асылташлар кирәк. Башка бар нәрсә чери, таркала, юкка чыга, тузан булып оча. Болар мәңгелек. Болар кала капкасын ачарга да, хөкемдарлар күңеленә юл табарга да ярдәм итәр. Шунысын онытма, затлы мал дошман җанына вәсвәсә сала, үчләштерә, көнләштерә, нәфесен котырта. Казан-йорт казнасына керәсе бер генә тәңкәң дә дошманыңа мәгълүм булмасын. Бусын борыныңа киртләп куй! Аягың житез, зиһенең йөгерек, кулың нык, сүзең акыллы, йортың таза, авызың биктә булсын! Амин!

Шәһәр капкалары өстендәге күзәтчеләрнең дум-думбакларда, давылбазларда[1] бәреп Казанның олы сәүдәгәрләренә яшерен телдә хәбәр биреп, базарга кай тарафтан нинди кәрван килүен белгертеп торуын да шул чакта белде Сәет. Хәзер бу тел аңа да таныш.

Озакламый Казан өстендә кояш күтәрелер, аның алтын нурлары йөзләрчә манараларда чагылып күзне иркәләр. Идел ягыннан искән йомшак җилләр меңнәрчә чакрым юл үткән кәрванчыларны назлар, күңелләренә хушлык бирер. Чишмәләрдән челтерәп аккан көмеш сулар аларның сусынын басар, буыннарына ял бирер.

Күп тә үтмәс, башка капкалар өстендә дә күзәтчеләрнең үткен күзе яңа кәрваннарны күрер, Идел өстеннән Казан суына борылучы көймәләрне абайлар. Дум-думбаклар, давылбазлар телгә килер. Кайлардан килә икән бүген арыган юлчылар? Гарәп илләреннәнме, Шам-Шәрифтәнме, Румнанмы. Су өстеннән урыс көймәләре шумыймы? Барысы да аңа — Сәеткә билгеле булыр. Үз бәхетен ул да йоклап калмас. Әле базар әһелләре белән ярминкәгә китерелгән мал-туарга хак бәһа кую да — алар кулында. Бер генә базаркән дә, алыпсатар да ул хакны бозарга җөрьәт итми. Базарбашның күзләре үткен, колаклары сизгер.

Сәетнең иреннәре дога урынына шушы сүзләрне пышылдады. Артык диндар кеше түгел ул, әмма намазлык өстендә дисбе тартып утыруның үз рәхәте, җанга тынычлык бирә торган хасияте бар. Дөнья мәшәкатьләреннән арынып тору рухны ныгыта, канны сафландыра, зиһенне үткенләтә. Тик менә бүген беренче кат иреннәре дога сүзен түгел, дөнья малын әйтеп селкенә. Хәерлегә булсын!

Саклык белән генә муеныннан тамганы алды һәм инде кемнәрнеңдер изүендә йөри-йөри шомарып беткән, бүлмәдәге сүрән яктылыкта агарып күренгән көмеш тәңкәне әйләндерә-әйләндерә карый башлады.

— И хикмәти хода! Бу тәңкәнең нинди яшерен кодрәте бар соң?— Иреннәре үзеннән-үзе шул сорауларны кабатлады. Сәетнең йөрәге ашкына, һәр ике ягына ниндидер аңлаешсыз билгеләр, башына таҗ киде-

[1] Давылбаз — бәрмә музыка уен коралы.

релгән канатлы елан сурәте төшерелгән тәңкәнең көчен сынап карыйсы, кәрваны белән ерак сәяхәтләргә, Каф тау илләренә, сартлар арасына, Рум базарларына сәфәр чыгасы килеп талпына. Күрсәтелгән олуг ышанычны аклау, казнага кирәк малны табу өчен ул теләсә нинди авырлыкларга да түзәргә әзер иде. Ат аунаган җирдә ток кала. Үзенең дә буш калмаячагын, иле-коне бөтәйгәннән-бөтәячәген дә сизенә Сәет. Дөньялар гына имин булсын! Әнә кызы — бер кашык су белән йотарлык Галиясе үсеп килә. Бирнә туплыйсы бар. Бүз бала Җәгъфәр дә сөлектәй егет булып житешеп бара. Күз генә тимәсен!

Күрше бүлмәдәге кыштырдаган авазларны ишетеп, сискәнеп китте, уйларыннан бүленде, тәңкәне тиз генә куенына яшерде. Голйөземнең һичшиксез бу бүлмәгә кагыласын белгәнгә, җанына талгын бер рәхәтлек иңде, аның иртәнге наз белән тулы йөзен күз алдына китереп, елмаеп куйды.

Хатыны озак көттермәде. «Комачауламасам ярар тагы»,— дип, саклангып кына ишекне ачты, иренең үзен көтеп утыруын күреп шелтәләп баш чайкады:

— Шушы язгы базар алдыннан чабышка әзерләнгән ат шикелле кыланасың, сиңа әйтәм. Малай чагың узган, аз гына дәрәҗәлерәк кылансаң да ярар иде... Тоне буе керфек какмадың бит!..

— Их,— диде Сәет. «Нинди дәрәҗә әле», димәкче булды, ирексездән куеныңдагы көмеш тәңкәне сыйпап куйды, тик тотлыгып калды. Боек серне хәтта сөекле хатынына да ачарга ярамый, тылсымлы кочкә ия тамганың мәгънәсен, асыл сыйфатларын белгертергә рөхсәт ителми иде. Әйтеп бирәсе килгәне телендә йотылып калды, иреннәре арасыннан бөтенләй башка сүзләр чыкты:

— Их,— дип кабатлады ул.— Белмисең, Голйөзем, олы базар шул чабыш бит инде ул. Кем уза, кем уздыра...

— Ел саен була лабаса. Узсаң да, уздырсаң да, барыбер үзеңнән уза алмассың. Безгә артыгы кирәкми. Балалар аякка басып килә... Тормышыбыз түгәрәк...

— Иргә таңнан кире сүзләр белән шелтәләмә әле син мине, Голем. Мин беләм, быел бөтенесе дә башкача булыр. Шулай тиеш. Фәрештәләр шулай белдерде.

...Йөзе агарып, беләгеннән канлы чүпрәк белән урап кайткан кошнән бирле иренең күзгә күренеп үзгәрүен, үз эченә бикләнүен, кайчакларда саташкандай авыз эченнән нәрсәдер мыгырдануын күргән саен Голйөземнең үзәге өзелә, җаны күбәләктәй бөргеләнә башлый иде. Сер яшерә торган кеше түгел иде бит ул. Уендагы — телендә, кесәсендәгесе — кулында булыр иде. Ни булган Сәеткә?! Начар юлга басмагандыр лабаса! Тагын шул халәте кабатланды, әмма ниген чыгарып селкергә ашыкмады, иплән кенә сорады:

— Авырмыйсыңмы соң син, Сәет? Әллә пешләдең кебек. Мин аңламыйммы?

— Аңламыйсың шул, аңламыйсың,— дип тәкърарлады ирс. Башка вакытта сүз әйтергә дә бирми кочагына ала иде, бүген исә аркасыннан гына сөеп куйды. Аның гайре табигый ялтыраган зәңгәр күзләрендә очыну-канатлану да, шашкын ашкыну да күреп, Голйөзем сиздерми генә берничә кат изүенә төкереп алды, узалдына пышылдады: «Изгелеккә генә булсын инде. Аллам сакласын... Аллам сакласын...»

Шәһәр капкасы өстендәге манарада дум-думбакларның аваз бирүе булды. Сәетне алыштырып куйдылар диярсең, йөзендәге елмаю юкка чыкты, атларга күтәрелгән аягын да идәнгә төшермичә тынып калды.

— Доң-доң-доң-доң...

— Дап-дап...

Һәр авазга җаван биргәндәй, башын селкеп, «Ыһы, ыһы, ыһы»,— диярго керешге, сарылт мыеты астыннан ялтырап ак тешләре күренде, битенә капагать елмаю чыкты.

Голйөземнең исә һәр авазлан йөрәгенә җәрәхәт ясала, һәр аваз авырттыргыч ук булып бәгыренә кадала иде.

Кинәт Сәет шашкын бер коч белән Голйөземне кочаклап алды һәм, күтәреп бүлмә буйлап әйләндергәч, озак кына җиргә төшерми кысып торды.

— Борчылма, Голем,— диде ул аны күкрәгенә тагын да катырак кысып.— барысы да без дигәнчә бара... Артыгын әйтә алмыйм. Барысы да яхшыга... Әйдә, табып әзерлә. Базарга иртәрәк чыгасы булыр.

## Чакырылмаган кунаклар

Игелек эшләсәгез дә — үзегезгә,
явызлык эшләсәгез дә — үзегезгә.

Коръәннән.

Мул сулы, йөгерек елга ярындагы болында копе-төпе учаклар дөрли. Таганга асылган җиз казаннарда шулпа быгырдый, ахактай күмер өстендә ит кыза, кайнарколдә балык мәмри. Елга аръягыннан йомшак җил шомырт һәм болын чәчәкләре исен китерә, алар киндер капчыклардагы йөзем, өрек, күрәгә, исемнәрен белеп бетергесез башка җимешләрнең хуш исе белән аралашалар да баш әйләндергеч бер ымсыну, шушы муллыкка чуму теләге уяталар. Төрле-төрле телләрдә, шивәләрдә сөйләшүче базарчыларның шау-шуын күмеп дөяләр кычкыра, сыерлар мөгри, ишәкләр бакыра, атлар кешни... Бу — бөтен җиһанга билгеле атаклы Ташаяк ярминкәсе, казанлыларның мактанычы, горурлыгы.

Үткен сәүдәгәр бу базарда еллык мая туплый, малын алыштыра, бәхәсләшә, тарткалаша, сата, ала, алдый, алдана. Кулдан-кулга елга булып алтын-көмеш ага, базар ияләренең яшерен сандыкларына, капчыкларына, янчыкларына күзгә күренмәс чишмә булып саркып керә.

Киштәләрдә камка[1], җофар тиресе, гәрәбә, савыт-саба, сәхтиян читекләр, затлы бүрекләр... тәпәннәрдә сары бал, тау-тау өелгән капчыкларда бодай, тары, арпа... көтү-көтү аяклы мал... Тимерче осталарда, һөнәрчеләрдә — шам кылыч, хәнҗәр, кобә, ук-җәя, сөңге очы, түтәләре көмешләп бизәлгән мылтык, тимер баш киемнәре...

Кәрваннарның берсе килә, берсе китә. Тамгачыларга тын алырга да вакыт юк. Һәр яңа килгән кәрванның малын барлап, тиешле күләмдә салымны исәпләп, тиешен-тиешлә хан казнасына алырга кирәк. Мәйдан уртасындагы зур таш аякка[2] салым акчасы агыла. Аны күп капчыкларга шыплап тутырып, тамгалап хан сараена озата торалар.

Инде иртәнге якта ук эшен бетергән Сәеткә боларны карап йөрү рәхәтлек бирә, озын-озак кыш айларында кыбырсыган җаны ләззәт кичерә иде.

Иртәдән бирле әтисенә ияреп, ярдәмләшеп йөргән Җәгъфәргә мондый хисләр таныш түгел әле. Ул инде беренчә мәртәбә әйтеп карады:

— Әти, кайтыйк инде. Эш бетте бит...

— Ашыкма, улым! Кайтырбыз. Эшең нәрсә, битең нәрсә...

Сәетнең һәр сүзендә вәкарь, үз дәрәҗәсен белгән кешеләрнеке ча салмаклык, олылык сизелә. Әтисен мондый итеп белмәгән Җәгъфәр аптырый, аңдагы үзгәрешне күреп, сизеп тора, сәерсенә. Әмма ата кеше моны үзе белми, улының җилкәсенә кулын салып, тормыш сабагы өйрәтә-өйрәтә атлый.

— Күр, өйрән, мыегыңа чорна. Бу кәсеп сиңа каласы... Бер нәрсәне дә күзеңнән ычкындырма. Кара, хәтереңә сеңдер: кемнәр ни ала? Кемгә нәрсә кирәк? Боларны белеп тору — безнең эштә уңышка ирешүнең яртысы сере. Оста сәүдәгәр, чын базарчы беркайчан да мондый мөмкинлекне кулыннан ычкындырмас.

---

[1] Камка — чин ефәге.

[2] Аяк — савыт, ташаяк — таш савыт. Ташаяк ярминкәсе дигән сүз шуннан чыккан.

Тагын бик күп нәрсәләрне сөйлисе килә Сәетнең. Төшемле булды аңа быелгы базар. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында кайдан нинди мал килүен белеп торуы, тамгачылар күзәтүенә бәйсезлеге аркасында ул туплаган нәрсәләрен бик тиз генә табышлы итеп урнаштырды. Инде туктарга, тынычланырга да мөмкин иде. Әмма базарда көтелмәгән хәлләр туып кына тора. Берсен дә күз уңыннан ычкындырасы түгел. Нургали агага биргән вәгъдәсе, өстенә йөкләнгән йомышы да бар бит әле аның. Сәетнең ышанычны аклыйсы, үзеннән көтелгәнгә караганда да саллырак өлеш белән базарбаш катына барасы килә. Күрсен! Ышансын! Кем белә, алла боерса, киләчәктә тамганы Җәгъфәргә тапшырырга да насыйп итәр. Хәзергә аңа моны белдерергә ярамый. Яшь әле. Кавырсыны йомшаграк, күңелендә яшьлек вәсвәсәсе... Егетне өйрәтергә кирәк. Үзбаш тормыш корасы, дөнья йөген җигелеп тартасы көннәре алда...

Сәетнең уйлары чуала. Җәгъфәрнең бөтен килеш-килбәте белән Голйөземгә тартым йөзеннән бөркелгән сабырлыкны, улының басынкылыгын, тырышлыгын күреп, күңеленә тагын рәхәт булып китә. Әйе, юка күлмәге аркылы беленеп торган беләкләрендә көч сизелә, күзләрендә акыл гөемләнә малайның. Картлык көнендә таянычы, караучысы, булачак кешесе. Бәхете, тәүфигы гына булсын!..

Ата белән ул акрын гына сәүдә рәтләре арасыннан атлыйлар. Күзләре үткен, колаклары сизгер. Кайда нәрсә бар?

Әнә коралчылар янында ике кеше бәхәсләшә. Җилкәсенә төшеп торган житү чәчле, көрәктәй сакаллы, өстенә озын кара чирмеш чикмәне кигән сәүдәгәр, як-ягына каранып ала да, янәшәсендәге иптәшенә нидер пышылдый. Аннан соң алар тимерче остага нидер аңлатырга, төшендерергә тырышкандай икесе берьюлы диярлек сөйләргә тотыналар. Күрәсең, бәяне төшерергә телиләр. Әмма кире оста алдына тезеп куйган затлы коралларына кулы белән ишарәли дә баш селки. «Юк! Мондый малны бүтән беркайда да таба алмассыз», — ди кебек.

Сәет аларның сатулашуы белән кызыксынып китүен сизми дә калды. Якынрак килеп, читтән генә күзәтергә керешге, сүзләренә колак салды.

— Бөтен коралыңны тулаем алабыз. Әйдә, кул сугышыйк та бетерик!

Житү чәчленең сүзен иптәше куәтләде:

— Без биргәнне сиңа бүтән беркем дә бирмәячәк. Саф алтын белән түлибез. Бәһасе нәкъ шулай — ун алтын.

Коралчының йөзенә ачу галәмәте чыкты.

— Сез нәрсә... Корган агачка бәрелүгә яньчелә торган тимер дип белдегезме әллә? Шам корычыннан ясалган кылыч бит алар. Чәч бөртеген урталай яра...

Әйткәннәрен расларга теләп булса кирәк, ул жыерчыкларына күмер-корым сеңгән бармаклары белән чигәсеннән бер бөртек чәч йолкып алды, икенче кулындагы сояк саплы, бизәкләп эшләнгән хәнҗәрне алдына куеп, чәчне өреп төшерде. Кара төк урталай өзелеп ике якка төшеп китте.

— Күрдегезме? Мондый хәнҗәрне сез бүтән базарда мәңге таба алмыйсыз, — диде ул канәгать елмаеп. — Сере миндә монда. Башка җирдә юк. — Һәм ул үзенең маңгаена төртеп күрсәтте.

Сатулашучылар бер-берсенә мәгънәле карашып алдылар.

— Яхшы, тагын бер алтынга арттырабыз, — диде яшьрәге.

Сәүдәгәрләр татарча сөйләшсәләр дә, калын авазларны нечкәртеп, сүзләрне тырышып әйтүләреннән аларның казанлы да, чирмеш тә түгеллеген аңларга була иде. Шулай ук алар Кырым, Әстерхан иленнән дә, Сәмәрканд янсә Себердән дә түгел, ят бер кавемнән иде. Руминан да булмаслар. Алар башкачарак. Әрмәннәр түгел дә түгел. Алар кара була, олы күзле була. Боларның исә чәчләре житен сыман, чырайлары кояшта кызарып өлгерсә дә, яка турындагы муеннары агарып күренә иде.

Сәетнең йөрәге дерт итеп китте. Әллә нинди, үзе дә аңлатып бирә алмас бер сизенү белән ул аларның кай яктан икәнен чамалап алган иде. Алар белән аралашудан качарга тырыша, күп еллар элек булган вакыйгаларны күңелендә бер дә яңартырга ашкынып тормый иде. Өзелгәнне кире ялгыйсы

килми, авыр хатирәләрнең кабатлануын теләми. Үткән, беткән. Шушы Казанда Гөлйөзем белән, балалары белән тыныч кына яшәргә иде бит!.. Очрашу, аралашу җанына шик-шөбһә индерәчәк, сүндерергә тырышкан вәсвәсәле уйларны азындырачак иде.

Дулкынлануын янында гына басып торган Җәгъфәргә сиздермәскә тырышып, аны җиңеннән тартты:

— Китик, улым!

Көтмәгәндә Җәгъфәр каршы төште.

— Хәтерлисеңме, әти, балигъ булгач, сөяк саплы хәнҗәр бүләк итәрмен дигән идең. Мин менә шундыйны теләр идем,— диде ул коралчы кулындагы хәнҗәргә ишарәләп.— Тагын ун көннән миңа уналты тула...

Җаны карышса да, малаеның сүзен аяк астына салырга базмады. Әйткәне хак иде, вәгъдә биргән иде. Сүзендә тора белүе белән дә улында тугрылык, ихтирам тәрбияләргә теләгән ата буйсынмыйча булдыра алмады.

Сатулашучылар янына килделәр. Җәгъфәр коралчы оста алдындагы хәнҗәрләрдән иң затлысын — саргылт шома сөяк сабына уеп чәчәкбизәкләр төшерелгәнен, күгелҗем-зәңгәр төс белән балкыган кырычлысын алды.

— Күпме сорыйсың?— диде Сәет.

Сатулашудан, әйберләрен мактаудан аерым бер тәм таба торган коралчы җавап бирергә ашыкмады.

— Мин аларны мал рәтен белгән кешегә генә сатам,— диде ул ачулы тавыш белән.— Андый хәнҗәрне көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Уенчык түгел ул...

Күңелендә авыр хатирәләр уяткан сатулашучылар яныннан тизрәк китәргә теләгән Сәет җавап биреп тормады, кесәсеннән ике алтын чыгарып коралчыга сузды.

— Сатулашмыйк. Шушыңа ризамы?

Остаиың шатлыгы йөзенә бәреп чыкты. Ул мондый бәһагә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, сүзсез калды. «менә күрдегезме?» дигәндәй каршындагы сәүдәгәрләргә төбәлде. Шул мизгелдә Сәет тә аларга борылды һәм... житү чәчле, кара киемлесенең текәлеп үзенә каравын абайлап алды. Куе, калын кашлар астындагы яшькелт күзләр аны бораулый сыман иде. Кем диярга соң моны? Кайдадыр күргәне дә бар түгелме? Исенә төшерә алмады. Җәгъфәргә ым кагып, бу сәер сәүдәгәрләр яныннан китәргә ашыкты.

Кемнәр иде соң болар!? Әгәр таныш булсалар, нигә үзләре эндәшмәде? Чыннан да урыслармы соң алар? Гадәттә, урыс сәүдәгәрләре Казанда болгари күн эзли, сәхтиян читек, көмеш савыт-саба, алка, йөзек, беләзек ала, ашлык төятә. Ә болар коралчы янында. «Бәлки ялгышамдыр»,— дип куйды Сәет онытылырга теләп, хәнҗәр белән уйнап баручы улына карады. Ләкин тынычлана алмады. Күңелендә борын тырткан сорауларга җавап табасы килә иде.

Кинәт аның башына уй килде.

— Син, улым, кайта тор! Гарәп сәүдәгәрләрен күреп сөйләшәсем бар икән. Онытып җибәргәнмен,— диде ул һәм малаен озатырга ашыкты.

Кулына чып-чын хәнҗәр эләгү шатлыгыннан дөньясын оныткан Җәгъфәр аңы-моны сорап тормады, шәһәр капкасына таба йөгерде. Сәет исә кеше-кара күзенә бик чалынырга теләмичә, акрын гына атлап, бөтенләй икенче якка — яңадан коралчылар рәтенә таба китеп барды.

Корал — кыйммәтле мал. Аны, гадәттә, сайлап, җентекләп тикшереп алалар. Корал янында яшь-җилкенчәк, азамат ирләр кайнаша. Сәет тавышсызтынсыз гына шул төркемгә кушылды.

Коралчылар рәте каланың колач житкесез юан имән бүрәнәләрдән бурап күтәрелгән биек коймасы ягыннан Казан суына кадәр сузылган иде. Осталар башка сәүдәгәрләр шикелле кеше чакырып кычкырмыйлар, дәрәҗәләрен белеп, язгы кояшта җылынып утыра бирәләр. Базардагы һәр хәрәкәтнең, айпалу-чайпалуның мәгънәсен төшенеп алырга күнеккән Сәет ныклабрак караган, күзәткән саен мондагы яшерен җанлылыкны тоя барды. Башка вакытта хөкем сөргән сабырлык, вәкарь, тәкъвалык беткән кебек иде.

Табигый ки, моны базарга беренче тапкыр килгән кеше күрмәс-сизмәс иде. Әмма бүз бала чагыннан бөтен гомерен сату-алуда үткәргән Сәетнең үткен күзләре башкалар күрмәгәнне күрә, колагы күпне ишетә, акылы һәр чалымда мәгънә таба иде.

Әнә йомышчы малайлар әрле-бирле йөренә. Йөзләреннән балаларча гамьсезлек качкан. Әле бер, әле икенче төркем янына нидер китерәләр, алып китәләр. Тагын бер нәрсәгә игътибар итте сәүдәгәр — сатып алучылар арасында кайдан кем икәнлекләрен танытмаслык итеп тоташ карадан киенгән елгыр әдәмнәр күп. Алар артык сатулашмый, күп әйберне тулаем алалар булса кирәк, пигездә сүзне кул сугышып бетерсәләр дә, тоткан нәрсәләре күренми. Моны да аңлый Сәет — кичен аларның олауларына килешенгән тауарлар китереләчәк. Төнлә яисә таң алдыннан ул олаулар тавыш-тынсыз гына каядыр юкка чыгачак.

Бу начар фал. Коралны күпләп алучылар изгелектә йөрмәс. Хәрәмчеләрнең кайсы кавемнән икәнен тәгаенләсә дә, нинди таифәдән, нинди максат белән йөрүләрен аныклый алмый. Кемнәр алар? Идел өстеннән көймәдә, салда агучы сәүдәгәрләрне дер селкетеп тотучы елга юлбасарлары — ушкуйникларны, әллә патшаларына баш бирмәскә талпынучы берәр урыс кенәзенең кешеләреме? Әллә Казанның үзенә үк куркыныч яныймы? Дөньялар имин түгел. Казанлыларга хөсетле Шаһгали дөньяны бутап киткәннән бирле кырмыска оясыдай гөжләгән каланың тынычланып җитә алганы юк. Хәер, шөкер, соңгы вакытта Әстерхан белән дә, Кырым белән дә дуслык ныгыды. Алар артында бөек һәм изге солтанның куәтле калканы бар. Шаһгали дә борынын тыгарга батырчылык итмәс, иншалла. Тагын сәүдәгәрләр турында уйлый башлады. Боларның Казанда бистә булып яшәүче урыслар белән бер-бер бәйләнеше юкмы? Кемнәр генә булмасын, коралны күпләп алу өчен алтын-көмешне кызганмаулары хак иде.

Иң беренче теләге күргән-белгәннәрен түкми-чәчми тизрәк базарбашка җиткерү булды. Күңелендә укмашып килгән шик-шөбһәләрне аңа җиткерәсе, нинди сәер хәзерлек турында кисәтәсе иде бит! Әмма башына икенче бер уй да килде: Казаннан алып Әстерханга, Кырымга гына түгел, Чин дәүләте чикләренәчә таралган базарларда шылт иткәнне дә белеп торучы базарбаш бу хәлләрдән хәбәрдар түгелдер дисеңме?! Юк-бар шигең белән олуг кешеләрне бимазалап йөрү килешерме? Иң яхшысы Әҗем карт белән сөйләшү булыр иде дә, аны иртәдән бирле базарда очратканы юк. Әллә сырхап киткән, әллә эшне йомышчылары, ярдәмчеләре аша гына йөртә? Кем белсен, һәр базарчының малтабарның үз йоласы, үзенчә эш йөртү рәвеше бар. Ярминкәнең иң кызган чагында берничә көнгә югалып тору Әҗем карт өчен ят нәрсә түгел. Югалып торыр да, күз күрмәгән, колак ишетмәгән ят мал белән базар теленә керер.

Аптырашта калды Сәет. Белгән хәтлесен башкалар белән дә уртаклаша алмый. Сарай әһелләре аңа ят: биләр, карачылар Сәет-сәүдәгәр белән аралашырга бик атлыгып тормый. Эре халык!

Шулай да күзәтүләрен ахырынача җиткерергә карар бирде. Коралчылар рәтенең буеннан-буена ашыкмый гына узды да, гадәттә урыс сәүдәгәрләре урнаша торган якка — Болак буена төшеп китте. Монда — ашлык сәүдәсе. Казан ханлыгының туфрагы уңдырышлы. Бәрәкәтле, ашлы җирләр. Базарда арышы, бодае, тарысы, арпасы дисеңме, ногыт яисә борай дисеңме — барысы да бар. Аллаһы тәгалә мәрхәмәтле булды. Соңгы ике-өч елда явым төшем җитәрлек, яз-җәйләре вакытын белеп кенә, көттермичә генә килде, игеннәр каерылып уңды.

Ул яхшы бела: иген уңмаган, алла рәхмәтеннән чит калган илләр дә бар. Алар ашлык өчен алтынын да, көмешен дә, газиз хатынын да кызганмас. Ничәнчедер сәнәдә Болгарга хатыннарын-кызларын китереп, кол, кәнизәк итеп сатып йөргән урысларны казанлылар әле һаман да гыйбрәт итеп сөйли. Ачлык — мәрхәмәтсез, аннан да явыз нәрсә юктыр! Шөкер, казанлылар тилмерми... Аларның мондый түбәнлеккә төшкәне юк.

Болак буенда сату-алу кайнамакта. Ярдан су эченә сузылган агач басмалар икешәр батманлы капчык күтәргән йөкчеләрнең йөгерә-атлый узуыннан

сыгылып-сыгылып кала. Амбар-келәтләрдә тау-тау өелгән ашлык әкренләп көймәләргә күчә.

Көймәләр күп. Аларның икешәр-өчәр җилкән күтәргән биниһая олылары да, тар күкрәкләре белән Идел суын ярып коштай алга җилкенерлек тиз йөрешле — ишкәклеләре дә бар. Егерме-утыз колны чылбырлар белән ишкәк янына богаулаган андый көймәләрне күргә Сәетнең йөрәге дерт итеп куя:

— Аллам сакласын! — Коллыкка, әсирлеккә төшүдән дә кызганыч, үкенечле хәлне ул белми.

Үткен күзе тагын шуны абайлап өлгерде: көймәләрнең күбесе урысныкы. Ашлык җыя, корал туплый урыс. Юньлегә түгелдер!.. Аянычлы көннәр артта калды, тыныч кына, иминлектә яши башлаганнар иде түгелме соң?! Казан өстендә тагын кара болытлар куерамы әллә?

Сәет үзенең генә башы җитмәслек авыр уйлардан уфтанып куйды һәм, ичмасам, күзем күрмәсен дип, кире калага таба борылды. Аяк астындагы сукмакны да, тирә-ягында шаулашучы базарчыларны да, күк йөзендә ишелеп-ишелеп кургашын төсендәге болытлар уйнаганны да ул күрми иде. Миендә мең төрле сорау бәргәләнә. Тагын кемнәрнеңдер каны коелачак, кемнәрнеңдер яшьләре, каргышлары, аһ-зарлары белән җир тулачак. Мин нишлим?! Мин нишләргә тиеш?

Бик сорашасы, белешәсе килсә дә, урыс сәүдәгәрләре янына бара алмый иде Сәет. Алар арасында күренмәскә, аралашмаска тырышуының үзе һәм бөтен калада берничә генә кеше белгән яшерен, кемгә дә әйтә алмаслык сере бар. Күрәсең, ул үзе белән бергә каберенә дә керер.

Сәет шулай дип уйлый, шуңа ышана, шул ышаныч белән яши. Улы Җәгъфәрнең, кызы Галиянең бәгырьләренә тоз салырга, гөнаһсыз чиста җаннарына кагылырга, шик яисә үкенү уятырга теләми.

Баһадир гәүдәсе бердән кечерәеп калгандай булды, башы аска иелде. Иртәнге шатлыгының, уңышлы сәүдә сөенеченең эзе дә калмады. Шик корты кешене эчтән кимерә, күзгә күрсәтми генә бәгырен ашый, тәнен киптерә.

Каршында кинәт үсеп чыккан шәүләдән сискәнеп китте Сәет. Юлга җәелгән имән такталарның нәкъ ул барган сайгагында кара киемле сәүдәгәр басып тора иде. Коралчы белән сатулашкан яшькелт күзле кеше түгелме соң бу? Әнә ич, күзләре тагын аны бораулый, кызыксынып, җанына үтәрдәй булып чекрәйгән.

Шикләнүе йөзенә чыкты булса кирәк, кара киемле, аны тынычландырырга теләгәндәй, кулын күтәреп сак кына ишарә ясады, тавышы да шыпырт чыкты:

— Син миннән курыкма, юлбасар түгелмен, — диде ул тирә-ягына карап.

Базар белән шәһәр арасын тоташтырган җәяүлеләр сукмагында кеше-фәлән күренми иде. Кара киемле якыная төште һәм сүзен дәвам итәргә теләп авызын ачты. Сәетнең бер генә кеше белән дә сөйләшәсе, бигрәк тә үзе шикләнгән әдәмнәр белән аралашасы килми иде, бүлдерергә ашыкты:

— Минем сезнең белән бүлешер малым да, сөйләшер сүзем дә юк, — диде ул шушының белән очраклы кешедән аерылып китәргә теләвен аңлатып.

— Ашыкма... Ашыкма, — дип кабатлады яшькелт күз. — Куеньмда таш түгел. Әйтеремне тыңла да үзең хөкем чыгарырсың. Ни кылу — анысы синең кулда.

Кызыксыну шөбһәсен җиңде, Сәет тыңларга әзерләгән белдереп баш иде.

— Әйтеп кара! Тыңлыйм...

Кара киемле көтмәгәндә аның колагына пышылдады:

— Савелий Кузьмичны беләсеңме?

Сәетнең башына суктылармыни, тын алуы авырлашты, битенә, колакларына кан йөгерде, муенына хәтле тимгел-тимгел кызарып чыкты, ни әйтергә белмичә, торараштай катты да калды. «Менә, уңжиде ел үткәннән соң!» — дип уйлап куярга гына өлгерде ул. «Юк!» дияр иде, үзен тотышы.

битенә йөгергән кан аның белгәнлеген кычкырып тора. «Әйе» дияр идең, ул сүз артыннан тагын нинди хәбәрләр ишетәчәге өркетә, җанына күтәргесез таш булып баса иде. Ләкин күпме генә каушамасын, ул үзенең бу кеше янынннан тиз генә китә алмаячагын да аңлый. Савелий Кузьмич дигән бу исем аның бөтен ихтыярын богаулап куйган, аны үзенә чакыра, тарта, кара киемле артыннан теләсә кая барырга мәҗбүр итә иде. Үзе дә сизмәстән, Сәет ике ут арасында калды. Ләкин теле әйләнмәде, моннан күп еллар элек ясалган яшьлек хатасы аның телен бикли, сүз әйтергә комачаулый иде. Кыяфәтенә битарафлык чыгарырга тырышып, сүзсез генә кара киемленең йөзенә текәлде.

Шактый озак басып торгач, ниһаять, ул телгә килде:

— Кайдадыр ишеткәнем бар иде кебек...

Теле тотлыкты, бәйсез һәм җиңел генә әйтеп салырга теләгәне килеп чыкмады.

Кара киемле исә, шулай булырга тиешлеген көткән, ни булачагын алдан белгән кешедәй, артык каушау галәмәте күрсәтмәде, шулай ук йөзендә сөенү әсәре дә юк иде.

— Шулайдыр дип уйлаган идем аны,— диде ул һаман да тавышын күтәрмичә генә.— Ни булса да, минем сиңа әйтер сүзем бар. Савелий Кузьмичның гөнаһысына кермим, әйбәт әдәм иде... Йә, тыңлыйсыңмы?..

«Нигә «иде» дип сөйли? Нигә һаман сер яшерә бу?» Сәет кара киемленең сүзләреннән бөтенләй тәкатьсез калган иде, бар белгәнен тыны белән суырып алырдай булып, күзләренә текәлде.

— Кеше күзенә бергә чалынуыбыз хәерлегә булмас... һәрхәлдә, сиңа... Әнә яңгыр да яварга җыена,— диде кара киемле күк йөзенә ишарәләп.— Аулаграк җирдә сөйләшсәк, сиңа да, миңа да мәслихәтрәк булыр.

— Сон... алланың рәхмәте,— дип икеләнебрәк башлаган Сәеткә артык сүз озайтырга ирек бирмәстән, ул ышандырырлык итеп, кырыс кына берничә сүз әйтте:

— Исмәгыйль бай кәрван-сараенда! Унҗиденче бүлмә... Көтәм.— Һәм күтәрелеп тә карамыйча, ашыгып китеп барды.

«Барыргамы, бармаскамы?» Сәет икеләнеп калды. Күңел төбендә бөреләнгән шик тойгысы яңадан канат җәйде, яндыргыч авырту белән йөрәген кысып алды. «Тукта! Болар нинди мәкер белән Сәетне тозакка кертергә маташмыймы?!»

Үзе генә хәл итә алмаслык четерекле сорау сызландырып миен борауламый башлады. «Әллә соң туп-туры Нургали ага янына китәргәме? Аңлар иде, бер-бер чара күрер иде бит. Белгәннәрен үзендә яшереп калдырса, мәңге үкенеп яшәргә туры килмәсме?!» Кистереп кенә «юк!» дип чакыруны кире какмавына үртәлеп, үз-үзен белештермичә иреннәрен чәйнәргә керешге.

Хәер, шулай уйланса да, котылгысыз тоелган хәлдән чыгу юлын эзләп бәргәләнсә дә, ул үзенең ни өчен буйсыз калганлыгын яхшы белә, баш тарта алмаячагын да ачык тоемлый иде. «Уф!— дип куйды Сәет.— Бәла агач башыннан йөрми... Күрәчәгең булса...» Уйлаганының, чуалчык фикерләренең очына чыга алмады, кул селтәде дә мәҗбүри барган кеше төсле акрын гына атлап, шәһәр капкасына таба, таныш түгел кеше артыннан кузгалды.

Кәрван-сарай шәһәр капкасыннан ерак түгел. Урта кулдапрак исәпләнгән бу кунак йортына хәллерәк сәүдәгәрләрнең сирәк тукталганын белә иде Сәет. Бик үк чиста куллы булмаган кешеләрнең җыелу урыны дип тә ишеткәне бар. Уй-максатын уртага салып сөйләшергә күнеккән малтабарлар белән эш итәргә яратучы Сәетнең күңеле тартмый, аягы атларга теләми. «Шәһәр капкасы ерак түгел. Ул-бу булса... андагы сакчылар ярдәмсез калдырмас. Бер чакыру җитәр»,— дип үз-үзен тынычландырырга тырышты, аягын сөйрәп, суеымга алып барылучы мал шикелле тартылып атлады да атлады. «Савелий Кузьмич әйбәт әдәм иде»,— дигән сүзләр аны үз ирегеннән башка алга өстери иде.

Бөтен җиһан кинәт караңгылыкка чумды, әйтерсең лә кара болыт убылып җиргә төште. Юка тузан элпәсе белән капланган сайгаклар өстендә эре-

эре тамчылар биешә башлады. Тыгыз һәм куе яңгыр пәрдәсе тирә-якны томалап алды, күз күреме ераклыкта бер генә нәрсәне дә абайлап булмаслык эңгер-меңгер урнашты.

Таш капкадан ничек узганын да, кәрван-сарай ишегалдындагы шау-шу, атлар кешнәвен, хезмәтчеләрнең тыз-быз йөгерешүен, биек баскычтан күтәрелеп, гөмбәз түшәмле алгы якка ничек килеп керүен дә сизми калды Сәет. Алгы яктан өч тарафка сузылган өч тар аралыкта ут юк, кеше-кара күренми, тыштагы гарасаттан соң бар нәрсә үле тынлыкка чумган кебек иде. Кая барырга белмичә аптырап калды. Бераздан күзләре ияләшә төште, бүлмә ишекләрендәге саннарны абайларлык хәлгә килгәч, күңелендәге шомны җиңәргә тырышып алга атлады.

Унҗиденче бүлмә уртадагы бүлемтекнең иң азагында, җир астына уелып кергәндәй, тар бер аралыкка урнашкан иде. Сакланып кына ишекне этте. Калын имән такталар тавышсыз ачылды, төсле пыялалар аша саркыган сүрән яктылыкта ул әлеге дә баягы кара киемле кешене күреп алды.

— Әйдә, уз, Александр Савельич,— диде бүлмә хуҗасы карлыккан тонык тавыш белән.— Шикләнмә!— һәм туп-туры итеп күзенә карап торгач, ашыкмый гына өстәде.— Килеренне беләидем...

Сәетнең бугазына төер килеп тыгылды, тагын базардагы хәлгә кабатланды — башына кан йөгерде, үз-үзен белештермичә ишек катындагы урындыкка килеп төште.

— Син... син ялгышасың! Мин Сәет Сәлим углы,— дип пышылдады ул якасын ычкындырырга тырышып. Тавышы гыжылдауга охшап чыкты. Тынлаусыз бармаклары күлмәк сәдәфләрен таба алмый интекте.

— Исемеңне алыштырсаң да, кыяфәтеңне алыштыра алмагансың, Санька! Мин таныдым сине... Ә син... хәтерлисеңме?..

Кара киемле кеше артык тыныч иде. Аның бу тынычлыгы акрынлап Сәеткә дә күчә башлады, беренчи куркыныч янамавын тоемлап, сәүдәгәр үз-үзен кулга алды һәм, иплән кенә бөтенесен дә ачыкларга дип, күңеленә беркетеп куйды.

— Йә, шулай да булсын ди. Сузмыйк. Сиңа миннән ни кирәк?— диде ул битараф күренергә тырышып.

— Берни дә кирәкми, Санька,— диде кара киемле.— Ни өчен үзеңне танытмаска тырышуыңның сәбәбен белмим, нишләп исемеңне-җисемеңне алыштыргансыңдыр — анысы да миңа мәгълүм түгел. Гөнаһыңа кермим. Теләмисең икән, сөйләмә...

Урыс сәүдәгәре сөйләвеннән туктап калды һәм кулларын артка куеп, ишекле-түрле йөренергә тотынды. Аның дагалы итекләре шыгырдый, авыр гәүдәсеннән идән сайгаклары сыгылып-сыгылып кала иде.

— Әйе, миңа синнән берни дә кирәкми,— дип кабатлады ул Сәет янына ук килеп.— Әмма әтиеңә биргән сүзем бар, васыятен үтәми калып, гомер буе күңелемдә гөнаһ ташы йөртәсем юк.

Сәет аның күкрәгенә ишелеп төшкән куе кара сакалына, ток баскан зур битенә, яшькелт күзләренә күтәрелеп карады һәм кинәт эчендә еллар буе хәтерен бәйләп торган ниндидер җеп шартлап өзелгәндәй булды.

— Син... син Иван дәдәй түгелме соң?— дип пышылдады ул үз-үзен белештермичә. Бите чин кәгазедәй агарып калды, бармаклары дерелди башлады.

Кара киемленең исә битендә бер төге дә селкенмәде, ул Сәетнең күзләренә текәлгән һәм моңнан унҗиде ел элек Идел дулкыннары кочагында югалган серне белергә теләгәндәй, бәгыренә үтәрдәй булып бораулый иде.

Авыр тынлыкны күтәрә алмады Сәет, күзләрен читкә күчерде, карашы бүлмә эчендәге җиһазлардан, түшәм, тәрәзә буйларыннан йөгереп узды. Мие котырынып эшли башлады. Очраклы рәвештә генә аның кемлеген, нинди юлда йөргәнлеген, вөҗүде шапшаклыгын белгән, сизенгән иде. Бу кеше теләсә нинди мәкерне дә калтыранмыйча эшли алачак иде. «Әгәр ишеккә ташлансам»,— дигән уй чагылып үтте. Ләкин кара киемленең бер кулы билендәге хәнҗәренә таянган, ул тын да алмый Сәетнең ни әйтерен көтеп то-

ра. Сәет уеннан кире кайтырга мәҗбүр булды. Көч ягыннан аңа бирешмәслеген белсә дә, мәсьәләне ничек тә тыныч хәл итәргә кирәк, серле тамга иясенең базар башбаштаклыгында катнашырга хакы юк. Чигенер юл юк иде. Бөтен кәрван-сарай кара киемле урыс кешеләре белән мыжлап тора. Моннан чыгып китә алса да, караңгы борылышларның берсендә аркасына пычак килеп кадалмаячагын беркем дә әйтә алмый. Үзенең хәле белән килешергә мәҗбүр Сәет, ашыкмыйча гына әңгәмәне дәвам иттерергә булды. «Инде буласы булган, кайчан да бер кылган җинаятең өчен җавап бирергә дә кирәктер. Хәер, җинаятьме соң ул?! Котылгысыз бер яшьлек шаяруы гына түгел идеме? Иван сәүдәгәрнең үз өстендә тагын да пычраграк җинаятьләр бар түгелме?» Уйларының очына чыга алмады. «Һәр әдәм баласы үзе өчен үзе җавап бирергә тиеш. Иваннан да сорарлар әле ул әҗерне...»

— Мин китергән зыянымны уны белән каплый алам. Бәхилләтермен. Дөнья булгач, төрле хәлләр була тора. Тау белән тау гына очрашмый. Әдәми зат юллары исә бер аллага гына мәгълүм,— диде ул, ниһаять, сабырлыгын, батырлыгын җыеп.

Кара киемле җиңел сулап куйды.

— Таныдың! Миһербаның бетмәгән икән әле,— диде ул читкәрәк китеп.— Әйдә, түрдән уз. Бабайлар әйтмешли, аяк өстендә хакыйкатьне ачыклап булмый.— Канәгать кыяфәт белән кулларын угалагач, тагын өстәп куйды:— Мин синнән акча юллап килмәдем. Түләргә теләсәң, гаебеңне йолар өчен башка юллар да бар... Сөйләшербез...

Сәет өстәл янына күчеп утырды. Кара киемле кемнедер көтә идеме, әллә кемнән дә булса шикләнә идеме — ишек янында колак салып тыңланып торгач кына, аның каршында урын алды.

— Әйе, мин синнән акча юллап килмәдем,— дип кабатлады ул тагын бер мәртәбә.— Үткән эшкә салават. Шулай бит... Әтиең мәрхүмнең теләге шундый иде...

— Ә ул кайчан... ничек? — Сәетнең күзләренә яшь тыгылды, әмма үзенең хәләтен Иван сәүдәгәргә сиздерәсе килми, бөтен түземен җыеп, бәгыреннән күтәрелеп килүче ачы дулкынны тыярга тырыша, тышына чыгармый иде.

— Анысын да ишетерсең... Иң элек атаң васыятен үтим. Үлгәндә дә синең Иделгә батуыңа ышанмады ул. Һаман көтте, кешеләргә белдерми генә, аһ-зарсыз, кан яшьсез генә елады. Көтте. Әйе, синең үлемеңә ышанмады, нидер сизенеп яшәде. Васыяте дә шул: кайда да булса, кайчан да булса юлларыгыз очрашса, төпчегемә, улыма, Санькага ярдәм ит, туры юлга чыгар, мәрхәмәтеңнән ташлама, диде. Алдангандыр ул, күзен ач, диде.— Иван сәүдәгәр авыр сулап куйды, бу хатирәләрдә казыну аның үзенә дә җиңел түгел идеме, кулы белән авызын каплап йөткереп куйгач, тагын дәвам итте:— Синең монда ничек килеп эләгүең, ничек яшәвең миңа караңгы. Әмма күрәм, яхшы ук дәрәҗәле, маллы, хәлле кеше булгансың. Кыяфәтең дә бернекечә түгел,— диде ул Сәетнең өстендәге Казанча киемнәргә, мөселманча калдырылган сакал-мыегына ишарәләп.— Ата-баба юлыннан читкә тайпылгансың... Әмма аларда минем эшем юк. Аларын... үзегез хәл итәрсез...

«Кем белән хәл итәрбез. Кем ул тагын?» — дип сорамакчы булган Сәетне күз карашы белән генә туктатты һәм иелә төшеп, як-ягына карангалап, пышылдарга кереште:

— Сер сыйдырыр кешеме син? Бу сүзләрнең моннан беркая да чыкмаячагына ант итәсеңме? Артыгын сорашмаячаксыңмы?.. Ант ит! Итәсеңме?..

Иван сәүдәгәрнең серне акрынлап-акрынлап кына, җанын суыргандай газаплап, әйтеп бетермичә чыгаруыннан үртәлгән Сәет ни эшләргә белми иде. Әтисе, туганнары, әнисе хакында ишетәсе килү, моннан унҗиде ел элек өзеп ташланган җепне ничек тә булса ялгап карау теләге аның ихтыярын сындыра иде.

— Ант, ант, ант,— дип кабатлады ул үзе өчен әле һаман сер булып калган кара киемленең сүзләреннән сихерләнгәндәй.

— Алайсаң, тыңла! Кыяфәтең үзгәрсә дә, тәнеңдә безнең кан — урыс каны агадыр. Онытма! Кем булсаң да, киңәшемне тот: Казанга олы афәт

яный. Үзең генә китәсеңме, балаларыңны, хатыныңны аласыңмы — анысы синең эш. Әмма исән калыйм дисәң, якты дөньяда яшим дисәң, сузма, кит Мәскәү илenә кайтасыңмы, башка берәр якка чыгып югаласыңмы — әйтә алмыйм. Бер нәрсәне төгәл беләм, Казан өстенә моңарчы булмаганча афәт килә, кан-яшь килә. Шәһәрегезнең ташын ташка, агачын агачка актарып ташларлык көч килә. Күк йөзен канлы болыт каплар. Исәпне өзәр чак җитте. Башкасын әйтә алмыйм, сорама да, төпченмә дә. Телем йозакта. Хыянәткә кереп җанымны пычратасым килми...

Кара киемле изүеннән көмеш тәре чыгарды, аны үбеп чукынып куйды һәм үзалдына пышылдады:

— Савелий Кузьмичка биргән вәгъдәм үтәлде. Җаным тынычланды. Йа ходаем, үзең сакла, дошманнарның күзен капла, күңелемдәге тәшвишне алып ташла. Үлгәннәр алдындагы бурычымнан азат ит! О мәрхәмәтле Иисусе Христосе...

Сәетнең күңелендәге шом, караңгы уйлар таралмады гына түгел, тагын да куерып, каты таш булып бәгыренә ятты, авырттырып йөрәген кыса башлады. Ант белән телен бәйләп куйган бу әдәмнән башкасын сорашып та, белешеп тә булмый иде инде. Китәргә җыенып урыныннан күтәрелде.

— Өстемнән авыр йөк төште,— диде кара киемле җиңел сулап һәм Сәетнең китәргә җыенуын, аптыраулы карашын күреп, янәдән утырырга ишарә ясады. — Аз гына сабыр ит! Хәзер... күрерсең! Мин комачауламыйм...— һәм каударланып, үзеннән һич көтелмәгән җитезлек белән чыгып та китте.

Шактый озак утырды Сәет. Тәсле пыяла аша бүлмәгә кичке эңгер керде, ерактан дөяләр бакыруы, базардан кайтучыларның чыр-чу килеп сөйләшүе, бер-берсенә кычкырып эндәшүләре ишетелде. «Әллә ташлап китәргәме?» — дип уктала да, серле җепләр белән бәйләнгән, ант сүзе белән үзен шушы әдәмгә беркетеп куйганлыктан, бер карарга да килә алмады, бер ноктага текәлеп утыруын белде. «Тагын ниләр булыр? Язмыш аңа тагын нинди сынаулар әзерли? Иван сәүдәгәрнең сүзләре чынмы? Чын булса, миңа нишләргә?»

Шартлап ишек ачылды. Сискәнеп башын күтәргән Сәет ишек катындагы кешене күреп, кычкырып җибәрүен сизми дә калды.

— Васька!.. Синме бу...

— Санька! Брат ты мой непутевый...

Берничә мизгелдән бер-берсенә бер тамчы судай охшаш, баһадир гәүдәле бу кешеләр үз-үзләрен белештермичә кочаклашалар, аркаларына шап-шоп бәрешәләр иде.

— Чынлап та синме соң бу, Санька, Санек?

— Мин булмый кем булсын, Василий. Ә бу синме соң?!

Васька бераз читкәрәк китеп карап тора да тагын Сәетне кочагына ала, туктаусыз сөйләнә:

— Их, Санька, Санька!.. Батып үлгән кеше идең бит... Ә син!..

Туганнар соешеп туймастай булып, күзләре талганчы бер-берсенә карашып тордылар. Ниһаять, Васька күрешү хисләреннән беренче булып айныды булса кирәк, бармагын шартлатып куйды.

— Нигә болай шаккатышып торабыз соң әле!.. Таң атканчы төн безнеке... Әй, йомышчы!

Ул ишеккә тибеп җибәрде һәм караңгылыкка кычкырды:

— Йомышчы! Кадалып киттеңме әллә! Кайда йөрисең?

Кесәсеннән чакма чыгарып оч ялъле бакыр шәмдәлгә ут элдерде һәм тиз арада хезмәтчеләрдән кемнең дә булса керүенә тәкате бетеп, бәреләсугыла чыгып та китте. Бераздан аның балкыган йөзе күренде.

Өстәлгә ак керәчтән эшләнгән савытлар белән төрле тәм-том кереп утырды, олы җамаяктагы пешкән иттән борыннарны кытыклап хуш ис таралды. Василийның бер бармак шартлатуыннан ни әйтергә теләвен аңлаган йомышчы малай нечкә борынлы озынча балчык кувшиннар кертеп утыртты.

Ширбәт, кымыз, ачы балдан гайре эчемлек татып карамаган, ислам канунңары кушканча яшәргә гадәтләнгән Сәет ул савытларда шәраб ките-

релгәнлегең бик яхшы белә иде. Кәрван-сарайда Румнан, Урыс иленнән, Әрмәнстаннан килүчеләр өчен шәраб та тотылуы беркемнән дә сер түгел. Һәркемнең үз юласы. Казанлылар чит-ятларның гореф-гадәтенә тыкшынмый. Әмма эчәсе, үзен исерткеч белән ярсытасы килми иде Сәетнең. Шулай да каршы төшүне яхшысынмады. Уналты ел бер болыннарда аунап, бер чишмә суын эчеп, бер ятакта тәгәрәп үскән газиз туганының бер генә теләгенә дә каршы килә алмый иде ул.

Өстәл янына утырыштылар. Василий касәләргә нечкә кувшиннан эчемлек койды. Туганнарның берсе почмакка борылып чукынып алды, икенчесе авыз эченнән генә: «Бисмиллаһ ир-рахман-ир-рахим», — дип пышылдады. Аның нидер укынганын күреп, Васяның күзләре сәер ялтырап алды, тик ул аны сиздермәде, энесен хуплагандай баш селкеп, эчемлекне авызына койды. Сәетнең сынагасы килми иде, ул да абыйсының хәрәкәтен кабатлады. Бераздан тәне җылынып китте, башы әйләнеп киткәндәй сәер җиңеллек гәүдәсен төреп алды. Ничә еллар күрешмәгәненә, кош теле хәтле генә хәбәр җибәреп карт атасын, анасын, туганнарын тынычландыра алмавына үкенү хисе каядыр очты, рәхәт булып, күңелле булып калды. «Ә исеңдәме? Хәтерлисеңме?..» — дип бер-берсен бүлдерә-бүлдерә истәлекләр дөньясына чумдылар.

Таш диварларда шәм яктысы уйный. Көндезге мәшәкатьтән, шау-шудан соң кәрван-сарай төнге тынлыкка чумган. Ә ике туганның күзенә йокы кермн. Сөйләшәсе сүзләр исәпсез, аңлашасы, озак еллар каңгырап яшәгәннән соң яңадан туганлашасы бар.

Балчык кувшиннардагы шәраб кимегән саен, Василийның күзләре ныграк елтырый, сүзләре кими. Менә ул иң кисәргә дип алган пычагына карап уйга чумды һәм каш астыннан Сәеткә текәлде. Карашы авыр, томанлы иде. Кинәт ул бөтен ачуын чыгарырга теләгәндәй кизәнеп, пычакны өстәлгә кадады.

Чыңлап калган пычак йөзендә ут шәүләләре биеште.

— Син... синең аркада китте батя якты дөньядан. Югалуыңны күтәрә алмады, — диде ул ыңгырашып. — Соңгы сулышынача сине көтте. Ышанмады ул синең үлгәнеңә... Хыянәтеңә ышанмады...

Сәетнең тыны кысылды.

— Хыянәт?! Нинди хыянәт? Кемгә? Авызыңны үлчәп ач, туганкаем! Кайда утырганыңны онытма! — Эчемлектән каны уйный башлаган Сәет күне буе күңелендә җыелып килгән шом, ачу, үрталу, әрнүне бер тында чыгарды да салды. — Кемгә хыянәт? Синамы? Батягамы? Кемгә зарар салганым бар?!

Аның олы йодрыгы дыңк итеп өстәлгә килеп төште. Мөлдерәмә тулы касәләр сикереште, чайпалып түгелгән куе кызыл шәраб өстәл кырыеннан, кан тамчыларын хәтерләтеп, идәнгә тама башлады.

Бүлмәдә үле тынлык урнашты. Хәтта тамчыларның идәнгә төшеп бәрелүенә хәтле аермачык булып ишетелә башлады.

— Тып-тып-тып...

Тынлыкны олкән туган бүлде. Аның алара башлаган күзләренә яңадан элеккеге нур кайтты, энесенең каты сүзе, өстәл тактасын сындырырлык итеп китереп сугуы бердән айнытып җибәрде. Тыныч, әмма бәгыренә үткәрергә теләгәндәй катылык белән, һәр сүзен теш арасыннан чыгарып әйтеп куйды:

— Син безнең белән китәсең. Юкса...

— Нәрсә юкса? Куркытасыңмы? — Сәет кычкыруга күчкәнен сизми дә калды. — Кая китим? Ник китәргә тиеш ди мин? Оям монда, хатыным, балаларым монда... Мин — Казан кешесе. Казан җире минем өчен газиз туфрак, газиз ил-йорт...

— Ә Углич? Ул синең өчен читме? Анаң сөтен имгән йорт хәзер ят булдымы? Оятыңа көч килер...

— Мин алай димәдем. Каршы куйма!

— Ә мин каршы куям. Мин куймасам, аны тормыш үзе куя, — дип ярсыды Василий. — Акылыңа кил!

Әле күптән түгел генә кочаклашып үбешкән, араларыннан җил дә үтмәслек тоелган туганнарны алыштырып куйдылар диярсең, берсен-берсе

бүлдерә-бүлдерә бәхәсләшергә тотындылар, битләре кызарып чыкты, күзләрен кан басты.

— Һәрнәрсәнең киресе бар,— дип кычкырды абый кеше пычагына тотынып.— Мыегыңа чорна. Моңарчы кермәгән икән, хәзер миеңә сеңсен. Утка — су, көнгә — төн, җиргә — күк... Урыс дигәч — татар бар, татар барда хәтәр бар.

— Көн төнгә комачауламый, җир белән күк аерылгысыз...

— Ә ут суга комачауламыймы? Алар да аерылгысызмы?

— Таяк белән бармакны чагыштырма. Утсыз йә сусыз яшәп кара! Кайсысы кирәгрәк? Үзең дә әйтә алмыйсың ич,— дип каршы төште Сәет.

Аның: «Мин Казанда яшәгәннән ни була? Табышканбыз икән, инде бергә-бергә аралашып яшик, ярдәмләшик. Казанда минем сүзем үтсә, Угличта синеке... Ачуланышмыйк. Безгә ни җитми?»— диясе килә. Әмма Василийның менә-менә күкерттәй кабынып китәргә әзерлегенен күрү, ярсып пычагына ябышуы зиһенен чуалта, теленә ачулы сүзләр килә дә керә:

— Татар белән бүлешмәгән нәрсәң бар? Нигә Казанга каныгасың? Җитте сиңа!

— Юк инде. Җитмәде. Аңлатып бир миңа: урыска туган булгач, нигә унҗиде ел буе качып яшәдең? Кемнән курыктың? Газиз атаңа, күкрәк сөтен имезеп үстергән анаңа хәбәр бирмәслек дәрәҗәдә нәрсәдән өректең? Әллә өркеттеләрме?

Василийның соңгы сүзләре Сәетне телсез калдырды. Ул мондый җавапка, мондый борылышка әзер түгел иде. Асыл сәбәпләрен аңлату өчен көннәр генә түгел, бәлки айлар да җитмәс. Каны уйнаган үгездәй өстенә ташланырга әзер туганына ни әйтергә? Доньяда туганлык хисеннән дә көчлерәк башка бер хисләр барлыгын ничек төшендерергә? Әллә үзе дә ялгышканмы?! Бер йөрәккә ата-ана мәхәббәте белән янәшә башка мәхәббәт тә, тугрылык та сыймас идемени? Кызган башында кайнаган уйларының берсенә дә җавап таба алмады. Хәер, ул әлек тә бу турыда баш вата, әмма очына чыга алмый кул селтәргә мәҗбүр була иде. Ул үзен хыянәт иткән дип санамый, әмма бик үк туры юлда булмаганлыгын да белә. Дөрес, мал белән, акча белән, кемнеңдер мөлкәте белән эш иткәндә гадел куллы, туры сүзле булды, хәрамга бармады. Кайда юлдан язды соң ул, кайда ялгышты? Әллә соң болар берсе дә ялгыш түгел, ә Василий үзе ялгышамы? Тәмам чуалып беткән Сәет эчендәге утка чыдый алмый ыңгырашып куюын сизми дә калды, тешләрен кысып, килешергә теләгәнен белдерде:

— Сөйләшмик бу турыда, Вася. Җитәр! Бүлешмик инде. Әйдә, касәләрне тутыр да... Газиз әткәбезне искә алыйк...

Василий күтәрелеп бәрелде:

— Әһә, хәзер исеңә төштеме?..

Ул сикереп торып хөҗрә буйлап урап килде дә Сәетнең күзләренә текәлде, аңлатырга, төшендерергә теләп сөйли башлады:

— Менә бүлешмәгән нәрсәң бар дисең. Ә син уйла, наданлыгыңа барма. Күзеңне ач! Үҗәтлек яхшылыкка илтми. Мин ханнар, кенәзләр тормышына катышмыйм, шулай да беләм. Татар ханы Олуг Мөхәммәт Мәскәүне таламадымы? Тагын Устюг каласын, Муромны, Владимирны кем басты? Казанлылар... Тагын саныйммы? Җиттеме?!

— Санама! Мин дә синнән ким белмим. Тиеш ясакларын түләсәләр, басмаслар иде. Без дә... казанлылар да саный алабыз. Теләсәң, мин ераграктан да башлый алам. Аннан алдарак кына бер сәбәпсез Болгарны, Казанны, Җүкәтауны, Кирмәнчекне кем харап итте? Илһам ханны, аның анасы Суфияны кем әсирлектә чеpeттe? Шул ук елны Казанга тагын кем җәфа алып килде, халкын канга батырды?.. Урысның ун явына татар бер таңкыр җавап биреп килмәдеме? Бер булды, берәгәйле булды. Сүз юк. Син үзең, йә, ни зыян күрдең казанлылардан? Йә, әйт... Әле хәзер дә Казан пайтәхетендә кунак булып утырасың түгелме?

— Җитте! —Василий ярсып, өстәл сугып кычкырып җибәрде.— Үзеңне «Без — казанлылар» дип сөйлисең икән. Сатылуың җиткән. Татар белән каберең якын булмасын! Мин сиңа туган түгел. Урыс татарга туган булмый.

— Ашыкма! Кенәзегез Иоанн Васильевичның әнкәсе Елена үзе дә татар нәселеннән дип сөйлиләр... Глинскийларның Мамайлардан чыкканын гына беләсеңдер. Шул сөйрәлчекнең көчеге...

Василий әйтеп бетерергә ирек бирмәде. Сәетнең бугазына ябышты.

— Патша хәзрәтләренә тел тигертмәм...

Сәет торып басты, бөтен гәүдәсе белән киерелеп селтәнде. Мондый елгырлык көтмәгән абзасы лапылдап хөҗрә почмагына барып төште.

— Үтерәм, кабахәт! Сатлык...

Пәһлевандай көчле ике олы гәүдә идәндә бәргәләнә башлады. Алар тәгәрәп китәләр, бер-берсенең өстенә чыгарга тырышып, таяныр урын эзлиләр. Әмма шәраб аккан идән шома, аяк-куллары таеп-таеп китә иде. Көчләре бер чамадарак булгангамы, берсе дә җиңә алмый озак тартыштылар. Менә Василийның аягы диварга килеп тәрәлде. Ул бер селтәнү белән гәүдәсен өскә ыргытып, чалкан төшкән Сәеткә менеп атланды, шәрабка манылган кулы белән билендәге хәнҗәрне суырып чыгарды.

Сәетнең бугазына ялтырап торган очлы тимер килеп терәлде. Аз гына каршылык күрсәтсә дә, хәнҗәрнең муенына килеп керәчәген аңлап, ул хәрәкәтсез калды. Абзасы гыж-гыж мышнады, аның кан баскан күзләреннән шәфкать, кызгану көтәрлек түгел иде. Менә очлы тимер кысканнан-кыса, авырттырып тәнгә керә бара. Бөтен дөнья кинәттән тарайды, күк йөзе, җирсулар, елгалар-күлләр, Казан каласы, Углич, ерактагы Мәскәү — барысы да гузан бөртегедәй кечерәеп, шушы хәнҗәр очына сыеп бетте сыман.

— Иә, әйт... кем сөйрәлчек?.. Кем көчек? Күпмегә сса-тыл-ды-ы-ың?..

Борынына абзасының авызыннан шәраб, сарымсак исе килеп бәрелде, аны укшытып җибәрде. Гәүдәсе таш булып катты, ул теленә әйләндереп бер сүз әйтә алмаячагын, ялынмаячагын, ялвармаячагын да белә. «Мәхәббәтем хыянәт дип санала икән, яшәвемнең кемгә кирәге бар?» Баш сөяген тишеп чыккандай авырттырып шундый уй чагылып узды. Икенче мизгелдә Гөлйөземне, улы Җәгъфәрне, кызы Галияне күз алдына китерде, тешләрен кысып «уф!» дип куюын сизми дә калды. Алар хакына яшәргә, өстә албастыдай баскан Васяны селтәп атарлык көч табарга кирәк иде. Кирәк иде!

Кинәт бүлмә ишеге ачылды, бер-берсенең күзенә керердәй булып бәреккән ике гәүдә янына озын кара шәүлә сикерде. Очкан шапкә ул Василийның кулына тибеп җибәрде, пычак атылып китте һәм ике бертуганны айныткан, түр башындагы тәрәзә пыяласын челпәрәмә китерде. Шул ук мизгелдә көчле куллар Василийны идәннән суырып торгызды.

— Нәрсә бүлешә алмадыгыз? Шушылай аңлашырга идемени? — диде ул ачу белән. — Сагынуыгыз шундыймыни?!

Василийны бер якка этеп, ул кулын Сәеткә сузды.

— Тор! Туган кулыннан үлүдән дә яман нәрсә юк. Аллам сакласын!..

Кулларының, гәүдәсенең калтыравын басарга, җанында кайнаган ачуны сүндерергә тырышкан Сәет еш-еш сулый-сулый аның кулын читкә этте һәм идәннән күтәрелде. Каршысында Иван сәүдәгәр басып тора иде.

Коткаручы аларга күтәрелеп тә карамыйча өстәл янына килде, кувшинның авызыннан берничә йотым ясагач, туганнарны табын янына чакырды.

— Иә, җитте сезгә, көзге әтәчләр. Бүлешәсе малыгыз юк. Туганлашу хакына берне җибәрәсез дә... Аннан күземә күренмәгез!

Василий белән Сәет бер-берсенең күзләренә карамаска тырышып, кулларына көчләп тоттырылган касәләрне чәкештерми генә эчеп куйдылар. Василийның куллары калтырый иде, кызыл шәраб сакалы буйлап агып төште. Кинәт ул савытын кизәнеп идәнгә бәрде һәм илереп Сәетнең күкрәгенә ташланды, кочаклап үбәргә кереште.

— Кичер, туганым! Шайтан бутады. Энем кадәр энемне үз кулым белән һәлак итә яздым... Ки-че-е-ер!

Әле генә җан ачуы белән изәргә, сытарга, юк итәргә теләгән абзасының халәте Сәеткә дә күчте шикелле, күңеле йомшады. Иреннәре исә:

— Без бит бер каннан... Без бит туганнар, — дип кабатлый иде.

Сәетне озатырга Иван үзе чыкты. Кәрван-сарай капкасы янында туктап, як-ягына карангач, иелеп колагына пышылдады:

— Монда күргәннәреңне оныт! Бу юлы түләү башкача булыр. Колагыңа киртлә, келәтеңдәге бар малны чыгарып салсаң салырсың, без әйткәнне эшләрсең... Дары, корал... барысы да синең кулга күчә барсын! Ал, яшер! Акчаңны кызганма. Урыс патшасы игелек күрсәткәннәргә мәрхәмәтле... Казанның дары базлары кайда, белеш, барысын да хәтереңә сеңдер. Гаскәрләре күпме? Кайдан ярдәм килү ихтималы бар... Озакламый болар безгә кирәк булачак. Ә инде ханның якыннарына, ясавылларга серне тишсәң, синең белән менә бу сөйләшер.— Иванның кулында үткен хәнҗәр күренде.— Үзең булмасаң, углыңның йөрәгенә кадалыр. Күрдек. Кем икәнен беләбез. Табарбыз!

Чыкканнан бирле иреннән кысып килгән Сәетнең тез буыннары калтырап китте. Башында мең төрле уй бәргәләнде. «Менә куркыныч кайдан яный икән. Шигем дөрес булган...»

Аның дәшмәвен Иван ризалык билгесе дип кабул итте булса кирәк, аркасыннан какты.

— Бар! Без әле очрашырбыз... Ә абыеңа үпкәләмә. Дуамал, кайнар булса да, әйбәт, тугрылыклы кеше...

Төнге урамда аның аяк тавышлары гына яңгырап калды.

Башта Казаннан китәргә кыстаган, дус булып, әтисе васыятен үтәргә килгән киң күңелле, изге булып күренгән, соңыннан иң кадерлесенә — улына үлем белән янап, хыянәткә этәрүче кеше Сәетне ботенләй сәерсендерде. Авыр уйларына бирелеп акрын гына атлый бирде. Кинәт зиһене ачылып китте: Иван — сәүдәгәр түгел. Әтисе белән йөргән чакларда да янчык тулы алтыны-көмеше булган бу кеше базар тирәсендә артык чуалмый иде. Димәк, элек тә ниндидер яшерен йомышы, үзе генә белгән эше булган. Кем ул? Бу соравына җавап таба алмаса да, Василий белән күрешкән-сөйләшкәндә аның кайдандыр тыңлап, ишетеп торуын аңлады. Шулай булмаса, иң хәтәр мизгелдә килеп керер идеме?! Сәет үлде ни дә, үлмәде ни — аңа барыбер түгел идемени? Ә Сәет аңа кирәк булган, хәзер дә кирәк. Ул ниндидер мәкерле теләкләрен тормышка ашыруда аңа өмет баглый, ярдәм итәр дип ышана.

Баштан ук үзенә мөрәҗәгать итмәвенең сәбәбе дә аңлашылды Сәеткә. Вася житкерер дип өметләнгән. Абыйсы ул көткәнчә салкын кан белән, туганнарча сөйләшәсе урында дуамалланып пычакка ябышты, ботен эшне харап итеп ташлый язды. Менә шунда инде Иванның үзенә катнашудан башка чара калмагандыр. Ни кайнар Вася, ул килеп керүгә, чүпрәккә әйләнде дә калды. Юкка түгел бу! Иван сәүдәгәр артында ниндидер үтә дә көчле, мәкерле, максатына ирешү юлында берниндидер җирәнгеч үтерүдән дә курыкмый торган дәһшәтле көчләр тора.

Сәетнең аркасы чымырдап китте. Кара киемлеләр фикер сөрешенә төшенү бер яктан сөендерсә, саклану чаралары күрү мөмкинлеген ачса, икенче яктан шомландыра, куркыта, канын катыра иде. «Мондый кеше бернәрсә алдында да тукталып калмас. Бертуганнар арасында уч, мәкер ялкыны дөрләтә алган әдәм, һичшиксез, азау ярган җаһиллардан. Бер гонаһсыз сабый каны коелганда да аның кулы калтырамас, җаны тетрәмәс!»

Бар дөньясы бер кон эчендә асты-өскә килгән Сәет кайтып житүен сизми дә калды. Тынлаусызга әйләнгән бармаклары озак капшанды, ишекне ача алмый интекте. Башка вакытта ул кайтмыйча ябылмаган ишек бу юлы эчтән бикле иде. Менә йомшак аяк тавышлары. Голйөземнең сакланып кына эндәшкәне ишетелде:

— Сәет, синме?

— Мин... мин. Ач,— диде Сәет. Тавышы үзенеке түгел иде.

Келә шалтырады, шәм яктысында хатынының агарынган йөзе күренде, күзләре зур булып ачылды.

— Ни булды? Кемнәр нишләтте сине?— дип пышылдады ул куркынып. Кулыннан шәме төшеп китте. Алгы якны куе караңгылык басты.

Үз кайгыларына чумган ир белән хатын урамның каршы ягында катып калган сыңар шәүләне, аның һәр сүзләрен йотып баруын күрмиләр, бу турыда башларына да китермиләр иде, әлбәттә.

— Борчылма... Берни дә булмады.— Сәет Гөлйөземне тынычландырырга ашыкты.— Керик. Эшем күп булды... тоткарландым...

Гөлйөзем икенче шәм алып чыкты һәм иренең куе кызыл шәрабка буялган киемнәренә, тузгыган кыяфәтенә карап, тораташтай катып калды, илереп кычкырып җибәрде:

— Кан!.. Муеныңда яра... Бәгърем, ни булды?..

Көне буе үзен тыеп, ачуын, шиген җыеп, тешен кысып түзгән Сәет җикереп куюын сизми дә калды:

— Җитте диләр сиңа! Әйттем бит, соңыннан... соңыннан!..

Унҗиде ел бер тән, бер җан булып яшәгән бербөтен икегә бүленде, араларына беренче тапкыр кара күләгә ятты.

Төн. Бизәкле келәмнәр, укалы шәмаилләр белән бизәлгән, идәненә болгар паласлары җәелгән зиннәтле бүлмәдә шомлы тынлык. Көмеш шәмдәлдәге ялгыз шәм ялкыны намазлык өстендәге ак шәүлә хәрәкәтеннән тирбәлеп-тирбәлеп куя, диварларда күләгә булып бии.

Кеше илаһи затлар белән сөйләшә, үзенә ярлыкау сорый, мәрхәмәтле күк иярәреннән ярдәм көтә.

— Йә, аллам, кылган гонаһларымны кичер. Кодрәтең илә юктан бар иткән, тәнебезгә җан өргән, күзебезне ачкан, җаныбызга иман иңдергәнсең... Инде дә рәхмәтеңнән ташлама! Бәнем гонаһларымда хәләл җефетемнең, газиз углым илә кызымның кәррә катнашы, гаебе юктыр. Алар хакына булса да гаебемне кичер. Аларны сакла! Күземне ач! Инде ни кылыйм? Ике ут арасында калып көлгә әйләнимме? Телләре, диннәре төрле булса да, бер аллаһы тәгаләгә табынучы, Гайса пәйгамбәр илә Мөхәммәд рәсулуллаһы юлыннан син боеккә согынучы колларыңның зиһеннәрен ач, җан кыяр коралларын юк ит. Җаннарына мәрхәмәт, шәфкать иңдер... Йә, аллам, бәндәләреңә туры юл күрсәт!

Сәҗдәгә китеп, бөтен уен-зиһенен туплап, бәгырен телгәләгән ялваруларын күккә иңдерергә тырышты Сәет. «Диннәр, табыну-ышану төрле булса да, аллаһы тәгалә бердер, шәриге вә тиңдәше юктыр. Кем белә, бәлки аңа башкача да мөрәҗәгать итеп карарга дыр?..»

Ул бүлмә буйлап йөренеп килде, намазлыкны төреп, читкә алып куйгач, нишләргә белмәгәндәй, башын тотып бик озак уйланып утырды һәм тәвәккәлләде. Яшерен эшләнгән эш башкарган кебек як-ягына каранып алды һәм түр почмакка барып тезләнде, иреннәре ашыгып-ашыгып дога сүзләрен кабатларга кереште:

— О боже, знаю о тебе, яко милостив еси и праведен; не на лице зриши человеком, но и правды сердца их испытуеши. Виждь ныне скорбь и беду, и помози нам, рабам твоим, будь нам истинный судья, и суди в правду меж братьями, ослепленными враждою и кровью — казанцами и русскими, и обличи вину коегождо. Все мы равны пред тобою... О боже, яко милостив еси праведен...

Таң атканчы илаһи затлар белән сөйләште Сәет. Күз алдыннан үкенечле дә, сөенечле дә, газаплы да, татлы да булган хатирәләр узды, бер төн эчендә ул моңарчы яшәлгән бөтен гомер юлын яңадан узды.

## Пәри кызы

*Ул сурәт күземә күренү калды,*
*Хәтеремне, һушымны җомлә алды.*

КОЛ ГАЛИ. «Кыйссаи Йосыф»

...Агым уңаена җай гына аккан коймәләр Идел кушылдыгына җитәрәк тизлекләрен акрынайттылар. Каршы агым, аларны үткәрергә теләмәгәндәй, үзәнне тотырып дулкынлана, әрәмә каплаган ярларга сугылып бәргәләнә иде.

— Ишкәкләрне төшерергә-ә-ә!

Көймәченең карлыккан тавышы иртәнге җылы кояшка битләрен куеп изрәгән мосафирларны айнытып җибәрде. Капчыклар арасына сыенып йокымсыраган Санька сискәнеп сикереп торды, күзләрен угалады.

— Нәрсә? Әллә ушкуйникләрмы?

Егетнең сугышырга әзерләнгән яшь әтәчтәй муенын сузып, кулларын йодрыклап як-ягына каранаунннан көймәдәгеләр шаркылдап көлештеләр.

— Йоклап калдың. Үттек инде,— диде берсе, шаркылдавын тыя алмыйча.

— Син генә булмадың. Кирәкләрен бирә идең!— дип көлемсерәде икенчесе.

Юлга чыкканнан бирле Идел юлбасарларыннан, талаучылардан шикләнеп, бөтен саклану чараларын күреп, хәтта кычкырып сөйләшергә базмыйча тын гына барган сәүдәгәрләргә җан керде, бер-берсен бүлдереп сөйләшергә, көлешергә тотындылар. Кинәт барысы да тынды, ниндидер табышсыз боерыкка буйсынгандай, бер якка карап сүзсез калдылар. Үз гомерендә беренче тапкыр ерак юлга чыккан Санька әле һаман бернәрсә дә аңламый иде. Ул да башкалар борылган якка карады һәм... сихерләнгәндәй, күзләрен зур ачып, каршында пәйда булган әкияти манзарага текәлде.

— Нәрсә бу?— Иреннәре үзенә буйсынмыйча бер үк сүзләрне кабатларга керәште:— Өнемме бу, төшемме? Төш күрәмме соң әллә?

Каяндыр килеп чыккан шаян җил су өстендә тирбәлгән иртәнге сыек томанны ерткалап тарата барган саен, күз алдындагы күренеш тә үзгәрә, төсләре ачыклана, тынсыз калырга мәҗбүр итә иде. Әнә, томан өстеннән бер-берсен уздырырга теләгәндәй, шәмдәй төз, ярымайлы, нечкә, биек манаралар күккә үрелде, аларның алтынланган очларында кояш нуры җемелдәде. Алар сансыз, исәпсез иде. Әйтерсең лә алар акрын гына үсәләр һәм, күктәге ап-ак каурый болытларга тоташырга ашыккандай, томан эчендә йөзәләр иде.

Якынайган саен тылсымлы сурәт зурая, матурлана бара. Әнә инде төрле төсләргә буялган йорт түбәләре, ялык-йолык килүче ярымтүгәрәк гөмбәзләр пәйда булды. Каезланган юан, таза бүрәнәләрдән тезелгән коймалар килеп чыкты, калын, нык капкалар күренде. Болар бөтенесе дә Саньканы сихерли, үзенә чакыра. Гүяки калкулык өстенә утырган шәһәр — иксез-чиксез диңгездә йөзүче тылсымлы көймә, ә ул үзе — мәхәббәтен, үзенә тиң ярны эзләп баручы пәһлеван. Бары тик шушы көймәне куып җитәргә һәм аңа утырырга гына кирәк. Бөтен-бөтен хыялларың шунда тормышка ашар, эзләгәнеңне табарсың, көчеңне, җегәреңне күрсәтерсең, дан-шөһрәткә, мал-мөлкәткә ия булырсың.

— Тизрәк, тизрәк! Алга! Бәхетле, матур кешеләр яшидер монда...

Томан таралуга, тагын икенче күренеш ачылды. Офыкта, күз күреме ераклыктагы урманнар өстендә салават күпере пәйда булды. Ул бер очы белән урманнарга таянса, икенче очы белән артта калган Идел өстенә барып тоташты. Әйтерсең лә биниһая олы капка аларның килүен генә көтеп торган да, менә хәзер тылсымлы дөньяга юл ача, керер урын күрсәтә иде.

Башкасын ачык кына хәтерләми Санька. Ул үзен сихерләгән күренештән әле бик озак айный алмады. Аның халәтен аңламаган атасы инде күптән дөнья мәшәкатьләренә чумган, улының агач сындай катып калуын үзенчә аңлап, аңа нидер сөйли иде:

— Казан каласы шушы булыр... Алдарак Кабан күле... аннан Болак суы агып чыгар... без йөзгәнен Казан суы диярләр. Балык исәпсез бу якларда. Җаның ниндиен тели... Насыйп итсә, юлыбыз уңса, барысын да күрсәтермен...

Шәһәр түбәнә килеп җиткәндә генә күк гөмбәзендә салават күпере балкуын Санька яхшыга юрады, күктәге илаһи көчләр аңа мәрхәмәт күрсәтә, бәхетенең шушы калада икәнлегенә ишарәле дип күңеленә беркетеп куйды. Ни генә булса да, бу калада аңа яманлык кылынмас, юрагань юш килер, теләгәне тормышка ашар, бәхетен табар...

Әтисенең ачуланыбрак әйткәне айнытып җибәрде.

— Җитәр! Баганадай торма. Бер генә килмәссең әле. Гомерең булса... Өйрәнгәнеңне онытмадыңмы? Сынау тотасы кенең...

Санька, яңа гына күргәндәй, әтисенә, аның шомланып калган җете зәңгәр күзләренә, сакалын аралаштырып кыймылдаган юан бармакларына карап катты да калды. Савелий Кузьмич, берни булмагандай, улы белән татарча сөйләшеп ята иде.

— Мыегыңа чорнап куй, казанлылар белән тора салып эш турында сөйләшмә! Иң элек саулык-сәламәтлекләрен, хәл-әхвәл сораш, дөнья хәлләренә күч, акрынлап кына, иплән кенә кызыксынганыңа җеп сузарсың. Алар кабаланганны сөйми.

— Беләм бит инде, мең мәртәбә әйттең,— диде Санька ризасыз гына.

Ата белән улның сөйләшүенә колак салып утырганниндидер сәүдәгәр тәкәллефсез генә аларның сүзен бүлдерде.

— Казанлылар белән сөйләшкәндә телеңдә бал, куеныңда таш булсын. Монысын нигә әйтмисең, Савелий Кузьмич?!

Юлга чыкканнан бирле беркем белән дә ачылып сөйләшмәгән, үз дөньясына бикләнгән төксе чырайлы, яшькелт күзле бу сәүдәгәрне көймәдәгеләр бик өнәп бетерми иде. Бернинди мал төятмәгән, базарга ни максат белән баруы мәгълүм булмаган озын буйлыдан бераз гына шикләнәләр дә булса кирәк. Һәрхәлдә, аның янында ачылып бетмәгән кебек күренәләр, тел яшерәләр иде.

Әтисе ризасызлыгын бик сиздермичә, башын чайкап, басынкы гына җавап бирде:

— Юк инде, Иван. Гомерем буе намуслы сәүдәгәр булдым. Улымда да икейөзлелек күрәсем килми. Казанда да дусларым бар, Мәскәүдә дә, далада да... Улымның да шулай булуын телим.

Иван көлемсерәп куйды, әмма сүзне дәвам иттермәде. Әтисе гүя үзен кемдер бүлдергәнне онытып, ачулы тавыш белән яңадан Санькага карап сөйләргә кереште:

— Мең дә бер тапкыр кабатлармын. Дөньяда кешеләр белән дус яшим дисәң, аларның гореф-гадәтен ихтирам ит, өйрән, телен бел. Йә, әйт әле, базар аксакаллары белән ничек күрешәсе?..

Татлы уй-хыялларыннан бүленгәнгә үртәлүе чыгып бетмәгән Санька, яратмаган сабагын кабатлаган бала шикелле, әйтеп куйды:

— Әссәламегаләйкем, базар агалары! Исәнлек-саулыкмы, дөньялар иминме, ил-көн тынычмы?

Савелий Кузьмичның киң йөзенә канәгатьләнү билгеләре чыкты.

— Аң бул! Без — сәүдә кешеләре. Кайда нинди ызгыш булу безгә кагылмый. Без — тыныч юлда. Телебез сугыш теле түгел, сату-алу, аңлашу теле.

«Шушы тел дигәне белән үтерә инде», дип уйлап куйды Санька ачусыз гына. Әле Угличта чагында ук теңкәсенә тия иде. «Имеш, өйрән, бел. Безгә, малтабарларга, ике-өч тел белү фарыз. Шуларның беренчесе — татарныкы. Угличтан чыгып Иделгә ишкәк салуга, аннан башка бер адым да атлый алмыйсың. Бар Казанга, бар Ханкирмәнгә, Әстерханга, Кырымга, чык нугайлар, сартлар, кыргызлар ягына, Себергә юл тот — кояш чыгышы ягындагы барча илләрдә шул тел. Аны белсәң, далада да, тауларда да, урманнарда да җавапсыз калмассың. Гарәпләр дә, һиндләр дә сүзеңне аңлар, әйткәнеңә колак салыр. Төрек кавеме күп санлы, көчле... Сәүдәң уң булсын дисәң, тел өйрән!»

Борынгы купецлар нәселеннән килгән Савелий Кузьмич, дөньяны ишетеп түгел, үзе күреп, йөреп таныган кеше буларак, улларында сату-алу эшенә генә түгел, гыйлем эстәүгә, телләр белүгә дә ихтыяҗ тәрбияләргә тырыша иде.

«Картаелды. Буыннарда җегәр бетеп килә. Инде бу малаемны да үз көнен үзе күрерлек итеп урнаштыра алсам, җаным тынычланыр иде. Дөньялар имин түгел. Сату-алу белән, мал алмашып кына яшисе иде дә бит... Хаким затларга барысы да берьюлы кирәк. Әйтерсең, җир җитми, һава җитми... Тегендә баргач, барыбыз да бер буласы юкса».

Тире, җитен һәм киндер сүсе тутырылган капчыкларны Болак буендагы лапасларга урнаштырганчы кояш күк гөмбәзенең уртасыннан үтеп, бату ягы-

на авышты. Көймәчеләр, үз йомышларын юллап, һөнәрчеләр мәхәлләсенә китеп бардылар. Йокысызлыктан, ерак юлдан шактый арыган Савелий Кузьмич кәрван-сарайның җиләс хөҗрәсендә ял итәргә ятты. Сихри кала белән тизрәк танышырга ашыккан Санька гына мендәргә таянырга ашыкмады. Көймәдә ауный-ауный пычранып беткән өс-башын салып ташлады, чиста күлмәк-чалбар, аякларына әтисе узган ел Ташаяк базарыннан алып кайткан сәхтиян читек киде, билен чуклы билбау белән буды, чукынырга теләп почмакта берни дә тапмагач, ишеккә карап маңгай тирәсендә тәре сурәте ясап бармакларын уйнатты да җиңел сулап урамга чыгып китте.

Монда бөтенесе дә башкача иде. Челтәр бизәк тотылган өй кыекларына, аклыгы белән күзне камаштырган ташпулатларга, чат саен диярлек күккә ашкынган печкә манараларга сокланып бик озак йөрде Санька. Шәһәр чиста иде, пөхтә иде. Ширбәтчеләр янында сусынын басты, хәлвәчеләрнең татлы нигъмәтләреннән авыз итте, төрле илләрдән килгән базарчыларның ят киемнәренә, аңлаешсыз телләрдә сөйләшүенә, аларның күплегенә, төрлелегенә хәйран калды.

Кәрван-сарайга кайтырга чыккач кына шактый нык арыганын сизеп алды. Аяк табаннары ут яна, күлмәге аркасына ябышты.

— Их, бер чумып чыгарга иде. Әнә ич, Кабаны да, Болагы да ымсындырып, чакырып тора...

Яшел камышлык арасында көмеш көзгедәй ялтыраучы Кабанга таба егетнең аяклары үзеннән-үзе атлады.

Шомырт, балан, миләш куакларын, талларны аралап су буена үтте дә ашыгып-кабаланып киемнәрен салып ташлады, төбендә чуерташлар аермачык күренеп торган, үтә күренмәле чиста суга сикерде.

— А-а-ай-ай-ай!..

Күл өстендә аның рәхәт сискәнүле авазы гына яңгырап калды.

Үзе-үзен белештермичә тирәнгә чумган Санька ничек атылып чыкканын да сизми калды. Күл боз кебек салкын иде. Хәтта аннан тибеп чыккан чишмә суларының уйнаклавына хәтле тойган кебек булды. Әмма ни гаҗәп, күз ачып йомган арада су аны сафландырып та өлгерде, арыган-талганлыгын, әйтерсең, кул белән алып ташладылар. Атна буе көймәдә хәрәкәтсезлектән ялыккан яшь, көчле тәннең уйнуйсы, колач салып йөзәсе килә башлады.

Коенып арыгач, яр буена чыкты да яшел чирәм өстенә сузылды. Арупалчыгу барыбер үзенекен итте: башын беләкләренә куюга, күзләре йомылды. Шулай күпме вакыт узгандыр, янәшәдә генә чырык-чырык көлешкән тавышлардан сискәнеп уянып китте. Кул-аякларын тирә-якка ташлап чалкан яткан Санька сикереп торды. Янәшәдәге куак артында гына бер төркем шәрә кызлар уйный иде. Ялт итеп яңадан җиргә сеңде. Шәһвәте кузгалды. Үзенең дә анадан тума икәнлеге, исенә төште. Оятыннан җир тишегенә керергә китәрдәй булса да, ул таллар арасында чәчелеп калган киемнәре янына бара алмый иде инде. Җитмәсә, ул чишенгән куак төбендә генә, эссе җәй булуга карамастан, башына очлы бүрек кигән, кулына озын таяк тоткан бер карчык утыра. Әйтерсең, каз бәбкәләрен тилгәннән саклый.

Санька күрәчәгенә куя селтәде. Кызларның беркемнән, бернәрсәдән шикләнмичә табигый кыланулары моңарчы татылмаган рәхәт соклану тудыра, татлы ләззәт йөрәген сулкылдата иде. Тезләрен кочаклап утырды да дөньясын онытты. Кызлар яшь, берсеннән-берсе чибәр. Аларның сыгылмалы ап-ак сыннары, аркаларына ябма булып сузылган куе озын чәчләре, талгын хәрәкәтләре сихерләде егетне. Бу мизгелләрдә ул кайда нишләп утыруын да, хәтта үзенең кемлеген дә оныткан иде. Иреннәре дога укыгандай тавышсыз гына кыймылдады:

— Йа тәңрем! Нинди илаһи затлар болар? Күктән төшкән фәрештәләрме әллә? Җир кызларының мондый гүзәлләре дә буламы икәнни?!

Кызларның буй-сыннарында бер генә кимчелек тә, камил булмаган бер генә сызык та юк иде. «Юк, юк! Болар илаһи зат... Менә кара ялмалары

ачылыр, тәннәре шикелле үк ак канатлар үсеп чыгар, бер талпыну белән күккә ашарлар».

Каты итеп үзенең ботын чеметеп карады, шулкадәр каты чеметте ки, хәтта суелып кан чыкты. Авыртуны сизмәде. Юк! Бу ниндидер тылсым, аңлаешсыз сихри халәт иде.

Баштарак аларны тоташ бер төркем итеп күргән егет, күзләре ияләшкән саен, һәрберсенең йөз чалымнарын, гәүдә сыгылышларын, хәрәкәтләрен аера башлады. Кызлар шаян, көлешә-көлешә күлгә чумалар да, бер-берсенә су чәчрәтеп уйныйлар. Күл өстендә аларның чыр-чу килүе генә яңгырап тора. Әйтерсең лә күл аларны бөздай салкынлык түгел, яңа сауган сөт җылылыгы белән кочагына ала. Мондагы суның кешегә көч, дәрт өстәү хасиятен сизеп өлгерсә дә, кызларның түземлегенә, чыдамлыгына хәйран калды Санька.

Ниһаять, озаклап чупырдашкан кызлар берзаман күшегеп ярга сибелде. Күк йөзендәге бүрек хәтле генә болыт кояшны каплауга, арадан берсе такмакларга керешә:

Асыл кояш, кил бире,
Кил бире, китмә кире!
Кошлар да көтә сине...

Кызлар түгәрәкләп бастылар да, бер-берсенең кулларына чәбәкләп бәрә-бәрә, көйләп такмакка кушылдылар:

...Уйнап йөри кызылтүш,
Юлга чыккан сыерчык,
Бар да чакра: кояш, чык!

Гүя, шушы такмакны гына көтеп торган, бүректәй болыт колакчынна-рын җыеп күз алдында кечерәйде дә, түгәрәк тәлинкәгә әйләнеп, бер якка тәгәрәде. Алан алтын нурга күмелде. Табигать балалары кул чаптылар, рәхәтләнеп көлештеләр.

— Ягез, кызлар, китик инде, кич җитә,— дип аваз салды берсе.

Аңа икенчесе җыр белән җавап бирде:

Ак киндерләр шома була
Туңылдатып тукмасаң.
Егетләр дә яратмыйлар
Иртә ятып йокласаң.

Җырлап бетерүгә, үзе үк шаянланып кычкырып та җибәрде:

— Кемдер егетләр кочагына керергә ашыга. Сабырсызлар үпкәләмәсен. Кайтабыз, кайтабыз!

Аның тавышы уенчак, яңгыравык иде, ягымлы иде. Әйтерсең лә кемдер көмеш кыңгыраучыкка кагылып узды. Аның чыңнары Саньканың колагында бик озак яңгырап торды әле.

— И Гөлйөзем, син һаман шулай ашыгасың инде,— диеште кызлар үпкәләгән сыман.

— Кайтырбыз әле...

Әмма Гөлйөзем дигәннәре, баш-башларына кызыллы-яшелле шакмак бизәкләр төшерелгән ак тастымал алып, биленә кадәр төшеп торган чәчләрен корыта башлаган иде инде. Ул җавап кайтарып тормады, көмеш тәңкәләр тезелгән чулпыларын толымнарына кушып, өчәрләп үрергә кереште.

Талчыбыктай зифа, бөтен буй-сынынннан нур балкыган бу кыз башкалардан шаянлыгы белән дә, хәрәкәтләренең талгын йомшаклыгы белән дә аерылып тора иде. Әнә тавышы да нинди матур икән! Саньканың күзенә бүтән кызлар күренмәс булды. Шушы Гөлйөзем дигәннәре сокландыргыч бер сурәт булып күңеленә керә, һәр хәрәкәте килешле, тансык иде аның. Үз-үзен белештермичә ыңгырашкандай «аһ!» дип куюын сизми дә калды.

Хава хәлендә калган табигать балалары Адәм рәвешендәге бу егетнең монда качып утырганлыгын белсәләр, кызык өчен генә булса да аны хур итү җаен табарлар иде. Чая кызлар нишләргә кирәген белерләр иде. Бәхетенә, киемнәрен барлау белән мәшгуль кызлар аның аһ органын ишетмәделәр. Санька телен тешләде, гәүдәсе тораташ булып катты. Шушы хәлдә булса да аның кызларны җибәрәсе килми, мәңге-мәңге шулай карап, сокланып утырырга әзер иде.

Куак артындагы ачыклык бушап, тынып калды. Буыннары тәмам оеган, йозләрчә энә кадалгандай авырттырып тартышкан аякларын уа-уа Санька торып басты һәм сакланып кына кызлар утырган якка күз салды. Берәрсе калмаганмы? Китеп өлгергәннәрме?! Чү! Нәрсә бу? Алан кырыендагы ботакта эре-эре чәчәкле искиткеч матур яшел яулык эленеп калган иде. Санька аның янына ничек барып җитүен, ничек кулына алуын, бите белән яулыкка каплануын сизми дә калды. Юка, затлы ефәктән баш әйләндергеч хуш ис аңкый. Ул ис борынны кытыклый, сулыш юлларыннан җанының үзәгенә барып җитә, йөрәген еш-еш тибәргә мәҗбүр итә иде. Шушы ләззәткә исереп күпме торгандыр, белми, якынлашып килүче аяк тавышыннан сискәнеп, тиз генә куак артына сикерде. Аланга иптәшләре Гөлйөзем дип дәшкән кыз кереп килә иде.

Нindидер ярамаган эш өстендә тотылган малайдай, Саньканың битенә кызыллык йөгерде, сокланулы, гафу үтенүле күзләрен кызга төбәп катты да калды, аяклары, әйтерсең, җиргә беректе, теле аңкавына ябышып калды. Ул кыз янына чыга да, ташлап та китә алмый. Чарасызлыктан гаҗиз калган җаны читлеккә эләккән кошчыктай бәргәләнә башлады.

Тынлыкны кыз бозды:

— Син кем? Әдәми затмы, пәри затмы?— диде ул, нәрсәдәндер шикләнгәндәй як-ягына каранып.

Бер генә саксыз хәрәкәт ясаса да, кызның бүредән качкан боландай куаклар арасында югалырга әзерлеген күреп-сизеп торган Санька, кыюсызлыгын җиңеп, аны тынычландырырга ашыкты:

— Курыкма!.. Әдәми зат мин...

Тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, кирәкле сүзләр таба алмады, башлаган җөмләсе авыз эчендә әвәләнеп, буталып калды.

— Әдәми зат булсаң, чык, яулыгымны бир!— диде кыз бераз кыюлана төшеп һәм шелтәле караш белән өстәп тә куйды:— Кызлар су кергәнне сагалап тору килешми...

«Мин карап тормадым»,— димәкче иде Санька, әмма теленнән бөтенләй башка сүзләр ычкынды:

— Әдәми зат булсам да, мин... чыга алмыйм... Яулыгыңны бик бирер идем дә...

Әллә нәрсә булды, ул оялу дигән нәрсәне онытты, кызның үзе кебек үк кыю сөйләшә башлады.

Беренче курку хисен җиңгән Гөлйөзем үзе дә сихерләнгән кебек гайре табигый халәт кичерә иде. Яшел яфраклар арасыннан керфек тә какмый үзенә төбәлгән күзләрдән дулкын-дулкын булып нindидер тылсымлы көч агыла, ул кызның ихтыярын сындыра, аяк-кулларын богаулый, китмәскә, шушында калырга өнди иде. Егетнең көч тулы беләкләре, киң күкрәге, таза иңнәреннән үсеп чыккан туры муены, җитенгә охшаш сары чәчләре күңелендә аңлаешсыз, әмма тансык бер сурәт булып оеша. Мондый ак чырайлы егетне аның үз гомерендә әле беренче тапкыр күрүе иде. Шул ук вакытта Гөлйөземнең бу оялчан егетне сөйләштерәсе, тавышын ишетәсе килә.

— Нигә чыга алмыйсың?— диде ул шаянланып.

— Мин... мин,— дип кабатлады Санька ни әйтергә белмичә.

Аның хәлен аңлаганын сиздереп, Гөлйөзем кычкырып көлеп җибәрде. Күл өстенә көмеш тәңкәләр сиптеләрмени...

— Син калдырып кит!— диде ул көлүеннән тыела алмыйча.— Мин алып китәрмен.

— Бер шартым бар,— диде кыюланганнан-кыюлана барган Санька.— Син аланнан чыгып тор, яулыгыңны үзем китереп бирермен...

Сәер халәтен әле үзе дә аңлап бетермәгән Гөлйөземнең китәсе килми, шул ук вакытта ниндидер икеләнү, егетнең үзенә якынаюыннан куркуга охшаш бер хис баш калкыта иде.

— Ю-у-ук инде. Син калдырып кит. Аннары куып җитәрсең,— диде ул кинәт кенә бер карарга килеп.

Санька яулыкны үзе яшеренгән куак ботагына элеп куйды һәм ашыгып агачлар арасына кереп китте.

Ул киенеп чыкканда аланда беркем дә юк иде инде. Тик кызларның чыннан да булганлыгын, су коенганлыгын белдереп, сары ком өстендә юеш аяк эзләре генә ярылып ята. Аяныч хисе яшен ташы булып йөрәген янды-рып үтте, үз-үзен белештермичә йодрыгы белән учына китереп бәрде. «Озак мыштырдадым!» Югалган кызны куып җитү өмете белән алга ыргылды. Агач яфраклары битенә бәрде, куллары сыдырылды, әмма авыртуны, сыдырылуны Санька сизми, бер югалтса мәңге таба алмаячак тоелган кызны куып җитәргә, әйтелми калган иң кирәкле сүзләрне җиткерергә кирәк иде.

Сукмаклар күп иде. Аларның кайсыннан китәргә белмәгән Санька аңда ташланды, моңда ташланды, туктап, тын да алмый тынлыкка колак салды, әмма әрәмәдә шылт иткән тавыш та юк иде. Әнә Казан да якында гына. Шәһәргә илтүче юлда исә атлы олаулар, каядыр ашыгучы җайдаклардан башка беркем дә күренми. Гөлйөзем генә түгел, әле бая гына шау-гөр килеп су коенган кызлар төркеме дә, җир тишегенә кереп киткәндәй, юкка чыккан иде.

Санька үзгәрде, уйчанланды. Эш турында, Казанга ни өчен килүләре турында онытты. Суырылып калды. Өлкәннәрнең һәр сүзенә колак салырга күнеккән егет хәзер аларны бөтенләй ишетми кебек иде.

Улындагы үзгәрешне Савелий Кузьмич үзенчә юрый: егет яшь, олы базарга беренче килүе, мәгърибтән һәм мәшрикътән, көн ягыннан һәм төн ягыннан килгән йөзләрчә сәүдәгәрләр, чит мәмләкәт кешеләре арасында каушап калуы гаҗәп түгел. Иялəшер әле...

Көне-төне сату-алу, тавар алмашу белән мәшгуль ата баштарак артык әһәмият бирмәгән иде. Әмма егетнең сәерлеге күзгә күренеп артты. Балаларына карата гадел, каты куллы Савелий Кузьмич улын акылга утыртырга да күп сорамас иде, тик җиткән егетне базар уртасында тотып яруның килешеп бетмәячәген аңлый, тагын кул селти: «Кайткач күрсәтермен мин сиңа Казанны да, өлкәннәр сүзен санга сукмауны да!»

Саньканы сихерләделәр, ахрысы. Шулай булмаса, бу кадәр үк интекмәс, төнлә кулларын сузып, ымсынып уянмас иде. Тик ниндидер татлы газап, бәхетле сыкрану иде ул. Шикләнеп тә куя: «Юкка гына әдәми затмы, пәри затмы син,— дип сорамагандыр ул. Бәлки, үзе пәри кызы булгандыр. Әгәр кеше затыннан булса, бер күренер иде, очратыр иде!.. Юк бит! Юк...»

Кайтып китәр көннәр якынлашкан саен сызлануы арта, йөрәге өзгәләнә, китү көннәрен җиткермәс өчен кулыннан килгәннең барын да эшләргә әзер иде ул. Әтисенең үртәлүен сизә, бергә көймәдә килгәннәрнең аңа акылы җиңеләйгән кешегә карагандай мөнәсәбәтләрен дә күрә, әмма үзен берни дә эшләтә алмый. Аның күңелен бер генә нәрсә били: Гөлйөзем, Гөлйөзем, Гөлйөзем!..

Ул аны тагын бер генә тапкыр, ерактан гына булса да күрер өчен әтисенең ярты малын чыгарып бирергә дә риза иде. Тик күңелдәге сурәтне чынга ашырыр көч, күрәсең, бу дөньяда юктыр. Мәхәббәтне акчага сатып алып булмый.

Санька бер генә мизгелне дә кәрван-сарайның тынчу хөҗрәсендә бикләнеп үткәрергә теләми иде. «Тизрәк, тизрәк калага, кешеләр арасына, Кабан буена!.. Пәри кызы булмаса, иртәдән кичкә кадәр шаулаган шәһәргә чыкмый калмас! Кабан күлен урамый түзә алмас!..»

Аркасына капчык салып көймәгә йөгергәндә дә, сыгылмалы басмадан ярга ашыкканда да күңелендә гел шул уй бәргәләнде. Авыр капчыкны көймә төбенә китереп салды да тирле маңгаен кул аркасы белән сыпырып, тау башыннан ымсындырып, чакырып торучы калага текәлде.

— И Казан! Гөлйөзем атлы гүзәленне кай тарафларыңа яшереп саклыйсың? Нигә серләреңне ачмыйсың, тылсымлы каяа?!

Санька өчен Казан, чыннан да, серле иде, аңлаешсыз иде. Монда бөтенесе дә башкача. Монда башка ил, башка төрле халык, башка дин, башка төрле йолалар, гадәтләр... Дөньяда иң матур дип исәпләп йөргән, Идел буена укмашып утырган Углич моның янында бер авыл шикелле булды да калды.

Калын бүрәнә коймалар, урлар, су тутырылган тирән чокырлар белән уратылган Казан үзе әле тагын икегә — эчке һәм тышкы шәһәргә бүленә икән. Эчке шәһәрдә хан сарае, биек манаралы мәһабәт мәчетләр, икешәрөчәр катлы таш пулатлар, манаралар белән узышып күккә үрелгән юан тирәк агачлары. Тышкы шәһәрдә яшәүчеләр дә йортларын бизәкләп, мөмкин кадәр затлырак итеп салырга тырышканнар. Тау битенә сыенган өйләр, таштан, таудан үсеп чыккандай тоела. Шәһәрнең тышында әле тагын эреле-ваклы бистәләр бар иде.

Санька шуларны күздән кичерде һәм түземсезләнеп капчыкларны санарга кереште. Тагын утыз капчык. Бу йөкчеләр нигә шулкадәр акрын кыймылдый? Егерме биш... Егерме... Капчыклар кимегән саен Саньканың күкрәге киңәя, сулыш алуы җиңеләя кебек. Басма — көймә — яр буе, басма — көймә — яр буе... Аяклары үзеннән-үзе атлый. Менә соңгы капчык...

— Бар, ял ит! Иртәгә өйләдән соң кузгалабыз. Көймәчеләргә әйтелгән, — диде йомшарып калган Савелий Кузьмич.

Бу сүзләре белән Саньканың җанына тагын да авырттырыбрак яра ясаганын ул, әлбәттә, белми иде.

Санька сыкрануын онытып, сикереп торганын сизми дә калды.

— Ассаң ас, киссәң кис... Мин иртәгә Казаннан китә алмыйм. Эшем бетмәгән, — дип ярып салды ул.

Улының үҗәтлегеннән тәмам гаҗиз калган, бәгыреннән өзелеп төшкән соңгы тамчысын — төпчеген аерата яраткан, шуны берничек тә белдерә алмаган ата кеше йөрәгенә чыдый алмыйча уфтанып куйды һәм шартлатып өстәлгә китереп сукты.

— Җитте! Шәһәргә аягыңны да атламыйсың!.. Мин сине... бәйләп алып китәм...

* * *

Менә ничәнче көн инде Гөлйөземнең күңелен үкенү хисе телгәли, менә ничәнче көн инде аны зур булып ачылган җете зәңгәр күзләр эзәрлекли. Ятса да, торса да, һаман шул күзләр аны каядыр чакыра, ымсындырып тылсымлы нурлар җибәрә кебек, нәрсәдер әйтергә, аңлатырга тели, бергә-бергә каядыр еракка, алсу томаннар артындагы киңлекләргә өнди. Су буенда үз гомерендә беренче тапкыр күргән егетнең сурәтен ул, никадәр теләсә дә, күңеленнән йолкып ата алмый иде. Төшләрендә күрә. Имеш, кулга-кул тотышканнар да аллы-гөлле чәчәкләр каплаган иксе-чиксез болыннар буйлап йөгерәләр. Алда нәкъ аның күзләредәй җете зәңгәр булып җәелгән олуг диңгез шаулый. Менә алар йөгереп киләләр дә дулкыннар кочагына ташланалар, салмак кына тирбәлгән су өстендә бергәләп чайкалалар, тәннәренә бәрелеп уйнаган талгын җылы агымда ләззәтләнеп изриләр.

«Барысына да үзем гаепле, — дип уфтана Гөлйөзем. — Яулыгымны алгач та кызлар артыннан җитәм дип җир асты юлына ташланмасам, аның белән бергә кайткан булыр идек. Куып җитәр иде. Сөйләшер идек...» Киң күкрәкле, көчле бу егетнең үзенә бер генә кәррә дә яманлык кылмаячагына ул җаны-тәне белән ышана иде. Андый чиста, моңсу һәм самими күзләр әшәкелек ияләрендә — хәрамзадәләрдә булмый, була да алмый.

Каланың Болак капкасы янындагы манара эченә илтә торган яшерен юл су буендагы текә яр астыннан башлана. Аңа керү урыны гөлҗимеш куаклары, калын-калын өянкеләргә үрелгән колмак үсентеләре белән томаланган, сукмакны исә котырып үскән әрекмән яфраклары каплаган. Табигать, аны

кеше күзеннән яшерергә теләгәндәй, бөтен хыялын эшкә җиккән, бер генә ачык җирне дә калдырмый яшел үсентеләр сипкән иде. Дөрес, яшерен юлны калада бик сирәк кешеләр белә. Әмма абыйсы хан хезмәтендә чагдавыл[1] булып торучы Гөлйөзем өчен ул сер түгел иде.

Сеңлесен үлеп яраткан абый кеше аны кат-кат антлар иттерә-иттерә генә әйтте:

— Үлгәндә дә серне ятларга ачма! Яу килгәндә, Казан-йортка һәлакәт янаганда гына файдалана торган юл ул. Колагыңа киртләп куй,—дип кат-кат кисәтте.—Бел, аның белән шаярырга ярамый.

Шаярырга ярамый! Гөлйөзем сүзендә тормады. Су буенда очраган егетне шаярту, күктән төшкән зат шикелле аның күз алдында гаип булу теләге җиңде—яулыгын алуга аяк очларына гына басып яр астына, куаклар арасына чумды. Тапи йөри башлауга табигать кочагында үскән кыз өчен бер ботакны да селкетми әрәмәдә йөрү артык катлаулы түгел иде.

Менә хәзер шуның җәзасын күрә. «Нигә качтым, нигә көтмәдем икән?»—дип өзгәләнә. Ләкин үткәнне кире кайтарып булмый. Исемен дә белмәгән бу ят егетне кайда да булса очратачагына өмет юк. Казанныкына да охшамаган үзе. Кем белә, бәлки чит-ят илләрдән килгән шаһзадәдер!

Гөлйөзем чигү чигә. Әти-әниләре аңа кул эшен дә ныклап өйрәтергә ниятлиләр, шуның өчен махсус чигүче оста яллаганнар иде. Ул көн дә килеп тегү, чигү, каю, чәмчәләү кебек хатын-кызга лазем эшләрдән сабак бирә. Укалап чигү, энҗе, сәйлән тезү кебек шөгыль Казан кызларының яраткан эше генә түгел, аларның данын ерак-еракларга таратуга сәбәпче дә иде. Гөлйөземнәрнең өе иркен. Дус кызларын да чакырып утыру бер гадәткә әйләнгән иде.

Үзе чигү чигә, күз алдында исә Акканат сурәте. Зәңгәр күзле яшь пәһлеванга ул үзенчә шулай исем кушып өлгергән иде инде. Кара бәрхетнең уртасына ике зур энҗе беркетте, алар тирәсенә зәңгәр сәйләннәрдән түгәрәк чигеп куйды. Бу—Акканат күзләре. Аннан тары бөртеге чаклы гына вак сәйләннәрне җепкә тезеп, кыйгачланып күтәрелүче канатлар ясарга керешге. Ак сәйләннәр арасына сирәкләп кенә зәңгәрләрен салып чыкты. Чиста күк йөзендә талпынучы кошка охшаш сурәт пәйда булды. Чигеп бетергәч, калфагын чәчләренә беркетеп, өстенә ак ефәк яулык салды да кулына көзге алды.

— Аһ, Гөлйөзем, син нинди чибәр!—дип куйды дус кызларының берсе. Кинәт кулыннан эшен ташлап, Гөлйөземне кочаклап алды.—Тукта, тукта! Син бит бөтенләй чит-ят бизәк төшергәнсең. Остазым-ханым безгә мондыйны өйрәтмәде бит. Каян алдың?

Гөлйөзем серле генә елмайды:

— Таптым инде...

Дусты үпкәләп баш чайкады:

— Шуны миңа күрсәтмәгәнсең... Мин дә чиккән булыр идем.

— Аның ничек килеп чыкканын үзем дә белмим. Куллар үзеннән-үзе чикте бугай...

Калфак бизәге, чыннан да, матур иде. Кара бәрхет өстенә төшкән сәйлән-нәкышлар таныш түгел, әмма онытылып кына торган җанга якын бер сурәтне хәтерләтә иде. Анда күк зәңгәрлеге дә, кышкы кар аклыгы да, чишмә суларының үтә күренмәле сафлыгы да бар иде сыман.

— Бәхет кошым шундый минем,—дип пышылдады Гөлйөзем һәм ашыкмый гына сөйләшеп торган җиреннән кинәт кенә чигү эн әләрен бер якка ташлады, ашыгып-каударланып ишек тоткасына барып ябышты, ялваргандай эндәште:

— Остазым-ханым, ачуланма мине! Бик азга гына калага чыгып керәсем бар. Рөхсәт итче!

— Әллә нишләдең, сәерләндең син, Гөлйөзем. Әллә гашыйк булдың инде,—диде чигүче ханым аптыраулы караш ташлап.—Әниләрең сизмәсен

---

[1] Чагдавыл — сакчы.

Ачуланырлар... Бар, тиз йөре...— Яраткан шәкертенә ул берничек тә каршы төшә алмый иде.

Гөлйөземнең битенә куе кызыллык йөгерде, керфекләре зур кара күзләрен каплап, сирпелеп алды.

«Коенырга бер килгән егет тагын килми калмас. Кабан күленең сихәтен, сафландыргыч хасиятен татыган кеше анда кайтмый калмый». Кыз шулай уйлый. Акканатның анда киләчәген күңеле сизенә. Ул моны берничек тә аңлата алмый, әмма егетнең күзләре һаман шунда, аланлыкка чакыра кебек тоела.

Йөрәге очар коштай талпынган Гөлйөзем шәһәр капкасы янына килеп җитүен сизми дә калды. Шыпырт кына манара астына чумарга, турыдан — яшерен юлдан йөгерергә исәпләгән кыз кирмән коймасыннан алдына сикереп төшкән күләгәдән сискәнеп китте, куркынып авызын каплады.

— Кая йөгерәсең, Гөлйөзем? Болай чибәрләнеп... Ешладың әле...

Каршында авызын ерып капка сакчылары башлыгы — токавыл Шәһит басып тора иде. Аның йөзе балкый, чем-кара мыеклары астыннан ап-ак тешләре елтырый. Ул шаяртуын белде:

— Әллә безне сагынып киләсең инде? Шулай бит, Фәрит,— дип кычкырды ул капка өстенә карап.

Биек имән бураның тәрәзә сыман калдырылган уентыгында абыйсының йөзе күренде. Ул баш чайкады.

— Белмим, белмим... Кемне сагына torгандыр...

Егетләр мәгънәле карашып көлештеләр.. Аларның кызны шаяртасы килүләре әллә каян сизелеп тора иде.

Тизрәк ычкынырга зар булган Гөлйөзем ялварулы карашын абыйсына текәде.

— Зинһар дим, җибәрегез инде... Эш күп икәнен беләсең ич!.. Күл буена гына...

Абыйсы ярар сана дигән шикелле кул селтәде. Әмма Шәһитнең җибәрәсе килмәгәне йөзенә чыккан, ул һаман үзенекен туглады:

— Бүген кич чыксаң, җибәрәм. Вәгъдәме?

Гөлйөзем иңсәләрен җыерды да, аның янынннан читләтеп узып, манара эченә кереп китте. Моннан Кабан буе кул сузымында гына. Тизрәк! Тизрәк! Акканат аны көтәдер, күзләрен текәп юлга багадыр...

Колмак ботакларын аралап текә яр астына килеп чыкты, саклык белән генә эзләрен яңадан каплап куйды да комлы аланга ашыкты. Алан буш иде. Ул яр буйлап берничә кат урап килде, күл өстенә озаклап карап торды. Тирә-якта шылт иткән аваз да юк. Табигать мәрткә киткәндәй куе, тыгыз тынлыкка күмелгән иде.

Очынулы адымнары сүлпәнәйде. «Күңелем алданды микәнни? Юкса чакыруын сиздем, тойдым бит»,— дип өзгәләнде. Акрын гына яңадан шәһәргә атлады.

Акканатсыз үткән һәр көн Гөлйөземгә әллә нинди сагышлы газап өсти, моңланырга, үз эченә бикләнергә мәҗбүр итә иде. Шуңадырмы, ахирәт кызлары хәзер сирәгрәк керә. Аларның да күбесе һөнәрчеләр затыннан. Күп вакытларын кул эше белән үткәрәләр. Хәер, кызларга ул серен чишмәде. Күл буендагы тылсымлы очрашуны аның үзе генә белəсе, үзе генә хыялланасы килә иде.

Алда ярминкә бизәге — җомга җыены бар бит әле. Ташаякның гөрләп торган чагы. Әнә Казан суы буендагы болыннарда чаң-кубызлар чыңлый, сорнай-кәрнайларның, кубызларның дәртле тавышлары яңгырый, курай моңлана, сазлар өздерә, думбаклар бәргәләнә-бәргәләнә биергә чакыра.

Казанлылар тар күңелле түгел. Ярминкәгә килгән сәүдәгәрләр, малтабарлар, һөнәрчеләр, ерак сәяхәтләрдән ямь табучыларның барысын да сөрән салучылар бәйрәмгә чакыра. Бүген җомга җыены, бүген олы бәйрәм! Күп тә үтмәс, чаң-кубызларга тагын дисталәрчә ят уен коралларының авазлары кушылыр, туң бәгырьләрне дә эретерлек, очынып биерлек дәртле көйләр яңгырар.

Гөлйөзем шунда ашыга. Юк! Бүген бисе дә, җырлыйсы да килми аның. Күңеленең иң төбендә яшерен өмете бар — Акканатны күрү, аның күзләренә багу. Тәнендә җаны булган егет Ташаяк ярминкәсенә килеп тә кичке җыенга чыкмый калмас. Ул шуңа ышана, шуны тели. Акканат булмаса — җыенның яме, уенның тәме качар...

Унбишен яңа гына тутырган, уеннарга да яңарак кына катнаша башлаган Гөлйөземнең пакь күңеле башка егетләргә күтәрелеп карарга да рөхсәт бирми, хыялый сурәтенә тугрылык саклый. Шәһит килеп чыкмасын дип шикләнә, ул очраса, Акканатка юл куймас, күрешергә дә, сөйләшергә дә ирек бирмәс. Теләсә кайчан кылычка тотынырга әзер мәргән егет, шиксез, Акканатны да бәхәскә чакырмый калмас иде.

Морзалар нәселенең горурлык, егетлек көндәшлеге, кызлар намусы турында үз төшенчәләре бар. Алар күп нәрсәне кылыч белән хәл итә.

— Акканатым минем, ак нурым,— дип кабатлый ул эчтән генә.— Кил инде. Бер күрим дә хәлеңне белим. Син чыннан да бар идеңме соң, әллә күл төбеннән күтәрелгән пәри егете идеңме?

Имештер, күл төбендә су кызлары, җен-пәриләр яши, дип әкиятләр тыңлап үскән кызның кайчагында күңелендә вәсвәсә уяна. Куак өстеннән башы белән киң күкрәге генә күренеп торган ап-ак тәнле сәер егет пәри зат булса да, гаҗәп түгел. Төпсез күл бит ул! Күңеленә мондый шөбһә керүгә, белгәннәрен укый, шомлы уйларны куарга тотына:

— Юк! Юк!.. Пәри егетеннән андый да җылылык, кайнар тарту көче бөркелмәс иде!..

Алан өстендә җыр авазлары сирәгәя төште, чаң-кубызлар талды, курайчыларның тыны бетте. Яшьләр берәм-берәм дә, парлашып та, төркем-төркем булып та кала ягына китә башлады. Мәйданда иң чая, иң дәртле егетләр, җырлап, уйнап туймаган кызлар гына калыр, алар таң йолдызы калыкканчы йөрерләр. И бәхетлеләр!

Өметенең акланмавын аңлаган, хыялындагы егетнең чынлыгына шикләнә башлаган Гөлйөзем дә шәһәргә таба атлады. Күзләрен моң басты. Әллә яшь иде ул, әллә инде... Кинәт томан пәрдәсе каплаган күзләре зур булып ачылды, йөрәге, тозакка эләккән болан баласыдай, бәргәләнергә тотынды, аякларының хәле бетте. Кала ягыннан, талпынып очкан кошны хәтерләтеп, Акканат ашыга иде.

Менә ул Гөлйөземгә якынлашты һәм... кызның үзе шикелле үк, аннан берничә адымда тораташка әйләнде. Телләре түгел, бер-берсенә төбәлгән күзләре генә сүзсез аңлашты, серләште, моң-зарларын уртаклашты.

Егетнең күз төбендә шәмәхәләнеп торган урынны күрүгә, кызганудан Гөлйөземнең йөрәге кысылды, ярдәмчесез нәни баланы сөйгәндәй, аны йомшак сары чәчләреннән сыйпап иркәлисе, юатасы килә башлады. Куркынып кычкырып җибүрүен сизми дә калды:

— Ни булды сиңа, Акканатым? Нишләдең?

«Акканатым» сүзеннән Саньканың иңнәренә канатлар үсеп чыккандай булды. Шушы кызны яклап, саклап теләсә нинди яуга каршы ташланырлык көч тоя иде ул үзендә.

— Зарар юк!—дигән булды.— Егет кеше ярасыз булмас. Ә чын исемем минем Александр.

— Нинди сәер исем,— дип пышылдады кыз. Алек-сан-дыр!

— Юк инде, мине Санька гына диләр. Дөньяда иң матур исем — синеке, Гөлйөзем. Мин аны ишеткәч тә, мондый исем бары тик фәрештәләрдә генә була торгандыр, дип уйлаган идем... Син бит минем фәрештәм, Казан фәрештәсе...

...Күк йөзендә берәм-берәм йолдызлар кабынды. Идел ягыннан салкынча җил исеп куйды. Алар исә бернәрсә дә белмичә, бернәрсә дә сизмичә бардылар да бардылар. Күпме вакыт үтүе, күк йөзенең шәмәхәләнеп таң атар чак җиткәненнән хәбәр бирүе дә аларны борчымый. Бөтен дөнья, бөтен җиһан, Идел һәм Казан суы, Кабан һәм Болак, чирәм арасына яшеренгән бөҗәкләр һәм судагы балыклар — барчасы да алар өчен, гүя яшәүдән тукта-

ган, юкка чыккан. Доньяның үзәгендә ике генә зат — алар, Гөлйөзем белән Санька гына калган иде.

— Мин сине өеңә кадәр озатып куям, яме,— диде Санька. Аның әле һаман да бу очрашуны өзәсе килми, аерылырга теләми, ләкин шулай кирәк икәнлеген белә һәм Гөлйөземгә нинди дә булса зыян китерүдән куркыну йөрәген кысылып-кысылып куярга мәҗбүр итә.— Сине өеңдә ачуланмаслармы?..

— Рәхмәт,— диде Гөлйөзем һәм иңнәрен җыерып куйды.— Минем бит әле болай озак йөргәнем юк иде...

Шулчак шаулап чабып килүче ат тавышыннан сискәнеп, икесе ике якка тартылдылар. Парлап җигелгән җиңел арба өермәдәй томырылып кыз белән егет арасына килеп керде. Атлар кешнәшеп арт аякларына чүктеләр. Җиргә кара күләгә сикереп төште һәм эһ дигәнче кызны бөтәрләп, икенче күләгәнең аяк астына ыргытты, арбага сикерде. Шуны гына көтеп торган шәүлә камчы белән орды, зәһәр авыртуга чыдый алмаган атлар караңгылыкка ыргылды.

Санька арбага сикерде һәм сыңар кулы белән арттагы аратага ябышып өлгерде. Тик ыргылган атларның тартылуы шулкадәр кинәт булды ки, иреннәрен канга батырганчы тешләгән егет, ычкынып, үлән өстенә тәгәрәде.

— Ак-кана-ты-ы-ым!

Төн пәрдәсен ертып, Гөлйөземнең ачыргаланып кычкырганы ишетелде.

Күз ачып йомганчы булган бу мәкерле, җан тетрәткеч явызлыктан Саньканың бөтен тәне куырылып килде, әйтерсең, йөрәгенә үтмәс хәнҗәр кададылар. Ул сикереп торды һәм үкенеченнән, чарасызлыгыннан буылып, арба югалган якка ыргылды.

## Ата белән ул

I

> Агыйделнең аланы,
> Пешә икән баланы.
> Ата-ана үстерә икән
> Хәсрәт өчен баланы.
>
> Халык җыры

Сызылып таң атты. Күккә омтылган дистәләрчә манаралардан шәһәр өстенә дулкын-дулкын булып иртәнге азан тавышлары таралды.

Нindидер илаһи мәкам белән яңгыраган бу авазларны ишеткән саен Савелий Кузьмичның күңеле тула, күзләрен томан пәрдәсе каплый. Танып белсә дә, җаннарын аңлап бетермәгән казанлыларның, мөселман динен тотучыларның меӊ-мең еллар җыелып килгән аһ-зары, моң-сагышы шулай чайпалып түгеләдер сыман тоела башлый. Хаксызга рәнҗетелгәннәр, яу кырларында ятып калганнарның җаны елыйдыр, алар шул манаралардан исәннәрне кисәтәдер: аң булыгыз, үзегез кебек бәндәләрне рәнҗетмәгез. Хак тәгалә каршында барыбыз да тигез, барыбыз да хакның бәндәләре...

Мәгънәсен аңламаган бу доганы шулай үзенчә тәгаенли карт сәүдәгәр.

— Әйе, дөрес сүзләр!— дип пышылдады ул һәм почмакка карап, бармак ишарәләре белән тәре сурәте ясагач, сукрана-сукрана ятагыннан кузгалды.— Түзем җитми шул әдәм баласына, сабырлык җитми...

Улы исенә төште, тагын чукынып алды. Бүтән каршы әйтмәслек итеп сабак укыту өчен ул аны хөҗрәгә бикләп калдырган иде. «Уйланырга вакыты булгандыр. Артыграк җибәрдем җибәрүен... Ләкин алла гафу итәр... Ата кулы суккан җир тәмугта янмый».

Савелий Кузьмич авыр уйларыннан арына алмый иде әле. Акрын гына күрше хөҗрә ишеге янына килде һәм ачкычны тыгып борып җибәрде.

— Йә, улым! Карт атаны гафу ит! Үзең өчен тырышам...

Эчтән тавыш-тын ишетелмәде. Күңеленә тула барган шомны җиңәргә тырышып, бүлмәгә күз салды. Хөҗрә буш иде. Тик идәннән өч терсәк биеклегендә уелган тар тәрәзәнең пыялалары алынган, аннан саркып иртәнге томан керә иде.

Авыр гәүдәсе лыпылдап ишек катындагы урындыкка килеп төште, тыны кысылды, калтыранган бармаклары утыртма якасының сәдәфләрен ычкындыра алмыйча азапланды.

Карт сәүдәгәр ачуыннан, чарасызлыгыннан, гарьлегеннән, улына рәнҗешеннән буылды, тешләрен шыгырдатты:

— И бала, ба-ла-а-а!.. Мин ялгыштыммы, синме?..

Йодрыклары таш диварны төйде.

Кояшның күтәрелеп тәрәзәдән каравын, ярымкараңгы хөҗрәнең алтынсу нурларга күмелүен дә, кәрван-сарай ишегалдында атлар кешнәвен, дөяләр бакыруын, тәгәрмәчләр шыгырдавын, арбачыларның үзара кычкырышуын да Савелий Кузьмич сизми иде. Аңа бу дөньяның кызыгы, яме калмады, газаплы уйлары бөтен җиһанны кара болыт белән каплады, зиһенен чуалтты.

Иягенә таянып уйга чумган карт сискәнеп китте. Кинәт бүлмә яңадан караңгылыкка чумды, яктылыкны томалап, тәрәзәдә кемнеңдер тузгыган чәчле башы күренде. Киң җилкәле гәүдә тәрәзә яңакларына ышкыла-сыдырыла эчкә шуышты һәм тып итеп идәнгә сикереп төште. Тынсыз калган сәүдәгәр каршында җирдә яткырып аунаткандай тузанга баткан, киемнәре ертылган Санька басып тора иде. Аның тез башлары умырылып чыккан, чалбар ертыгыннан канлы җәрәхәтләре күренә, үзе еш-еш сулый иде.

Ата белән бала бер-берсенә карашып шактый озак сүзсез тордылар. Әйтерсең лә күзләре белән бер-берсен капшыйлар, ни булганын аңларга телиләр иде.

Ниһаять, Савелий Кузьмич зиһенен җыйды, карлыккан, басынкы тавыш белән илереп сорады:

— Санька, синме бу?! Ни булды сиңа?..

Аның авыр сулавыннан, тавышына чыккан газабыннан Саньканың йөрәге куырылып килде, артык болай тора алмавын аңлап, әтисе каршына ташланды, җәрәхәтенең авыртуын да сизмичә тезләре белән шуышып килде. Кипкән авыз куышлыгында теле бәргәләнде, сүзләре өтек-төтек чыкты:

— Батя... Гафу ит мине... Мин... Казаннан китә алмыйм... Һич югы тагын... тагын ике көн...

Егетнең тавышы калтырый, күзләрендә яшь күренмәсә дә, бөтен җаны елаганы сизелә иде.

Савелий Кузьмичның иртәдән бирле күңелендә кайнаган шикләре, утка май сипкәндәй, дөрт итеп кабынды, төгәл бер фикер булып ялкынлана башлады: «Егет ялгыш юлга баскан. Җаһил әдәмнәр кармагына капкан. Шуннан ычкына алмый. Йа хода! Үзең ярлыка!.. Газиземә ярдәм итү өчен җаным фида булсын!»

Шик-шөбһәсен тавышына чыгармаска, мөмкин кадәр ягымлы, дустанә булырга тырышып эндәште:

— И улым, улым! Атаң ярдәм итмәс идемени?! Нигә баштан ук барысын да сөйләмәдең? Миннән дә якын тагын кемең бар? Ник җанымны кыйныйсың, ник әйтмисең?..

Санька моң тулы, сагышлы һәм шул ук вакытта ниндидер аңлаешсыз үҗәтлек, тәвәккәллек чалымнары беленеп торган күзләрен атасына төбәп, акрын гына сөйли башлады:

— Беләм, әти. Шуңа үтенеп сорыйм... Миңа Казанда калырга кирәк! Җанымда ни актарылганын белсәң, аңлар идең, төшенер идең... Мин бит юкка...

— Житте сиңа,— дип бүлдерде тәкате беткән Савелий Кузьмич.— Мин бит синнән ни булганын сорыйм. Әйт, кемнәр кулына төштең? Нинди юлда йөрисең син?..

Бүлмәдә тынлык урнашты. Йөрәкне изүче авыр тынлык.

— Әти... Мин бит гашыйк булдым...

Әйтерсең, бөтен тәнен-җанын кысып, яндырып торган утлы кыршауны алып ташладылар, дәһшәте белән куркытып, рухын сытып бетергән шикләр өермәсе бөтерелеп очты. Савелий Кузьмич буылып-буылып көләргә тотынды, күзләреннән атылып яшь чыкты. Әллә нинди шатлыклы да, шашкын да, сәер дә көлү иде ул. Атасының гайре табигый шашкынлыгы Санькага да күчте. Баштарак аның күз яше аша шаркылдавын сәерсенеп күзәткән егет үзе дә сыны белән бөгелеп төште, тыела алмыйча көләргә кереште.

— Кайгың шул гына идеме?—дип гөрелдәде Савелий Кузьмич көлүеннән тыела алмыйча.—Шуның өчен көннәр-төннәр сугышып йөрергә кирәк идеме? Һай, бизәгәннәр соң үзеңне!..

Улының мәхәббәт газабыннан көлүне килештермәсә дә, каяндыр күкрәк астыннан күтәрелгән дулкын аңа һич кенә тынычланырга ирек бирми иде. Ниһаять, ул үзен кулга алды, иплəп кенә сораштырырга тотынды.

— Йә, кем инде ул бәхет кошы? Берәр сәүдәгәр кызымы?

Егет авыр сулап куйды һәм, бар кичерешләрен бер авазга салып бетерергә теләгәндәй, уфтанып җавап бирде:

— Мин аның кем кызы икәнен дә, кайда торганын да белмим. Бер нәрсәне генә төгәл беләм: ул фәрештәгә тиң кеше. Аннан башка миңа якты тормыш юк. Ансыз тормыш миңа кирәкми...

— Кайда таныштыгыз? Ничек? Күрештегезме... Сөйләшмәдегезмени? Исемен дә белмисеңме?

Атасының бер-бер артлы ашыгып тезгән сорауларыннан югалып калган Санькага Гөлйөземне кайда, ничек күрүе, төнге очрашуы турында бәйнәбәйнә сөйләп бирүдән башка чара калмады.

Аның һәр сүзеннән үзенчә мәгънә чыгарырга тырышып, барысын-барысын күңеленнән үткәреп тыңлаган ата кеше түземсезләнеп бүлдерде:

— Аңлашып бетерә алмадыгызмыни соң?

— Юк!—диде Санька үкенүенә чыдый алмыйча.—Кичә төнлә аны минем кулымнан йолкып, урлап алып киттеләр...

— Кемнәр?.. Ничек?..

Күбрәк ишеткән, белгән саен Савелий Кузьмичның йөзе караңгыланганнан-караңгылана барды. Санька сөйләп бетергәч тә әле бик озак тавыш-тынсыз утырды, бармаклары нәрсәдер эзләп капшанды, сакал-мыекларын сыйпаштырып куйды. Күрәсең, ул ни әйтергә, моны нәрсәгә юрарга белми иде. Урыс кенәзлекләрен аркылыга-буйга гизгән, мөселман дәүләтләренең яшәү рәвешен һәм кануннарын ярыйсы гына белгән, һәркайсында озаклап сату иткән карт сәүдәгәр хәтерендә моңа охшаш вакыйгалар эзли, кайчандыр ишеткән хәлләрне исенә төшерергә тырыша иде.

— Урлаучылар ничек киенгән иде? Хәтерләп кала алмадыңмы?—диде ул, ниһаять.—Сиңа, кызга бер-бер сүз әйттеләрме?

— Ю-у-ук!—дип баш чайкады Санька.—Киемнәрен аз гына төсмерләдем. Гаскәриләр булса кирәк. Тимер көбәдән икәнлекләрен абайлап калдым.

Савелий Кузьмичның йөзеннән сөенү шикелле яктылык узды, әмма бераздан куркынып Санькага текәлде.

— Бу юлы алла саклаган сине!—диде ул шомланып.—Бу кыз гади кыз түгел. Һөнәрче, сәүдәгәр балаларын болай сакламыйлар. Аңлыйсыңмы? Синең кыз каршында юк итәселәре генә килмәгән. Аны аяганнар. Юкса...—Аның тавышы торган саен куркынычрак, дәһшәтлерәк яңгырый башлады:—Алар сине танып, хәтерләп калган булырга тиеш. Алар гафу итми. Аң бул! Ялгызың чыгып китсәң, кайтып кермәвең дә бик ихтимал... Инде хәзер үк соң булуы мөмкин!

Санька әтисенең сүзләрен тыңлый, ишетә, әмма йөрәге аларны кабул итми. Ул сөйләгән дәһшәткә ышанасы килми. Юк! Булмас! Гөлйөзем ханнар нәселеннән дә, карачылардан да түгел. Нәнкәләр кулында үскән нәзберек гөлләр андый кыю, батыр булмас. Колагында исә Гөлйөземнең ялварып, илереп, ярдәм сорап кычкырганы яңгырый:

— Ак канатым ми-не-е-ем!

Ул бит аңа ярдәм итәргә, урлап качкан җаһилләр кулыннан коткарырга тиеш иде! Коткарырга тиеш!..

— Юк, əти! Мин аны тагын бер кат күрмичә китмим. Аның миннән башка ярдәмчесе юк!—дип, тискәреләнеп үзенекен кабатлады ул.— Гөлйөзем карачылардан, би-морзалардан түгел. Йөрәгем сизә... Алардан булса да, мин аны күрергә тиеш.

— Белмим, белмим,—дип куйды Савелий Кузьмич.— Сине монда ни көтәдер... Ут белән шаярма.—Һәм кинәт кырысланып, усал итеп өстәде:—Сиңа, христиан кешегә, мөселманнар белән яр булу килешми. Аның онытма! Ут белән су кушылмый.

Санька ачу белән сораганын сизми дә калды.

— Егет белән кыз арасында диннең ни катнашы бар? Алла яратмаска кушамы? Пәйгамбәрләреме?

— Аллага тел тидермә!—Савелий Кузьмич малаена кизәнгән җиреннән кинәт тукталып калды һәм, әле кайчан гына аның өчен җаны тетрәгәне исенә төшепме, тавышына ягымлылык чыгарырга ашыкты:— Җирдә кешеләрне алла түгел, аның вәкилләре—патшалар хөкем итә. Сафагәрәй хан—укымышлы, гадел хөкемдардыр дип беләм. Әмма ул да хан карачысы кызының христианга чыгуын яратмас. Алар безне кяфер дип йөри.

— Ә без аларны? Без аларны ничек атыйбыз?

Савелий Кузьмич диндар кеше түгел иде. Әмма улының маңгайга бәреп әйткәненә җавап бирми булдыра алмады. Аңа ничек тә ике яшь арасына салкынлык кертергә кирәк. Саньканың күңеленә иләслек саласы бар,—ә моның өчен дин кануннары иң кулай нәрсә иде.

— Басурман дибез, неверныйлар дибез. Хагында да шулай ич,—диде ул.

Санька бераз уйланып утырды, әмма аның килешергә теләмәгәнлеге йөзенә чыккан, ул каршы төшәргә миндидер яңа дәлилләр, сүзләр эзли иде булса кирәк. Кинәт аның күзләре очкынланып китте.

— Кешеләрне кем яраткан?—дип ярып салды ул тиктомалдан.

— Кем булсын, алла,—дип җавап кайтарды Савелий Кузьмич.

— Барысын дамы?

— Барысын да.

— Үзе яраткан бәндәләрне алла яклый да, саклый да, ярлыкый да. Шулаймы?

— Әлбәттә, шулай,—диде сәүдәгәр тынычлана төшеп.—Аллаһы тәгаләнең рәхмәте бик киңдер. Кылган гөнаһларыңны, гаепләреңне танысаң, ярлыкар да, гафу да итәр.

— Димәк, мөселманнарны да алла яраткан. Ул аларны да яклый, саклый. Алар да хакның бәндәсе. Колларына бер-берсенә дошман булып яшәргә алла кушмый торгандыр. Димәк, без бертуганнар.

Улының сүзне сүзгә ялгап мондый нәтиҗә чыгаруын көтмәгән Савелий Кузьмич нәрсә әйтергә белми аптырады. Бер карасаң, аның сүзләрендә дөреслек бар кебек. Әмма мәхәббәт дип шашкан малайга юл куярга, сүздә җиңдереп, бала каршында абруеңны төшерергә ярамый. Ул тешләрен кысып, ачу белән каршы төште:

— Онытма, татарлар безнең дошманыбыз. Дошман туган була алмый.

— Бер алла бәндәләре дошман түгел. Бу—гөнаһ!—Санька ачыргаланып үзенекен расларга, хис иткәнен, уйлап тапканын белдереп калырга ашыга иде.—Дошман дисең, алайса нигә үзең дошман белән сәүдә итәсең? Димәк, син алардан башка яши алмыйсың. Һаман-һаман татарларга килеп егылганыңны белмиммени!? Ничә ачлыктан алар коткарды?.. Угличка да, Новгородка да батман-батман бодайны Казаннан ташыйсың бит... Әнә бу юлы да күпме төяттең. Ярдәмләшеп яшәгән мөселман белән христианның дошманлашуы гөнаһ! Моны алла кушмый. Мин беләм...

Карт сәүдәгәр күз алдында гөнаһка баткан улын туктатыр өчен каты итеп кычкырып җибәрүдән башка чара тапмады:

— Житте! Авызыңны үлчәп ач! Синең аркада җәһәннәм утында янасым килми.

Санька җавап биреп тормады, әмма атасына күзләрен тутырып карап, һәр сүзен кистереп әйтте:

— Батя, мин барыбер Казанда калам!

Савелий Кузьмичның башына күсәк белән ордыларммыни, тагын тынсыз-өнсез калды. Улындагы кирелекне ул берничек тә аңлый алмый, әмма шунысын яхшы белә: моңа ничек тә чик куярга, мәхәббәт дип шашкан көчекне авызлыкларга кирәк иде. Улы белән ризалашу төсмере чыгарып, кинешкәндәй әйтеп куйды:

— Яхшы! Уйлашыйк. Карарбыз,— диде һәм сыкранып, күкрәгән уа-уа ишеккә юнәлде.

Бераздан бернинди явызлык көтмәгән Санька янына өрлектәй өч көймәче килеп керде. Алар сүзсез-нисез генә егеткә якынлаштылар һәм «эһ» дигәнче аны бөтәрләп, кул-аякларын бәйләп идәнгә ташладылар.

Күп тә үтмәде, кәрван-сарайдан Болакка таба җигүле ат чаптырып китеп барды. Берничә көймәче һәм Савелий Кузьмич утырган арбада торыпша белән капланган озынча капчыкны гына шәйләргә була иде.

Гәрәбәдәй Казан бодае, чынаяк савыт-саба, көбә, шам корычыннан[1] ясалган затлы корал, ефәк һәм батман-батман башка мал төягән зур көймә Болак суын ерып Казан-суга юл алды. Ашыгычрак кузгалсалар да, сәүдәгәрләр канәгать иде. Алып килгән хәтле бар әйберләрен яхшы бәягә урнаштыра алдылар. Углич базарында дүрт күз белән көтелә торган яхшы тавар төяттеләр. Ярминкә уңды. Һәркемнең кәефе әйбәт иде. Бигрәк тә Иван сәүдәгәр шат. Ул изүен җилбәгәй җибәргән, куе сары йон баскан күкрәген җилгә куеп, көймә борынында авыз эченнән генә нидер көйли-көйли алга текәлгән. Аның ашкынуын, ашыгуын кем дә аңламый. Хәер, ярминкәгә килүгә үк алтын белән генә эш иткән, булат кылыч, хәнҗәр, көбә, мылтык кебек кирәк-яракны кулдан ычкындырмаска тырышып, кул сугып кына тулаем алган бу малтабарны өнәп бетермиләр, аннан шикләнәләр, шул шикләнүләр, шөбһә сүзсез ихтирамга әйләнә кебек иде. Һәрхәлдә, үз эшен бетергән кешенең тизрәк кайтырга ашыгуы һәркемгә табигый тоела.

Савелий Кузьмич кына сүзсез. Аның җыерылган маңгаен, куе сакал-мыек арасында кысылган иреннәрен күпләр игътибарга алмады. Сәүдәгәрләр арасында башлык итеп танылган картның сүзгә артык һәвәс түгеллеген, үз дөньясына бикләнергә яратуын күпләр белә иде. Ыгы-зыгы, уңышлы сәүдә белән мәш килүче базарчылар шулай ук көймәдә бер кешенең җитмәвен дә сизми калдылар. Кузгалыр алдыннан гына йөк өстенә кертеп ташланган һәм торыпша белән капланган озынча капчыкка да беркем игътибар итмәде. Һәркемнең үз мәшәкате мәшәкать иде.

Агым уңаена аккан көймә ишкәкчеләрнең бердәм талпынуыннан көч алып, кызулаганнан-кызулый, тизлеген арттыра бара. Төн җиткәнче Иделгә чыгарга, аның киң ярлары арасына сыенырга кирәк. Мал төягән көймәнең юлда, киңлектә булуы хәерле. Дөнья хәлен белеп булмый, мал тупланган җиргә юлбасар җыелмый калмас.

Берәүләрнең юл капчыгыннан пешкән тавык, йомырка, кыздырган балык, казанлылар гына ясый торган хуш исле казылык, яшел суган чыкты, икенчеләр озын муенлы шешәләрнең бөкесен ачты. Көймә төшемле эш башкарган хуш күңелле кешеләрнең бәйрәмен, шау-шуын Идел кочагына алып кереп китте.

Савелий Кузьмич бәйрәмгә кушылмады. Ул аяк-кулы бәйләнгән, авызы тастымал белән капланган Саньканы уйлый, аның өчен борчыла. Тыны бетмәсме, капчыкта уңайсыз түгелме?.. Һәр боерыгын сүзсез үтәүчәк көймәчеләрнең улына артык зыян китермәскә тырышуларын белсә дә, җаны урынында түгел. Никадәр кире, үҗәт булмасын, барыбер үз каның, җаныңның бер кисәге ләбаса! Иншалла, акылына килер. Бу афәттән котылгач, үзе дә рәхмәт укыр әле дип юана. Менә Казан биләмәләреннән чыгарбыз, ара ерагайган саен күңеле суынып дип өметләнә. Анда инде егетне бәйдән ычкындырырга да мөмкин булыр. Шашкын агымлы, мул сулы киң

[1] Шам корыч — иң яхшы корыч. Димашык корычы.

Идел уртасында беркая да бара алмас. Угличка кайтуга ук егеткә кыз ярәшергә, озак сузмыйча башлы-күзле итәргә кирәк. Әнә күршедәге Тимофий сәүдәгәрнең кызы пешкән җиләк кебек өлгереп килә. Аңа да ия тиз табылыр. Бер кашык су белән йотарлык шундый гүзәлне күргә, егетеңнең дә күзе ачылыр. Казан вакыйгасы яшьлекнең бер җүләрлеге, дуамал кабынуы булып кына исендә калыр. Шулай гына була күрсен! Йа хода, ярдәмеңнән ташлама! Тизрәк, тизрәк Угличка! Туган йортка! Анда һәр агач, һәр таш, һәр чишмә ярдәм итәр, егеткә айнытыкыч тәэсир ясар. Кода-кодагый булып, үз ишләрең белән аралашып, ярдәмләшеп яшәүгә ни җитә!?

Теше-тырнагы белән каршы торса да, өч әзмәвернең көченә буйсынырга мәҗбүр булган Санька, көймәчеләрнең усаллыгыннан бигрәк, атасының мәкеренә рәнҗеде. Ник аңламады ул мине?! Аңлата алмадыммы? Ләкин аңа сөйләшеп торырга ирек бирмәделәр, кулларын артка каерып бәйләделәр, аякларын сугымга әзерләнгән малныкыдай тышауладылар, авызын каерып сөлге белән капладылар.

Кайсысыдыр калын тавыш белән дәште:

— Арбада дулап тавыш чыгармасын тагы. Сыла берне!..

Калганын хәтерләми Санька. Ниндидер каты нәрсә башына килеп төште, күз алдында кызыллы-яшелле бөҗралар биешеп алды һәм... дөнья тынды.

Тәненең оюына чыдый алмый күзен ачканда бар дөнья караңгылыкка чумган иде. Аяк-кулларын кыймылдатып карады, әмма гәүдәсе аңа буйсынмады. Калын сүс аркан беләкләрне авырттырып кыра, аякларындагы тышау сыйрак итен кисеп кергән, бөтен тәне утлы энәләр кадалгандай яна иде. Иягең аска-өскә, уңга-сулга йөртеп тастымалдан котылу җаен карый башлады. Көймәчеләр артык нык тырышкан, калын киндер тукыма каты тарттырып бәйләнгән иде. Бит тиресе суелыр хәлгә җитсә дә, ул акрын гына башын боргалавын белде. Менә тастымал бераз бушады, соңгы көчен җыеп кискен тартылуга, муенга шуып төште. Беренче уе: «Кабахәтләр, чишегез мине!» — дип кычкыру иде. Ләкин янында гына көлешкән, лыбыр-лыбыр сөйләшкән тавышларны ишетеп, телен тешләде. Тукта! Кайда соң мин? Кәрван-сарайдамы? Хәер, түгелдер. Әзмәверләрнең берсе: «Арбада дуламасын!» — дигән иде түгелме соң? Нинди арба? Мине кая алып баралар?..

Башыннан өермәләнеп узган сорауларга җавап табарга, кайдалыгын, нинди кешеләр арасында икәнлеген ачыкларга кирәк иде. Бәлки, әтисе әйткән куркыныч шушыдыр?.. Моның өчен шым гына тыңлап ятудан башка чара юк. Бәлки әле әтисенең мәкеренә түгел, ә ул әйткән куркынычка юлыккандыр... Кем белә...

Санькаының зиһене, уе кыл кебек тартылды, тын да алмый тирә-яктагы тавышларны тыңларга кереште. Чү! Әнә кайдадыр аста су чупылдады, озак миңгерәп ятудан саңгырауланган колакларына шыгырдау авазлары килеп керде.

Бәй, ишкәк тавышлары түгелме соң болар!? Әнә, һәр ике яктан шыгырдап суга чумалар да, салмак талпынган канатлар кебек, өскә күтәреләләр. Елга өстенә тамчылар коела.

Бишектә яткандай тирбәлүен абайлап алган Санька үзенең көймәдә икәнлеген, Идел уртасына җитеп дулкыннар өстендә чайкалуларын да аңлады. Димәк, аны аяк-кулларын бәйләп алып китеп баралар. Аны бер якка, Гөлйөземне икенче якка! Гөлйөзем исенә төшүгә, шытырдатып тешләрен кысты, йөрәге куырылып килде. Ул кайда хәзер? Аны нишләткәннәр? Нинди кабахәтләр кулына төште икән соң ул? Фәрештәмнең канатларын кем каерды?.. Ике күзеннән яшьләре агып төште. Ләкин ул аларны сөртә алмый, киндер капчык эчендәге яшь, чибәр, көчле егетнең иңсәләре генә калтырап-калтырап куя иде.

Күз яшьләре белән бергә чарасызлыктан интегү, рәнҗү, үпкә хисләре дә юылып төште бугай. Үз-үзен кулга алып, ихтыярын туплап ни эшләргә кирәклеген уйларга кереште.

Артык хәрәкәтләре белән игътибарны җәлеп итмәскә тырышып, аркасына каерылган кулларын кыймылдатырга тотынды. Кайчан да булса барыбер чишелер бит инде алар. Әмма төен шулкадәр тыгыз итеп, чиялап

бәйләнгән иде, күпме генә тырышмасын — бау бушамады. Аптыраудан, йөрәге әрнүдән бүтән чарасы калмаган Санька иреннәрен канаганчы тешләп, яткан урынында аунарга кереште. Чү! Кинәт аркасы ниндидер каты әйбергә килеп терәлде. Көчен җыеп шуңа омтылды һәм үзенең көймә кырыенда ятуын аңлап алды. Калын такталардан сумалалап, ныклап ясалган көймәнең кабыргалары эчке яктан берни белән дә капланмаган, алар тире эчендәге сөякләр сыман тырпаеп торалар иде. Саньканың куллары нәкъ әнә шул кабыргаларның берсе янында булып чыкты. Озак кармалана торгач, кабырга өстендәге ниндидер агач чөйне тапты һәм төенне шуңа эләктереп, салмак кына гәүдәсе белән алга тартылды. Ләкин капчык киндере комачаулый, киерелүгә үк төенне ычкындырып җибәрә иде. Ничә тапкыр бер үк хәрәкәтләрне кабатлагандыр, хәтерләми, ләкин инде булмый дип кул селтәргә җыенганда гына, бауның кинәт бушанып киткәнен сизеп алды. Озаклап бер җиргә ышкынудан капчык тишелгән һәм нечкә чөй куллагы бау арасына, төенгә килеп кергән иде. Түземлеген, соңгы көчен җыеп тагын бер талпынуга, бау чишелде, егет арыган кулларын угалады, җиңел сулап куйды. Аякны чишү өчен инде берничә мизгел дә җитә!.. Озакка сузарга ярамый! Санька көймәдән ничек качып китәсен, Казанга ничек барып җитәргә икәнен дә белми, әмма Гөлйөземнең «Акканатым!» дип кычкырган авазы күңелендә кабатланган саен, үзенең нәрсәдер эшләргә, йөгерергә, көрәшергә, кирәк булса, теш-тырнаклары белән сугышырга, теләсә кем белән бугазга-бугаз килергә әзерлеген тоя.

Куллары бушау шул юлда беренче җиңү иде. Өметенә таба тәүге адымны ясаудан канатланган Санька аякларындагы бауга үрелде һәм, якында гына кыштырдаган тавышлар ишетеп, тынсыз калды. Тирә-ягында кем бар икәнен белмәгән һәм тыпырчынуының кемнеңдер игътибарын җәлеп итү ихтималын аңлаудан бөтен тәне тораташ булып катты. Иреккә чыгам дигәндә генә...

Аяк тавышлары якынайганнан-якынайды, авыр гәүдәле кемдер тук мышный-мышный килде дә туктап калды. Бераздан аның бодай капчыклары өстенә сузылып ятканы ишетелде.

— Әйдә, сузыл шушында,— диде ул артыннан ияргән икенче берәүгә.

Озакламый аңысы да ятты булса кирәк, чакыру кабатланмады.

Саньканың түземе соң чиккә җиткән, кыл кебек тартылган бер халәттә ята иде. Җитмәсә, тамак төбе кыра, борынына тыгылган тузаннан төчкерәсе килә башлады. Ул ике куллап борынын кысты, корып, кытыршыланып калган тамак төбен төкерегә белән йомшартып, йөткерүдән сакланырга тырышты. Их, бер ярты гына чынаяк салкын су йотарга! Көймәгә бәрелеп чапылдаган дулкын тавышын ишетүгә, күзләре ачытып куйды. Су янында сусыз ятудан да газаплы нәрсә бар микән!

Аның колаклары шылт иткән тавышны да эләктереп ала, шуннан үзенчә нәтиҗә ясый, кайда кем барлыгын гөманларга тырыша. Аның монда икәнлеген беләме болар, әллә очраклы килгән кешеләрме? Менә, ниһаять, күршегә килеп яткан әдәмнәрнең берсе гырлый ук башлады. Икенчесе ризасыз тавыш белән эндәште:

— Йокы симертергә өлгерерсең... Мондый табышлы сәүдәдән соң рәхәтләнеп бер типтермәгәч, нинди алыпсатар син!?

Аның аңгәмәдәшен мыскыллабрак, үзен зурга куеп сөйләшүеннән Санька аңлап алды: Иван сәүдәгәр бит бу! Аны нишләптер яратып бетерми, сәбәбен үзе дә белми иде. Ләкин шунысын ачык тоя: Саньканың монда, торыпша астындагы капчык эчендә ятканын белсә, бөтен көймәгә шау-шу кубарачак, кешедән көлергә бер сәбәп табачак бу.

— Ә-ә... эй-е-е,— дип мыгырданды икенчесе йокы аралаш.

Шешәдән агач бөкенең шыгырдап чыгуы, калай чәркәләргә былкылдап сыекча акканы ишетелде. Эчемлек кабып куйдылар, тамак кырып ах-ух килештеләр. Саньканың авыз суларын китереп, казылык һәм яшел суган исе таралды.

— Син миңа тотын, югалмассың... Дөнья хәлен белеп, алдан күреп эш итүче бердәнбер купец мин,— дип мактанчык тавыш белән гөрелдәде Иван

сәүдәгәр — Савелий Кузьмич ул иске кеше, эш йөртүе дә үзе кебек. Менә сора син аннан бүгенге көндә патша хәзрәтләренә нинди малның кайтуы кирәгрәк дип. Белми ул аны, белә дә алмый, белмәячәк тә... Шул Угличы белән, базар хәерчесе белән саташкан карт ул... Ә мин... Мәскәү белән эш итәм. Мәскәү... ул инде Мәскәү! Аннан акмаса да тама. Бүреләр сугышканда безнең кебек каргаларга ризык мулдан буласы... Шулай бит!..

Янындагы яшьрәк тавышлы кеше аны хупларга ашыкты, ярарга тырышып хихылдавына ялагайлану төсмере чыкты:

— Дөрес әйтәсең, Иван дәдәй! Картның көймәбашы булырына да күп калмаган инде. Комы коела...

Санька ачудан йодрыкларын төйнәде, бу тавыш иясенең авызына ямаудан нинди рәхәт татыячагын уйлап, тешләрен шыгырдатты. Шул мизгелдә борынына ургылып тузан керде, эчләре актарылып чыгардай булып, киереләп төчкереп җибәрүен дә сизми калды. Бетте! Хәзер Иван сәүдәгәр бу якка сикерәчәк. Ул гәүдәсен бөгәрләп, үзе янына килеп баскан кешегә тибеп җибәрергә әзерләнде. Ни булса да булыр! Башка юл калмаган иде.

Эчемлектән җылынган Иван сәүдәгәр көтмәгәндә шаркылдап көлеп җибәрде.

— Кичкә таба бераз җиләсләнде... Дөрес сүзгә җавап юк. Ә син ашыкма-а,— дип суздьі ул.— Көймәбашына нәкъ шундый кеше кирәк... Казан белән дус кеше. Сезденме, тамгачылар тамга акчасын Савелийдан ничек алдылар?

— Ю-у-ук!

— Шул-шул! Ә мин күрәм, беләм. Әшнәләр бит алар. Таварын юньләп тикшереп тә тормадылар. Берәүне дер селкетерләр иде. Ә моңа... Аның көймәсендә булгач, безгә дә караш шулайрак...

— Аңа түгелдер... Арыган чаклары иде,— дип каршы төшә башлаган сәүдәгәрне Иван тиз туктатты:

— Алдарсың Казан тамгачыларын!.. Җитте! Йә тагын төчкерә башларсың... Салыйк!

Тагын касәләр чәкелдәште. Иванның шапырынуыннан туя башлаган Санька түземсезләнеп аларның китүен көтә иде. Шул ук вакытта исерек сәүдәгәрнең тугарылып мактануы, акча, мал табу ысулларыннан уртаклашуы гыйбрәтле, егет барысын да хәтеренә сеңдерергә тырышты.

Чираттагы йотым Иванның телен тагын да чишә төште:

— Менә мин бу ярминкәдән дә, искечә әйтсәк, йөз бәлиш[1] мая туплап кайтып барам. Эчне тишми бит. Алтын бәлиш биш мыскал, көмеш бәлиш сигез дирһәм көмеш авырлыгы... Шуның чиреге тамгачылардан йомып калынган, өч чиреге патша хәзрәтләре казнасыннан...

— Ни-и-чек?

— Патша казнасы хисабына йөргән сәүдәгәр алтын тапмаса, башын салсын! Ха-ха-ха...

Җәелеп көлә башлаган Иван кинәт кенә туктап калды да күршесенә ысылдады:

— Әгәр бер-бер сүз чыгарсаң!.. Эчәгеңне актарып этләргә ташлармын. Аң бул! Идел төбендә синең ишеләр берәү генә түгел!..

— Аллам сакласын! Без синең белән бер җепкә бәйләнгән... Җаным фида... Белмим дә, ишеткәнем дә юк...

Иван канәгать тавыш белән кеткелдәп алды һәм тагын җәелеп сөйләргә керешге.

— Вот то-то!.. Дөньяның кая таба әйләнгәнен белсәң, патшага да ярарсың, аллага да... Үзеңне дә рәнҗетмәссең.— Ул тагын пышылдауга күчте:— Казан тәхетенә янәдән Сафа Гәрәй утырды. Беләсең, ул Кырымйорттагы Сәхип Гәрәйнең бертуган энесе. Гәрәйләр белән шаярырга ярамый. Алар ягында нинди көч торганын беләсең. Мәскәүгә ярлык җибәргәннәр, имеш. Патшаның Казан өстенә йөрмәвен таләп кылганнар. Басурман Сәхипнең сүзләрен җиткергәннәр: «Әгәр дә Казанга кул күтәрсәгез, без хәзер сез-

[1] Бәлиш — акча берәмлеге.

нең өстегезгә әүвәлге шикелле коры татар гаскәре белән генә бармабыз. Минем үземнең тупчыларымнан башка төрек солтанының йөз мең атлы гаскәре бар. Син уйлама ки, мин Мөхәммәт Гәрәй шикелле коры гаскәр белән генә барырмын дип, юк, хәзер минем көчем аныкыннан күбрәк барачак. Казан җире минем йортым. Сафа Гәрәй хан — минем борадәрем». Шулай булгач, патша хәзрәтләренә бүгенге көндә ни кирәк? Табигый ки, корал кирәк. Мин төяткән йөкләрдә исә син атаң башы дип беләсеңме? Һа, юк! Корал ул. Иван ни эшләргә кирәген белә. Патшаның ни теләгәнен белә Иван... Әле тагын йөз алтын алмасаммы галиҗәнаб кулыннан. Исемем Иван бул-л-мас-сын! Мин — аның йом-мыш-чы-сы!.

Ул кикереп куйды, теле тотлыга башлады. Шешә төбендә эчемлек кими барган саен Иванның теле чишелә бара, мактанчыклыгы арта иде.

Хәрәкәтсез яткан Санькаының буыннары оеды, ул түземсезләнеп сәүдәгәрләрнең китүен, йә булмаса исереп йокыга талуларын көтә. Кайчан да булса бу исерек лыгырдауга чик куелырга тиеш бит инде! Ниһаять!.. Иван белән аның юлдашы тындылар, аларның бер-берсен уздырырга тырышкандай нечкәле-калынлы тавыш белән гырлаганнары гына ишетелә башлады. Житте! Кузгалырга! Санька чалбар кесәсеннән пәкесен чыгарды һәм ялт иткәнче аяктагы тышауларын өзгәләп ташлады, саклык белән генә капчыкны кисәргә керешге.

Күк йөзендә йолдызлар калыккан. Тирә-як тып-тын. Караңгы. Шыплап мал төягән зур көймә, җилкәннәрен төшереп, Идел уртасында йокыга талган иде. Су төбенә ташланган тимер ыргакның арканы киерелеп тартылган, көймә янында бәргәләнүче дулкыннарның чайпалуы гына ишетелеп тора. Казаннан тизрәк китәргә һәм киң суга чыгарга ашыккан көймәчеләр дә, мал төятеп арыган сәүдәгәрләр дә тирән йокыда.

Әле моңарчы ни кыласын белмәгән Санькаының башында бер фикер оешып та өлгерде. Караңгылыкка иялөшкән күзләре яхшы күрә, кайда ни ятуын, кемнең кайда йоклавын да абайлап алды. Сакланып кына капчыктан чыкты, этисен күреп күзләренә яшь тыгылса да, аның янына барырга кыймады. «Их, эти, эти, аңламадың. Бу эшкә мине үзең мәҗбүр итәсең,— дип уфтанып пышылдады.— Гаеп итмә, ачуланма улыңны. Башкача булдыра алмыйм. Шулай кирәк, эти. Әле Казанга соңгы килүең түгел. Күрешербез, очрашырбыз. Кайчан да булса бер аңлашырбыз».

Күзләренә тыгылган яшьне сөртеп тә тормыйча, пычагын тотып Иван сәүдәгәргә таба шуышты. Анысы исә капчыклар өстендә чалкан яткан, кулларын як-ягына сузып җибәргән, ярымачык изүендә исә бүлтәеп күн янчык беленеп тора иде. Санька аз гына уйланып торды һәм янчык асылган бауны эзләп табып, үткен пычак белән аны сиздерми генә кисеп тә төшерде. Янчык авыр иде. Санька аны төйнәп муенына асты, тирә-юньгә тагын бер кат күз йөртеп чыкты һәм көймә кырыена шуышты. Башта капчыкны, аннары торыпшаны суга төшерде һәм этисеннән пышылдап гафу үтенгәч, үзе дә Идел кочагына кереп китте, тавыш чыгармаска тырышып, еракта күгелҗемкара булып күренүче ярга таба йөзеп китте.

Идел буенда туган, балачагыннан дулкыннарга колач салып үскән егеткә елга үзе ярдәм итә иде кебек. Ул тавыш-тын чыгармаска тырышып, акрын гына ишүен белде. Көймә шактый еракта калды. Менә инде су өстендә аның шәүләсе дә абайланмый. Баштарак бик якын тоелган каралҗым текә яр исә һаман үз урынында, әйтерсең, Санька йөзми, бер урында тора. Казанның сул як ярда урнашканлыгын төгәл белгән егет, алга карап йөзде дә йөзде. Кайчан да булса барыбер шул ярга килеп чыгачак бит ул. Муенга эленгән авыр янчык аска тарта, итекләренә су тулды, алар төпкә сөйри башлады. Кулларындагы бау кырган җәрәхәтләре ачыта, җитмәсә, каяндыр килеп чыккан дулкын башыннан ук күмеп үтте. Егетнең авызына су тулды, тыны каплан- ды. Япа-ялгыз төнге Идел өстендә калу шомландыра, аңлаешсыз курку хисе йөрәкне кыса. Арыган кулларны ял иттерим дип ишүдән туктауга ук гәүдә аска омтыла. Егет тәмам арыды, гәүдәсе авырайганнан-авырайды. Башка чара юк иде, ул күкрәген тутырып сулу алды да дулкын астына чумды һәм юеш чолгаулардан тыгызланган итекләрен көч-хәл белән салып аткач,

жиңеләеп тагын су өстенә калыкты. Күкрәгенә дымлы, сафландыргыч һава тулды. Соңгы көчен җыеп, яңадан йөзәргә керешә. Әмма көче кимегәннән-кими, акча янчыгы муенга бәйләнгән таш кебек аны аска сөйри иде. Юкса, әнә чыгып җитәргә дә күп калмады. Куе агачлыклар белән капланган яр якын гына. Ләкин ул шулай тоела гынадыр. Кемдер аны үрти, ярны якын күрсәтеп алдый, ымсындырадыр.

Кылт итеп башыннан узган уйдан кул-аяклары хәрәкәтсез калды: «Хәрам мал мине төпкә сөйри. Шуның җәзасы бу! Кеше әйберенә кул суздым».

Кайдадыр бер якта су чапылдаганы ишетелде, тамчылар чәчрәгән кебек булды.

— Су иясе... Беттем! Аның белән очрашканчы хәрам акчадан котылырга кирәк!

Санька калтыранган хәлсез бармаклары белән муенындагы җепне өзәргә азаплана башлады, әмма суда тагын да тыгызланып калган калын җеп бирешми, ул агач кебек каткан иде. Аны бары пычак белән генә кисеп булачак. Кесәсенә тыгылды. Тар кесәдән пычак чыгарырга азапланган арада тагын төпкә китте. Сөяк сап кулына эләккәндә инде ул шактый су йотып өлгергән иде. Атылып өскә чыкты, кабаланып, мәңге туймастай булып еш-еш сулады һәм пычакны кыныннан алырга тырыша башлады. Элекке вакытта чалкан ятуга бишектәге сабыйны тибрәткәндәй бәллүләтеп торган Идел аны күтәрергә теләми иде. Бөтерелчек чоңгылга туры килдеме — таш кебек төпкә китте. Агымнан котылырга теләп бәргәләнгән арада шома сапның кулыннан ычкынганын сизми дә калды. Чумган хәлдә бөтерелеп аккан су уңаена ыргылды һәм тагын өскә чыкты. Хәле беткән, ул соңгы чиккә җитеп тартыша, яшәү өчен теше-тырнагы белән көрәшергә омтыла иде. Әмма хәрам мал аны ычкындырырга теләми. Көчле агым белән берләшеп, алар Саньканың җанын даулыйлар, дәһшәтле тирәнлеккә суыралар иде. Егет янчыкка ике куллап ябышты, чияләнгән төенне тешләре белән чәйнәргә керешә. Шул мизгелдә су өермәсе аны бөтереп алып та китте. Күз аллары караңгыланды һәм... әллә нинди сәер балкышта соңгы тапкыр Гөлйөземне күрде. Кара чәчләрен иңсәләренә таратып салган кыз кочагын җәеп аңа каршы йөгерә, нәрсәдер әйтеп кычкыра, тик тавышы ишетелми иде. Саньканың йөрәгеннән үкенеч уты чолгап алды, авызын ачып: «Көт мине, мин киләм»,— дип кычкырмакчы булды. Иреннәре аша саркылып су керде. Күз ачып йомган арада сурәт юкка чыкты, әллә кайдан гына этисе, шелтәле карашы белән бәгырен телгәләп әнисе пәйда булды, сөекле абыйсы — бергә уйнап үскән иң кадерле дусты Васька йөгереп узды. Алар барысы да Саньканы каядыр чакыралар, кул изиләр иде. Агым ирегенә бирелгән егетнең инде көрәшер ихтыяры, ташкынны җиңәр көче калмаган иде. Алтынлы янчыкны умырып тоткан килеш ул соңгы тапкыр талпынды да тынды. Дөнья дөм караңгы пәрдә белән капланды, яшелле-зәңгәрле утлы бөҗралар биеште дә... барысы да бетте.

## Көймәдә

Бер сәгать гадел кыйлмак яхшырак,<br>Кем гыйбадәт алтмыш ел озаграк.

МӨХӘММӘДЬЯР, XVI йөз шагыйре.

Җәйге төн кыска. Арыган-талган тәнгә сихәт китерүче йокы ләззәте керфек очына кунарга да өлгерми, сызылып таң ата башлый. Әмма кичке ыгы-зыгы, качып киткәндәгедәй ашыгычлык белән дәррәү кузгалырга, юлга җыенырга мәҗбүр булган сәүдәгәрләр, көймәчеләр җәйрәп йоклый. Малтабарлык хирыслегеннән айный төшкән, алҗыган кешеләрне колак төбендә туптан атсаң да уятырлык түгел иде.

Идел өстен куе караңгылык пәрдәсе баскач кына башын мендәргә куйган Савелий Кузьмич бастырылып уянып китте.

— А-а-ха-а-а!..

Аның куркынган, карлыккан тавыш белән илереп кычкыруыннан көймәдәгеләр боргаланып куйды, кемнеңдер йокы аралаш дога укып мыгырданганы, кемнәрнеңдер усал итеп сүгенгәне ишетелде.

Карт сәүдәгәрнең күкрәге, әйтерсең, биш батманлы капчык астында калгандай кысыла, сулыш ала алмый интегә иде. Гүяки, ниндидер албасты аның муеныннан буып алган да, изә, сыта, аны көймә төбендәге такталарга сылап куярга тели иде. «Нәрсә соң бу? Нинди гөнаһ шомлыгы?.. Бер-бер чир зәхмәте ябыштымы?» Ул күкрәген уа-уа торып утырды һәм кичен газиз углы ягына күз дә салмавыннан имәнеп, бу авырту-сызлануның сәбәбенә төшенде. Бигрәкләр дә ачуын чыгарган иде шул Санька. Улы турындагы авыр уйлары, кичерешләре, бәйдән ычкынгандай кыланучы төпчегенең хәленә керергә теләп тә, аны аңлый-төшенә алмавы, кара колдай аяк-кулын бәйләп салырга туры килүеннән туган бәргәләнү, чарасызлыктан, гаҗизлектән туган җан газабы иде бу.

«Әйдә, каты кулның, атага буйсынуның ни икәнен белсен! Талны яшь чагында бөгәләр. Хәзер бөкмәсәң, соңрак сындырырга туры килмәгәе»,— дип, үч итеп, аның янына юри бармаган, җәзасының катылыгын җанына үткәреп белгертергә, ачуының тирәнлеген сиздерергә теләгән иде. «О боже милостивый! Спаси и сохрани! Инде шәт төшенгәндер, сугымлык мал кебек бәйдә ятуның ачылыгын тойгандыр, суынгандыр. Җүләр булмаса аңлар! Дөнья кендегенең бер Казан кызына гына бәйләнмәгәнлеген дә төшенер, иншалла! Яшь чагында барыбыз да бер дуамалланып алабыз инде. Капчыктан чыгарырга кирәк. Озакламый кузгалырбыз, казанлылар мәмләкәте арттa калыр». Авыр уйларыннан чайкала-чайкала, бер-берсенә сыенып яткан көймәчеләргә басмаска тырышып, ул койрыкка, ашлык төялгән якка таба кузгалды.

Аның кузгалуын гына көтеп торгандай, көймәчеләр, сәүдәгәрләр кыймылдый башлады. Иртәнге салкынча һавадан бөрешеп калган малтабарлар җылыну өчен тиз-тиз хәрәкәтләнергә, үз-үзләренә суккаларга, авыз ачып киерелергә керештеләр.

Савелий Кузьмич уртадагы җилкән күчәренә менеп басты да кулын маңгаена куеп койрыкка текәлде. Көймә кырыена сузып салынган капчык юк, бодай көшеле өстендә ике кулын ике якка сузып җәйрәгән Иван сәүдәгәр белән аңа сыенган яшь алыпсатар гына ята иде. Эче жу итеп китте! Әллә нинди куркыныч, шомлы сизенүдән теле аңкавына ябышып калды, күкрәгеннән ыңгырашуга охшаш сызлану авазы чыкты. Кибеп, корып калган авызында теле буйсынмый, әйтерен әйтә алмый изаланды. Ниһаять, күкрәгендә барлыкка килгән төер йотылды, дәһшәтле тавыш белән кычкырып җибәрде:

—Сань-ка-а! Ул-ы-ы-ым!

Үз-үзен белештермичә җан көче белән әйтелгән чакыру авазы Идел өстеннән ерак-еракларга, куе урман каплаган биек ярларга барып җитте, кайтаваз булып көймә өстендә бәргәләнде.

— Сань-ка-а-ау-у-у-лы-ым!

Иван сәүдәгәр үзенә сыенган егетне читкә тибәреп торып утырды, сөякләре шатырдаганчы киерелеп иснәде һәм каты махмырдан айнып җитмәгән кешеләрчә алпан-тилпән атлап көймә читенә килеп басты. Ярминкәнең төшемле үтүеннән кабат сөенеп, җанга-тәнгә рәхәт бирүче янчыгын сыйпарга куенына үрелде. Калтыранган кулы йонлач күкрәге буйлап аска шуышты, кесәләренә суккалады һәм каударланып ике кулы белән дә үз-үзен капшарга тотынды. Бер мизгел эчендә махмыр зәхмәте онытылды, күзләрен кан басты һәм ул, кыргыйларча үкереп, йоклап яткан иптәшенә сикерде.

— Анаңны... кабер такталарын актарып, җиде кат җир астыннан... Минем белән шаярыргамы?!

Күз ачып йомганчы ул яшь сәүдәгәрне изүеннән һәм сыңар ботыннан умырып баш өстенә күтәрде.

— Әйт, кабахәт, янчык кайда? Алтын кайда? Бәрәм, суга тондырам...

Йокысыннан айнып җитмәгән егетнең күзләре шардай ачылды, куллары тотыныр әйбер эзләп чапаланды, теле тотлыкты:

— Нин-нин-ди... ал-ал-тын?.. Нишлисең... Иван дәд-дәдәй...—дип мыгырданды ул.

— Эчәгеңне актарып балыкларга ташлыйм, эт җан! Әйт! Синнән башка беркем дә белми иде,—дип кабатлады Иван һәм корбанын болгый-болгый көймә читенә якынлашты.

— Әйт, әҗәлең килеп җитте. Юкса...

Яшь сәүдәгәр эшнең нидә икәнен аңлап алды булса кирәк, еламсырап такмакларга тотынды:

— Ипи чыраен күрмим... Мин түгел, Иван дәдәй! Мин түгел... Эзләп кара. Мин түгел... Алла шаһит...

Иванның ачуы басыла төштеме, ул егетне селтәнеп бодай көшеле өстенә бәрде, тешләре арасыннан ачулы зәһәр янау сүзләре сытылып чыкты:

— Кара аны... һәр бөрмәңне тикшерәм... Әгәр дә, эт җан, алдасаң... Чишен, кабахәт, кай җиреңә тыктың?..

Савелий Кузьмич килеп җиткәндә ул бөгәрләнеп яткан егетне ярсый-ярсый типкәләргә керешкән иде инде.

— Чү! Тукта! Тел белән аңлатып булмыймыни?—Карт сәүдәгәр үзенең кайгысын оныткандай, мөмкин кадәр сабырлык күрсәтеп эндәшергә тырышты, ике куллап Иванны тотып алды да читкә тартты.

— Тукта дим! Ни булды? Аңлатып сөйләш!..

— Анасын... алтынны урлаган. Ул гына белә иде,—дип ярсуын баса алмыйча гырылдады Иван.—Җибәр! Җанын чыгарам мин аның...

Савелий Кузьмич аны кулыннан ычкындырды һәм яшьләрчә җитезлек белән араларына сикерде.

— Акылыңа кил, Иван! Алган булса да, көймәдән кача алмас. Бәлки, ул да түгелдер... Сабыр... Тикшерик. Аны үтереп кенә алтыннарың кире кайтырмы?..

Соңгы дәлиле тәэсир итте булса кирәк, Иван аларган күзләрен Савелий Кузьмичка текәп катып калды, йодрыгын йомарлап, ярсуына чыдый алмый тешләрен шыгырдатты.

— Йә, хәзер инде сабырлык белән генә уйлашыйк,—диде Кузьмич акрын гына. Салмаклыгы, басынкылыгы белән ул Иванның ачуын басарга, башкаларда ярсу уятмаска тырыша иде.—Нахак бәла тагудан да аяныч, үкенечле нәрсә юк. Үз өстеңә гонаһ алма!

Шау-шуга, көймәне дер селкетеп сугышуга уянып өлгергән сәүдәгәрләр, көймәчеләр аларны уратып алган иде инде.

— Нәрсә булган?

— Кем урлаган? Кемнекен?

— Һи, үзе төшереп калдыргандыр әле. Иванныкын алырсың, бар,—диде кемдер ризасыз тавыш белән.—Бәйләнергә сәбәп кенә эзләмиме?! Беләбез без...

Икенчесе аңа каршы төште:

— Ай-һай, Иван төшереп калдырамы? Кемнеңдер шакшы кулы уйнаган, иманым камил...

Артык сузарга, сәүдәгәрләрнең көймәчеләрдән, аларның исә малтабарлардан шикләнеп тавыш, җәнҗал кубаруына, бер-берсенә кул күтәрүгә юл куярга ярамый иде.

— Йә, иң элек тикшерик. Бөтен кеше дә көймәдәме?—диде Кузьмич тирә-якта күтәрелә башлаган шау-шуны күмәрлек каты тавыш белән.

— Саныйк! Әйдә, кереш, өлкән көймәче!

Утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге, куе кара сакаллы, әзмәвер гәүдәле ир авыз эченнән мыгырдый-мыгырдый, һәркемгә бармак төртеп санарга керешә:

— Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Әйләнә-тирәдәгеләрне санап бетергәч, ашыгып бодай көшеле өстенә, көймә кырыена күз төшереп алды, теле тотлыкты:

— Йоклап калганнар юкмы? Икәү җитми бит, Савелий Кузьмич,— диде ул. Аның йөзе агарып китте, маңгаена тир бәреп чыкты.

— Кемнәр юк?

Көймә башын уздырып, сәүдәгәрләрдән берәү мыскыллы тавыш белән сорап куйды:

— Ә үзеңне санадыңмы?

Каушаудан үзен исәпкә кертергә онытккан көймәче ачу белән җиргә төкерде, күкрәгенә бармагын төртеп тагын кабатлады:

— Барыбер бер кеше җитми бит, Кузьмич!

Инде күптән кем юклыгын чамалаган сәүдәгәрнең тагын йөрәге авырта башлады, йөзе кәгазьдәй агарды, сулышы кысылды.

Егетне бәйләп алып кайтуда катнашкан һәм бу хакта кешегә ләм-мим сүз әйтмәскә кушылган көймәченең дә хәле шәптән түгел, ул үзен гаепле санап башын түбән игән һәм колларча буйсынучанлык белән карт сәүдәгәрнең әмерен, хөкемен көтә иде.

Аларның нәрсәдер пышылдашуын күреп алган Иван кинәт мәчедәй җитезлек белән Савелий Кузьмичка ыргылды.

— А-а-а! Әнчегеңне яшердеңме? Әйт, кайда ул! Кайда?.. Ник дәшмисең? Ул урлап качкан. Ул... Алтын карагының атасы!..

Улын югалту газабына нахак яла ачысы кушылган карт сәүдәгәр түзә алмады, Иванның бугазыннан буып хырылдады:

— Җиттеме сиңа, юкмы?! Алтының белән буыл, тамагыңа тыгылсын! Тик телеңне генә тый!

Карттан мондый да җитезлек, beləгендә, батманлы гердәй йодрыгында мондый да көч-куәт яшеренгәнлеген көтмәгән Иванның башы бер якка салынып төште, бармаклары белән аның кулын кубарырга көчәнеп караса да, булдыра алмагач, күгәрә башлаган иреннәре арасыннан ризалыгын чыгарды:

— Булды... җибәр... әйтмәм...

Кулын бушата төшсә дә әле һаман аны ычкындырмаган Савелий Кузьмич һәр сүзен кистереп, утыртма читәнгә сыер тизәге чәпәгәндәй өздереп-өздереп кабатлады:

— Алтының үзеңә кайтыр. Малайны тапсак та, тапмасак та! Тик дәшмә, җанымны кыйнама! Санькада эшең булмасын. Юкса!..

Гайрәте шактый ук шиңгән Иван акланырга теләгәндәй сөйләнде:

— Миңа нәрсә... Кем алган, шул кайтарсын. Гаделлек өчен әйтүем... Сәүдәгәр бер-берсен алдый, талый башласа, кемгә ярар. Мин риза, риза, Савелий Кузьмич...

Картның тимер йозак булып каткан бармаклары акрын гына язылды. Иван муенын сыйпаштырып, башын боргалап алды һәм карт яныннан читкәрәк китеп, тагын үзенекен кычкырды:

— Белеп тор, Савелий Кузьмич! Алтыннарымны кайтармыйча барыбер тынмам... Белеп тор!..

— Җитте! Күпме иде алтының? Бар халык каршында әйтәм: барысы да үзеңә кайтыр... Тик борыныңа киртләп куй: Санька алмаган булса, гөнаһысы үзеңә... Җәһәннәм ялкынында куырылганда исеңә төшәр, еландай телләреңне чыгарып ялынырсың, соң булыр!..

Иванның кашы астында яшел күзләр ялтырады.

— Төп-төгәл ике йөз бәлиш иде,— диде ул кистереп һәм әле һаман да сынын җыя алмыйча бодай өстендә бөгәрләнеп яткан яшь сәүдәгәргә ымлады.— Әнә, шаһитым бар. Ул белә иде. Әйт, шулай идеме?

Яшь сәүдәгәрнең канлы иреннәре көч-хәл белән кыймылдады:

— Шулай!.. Нәкъ ике йөз бәлиш иде...

— Әтә-тә-тә... Никадәр байлык,— дип тел чартлатты кемдер.— Ай-һай, шулкадәр мөлкәтне үзе белән йөртер микән?..

Гаепне Санька өстенә аударып хата эшләвен, малтабарлар арасында дәрәҗәсен, абруен какшатуын белсә дә, Савелий Кузьмич телен тешләде. Малаеның югалуы аның ихтыярын сындырган, рухын изгән иде. Дөресен әйткәндә, улының кеше малына кул сузарына ул ышанмый, аның туры сүзле, гадел, саф күңелле икәнлеген белә. Ташаяк ярминкәсендәге кирелеге,

үҗәтлеге аңлашылмый, авырттырып җанын тырный иде. Ә хәзер?! Ахыры болай бетәчәген белсә, Казанда бер көн генә түгел, бер атна, бер айга калырга да ризалашыр иде. Их! Үткәнне кайтарып булмый шул!

...Көймә читенә кертеп ташланган капчыкта Санька ятканлыгын, аның тәнлә капчыгы-ние белән юкка чыкканлыгын әле генә аңлап алган сәүдәгәрләр бер-берсен бүлдерә-бүлдерә гөман кылырга, бәхәсләшергә керештеләр:

— Аягы-кулы бәйле кеше суга ничек төшсен!? Башыма сыймый. Аңлый алмыйм. Аллам сакласын, монда нинди дер явыз көчләрнең, елга иясенең кулы уйнамагае.— Картрак сәүдәгәрләрнең берсе чукынып, ашыга-ашыга дога сүзләрен мыгырдарга кереште.— Тизрәк кузгалырга кирәк! Каһәрле урын бу!..

— Ай-һай, капчыктагы егет ничек Иванның алтынына кул сузды икән?.. Ышанмыйм,— диде икенчесе башын чайкап.— Саньканың суга төшеп китүе хак булса да, алтынны алуы — нахак. Савелий Кузьмич үз өстенә күрәләтә ялган гаеп такты.

— Мин болайрак фикер йөртәм: яшь җан бит, хурлыгына түзә алмыйча бәргәләнгәндер, чыгарга итеп дулагандыр... Шулай бит!.. Дулаган гәүдә көймә читеннән суга ычкынмас дисеңме?

— Анысы шулайдыр да... Бәлки... Әмма Иванның алтыны кая киткән?! Менә монысы хикмәт, табышмак...

— Ышанасың икән, аның ач күзлеген кем белми. Саньканың юклыгын сизеп юри кыланмас дисеңме,— дип каршы пышылдады аңа яшьрәк сәүдәгәрләрдән берәү.— Алтын дигәндә, акча дигәндә газиз анасын сатып җибәрергә дә күп сорамас...

Телләре белән әйтмәсәләр дә, арада бер-береннән шикләнү, су ияләренең үченнән шомлану тойгысы уянып килә иде. Бу хәлнең озак дәвам итә алмаячагын белгән Савелий Кузьмич кайгысын, газабын читкә куарга тырышты, көймәбашы буларак дилбегәне ычкындырырга ярамый иде. «Һич югы, үле гәүдәсен булса да табарга кирәк. Угличка ни йөз белән кайтып күренермен?!» Аның күз алдында улының зифа буе, балаларча кабарынкылыгы да чыгып бетмәгән чиста чибәр йөзе килеп баса, очкынланып торган чаткылы зәңгәр күзләре пәйда була. Эчендәге ялкынны йотып, аһ оруын кешеләргә сиздермәскә тырыша. Аның яшьләрчә төз, таза бәдәне, әйтерсең, ун елга картайды, суырылып калды, маңгаендагы җыерчыклары тагын да тирәнәя төште.

— Каекларны суга төшерегез! Гәүдәсен эзләп карыйк. Һич югы...

Улының үлеме белән ризалашырга теләмәгән ата кешенең тавышы киселде, күзенә тыгылган яшьләрен кул аркасы белән сөртеп, башлаганын әйтеп бетерерлек көч тапты:

— Тапмыйча кайтмыйбыз...

Көймәчеләр ашыгып каекларга ташланды. Карт сәүдәгәрнең сүзсез ыңгырашуын, эчтән сызуын күреп тору, яшь, чибәр егетнең хикмәтле югалуы аларны да газаплый, аны бәйләп ташлауда үзләрен дә гаепле тою исә бу әрнүне тагын да көчәйтә төшә иде. Нәрсә дә булса эшләргә кирәклеген аңлау аларга җиңеллек китерде булса кирәк, берничә мизгелдән көймәнең борынына һәм койрыгына каплап салынган җиңел каеклар шапылдап суга төште, аларга ишкәк, колга, озын ыргак тоткан таза ирләр сикерде. Елга агымы уңаена суны иңләп өч каек йөзеп китте.

Әле һаман тынычлана алмаган, ярсуын ничек басарга белмәгән Иван көймә койрыгында аларны озатып калды. Аның чыраена кара күләгә иңгән, иреннәре кысылган, яшькелт күзләре тирә-юньне ачу белән бораулый иде.

Кинәт миен кисте реп узган көтелмәгән уйдан аның йөзе чалшаеп китте, кулларын болгап кычкырып җибәрде:

— Әй, туктагыз! Мине дә алыгыз! Бәлки, ярдәмем тияр...

Каекларның берсе борылып көймәгә якынлашты, Иван ашыга-ашыга чукынып каек төбенә сикерде.

— Аллага тапшырдык! Минем күзләрем үткен! Бәлки табарбыз да әле. Нинди кайгы, нинди олы кайгы,— дип сөйләнде ул, акланырга теләгәндәй.

Башында исә бөтенләй башка төрле уйлар чәбәләнә иде. «Әгәр тапсак, алтыннарым Санькада булмаса... Яки анда булса?.. Ничек кенә борсаң да, ике чабата бер кием, икесе дә зыянга. Тапкан суәттә йөз бәлиштән колак кагачаксың. Тапмау хәерлерәк... Тапмауның хакы — ике йөз бәлиш...»

Корылган хәйләсенең зирәклегеннән, фикеренең үткенлегеннән разыйканәгать булып ул кулларын угалады, иртәнге югалту ачысы онытылды, күңелендә өмет катыш сөенеч хисе бөреләнә башлады. Йөзенә кырыслык бирергә тырышып, кулын маңгаена куйды һәм игътибар белән тирә-якны күзәтергә кереште. «Мәетне беренче булып күрергә, аның янына каекчыларны ничек тә читкәрәк юнәлтергә кирәк».— дип уй корып куйды ул. Аннан соң күңелен тагын шөбһә басты. «Әгәр каекчылар күрсә?! Икесенә егермешәр бәлиштән телләренә йозак салып булырмы? Егерме бәлиш! Бу аңгыра сарыкларның төшенә дә кергән мал түгел! Шәт, ризалашырлар...»

Каеклар, бер-берсеннән яртышар чакрым ара калдырып, агым бәргән ярга таба юнәлде. Беренчесендә Савелий Кузьмичның кайгыдан сыгылган гәүдәсе шәйләнә.

— Йа алла! Газиз улымны, сөекле Александрымны, төпчегемне табарга ярдәм ит! Рәхмәтеңнән ташлама! Аны артык нык яратканга бирдеңме әллә миңа бу газапларны?

Савелий Кузьмичның иреннәре бертуктаусыз пышылдый да пышылдый, рәнҗүен, газабын күк ияләренә, бөек аллага, фәрештәләргә ирештерергә тели. Аңа ярдәм итәрлек затлар юк микәнни соң? Һич югы гәүдәсен кочаклап хушлашырга, сөекле улының газиз тәнен күз яшьләре белән юарга да насыйп итмәс микәнни?

Каеклардагы ирләрнең йөзләре кырыс, иреннәре кысылган, күзләре су өстендәге дулкыннарда. Агып килүче бер генә нәрсә дә аларның карашыннан читтә калмый. Әмма чал Иделнең кеше газапларында гаме юк. Ул ярларын тутырып, ерак-ераклардагы Хазар диңгезе белән кавышырга ашыккандай, түбәнгә ургыла да ургыла. Кочагына алганны чоңгыллар кире чыгармый. Салмак тирбәлешеп, бер-берсен куышкан салкын дулкыннар астында нинди генә серләр, нинди генә билгесез нәрсәләр юктыр!

Башкалардан арттарак яр буйлатып килгән каекта аягүрә баручы Иван сәүдәгәрнең йөрәге дерт итеп китте. Аның үткен күзләре Идел суын ярып кергән комташлы борын хасил иткән култыкның түрендә, тирә-ягын камыш баскан тымызык су өстендә соры бер нәрсә күреп алган иде. Агым уңаена төшүче каектан култыкны таллык каплаганын күтте дә ишкәкчеләргә эндәште:

— Егетләр, чак кына сабыр итегез әле. Теге култыкны карап килим. Кем белә...

Каек уртасында ишкәкләргә парлап утырган көймәчеләр борын артына уелып кергән култыкны күрми калганнар иде. Алар риза булды. Каек ишкәкләрен салмак шапылдатып, таллыкка якынлашты. Яр буена җитәр-җитмәс Иван суга сикерде һәм бил тиңентен төшеп тә китте. Аның карашы, ус култык эчендәге соргылт нәрсәдә иде, ул күн итек кунычыннан тулган пычрак ләмне сизмәгән дә кебек, лачтыр-лочтыр атлап куаклыкка кереп тә китте. Битенә бәрелгән ботакларны, кычыткан яндыруын ул тоймый, алай-болай ишкәкчеләр төшмәсен дип шикләнә һәм очып кына карап килә алмавына үртәлә иде.

Менә таллык артта калды. Илле адымнан да киң булмаган култык дигәне култык түгел, талгын гына агып ятучы җинсә, борынга санаганы — кечкенә утраучык икән ләбаса. Иван эре адымнар белән сикереп атлый-атлый әле ерактан ук күзе төшкән соргылт нәрсәгә ыргылды. Килеп җитте дә күн итек очы белән типте, тирә-якка су чәчрәде, аягына эләгеп, сүсемнәргә уралган киндер капчык килеп чыкты. Таныды Иван. Савелий Кузьмич ашлык тояга торган капчыкларның берсе иде бу. Әнә җөй кырында ак җеп белән салынган тамгасы да күренеп тора — «С. К.». Иван иелеп аны җәеп карады һәм капчыкның нәкъ уртасыннан — бәйләгән җиреннән түбәнәчә пычак белән урталай ярылганлыгын күреп алды. Ирен читенә мыс-

кыллы елмаю чыкты: «Без уйлаганча ук мескен түгел бу Санька. Килештерә белгән...»

Капчыкны тиз генә бөтәрләп яңадан су төбенә ташлады һәм ярдан олы таш китереп, бастырып та куйды. «Табылуына караганда үле саналуы хәерлерәк»,— дип уйлап куйды ул һәм тиздән кулына керәчәк алтыннарны исенә төшереп, канәгать елмайды, ашыкмый гына каекка таба атлады.

— Йә, нәрсә?— дип дүрт күз белән көтеп торган ишкәкчеләргә уфтанып кул селтәде.— Ялгышканмын!.. Эт үләксәсе...

Каек тагын агым буйлап төшеп китте.

Кич якынлашты. Иртәдән бирле локма ризык капмаган базар әһле һәм көймәчеләр сүзсез. Берни таба алмаган каекчылар арып-талып әйләнеп кайтты. Артык эзләүнең мәгънәсез икәнлеген күпләр аңлаган, ләкин кинәт башына төшкән кайгыдан күз алдында картайган Савелий Кузьмичны аяп, нәрсә дә булса әйтергә кыймый торалар иде.

Ә карт сәүдәгәр тирә-якта ни барын, малтабарлар һәм көймәчеләрнең ризасызлыгын, әйтерсең, күрми, сизми. Аның үз уйлары. Кайгысы йөрәген кыса, үзе белән улын да алырга карар кылган сәгатькә ләгънәт укый, үзен тирги, ни-нәрсә кылырга белмичә җаны бәргәләнә иде. Ул авыр сулап соңгы өмерне көткән көймәчеләргә, юлга берләшеп чыккан сәүдәгәрләргә күтәрелеп карады да, икеләнүен җиңеп, хисләрен чыгарды:

— Казанга кире кайтсак ничек булыр икән?! Күңелем сизенә, шунда булмагае... Батмаган ул... Юк! Ышанмыйм... Ышана алмыйм. Ул Казанда, йөрәгендә тәүге мәхәббәт уты кабызган калада. Соңгы тапкыр талпынып карыйк. Улым, төпчегем бит!.. Ансыз ничек кайтыйм?!

Сәүдәгәрләрнең йөзенә ризасызлык билгеләре чыкты. Сүзсез генә таптанып алдылар. Кемдер авыр сулап куйды, кемдер учына йөткерде. Барысы да башлап сүз әйтүчене көтәләр иде. Авыр тынлык урнашты.

Ниһаять, өлкәнрәк малтабарларның берсе тамак кырып куйды.

— Үлгән артыннан үлеп булмый, Савелий Кузьмич... Ниишлисең?.. Урыны җәннәттә булсын!.. Кайту ягына кузгалмыйкмы диюем. Вакыт сузып кына үлгәнне терелтеп булмас,— диде ул картның йөрәгенә җәрәхәт ясамаслык сүзләр эзләп, сабыр күренергә тырышып.

Шуны гына көтеп торгандай, башкалар шаулаша башлады:

— Шулай инде, Савелий Кузьмич, ни хәл итәсең. Безгә яшисе бит әле. Һәр көн күпме чыгым китерә, аныcын беләсең...

— Углич базарына өлгерәсе бар. Базар таралгач, кайтуның ни мәгънәсе?!

— Мине Мәскәүдә көтәләр. Вәгъдә — алтын. Сәүдәгәр вәгъдәсе ул! Пайтәхет белән эш иткәндә соңармавың хәерле...

Картның боларга каршы әйтерлек дәлиле юк, күңел төбендә пыскыган өмет утыннан гына ятлар йөрәгендә ялкын кабыза алмыйсың. Аларның исә һәр көне — алтын, акча, мал! Мал дигәндә боларны җиңәрлек көч юктыр... Савелий Кузьмичның соңгы ышанычы сүнде, башын тотып, уфтанып аска иелде.

Кинәт аның күзләре очкынланды, элеккеге кискенлеге, тәвәккәллеге йөзенә чыкты, һәрберсенә туры карап әйтте:

— Чыгымыгызны үзем күтәрәм. Сүземнең ныклыгын беләсез. Кайтыйк Казанга, зинһарлап сорыйм. Кайтыйк сана!..

Сәүдәгәрләр янә сүзсез калды. Аларның һәркайсы эчтән генә үтәчәк көннәр исәбен саный, чыгымының тәгаен сумасын билгеләргә тырыша иде.

Көтмәгәндә Иван сәүдәгәр телгә килде:

— Кысмырланмыйк, туганнар! Бәла агач башыннан йөрми. Хан каласыннан әйләнеп килгәннән генә бөлмәбез. Тәвәккәллик!.. Чыгымын да күтәргәч...

Берәү дә аннан мондый борылыш көтмәгән иде, ахрысы, сәерсенеп аңа текәлделәр.

— Ярый соң... Алай булгач, сузмыйк. Юл кешесенең юлда булуы хәерле,— дип беренче булып сүз башлаган сәүдәгәр бәхәскә йомгак ясады. Аңа каршы әйтүче табылмады.

Шуны гына көткәндәй, өлкән көймәче кычкырып әмер бирде:

— Җилкәннәрне күтәрергә-ә-ә! Юл — Казанга!

Кемдер көймә уртасындагы учакка ут элде, казан асты. Озакламый, Идел киңлекләренә аш исләре таратып, дәү көймә тулы тизлегенә алга омтылды.

Бодай өстенә җәелеп яткан Иванның исә үз уйлары. Бердән, тәвәккәллеге, кирәк чакта ярдәм кулы сузуы белән ул Савелий Кузьмичның ышанычын казанса, икенчедән, аның яшерен максаты. Казанга кайтуның аңа гына аңлаешлы хикмәте дә бар иде.

Яшь егетнең мәхәббәт маҗараларыннан азмы-күпме хәбәрдар, күзәтүчән һәм итәк астыннан ут йөртергә остарган сәүдәгәр монда да үз файдасын онытмаган иде. «Мин әйтсәм дә, әйтмәсәм дә — барыбер Савелий Кузьмич күндергән булыр иде. Маңка малае өчен акчасын җәлләми.— Бусы — бер.— Иван уйлана-уйлана бармакларын бөкли.— Икенчесе — Санька исән. Димәк, ул Казанда. Аны Казанда иң беренче булып атасы түгел, мин очратырга тиеш. Күрергә дә әйтергә: «Сине эзлиләр, күзләреңә чалынуга, тышаулап яңадан Угличка озатачаклар. Бу юлы инде элеккечә саксызлык күрсәтмәсләр, җилкән колгасына богаулаячаклар. Атаңның ачуы кабарган чак». Боларны ишетүгә, мәхәббәттән шашкан егетең шайтаннан җәяүләп качкандай юкка чыгачак, борынын да күрсәтмәячәк. Өченчесе — әгәр акчаны чыннан да ул алган булса, бугазлап кире кайтарачакмын, муенына буш янчык асып, мәетен кәрван-сарай ишегалдына кертеп атачакмын. О-хо-хо! Алтын ни генә эшләтми кешене. Йөз бәлиш янына тагын ике йөзне куш әле, Иванкаем! Шәпме?! Үзеңнеке дә кире кайта, янасы да өстәлә. Алтын алтынны чакыра. Мондый сума белән Угличта сасып яту түгел, Мәскәүнең, бөек кенәз сараеның да ишеге киерелеп ачылыр. Түземлек, сабырлык, Иванкаем! Күзеңне киереп ач, колагыңны торгыз! Башкалардан күбрәк күр, күбрәк ишет! Бәхетең кул сузымында гына...»

Ул киерелеп иснәде һәм бер атуда ике, юк, өч куян алачагы, аларның да нинди икәре кулга төшәчәге күз алдына килүгә, йодрыгы белән бодай көшеленә сугып алды, тәгам тулы табын янына утырырга әзерләнгән корсак колы кебек канәгатьлек хисенә чыдаша алмый кулларын уалады. «Алла кушып, барысы да мин дигәнчә булыр. Барысы да уйланылган, кире чигенер урын юк. Елгырлык, житезлек бир, ходаем!»

* * *

Идел ярындагы тау башына укмашып утырган, Мәскәүгә буйсындырылып мөстәкыйльлеген югалткан элеккеге кенәзлек үзәгенә — инде елдан-ел сүнеп, бөлеп баручы Угличка Савелий Кузьмичка ияреп кара хәсрәт кайтты. Күтәрә, җиңә, үткәрә алмаслык кайгы, югалту ачысы...

Туган йортка якынлашкан саен хәсрәтле әрнү дә зурая, тирәнәя бара иде. «Прасковьяга ни дип әйтермен?! Сөекле улыбызның инде дөньяда юклыгын ничекләр аңлатырмын?!» Савелий Кузьмичның миен шул сорау бораулый. Ни эшләргә белми бәргәләнә. Бердән, башын тезләренә куеп елыйсы, йомшак кулларына маңгаен тигереп тынычланасы җефете янына ашыга, икенче яктан, мондый да олуг кайгы белән, ямьсез хәбәр белән кайтасы килми, аяныч күрешүне сузасы, арткарак чигерәсе килә иде. Әмма берни дә эшләр әмәл юк. Барыбер кайтасы, барыбер әйтәсе...

Савелий Кузьмич төяп кайткан малына да кул селтәде. Бушату, урнаштыру эшләрен көймәчеләргә йөкләп, көймәбашына амбар ачкычын тоттырды да салмак атлап текә ярдан күтәрелә башлады. Хезмәтчеләрен җибәртеп, ат чакыртырга да мөмкин иде, әлбәттә. Ләкин карт сәүдәгәрнең беркемне дә күрәсе килми, ялгыз калып барысын бәйнә-бәйнә хәтереннән үткәрергә, сөекле Парашасын ничек тынычландырырга, нинди сүзләр табарга кирәклеген уйларга тели иде. Тик җылы сүзләр дә, югалтуны җиңеләйтер әмәл дә таба алмады. Ирексездән иреннәре кыймылдады, уфтанып:

— Их, Параша, Параша! Бала ата-анасыннан иртә үлмәсен икән ул! — дип куйды.

Унсигез еллап бер түшәкне уртак иткән Прасковья балаларына йомшак, ягымлы, кирәгенчә таләпчән һәм каты куллы, иренә игелекле һәм тугры хатын була белде. Тик... аның аңлашылмый торган, ничә еллар уйланып та серен таба алмаган бер сәер ягы бар: ялгыз калды исә Прасковья күзен бер ноктага теки дә хәрәкәтсез тына... Тирә-ягында ни барын, ни кылынганын күрмәс, ишетмәс дәрәҗәгә җитә. Әйтерсең, ул нәрсәнедер исенә төшерергә, кайчандыр үтә дә кадерле булган ниндидер хатирәләрне яңартырга тели. Савелий яшеренеп кенә күзәткәләп тә карады, хыянәттән, тугрылыксызлыктан шикләнгән күңел әллә нинди сурәтләр, фаразлар тудыра иде. Әмма Прасковья аларның берсенә дә сәбәп бирмәде. Тезләрен кочаклап утырыр да, ерак-еракларга карап сүзсез калыр. Аннан соң ул акрын гына чайкала башлый, иреннәре юка гына, кәгазь сыярлык кына булып ачыла да аннан ниндидер өн агыла башлый. Елау-сыктау да, җыр да түгел ул, ыңгырашуга охшаш бетмәс-төкәнмәс бер көй, бер моң. Тәүге тапкыр ишеткәндә Савелийның бала йоннары кабарды, бугазына төер тыгылды, тамагы кипте. Ул моның ни икәнен белми, әмма шушы көй, моң йөрәген кыса, тәнен эсселе-суыклы итә, тетрәндерә иде.

Прасковьяның нинди гаиләдән икәнен төгәл белми Савелий. Аның Углич якларында булмаганча чиста, гайре табигый ак тәне, биленә хәтле ишелеп төшкән алтынсу көлтәгә охшаш куе чәчләре, бу яклардагыча сусыл түгел, ә ниндидер җете куе зәңгәр күзләре әсир иткән иде яшь сәүдәгәрне. Йөзенең бу аклыгын башта үзенчә юрады Савелий: балачагын, үсмерлек чорын, яшьлеген калын таш диварлар арасында, Углич монастыреның тар тәрәзәле ярымкараңгы хөҗрәләрендә бикләнеп үткәргәнлегеннән күрде. Ирекккә чыгуга, бу аклыкны көн яктысы юып алыр, бетен җил, кояш ашар дип көтте. Алай булмады. Дөрес, Прасковья тагын да нәфисләнеп, матурланып китте, йөзенә исә чәчләренә тартым алтынсу төсмер генә иңде. Ул каралмый, тупасланмый торган затлардан иде, күрәсең...

Аңа өйләнүе дә әллә ничек сәер, көтмәгәнчә килеп чыккан иде. Күрәсең, барысын да язмыш үзенчә билгели, үзенчә оештыра торгандыр.

Мәрхүм атасы ихтыярына буйсынып өйләнгән беренче хатыны белән дә начар тормадылар анысы. Бер генә җитмәгән яклары, кешегә әйтмичә генә әрнетә торган уртак кайгылары булды: хатын балага узмый иде. Каударланып алыш-бирешкә, сәүдә эшенең четерекле дөньясына чумган Савелий башта моңа артык игътибар бирмәде. Булыр әле! Яшьбез, көчлебез, диде. Еллар узган саен шул үкенеч йөрәген ныграк кыса, кешедән кимлегеннән үртәлдерә башлады. Кәсептәшләренең аңа сиздермәскә тырышып көлүләре, «Кайсысы кысыр икән, хатынымы, үземе?» — дип сөйләнүләре исә ачык җәрәхәткә тоз сипкән кебек әрнеткеч тәэсир ясый иде. Әйе, көттереп, зарыктырып дөньяга килде Вася. Тик шатлыкка урап, сөенечкә төреп олы кайгы да алып килгән иде ул. Газапланып, интегеп бала табуга ай уздымы, юкмы, хатыны өзлегүдән мантый алмады. Васяны күкрәгенә кыскан хәлдә якты дөнья белән бәхилләште.

Әнә шул чакта Савелий Кузьмич өенә Прасковья аяк басты. Юк! Хатын булып түгел. Бала карауч, үксез Васяга нәнкә сыйфатында килде ул. Хәзер инде анык кына хәтерләми-дә, бер айлык бала тотып ялгыз калган атаның ул чактагы мазасы бар нәрсәне каплап киткән иде. Кәсептәшләреннән кем тәкъдим иткәндер, анысы да истә калмаган. Сәүдәгәр буларак бер генә нәрсәне хәтерли: «Арзан гына,— диделәр,— Менә дигән кол кызы. Нәселнәсәбе тәрбияле, асыл таифәдәндер»...

Дин сабагыннан ваз кичкән яшь монашка ул чакта Савелий өчен колачлап булгысыз авыр мәшәкатьтән коткаручы яшь бер фәрештәдәй тоелган иде. Чынлыгы да шулай. Кап-кара, башын-күзен каплап торган озын киемнәрен салып аткач, күз алдында чәчәк аткандай чибәрләнеп киткән басынкы холыклы, ягымлы Прасковья тора-бара сәүдәгәрнең бөтен дөньясын, җанын биләп алды. Аңа башка беркем дә кирәк түгел иде инде. Савелий Кузьмич хәзер дә аннан башка яшәүне күз алдына китерә алмый. Прасковья — Васяга мәрхәмәтле ана, аңа тугрылыклы хатын, Санькага җан биргән кадерле бер зат иде. Үз баласы тугач, өлкән угылга кадер кимер дип

шикләнгәне акланмады. Прасковья мәхәббәтен һәр ике балага тигез бүлә белде, теле һәм гамәле белән ни олысына, ни кечесенә аерымлау сиздермәде. Кеше мөгамәләсендә иң нечкә кимәлне дә тоемлау сәләтенә ия Савелий бары тик аның күзләрендә генә нindидер бер нур балкуын сизеп яшәде. Ул нур исә Санькага бакканда, аңа караганда гына кабынып ала иде. Гөнаһлы бәндә Савелий үзенә дә шундый нур кабынуын өмет итте. Әмма юкка! Соңыннан, газиз улыннан көнләшүен аңлап, тормышка ашмас хыялына кул селтәде. Тик, юк-юк та, шул нурны тансыклап, юксынып куя торган иде. Хәзер менә Прасковья янында аңлашырга, аңлатырга кирәк булачак. Йа хода, ярдәменнән ташлама!..

Җирдә ауный-ауный, Углич хатыннары шикелле чәчләрен йолкый-йолкый такмаклап елар дип көткән Савелий Кузьмич бер мәлгә хәтта аптырап калды. Прасковьяның күз карасы кинәт зурая башлады, бөтен зәңгәрлеген каплап, шомырт төсендәге зур төймәгә әйләнде, әмма авызыннан бер аваз чыкмады. Ул кулларын кушып, лып итеп урындыкка утырды, бер ноктага текәлеп тораташтай катты да калды.

«Ник еламый? Кычкырсын, битәрләсен, сүксен, илереп бер аһ орсын иде ичмасам!—дип үрсәләнде Савелий Кузьмич. Һич югы, идәнгә ятып аунасын иде...»

Ниһаять, көттереп, озак көттереп Прасковья телгә килде, хәлсез, әллә каян, бездән килгәндәй тоныкк тавыш белән эндәште:

— Кайда? Газиз улгым кайда?

— И-и-и анасы, әйттем бит инде... Үзем дә белмим бит ничек булганнарын. Идел дулкыннары серен чишми ласа...—дип кабат уфтанды гаиләбашлыгы, сүзләрен теш арасыннан чыгарып.—Үз җанымны да жәлләмәс идем дә...

Прасковья тагын телсез калды. Аның башына әллә нәрсә булды, ничәмә еллар искә төшерергә, күз алдына китерергә тырышкан сурәтләр оеша башлады. Әле ул аларның ни аңлатканын да, кемнең кем икәнен дә белми иде. Кинәт ике кулы белән дә башын тотып мендәргә ауды. Чигәне ике яктан кыскан авыртуга чыдый алмый, тешләрен кысып түзәргә, шул сызлауны куарга тырыша башлады. Күз алдына йөрәк парәсе—углы Санька килде. Иделнең салкын кочагыннан ычкынырга талпынып, ул: «Әни-и-ием».—дип ялварып, ярдәм сорап кычкыра иде. Кинәт тагын күренешләр алмашынды. Прасковьяның миен кисеп, яндырып икенче әрнеткеч тавыш яңгырап үтте:

— Әни-и-и-ем! Әне-кәч-чә-ә-ем!..

Ләкин бу тавыш Санькаsuccessныкы түгел. Тавышы да, сүзе дә аныкы түгел. Бөтенләй башка телдә, башка җирдә яңгыраган әрнүле ялвару иде бу. Тукта! Тукта! Ул илерү Прасковьяның үз эчендә, үз миендә бәргәләнә түгелме?! Нинди тел соң бу!? Нинди гаҗәеп якын аһәң, таныш та, таныш түгел дә тоелган сүзләр, бәгыреңне айкап чыккан газиз бер өн!

Идел өсте. Текә ярларны тутырып дулкынланган киң Идел кочагы. Җилкәннәрен киергән зур көймә... Көймә борынында кечкенә кызчыкны куенына сыендырган яшь бер хатын. Су өстеннән үсеп чыккан кыялар... Җилсез тарлавыкта шиңеп сүнгән җилкәннәр лыпырдавы... Каяндыр пәйда булган икенче бер көймә. Нindидер усал йөзләр. Сакал баскан, озын чәчле явыз адәмнәр... Пычак-хәнҗәрләр ялтыравы... Кан! Кан!.. Менә калын тырнаклы, йон баскан олы тупас кул аңа үрелә, әнисе кочагыннан йолкып ала. Нәни кызчык үз-үзен белештермичә ачыргаланып кычкыра:

— Әни-и-и-ем! Әне-кәч-чә-ә-ем!..

— Кызым! Кызымны бирегез! Кызымны!..

Тар кыялар арасыннан әзмәвер ирнең калын тавышы кайтаваз булып ишелеп төште:

— Ха-ха-ха! Кызың түгел, үзең кирәк безгә! Үзе-е-е-ең! Үзе-е-ең!

Нәни кызчык кулларын сузып әнисенә омтыла, кычкыра, елый, ялвара. Кинәт аның гәүдәсе очып өскә күтәрелә, елга юлбасарының бер селтәнүеннән ул котырып агучы күбекле дулкыннар арасына кереп югалачак. Шул мизгелдә икенче бер юлбасарның канлы кулы иптәшенең җилкәсеннән умырды, сары тешләре арасыннан зәһәрле ысылдау ишетелде:

— Кем баласы икәнен онытма! Көймәдәге бар мал бәһасенә торырлык әнчек!.. Морза нәселе... Ха-ха-ха... Әҗерен кайтарасыбыз бар!

Тагын күренешләр алышынды. Елап арыган, үксүдән шешенеп беткән нәни кызчык өстенә кара киемле, тупас йөзле хатыннар иелешкән. Аңлаешсыз телдә нидер сөйләшәләр, баш чайкыйлар. Авырту бер генә мизгелгә китеп торды. Һәм Прасковья инде ничә еллар үзен газаплаган сәер һәм газаплы соравына җавап тапты: ул — ул түгел икән ләбаса! Күкрәк астыннан бөрмәләнеп идәнгә хәтле сузылган кин, озын кызыл күлмәк эчендә Прасковья түгел, ә икенче бер кеше — кайчандыр Иделдә талап алынган нәни кызчык җаны, аның тәне. Теле дә аның башка икән ласа! Газиз углының Идел кочагында җан биргүе дөрес түгел. Түге-е-ел! Тү-ге-е-ел! Аның җаны әнисенең туган ягына ашкынган, шунда очкан!

— И-и газизем! — дип ыңгырашты Прасковья һәм илереп ятакка ауды. Коточкыч авырту тимер кыршау булып тагын ике чигәсен кысып алган иде.

Кинәт аңа өстендәге җете кызыл күлмәк ялкын булып тоела башлады. Идел өстендә ургылып ялкын уйный, аяусыз ут телләре җилкәннәрне ялмый, колгалар буйлап өскә, яшел әләмгә сикерә. Тизрәк, тизрәк бу уттан, ялкыннан котылырга кирәк! Ул сикереп торды, күлмәген йолкып ертырга, тарткаларга кереште. Әмма ефәк тыңлаусыз бармакларга бирешми иде.

— Ут! Ут! Янам!

Прасковья сикереп торды да ишегалдына йөгереп чыкты, кое янындагы улактан чиләкләп өстенә су коярга кереште. Ләкин ялкын кимемәде, ул, киресенчә, тагын да көчәя генә төште, тәненә сыланып, тагын да зәһәррәк яндыра, кыса, буа башлады.

Савелий Кузьмич хатынының хәлен аңламады. Аның чыгып йөгерүен үзенчә бәяләп юлына аркылы төшмәде. «Еласын, илерсен! Тынычлансын!» Аның күз карашы Василийда иде: «Бу дуамал тагын ни кылаңыр!?»

Василийның исә йөрәге таштай каткан иде. Ул энесенең, җаныннан артык күргән, үзеннән ныграк яраткан Санькаһың якты җир йөзендә юклыгына ышанмый. «Болай булуы мөмкин түгел. Бер елмаюы белән генә дә көн яктылыгын арттыручы, шат күңелле егет тормыштан болай китмәс!» Аның йөзенә кара йөгерде, күзләре пыялаланды, куллары йодрыкка төйнәлде.

Кинәт ул сикереп торып ишек яңагын тоярга кереште, ачу белән кысылган теш арасыннан мәгънәсез зәһәр сүзләр чыкты.

— Мин барыбер үч алачакмын. Аның үлеменә сәбәпчене җир астыннан эзләп табачакмын. Менә... күрерсез. Үч алачакмын. Үч! Үч! Үч! Казанга җитәрмен, табармын. Үч!

Аның гәүдәсе калтырана, гайрәт белән өзлексез имән борысны төйгән кулында кан күренде, бармаклары арасыннан тибеп чыкты, идәнгә тама башлады.

Кан!

Савелий Кузьмичның күз аллары караңгыланды, башы әйләнеп китте. «Тагын канмы!? Тагын үлемме!?»

— Җитте! Тукта! — дип җикерүен сизми дә калды. — Бүгеннән сиңа Казан юлы ябык! Мин исән чакта ике аягыңның берсен дә атламаячаксың. Аңладыңмы? Аңладыңмы, дим!..

Василий ничек тиз ярсып кабынса, шундый ук тизлек белән сүрелде дә. Күбрәк энесенә сыенып, аның фикере беләнрәк яшәргә күнеккән, җитез һәм үзбаш уйлаучан Санькаһың күләгәсенә әйләнә барган олкән угыл атасына каршы сүз әйтергә базмады, йодрыгын тагын бер кат селтәде дә канлы кулы белән яшьләрен сөртә-сөртә ишеккә ташланды. Аның үзалдына.кирелһнеп әйткәне генә ишетелеп калды:

— Мин барыбер үч алачакмын!

Шушы ук мизгелдә карт сәүдәгәр үзенең дә моннан соң Казанга бара алмаячагын аңлап алды. Аяк тартса да, җан тартмас. Сәбәпсез ачуы, газизен аңлый алмавы, урынсыз кул күтәрүе, мәсхәрәләгәндәй бәйләп ташлатуы белән рәнҗеткән, һәлакәткә этәргән җирләрдә кабат-кабат газапланачагын, җанына тынгы таба алмаячагын, күңелендә мал кайгысы түгел, үкенеч һәм җан кайгысы булачагын да төшенгән иде ул.

## Гөлйөзем

Аннан соң да гыйшкы һаман тәэсир кылды,
Гыйшкы аның көннән-көнгә артып торды,
Йокысыннан мәхрүм калды, йөзе сулды,—
Ашау-эчү кайгысын да белмәс имди.

КОЛ ГАЛИ. «Кыйссаи Йосыф»

Арбага килеп төшүгә янына сикереп, авызын кәчле, кытыршы учы белән томаларга азапланучы егетнең күкрәгенә ике кулын терәп, Гөлйөзем җан ачуы белән кычкырып җибәрде:

— Җибәрегез, дим! Җибәр!.. Мин сезгә кол кызы түгел. Мин... Мин сезне... абыйга әйтәм!..

Сүзләрен әйтеп бетерүе булды, тавыш-тынсыз мыштым егетләрдән берсе кычкырып көлеп җибәрде, кулын бушата төште.

— Күптән шулай диләр аны, Гөлйөзем. Юкса, юлбасарлар тозагына эләккәндәй чапаланасың...

Таныш тавыштан өстенә бозлы су сипкәндәй куырылып килде, тартылган кылдай киерелгән гәүдәсенең бердән хәле бетте, әрнү белән яшьләренә буылды.

— Сез... син... Ни хакыгыз бар? Мин аяклы мал түгел. Ни-и-ишлә-ә-дегез?.. Җибәрегез!

— Хурлыктан саклап калганга рәхмәт әйт,— дип ысылдады абыйсы Гөлйөземнең беләген кысып.— Күп кычкырсаң, төшеп ул егет аламаңны камчы белән ярырга да күп сорамам! Әнә арттан титаклый.

— Сез аны белмисез... Ник алама булсын. Нигә алай дисең?

Кыз рәнҗүеннән телсез калды, абыйсына каршы әйтер сүзләр таба алмыйча интекте.

— Акканатым,— дип үчекләүгә күчте абыйсы.— Кара канатың түгелме? Төн уртасында җиде ят белән кулга-кул тотынып... Оятсыз... Әткәйгә ни йөз белән күренерсең?! Ул хакта уйладыңмы?

— Башкалар йөри бит әле...

— Син башкалар түгел. Син минем сеңел! Тагын килеп кенә карасын... Менә шушы кулларым белән изеп ташлаячакмын...

Гөлйөзем үзен үчекләүдән, җан ачысы белән ачыргаланып кычкырганын үртәүдән оялып яшьләренә тыгылды, учы белән битен каплап, утыргычка сеңде.

— Йә, житте-житте, Гөлкәй!.. Син акыллы кыз... Болай йөрергә ярамаганын, беләсең. Бер ялгызыңа җыенда кем очрамас...— Абыйсы аны үгетләп юатырга, тынычландырырга керешге.— Ярәшелмәсә дә, күздә тотылган егетең бар. Болай килешми...

— Нинди егет,— дип ыңгырашты Гөлйөзем.— Ник минем өчен хәл итәсең?

Фәрит җиңелчә көлеп җавап бирде:

— Кызлар сездерми инде ул... Аларныкы яшерен...

Моңа кадәр тавыш-тынсыз утырган Шәһит гаепле тавыш белән сүзгә кушыласы итте:

— Йә инде, Гөлйөзем. Баш ярылып күз чыкмаган, тынычлан. Юк икән, димәк, юк. Бигрәк тә әйбәт!

Абыйсының кырыслыгын, елау түгел, алдында җиргә ятып аунасаң да сүзеннән кире кайтмаячагын белгән Гөлйөзем язмышына буйсынырга мәҗбүр иде. Ләкин аның рухы сынмаган, күңеле буйсынмаган, йөрәге «Акканатым! Акканатым!» — дип сулкылдый, Саньканың барыбер аны табачагына ышана иде.

Кичке җыен, Александр атлы саф күңелле егет, фаҗигале өзелгән очрашуны, абыйсының мәкерле хәйләсен Гөлйөзем кат-кат исенә төшерә, чара-

сызлыгыннан иреннәрен тешли, бер күрергә зар булып Акканатны сагына иде.

Үзе дә аңламый кыз. Мондый сәер, татлы да, газаплы да, әрнүле һәм сагышлы да халәтне кичергәне, җанын кая куярга белмичә өзгәләнгәне юк иде әле аның.

Барысы да гади, гадәти иде. Ата-ана сүзеннән чыкмаган, өлкәннәргә күтәрелеп каршы сүз әйтә белмәгән кызның күңеле урман уртасында камыш баскан тымызык күлдәй тыныч иде. Бернинди җил-давыл аны айкамый, дулкынландырмый, тирә-яктагы йозьяшәр имәннәр аның иминлеген, бөтенлеген саклый, чит-ят күзләрдән каплый иде кебек. Әллә каян килеп чыккан ак егет, әйтерсең, әнә шул күл өстендә өермә куптарды, җир асты чишмәләреннән дымга туенып яткан нәни генә көмеш күлнең астын-өскә китерде, мәңге тынычланмаслык итеп актарды да ташлады. Дулкыннары сикереп чыгарга җитешеп ярга ташлана, камышларның, талларның тамырын актара.

Башка ахирәтләре кебек үк үзен алда ни көткәнен дә анык белә иде Гөлйөзем. Кызлар гомере кыска — әти-әниләре, туган-тумачалары үз күргән берәр егеткә димләячәкләр, шартын китереп туен үткәрәчәкләр... Кыңгыраулы атлар, бизәкле паласлар... Кияү йортында телең балдай татлы булсын дип бал каптырырлар, холкына майдай йомшаклык теләп майдан авыз иттерерләр, тыныч, бәхетле тормыш юрап мамык мендәргә бастырырлар... Кияү куенына керү — яшерен хыял, өмет, бәхет...

Сөйгән егетенә чыга алган кыздан да бәхетле кеше юктыр, ходаем. Элегрәк нишләптер бу турыда уйланмый иде Гөлйөзем. Гадәткә кергәнчә, йола кушканча, барысы да шәригатьчә булыр, ата-ана баласына яманлык теләмәс дип белә, шуңа ышанып яши иде. Хәләл җефетемә тугрылыклы яр булырмын, иптәш булырмын, тупырдатып балалар үстерермен, дип хыяллана. Әмма күз алдында торганы, аһ, шуның яры булсамчы, дип өметләнгәне юк иде.

Ак егетне күргәннән соң, көчле кулының кайнарлыгын, чаткылы зәңгәр күзләренең бәгыреңә үтеп керердәй тылсымын тойганнан соң, колакны назлаучы йомшак тавышын ишеткәннән соң — аның күңелендәге уйлары, хыяллары чәлпәрәмә килде.

Гөлйөземнең күзләренә яшь тыгыла. Саньканың арба артында тәгәрәп калуын, аның ләгънә орып, нишләргә белмичә өзгәләнүен күз алдына китереп тагын яшенә буыла.

Читлеккә эләккән коштай бәргәләнде Гөлйөзем. Кулына ни тотса, шул төшеп китте, бүлмәсендә әрле-бирле йөренде дә йөренде. Башка бүлмәләрдән аерым итеп, йортның икенче катында кыек астына урнаштырылган, тар баскыч белән генә аш-су бүлмәсенә тоташтырылган хөҗрәсе кысан тоела башлады, аңа һава җитми кебек иде. Башка вакытта чигү чигеп, нинди дә булса кыйсса укып кызык таба, вакытның ничек үткәнен дә сизми кала торган кыз көнне үткәрә алмый изалана иде.

Тәрәзә каршына килеп басты да күзләрен офыкта каралҗымланып күренүче урманнарга текәп хәрәкәтсез калды.

Гөлйөземнәрнең өе тышкы шәһәрдә, кирмән коймаларыннан ерак түгел биек калкулыкта иде. Аның бүлмәсеннән бер-берсенә сыенып утырган эреле-ваклы йортлар да, кала тышындагы бистәләр дә, урман-болыннар да уч төбендәгедәй күренә. Күршеләрендәге тимерче, чүлмәкче, бакырчы, тукучы ише урта кул җитенкелектә яшәүче һөнәрчеләрнең ихаталарында ни кылынганын, кемнең нинди аш пешергәненә хәтле күреп, белеп торырга мөмкин иде. Алар арасында исә Галиәкбәр оста йорты тазалыгы, бөтенлеге белән дә, муллыгы һәм биеклеге белән дә аерылып торыр иде. Шулай булмый, атасы — алтын-көмеш белән, асылташлар белән эш итүче. Ләкин боларның берсе дә яшь кызның күңеленә ямь, тормышына тәм бирми иде инде.

Әнә ерак болында яшь тайлар уйнаклый, зәңгәр күктән тургайлар җыры коела, шәһәр урамнарыннан кемнәрнеңдер яңгыратып көлгәне ишетелә... «Барысы да, җиһандагы бар җан ияләре дә бәхетле... Һәммәсе дә тиңен, ярын тапкан. Мин генә ут йотып утырырга мәҗбүр». — дип уйлап куйды ул

həм. баскыч шыгырдаганнан сискәнеп, тиз генә ятагына барып капланды. Яшьле күзләрен, калтырап-калтырап куючы иреннәрен беркемгә дә күрсәтәсе килми иде.

Авыр адымнар акрын гына ишеккә якынлашты. Менә басмалар шыгырдаудан туктады. Кемдер ишек янында тынып калды, авыр итеп сулады. Шул сулыш алуыннан аңлады: өлкән киңәшчесе, яраткан нәнәсе килгән. Ләкин барыбер урыныннан күтәрелмәде. Никадәр генә киң күңелле, мәрхәмәтле һәм сабыр булмасын, нәнә — нәнә инде, ул аның язмышын хәл итүгә берничек тә ярдәм итә алмый. Тагын бер кат күкрәгенә капланып елаудан гына ни файда!?

Шыгырдап ишек ачылды, кулыннан мәңге төшмәс дисбесен тотып, карт нәнә килеп керде, шөбһәле, тәшвишле тавыш белән дәште:

— Әллә йоклыйсыңмы, кызым?

Гөлйөзем җавап бирмәде.

Нәнә тамак кырып куйды һәм алай да җавап ала алмагач, Гөлйөземнең аркасыннан бәпләп, сөйләнә-сөйләнә үзенчә уятырга кереште: •

— Тор инде, тор, йөрәк парәм. Кояш төшлектән авышып бара... Ә син һаман мендәрдән аерылмагансың. Бәхетеңне йоклап үткәрмә тагы...

— Нинди бәхет ул? И нәнәм... — дип сыкранды Гөлйөзем. — Беләсең ич инде...

Гөлйөземнең йөрәк серен уртаклашкан карт нәнә авыр сулап куйды:

— Кем белә, колыным!.. Баланың бәхете ата-ана кулында. Тыңлаучан булсаң, сүзләреннән чыкмасаң... саф сәфәктәй кызны рәнҗетмәсләр, юлына аркылы төшмәсләр дип беләм. Ата-анага баладан да кадерле нәрсә юк. Алла боерса, күрешерсез дә, табышырсыз да әле... Егетеңне әйтәм, ул да атаң каршына ачык йөз, чиста күңел белән килә белер. Казан ярминкәсенә йөрердәй адәм төшеп калганнардан булмас...

Карт нәнәнең акрын гына, иплә кенә әйткәннәреннән Гөлйөземгә әллә ничек җиңел булып китте, йөрәген кысып торган авырту акрынлап юкка чыга башлады кебек. Торып утырды да нәнәсенә ялварды:

— И нәнәм... сөйлә, тагын сөйлә... Синнән башка кемнән киңәш көтим? Күземне ач бу четерекле дөньяга!

— Ярый, ярый... Артыгын кыйналма, җәрәхәтеңә тоз сипмә. Фәрит абыеңны да аңларга тырыш, синең өчен дип, синең намусың өчен дип үрсәләнгәндер. Сөенеп торырга кирәк, «яклаучым, саклаучым бар» диеп...

Абыйсының исемен ишетүгә, Гөлйөзем тагын куырылып килде, йөзенә төксе кыяфәт чыкты.

Нәнә ялгышрак ычкындыруын аңлады булса кирәк, тиз генә сүзне икенчегә борды:

— Әйтергә онытып торам икән лә... Әтиеңнең йомышчысы килде. Кичекмәстән, хәзер үк сине чакырган. — Аның тавышында тәшвишле төсмерләр куерды, йөзенә борчылу галәмәте чыкты. Галиәкбәр оста, гадәттә, хатын-кыз эшенә тыкшынмый. Аның үз дөньясы, эреле-ваклы бетмәс-төкәнмәс үз мәшәкатьләре бар. Балаларга, йортка, аш-суга кагылышлы һәрнәрсәне Гөлйөземнең әнисе хәл итә. Йортта шундый кагыйдә иде. Ә инде Галиәкбәр останың йомышчы җибәртүе, Гөлйөземне остаханәгә атап чакыртуы гадәттән тыш хәл иде. Никадәр генә тыныч күренергә тырышмасын, нәнә үзенең борчылуын барыбер яшерә алмады.

Гөлйөземгә килсәк, ул әтисе янына остаханәгә йөрергә ярата иде. Галиәкбәр оста көннең күп вакытын ихата түрендәге бер катлы зур таш йортта үткәрә. Монда тылсымлы, сихерле, үзенчәлекле икенче бер дөнья. Монда ут һәм су, таш һәм алтын патшалыгы. Әтисе исә әнә шул буйсынмас көчләрне җиңеп, игә китереп, асыл бизәкләр, асыл сурәтләр тудыручы гали бер зат булып тоела Гөлйөземгә.

Кечкенә чагында иртән торуга ук остаханәгә йөгерер иде. Кечкенә сандалда чүкеп күбәләк канатыдай юка көмеш яфракчыклар ясаучы, эреле-ваклы ниндидер таш кисәкләрен эретеп балдак-йөзекләр коючы әтисе бер тылсым иясе иде. Остаханәдәге абыйлар Гөлйөземгә бакырдан коеп нәни балдаклар, беләзек, күкрәкчә кебек нәрсәләр ясап бирделәр. Шуларны тагып,

һәр бармагына берәр балдак киеп, кул чабып, көйли-көйли тыпырдаган нәни кызчыкны өлкән алтынчылар да, өйрәнчек егетләр дә мыек астыннан елмаеп күзәтә. Һәрберсе нинди дә булса бүләк бирергә генә торыр иде. Үсә төшкәч исә әтисе кырысланды. Көннәрнең берендә әйтте:

— Балам, син инде хәзер җиткән кыз булып киләсең. Һаман-һаман ут, корым арасында, егет-җилән, ир-ат тирәсендә йөрү килешмәс. Остаханәгә керүеңә асла рөхсәтем юк,— диде.

Сабыр холыклы ата аны өйрәнчеклеккә килгән чая егетләр күзеннәнерактарак тотуны хәерлерәк санаган иде.

Монысын, әлбәттә, Гөлйөзем белми һәм үз вакытында әле әтисенә үпкәләп, кинә саклап та йөргән иде. Һәм менә кинәт кенә атап чакыру, йомышчы җибәртеп дәшү. Бу юкка гына булмас! Гөлйөземнең йөрәге дерт итеп китте: Александр атлы чибәр егет килмәгәнме икән!? Таш ярып чыккан, елгалар, урманнар кичеп ярминкәгә килеп җиткән батыр егет атасы янына юлны тапса, гаҗәпме!?

Гөлйөзем иңнәренә ефәк япмасын гына элде дә, ике басманы бер итеп аска төште, пешекчеләрне гаҗәпкә калдырып, ишегалдындагы ташлардан сикерә-сикерә остаханәгә элдертте. «Менә-менә хәзер нәрсәдер булырга тиеш. Мине күрмичә Александр барыбер Казаннан китмәс. Китәргә тиеш түгел. Йөрәгем шулай сизенә. Аның урынында булсам, мин дә китмәс идем!»

Галиәкбәр останың хыял-өметләре зурдан иде. Шәҗәрә очы Казан һәм Болгар мәмләкәтенең иң оста алтынчыларына барып тоташкан, аларның һөнәр серләрен саклап килгән зәргәрнең эше күзгә күренеп алга бара, һәр көн аңа бәрәкәт, мал китерә, байлыгын ишәйтә иде. Казан патшалыгының иң оста алтынчысы дигән исем күпне белергә, һәр гамәлеңнең алдын-артын уйлап эш итәргә, күпне бирергә мәҗбүр итә. Шуның белән бергә, әҗере дә шактый сизелерлек иде.

Тышкы шәһәрдәге йорт-ихатасы мулдан, остаханәсе киң вә иркен булуга карамастан, ничек тә эчке шәһәрдән йорт алу исәбе бар иде Галиәкбәрнең. Ул белә: анда күчү Казанның иң күренекле затлары арасына керү, кайда да сүзең үтү дигәнне дә аңлата. Хәер, аларына хәзер дә зарланырлык түгел. Әмма тагын да яхшыракка, әйбәтрәккә омтылу кеше дигән затның табигатеннән килә торгандыр.

Эш шуңа таба бара иде дә инде.

Көннәрдән беркөнне остаханә ишеген сарай чапкыннары какты. Гади йомышчылардан гына да түгел. Олуг башын кече итеп Галиәкбәр катына Җангали ханның ышанычлысы, казнабашның ярдәмчесе үзе килгән иде. Мәмләкәттә акча сугуга күзәтчелек итүче, алтын-көмеш, асылташ ише хәзинә сакчысының үзенә сәлам бирүен яхшыга, бик яхшыга юрады алтынчы оста. Иелеп сәламен алды, остаханә түрендәге йомшак күн мендәр түшәлгән урынга күрсәтте, горурлыгын югалтмыйча гына тәмле сүзләр тезде:

— Рәхим ит, и бөек хакимнәрнең бере! Без фәкыйрегезнең караңгы хөҗрәсенә нур алып кердең... Алла рәхмәтеннән ташламасын! Мәрхәмәтеңне һәм әмереңне көтәм...

Казнабашның ярдәмчесе ияреп кергән тән сакчыларына башы белән ишарә ясады, тегеләре ашыгып алгы якка чыгып китте. Бары тик шуннан соң гына ул өстәлләрдә таралып яткан алтын-көмеш беләзек, йөзек кеби нәрсәләрне, аерым үтенеч белән ясалып ятучы асыл касәләрне күздән кичерде һәм канәгать калды булса кирәк, тамак кырып куйды, йөзенә елмаюга охшаш чалым кунды.

Галиәкбәр әле һаман аның ни йомыш, нинди әмер белән килүен аңлый алмый интегә иде. Салымнарын казнага вакытында озатып бара, сату-алуда кемгә дә булса хилафлык китергәне, нәфесенә юл куйганы юк. Тынлыкны бозу өчен тагын үзе эндәште:

— Галиҗәнаб казнабаш! Җаның ни тели? Хезмәтчеләргә әйтим, чәй китерсеннәрме, ширбәтме?

Вазифасын бер башка югары күтәреп атаганны казнабаш ярдәмчесе сизмәмешкә салышты һәм үзалдына елмаеп куйды: «Әйе, бу алтынчы беркатлы түгел. Мәмләкәтнең иң оста зәргәре исемен күтәрүе генә җитмәгән, телгә оста, кирәген әйтер өчен кесәгә керә торганнардан имәстер». Галиәкбәр абзый үзе дә сизмәстән аның иң яшерен хыялын чын итеп әйтеп ташлаган иде.

Казначы, кулы белән кагып, «Мәшәкатьләнмә!» дигәнне аңлатты да ишекле-түрле йөренә-йөренә акрын гына сөйли башлады:

— Сарай әһле сәбәпсез йөрмәс... Аңлагансыңдыр, беләсеңдер... Йомышымның җитдилеген искәртеп куймакчымын. Әмерне сарайга чакыртып та бирергә мөмкин иде. Үтә җаваплы, олы эш тапшырмакчыбыз. Аны әйткәнче бер шартым бар: синең ни эшләгәнеңне, сарайдан нинди йомыш алуыңны ни диван әһелләреннән, ни хезмәтчеләреңнән һичберкем белергә тиеш түгел. Авызың йозакта буласы... Син шуңа разыймы?

Галиәкбәр абзый ике кулын күкрәгенә кушырып баш иде:

— Тыңлыйм һәм буйсынам, галиҗәнаб казнабаш! Сарай сүзе безгә канундыр... Әйткәнегездән чыкмам!

Казна йомышчысы бер мәлгә тынып калды, аның үткен күзләре алтынчының эчендә, күңелендәгесен белергә теләгәндәй, Галиәкбәрне бораулый иде.

Ниһаять, ул тагын телгә килде, тавышында тантаналы, кисәтүле аһәң чыңлый башлады:

— Бу сарай йомышы гына түгел... Казан патшалыгының хөкемдары, олуг хан Җангали галиҗәнабларының шәхсән әмерен алып килдем мин сиңа, кем... Галиәкбәр оста. Тыңла да күңеленә сеңдер! Телдән кергән телдән чыкмасын! Килештекме?

— Килештек, галиҗәнаб!

— Алайсаң, тыңла!— Казнабаш ярдәмчесе өсте көмеш тәңкәләр белән бизәлгән, һәр төге уттай янып торган асыл кеш тиресеннән тегелгән кыйммәтле, затлы бүреген арткарак этеп куйды, хәлләсен ычкындырып җилләнеп алды. Алтын эретергә әзерләнгән Галиәкбәрнең остаханәсендә мич ягулы, бөркү иде.— Мөмкин кадәр тиз арада син, Галиәкбәр оста, җиһандагы теләсә-кайсы хөкемдарга һәдия кылсаң да йөз кызартмаслык алтын аяк, ягъни зур касә, маңгаена патшалык мөһере басылган затлар гына кулланырлык зәргәри савыт әзерләргә тиешсең. Аның кемгә тәгаенләнүен чамалыйсың булыр. Җангали хан Мәскәү хөкемдарларының ачуына түгел, рәхмәтенә мохтаҗ. Аң бул! Кылган эшең белән син аңа кулыңнан килгән ярдәмне күрсәткән булып чыгасың. Синең осталыгыңа таянып, олуг хан сиңа, Галиәкбәр оста, мәрхәмәтен күрсәтә. Акласаң — рәхмәтенә, игелегенә тиенерсең, булдыра алмасаң, нәфрәте-ачуы озак йөрмәс!..

— Алтынны казнадан китерерләрме? Ул кадәр малны табуым бик шикле, галиҗәнаб казнабаш... Фараз итүемчә, шактый мал, асылташ кирәк булачак.— Галиәкбәр останың тамагы карлыгып китте, тапшырылган эшнең яшеренлеге, дәрәҗәсе аны каушаткан, бер мәлгә ихтыярын йомшарткан иде.— Алтын җамаякка алтын мыскаллап түгел, батманлап китәсе...

Казначының йөзеннән ризасызлык галәмәте йөгереп узды, күзләре кысылды...

— Казна белән дә, сарай белән дә берниндм бәйләнешең юк. Булырга да тиеш түгел. Оныттыңмы, яшерен йомыш, яшерен эш! Сарай алтынчылары эшли алмас иде дип беләсеңме?— Аның тавышына мыскыллау төсмере чыкты.— Галиәкбәр останың бер савытлык алтыны юкмы?

Алтынчы сүзсез калды. Тәхет иясе йөкләгән эш артык чыгымлы булырга охшый. Әмма ул үзен сүз белән, вәгъдә белән бәйләп өлгергән иде инде. Ризалыгын биргәндәй, янә тамак кырып кына куя алды.

— Борчылма, алтыны да, асылташлары да кире үзеңә кайтыр. Ханлык хәзинәсеннән тиешеңне алырсың. Хезмәтеңә түләү дә муллап буласы. Шартын беләсең, ул — телсезлек! Ярты гына кәлимә сүз чыгарсаң да, җәзасы артыңнан куа килер... Аңладыңмы?— Казнабаш ярдәмчесенең сүзләрендә тимер чыңы яңгырый башлады.— Бүгеннән эшкә тотын! Никадәр тизрәк тот-

сан, шулкадәр хәерлерәк... Әзер булгач, хәбәрен җиткерерсең. Тик белеп тор, сарайга барып йөрү юк!

Галиәкбәрнең иңсә җыеруын күреп, ул кесәсеннән бакыр тәңкә чыгарды. Күптән түгел генә акча сугу остаханәсеннән чыккан тәңкә шома, алтындай ялтырый иде. Оста аның акча түгеллеген, гадәттә сан язылася ягында нинди дер тамга барлыгын гына шәйләп өлгерде.

— Әзер булгач, шушы тәңкәне тоттырып йомышчыны җибәрерсең... Мин барын да аңлармын. Тәңкәне туп-туры миңа бирәсе, миңа кайтарасы. Мин барын да үзем аңлармын. Ләкин сүз белән, тел белән берни дә әйтәсе түгел. Язу турында инде әйтеп тә тормыйм.

Көтмәгәндә килеп кергән казнабаш ярдәмчесе алтынчы-останы тәшвишле уйлар өермәсендә калдырып, ашыгычлык белән чыгып та китте.

Бөтен осталыгын, зиһенен эшкә җикте Галиәкбәр оста. Йокысы качты. Затлы, кыйммәтле савытның рәвешен күз алдына китерү өчен генә дә атнаун көн вакыт узды. Күңелен иң үртәгәне, үрсәләндергәне ашыгычлык булды. Җитмәсә ул моңа кадәр мәгълүм бер генә зиннәтне дә кабатламаска, аларга охшамаска тиеш иде бит. Ата-бабаларының моңарчы сер итеп саклаган алымнарын, кайчандыр алар ясаган кыйммәтле әйберләрне хәтереннән үткәрде һәм, ниһаять, тапты. Ике ягына дугаланып, сыртларын кабартып ябышкан аждаһа рәвешендәге тоткалы, өскә таба киңәеп килгән зур авызлы чүлмәк төслерәк бер савыт иде ул. Як-ягындагы бизәкләренә асылташлар беркетте, нигезенә вак асылташлар сибеп чыкты. Чүлмәк гаҗәеп дәрәҗәдә матур, сокландыргыч иде. Бүлмәсенә бикләнеп ул аны кат-кат карады, ут яктысында әйләндергәләп бизәкләренең урнашуын кат-кат тикшерде. Өйрәнчекләренә, кәсептәшләренә, хатынына күрсәтеп, аларның хуплау, соклану сүзләрен ишетәсе килсә дә, тыелып калырга мәҗбүр булды. Галиәкбәр останың үз гомерендә ясаган иң гүзәл, иң затлы, иң кадерле һәм кыйммәтле нәрсәсе кеше-кара күзенә чалынмыйча гына кайсыдыр . хөкемдарның хәзинәсендә урын алырга тиеш иде.

Соңгы тапкыр тикшерде дә сандыгына бикләде. Җангали ханның йомышын тиешенчә, сөйләшенгәнчә, килешенгәнчә үтәү генә аны шөбһәле уйларыннан, бөлүдән коткарып калачак. Монысын ул үтә дә яхшы аңлый иде.

Ләкин... алай булып чыкмады шул!

Галиәкбәр оста әле һаман аңына килеп җитә алмый. Бер көн эчендә бөлде дә калды. Хезмәтчеләргә түләргә акчасы, эшен дәвам итәргә алтынкөмеше юк! Барысы да бетте, барысы да пыран-заран килде. Өстендә фәрештәләр канат кагынган муллыгы, җитенкел е ташып торган өйдән бәрәкәт китте, хәерчелекнең аяусыз кара күләгәсе кунды. Барысына да шул алтын савыт сәбәпче. «Аh! Никләр генә ризалык бирдем, никләр генә ярлык сорамадым?!» — дип уфтанды Галиәкбәр оста. Әмма инде киткәнне, югалганны берничек тә кайтарып булмый иде. Дәһшәте, кодрәте Кырымнан Мәскәүгәчә таралган олуг хан белән дәгъвалашып кара!

Барысы да көтмәгәнчә сәер һәм бик тиз килеп чыкты. Барысы да куркынычлы, саташулы төштәге сыман.

Казнабаш ярдәмчесенең ышанычлылары зур алтын касәне алып киткәндә әйттеләр:

• — Иртәгә ястү намазыннан соң йомышчың казнабаш ярдәмчесенең ишегең шакысын. Теләгәнең алыр,— диделәр.

Үзенә нинди олы йомыш йөкләнгәнлеген белмәгән өйрәнчек егет исә ике кулын селтәп кайтып керде. Керде дә куркынган кешедәй як-ягына карап, пышылдап сөйләргә кереште. Аның күзләре зур булып ачылган, үзе еш-еш сулый, урынында басып тора алмыйча таптана иде.

— И алтынчы остазым! Шәһәр имеш-мимеш белән тулы. Чат саен гаскәриләр. Җангали хан галиҗәнаблары шәһит киткән, имеш. Тәхеткә яңадан гайрәтле Сафагәрәй хан кайткан,— ди...

— Болары соңыннан, болары соңыннан,— дип бүлдерде Галиәкбәр.— Әйт, казнабаш ярдәмчесен күрдеңме?

— Юк! Капкалары бикле иде. Күпме шакысам да ачмадылар. Анда да гаскәриләр... Озак йөрергә шикләндем...

Галиәкбәрнең тез астына китереп суктылармыни, бердән хәле китте, йөрәген тотып урындыкка чүкте. Әллә нинди куркыныч сизенүдән күз аллары караңгыланды.

Йомышчы егет җыеп кайткан хәбәр исә дөрескә чыкты. Җангалинең кайдалыгын сөрәнчеләр кычкырып йөрмәде. Аның белән бергә ышанычлысы, казнабаш ярдәмчесе дә гаип булган иде. Үз хисабыңа Җангалигә асылташлар белән бизәп алтын касә ясаганыңны инде хәзер берничек тә раслап булмаячак. Шаһитлар да, раслаучы язу-ярлык та юк. Барысы да сер иде, яшерен иде. Хәер, булса да, аларны тотып казый янына, каты куллы булса да гаделлеге белән даны чыккан Сафагәрәй хан катына килү олы мәгънәсезлек дип бәяләнер иде. Алай гына булса әле...

Галиәкбәр оста башын ике кулы белән учлап тирән уйга чумды. Остаханәдәге бүлмәсендә бикләнеп көн утырды, төн утырды, әмма котылыр, байлыгын кайтарыр чара тапмады. Бер генә юл бар — ул да булса, баш иеп рибачыларга[1] ялыну... Рибачыга бурычка баткан кеше тиз генә котыла алмас. Тик башка чара калмаган, бүтән юл юк иде.

Көннәр уза торды. Галиәкбәр оста рибачыларга барасы көнен һаман-һаман чигереп килде. Ләкин кайчан да булса барыбер аларга баш ияргә кирәклеген, мәҗбүр булачагын ул инде күптән аңлаган иде.

Углы Фәритнең хәбәре исә Галиәкбәр останың күзләрен ачты, котылгысыз караңгылыктан чыгу юлын күрсәтте. Аның тотылмаган ефәктәй хәзинәсе бар ич әле! Мал-мөлкәтле, шан-шәүкәтле нәсел белән туганлашу гына аны хәзер бу афәттән коткара алачак. Гөлйөзем! Гөлйөзем! Бар өмет синдә. Син генә нәселебезне бөлгенлектән, хурлыктан тартып чыгара аласың. И тәңрем, мәрхәмәтеңнән ташлама!

Алгы якта ишекнең шартлап ябылганы, өйрәнчек егетләрнең бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләшкәне ишетелде:

— Һи, Гөлйөземнең нурлы йөзен күрер көннәр дә бар икән... Бик сирәкләдең әле... Сагындырып кына йөри бәләсен дә инде.

Телләренә салынган шәкертләренең сөйләнүен тыңлый-тыңлый, ата кеше кызын каршыларга әзерләнде. Исәбе — уйлаганын сиздерми генә кызның кылын тартып карау, күңелендә тоткан бер-бер егет бармы-юкмы икәнлеген тикшерү иде. Хәерле сәгатьтә!

— Иә, кызым! Сөйләп җибәр, хәлләрең ничек? Әш тә эш... Күптән утырып сөйләшкәнебез дә юк икән, — дип бик ерактан башлады ул. Кулына көмеш җептән пәрәвезләп үргән беләзекне алды, кысага утыртылган ташның ныклыгын тикшергән шикелле тоткалап карады да, кызгылт-шәмәхә нурдан күзе чагылгандай, керфекләрен кысып, кызына төбәлде. — Иә, котәм...

— Ни хәлләр дип... — Әтисенең юкка гына, тиктомалдан гына чакырмаганын сиземләгән Гөлйөзем кирәкле сүзләр таба алмый интекте. — Ни турында сөйлим соң, әти? И беләсеңме, әле мин бер калфак чиктем, остазымханым да, башка кызлар да аһ итте. Күчереп алдылар. Нигә ул бизәкне бездән яшерден, диләр. Аның ничек килеп чыкканын мин үзем дә сизми калдым бит... Шундый да матур булды... Күрсәтермен әле, яме, әтием.

Кызының сызылып киткән кашларына, шомырт кара күзләренә, иңнәренә төшкән калын толымнарына яратып, сокланып карап торды Галиәкбәр оста.

Улы сөйләгәннәргә әллә ни исе китмәгән иде аның. Җыенда кыз-кыркын, егет-җиләннең очрашуы, уен-көлке, җыр-бию дигәндәй, бер бездән генә калмаган. Бөтен яме шунда ич. Уйнар чаклары, дип фикер йөрткән иде. Әмма кызының пешкән җиләктәй өлгергәнлеген, чибәрләгән янача күргәч, бәяләгәч, күңеленә хафа керде. «Фәрит дөрес уйлый. Аллам сакласын, мондый чибәргә күз салучылар, нәфес сузучылар аз булмас. Әлхәмделиллаһи шөкер, нәселдә яман ат чыгаручылар булмады анысы. Шулай да кисәтеп куюы зыян итмәс...» Әмма аның уйлаганы, көткәне бөтенләй башка нәрсә иде: «Кем белән булган? Безгә тиң нәселме? Бөлгенлектән коткара алырлык

[1] Рибачы — арттырып түләү шарты белән акча, мал бирен торучы.

даирәдәнме?» Әгәр андыйлардан булмаса, кызга ирегә беләп, җыеннар, уеннар белән хушлашырга туры киләчәк. Иплап кенә сорашуында булды.

— Ярар, ярар, кызым... Җыен ничек үтте?

Гөлйөземнең битенә күе кызыллык йөгерде. Әтисенең юктан гына сорашмавын күптән сизенгән кызның йөрәге дерт итеп куйды. Ничек итеп атаң хәтле атаңа сөйләмәк кирәк! Әни сораса бер хәл иде...

Әтисенең тавышында кырыслык, катылык чалымнары пәйда булды:

— Кемнәр белән чыктыгыз, кайда йөрдегез, дим. Нигә дәшмисең? Нәселебезгә тап төшерməячәгеңне беләм анысы, əмма да ләкин, кара аны... Сүзем бер булыр...

— Әти, мин бала түгел ич инде. Үземнең нишләгәнемне беләм ләбаса...

— Шуңа күрә сорыйм да. Бала булсаң, сорап та тормас идем. Йә, көтәм...

— Мин... мин...— Кызның теле тотлыга башлады, ни әйтергә белмичә, толымын бармагына урарга керешге. Сораганын сөйләтмичә туктамаячагын, каты куллы булса да, гаделлеген, үзен яратканын һәм кичерәчәген белсә дә, йөрәк серен ата белән уртаклашу җаваплылыгыннан шикләнә, икеләнә иде. Гөлйөзем кинәт үзендә көч тойды, каушавы, икеләнүе бетте. Санька белән очрашуы, җыенда йөрүләре, абыйсының урлап качуы хакында сөйләде дә ташлады.

Галиәкбәр абзый тәрәзәгә карап шактый озак уйланып утырды, беләзекне бер алды, бер куйды, тик торганда өстәлдәге коралларны җыештыра башлады. Башындагы уйлары чуалды: «Дөрес, урыс белән туганлашкан кешеләр дә бар анысы. Әнә, сәүдә бистәсендәгеләр татар кызлары өчен җан атып тора. Араларында Мәскәү, Новгород, дала белән эш йөртүчеләре дә байтак. Мал-мөлкәтле адәмнәр... Бу кем? Бер талпынуда баерга, алдауйолдау белән мал җыярга килгән хөсетле бәндәләрдән түгелме?» Ул яхшы белә: урыслар Казан кызларына никадәр генә кызыкмасын, горурлыгын җуймаган хор казанлылар урыс кавеменә әйләнеп капланырга тормый. Мал өчен генә, бер күлмәк иминлек өчен генә ата-баба йоласыннан баш тартыргамы?! Әгәренки бер ыштансыз урыс баласы булып чыкса!?

Галиәкбәр останың көмеш карасы йоккан бармаклары өстәл тактасында биеште, нәрсәнедер сорарга җөрьәт итмәгәндәй, икеләнеп әйтте:

— Ул егетне кайсы яктан дисең инде?

— Угличтан ул, әти... Ярминкәгә бодай төяргә килгәннәр... Көймә белән...

— Аны... яратасыңмы димме?

Гөлйөземнең бите алсуланды, җәядәй киерелгән озын керфекләре тибрәнеп күзен каплады.

— Әйе, әти...

— Бер-бер хезмәтчеме, сәүдәгәр баласымы соң?

— Ул кадәресен мин белмим инде аның... Әтисен сәүдәгәр дип әйтте шикелле. Без бит ул турыда юньләп сөйләшмәдек тә.

— Әтисенең исемен дә белмисеңме? Алар бит үз исемнәренә атасы исемен дә кушып сөйләшергә ярата.

— Юк инде, юк, әти...

Галиәкбәр абзый хәтереннән Углич сәүдәгәрләрен барларга, таныш-белешләрен үткәрергә кереште. Алтын-көмеш белән эш итүчеләрне исенә төшерергә тырышты. Әмма зәргәр буларак үзе ярминкәләргә артык еш чыгып йөрмәгәнгәме, бодай төяүчеләрдән кемне дә белми икән. Авыр сулап куйды. Ата-баба һөнәренә тугрылык саклаган Галиәкбәр абзый бары тик алтын-көмеш белән эш итүчеләрне генә чын сәүдәгәр, чын мал иясе дип белә иде. «Күрәсең, бу егеткә юлны бикләргә туры килер. Гөлйөзем мәсьәләсендә дә ялгышырга ярамый. Соңгы өмет, соңгы ышаныч. Гөлйөзем бары тик саф алтынга ия малтабар нәселенә генә яр булачак. Үзенең киләчәге дә, безнең бүгенгебез дә аның кулында. Йа алла, мәрхәмәтеннән ташлама!» Күңеленнән шундый карар чыгарса да, Галиәкбәр абзый әле һаман икеләнә иде. Бер яктан, кызын рәнҗетәсе килми, әгәр бай нәселдән булса, урыс кавеме белән туганлашырга да күп сорап тормас иде. Икенче

яктан, ата-баба йоласы бар, билгесезлек бар. Урыс бабасы диган яманат кутэрүе дэ рэхэт булмас. Хэер, анысына төкерер дэ иде. Хөкемдарлар энэ илне, мэмлэкэтне ныгыту өчен кем белэн генэ туганлашмыйлар да, кемне генэ кэлэшлеккэ алмыйлар. Кичэге дошманнары түр башында утырыр. Барысына да үзенэ төшенергэ, белешергэ кирэк иде. Э хэзергэ хөкем бер булыр.

Кызына туп-туры карап әйтте:

— Кяфер белэн очрашуыңа риза-бэхил түгелмен. Моннан ары минем рөхсэттэн башка калага чыгу юк! Балачагың үтте...

Кызының агарып калган йөзе, бармакларының ефэк япманы урап, бөтереп тотуы, мөлдерэмэ күзлэре күп нэрсэ сөйли иде. Эмма ата кеше хөкемен үзгэртмэде. «Ярминкэгэ килерлэр дэ китэрлэр. Бусы да озак тормас. Югалыр да онытылыр. Яшь кыз күңелендэге вэсвэсэ дэ озакка бармас. Су өстендэ көймэ эзе тиз җуела. Иншалла, бу да шулай булыр...»

Мендэр юпь-юеш. Гөлйөзем тыела алмый. Яшьлэре ирексездэн агалар да агалар. «Кяфер — бик начар, имансыз, хөсетле бер бэндэдер. Ак канатлы, эчкерсез, очкынланып торган зэңгэр күзле чиста егет ничек кяфер булсын!»

Онытылып, кайгысына буылып күпме яткандыр, кинэт башына килгэн уйдан сикереп торды, күзлэрен сөртте. Ишегалдына чыгып җиз комгандагы чишмэ суы белэн битен чылатты. Хэрэкэтлэре җитезлэнде, томан элпэсе каплаган күзлэренэ нур кайтты.

Абыйсының бүлмэсенэ керде, ишек өстендэге чөйгэ карап, кинэт туктап калды. Абыйсының очлы башлы, затлы бүреге эленеп тора иде. Эһэ! Менэ монысы Фэритнең бэйрэмнэрдэ кия торган чалбары, ак күлмэге. Якасындагы, җиңендэге бизэклэрне Гөлйөзем үзе чигеп биргэн иде. Тагын нэрсэ? Тышта салкынчарак. Өскэ кимичэ дэ ярамас. Гөлйөзем ашыга-кабалана күлмэген салып атты, гадэтлэнмэгэн киемнэрне үлчэргэ кереште. Барысы да нэкъ аңа атап теккэн диярсең. Буйга абыйсы белэн бер чамадарак кызга аның киемнэре үтэ дэ килешеп, гэүдэсенэ ятып тора иде. Җилкэсе киңрэк киңлэгэн... Хэер, анысын гына кем карый аның...

Ул биленэ каеш салды, өстенэ җиңе терсэк буена гына җитэрлек итеп калдырылган, абыйсының буен тагын да зифа, озын итеп күрсэтэ торган билле җилэнен киде. Озаклап юанырга вакыт аз. Йөгереп килеп чөйдэге бүрекне алды һэм озын толымнарын баш түбэсенэ чорнап, аны очлы бүрек белэн бастырып та куйды. Тэрэзэдэ чалынган шэүлэсенэ сокланып карап алды. Кара син аны. Нэкъ яшүсмер егет! Танып карасыннар инде хэзер, бар!..

Аякта үкчэле читек, башта затлы бүрек. Морза баласымыни! Лэкин эле барыбер нэрсэдер җитми иде кебек. Аксөяклэргэ хас сыйфатларны хэтереннэн үткэрергэ керешкэн кыз аңлап та алды: хэнҗэре юк лабаса! Ул — затлылык, ирлек, егетлек, хөрлек билгесе. Көмеш кынына канатлы аждаһа сурэте уелган сөяк саплы кечкенэ хэнҗэрне дэ тагып җибэргэч, Гөлйөзем үзен тиешле сурэткэ керде исэплэп, канэгать елмаеп куйды. Эйдэ, хэзер танып карасыннар инде! Сэйранга чыккан угланда кемнең ни катнашы бар?!

Өйдэн чыгып киткэндэ бик тиз генэ хэл иткэн кыз таныш түгел мохитта бөтенлэй аптырап калды. Болактан Казан-суга хэтле халык мыжлаган җирдэ танышыңны түгел, үзеңне югалтырлык иде. Урыс сэүдэгэрлэрен күрде, эмма: «Сез Угличтан түгелме?» — дип сорарга батырчылыгы җитмэде. «Кемне эзлисең?» — диярлэр. Кыз бала: «Александр кирэк!» — дисенме?! Ояты ни тора. Гөлйөзем үзенең ирлэр киемендэ икэнен исенэ төшереп, чак кына көлеп җибэрмэде. Егет егет кешене сораса, оятмы?! Аягына көч керде, арыганлыгы онытылды. Иңнэрендэ канатлар үстемени, тагын дэртлэнеп, менэ-менэ очратачагына өметлэнеп базар эйлэнүен дэвам итте.

Күрэсең, иптэшенме, дустыңмы югалтканнар, аймыл булышканнар бер ул гына түгел. Энэ озын гэүдэле, ярсу кыяфэтле бер адэм үтеп киткэн һэр егетнең күзенэ керердэй булып карап кала. Эзлэгэне ул булмый, ахрысы, ачуланып, теш арасыннан чертлэтеп җиргэ төкерэ дэ, тагын озын куллары болгап китеп бара. Бер сэер ягын да абайлап өлгерде Гөлйөзем. Куе кара са-

каллы, калын кашлы, күрер күзгә яшь тоелса да картларча бөкрәя төшеп атлаган бу алла бәндәсе кемнәндер кача, шикләнә иде шикелле. Юка чикмән якасын бастырып куйган, башын бормаска тырышып, тирә-якны ялт-йолт күзәтә, кабалана иде кебек. Аның яныннан тизрәк үтеп китәргә ашыккан Гөлйөзем урыс киемендәге бу кешенең салкын карашын үзендә тоеп, сискәнеп китте. Калын каш астындагы яшел күзләр, әйтерсең, аны чишендереп капшый, үзәгенә үтәрдәй булып текәлгән иде. Тәне юеш, салкын бакага кагылгандай чирканып куйды. «И ходаем, дөрес юлда йөрми, ахрысы, бу алла бәндәсе».— дип укынып, тизрәк читкә китү ягын карады.

Әмма озакламый яшел күзле адәмне дә, базарга ник килүен дә оныта язды. Ташаяктан кала капкасына сузылган юл ягыннан ишетелгән яшерен дәрт, моң катыш өметләнү, талпыну сизелеп торган авазлар аны үзенә тарттагы, аяклары үзеннән-үзе шул якка атлады.

Үз-үзен белештермичә кешеләрне терсәге белән аралап алга үткән кыз, каршында ачылган күренештән, телсез кала язды. Бөжра ясап уратып алган халык арасында, яшел мәйданда нибарысы бер кеше — нәкышлап чиккән ак күлмәктән, куе зәңгәр төстәге чалбар балакларын саурый читек кунычына тыккан җыйнак кына гәүдәле яшь-яшь егет, озын чәчле, ак йөзле ялгыз көйче утыра иде.

«Ничек берьюлы шулкадәр күп аваз чыгара соң бу?» — дип уйлап куярга өлгермәде, серен аңлап, рәхәтләнеп елмаеп та җибәрде.

Хәйләкәр көйче барысын да шулкадәр оста җайлаган иде ки, ничәмәничә мәмләкәтләрне кичкән елгыр базарчылар гаҗәпләнеп тел шартлаталар, шаккатып бот чабалар иде.

— Билләһи, валлаһи, мондаен оста көйчене күргәнем юк иде...

— Тавышы да тавышы... Чичәннәрнең чичәне бу егет!..

— Афәрин! Мең яшә, акыллым! Дәрт-дәрман өстәдең.

— Казанның атаклы көйчеләре нәселеннән ул.— диде кемдер аны белгәне белән горурланып, танышлыгы белән мактанырга теләгәндәй тамак кырып.

Хуплау сүзләре бер дә юкка түгел: көйче, чыннан да, бер тылсым иясе булып тоела, көе, моңы, җыры, хәтта ки сөлектәй зифа сынын егетләрчә тотуы, карашындагы яшерен горурлыгы белән дә тыңлаучыларны әсир итә, көй хөкеменә буйсындыра иде.

Гөлйөзем аның тапкырлыгына, осталыгына, исемнәрен дә белеп бетермәгән уен коралларының саф авазларына сокланды. Әнә бит ничек җаен тапкан, берүзе дистә көйчене алыштыра. Егет муенына тал чыбыгыннан бөгеп бөҗра кигән, аңа беркетелгән дүрт-биш курай сыбызгысы иреннәренә терәлеп үк диярлек тора. Беләгенә каеш белән төрле зурлыктагы шөлдерләр, көмеш кыңгыраучыклар таккан, читек башында юка җиз түгәрәкләр беркетелгән ниндидер җайланма. Аягын хәрәкәтләндерүгә, алар бер-берсенә бәреләләр дә нечкә чың тудыралар. Кулында ялтыравык бизәкле, күз явын алырлык итеп шомартылган думбыра... Егет үзе исә шакмаклап ясалган зур давылбаз[1] өстенә кунаклаган. Әйтерсең, тәхеттәге шаһзадә!

Менә ул кара мыек астыннан ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды да күзләрен бер ноктага төбәп талпынып куйды. Шөлдерләр, кыңгыраучыклар чыңлады, җиңелчә аяк сикертүгә буйсынып, җиз түгәрәкләр чылтырады, озын бармаклары иркәләгәндәй итеп кенә йомшак кылларга кагылды. Иреннәре курайның әле берсенә, әле икенчесенә өрә, күчеш саен аларның тавышы үзгәрә, йә калынайя, йә нечкәрә, тойгыларга яңа төсмер биреп сызлана иде. Егетнең хәрәкәтләре кызулаган саен уен кораллары да дәртлерәк тавышлар чыгара, йөрәк тибешен дөпелдәп сулкылдаудан алып бәргәләнгән кошчык хәленә китерә, талпындыра, канатландыра иде. Кинәт кенә ул читек үкчәләре белән ике яклап давылбазга китереп бәрде, киереп тарттырылган үгез тиресеннән калын, куе авазлар чыкты. Әйтерсең, туптан аттылар. Гөрселдәүгә охшаш бу ярсулы аһәң көйне бозмый, киресенчә аны тагын да көчәйтә, дәртен ташыта иде.

---

[1] Давылбаз — барабанның бер төре.

Гөлйөзем карады да катты. Ул моннан китә алмый, сихерләнгәндәй көйчене күзәтә, тылсымлы авазлар дулкынында тирбәлә, күңелендә үзе дә аңламаган шашкын хисләр баш күтәрә. Көй ләззәте бөтен тамырлар буйлап тарала, аяк бармакларына хәтле чемердәп куярга мәҗбүр итә иде. Күңелендә җыелган, Александр атлы егеткә әйтәсе килгән, әлеге әйтелмәгән барлык хисләре, тойгылары шушы көйдә чагыла, канатлана иде кебек.

Көй бетте. Әсәрләнгән тыңлаучылар шактый озак тын да алмыйча басып тордылар. Аннан соң, әйтерсең, көтмәгәндә давыл купты, мәйдан өстендә тойгыларын тыя алмаган йөзләгән кешеләрнең хисләнеп кычкыруыннан өермә күтәрелдемени, егет каршындагы ачыклыкка алтын, көмеш таңкәләр ява башлады.

— Һай, егет, рәхмәт яусын! Җаныма дәва бирдең!

— Мең яшә! Мең яшә!..

Ә көйче боларны, әйтерсең, күрми дә, сизми дә. Йөзендәге бер генә чалымы да үзгәрмәде. Тыйнаклыгы, үзен тотышындагы басынкылыгы аны тагын күкләргә күтәреп мактарга, рәхмәтләр яудырырга мәҗбүр итә иде.

Ул халыкны тынычландырырга теләп кулын күтәрде. Әгәр «Җиргә егылыгыз».— дип әйтсә, сүзсез аның ихтыярына буйсыначак халык төркеме тынсыз калды. Тагын курайлар телгә килде, кыллар тартылып дерелдәде. Егетнең иреннәре арасыннан ниндидер таныш түгел яңа, озын көйнең моңнары агыла башлады:

И кабер, ачыл, тиз ачыл, сөйгәнемне мин күрим,
Мин керим аның янына, мин бу дөньяны сөймим.
Гүр караңгы, гүр кысынкы, гүр юеш сиңа, бәләм.
Мин туйдым якты дөньядан, мин синең янга килəм.

Гөлйөземнең күзләренә яшь тыгылды, йөрәге актарылуга чыдый алмыйча иренен тешләде, йодрыкларын кысты. «И бәгърем, синең дә шундый кайгыларың бармыни соң? Нинди җаһиллар сиңа шундаен яра ясады?! Ничек итеп якты җир йөзләрендә тормак кирәк»... Буе белән сыгылып төшкән кыз үзе дә сизми бер-бер артлы шул сүзләрне кабатлый иде. Тирәягында тагын кемнәрнеңдер сиздермәскә тырышып мышкылдаганы, хисләрен тыя алмыйча тирән итеп: «Ah!» дип куюлары ишетелә башлады. Күрәсең, дөнья тигез генә түгел. Җаннарын ачып карасаң, кемнең дә йөрәгендә ярасы, үзе генә белгән җәрәхәте, тешләрен кысып, иреннәрен чәйнәп онытырга теләгән, ләкин онытылмый, бетми, сүнми торган кайгысы, хәсрәте бар.

Җыр Санька-Александрны, базарга ни өчен килүен исенә төшерде. Җырдан, моңнан исергән Гөлйөзем көйчене тагын, тагын, тагын тыңлыйсы килсә дә, үзен мәйданны ташлап китәргә мәҗбүр итте. Сөйгәнең өчен, аның белән бергә булу өчен елау-сыктау гына җитми, күрәшә, үз дигәненә ирешә белергә дә кирәк икән әле. Сөйгәне янына хәтта кабергә керергә риза егет турындагы җыр юкка чыгарылмагандыр. Ярыннан аерылган — якты дөньядан туйган... Ә Гөлйөзем үз дигәненә ирешәчәк. Белеп тор, газиз әткәем, аңла мине, кадерле әнкәем, аяк чалма миңа, туган абыем!

Җырчыдан ерагайган саен кыз күңелендә хәлиткеч адымны ясау теләге кискенләште. Сузарга ярамый иде.

Урыс сәүдәгәрләре, гадәттә, Болак буенда туктый торган иде. Ялгышмаса, Санька да шулай дигән иде кебек.

Яр өстендә бер-берсеннән берничә терсәк ара гына калдырып салынган лапаслар янында, чыннан да, лыбыр-лыбыр урыс телендә сөйләшәләр иде. Боларның кайсылары Угличтан икән соң? Гөлйөзем тәвәккәлләде, борыны белән ярга терәлгән көймә читендә авыз эченнән нидер көйләп утырган калын сакаллы берәүгә эндәште:

— Абзый кеше, әйтегез әле зинһар, сез Угличтан түгелме?

— Юк, энекәш. Ялгышмасам, алар күптән кузгалды бугай инде. Юкка эзлисең,— дип кул селтәде көймәче агай битараф кыяфәт белән.

Шулчак Гөлйөзем каршында, җир астыннан үсеп чыккандай, яшел күзле, калын кашлы баягы адәм пәйда булды. Ул кызның үзәгенә үтәрдәй иттереп, сеңдереп карап алды да ярарга тырышкандай төче тавыш белән сүз кушты:

— Без идек Угличтан, ачуланмасаң... Кем кирәк иде димме, нәрсә кирәк иде дип әйтимме?.. Баш өсте. Әмереңне тыңлыйм, и-и яшь шаһзадә...

Ялагай кылануын яратмады, тавышының төчелеге ошамады, Гөлйөзем җавап бирергә ашыкмады. Башыннан йөз төрле уй чагылып үтте. Бүген инде икенче тапкыр юлына каршы төшкән бу кешенең нинди дер мәкере, хәйләсе бар сыман тоела иде. Ләкин, күрәсең, башка чара юктыр. Очраган бер кешедән: «Сез Угличтан түгелме?» — дип сорашып йөреп булмый ласа. Бәлки, юкка шикләнәдер. Тәҗрибәсез, әле мыек та типмәгән яшь егетне шаяртырга маташуыдыр. Базарда ни булмас! Әнә ич, үзе әйтеп тора: «Мин Угличтан».— ди. Чит-ят кавем кешеләренең гадәт-йолаларын каян белеп бетерәсең!..

Гөлйөземнең башка чарасы юк иде, гозерен чыгармый булдыра алмады.

— Миңа... Александр... кирәк иде,— диде ул ихтыярын җыеп.— Аны күрәсе бар иде...

Чикмән якасын утыртып куйган яшел күз ялт-йолт як-ягына каранып алды да, Гөлйөземгә якыная төшеп, пышылдауга күчте:

— Кайсы Александр икән соң?— дип сузды ул ниндидер уеның очына чыгарга тырышкан кеше шикелле.— Бездә Александрлар күп...

— Сәүдәгәр баласы... Яшь егет... Казанда бодай төятергә тиешләр иде.

— Ә-ә... аны әйтәсең икән...— Яшел күзленең тавышына кайгы төсмере чыкты, гәүдәсе тагын да бөкрәя төште.— Ай, энекәш, олы кайгыга дучар булдык бит әле... Иделдә батып үлде бит ул... Сизми дә калдык. Юкса...

Ул тагын нидер сөйли, Гөлйөземнең күзенә керердәй булып хәбәрнең аңа ничек тәэсир иткәнен күзәтә иде.

Кызның күз аллары караңгыланып китте, авызын учы белән каплады. Күзләре зур булып ачылды.

— Ялгышмыйсыңмы, абый... Ул озын, сары чәчле, зәңгәр күзле...

— Беләм, беләм,— дип бүлдерде кара чикмән иясе.— Уналтысы яңа гына тулган җиләктәй егет иде. Ничек ялгышыйм... Үле гәүдәсен судан үз кулларым белән тартып чыгардым...

— Булмас, булырга тиеш түгел, ялгышасың,— дип пышылдады Гөлйөземнең иреннәре. Ул үзенең ни сөйләгәнен, ни эшләгәнен белми, аяныч, әрнүле хәбәр бөтен миен ялкын белән чорнаган, күз алдында утлы боҗралар биешә иде.

Хәбәрнең яшь егетне яшен суккандай миңгерәтүен күреп торган Иван сәүдәгәр кызларга охшаган бу чибәр егет белән Александр арасында ниндидер бәйләнеш барлыгын инде күптән аңлаган, серне чиштерерлек әмәлләр, ысуллар эзли иде.

Кинәт ул корбанына ташланган елан тизлеге белән Гөлйөземнең колагыннан эләктереп алды да күз ачып йомганчы ике лапас арасындагы бушлыкка тартып кертте. Усал итеп, зәһәр ысылдап сорады:

— Ә хәзер инде дөресен әйт! Аны нигә эзлисең?

Хәлнең мондый борылыш аласын бөтенләй көтмәгән Гөлйөзем югалып калды, тимер җәмки булып кыскан көчле бармаклардан котылырга теләп башын боргалады. Әмма яшел күз көчле, кысканнан-кыса, ычкындыру уенда да юк иде.

— Әйт тизрәк! Тизрәк, тизрәк!— Тагын усал пышылдады ул.— Юкса...

Күзләренә яшь тула башлаган, ялварып еларга җыенган кыз бала кинәт үзенең ирләр киемендә икәнен, егет икәнен исенә төшерде. Әйтерсең, абыйсының киемнәре көч бирде, ихтыярына ирләрчә катылык өстәде. Яшен тизлеге белән ул хәнҗәрен тартып чыгарды да дошманының корсагына терәде, тавышына бөтен ачуын, рәнҗүен салып, усаллык белән кычкырды:

— Селкенмә! Казан егетләре белән сөйләшәсең!

Озын, каты бармаклар колакны ычкындырды, гаҗәпләнүдән яшел күзнең керфекләре челт-челт йомылды, ияге аска салынып төште.

— С-си-ин... с-и-и-н.— дип мыгырданып куйды ул гәүдәсен туры тотарга тырышып. Күз кырые белән очлы хәнҗәрнең кояш нурында ялтыравын күреп өлгергән Иван бер мизгелгә каушап калды.

Ә кызга шул гына кирәк иде дә. Кайчандыр сабан туенда чин ягыннан килгән көрәшчеләрнең кул сугышын караганы, батырлардан берсенең сынын җыя алмыйча сыгылып төшкәне күз алдына килде. Аны-моны уйлаганчы, аягы хәрәкәткә килде, дошманының корсак астына китереп тә типте. Кара чикмән иясе әллә нинди ямьсез тавыш белән илереп урталай сынды, кычкырып уаланырга кереште.

Гөлйөзем исә лапас арасыннан атылып чыкты да, артыннан бер өер эт кугандай, шәһәргә таба томырылды.

Бетте! Барысы да юкка чыкты!.. Александр атлы фәрештә егет татлы төш булып томанга уралып югалды. Күңелдә бушлык, йөрәктә әллә нинди җирәнгеч хәлсезлек. Дөньяның яме, яшәүнең тәме калмады.

Гөлйөзем сүнде, күз алдында сула, сүрелә башлады. Бер мәгънәсезгә йорт буенча кая сугылырга белмичә йөри-йөри дә бүлмәсенә кереп бикләнә, яшьләренә буыла. Хәзер аңа беркем дә, дөньядагы бер кеше дә ярдәм итә алмый.

«Аһ, көйче егет! Никләргә генә сине күрдем, моңлы җырыңны ишеттем икән! Әллә соң ул моң, ул яшьсез елау, сыкрау минем күрәчәгемне сиздергәнме?! Кабереңнең кайда икәнен генә дә белмим бит ичмасам!» — дип өзгәләнә Гөлйөзем. Иреннәре арасыннан яңа ишеткән моңлы, җан тетрәткеч хәсрәтле көй агыла.

> И кабер, ачыл, тиз ачыл, сөйгәнемне мин күрим,
> Мин керим аның янына, мин бу дөньяны сөймим.
> Гүр караңгы, гүр кысынкы, гүр юеш сиңа, бәләм.
> Мин туйдым якты дөньядан, мин синең янга килəм.

«Әллә суларга ташланыргамы соң! Минем җаным да аныкы белән Идел дулкыннары арасында очрашыр, күбәләккә әйләнеп, бергә талпыныр иде!»

Кайгылы хәбәр белән бергә, зәргәр Галиәкбәр абзыйлар өенә тагын бер хәсрәт керде.

Бер көн эчендә бар мөлкәтеннән колак кагуын, бөлгенлеккә якыннарыннан яшерә алган, эчтән генә янган, эчтән генә сызган Галиәкбәр оста язмышның бу сынавын күтәрә алмады. Кызының күз алдында сулуында үзен дә гаепле санаган атаның чәчләренә чал кунды, күзенең нуры сүнде. «Шулкадәр дә ярату буламы икәнни соң, и раббым!» Алтын кайгысы, мал кайгысы артка чигенде. Әгәренки терелеп кайта калса, Гөлйөземне ул үз кулы белән шул егет кулына тапшырыр хәлгә җитте. Ләкин соң инде. Үткәнне кайтарып булмый.

Әни кеше үзенчә юатырга тырышты, иркәләп, назлап сөйләштерергә, кайгысын куарга җай эзләде:

— Кызым, балам, күз нурым! Ул кадәр өзгәләнмәсәнә, бетермәсәнә үзеңне... Дөнья бер бүген белән бетми. Үзсын вакыт... Шуннан да олы дәва юк. Күңелеңә ошаган егетне тагын очратырсың. Барысы да онытылыр... Кем булса да каршы килмәбез. Үз теләгәнеңә чыгарсың...

— И-и-и әни! Миңа беркем дә кирәкми инде... Теләсә нишләтегез!..

> Гүр караңгы, гүр кысынкы, гүр юеш сиңа, бәләм,
> Мин туйдым якты дөньядан, мин синең янга килəм...

Кыз авызыннан ишеткән җырдан әнисенең тәне эсселе-суыклы булып китте.

— Йа хода! Үзең сакла, акылыңа гына зыян килә күрмәсен!

## Качкынлыкта

Дус итеп серең сөйләмә,
Таңда дошман булмасын,
Дошман дип хәтерен калдырма,
Таңда дустың булмасын.

Татар халык мәкале

— Мин кайда?..

Үзенең тавышын танымады Санька. Йөрәге калтырый, бөтен буыннарында хәлсезлек. Әйтерсең, ул үзендә тау-ташларны актарырлык егәр тойган яшь егет түгел, ниндидер бер сыек бөҗәк, әкәм-төкәм.

— Ашыкма, улым, ашыкма!—диде кемдер.—Ятып тор. Аллага шөкер, гомереӊ бар икән әле. Кулымда җан бирерсең, дип котым очкан иде.

Санька күзләрен ачып җибәрде һәм өстенә иелгән ак сакаллы, бөтен битен, маңгаен тирән җыерчыклар буразналаган таныш түгел картны күреп, күзләрен йомды.

— Кем син? Мин кайда?

Кинәт үзенең көймәдән качуы, озак-озак ярга таба йөзүе һәм су төбенә китү газаплары, үлем белән тартышуы исенә төште. «Димәк, мин теге дөньяда! Алайса бу карт кем? Ул да минем шикелле Идел төбендә әҗәлен тапкан алла бәндәсеме? Әллә су иясе шул үземе?! Алай булса, ни өчен «Гомереӊ бар икән әле» дип сөенә?

Ул күзләрен ачарга курка, төрле хәшәрәтләрнең муенына, битенә, кулаякларына сарыласын, канын суыра башлауларын көтеп чиркана иде. Тирәякта тынлык. Һәр сүүсем артыннан кан баскан пыяла күзләр аны күзәтәдер, бер кыймылдауга салкын тәнле хәшәрәтләр өерләре белән аӊа ташланырлар, бер-берсен изә-сыта чолгап алырлар сыман...

Тагын кемнең дә булса тавыш бирүен көтеп бик озак ятты Санька. Инде телсез, хәрәкәтсез яту газабы түзә алмаслык авыртуга әйләнеп, башын, гәүдәсен кыса башлагач, шикләнеп кенә, сиздермәскә тырышып керфекләрен ярым ачып дөньяга күз салды. Бака ефәге томалаган, төрле хәшәрәтләр мыжлаган караңгы чоңгылда түгел, ә Иделнең текә яры астында, ат башыдай зур, шома чуерташлар өстенә җәелгән печәндә ята икән лабаса. Су иясенең чәчләре урынында зәһәр еланнар мыжгымый, кыска гына калдырылган чал чәчле мөлаем карт икән ул.

— Мин кайда соң? Монда ничек килеп эләктем?—диде ул, ниһаять, зиһенен җыя төшеп.

— Борчылма! Син имин-аман җирдә,—диде карт әүвәлгечә тыныч тавыш белән.—Шөкер, изге рухлар ярдәменнән ташламаган. Күземне ачтылар, үзеңне коткарырлык көч бирделәр. Бигрәкләр дә шомлы җиргә эләккәнсең. Суның котырып аккан урыны. Көймә-каекларны да әйләндереп кенә сала ул...

Санька ашыгып, каударланып муенына тотынды. Аска сөйрәгән хәрам мал урынындамы? Шул гына батырды, төпкә сөйрәде ич. Каһәр төшкән алтын!..

Аның хәрәкәтләрен, сискәнеп нидер эзләвен күзәтеп торган карт сүрән генә елмайды.

— Курыкма, улым! Юлбасар түгелмен. Кеше малына кызыкмыйм. Тамагым тук, өстем бөтен. Шөкер, Идел анысын да, монысын да муллан бирә...

Оятыннан бугазына төер килеп тыгылган Санька каршы бер сүз дә әйтмәде, икенче якка борылып ятты һәм тагын онытылды. Хәлсезлек үзенекен итте, күзләре йомылды. Картның тыныч, ягымлы тавышыннан бөтен җанына рәхәт бер иңрәү сыман талгынлык иңгән иде, тирән йокыга талганын сизми дә калды.

Менә Идел өстендә сары табак булып кояш күтәрелде, бөтен тирә-як кош-корт сайравына күмелде. Чикерткә кычкыра, бал кортлары,

шөпшәләрнең чәчәктән-чәчәккә күчеп выжылдаганы ишетелә. Күк йөзе чалт аяз. Ник бер болыт әсәре булсын! Санька куе үләнлектә, чуар келәм булып җир җиләге, ак чәчәк баскан аланлыкта ята, имеш. Матурлыктан, киңлектән хәйран калган, телен әйләндереп бер сүз дә әйтә алмый. Чү! Әнә алан башыннан кочагын җәеп аңа каршы бер кыз йөгерә түгелме соң?! Гөлйөзем ич ул! Тизрәк, тизрәк аңа каршы чыгарга, көмеш тавышын ишетергә, серле моң тулы күзләренә багарга! Кулга-кул тотынып чәчәкле алан буйлап барырга да барырга иде. Аның бәхете күңеленә сыеша алмый, очаталпына, бөтен гәүдәсе каядыр ашыгып канатлана иде.

Санька сикереп торырга теләде, әмма җирдән кубарыла алмады, гәүдәсе тораташтай каткан, бармакларын селкетерлек тә хәле юк. Ә Гөлйөзем аны чакыра, кулларын сузып ялвара, нидер ымлый, күрсәтә иде. Егет тешләрен кысып, бар көченә алга ыргылды һәм кинәт җирдән аерылуын сизеп алды. Күз алдындагы алан кинәт юкка чыкты. Ул сәерсенеп як-ягына каранды һәм үзен яр буендагы ташлар өстендә күреп, ыңгырашып куйды.

Әлеге саташу төш түгел! Гөлйөзем аны көтә ич... Аның коткаруын, кара төндә карчыга булып очып кунган залим әдәмнәр кулыннан йолып алуын көтә. Тизрәк, тизрәк янадан Казанга! Гөлйөземне коткарырга! Ашыгырга, бик тә ашыгырга кирәк!.. Юкса соң булуы мөмкин.

Ни кылырга белмәгән Санька үрсәләнеп картны эзләде. Изге күңелле бу кеше ярдәм итми калмас, юл күрсәтер, ни эшләргә кирәген өйрәтер. Буш итмәс аны Санька. Күн янчыгындагы байлык тулаем да кызганыч түгел!.. Кая гына киткән соң бу карт?! Артында яфрак кыштырдаганнан сискәнеп борылып карады. Куаклар арасындагы тар сукмактан коткаручысы чыгып килә иде. Кулындагы ятмәдә беләк буе җәен, өч кызылканат чапалана.

— Бәхетең бар икән,— дип елмайды ул.— Табышлы көн булды бу! Беренче ауга... сине эләктергән идем, икенчесенә, күр, никадәр байлык.

Картның йөзе җыерчыклы, кояшта янган, каралган булса да, күзләре яшь, очкынланып балкый иде. Аңа җавап итеп елмаюын Санька сизми дә калды.

— Рәхмәт инде сиңа, бабакай! Гомерем буе изгелегеңне онытмам. Тик монда озак кала алмыйм, миңа мөмкин кадәр тизрәк Казанга кайтырга кирәк.

— Кайтырсың... Боерган булса... Шулай да мин сиңа ашыкмаска киңәш итәр идем.

Аның сүзләрендә сабырлык һәм әйтелеп бетмәгән мәгънә тоеп, Санька ашыгып муенына үрелде. Ике куллап көч белән тартуга бау өзелеп тә чыкты.

— Менә, бабакай, минем бүтән нәрсәм юк. Изгелегең өчен шушыларны ал да... юл күрсәт! Кая барыйм?

Карт өстенә сикерергә әзерләнгән зәһәр еланны күргәндәй, Саньканың ачык изүенә текәлде, күзләренә курку, нәфрәт чыкты. Кинәт ике кулын да алга сузып, ямьсез, карлыккан тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Кит! Кит! Күземнән югал, кяфер!— Һәм үз-үзен белештермичә артка тайчанды. Аягы шома ташка эләгеп, буе белән чалкан барып төште.

Әле яңа гына үзенә елмайган, ашыкмаска киңәш иткән картның нәрсәдән шул хәтле куркуын аңламаган Санька муенына үрелде һәм анда тагын хәерсез янчыкны табып, телен тешләде. Кулында исә... ефәк җепкә тагылган саллы көмеш тәре тирбәлә иде. Егет аны ачу белән җиргә бәрде һәм карт янына тезләнде. Балыкчының күзләре йомылган, ул тавыш-тынсыз калган иде. Калтыранган куллары белән картның башын күтәрде, аны йомшакка, үзе яткан җиргә илтеп салмакчы иде. Баш астындагы ташта кызыл тап күреп, йөрәге жу итеп китте. Карт җайсыз егылган да очлы ташка эләккән, күрәсең. Җәрәхәтеннән кан саркый иде.

Менә ул акрын гына күзләрен ачты, бернәрсә аңламыйча Санькага карап торды һәм тагын керфекләре йомылды.

— Бабакай!.. Ни булды сиңа? Нишлим? Ничекләр генә ярдәм итим,— дип өзгәләнде Санька.— Нидән курыктың син?

Ул аның нәрсәдән куркуын аңлый алмый интегә. Христианга да, яһудигә дә, мәҗүсигә дә бердәй тигез караучы казанлы тәредән генә шул хәтле өрекмәс бит инде.

Карт телсез иде.

Санька624ың бөтен гәүдәсе куырылып килде, йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып бәргәләнә башлады.

Гөлйөзем янына талпынган җанының кыйналуына түзә алмыйча, ачу белән үзенең күкрәгенә сукты. Ләкин никадәр генә ашкынса да, ул карт балыкчыны болай гына калдырып китә алмый иде. Нәрсәдер эшләргә, нидер кылырга кирәк. Ярдәм көтәр кеше юк. Ул яр буйлап йөгереп урап килде, картның шалашын, йә булмаса торган куышын табарга иде бит. Ерак та түгел комташны киртләп баскычланып күтәрелгән сукмакны күреп алды һәм алга ыргылды.

Яр өстендәге куе агачлык арасындагы аланда сыңар тәрәзәсе Идел ягына караган, түбәсен камыш белән япкан кечкенә генә өй тора иде. Санька кабаланып шунда чапты, җиңел сулап куйды. Менә ярдәмгә кешеләр чакырыр, картны кертеп салырлар, урнаштырырлар. Аннан соң... Казанга!

Өй тирәсендә тынлык. Ишегалдындагы учак күптән сүнгән. Таганга асылган җиз казан буш. Тирә-якта кара күмергә әйләнгән кисәү агачлары гына аунап ята. Шылт иткән аваз да юк. Санька тамак кырып куйды һәм улбу ишетелмәгәч, кыюланып ишекне шакыды. Җавап бирүче булмады. Тагын шакыды һәм ишекне ачып җибәрде. Түр башындагы мич, аңа терәп салынган сәке, чүлмәк савыт-саба, бернича тәбәнәк урындык һәм балык тоту ау кирәк-яракларыннан башка өйдә бернәрсә дә юк иде. Аңлап алды: картның йорты булырга тиеш бу! Һәрхәлдә, монда картны беләләрдер.

Йөгереп яр астына төште һәм картны күтәреп алып менде, сәкегә җайлап салып, өстенә каплады. Тагын нишләргә икән дигәндәй як-ягына каранды. Аста калган балыклар искә төште, тагын шунда йөгерде. Аларны күтәреп менгәч кенә Идел өстенә күз салды.

Елга уртасында ялгыз көймә чайкала. Савелий Кузьмич көймәсе. Аның җилкәннәре төшерелгән. Артка тагылган өч каекның өчесе дә юкка чыккан. Көймә, ишкәкләрен салмак кына шапылдатып, Казанга таба төшеп бара. Әнә көймә борынында берәү күренде, ул кулларын маңгаена куеп Идел өстен күзли, көймәдәге башка кешеләр дә сузылып-сузылып тирә-якны күзәтәләр. Яр буена табарак бер-берсеннән чирек чакрымнар ара калдырып, өч каек килә. Алдагысында Савелий Кузьмичның тузгыган чәчле башын, бер тон эчендә сыгылып төшкән баһадир гәүдәсен дә абайлап була. Менә ул каек төбендәге капчыктан түгәрәк ипи алды һәм нәрсәдер укынып, аны агым уртасына йөздереп җибәрде.

Саньканың йөрәге жу итеп китте. Аны эзлиләр түгелме соң?! Карт балыкчы менә нәрсәгә ишарәләгән икән. Түгәрәк икмәк кеше баткан җирдә туктап әйләнә башларга тиеш. Әгәр бу ырым чын булса, икмәк Санькага таба йөзәчәк. Бетмәгән ризыгың сине эзләп табасы...

Егет тавыш-тынсыз гына куаклар арасына чумды. Күзләренә тыгылган яшьне йодрыгы белән сөртә-сөртә куелыкка атлады, иреннәре бертуктаусыз пышылдады да пышылдады:

— Әтием, бәгърем, кичер мине! Нинди утларга салуымны беләм... Тик нишлим?.. Ни кылыйм? Гөлйөземне күрмәсәм, миңа якты доньяның мәгънәсе юк! Кичер... Ә мин... кайтырмын. Кайтырмын!

Ни эшләргә белмәгән Санька тагын яр буена чыкты, тагын куаклар арасына качты, көймә Идел борылышында күздән югалганчы җанында икеләнү хисе бәргәләнде. Җилкән колгалары борылыштагы калкулык артына күмелүгә эчендә ниндидер бер җеп өзелгәндәй булды, җаны тынычлап калды, күңеле урынына утырды. Икеләнү хисе, әйтерсең, шул колгаларга уралып еракка, Идел киңлекләренә кереп юкка чыкты.

Санька ашыкмый гына коры-сары җыйды, ишегалдындагы учакка ут элде һәм җәенне чистартып, кисәкләргә турап, казанга салды. Кичтән бирле бер кабым ризык кермәгәнлеге үзен шактый сиздерә башлаган иде инде. Сукмак читләреннән эзләп әрекмән яфрагы табып алды. Карт балыкчының

арасына ябарга кирәк булыр. Бәрелгән җиргә әнисе шундый яфрак яба торган иде.

Карт әле һаман күзен ачмаган. Егет аның маңгаен тотып карады. Ут яна. Күрәсең, Санькаdebug коткарганда үзе дә суга чумган. Бөтен тәне кызыша. Һушына килсә дә, аны мондый хәлдә ташлап калдыру турында уйларга да ярамый иде.

Шулпа быгырдап кайнап чыкты. Санька белә: балык шулпасына юа, кузгалак, балтырган ише нәрсәләр килешә. Аларны эзләп тапты, мич аралыгындагы тәпәннән тоз килеп чыкты. Пешкән балык исе, шулпа исе, төрле үләннәрнең хуш исе борынны кытыклый башлады, авызга су җыелды. Ул ашыкмый гына ашны җамаякларга бүлде. Их, бер генә кисәк икмәк булсачы! Хәер, шулпа болай да ашап туйгысыз. Җәен ите ап-ак булып, кисәкләргә таралып тора. Ачык һавада мәмрәп пешкән балык теләсә-нинди талымчан кешенең дә нәфесен кузгатырлык иде.

Ашны карт янына китереп куйды һәм аны уятырга теләп, маңгаена учын салды. Аның тиз генә тормаячагын белсә дә, инәлеп кабатлады:

— Бабакай! Тор инде, уян! Ач күзеңне... Әнә балык та пеште. Бабакай дим...

Балыкчы карт күзләрен ачты, танымыйча Санькага карап торгач, куллары белән аны куган хәрәкәтләр ясарга керешле. Учларын читкә каратып селтәнүе: «Күземнән югал, кит»,— дигәнне аңлата иде булса кирәк. Санька аңлый алмый интегә: нигә куа ул? Санька аңа нинди зыян китергән? Шундый ук куркыныч затмыни соң ул? Бәлки, теге каһәр суккан янчык шулай тәэсир итәдер. Ул озак уйлап тормыйча, мич кырыендагы почмактан үткен пычак алды һәм шартлатып янчыкны кисеп төшерде, аны кая куярга белмичә аптыраныл торгач, ишек катындагы ау кораллары арасына ыргытты. Ятсын шунда. Кемгә дә булса бәлки файдасы тияр әле!

Карт янә күзләрен ачты. Шуны гына көтеп утырган егет, кашыкка аш алып, аны картның иреннәре янына китерде.

— Бабакай, аша инде!...

Әллә ялваруы тәэсир итте, әллә карт чыннан да бик ачыккан иде, бу юлы каршы килмәде, егет кулыннан ризык алды. Аның битләре алланып китте, күзләренә нур кайтты. Сәер итеп, текәлеп Санькага, аның йөзенә, көлмәк якасындагы бизәкләргә карап торды. Әмма аңа мөнәсәбәтен үзгәртмәде. Аның йөзеннән ризалык та, канәгатьсезлек тә, курку да, шикләнү дә абайланмый. Ул тулысы белән үз эченә бикләнгән, аңа гына мәгълүм ниндидер бүтән бер дөньяда яши сыман иде.

Санька картның урын-җирен рәтләде, башындагы әрекмән яфрагын алыштырды да ятарга ишарәләде. Үзе сөйләшмәгән кеше белән ул да ирексездән ым-ишарә аша аралаша башлаган иде. Карт сүзсез генә урынына ятты. Ул һаман нидер уйлый, нәрсәгәдер борчыла кебек. Егет аңа комачауламас өчен тышка чыкты да чирәмгә сузылды. Мәңге бетмәстәй тоелган көнне ничек тә уздырырга кирәк иде. Тизрәк бабай гына терелсен дә...

Төнге урман уртасында учак дөрли. Ялкын телләре бер-берсе белән узышып күккә үрли. Коры агач шартлап-шартлап куя. Учак янында ике шәүлә тирбәлә. Салмак кына сөйләшәләр.

— Бабакай, сиңа мин гомерем буе рәхмәт укырмын! Үлгән идем ич инде. Син мине кабердән тартып алдың...

— Анысы шулай,— дип көрсенә карт тавыш.— Бу хакта бүтән сөйләмә. Җыясы ризыгың калгандыр. Әҗәтеңне кайтардың инде...

— Юк, юк, бабай!— Яшь тавыш каударланып, бүлдерүләреннән курыккандай кабаланып сөйли.— Мин үземдәге бөтен алтынны сиңа калдырам! Кешеләр арасына, калага кайтырсың. Картлыгың балда-майда үтәр...

— Юкны сөйләмә! Миңа алтын кирәкми. Бөтен явызлыкның, мәкернең башы шунда. Аңа ягылып, җанымны пычратасым килми. Булган хәтлесе дә бик җиткән! Алтыннарың кирәгер әле. Яшь кешесең. Күрәчәгең алда...

— Бабакай! Мин бит чын күңелдән... Ярдәм итәргә теләп... Әтием хәлле кешеләрдән... Аннан гына безгә зыян килми.

— Ярый... Әйтеп бетерим инде алайсаң. Баштарак мин сине угры-фәлән түгелме дип шикләнгән идем. Ушкуйниклар азынды. Шуларның берәрсе түгелме дидем. Хәзер белдем, синдә алтын мәкере, явызлыгы йокмаган. Күңелең чиста. Тик кара төндә ничек Иделгә төшүеңне белмим. Анысы миңа караңгы... Һәрхәлдә үз ирегең белән түгелдер...

— Их, бабай, белсәң иде эчемдә нинди утлар дөрләгәнен! Үзем монда, җаным Казанда минем. Кошлар булып очып китәр идем...

Карт тавыш әкрен генә кеткелдәп куйды:

— Яшь чакта барыбыз да шундый... Барыбыз да канатланып очар идек...

Учак дөрли. Учак янында балыкчы карт белән Санька. Ялкын шәүләсе картның йөзендә бии. Егет аңа карап үз уйларына чумган. Балыкчының аны башта чоңгылдан коткаруы, аннан соң өрәк күргәндәй куркып үз яныннан тибәрүе, соңра тагын аңа мәрхәмәтенең сәбәбен аңлый алмый интегә. Бөтенесе нибары ике көн эчендә давыллы өермәдәй уйнап үткән шомлы вакыйгаларда нинди дер аңлаешсыз әзлеклелек бар кебек. Мәрхәмәт һәм нәфрәт, дуслык һәм дошманлык, үз итү һәм читкә тибәрү... Алар шулай бер-берсенә бәйләнеп, үрелеп киләләрме соң әллә?

Мәхәббәте хакына ут-суларга керергә әзер егет ашкыну белән сабырлык арасында, ук булып очу теләге һәм Идел буенда яту мәҗбүрлеге арасында гаҗиз. Учактагы утны ул үзенә тиңли. Йөрәгендә шундый ук ялкын дөрли ләбаса.

Ашыкмый гына гәп йомгагын сүтәләр. Егетнең тышкы сабырлыгында дуамал ашкыну чалымнары, картның сабырлыгында күпне күргән кеше зирәклеге...

Аның үз туксаны туксан.

— Сабыр ит! Сабыр иткән морадына җиткән. Бу хәлеңдә син әлегә Казанга кайта алмыйсың. Иманым камил, анда күренүгә ук бәйләп Угличка озатачаклар. Әтиең сүзе үтә торган, каты куллы адәмнәрдән күренә. Үҗәтлектә синнән кайтыш булмас. Сөйләвеңнән чыгып фикер йөртәм: үзе китсә дә, дусларына әйтеп калдырыр. Белеп тор, сине көтәләр... Синең батып үлүеңә ышангандыр дип беләсеңме? Тагын бер генә соравым бар: алтыннарыңны әтиең үзе биргән идеме?

Саньканың битенә гөлт итеп ут кабынгандай булды. Йөзенең кызыллыгын сиздермәс өчен учактан читкәрәк китеп утырды. Телендә исә тагын шул ук сүзләр кабатланды:

— Нишлим соң? Нишлим, бабакай? Анда Гөлйөзем... Хәлен беләсең ич...

— Белгәнгә күрә әйтәм дә,— дип, соравын җавапсыз калдырганны сизмәгәнгә салышып дәште карт балыкчы.— Гөлйөземеңне әйтәм, кол-чуралардан булырга охшамаган. Ирекле кеше кызына Казанда кем дә кул күтәрмәс. Беләм! Күңелем шулай сизә, кызыңа берни дә булмас. Очрашырсыз, алла насыйп итсә, кавышырсыз да бәлки. Тик, әйтеп куям, ай-һай авыр, күтәреп булгысыз авыр эшкә алынгансың. Ә хәзергә түз! Ата-анаңа да хәбәр җибәрерсең. Вакыты җиткәч, сине Казанга озату җаен табармын...

Балыкчы карт сүзен әйтеп бетермәде, нәрсәдер исенә төшкән, ашыгыч эше бар кеше сыман ашыгып йортка кереп китте. Озак та үтмәде, кулына ике терсәк озынлыгы кипкән курай тотып килеп чыкты, нидер вәгъдә иткән кебек өметләндереп әйтте:

— Хәзер мин сиңа гыйбрәтле бер кыйсса сөйлим. Аңларсың... — Үткен пычак белән курайның бер очын кыеклап кисеп төшерде, ике бармак ара калдырып тишек уйды, тагын бераз ара калдырып яңа тишекләр ясады. Уйчан карап, тамак кыргалап алгач, курайны иреннәре арасына куеп өрә башлады. Кипкән курайдан, гап-гади үлән сабагыннан моңарчы ишетмәгән, урман-даланың үзе кебек үк серле, тылсымлы, моңлы көй агыла башлады. Саньканың бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Әйтерсең, аны алыштырып куйдылар, җанын тырнап торган уйлары каядыр очты, күңелендә өмет, ышаныч ныгый башлады кебек. Ул аның нинди өмет, нинди ышаныч икәнен дә белми, тик курайдан агылган көйдән тамырларына көч кергәнен, ашыгып бәргәләнгән җанына сабырлык иңгәнен, сынган рухы яңарганын гына тоя.

Карт күзләрен йомды. Ярым ачык иреннәреннән шул көйгә сузылган, гыжлауга охшаш авазлар яңгырады. Саньканың мондый әйтешне гомерендә беренче кат ишетүе. Чит-ят булса да, рухи халәтенең бөтен нечкәлеген бары тик шушы көй, шушы өзгәләнү, газаплы моң гына аңлатып бирә ала дыр, моннан башка бар көйләр дә, җырулар да мәгънәсез кычкыру, шаяру гына булып каладыр сыман.

Йосыф, килеп, аңа үз камчысын сонды,
Хатын камчыга өг 'е дә кире бирде,
Камчыга ут кабынганын Йосыф күрде,—
Камчы янып, Йосыф кулын пешерер имди.

Зөләйха әйтте: «Күрдеңме, аңладыңмы,
Камчыга ут кабуга син таң калдыңмы?
Кулыңны пешергәнгә түзалмадыңмы?—
Ул ут мине кырык ел көйдерә имди!»...

Тылсымлы моң дөньясында сихерләнеп озак утырдылар. Тынлыкны балыкчы карт бүлде:

— Менә шулай,— диде ул озак көйләүдән арыган тавыш белән.— Дөньяда адәм балалары бер-берсе өчен яратыла. Ялгыз кеше — ярты кеше. Бербөтен булыр өчен әнә шул үзенә билгеләнеп дөньяга килгән затны таба, аның өчен көрәшә белергә дә кирәк. Мин сиңа сокланам, аны табарыңа ышанам. Бәхетеңне китереп бирмәсләр, егеткәем. Син шушы хакыйкатьне, үзеңә тиң затны белүең белән дә бәхетле кешесең...

Санька моң дөньясыннан айнып алмаган иде әле. Картның үзенә атап әйтелгән сүзләренең мәгънәсе соң гына барып җитте. Сораганын сизми дә калды.

— Бабакай, ә синең андый затың... ярың бар идеме?

Карт балыкчы сискәнеп китте. Бик озак бер ноктага текәлеп утыргач кына, авыр сулап, уфтанып җавап бирде:

— Бар иде, улым, бар иде...

— Ә кайда соң ул?

— Моннан ун-унбиш еллар булыр... Без яу чаптык. Гаскәри идем... Без юкта чакта урыс дошманнар килеп авылны туздырган. Минем... Зәйнәбемне дә харап иткәннәр... Язмышын белмим. Балаларымны да кылычтан үткәргәннәр.

Балыкчының күзенә яшь тыгылды, ул Санькага күтәрелеп карамыйча йортка кереп китте.

Авыр тынлыктан икесе дә котыла алмадылар. Соң гына йокларга яттылар. Ике арадагы элекке җылылыкка бәс сарды кебек.

Өченче көн дигәндә Иделдә Углич көймәсе күренде. Уңайга искән җилдән җилкәннәрен киергән көймә кызулаганнан-кызулый, агымның бар икәнен дә сизмичә югарыга үрли иде.

Санька аны яр башындагы калын имән артына качып күзәтеп калды. Күңелендә тагын нәрсәдер өзелде, күңеле тулды. Тик ул хәзер берни дә эшли алмый иде инде. Язмышы аны башка якларга чакыра, үзенең ярын чит-ят кавемнән эзләргә әйди иде.

— Менә хәзер Казанга кайтсаң да ярар,— диде аның көймәне озатып калуын күргән ялгыз балыкчы.— Моннан ярты көнлек юлда саклаубашы[1] бар. Аннан ике көнгә бер пайтәхеткә алмаш җайдаклар чаба. Мин аларга балык илткәлим. Бу юлы үзем бармам. Йомышымны син юлларсың. Үзеңә дә уңай булыр. Шикләнмә, тоткавыл Шәһитне сора. Ярдәм итми калмас. Яшь булса да, акыллы, төпле егет. Ордым-бәрдем түгел.

Саньканың биштәренә карт балыкның яңа тотылганын да, кипкәнен дә тутырды, чүлмәк белән уылдык тыкты, берничә көлчә салды.

— Юлда үзеңә дә җитәр, саклаубаштагыларга да...

---

[1] Саклаубашы — гаскәр сакта тора торган җир. Хәзерге пост мәгънәсендә.

Хушлашу, аерылышу авыр, икесенә дә моңсу иде. Зәйнәбенең балаларының һәлакәтен сөйләгәннән соң үз эченә бикләнеп калган картның ничек тә күңелен күтәрәсе, аңа юаткыч сүзләр әйтәсе килә иде. Хәтерендә күпме казынмасын, Санька андый зур югалтудан юатырлык сүзләр таба алмады. Гаскәриләр нәселеннән булмаса да, ничектер үзен дә гаепле шикеллерәк хис итә, «урыс дошманнар кылычтан үткәргән», дигән сүзләр аның бәгыренә дә пычак булып кадалган иде.

Кинәт башына бер фикер килде.

— Бабакай, Казанга бергәләп кайтыйк! Бергә-бергә көн күрербез әле,— диде ул дәртләнеп, уеның гадилегенә һәм картка ярдәм итәргә мөмкинлек чыгуга куанып.

— Юк инде, улым! Мин кешеләрдән биздем. Алар арасында кызык түгел миңа...

Карт Саньканың нәүмиз караган күзләреннән карашын читкә алды һәм:

— Бер тиенең дә кирәкми,— дип өстәп куйды.

— Нигә, бабакай! Мин бит чын күңелемнән әйтәм...

— Үпкәләмә! Дошман кавеменнән ярдәм ала алмыйм.

Саньканың яңагына чаптылармыни, бите кызарып чыкты, еш-еш сулый башлады.

— Мин бит сиңа дошман түгел,— дип кычкырып җибәрде ул ачыргаланып.— Алайса, ник миңа ярдәм иттең?! Нигә кире суга төртеп төшермәдең?

— Әй-йе, син дошман түгел,— диде карт сабыр гына.— Ялгыз башың син дошман түгел... Ялгыз бүре ат көтүенә һөҗүм итми. Өере белән килсә... Өернең үз кануннары бар. Динегез шулай кушамы, патшагызмы? Белмим...— Моңсу гына Санькага карап торды һәм елмаеп, яратып өстәп куйды:— Сине үземнең малаема охшатам. Ул да шушындый чибәр егет булыр иде... Йә, ярый. Юл кешесенең юлда булуы яхшы.

Карт кулларын кушырып дога укыды һәм кай тарафка ничек барасын аңлаткач, тагын бер киңәш бирде:

— Син сәүдәгәр баласы. Казанда бик авырга килсә, соңгы чиктә Әҗемгә барып егыл. Балыкчы бабайдан килдем диген. Үзе аңлар. Кулыннан килгән ярдәмен кызганмас. Малтабар булса да, әүлия кеше. Урыс бистәсенә борыныңны тыкма. Атаңның сер сыйдырыр кешеләре байтактыр... Угличка хәбәр итү җаен тапмый калмаслар.

Санька аягына чабаталар киде, аркасына биштәр асты. Казанда ни көтәсен анык белмәсә дә, күңеле күккә омтылган сабан тургаедай ашкынып җырлый, бер көйгә талпына: Алда Казан, анда Гөлйөзем! Алда нурлы кала, алда мәхәббәт сурәте!

Картка карап кул болгады да җиңел адымнар белән чикләвек куаклары арасындагы тар сукмактан атлап китте. «Эх, канатланып очарга иде дә ук җитмәс биеклектән лачын кебек ташланып, кызны күтәреп алырга иде! Очарга иде бергә-бергә... Канатлар талганчы, йөрәкләр бер булып тибә башлаганчы... Курсеннәр иде Казанда да, Угличта да...»

Санька Гөлйөземнән кала үзе өчен иң кадерле затны — ике яшькә өлкәнрәк агасын исенә төшерде. Угличта Вася барында аңа беркем дә бармак белән кагылырга да җөрьәт итми иде. Энесен җаныннан газиз күргән абый кеше аның яклаучысы, саклаучысы, кырыс һәм гадел остазы да иде бит! Әллә нинди бер ачыну белән Санька хәзер үзенә нәкъ менә агасы җитмәгәнлеген, таяныр кешесе булмаганлыгын аңлады.

Уйланып бара-бара шактый юл үтелгән. Бөдрә каеннар белән аралашкан наратлыкны үтеп, киң аланга килеп чыгуга, кемнеңдер кычкыруын ишетеп туктап калды.

— Саня-а-а! Санька дим, улым!..

Аланга ашыгып-кабаланып балыкчы карт килеп керде. Ул еш-еш сулый, аркасына тир бәреп чыккан, һәрвакыт пөхтә, җыйнак сакалы таралып, аңа нииндидер таныш түгел төсмер биргән иде.

— Ни булды, бабакай? Нигә ашыгасың?

Санькаңың соравын карт балыкчы җавапсыз калдырды. Каударланып изүенә тыгылды һәм калтыранган бармаклары белән күн янчыкны тартып чыгарды, аны ачулы кыяфәт белән Санькага сузды.

— Мә, ал! Миңа синең алтыннарың кирәкми...

— Соң, бабай... Миңа да кирәкми бит ул! Ал инде, бабакай... Минем сиңа игелек эшлисем килгән иде...

— Изгелекне хәрәмләшеп эшләмиләр.— Картның йөзенә кырыслык чыкты, һәр сүзен кистереп әйтте:— Синең яшиселәрең алда әле. Кирәге чыгар. Чыкмый икән, хәерчеләргә өләшерсең...

Санькаңың күзләренә яшь тыгылды. Ау кораллары арасына яшереп калдырган һәм тагын үзенә кире кайткан бу янчык аның кулларын яндыра сыман иде.

Сүрән генә хушлаштылар. Үзенә карата мәрхәмәтле дә, кырыс та була белгән, яктырып аталарча сөйгән һәм кинәт читкә этәргән картны Санька аңлый алмый иде. Табышмак булып калган балыкчы аның күңелендә аңлаешсыз хисләр өермәсен кузгатты.

Әнә, кояш инде төшлеккә күтәрелеп килә. Ашыгырга кирәк. Бәлки әле алмаш җайдаклар Казанга бүген үк чабар. Алар белән Санька да канатланып очар, бәхетенә якынлашыр.

*Ахыры киләсе санда.*



# ШИГЪРИЯТ

## Халисә Мөдәррисова

### Урман

Илаһи көз. Учак кебек урман.
Әйтерсең, ут, ялкын бәйрәме.
Үрелдисәм куздай тәлгәшләрдән
Җанга үтә очкын бәйләме.

Мин урманның җәйге чагын беләм,
Шаулап торган чәчкә аланын.
Җәй булса да бар хисләре тыныч,
Сабыр-салмак, горур чакларын.

Урап йөрдем күпме ул урманны,
Мин хуҗадай һәрбер җиренә,
Кунак булдым яшерен сукмакларда,
Төшенмичә аның серенә.

Шул ук урман. Шул ук түгел — башка,
Көз моңнары сарган бу күңел.
Хисләрендә моңсу дуамаллык,
Юк, бу инде гади җәй түгел.

Илаһи көз. Ялкын чәчә урман,
Тыелгысыз горур бер балкыш.
Гаҗизмен мин: керсәм чыга алмам,
Ялкын ялмар җанны, дим, — ялгыш...

* * *

Әйтерсең лә безгә санамыйча,
Үлчәмичә гомер бирелгән.
Кадерен белми көннәр-сәйләннәрне
Коябыз без гомер җебеннән.

Мәшәкатьләр, ыгы-зыгы белән
Бу дөньяны кемнәр үзгәртә!?
Кемнәр килеп, кемнәр киткәннәрен
Битараф ай гына күзәтә.

---

Халисә МӨДӘРРИСОВА — *Башкортстанда яшәүче татар шагыйрәсе. Журналыбызда күптәннән басылып килә. Башкорт телендә чыккан китабы да бар.*

Жандай дуслар белән бер сөйләшсәң,
Кайгыларың булыр көл-күмер.
Өлгермибез — эшем ияләре...
Әйтерсең лә ике бу гомер.

Зәңгәр кичкә, бәсле иртәләргә
Сокланып та туймас вакытта,
Кадерен белеп сөяр иркәләрне
Күмәбез без арзан ваклыкка.

Чәчеләбез, түгеләбез һаман,
Күз төбенә сызыла җыерчык.
Сәйлән-көннәр гомер-җептән ага,
Мәңге тик ай — көләч кыерчык.

## Кыйбла

Элмә күләгәләр күңелемә,
Үткәннәрдә кояш янганга.
Мәхәббәтем кайнар ком чүлендә
Яшел утрау булып калганга.

Киртә корма, көчең җитә алмас,
Сахраларда самум җиленә.
Яз булса да синең дарьяларда,
Дулкын какмый күңелем күленә.

Син кагылма минем күңелемә,
Сәҗдә кылсам, кыйблам чүлдәдер.

Ялгышларым бары үземнеке,
Хөкем итү язык кемгәдер.

Син кагылма минем үткәннәргә,
Үткәнемдә — кояш, җидегән.
Тын үзәннән күпме бәндә үткән,
Тик бик азлар күккә үрелгән.

Оҗмахларың миңа кирәк түгел,
Үз гөнаһым үземә җитәрлек.
Үз кыйбламда һаман сөю яна,
Пәйгамбәрләр тәкбир әйтерлек.

## Ак тынлык

Күңелем тулы ак тынлык,
Әйтерсең син булмаган.
Җәйдән калган агачта тик
Миләш-муенчак.. таган.

Күңелдә кыш. Ни кылсам да
Җәйне туктаталмадым.
Көрт баса күңел түренең
Иң садә сукмакларын.

Көрт баса. Шомырт иңендә
Җәй хатирәсе калган.

Ятимсерәп җилдә бии
Дивана кебек таган.

Бии, елый, өзгәләнә:
«Онытма берәү барда...»
Ә эзләр күмелеп бара
Кар баскан верандада.

Күңелем тулы ак тынлык,
«Уйла» дип, кайчак кына
Җилдә җилферди ялварып
Миләш-муенчак кына.

## Еллар аша

Еллар аша, юллар аша
Сиңа эндәштем бүген.

Син минем гомерлек бәйрәм,
Мәңгелек җырым минем.

Танымадың тавышымны,
Өздем телефон өнен.
Син мине мең гамь эченнән
Танырга тиеш идең.

Сагынырга, онытмаска
Бары син хаклы идең,

Син минем гомерлек газап,
Мәңгелек моңым минем.

Акыл белә: җеп очы буш,
Йөрәк тыңламый мине,
Буш телефон өне кебек
Һаман чакыра сине.

## Кызыл шомырт

Юлларыңны, җырларыңны,
Елларыңны бер оныт:
Учымда мөлдерәп ята
Егерме кызыл шомырт.

Арадагы упкын аша
Минем якка бау ыргыт...
Куз кебек җанны көйдерә
Егерме кызыл шомырт.

Мөлдерәп күзләргә бага:
«Соң булса да ал йолып
Югалган елларыбыздан...»
...Егерме кызыл шомырт.

Мең сорауга, мең назыңа
Җавапсыз калам тынып.
Учымнан җиргә коела
Егерме кызыл шомырт.

* * *

Тәрәзәгә маңгай терәп
Килер диеп юрадым,
«Килмәгәнгә елый», — димә,
Төн елый, мин еламыйм.

Ничә еллар өнсез, сүзсез
Күңелемә урадым,

Ишелә болыт урамга,
Төн елый, мин еламыйм.

Яңгыр ява шәһәреңә,
Ташка чәчри хыялым.
«Мине сагынып елый», — димә,
Күк елый, мин еламыйм.

# Рафаэль Газизов

* * *

Каенлыкта үлән тамырлана,
Үлән үсә күзгә күренеп,
Чәчәкләре былбыл сайравыннан
Тамып калганнардыр өзелеп.
Каен кызы судан кайткан чакта
Чиләгеме киткән чайкалып,
Каен суы эчкән шунда гөлләр—
Хуш исләре җанны айкарлык.
Чәчәкләрне каен аклыгымы
Колагыннан тартып үстерә,
Ә үләннәр, яшел чикерткәдәй,
Урман ешлыгына сикерә.
Урман куенына атлый гөлләр,
Сукмаклардан керәм ашыгып,
Бер җылы сүз әйтәм—юкәләрнең
Бөреләре китә ачылып.
Дәвалар мине ак каеннар,
Йөрәгемнең бардыр ярасы,
Каеннарның аклыкларын җыям,
Гомер буе чәчеп барасы...

## Мәскәү

Мин шәһәрне карап йөрдем бүген:
Метролары мәрмәр киемнән,
Әйе, бу залларның бизәгендә
Ялтырыйлар безнең тиеннәр.
Йортларында купшы мәһабәтлек
Ташып тора һәрбер ташыннан,
Монда мәшһүр ирләр яшәгәннәр—
Сурәтләре ташка басылган.
Табалмадым кырда бөкерәеп
Урак урган әни сурәтен,
Диварлары иркен, тик шәһәрнең
Күңеле тар булган, күрәсең.
Асфальт юллар буйлап атлап уздым,
Бездә җәеләсе юллардыр.
Кемгә генә һәйкәл куймаганнар,
Безгә куеласы сыннардыр.
Урамнарың, шәһәр, киң булса да,
Авыл өчен күңелең тар икән,
Мин ишеттем: курант чыңнарында
Безнең ыңгырашу бар икән.
Иван Калитадай, акчаларны
Авыллардан алдың сыпырып,
Авыл калды ялган вәгъдәләрнең
Төпсез чуманына утырып.

---

Рафаэль ГАЗИЗОВ — *Мамадыш районы Кече Кирмән авылында яши. Укытучы. Ике шигырь китабы авторы. Проза әсәрләре дә яза.*

Бездә юллар — тездән, колхозчылар
Бармак белән генә санарлык,
Аларын да инде, минеке дип,
Күтәп тора изге намазлык.
Кибетеңдә колбасалар очсыз,
Аңа карап беркем күп алмый,
Мин ышандым моңа үзем күргәч,
Ләкин авылдашлар ышанмый.
Шәһре Мәскәү, изгелек һәм гөнаһ
Яши синдә һәрбер адымда,
Чүмеч белән син бал чөмерәсең,
Сабы бәреләә безнең авызга.

## Йола

Уң аяктан атлап чыгып китәм
Көн дә бусагасын өемнең,
Бу йоланың, ахры, хикмәте бар:
Гел түрендә яши күңелнең!
Кемнәр әйтер, аның чишмә башы
Кайсы гасырларның төбендә?
Җәллад көчсез булган, милли кыллар
Исән килеп җиткән бүгенгә.
Болгар бабайлардан калган кыллар
Зыңлап куя кайчак җаннарда,
Сорый алар: мәчетләрдән җыйган
Көмеш айлар ята кайларда?
Манаралар ауган, корьәннәргә
Мөһер суккан... дуңгыз тәрәте,
Гыйлем йорты, мунчалары белән
Дөрләп янган Казан дәүләте.
Иманны да капшап йөргән баскак,
Ул тирәндә булган, тапмаган.
Ләкин җанда исән бер чәчкә юк,
Бер тамыр юк балта чапмаган.
Дәваларга вакыт тамырларны,
Терелтергә вакыт тарихны,
Кая болай кузгаласың, халкым:
Дөреслекне даулап барышмы?!
Шулай булса, уң аяктан атла
Изге бусагасын ил-йортның,
Чөнки Европада иң беренче
Чуен эреткәнең онытның.
Рәсәй яланаяк йөргән чакта,
(Баеганда — кисә чабата)
Тырыш болгар халкы, минем халкым,
Читек киеп йөргән ләбаса.
Читек кирәк, татар тагы булсын
Бәрхет түбәтәйләр башларда,
Әнә, ничә гасыр тарих үкси
Бабайлардан калган ташларда.
Изге халкым, уң аяктан атлап
Каршы ал син туар таңыңны,
Төзәлмәсме авыр җәрәхәтләр?—
Уң аяктан атлыйк адымны.

## Кызыл мәйдан. Казан соборы

Изге чиркәү күрдем, нигезенә
Бабайларның башы салынган.
Казан ханлыгының хак кояшы
Сүнгән, гөмбәзләргә ябылган.
Кирпечләрен күрдем — бабайларның
Каны сеңгәнгәдер — кызыллар,
Гөмбәзләре канлы йодрык булып
Еллар аша күккә сузылган.
Кызыл кирпечләре — чи ярадыр,
Бу яралар сызлый күптәннән.
Чиркәүләре белән мәчетләрне,
Туган телне таптап үткәннәр.
Чиркәүләрнең табан асларында
Болгар зиратлары сытылган,
Бабайларның изге кабер ташы
Чиркәү нигезенә тотылган.
Чиркәү нигезендә бертуктаусыз
Шыкырдата ташлар тешләрен.
Дүрт гасырлык гөнаһ кыла алар.
Нишләсен соң, ташлар нишләсен?!
Алып куя алмый таркау халык
Ташны түгел, хәтта саламны,
Ә чын ирләр мәңге ятып калган
Саклаганда шәһри Казанны.
Болгар бабайларның рәнҗешләре
Шыкырдаучы кабер таш мәллә?..
Улакларга сипкән онны ялап
Йоклый, җавап бирми мәхәллә.

## Тәрәзәләр

Тәрәзәңне ачып кош очырдың,
Ул кошчыгың, әни, мин идем.
Бәхет эзләп киттем туган җирдән,—
Бәхет агачыннан өзелдем...
Тормыш мәшәкате күмеп китте
Әниемнең чакыру сүзләрен.
Туган өем көткән биш күз белән.
Бишесе дә — әни күзләре.
Малай чакта ат дагасы кактым
Җеннәр кермәсен дип өемә,
Изге өйгә алар керәме соң?!
Дага какканмын мин үземә.
Кайтып киләм, чишмә сукмагында
Кая әниемнең эзләре?
Такта кадакланган тәрәзәләр,
Тәрәзәләр — әни күзләре.

# Чәчмә әсәрләр

## Гурий Тавлин

# АФӘТ

РОМАН

### Унберенче бүлек

**2**



Ике генә көн элек мин тышлыгында «Хранить вечно» дигән язулы «Дело»мны аерым бүлмәдә иртәдән кичкә кадәр ялгызым актарып утырдым. Шактый калын эшем белән тулысынча танышканнан соң, билгеләнгән статьяга риза, дип имзамны салгач, өстемнән тау төшкәндәй булды. Тик чебеннән фил ясауга чик килде дип шатлануым юкка булды, өч көн үткәч, тикшерүчем — капитан Горшенин мине кабинетына тагын мөнгерттe.

— Мин сезнең җинаятегезне 58-10 статьясының 1 нче матдәсе белән дөрес квалификацияләмәгәнмен, Кадыйров, гафу итегез, — диде ул сәламемне алгач, сейфыннан кәгазьләр чыгарып. — Шуңа күрә прокурор, эшегезне кире кайтарып, сезнең кылган җинаятегезне 58-10 статьясының 2 нче матдәсенә туры китереп квалификацияләргә кушты. Мин, ялгышымны танып, аның белән килештем. Сез хәзер, җинаять статьягызның үзгәрүе белән таныштырылуыгызны раслап, менә бу кәгазьгә кул куегыз, мин сезне бүген шуңа чакырдым. — Тикшерүчем миңа машинкада ниндидер текст басылган кәгазь сузды.

— Әйтегез әле, миңа гаепсездән ябыштырылган чирканыч статьяның 2 нче матдәсе нәрсәне аңлата?

— Контрреволюцион милләтчелек рухында советка каршы агитация алып баруны, Кадыйров.

Капитан Горшенин бу сүзләре белән, әйтерсең, түбәмә орды, колакларым шаулый башлады.

— Турысын әйтегез әле, сез үзегез минем шундый мәгънәсез агитация алып барганыма ышанасызмы?

Капитан канәгать елмайды.

— Ышансам, мин сезгә 58-10 статьясының 1 нче матдәсен билгеләмәгән булыр идем. Прокурор ышанмый, делогызны ул кире кайтарды.

— Бу яңа статья минем алдагы гомеремне күпмегә озайтачак?

---

Ахыры. Башы журналның 10 нчы санында.

— 3 елдан алып 25 елга кадәр.

— Рәхмәт. Кая, ручка бирегез, кул куям.— Мин машинкада нәрсәдер басылган кәгазьне укып та тормыйча аңа имзамны салдым.— Булды, урак тәгәлләнде, көлтә җыясы гына калды.

— Сез статьягыз үзгәрүгә борчылмыйсыз, киресенчә, шатланасыз кебек.

— Бу яңалыкны ишеткәч, сез мине йөгереп барып кабинетыгыз стенасына башын бәрер, йә мине кулга алырга санкция биргән, хәзер бу төрмәдә әтәч булып кычкыручы, камерасында күңел кайтаргыч спектакльләр куючы элекке республика прокуроры Ибраһим Надеев шикелле симулянтланып күз буярга тотыныр дип уйлаган идегезме?

— Причем монда стенага баш бәрү һәм симулянт Надеев? Настроениегезне аңламыйм мин сезнең.

— Үзегезгә дә, алла кушып, шундый статья бирсәләр, аңларсыз. Миңа суд тиз булырмы — шуны әйтегез. Гомеремнең 25 елга озайтылуын тизрәк раслатасым килә минем.

— Бәлки, сезгә 25 ел бирмәсләр, 10 ел белән чикләнерләр.

— Мин 10 елга риза түгел, капитан. Утыргач утыргач, нигә 10 ел белән чикләнергә? Мине җинаятьче итәргә күпме көч куйдыгыз, күпме чәпетергә тиешле ясадыгыз, тулысынча бирсеннәр. Колониягә эләккәч, сезне мин түземсезлек белән көтәрмен, безгә — иске танышларга — анда бергә-бергә гомер уздыру күңеллерәк булыр.

— Сафсата сатмагыз! Күр, оятсызны, мине үзе белән бер рәткә куя, көлык. Җитте, олагыгыз камерагызга!..

— Генрих Ягода белән Николай Ежов та үзләрен җинаятьчегә санамаганнардыр, хәзер кайда алар? Тәмугта. Мин сезгә дә, миңа һәм күпләргә эшләгән «яхшылыкларыгыз» өчен, шундый ук язмыш килүен телим.

## 3

Хөкем залына мине ялгызымны гына түгел, Риан белән бергә китергәннәр булып чыкты. Тимер ишекне шар ачып, башта кузовтан — мине, аннары Рианны төшерделәр. Без бер-беребез белән исәнләшмәдек, капылт кына карашып алдык та, автоматын атарга әзер хәлдә торкан таза бәдәнле, авыр адымлы солдат артыннан, кулларыбызны артка куеп, ишеккә юнәлдек.

Бина эченә кергәч, меңләгән кешеләрнең аяк табаннарыннан кыршалып беткән баскычтан икенче катка күтәрелдек. Анда безне тагын бер солдат көтеп торган икән, ул кыска гына коридордагы кырый ишекне ачып:

— Үтегез,— диде.

Без, «ахирәт дуслар», урта кул зурлыктагы бүлмә эченә уздык. Коралды солдатлар коридорда калды. Артыбыздан шап итеп ишек ябылды һәм йозакта ачкыч борылган тавыш ишетелде. Мин, кызыксынып, як-ягыма карандым. Күзләремә беренче булып бүлмә стеналарының шапшаклыгы, аларга кадак беләнме, бүтән очлы нәрсәләр беләнме тырнап язылган нииндидер язулар ташланды. Идән уртасында өстәл, берничә урындык һәм озын эскәмия тора иде. Мин, аларны әйләнеп үтеп, калын рәшәткә белән ныгытылган тәрәзәгә барып тышка карадым. Ишегалды буш, безне алып килгән «кара козгын» машинасы анда юк, ул киткән иде инде. Миңа ничектер моңсу булып китте. Юлда килгәндә күрелгән иркенлек белән мондагы ташландык ишегалды арасындагы капма-каршылык күңелемне тетрәтте.

Бүлмәдә без Риан белән икәү генә булсак та, бер-беребезгә сүз катмадык. Мин тормышымны диаметраль капма-каршы юнәлешкә борган ул чирканыч затны бүлмәдә юк, монда бербашым гына дип санадым. Рианны да минем белән бергә хөкем итәләр, ахыры, юкса икебезне дә монда нигә китерерләр иде, дип уйладым мин тәрәзәдән тышны күзәтүемне дәвам итеп. Бу бүлмәдә без банкага ябылган ике үрмәкүчтән кай ягыбыз белән ким? Аны, теләсәм, хәзер буып ташлый алам бит. Дөрес, әчке төрмәдә ярым ач яшәп, җиде ай эчендә ярыйсы ук хәлсезләндем, соңгы вакытларда сорауга чакырганда баскычтан өченче каттагы тикшерүчем бүлмәсенә көчкә күтәрелә идем инде. Әмма, үч алырга теләсәм, Рианны дөмектерерлек кенә дәрман

табар идем. Теләмәдем, җирәндем. Тизәккә кагылсаң, сасысы чыга, диган гыйбрәтле тәгъбир бар, нигә дип нәҗескә кагылып пычранырга?! Ярар, бер хаинне мин юк иттем, ди. Ләкин ул ялгызы гына булса икән! Алар хәзер шундый үрчегәннәр, көнгә унарлап бусаң да, барсын да буып бетерерлек түгел. Миңа очраганнары гына да әнә күпме... Сәхи ага, Геваргиз, Аитов, Капкаев, Йөзәев, Әүдәкиев, тагын әллә кемнәр... Безне саклаучы солдатлар нигә шулкадәр ваемсызлардыр: өстебездән бикләделәр дә оныттылар. Теләсә нишләсеннәр, ник шунда чәнчелмиләр, безгә аңардан җил дә, яңгыр да тими, диләр, күрәсең. Безнең монда бер-беребезне күрәлмәвебезне белмидер алар...

Вакыт үтә тора, безне хөкем итәргә ашыкмыйлар сыман, коридорда да, бөтен бинада да шылт иткән тавыш юк. Әти белән әни дә, хөкемне минем кебек үк, бәлки шушы бүлмәдә көткәннәрдер?.. Стеналардагы тырналмышлар арасында аларның да язулары юкмы икән? Юктыр, әти җитди, юк-бар белән шөгыльләнми иде, әнинең дә стенада ядкарен калдырырга кулы бармас, аның нәрсәнедер бозуны, пычратуны күрсә коты алына иде. Аннары аларны кулга алганга унөч ел узды ич инде, язу калдырсалар да, күптән юкка чыккандыр. Шулай да эш юктан стеналардагы тырмалышларны карыйм әле. Риан аларны әнә монда кергәннән бирле күзлекләрен ялтырата-ялтырата өйрәнә, аны, әйтерсең, шул язуларны тикшерергә махсус китерделәр...

Мин дә ишек каты стенага барып язуларга күз йөртә башладым.

Мы живем под собой не чуя страны,
Наши речи за десять шагов не слышны,
А где хватит на полразговорца,
Там припомнят кремлевского горца...

Башны Себер җибәрерлек шигырь бит бу!.. Кем язган аны һәм ни өчен республика Верховный суды бинасындагы бүлмә диварына тырмачлаган? Мин аны ирексездән ятлый башладым: «Мы живем под собой не чуя страны, наши речи за десять шагов не слышны...» Ике-өч минут та үтмәгәндер, дивардагы хәтәр юллар күңелемә уелдылар. Моңарчы бер генә шигырьне дә алай тиз ятлаганым юк иде, даһи кеше язгандыр аны.

Менә татарча язу:

Биек кенә биек моржалардан
Кара төтен чыга кыл кебек;
Тоткын хәлен кеше белми,
Бер көне дә аның ел кебек...

Кешеләр кайнар хисләрен, сагышлы җыр итеп, пычрак стенага уйганнар. Монда никадәр хәсрәт, борчылу, аптыраш, нәфрәт, каргыш, исәпсез-хисапсыз чарасызлык.

Мин ул язуларны уку белән мавыгып, безне хөкем залына алып керергә ишекне ачуларын да сизмәдем.

Хөкем залы. Монда кемнәрнең генә ачы күз яшьләре түгелмәгәндер?.. Менә сукыр язмыш мине дә зал читендәге меңнәр ләгънәтләгән шөкәтсез почмактагы каһәрле эскәмиягә, Риан янәшәсенә утыртты. Риан бу урынга үз ирке, үз теләге белән килде һәм, ул гына да түгел, ялгызына күңелсез булыр диптер, мине дә үзенә ияртте. Әнә хәзер калын пыялалы күзлеге аша, киңчел борынын ара-тирә тартып, такыр башын әле бер, әле икенче якка кыйшайтып буш залны күзәтә. Беләсе иде, нәрсә уйлый икән ул хаин?..

Кыл уртасында кешеләргә йөрергә юл калдырып унмы, унбишме рәт урындыклар тезелгән хөкем залында Риан белән миннән һәм безне киртәләгән коймачыкның ике башына баскан ике сакчы солдаттан башка кеше юк. Монда без генә булырбыз микәнни, дип уйлап бетерергә өлгермәдем, түрдәге ачык ишектән залга Оля килеп керде. Көтелмәгән бу хәлдән бөтен тәнем эсселе-суыклы булды. Миңа бүген суд буласын ул каян белгән, аны аңа кем әйткән?.. Передача китергәч, арабыздагы җепләрне өзәргә кирәклеген әйтеп язган идем ич инде. Аңа тагын ни җитмәгән?..

Оля атлый-йөгерә коймачык янына килде.
— Исәнме, Ирек?
— Исәнме, Оля. Син ник килдең монда, кем чакырды? Мине аз гына булса да хөрмәт итсәң, хәзер үк чыгып кит бу залдан.
— Ирек, бәгърем, кума, миңа синсез авыр, сагынуга түзалмадым...
Безне саклаучы солдатларның берсе аңа катгый итеп:
— Гражданка, китегез моннан, гаепләнүчегә беркем белән дә аралашырга рөхсәт ителми,— диде.
— Миңа ярый, мин Кадыйровның кәләше. Безнең бер-беребезне күрмәвебезгә биш былтыр инде.
— Гражданка, кабатлыйм, китегез моннан! Гаепләнүченең кеме генә булсагыз да, аның белән сөйләшергә рөхсәт юк.
Бу сүзләрне Оля ишетмәде дә кебек. Ул, коймачыкка тотынып, миңа яшьле күзләрен төбәп, басып торуын дәвам итте.
— Оля, күгәрченкәй, зинһар, тыңла солдатны, чыгып кит залдан, син мине инде юк дип сана. Безнең юлларыбыз аерылды, алар бүтән беркайчан да кушылмаячаклар. Бар чык, үз җаныңны да, минекен дә телгәләмә,— дип инәлдем аңа.
— Юкны сөйләмә, мин сине нинди генә хәлеңдә дә ялгызыңны гына калдырмаячакмын.
— Гражданка, китегез моннан, юкса сезне залдан кулыгыздан җитәкләп чыгарырга туры килер!
Оля, күзләрен миннән алмыйча, теләр-теләмәс артка чигенде. Шулчак каршыдагы ян ишектән егерме-егерме биш яшьләрдәге бер кыз чыгып:
— Басыгыз, суд килә!— дип кычкырды.
Риан да, мин дә урыннарыбыздан тордык. Кыз чыккан ишектән үк башта кулына зур калын папка тотып аксак ир-ат, аның артыннан кырыклар тирәсендәге бер хатын һәм өч ир кеше чыкты. Аксак ир зал идәненнән егерме биш сантиметр чамасы күтәрелеп торган калкулыктагы өстәл артына үтеп, андагы биек аркалы өч урындыкның уртадагысына утырды. Хатын аның уң ягына, ирләрнең берсе сул ягына урнашты. Калган ике ир залның ике ягындагы аерым өстәлләр артына бер-берләренә кара-каршы утырдылар. Суд килгәнен белдергән кыз калкулыктагы кечкенә өстәл артына урнашты. Риан белән мин эскәмиябезгә яңадан утырдык. Бераздан зур өстәл янындагы урта урындыкка урынлашкан аксак ир Риан белән минем якка карап:
— Сезнең кайсыгыз Кадыйров?— диде.
Мин урынымнан тордым.
— Үзегезне гаепләү сөземтәсе белән сез танышмы? Аны кулыгызга бирделәрме?
— Таныш. Бирделәр.
— Анда күрсәтелгән гаепләрегезне таныйсызмы? Үзегезне гаепле саныйсызмы?
— Юк, санамыйм.
Оля, һәр сүземне йотып алырга тырышкан төсле, миңа төбәлгән иде. Аксак ирнең судья икәненә суд барышында төшендем, минем гаебемне тану, танымавымны белешкәндә хөкем залына атлаганда үрдәк күк тирбәнеп укытучым Гаҗиева һәм күзләрен кашлары астыннан карап, ирennәрен турсайтып, Рианның фатирдашы Йозаев кереп урындыкларның иң арткы рәтенә утырдылар.
Аксак ир, янында утырган хатын һәм ир белән нәрсә турындадыр пышылдашкач, мине гаепләү сөземтәсен укып чыкты. Аннары залга карамый гына:
— Шаһит Саттаров биредәме?— диде.
— Биредә, биредә,— дип кабаланып урыныннан торды Риан.
— Сез Кадыйров турында нәрсә әйтә аласыз?
— Кадыйров советка, коммунистлар партиясе политикасына, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга дошман кеше. Аның чын йөзен мин фаш иттем, бирегә сезнең каршыга аны мин китереп бастырдым.

— Кабахәт!—диде аңа, үтерерлек итеп карап, бөтен залны яңгыратып Оля.—Сатлык җан булудан бүтән нәрсәгә ярыйсың син, әтрәк әләм!.. Кеше түгел, Иуда син, хаин!..

— Гражданка, безнең эшебезгә комачауламагыз, чыгып китегез хөкем залыннан!..

Оля судьяга каршы килмәде, башын горур тотып, ишеккә юнәлде. Әмма ул залдан чыкмады, арткы урындыкларның берсенә барып утырды.

— Кадыйров, әйтегез әле, Саттаров хаклымы?

— Ул миңа ташлаган гаепләр уйдырма! Мин — коммунист. Совет власте, бөек партиябез өчен сугышта кан түктем. Сталин исеме белән фашистларны тукмаштым. Саттаров миңа яла яга.

— Саттаров әйткәннәрнең нахаклыгын нәрсә белән дәлилли аласыз?

— Саф намусым белән.

— Бу дәлил түгел, коры сүзләр, Кадыйров.

— Саттаровның сүзләре юешме? Ул миңа яккан гаепләрен нәрсә белән дәлилли?

— Икегез дә утырыгыз. Ары киттек. Шаһит Гаҗиева мондамы?

— Монда.—Арткы рәттәге урыныннан, иреннәрен бөрештереп, Бану Гыйбатовна күтәрелде.

— Бирегә килегез.

Укытучыма ялган сөйләмәскә кисәтелүен раслатып кул куйдырдылар.

— Гражданка Гаҗиева, сез Кадыйров турында тикшерүчегә сөйләгәннәрегездән баш тартмыйсызмы?

— Баш тартмыйм, нигә тартыйм?.. Кадыйров студентларны халык дошманы Галимҗан Ибраһимовның зарарлы әсәрләрен өйрәнергә чакырды. Институт коммунистлары аны шуның өчен партиядән дә кудылар.

— Кадыйров, гражданка Гаҗиеваның сезнең хакта әйткәннәренә нәрсә өсти аласыз?

— Бану Гыйбатовна лекциясе вакытында мин биргән сорауны дөрес аңламады. Мин: «Үз вакытында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзүдә актив катнашкан, даһи Ленин белән берничә тапкыр очрашып сөйләшкән, соңыннан 1937 елда репрессияләнгән язучының әсәрләрендә бөтен нәрсә бүгенге тормышка дошманлык рухында язылганмыни?» — дип кенә сорадым. Өстемә ташланган бу гаепне дә таный алмыйм, гафу итегез.

— Кадыйров эше буенча шаһитләрдән монда тагын кем бар?

— Мин...

— Бирегә килегез. Сезнең фамилиягез ничек?

— Йөзәев.

Судта Йөзәев тә минем файдага сөйләмәде, республика дәүләт иминлеге министрлыгы тикшерүчесе капитан Горшенин безне кара-каршы очраштырганда әйткән сүзләрен үк кабатлады.

Аннары судья миңа:

— Сез, советка каршы буржуаз милләтчелек рухында агитация алып барып, нәрсәгә ирешергә исәп тоттыгыз?—дигән сорау бирде.

Бу сорауга:

— Минем совет строена каршы бернинди агитация дә алып барганым юк. Миңа буржуаз милләтчелек рухы ябыштырырга тырышу таза материягә юри салынган ямау кебек ярылып яткан хаталык,—дип җавап кайтардым.

Миңа бүтән сорау бирүче булмады. Бераздан каршы якта аерым өстәл янында утырган ир сүз алды. Аны судья, дәүләт гаепләүчесе, диде. Ул кеше бик ялкынланып башта халыкара хәлнең киеренкелегенә, АКШның котырынып коралланa башлавына, халыкны күпләп кыра торган атом-төш кораллары, бактериологик һәм башка төрле кораллар җитештерү темпын көчәйтүенә, өченче бөтендөнья сугышы, кешеләрне күпләп кыру коралларыннан файдалану куркынычы бик нык үсүгә тукталды. Аннары партиянең идеология фронтында илебездә буржуаз карашлар һәм гореф-гадәтләр калдыкларына кискен көрәш җәелдерүенә, империалистик Көнбатыш реакцион культурасының череткеч йогынтысын тәмам бетерүгә, барлык совет граж-

даннарын аңлы патриотлар итүгә, хезмәт ияләренең культура дәрәҗәсен тагын да югарырак күтәрү бурычлары куюына кагылды. Коммунистлар партиясе көндәлек эшендә совет кешеләренең физик һәм акыл сәләтләрен һәръяклап үсүен тәэмин итәргә, аларның аңындагы капитализм калдыкларын бетерергә омтылуына, илебездә ирешелгән уңышлар арткан саен сыйнфый көрәшнең кискенләшә баруына, шуңа күрә илебездәге социалистик стройга канәгатьсезлек күрсәткән һәм аны төрлечә җимерергә омтылган кешеләргә карата аяусыз булырга кирәклегенә аеруча басым ясады. Сүзенең ахырында ул атаклы чех коммунисты патриот Юлиус Фучикның, кешеләр, уяу булыгыз, дип юкка гына әйтмәвен телгә алды һәм мине кылган җинаятьләрем өчен 10 елга иректән мәхрүм итүне сорады.

Прокурор чыгышыннан соң башым әйләнгәндәй булды. Аның миңа 10 ел бирергә тәкъдим итүенә чын күңелдән шатландым. 10 ел — 25 ел түгел, төрмәдән чыкканда утыз биш яшьләр тирәсе була миңа, дип уйладым. Шул уйларга бирелеп, безне залдан бүлеп торган коймачыктан ерак түгел аерым өстәл янында утырган адвокатның үземне яклап нәрсәләр сөйләвенә колак салырга да оныттым.

Соңгы сүз миңа бирелде.

— Суд минем эшемә җитди якын килер, башбаштаклыкка чик куяр дип көткән идем,— дип башладым сүземне, судьяга карап.— Сез бирeдә тикшерү вакытындагы сорау алуларда капитан Горшенин миннән ничек совет строеның дошманы ясаса, шуны җиңел генә кабатладыгыз. Мәсьәләнең асылын ачыклау сезнең вазифагыз түгел, күрәсең. Ничек кенә булмасын, мин социалистик стройның дошманы түгел һәм, ианып әйтәм, булмам да. Мин — коммунист, иркемнән мәхрүм ителгәч тә коммунист булып калам. Ялганның аяклары кыска, ди халык, хаклыкның өстен чыгачагына, ялганның җиңеләчәгенә караңгы төнне якты көн алмашачагына ышанган кебек үк ышанам,— дип тәмамладым сүземне.

Хөкем озакка сузылмады, ул 15—20 минут чамасы гына барды. Мине 10 елга иректән һәм 5 елга сайлау-сайлану хокукларыннан мәхрүм иттеләр. Риан хөкемгә тартылмады, аны судка шаһит итеп кенә алып килгәннәр булып чыкты. Хөкемнән соң безне «кара козгын»га утыртып яңадан эчке төрмәгә алып кайттылар.

## Уникенче бүлек

### 1

Судтан соң мине эчке төрмәнең беренче катындагы гомуми камерага керттеләр. Анда алты кеше бар иде инде, мин җиденче булдым. Эчке төрмәдәге бу гомуми камера — хөкем ителгәннәр камерасы икән. Артымнан ишек шалтырап ябылу белән яныма озын буйлы, калын күзлекле, 30-32 яшьләрдәге кеше килеп:

— Судтанмы?— дип сорады.

— Әйе.

— Гомереңне күпмегә озайттылар?

— Ун елга.

— Аякларыңны сөрлектереп, мөгезләреңне дә сындырганнардыр, шәт?

— Әйткәнегезне аңламадым, аңлатыгызчы...

— Тоткыннар телендә аякларны сөрлектерү — сөргенне, мөгезләрне сындыру сайлау-сайлану хокукларыннан мәхрүм ителүне аңлата.

— Аякларны сөрлектермәделәр, алла саклады, мөгезләрне генә биш елга сындырдылар.

— Статьяң илле сигезме?

— Әйе.

Камерадагы бүтән кешеләр минем белән кызыксынмадылар. Аларның берсе караватка сузылып яткан да китап укый, икесе бик бирелеп шахмат уйный, берсе аларның уенын күзәтә, берсе йөзен чытып арлы-бирле йөрене иде. Мин булачак камерадашларыма күз йөртеп чыктым. Араларында татарлар юк кебек. Камерага кергәч тә минем белән әңгәмә башлаган бәндә түр почмактагы буш караватка күрсәтеп:

— Урнаш әнә шунда, минем янәшәмдә булырсың,— диде, һәм аннары,— таныш булыйк, Петеримов Алексей Павлович, инженер,— дип танышырга кулын сузды.

Мин, исем-фамилиямне һәм студент икәнемне әйтеп, кулын кыстым.

— Укуыңны хәзер син лагпунктларда дәвам итәрсең инде. Аларда институт яки университет кына түгел, чын академия — тәмугка имтиханнарсыз керергә әзерләү академиясе,— диде шахмат уйнаучыларның берсе тактадагы фигуралардан башын күтәрми генә.

Шулчак өстенә таушалып беткән коңгырт костюм кигән таза бәдәнле, чытык чырайлы, арлы-бирле идән буйлап йөргән кеше йодрыклары белән ишекне бик нык төя башлады. Коридордагы надзиратель:

— Кайсыгыз тәртипсезләнә, нәрсә кирәк?— дип кормушканы ачты.

— Мине полковникка илтегез!— диде аңа ишек төюче.

— Доцко, тәртипсезләнмә, полковник урынында юк, дип әйттем ич инде мин сиңа.

— Алайса министрга илт мине, ул урынындадыр.

— Министр анда тик сине генә көтеп утыра ди, бар. Ул бүген бөтенләй килмәде, беләсең килсә.

— Начальстводан кем янына булса да илт, миңа барыбер.

— Электәгечә хатының янына кайтарып җибәрүне сорамакчы буласыңмы әллә? Ул көннәр үтте, Доцко, үтте. Алар инде кире кайтмаслар, көтмә...

— Миңа полковник кирәк. Полковник яки прокурор. Шуларның икесенең берсен чакырмыйча, мин тынычланмаячакмын.

— Юашландыру күлмәге киертсәк, тынычланырсың. Бәяң төште. Синең кубызыңа берәү дә биемәс хәзер.

Надзиратель, әңгәмә төгәлләнгәнне аңлатып, кормушка капкачын шапылдатып япкач, Доцко, өстәл янына барып, анда торган калай кружкаларның берсенә зур алюмин чәйнектән тутырып су салды, аннары тәрәзә турындагы караватка сикереп менеп ачык форточканың пыяласын терсәге белән коеп төшерде. Шуннан соң, идәнгә коелган пыяла ватыкларын, ишек катында ботинка үкчәләре белән таптап ваклагач, учына җыеп авызына каплады да кружкага салган суын комсызланып голт-голт эчте.

— Хушыгыз, фраерлар, яратмый идем сезне, гаеп итмәгез,— диде ул, берәүгә дә карамыйча, кулындагы кружкасын өстәлгә куеп, мескен тавыш белән.

Аның идәннән пыяла ватыклары җыйган кулы каный иде, күм-күк булган ирен читләренә дә кан бәреп чыкты. Шахмат уйнаучылар тиз генә урыннарыннан торып камера ишеген куллары, аяклары белән дөбердәтергә керештеләр.

— Мин сине хәзер акылга өйрәтәм, адәм актыгы!— дип, надзиратель кормушканы ачты һәм шундук сагаеп артка чигенде.— Нәрсә кирәк сезгә?

— Тиз врач чакыртыгыз, Доцко, форточканы ватып, бер уч пыяла ватыклары йотты.

— Допрыгался, значит. Подохнет, туда ему и дорога. По нему давно могила рыдала,— дип, надзиратель кормушканы япты.

Ун минут чамасы үткәч, чырае язгы пычрак кар төсенә кергән Доцконы, носилкага салып, камерадан алып чыгып киттеләр.

Камерадашларым миңа шул көнне үк Доцконың провокатор булганын сөйләделәр. Доцко башта караклар шайкасында бер сәүдә складын басканда тотылып алты елга хөкем ителә. Лагерьга эләккәч, үзе белән аралашкан иптәшләре өстеннән ошак арты ошак ясап, лагерь башлыкларының ышанычын казана.

Сугыштан соңгы елларда Казанда кайбер семьяларны көпә-көндез фатирларына кереп суеп, әйберләрен талап чыгулар ешаеп китә. Милиция шактый вакыт бандитларның эзенә төшә алмый. Ә эшләнгән җинаятьне җәзасыз калдыруны хокук органнары хуп күрмиләр. «Акыллы баш» юристлар үтерелгән семьяга беренче тап булган, җинаять турында милициягә башлап хәбәр иткән кешеләрнең, күп уйлап тормастан, җинаятьтә үзләрен гаепliләр. Аларны кулга алып, үтерүдә һәм талауда катнашуларын төрлечә икърар иттерергә тырышалар. Үтерү һәм талауларда гаепләнеп кулга алынучылар исә эшләмәгән җинаятьләрне өсләренә алудан аяк терәп баш тарталар. Җинаятьне ачылмаган килеш калдыруны тикшерү органнары үзләре өчен хурлык санап, провокация юлына басалар. Тикшерүчеләргә кемдер аларның эшләрендә булышырга лагерьда утырган ошакчы Доцконы тәкъдим итә. Доцконы, озакка сузмый, төрмәгә алып киләләр һәм тикшерүчеләр аңа үзләренә нинди ярдәм кирәген аңлаталар. Ул эшлисе «хезмәте» өчен үзен кичекмәстән иреккә чыгаруны таләп итә. Тикшерүчеләр моңа риза булалар. Доцко ирекkә чыга. Берничә көннән соң аны үтерүләрнең кайда, кайчан, ничек булулары белән таныштыралар һәм җинаятьтә бернинди катнашлары булмаган, әмма үтерү һәм талауларда гаепләнеп кулга алынган кешеләр янына утырталар. Доцко камерадашларының ни өчен утыртылулары, нәрсәдә гаепләнүләре белән кызыксынып, эшнең ничек «булганын» сөйләтә. Гаепсездән гаепләләр аңа тикшерүчеләренең нәрсәне икърар иттерергә тырышуларыннан зарланалар. Петро Доцко алар сөйләгәннәрне «мыегына чорный бара» һәм үз «эше» белән тикшерүче янына чакырылгач, фәлән урамда яшәгән фәләновлар семьясын вәхшиләрчә үтереп талап чыккан фәләновның «сөйләгәннәрен» түкми-чәчми язып бирә. Аннары үтерү һәм талауда гаепләнүче кешене Доцко белән кара-каршы очраштырып, сорау алалар. Җинаять эшләмәгән һәм аны эшләү башына да килмәгән кеше үзенә нахак ягылган гаепләрне танымый, әлбәттә. Ә Доцко аны, син миңа камерада үз телең белән фәлән көнне, фәлән вакытта, фәлән кеше белән фәлән урамда фәләннәрне үтердек дип сөйләдең, дип бичараны «фаш итә». Шул юл белән, ниндидер банда эшләгән унбишме, егермеме җинаять өчен нахакка гаепләнеп зур сроклар алган кырыкка якын кеше илебезнең иң ерак почмакларындагы иң хәтәр хезмәт белән төзәтү лагерьларына озатыла. Доцко иректә яши, квартира ала, өйләнә. Кирәк чакта аны «игелекле дуслары» яңа провокацияләрдә файдаланалар. Русларда бау ишелеп никадәр генә озынга сузылса да, аның очы булмый калмый дигән тәкъбир бар. Ул Доцко белән булган очракка бик тә туры килә. Ахырда банда фаш ителә. Аның башлыгы Казан районнарының берсендә янгын сүндерүчеләр командасы начальнигы вазифаларын үтәүче Кармаков фамилияле милиция өлкән лейтенанты икәне ачыла. Кармаков, кулга алынгач, тикшерүчеләренә, йә сез мине азат итәсез, йә мин сезнең гаепсез кешеләрне безнең банда эшләгән җинаятьләр өчен нахакка хөкемгә тарттыруыгызны фаш итәм, икенең берсен сайлагыз, ди.

Муеннарынача пычракка баткан Казан тикшерүчеләре һәм Казандагы «гадел» хөкем органнары вәкилләре банда башлыгының таләбен бәлки кабул да итәрләр иде, тик инде Казандагы вәхшиләрчә үтерүләрдә топ гаепле кешенең тотылуы Мәскәүгә хәбәр ителгән була. Хакыйкать җиңә. Кармаков атарга хөкем ителә. Бернинди гаепсез нахакка утыртылган кешеләр акланалар. Аларның кайберләре гаделлекнең тантана итүен күрергә өлгермиләр, лагерьларда үлеп калалар. Доцко, аның булышлыгы белән хөкемгә тартылучылар акланган, кулга алына. Монда ул төрмә әһелләрен электәгечә үз кубызына биетергә чамалап карый, ләкин инде, базары үтеп, бәясе төшкәнгә күрә, берничә дә ирешә алмый. Вак пыяла ватыклары йоткач үлми калса, бәлки аңа яңадан игътибар итәрләр?.. Булмастай хәлләр юк дөньяда, алла йоклаганда шайтан ни теләсә шуны эшли, ди халык. Җил ары иссә ары, бире иссә бире бөгелә безнең төрмәләрдәге түрәләр. Алардан теләсә нинди кабахәтлекләр көтәргә мөмкин...

Иртәгесен эчке төрмә башлыгы кече лейтенант Пронин миңа хөкем карарын, биш бит кәгазь, ручка һәм кара кертте. Ул

— Менә, теләсәгез хөкем карарыгызны йомшартуны сорап кассация шикаяте язарсыз, уйлагыз,— диде.

— Уйлыйсы юк аңа, язар,— дип җавап кайтарды начальникка партия өлкә комитетының элекке хезмәткәре Тарасов.

Төрмә начальнигы камерадан чыккач, ул хөкем карарымны укыды да:

— Безнең тикшерү һәм юстиция органнарында һаман да үзгәрешләр юк, торгынлык икән әле,— дип нәтиҗә ясады.

Илленең өске ягындагы ул кеше кичә минем белән шактый озак сөйләшеп утырды.

— Сезнең бөтен тормышыгыз әле алда, минем генә ул туем узган, туным тузган. Унөч ел гомерем җилгә очты, алда тагын күпмесе очары билгесез. Гаебем исә тамчы да юк иде. Халык дошманнары белән бергә эшләп, аларның чын йөзләрен күрмәдем, аларны фаш итмәдем, янәсе. Мордовиядәге Потьма сазлыкларында ун ел черкиләр туйдыргач, ирекка чыгарылып, Себергә сөрелдем. Инде менә яңа срок бирүләрен көтеп ятам. Бер уңмаган биш уңмый, биш уңмаган һич уңмый, энекәш. Лагерьлар һәм колонияләрдә алга карый белгән башлы, зирәк, үз фикерләре бар кешеләр утыра. Сталин үзеннән акыллы кешеләрне өнәми, алардан мөмкин кадәр тизрәк арыну ягын карый.

Әңгәмәдәшемнең Сталинга сүз тидерүен өнәмәдем. Ун ел төрмә һәм лагерьларда интегеп, өч елга якын сөрген шулпасы чөмереп каты бәгырьлегә әверелгән элекке обком кешесе, дип уйладым. Ләкин тормышта нәрсә белә идем дә, нинди тәҗрибәм бар иде соң әле минем... Шулчак, бәлки бу кеше утыз җиденче елда әти белән дә очрашкан булгандыр, дигән кызыксыну уянды. Аңардан тартынып кына республикада утыз җиденче елгы вакыйгалар, аларның ничек һәм нәрсәдән башланулары турында кыскача гына булса да сөйләвен үтендем. Артемий Михайлович ялындырмады, үтенечемә колак салды.

— 1937 елда Татарстан партия оешмасын тар-мар итүгә Маленков зур өлеш кертте,— дип башлады ул сүзен. Шул елның августында ВКП(б) Үзәк Комитетының Маленков җитәкчелегендәге махсус группасы Казанга килеп төште. Аңа кадәр Татарстан өлкә комитетының ул вакыттагы беренче секретаре Альфред Карлович Лепа Мәскәүгә чакырып алынган иде.

Маленков Казанга килгәч, өлкә комитетының чираттан тыш пленумы җыйналды. Пленумның беренче утырышында Георгий Максимилианович иптәш Лепаны халык дошманнарын яклаганы һәм үз канаты астына алганы өчен ВКП(б) Үзәк Комитеты эшеннән алганын, аның урынына Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре вазифаларын үтәргә республика эчке эшләр халык комиссары Александр Михайлович Алемасовны тәкъдим иткәнен белдерде. Алемасов, аңа кадәр Татарстанда айдан артык кына эшләгәнгә, халыкка әле бөтенләй таныш түгел иде. Яңа беренче секретарь үзенең пленумда ясаган тәүге докладында ук республикада әле фаш ителмәгән халык дошманнары, капиталистик илләр разведкалары агентлары мыжгуын сөйләде, Казан тимер юлының япон шпионнары кулында икәнен әйтте. Байтак кеше пленум составыннан һәм партиядән чыгарылды. Аларның күбесе инде кулга алынганнар, төрмәдә утыралар иде. Фикер алышуларда катнашкан кешеләрнең чыгышларын Маленков һәм Алемасов мәсхәрәле репликалар белән бүлделәр. Карт большевик Вольфовичның чыгышын Маленков туктаусыз бүлдерде. Татарстан үзәк башкарма комитеты председателе Гомәр Байчуринның һәм башкаларның чыгышлары да өзлексез бүленделәр. Вольфович трибунадан төшкәндә, үзенең язмышы инде хәл ителгәнен төшенеп: «Минем белән ни генә булмасын, мин большевик булып калырмын!» — дип белдерде.

Маленков Казаннан киткәннән соң Алемасов республикада каты террор режимы оештырды, меңләгән коммунистлар һәм партиясезләр кулга алынып юк ителде.

— Ул башбаштаклыклар турында иптәш Сталинга хәбәр итүче, язучы булмадымыни?— дидем мин, аптырап.

— Эһ, нинди беркатлы әле сез, энекәш. Аңа язудан, хәбәр итүдән ни файда?!. Бу эшләр барсы да Сталинның үзе тарафыннан оештырылды бит. Андый законсызлыклар бер Татарстанда гына булды дисезмени сез? Алар илебезнең теләсә кайсы почмагында эшләнде. Ахырда, дөнья каршында аклаңыр, үз өстеннән гаепне төшерер өчен Сталин башта Ягоданы, аннары Ежовны аттырды. Янәсе алар революциягә кадәрге стажлы гадел коммунистларны, Ленинның турылыклы көрәштәшләрен үзбелдекләре белән юк иткәннәр. Шундый ук башбаштаклыклар хәзер дә дәвам итә. Менә сезнең үзегезнең партия һәм хөкүмәтебез алдында нинди гаебегез бар? Кулымны кисәргә бирәм, берниндн гаебегез дә юк. Сездән әнә милләтче ясаганнар. Электәге үк стиль, электәге үк ысул. Менә минем әле һаман да исән яшәвем, дөмекмәвем Берия этләренә ошамады, тырнак астыннан кер эзләргә монда китерделәр. Кем әйтмешли, в дальнейшем или шах умрет, или ишак сдохнет, одно из двух... Шунда гына безгә бәлки якты көн туар...

Артемий Михайлович хөкем карарымны укып чыккач, өстәл янына утырып, кәгазьләрне, ручканы, караны миңа этәрде.

— Языгыз, мин әйтеп торырмын,— диде ул, карышырга урын калдырмаслык итеп.— Озын язмабыз, курыкмагыз, озын язылганны укырга иренәләр бездә. Ятып калганчы атып калырга кирәк. Минем бер акыллы дустым, бәхетле булыр өчен бәхетне башта югалту зарур, аннары яңадан аның яртысын гына табу да кешенең башын күккә тидерергә җитә, дия иде. Языгыз, башына СССР Верховный судына 58-10 статьясының 2 нче матдәсе буенча 10 елга иректән мәхрүм ителгән Фәләнов Фәлән Фәләновичтан кассация шикаяте дип куегыз. Яздыгызмы? Ярар, төп текстка күчәбез. Мин җиде айдан артык Татарстан дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгының эчке төрмәсендә тикшерелүдә булдым. Мине советка каршы милли рухта контрреволюцион агитация алып баруда гаепләделәр. Тикшерү вакытында бер протоколга да кул куймадым. Чөнки ул протоколларда үземә куелган сорауларга биргән җавапларым дөрес теркәлмәделәр. Тикшерү вакытында да, судта да үземне гаепле санамадым. Шуңа да карамастан, Татарстан Верховный суды минем эшемне җентекләп тикшермәде, тикшерүче язган гаепләү сөземтәсен хөкем карарында сүзгә-сүз кабатлап, срок бирү белән чикләнде. Суд минем язмышымны 15—20 минут эчендә ашыгыч хәл итеп, хөкем карары чыгарды. Мин СССР Верховный судыннан, әгәр безнең илебездә хакыйкать инде сүздә генә булмаса, эшемә ленинча, чын большевикларча якын килүегезне сорыйм. Булдымы? Шикаятегезгә бүтән бер сүз дә өстәмибез. Имзагызны салыгыз һәм бүгенге числоны куегыз. Әмма, инанып әйтәм, Мәскәүдәге ялкау чиновниклар бу кыска гына жалобаны да укып тормаячаклар, хөкем карарыгызны үзгәртергә нигез юк, ул көчендә кала, дип язып җибәрәчәкләр.

Мин:

— СССР Верховный судының ничек җавап бирәсен белә торып, нигә анда бу шикаятьне җибәрәбез соң, Артемий Михайлович?— дидем.

— Бездә хакыйкатьнең тапталуына, кеше язмышына ленинча якын килүнең юклыгына ышанып өчен, энекәш.

Мин, шикаятемнең һәр сүзен вәзенләп үлчәп укып чыккач, бусага төбенә барып ишек шакыдым.

— Ни кирәк, нәрсә бар?— диде коридордагы надзиратель, ишектәге бүре күзеннән карап.

— Төрмә начальнигын чакырыгыз.

— Нигә кирәк булды ул сезгә?

— Шикаять яздым, шуны тапшырырга.

— Бирегез миңа, үзем тапшырырмын.— Надзиратель кормушканы ачып миңа текәлде.

— Юк, сезгә бирмим, аны кече лейтенантның үз кулына тапшырам.

— Мәйлегез.— Кормушка ябылды.

— Шикаятегезне аңа бирми дөрес эшләдегез,— дип яныма килеп басты кичә миңа бу камерага кергәч беренче сүз кушкан инженер Алексей Павлович Петеримов.— Берсенә дә ышаныч юк аларның монда. Алыр да ерткалап

ташлар. Тыңлап тордым, кискен яздыгыз, ул кадәр үк усал язарга кирәкмәс иде, Сабирыч. Моның өчен сезнең хәтта срогыгызны арттырулары да мөмкин. 58 нче статья резина кебек бит ул — сузыла.

Кара, ул турыда уйламадым бит мин, ун ел егерме биш ел түгел, бәлки, чыннан да, җибәрмәскә кирәктер аны?.. Юк, ни булса булыр — җибәрәм!..

— Сузылмас, Алексей Павлович, минем җинаять эшләгәнем юк ич.

— Минем бармы? Кичә сөйләдем үзегезгә, әчкән баштан телемне тик тотмаганым, күңелем төшкән хатынны үземә каратыр өчен, мин ЦРУ резиденты, дип шапырынганым өчен каптым монда. Чын резидент булу-булмавыма карап тормадылар хәрби трибуналда, 10 ел чәпеделәр менә. Нинди шпион мин? Көлке бит...

— Көлке түгел, улым, еларлык бу. Син, яшь кеше, мактанып телең тик тота белмәгәнсең, бу гафу ителерлек. Мин дә менә, 76 яшьлек тиле, телемә хуҗа була белмәдем, бу инде, турысын әйтәм, һич гафу итәрлек түгел. Күршем белән Америкада соңгы сайлауларда кемне — Трумэннымы, Эйзенхауэрнымы президент итеп сайларлар, дип бәхәсләштек. Мин Эйзенхауэрны дидем, күршем Трумэнны диде. Пенсионер картларның тел кашудан бүтән эшләре юк бит. Бәхәстә җиңүчегә җиңелүче бер ярты аракы куярга тиеш иде. Президент итеп Эйзенхауэр сайланды — мин җиңдем. Күршемнең яртысын үзе белән икәүләп үк салдык. Салган баштан, Японияга ике атом бомбасы ташлаткан милитарист Трумэнга гашыйк син, шифаханәгә психик бөтенлегеңне тикшертергә бар, башыңдагы шөрепләрең барсы да урыннарында микән, карасыннар дип көлдем тегеңәрдән. Әгәр башыңда шөрепләрең тулмас чыкса, миңа тагын бер ярты куярсың, дип тә җидәрдем. Серкәсе су күтәрмәде күршемнең. Бер ярты аракысын отуым өстенә, үзен мыскыллап көлгәнем өчен үч алды. Мине, ул — Трумэн яклы, ул сугыш тели, Америка милитаристларын авыз суларын корытып мактый, кайчан безгә дә атом бомбаларын ташларлар, тизрәк ташласыннар иде инде дип төннәрен йокламый, дип монда язып биргән булып чыкты. Үзе яклаган Трумэнны миңа якты да куйды карт ялганчы. Ниндилеген белсәм, аңа бер генә ярты түгел, биш ярты куйган булыр идем, кайда югалтасыңны, кайда табасыңны алдан белә алмыйсың бит... Мин, 76 яшьлек ахмак, телемне тыя белмәгәнем өчен 10 ел алдым. Яшимме инде мин ул 10 елны? Яшәмим. Минем әти дә, әни дә 80 гә җитми үлделәр...

Кеше язмышлары... Җирдә никадәр кеше яшәсә, шул кадәр үк язмыш. Кешеләр төрле-төрле булган кебек, язмышлары да төрле-төрле. Берсе икенчесен кабатлаган охшаш язмышлар юк.

## 2

Сәгать унберләр тирәсендә ишектәге кормушка тәрәзәсе ачылды. Аннан миңа бу төрмәгә утыртылуымның икенче көнендә үк кул күтәргән бетчә бит старшинаның кызыл чырае күренде.

— Кадыйров, кил, передача ал.

Мин ишеккә бардым. Старшина эреле-ваклы кәгазь төргәкләрне берәмберәм кормушканың ачык капкачына тезә башлады.

— Старшина, ашыкмагыз. Үзегезгә мәгълүм, мин передачалардан баш тарттым, алмыйм, кире алып китегез.

— Сез аңардан тикшерү вакытында баш тарттыгыз, тикшерелүегез бетте, инде сезне хөкем иттеләр. Алыгыз, мин аны кире илтмим. Ризык эчегезне тишмәс...

— Алмыйм дигәч алмыйм, старшина, юкка баш катырмагыз.

— Сезгә аны кем китергәне белән дә кызыксынмыйсызмы?

— Кызыксынмыйм.

— Шундый чибәр кыз китерде аны. Үзеңә бер дигән туташны караткансың, — дип минем җил ягыма кабык сөяргә керешәте бетчә бит. — Ул министрга синең белән күрештерүен даулап гариза да язды. Сиңа да менә хаты бар. Китергән передачасын тапшыртмый торып безгә тынгылык бирмәячәк ул.

— Старшина, бүтән кабатламыйм, передачасын да, хатын да алмыйм. Башка бу хәлгә калырга теләмәсәгез, кисеп әйтегез аңа, йөрмәсен бу тирәдә. Җенем сөйми, күрәлмим мин аны, диде диегез. Министр рөхсәт итсә дә, күрешергә чыкмаячакмын.

Бетчә бит, мине көндерә алмагач, камерадагы иптәшләремә мөрәҗәгать итте:

— Ризалаштырыгыз әле шул киребеткәнне ә, керегез хәлемә. Аның кызы да үзе күк үк үҗәт, китергән передачасын кире чыгарсам, миңа ана юлбарыс күк ташланачак. Туганкайлар, Кадыйров белән сөйләшегез, ә..

Камерадагы иптәшләрем барысы да миңа төбәлделәр.

— Бәлки алырсың, Сабирыч?—диде инженер Алексей Павлович, күзлекләрен ялтыратып.

— Юк,—дидем мин аңа.—Алмыйм булгач алмыйм. Миңа ул кыз белән арамны капылт өзәргә кирәк. Корабларым инде янды минем, диңгезне яңадан кичеп элекке ярга чыгар нәрсәм юк. Шуңа күрә ул кыз белән арабызны капылт кисүем бу.

— Үзең ишеттең, начальник, сиңа ярдәм итү безнең дә кулдан килми,—диделәр старшинага.

Бетчә бит, минем адреска тугыз катлы итеп сүгенеп, кәгазь төргәкләрен ниндидер савытка җәһәт кенә сибереп төшерде дә, кормушканы ачу белән шапылдатып япты.

Передача алудан баш тарткач, күп тә үтмәде, камерабызга төрмә начальнигы кече лейтенант Пронин кереп мине үзенә ияртеп алып чыкты. Мин начальникның үземне кая алып баруы белән кызыксынмадым, ул әйтмәде. Пронинның, гомумән, авызы йозакта кебек аның, бетчә бит старшина шикелле кирәккә-кирәкмәскә лыгырдарга яратмый. Төрмә коридорыннан каравыл бүлмәсенә, аннан министрлык бинасы коридорына чыктык. Шунда гына кече лейтенант:

— Сезнең белән күрешергә хатыныгыз килде. Сезгә минем алда ярты сәгать бергә булырга рөхсәт иттеләр. Күңелсезлек килеп чыкмасын өчен әңгәмәдә ни сөйләвегезне чамалап куегыз. Бездә стеналарның да колагы ишетә,—диде дә ишегенә тыш яктан «Кызыл почмак» дип язылган шактый иркен һәм чиста бүлмәгә кертте.

Мин бусаганы атлауга:

— Үлеп сагындым сине, бәгырькәем!—дип муеныма Оля килеп асылынды һәм бит алмаларымны, күзләремне, иреннәремне шашып үбәргә керешге.

Башымнан ирексездән: «Минә хатыным кем икән»,—дигән татлы һәм бер үк вакытта хафалы уй узды. Мине милләтчелектә, татарлыкта гаепләп хөкем иттеләр, чибәр рус кызы беркатлы Оля менә кайнар кочагына кысып иркәли, җылы, мөкатдәс сүзләр пышылдый. Бу ничек инде алай, ул бит судта булды, нәрсәдә гаепләнүемне үз колаклары белән ишетте. Берни аңлашылмый торган буталчык, җепләре чуалып чәбәләнеп беткән йомгакка бәрабәр түгелдер ич ул тормыш?..

Пронин безне зур өстәлнең ике ягына кара-каршы утырткач, үзе бүлмәнең аргы башына узып газеталар караштыра башлады.

— Йә, хәлең ничек, Ирек?—диде Оля, елмаеп.

— Ботларын кемдер өзгәч, сикерә алмаган чикерткәнеке кебек. Оля. Ә синең?

— Минеке дә шулай.

Арабызда тынлык урнашты. Бераздан Оля:

— Ирек, нигә мине рәнҗетәсең?—диде.—Минем, синнән кала, бер якын кешем дә юк бит.

— Рәнҗетмим,—дидем, авыр сулап.—Ун ел аз гомер түгел, ул минем өчен гүргә керү белән бер. Ун ел үтеп артта калгач та мин кешечә яши алмаячакмын, чөнки маңгаема сугылган «халык дошманы» мөһере—мәңгелек. Син бәхеткә лаек. Гомер ике килми, әзлә бәхетеңне башка берәү белән, минем дөньяда барлыгымны оныт.

Оляның йөзе караңгыланды.

— Мин кем синa, кешеме, уенчыкмы?—диде ул, ярсып.—Шәп. Син бөтенесен инде үзеңчә хәл иткәнсең, барсын да теләгәнеңчә үз шүрлекләреңә пөхтәләп тезгәнсең, миңа уйларга да калдырмагансың. Нишләгәнемне белмәслек сантыймы мин? Син бәлагә тарыдың, мин синнән йөз борырга тиешмени?

— Оля, безне бер нәрсә дә бәйләми бит әле,—дип каршы төштем мин кече лейтенант утырган якка карап, акрын гына.

— Ялгышасың, бәгырькәем, бәйли, синең законлы хатының мин.—Оля редикүленнән ниндидер кәгазь чыгарып миңа сузды.

Никахлашу таныклыгы!.. Анда үз фамилиямне һәм Оля фамилиясен күреп гаҗәпләнүдән өнсез калдым.

— Эшләр менә шулай, бәгырькәем. Мин сине башыңа килгән бәладән йолып чыгармый тынычланмаячакмын. Шундый максат куйдым үземә. Иреккә чыккач, теләсәң нишләрсең аннары. Ә хәзергә ничек кирәк табам, ай-ваеңа карамый шулай эш итәчәкмен. Кассация шикаяте яздыңмы?

— Яздым.

— Судта соңгы сүзеңне әйткәнеңчә итепме?

— Андагыдан да катгыйрак чыкты шикелле.

— Бик әйбәт. Минем передачаларымнан баш тартмаска туры килер сиңа хәзер. Без бит бер җан, бер тән.—Оля мәгънәле итеп күзен кысты.—Ир—баш, хатын—муен, буйсынырга туры килер сиңа муеныңа моннан ары.

Яныбызга төрмә начальнигы килде.

— Вакытыгыз чыкты,—диде ул, сәгатенә күрсәтеп.—Саубуллашыгыз.

— Тагын биш кенә минут утыртыгыз, зинһар,—дип үтенде аңардан Оля.

— Юк, ярамый,—диде кече лейтенант, кырыс тавыш белән.

— Рәхмәт. Ярамый икән, ярамый. Кешелекле хәрбигә каршы килү җинаять ул.—Оля өстәлнең икенче ягыннан чыгып минем янга килеп басты.—Иәле, иркәем, бер суырып үбеп тынычландыр йөгәремне. Сез, иптәш начальник, читкә карагыз, уңайсызлануыгыз бар...

Олядан аерылгач, уйга калдым. Мин кем хәзер? Үз ирке белән берни эшли алмый торган пешка, бүтән нәрсә түгел. Монда утырган арада әнә хатынлы булырга да өлгергәнмен. Оля ни өчен минем рөхсәтемнән башка эшләгән аны? Гаҗәп, үзен ничек кыю тота, менә холык дисәң дә холык аңарда!.. Кыз булып түгел, малай булып туасы калган аңа. Сине бу хәлеңнән йолмый торып тынычланмаячакмын, ди. Белмим, теләгеңә ирешә алырсың микән, минем йөз аклыгым, намусым өчен көрәш җиңел булмас сиңа, кызый. Алдыңда берсеннән-берсе биек законсызлык киртәләре, бюрократлык чытырманлыклары, битарафлык сазлыклары, кешеләрнең хәтта үз куләгәләреннән дә өркеп кыл да кыймылдатырга теләмәүләре көтә сине...

## 3

Минем кассация шикаятемә, хөкем карары үз көчендә кала, аны үзгәртергә нигез юк, дигән җавап килде.

— Мәскәүдә сезнең язган жалобагызны укып та тормаячаклар, дип әйттем мин, хәтерегездәдер, шулай булды да. Ләкин борынгызны салындырмагыз, дөньяның асты-өскә килмәде. Хаклык барыбер җиңәчәк. Нинди генә шартларда да үз йөзегезне югалтмаска, кеше булып калырга тырышыгыз. Алда сезне коточкыч авырлыклар көтә, нинди генә шартларда да җебеп төшмәгез, көрәшегез,—диде Артем Михайлович, кәефем кырылганны күреп.

Җиңел аңа шулай фикер йөртүе, уноч еллап тоткын тормышында ачыны-төчене татып тиресе калынайган аның. Фронтта булса, сугышта уңында, сулында, алдында, артында, дан-шөһрәт яуларга омтылган бушбашларның ахмак боерыкларын үтәгәндә әзмәвердәй ирләрнең һәлак булуларын күрсә, миңе алда көткән ниндидер коточкыч авырлыклар турында искәртмәс иде

ул, дип уйладым үртәләп. Соңыннан исә үземнең бу ашыгыч хөкемем, кабаланулы хаксызлыгым өчен күп тапкырлар үкенергә туры килде миңа.

Балачактан ук тормышны мин тик тоташ көрәшләрдән генә тора итеп тоеп үстем. Коллективлашуны тәгәлләү өчен көрәш, югары уңыш өчен көрәш, укый-яза белмәүчелеккә каршы көрәш, яхшы һәм бик яхшы билгеләренә генә уку өчен көрәш, чит элементлар, корткычлар белән көрәш, дингә каршы көрәш, җәмәгать байлыгын әрәм-шәрәм итүләргә каршы көрәш, фашист илбасарларына каршы көрәш, сугыштан соңгы җимерекләрне торгызу өчен көрәш, социализм өчен көрәш һәм тагын әллә никадәр көрәшләр! Монда Артемий Михайлович мине алда үземне көткән кыенлыклар алдында җебеп төшмәскә, аларга каршы көрәшергә чакыра. Нигә кеше гомере буе гел көрәшергә, көрәшсез яшәргә тиеш түгел икән?.. Кеше туктаусыз көрәшер өчен түгел, яшәү өчен туа бит. Алай булгач, яшәү өчен көрәшне ничек аңларга? Юк, башым җитми моңа, карурмандагы үтә алмаслык шырлык-чытырманлык кебек бу...



## Унөченче бүлек

### I

— Кадыйров, әйберләреңне алып чыгарга җыен,— диде кассация шикаятенә җавап килгәннең икенче көнендә эчке төрмә начальнигы Пронин, камерабызга кереп.

Мин, өстемне тиз-тиз киенеп, урын-җир әйберләремне култык астыма кыстырдым да:

— Мин әзер, кече лейтенант,— дидем. Аннары камерадашларыма борылдым:— Хушыгыз, иптәшләр. Барыгызга да чын күңелдән сабырлык, чыдамлык, сәламәтлек һәм, иң мөһиме, тизрәк ирек яулау телим!..

— Хуш, туганкай. Безгә теләгән теләкләрең үзеңә дә бише белән кайтсын. Хәерле юл сиңа!

Төрмә ишегалдында мине тоткыннарның түләүсез таксие — калай белән тышланган «кара козгын» машинасы көтә булып чыкты. Мине «козгын» кузовы эчендәге кысан һәм караңгы «шкаф»ларның берсенә кертеп бикләгәч, машина озак тормады, кузгалып китте. Шәһәрдәге колонияләрнең берсенә юнәлдек бугай, кайсына икән? Анда ничек каршылар, нәрсә эшләтерләр, бер эш тә майтара белмим бит мин... Ялгыш әйтәм, җир казый беләм, аны сугышта өйрәндем. Курск тирәләреннән башлап Померания чигендәге Одер елгасына кадәр арада танкыбызны фашист авиациясеннән яшерү өчен иптәшләрем белән йөзләгән траншеялар, сугышта һәлак булган иптәшләребезне җирләргә бихисап туганнар каберләре казыштым... Машина кузовы як-якка чайкалудан туктагач, уйларым бүленде. Шыгырдап капка ачылган тавыш ишетелде. Кемдер:

— Үтегез!— дип кычкырды.

Кая китерделәр мине?.. Эчке төрмә ишегалдыннан кузгалып китүебезгә күп дисәң, биш минут үтте, инде каядыр килеп тә җиттек. Бәлки, Красин урамындагы теге зур квадрат рәвешендәге котсыз таш капчыкка күчергәннәрдер? Якын-тирәдә тоткыннарны асрый торган урын шул гына бугай бит монда?..

Кузов ишеген ачып, мине «шкаф»ымнан чыгаргач, җиргә төшерделәр. Әйләнә-тирәмә күз ташлагач, кремль буендагы пересылкага китерелүемне төшендем. Димәк, каядыр озатачаклар... Мин як-ягыма каранган арада «козгын» кузовыннан тагын кемдер төште. Риан?! Аптырап киттем. Безне срогыбызны үтәргә бергә җибәрергә булганнар, күрәсең. Миңа һәм берничә башка кешегә «булышканы» өчен күпме бирделәр икән аңа? Минә ахмак димә инде аны, тимер читлеккә тыелгысыз фантазиясенең корбаны булып атылып килеп керүе генә җитмәде, үзенә иптәшкә мине дә ияртте. Ул ук чаккан

Габдрахман Ландыш дигән кешене нишләттеләр икән? Ул кеше турында миннән дә сорап йөдәттеләр бит. Минем исә аны белү түгел, хәтта күргәнем дә юк иде.

Безне пересылка төрмәсе биналарының берсе астында өсте көймәләп эшләнгән киң үткел аша эчке ишегалдына алып кергәч, каршыдагы бинаның подвалына төшерделәр. Анда ярым караңгы коридор буйлап бераз баргач, кечкенә генә бүлмәдә чишенергә һәм юынырга кирәргә куштылар. Чишенгәндә мин Рианны күзәттем. Ул да ярыйсы ук ябыккан, башы минеке кебек үк такыр, төсе сап-сары. Кыяфәте мескен. Аңарда элекке ясалмалыгының эзе дә калмаган. Хәзер ул башын бер яккарак салып, ияген алга чыгармый. Йөрүе дә үзгәргән, башта үкчәсенә түгел, берьюлы тулы табанына баса. Төрмә файдага киткән аңа, укасын койган...

Пересылканың мунчасы шәп икән, суының кайнары да, салкыны да җаның күпме тели,— шулкадәр. Монда республика дәүләт иминлеге министрлыгының эчке төрмәсендәге шикелле, җәһәтрәк юыныгыз, дип ашыктыручы юк, бөтен мунчада Риан белән икебез генә. Әмма бер-беребезгә ләм-мим сүз дәшмибез. Гүя, без бер-беребезнең телләребезне аңламаучы ике милләт кешесе. Күр, ләгәннәрне монда алдагы йөз елга чаклы чыдарлыкларны, тузмаслыкларны алганнар. Һәрберсенә бер чиләк су сыешлы, үзләре, бармак калынлык, авыр. Дөмектерергәме әллә бу хаинны башына шушы ләгән белән орып?.. Янэбызда комачаулар кеше юк бит. Аны үтерсәм, дөнья бер имгәктән, бер сатлык җаннан арыныр, мин чын җинаятем өчен яңа срок алырмын һәм нахакка түгел, ни өчен утыртылуымны белеп утырырмын... Тәвәккәллим булмаса...

Мин, кулыма авыр ләгәнне алып, Рианга таба юнәлдем. Ул күзлексез берни күрми, гамьсез генә юына, гөнаһ эшләгән кешегә һич охшамый. Мескен дә мескен. Риан да мескен. Ул гаҗиз сабый белән бер. Юк, кул күтәрә алмыйм аңа. Миңа мәңге гафу итмәслек этлек эшләгән, язмышымны җәһәннәм юлына борган Риан түгел бу. Ул Риан башка иде, бу башка... Әйдә, яши бирсен, үзенең кешелек йөзен югалтуына, кан эчүче вурдалакка әверелүенә, бәлки, киләчәктә үкенер ул. Тик үкенер микән? Андыйлар үткәннәренә аек күз белән карап, дөрес бәя бирә белмиләр шикелле. Яшәсен әйдә, пычратмыйм кулымны нәҗескә, намусым пакь калсын...

Мин артык юынмадым, кулымдагы ләгәнемә су алып тиз генә коендым да тәнемне сөлге белән корыту өчен кечкенә бүлмәгә чыктым.

Мунчадан соң Рианны миннән аердылар. Мин аны пересылкада бүтән күрмәдем.

## 2

— Син кем? Кил әле бире,— дип каршылады мине пересылкада, зур камерага кергәч, ике катлы сәке-сәндерәнең өске катында аякларын аска салындырып утырган, авызы яра җөеннән кыйшайган утыз яшьләр тирәсендәге чандыр бер кеше.

— Студент мин,— дидем, теләр-теләмәс кенә.

— Китап корты икәнсең. Статьяң нинди?

— 58-10.

— Такылдык, димәк. Романнар сөйли беләсеңме? «Мең дә бер кичә»не, «Мюнхаузен маҗаралары»н, «Граф Монто-Кристо»ны?»

— Укыганым бар, ләкин сөйләргә туры килмәде.

— Әйберләреңне бир миңа. Булды. Мен бирегә, урнаш безнең янга. Романнарны әйбәт сөйләсәң, берәүдән дә кыерсыттырмабыз, сөйли белмәсәң, моннан төшереп параша янәшәсенә яткырырбыз.

Камера зур. Сәке-сәндерәләрдә кешеләр шыгрым, бер генә буш урын да юк кебек.

Мин чакырган җиргә күтәрелдем.

— Исемең ничек?— диде мине өскә менәргә чакырган кылый авыз.

— Ирек.

— Мин — Семка. Алар, — ул янындагы иптәшләренә күрсәтте, — минем яраннарым: Дима, Арик, Филя, Муха. Шәп егетләр. Әгәр сөйләвең безгә ошаса, сине үз канат астыбызга алырбыз. Сөйли белмәсәң, үзеңә үпкәләрсең. Килештекме?

— Килештек, Семен Батькович.

— Антоныч.

— Килештек, Семен Антоныч.

Көтмәгәндә исеме һәм әтисенең исеме белән атавым кылый авызның күңеленә хуш килде, шундук ул яраннарына борылып:

— Май чүлмәге тышыннан билгеле, диләр. Культуралы кешене микроскоп пыяласына салып карыйсы юк, ул зурайткыч приборсыз да ярылып ята, гади күзгә дә бәрелеп тора. Сез мине Семка да Семка дисез, ә студент кем икәнемне күз төшерү белән чамалады. Моннан соң мин сезгә дә Семка түгел, Семен Антоныч булырмын. Төшендегезме? — диде.

— Төшендек, Семен Антоныч.

Кылый авыз тәмәкедән саргайган тешләрен ыржайтып көлде.

— Молодцы! Син, студент, җайлап утыр, әйберләреңне менә монда җәй. Кая, Муха, студентка тартырга бир әле.

— Рәхмәт, кирәкми, мин тартмыйм, өйрәнмәдем.

— Бәлки, син безгә хәзер үк нәрсә дә булса сөйләп ташларсың? — диде кылый авыз, хәйләкәр елмаеп.

— Шушы төрмә турында сөйлимме?

— Аның нәрсәсен сөйләрсең икән? Төрмә күк төрмә инде ул, кызыгы булмас, роман сөйлә син безгә.

— Унсигезенче гасырда, әби патша заманында, бу төрмәдә крестьяннар фетнәсе башлыгы Емельян Иванович Пугачев утырганын һәм аның моннан ничек качканын беләсезме соң?

— Белмибез. Пугачев нindirәк кеше булган, ни өчен монда утыртылган соң ул, сөйлә.

Мин Пугачев турында кыска гына итеп сөйләп бирдем.

— Бәлки без Пугачев утырган ук камерада утырабыздыр? Сез аның монда кайсы камерада утырганын белмисезме? — диде яраннарның Муха дигәне.

— Белмим, егетләр. Аның биредә кайсы камерада утыруы тарихта сакланмаган.

— Пугачевны әби патша ялчыларына яраннары тотып биргәне уйдырма түгелме? — дип кызыксынды кылый авыз.

— Түгел, хак, Семен Антоныч. Аларның тарихта хәтта фамилияләре дә билгеле. Әмма әби патша ул хыянәтчеләргә рәхмәт әйтмәгән, Пугачев белән бергә аларны да җәзалаткан.

— Хатын-кыз булса да, бик дөрес эшләгән. Ярдәмчеләреңә ышаныч — суга таяну белән бер. Син көчле чакта алар табаныңны ялыйлар, көчең токанәсә саталар, — диде кылый авыз.

— Бу төрмәдә Владимир Ульяновның да утырганын беләсездер, могаен?

Кылый авыз һәм яраннар бер-берләренә карашып алдылар. Аларның мин әйткәнне белмәүләрен икърар итәргә уңайсызлануларын аңладым.

— Владимир Ульянов кем соң ул? Кайчан һәм ни өчен утырган монда? — дип кызыксынды яраннарның берсе.

— Ульянов — Владимир Ильич Ленинның чын фамилиясе. Ул, 1887 елның җәендә Сембер гимназиясен алтын медаль белән тәмамлагач, Казан университетына укырга кергән. Шул елның декабре башында Рәсәй югары уку йортларындагы кадими тәртипләргә каршы җыен оештыруда актив катнашкан өчен бер төркем студентлар белән университеттан куылып кулга алына. Аны сөргенгә җибәргәнче шушы төрмәдә ябып тотканнар.

— Ә минем дә монда инде өченче тапкыр утыруымны беләсеңме син, студент? — диде кылый авыз, миңа карап.

— Белмим. Сез биредә инде өченче кат ни өчен утырасыз соң, бәлки сөйләрсез?

Минем соравымнан кылый авыз үзе дә, яраннары да эчләре катып көлделәр.

— Кызык, син Пугачев белән Ленинның бу төрмәдә берәр тапкыр утырганнарын да беләсең, ә Семен Антоныч монда инде өченче кат кандалалар симертә, аны белмисең. Сөйләгәннәреңнең барысы да ялган булса кирәк синең, студент. Сиңа парашаны кочаклап йокларга туры килмәгәе,— диде яраннарның берсе.

— Сез миңа нәрсәдер сөйләргә куштыгыз, мин сөйләдем.

— Без синең роман сөйләвеңне үтендек.

— Мин сезгә тарихи шәхесләр, тарихи сәхифәләр турында сөйләдем. Аларны сез беркайчан да онытмаячаксыз. Романнар аерым кешеләр бармакларыннан суырып язган уйдырмалар җыелмасы гына бит.

— Ярар, сөйләдең, булды, рәхмәт. Син, студент, минем монда ни өчен өченче кат утыруымны сөйләвемне сорадың, тыңла. Бәлки кайчан да булса ул сиңа ярап куяр. Минем маҗараларымны илдәге бөтен караклар белә.

Кылый авыз сәндерә-сәкегә аякларын бөкләп җайлап утырды. Муха шундук аңа папирос каптырып шырпы сызды. Моңа кадәр сәндерә-сәкедә кайсы ничек теләсә, шулай урнашкан яраннар урыннарыннан калкып «шеф»ларына текәлделәр. Кылый авыз, папиросын ике тапкыр суыргач, янәшәсендә утырган яранына бирде.

— Фамилиям минем Афанасьев, караклар арасындагы кушаматым Семка Вьюн, ягъни Елдам Семка, дип башлады ул сүзен.— Сугышта катнашсам, валлаhи, герой исеме алган булыр идем, катнашмадым, утыруым комачаулады. Әмма зарар юк, бар кешегә дә алтын йолдыз тагып йөрергә димәгән. Фиргавеннәрне кырыкмаса кырык тапкыр авызларын ачтырып калдырдым, колонияләрдән биш тапкыр качтым. Төрмәдән качуга караганда инә күзеннән дөя үткәрү җиңелрәк икәнен әнә алар белә.— Кылый авыз яраннарына ымлады.— Сугышта катнашмасам да, тәнемдә җиде пуля ярасы бар, авызымны да ментлар[1] пулясы кыйшайтты. Качканда ничә генә атсалар да, барыбер гүргә озата алмадылар. Соңгысында шушы Казандагы Вахитов колониясеннән шылдым. Чын театр булды ул. Аны күрүчеләр генә аз булды. Колониягә эләккәч, мин, законниклар күк зонада йокы симертеп, йә төшәм санап ятмыйм, алай эч пошудан акылдан шашарга мөмкин. Беренче көннәрдән үк колония хуҗаларына үземне эш сөюче, тайгак юлга очраклы рәвештә баскан, эшләгән җинаятем өчен чиксез үкенүче, тизрәк төзәлеп иреккә чыгарга омтылучы кеше итеп күрсәтергә тырышам. Кыскасы, начальствоны үземчә гипнозлыйм, рецидивистлар белән аралашуымны, аллам сакласын, аларга күрсәтмәскә тырышам. Шул арада үзем түрәләрнең кайсына ничек якын килергә, кайсының җил ягына ничегрәк салам кыстыру җиңелрәк булырын өйрәнәм. Бер сүз белән әйткәндә, тик ятмыйм, тизрәк колониядән сызарга, ирек hавасы суларга чыгарга әзерлек алып барам. Вахитов колониясенә эләккәч тә шулай булды. Анда чуен эретү мичләре-вагранкалар бар. Эретелгән чуеннан, студент, менә синең ише hәм безнең ише тоткыннар җылыткыч батареяләр, колхозлар өчен гади генә авыл хуҗалыгы машиналары, җил көче белән җир астыннан су чыгару корылмалары детальләре коялар. Колониядәге меңләгән кешеләрне тик яткырып булмый, нәрсә беләндер шөгыльләндерергә кирәк бит, алар шихта дворында, обрубкада, заливкада, вагранкага шихта тутыруда, пескоструйда, тагын бик күп бүтән эшләрдә көн дә уникешәр сәгать тир түгәләр. Чуенны балчык яки комнан коеп булмый, аның өчен руда яки металл кирәк. Колониягә тимер юл тармагы кертелгән. Шул тармактан вагранкалар өчен ачык платформа-вагоннарда махсус чуен әзерләмәләр, төрле металл ватыклары китерелеп бушатыла. Бушаган платформа-вагоннарга колониядә зэклар житештергән әзер продукция төялә. Платформа-вагоннар, бушатылгач, кайчакта колония территориясендә төялмәгән килеш атналар буе тора. Төялгән платформа-вагоннарның кай урыннарынадыр качып колониядән чыгу турында уйларлык та түгел, аларны чыгарганда этләр белән җентекләп тикшерәләр. Паровозга да

[1] Мент — караклар телендә — милиционер.

утыра алмыйсың, аны да күз карасыдай саклыйлар, янына якын җибәрмиләр. Мин платформа-вагон ярдәмендә качарга булдым. Шуларның чуен китергәч буш торган берсен сайладым да колония начальнигына барып: гражданин начальник, зонадагы тимер юл буйлары төрле чүп-чар белән тулган, йөргәндә шайтан аягын сындырырлык. Аларны бераз рәткә китерергә, тазартырга рөхсәт итсәгез икән. Чүп-чарны буш торган платформа-вагонга төярбез, паравоз, әзер продукциягә килгәч, аны колониядән чыгарып, тимер юл буен җыештыруга җитәкчелек итүне мин үз өстемә алам, дидем. Начальникларның миләре үкчәләрендә, уйлау сәләтләре чикле, уйлары тәпиләреннән башларына менеп җиткәнче йә искерә, йә бөтенләй онытыла. Минем эшләргә ни өчен атлыгып торуымны зиһене үлчәвенә салып тормады, шатланып риза булды начальнигым. Эшлә, Афанасьев, синең бу эшне җиренә җиткереп башкарып чыгарыңа ышанам, чүп-чар җыярга күпме кеше кирәк, нарядчикка минем исемнән әйт, бирер, диде. Миңа колония начальнигы качарга шулай үзе булышты.

Ирektә калган корешларым (әшнәләрем) белән күптән хәбәрләшкән идем, алар анда әзерләнеп түземсезлек белән көтәләр иде инде мине.

Эшкә кичкырын тотындык. Миңа булышырга утызлап кеше җыйналды. Шулар арасындагы җиде кеше корган планымны белә, алар минем белән бергә качарга җыенучылар иде. Платформа-вагонны башта зонаның иң читенә тәгәрәтеп алып барып төядек тә, аннары эчкәрәк тәгәрәттек. Бераздан тагын да эчкәрәк, тагын да... Платформага чүп-чар ярыйсы ук төялгәч, мин үзем белән качарга ниятләгән иптәшләремә күз кыстым. Вакыт җитте, бу шайтан калтырчасын зона читендәге тимер капканы бәреп чыгарлык итеп шәпләп тәгәрәтә башлагыз, янәсе. Егетләрем ул боерыкны көтеп зарыкканнар иде инде, күз кысуыма, платформаның читләренә барып та ябыштылар. Ярым төялгән авыр платформа, шома рельслар өсләп тәгәрәвен кызулатканнан-кызулата барып, бервакытны тимер капканы бөтен авырлыгы белән күз ачып йомганчы җимереп, колониянең тышына тәгәрәвен белде. Безгә шул гына кирәк иде. Иптәшләрем дә кайсы җәяүләп, кайсы платформа читләренә тотынып зонадан чыктылар. Колония артта калгач, алдан сөйләшкәнчә, барыбыз да бер торкемгә җыелып түгел, һәммәбез аерым-аерым төрле якка ташландык. Бу артыбыздан куа чыгучыларның бурычларын кыенлаштыру, тотылсак барыбызны да берьюлы тоттырмас өчен эшләнде. Мин, ирektәге әшнәләрем белән алдан килешүем буенча, бер читтәге ташландык сарайга юл тоттым. Анда миңа мильтон киемнәре әзерләп куелырга тиеш иде. Капканы саклаучы вертухай, платформа капкага килеп бәрелгәч, вышкасыннан мәтәлеп төшкән иде булса кирәк, шактый вакыт тәшвиш куптармады, аннары гына автоматын тырылдатырга тотынды. Ул арада без кайсыбыз кая яшеренергә өлгергән идек. Мин, мильтон киемнәрен киеп, сарайдан чыктым да ашыкмый гына шәһәргә юнәлдем.

Өч ел тоттырмадым. Теге җиде иптәшемә ирек һавасын тәүлектән артык суларга туры килмәде, каптылар. Мин исә юри гел ментлар арасында йөрдем, бу качкындыр дип шикләнүче булмады. Башта чәч, сакал-мыек үскәнче бик үк оятсызланмадым, аннары, бераз кеше кыяфәтенә кергәч, Казанда гына калмадым, Мәскәүгә дә, күп кенә башка шәһәрләргә дә бардым. Ник берсе документларымны тикшерсен дә, ник берсе кемлегем белән кызыксынсын. Мактанып әйтмим, шәһәрдә йөргәндә дә, поезд, пароход, автобус кебек транспортларда да бер чакта да куян йөрәкләнмәдем, үземне тыныч, иркен тоттым. Чын булмасам да, милиционер әсәре идем бит. Торуым — качкан колониямнән өч кенә квартал җирдә бер карчыкта иде. Улы күк кадерләп асрады ул мине. Үз иптәшләрем үк сатмасалар, әле дә монда кыһсыр чәй чөмереп ятмас, рестораннарда тәти кызлар белән коньяк уртлап утырыр идем. Син, студент, монда Пугачев, Ленин утырган дисең, моннан соң бу төрмә турында сөйләгәндә мине дә телгә алырга онытма, йәме?!

— Онытмаска тырышырмын. Тик турысын әйтегез әле, Семен Антоныч, кешеләргә сезнең үз гомерегездә нинди яхшылык эшләгәнегез булды? Ялгызыгыз гына түгел, тәти кызлар белән бергә рестораннарда типтерерлек акча каян ала идегез?

— Кешеләргә нигә яхшылык эшләргә? Һәркем үзе өчен яши, мин дә шулай. Акчага килсәк, бай фраерлар азмыни, мине алар тәэмин итте. Үзләре теләп, үз ирекләре белән түгел, билгеле.

Кылый авызның сөйләмендәге фиргавен, мент, вертухай, мильтон, фраер кебек сүзләрнең туры мәгънәләрен мин, дөресен әйтим, аңламадым, тик якынча фараз гына иттем, әмма аның сөйләвен бүлүне кирәк санамадым. Мәсьәлә аерым сүзләрдә түгел иде, минем әңгәмәдәшемнең асылына төшенәсем, аның кемлеген беләсем килде.

— Пугачев белән Ленин үзләре турында уйламаганнар, халык бәхетен кайгыртканнар, Семен Антоныч. Үпкәләмәгез миңа, сез алар белән бер рәткә баса алмыйсыз,— дидем турыдан-туры.

Мактанчык сөйләүчем туры сүземә ачуланыр, чәпчер, сөйләүдән туктар дигән идем, ялгыштым. Ул мин уйлаганча ук сай акыллы булып чыкмады.

— Хак сүзгә җавап юк,— дип, саран гына елмаю белән чикләнде.

— Гомерегездә байтак кешеләрне елаткансыздыр сез?..

— Беркемне дә елатмадым, нигә кемнәрнедер елаткандыр дип уйлыйсың әле?

— Акчаларын, мал-мөлкәтләрен сезгә үз теләкләре белән бирергә теләмәгән кешеләрне.

— Ә-ә, аларны... Алар аз түгел, күп булды, күп, студент.

— Эшләгән эшләрегез өчен беркайчан да үкенмәдегезме?

— Син нәрсә, мильтонмы әллә, миннән сорау аласың. Нигә дип үкеним, мин дурак түгел бит.

— Ә менә Хиросимага беренче атом бомбасын ташлап чирек миллион кешенең җаннарын кыйган Америка очучысы Иберли, нишләгәнен алдан белмәсә дә, үкенгән һәм ахырда акылыннан шашкан. Ул дөньяда үзе өчен генә яшим димәгән.

Кылый авызның күзләрендә усал очкыннар кабынды.

— Син мине кеше үтерүче белән янәшә куйма, минем кулларымда кан эзе юк,— диде ул, горурлык белән.— Профессиям — караклык, ничек булдыра алам, шулай яшим.

— Кешеләр хисабына яшәү зур дәрәҗә түгел, Семен Антоныч,— дип каршы килдем аңа.

— Бездә кем генә башкалар хисабына яшәми соң? Тик эшче белән крестьян гына тамакларын тир түгеп туйдыралар, ә башкалар алар хисабына көн итәләр. Мин дә, син дә, алар да шундый әрәм тамаклар исәбенә керәбез. Бетерик бу турыда сүзне, студент, юкса күңелем болгана башлады. Җыен юк-бар турында без түгел, ат уйласын, аның башы зур. Кая, Муха, үз вазифаңны онытма, бир әле папирос, тартыйм. Аннары студент безгә берәр роман сөйләр. Кич староста сайларбыз. Әйдә, башла, студент, инде сине тыңлап багыйк.

Мин кылый авызга һәм аның яраннары Дима, Арик, Филя, Мухага нindирәк әйберне сөйләү отышлырак булырын уйларга өлгергән идем инде. Аларга таныш әйберне сөйләгәндә нәрсәнедер төшереп калдырсаң яки буташсаң, сине төзәтеп үзләренең «укымышлылыкларын» күрсәтәчәкләр, моңа юл куймаска кирәк, дидем үз-үземә. Башта ачыкларга кирәк, мин сөйлисе әйберне тыңлаганнары бармы икән аларның?

— Рокамболь турында ишеткәнегез бармы сезнең?

— Минем ишеткәнем бар,— диде яраннардан Арик исемлесе.— Тик миңа күптән сөйләгәннәр иде инде ул романны, эчтәлеген җуйлап хәтерләмим. Шунысын беләм, шәп роман ул, сөйлә, рәхәтләнеп тыңларбыз.

Мин дә аны инде керделе-чыктылы гына хәтерли идем, шулай да үземнән өсти-өсти булса да сөйләргә ниятләдем.

— Узган гасыр урталарында яшәгән француз язучысы Пансон дю Террайльнең Рокамболь турындагы әсәрләре берничә. Мин сезгә шуларның үзем укыган берсенең кыскача эчтәлеген сөйлим.

— Кыскартып маташма, тулысы белән сөйлә, безгә каядыр барырга соңга калабыз дип ашыгасы юк,— диде кылый авыз.

— Сезгә бер үтенечем бар, фикерләремне бутамас өчен бүлдермәскә тырышыгыз мине.

— Синеңчә булыр, студент, сузма, башла!

— Узган гасырның урталарында Парижның иң фәкыйрь урамнарының берсендә тышкы ягы ярыйсы ук чибәр бер йортның икенче катындагы өч бүлмәле фатирда кырыс кыяфәтле, бармак юанлык тимер таякны сүс бау кебек эһ тә итми бөгеп төйни һәм кирәк санасалар аны шундук чишеп янадан таякка әверелдерә ала торган сәер бер кеше яшәгән.

— Ул Рокамболь исемле булган.— дип әйтеп салды Муха.

— Юк, ул Жак исемле булган.— дидем мин.

Муха үзенекен такылдады:

— Мин Рокамбольдер дип уйлаган идем.

Аның минем сөйләвемне бүлүе кылый авызга ошамады.

— Комачаулама кешегә, такылдык, кит моннан, шушы минутта ук югал күземнән һәм янадан чакырганчы безнең тирәгә якын киләсе булма.

— Семка, беренче тапкырга гафу ит, зинһар, сөйләсен, бүтән бер сүз әйтмәм...

Кылый авызны Муханың аны тәкәллефсез төстә әшнәләрчә Семка дип атавы чыгырыннан чыгарды.

— Бүтәннәргә мин Семен Антоныч, ә син маңкага һаман Семка!.. Оятсыз! Бар әле өч көн парашаны саклап утыр. Ну!..— дип акырды ул бөтен камерага.

— Семен Антоныч, гафу ит, мин сизмәстән...

Кылый авыз урыныннан торып Муханы аякларына бастырды да кинәт артына тибеп сәке-сәндерәдән идәнгә мәтәлдереп төшерде.

— Утыр параша янына, үләксә, һәм аннан, яшисең килсә, китәсе булма! Кая, чыгар әле папиросыңны, Арик.— дип мөрәҗәгать итте аннары Рокамболь турында ишеткәнем бар иде дигән яранына. Тәмәке кабызып тәмләп суыргач, миңа:— Дәвам ит, студент, сиңа бүтән комачаулаучы булмас.— диде.

— Жакның ике баласы — буй җиткән улы һәм уналты яшьлек кызы булган. Жак балаларын, балалары аны бик яратканнар. Жакның хатыны да, балаларыннан башка туган-тумачалары да булмаган. Бер көнне Жак өеннән бик ашыгып каядыр чыгып киткән дә кич тә, икенче көнне дә, өченче көнне дә, бер атна үткәч тә балалары янына әйләнеп кайтмаган. Тик ун көннән соң гына боларга бик фәкыйрь киемле, йөзен сакал-мыек баскан бер бәндә килеп Жакның кинәт кенә үлеп киткәнен, үләр алдыннан балаларына васыять язуы калдырганлыгын әйткән. Егет белән кыз инде берничә көн ач утырган булганнар. Әтиләре калдырган васыять язуын укыгач, егетнең чәчләре үрә торган. Жак язуында аңа сеңлесен фәхишәләр йортына урнаштырырга, үзенә фатирларының кунак бүлмәләрендә люстралары эленгән тимер ыргакка бау тагып асылынырга киңәш биргән...

Мин Рокамболь маҗараларын берничә сәгать сөйләп ялыктым. Кылый авыз һәм аның яраннары Дима, Арик, Филя мине тын да алмый тыңладылар. Роман сөйләнеп беткәч, кылый авыз:

— Минә бу романны роман дисәң дә ярый. Молодец, студент, шәп әйбер сөйләдең, сине моның өчен сыйлыйбыз хәзер.— диде арқамнан кагып.— Филя, заначканы сал әле уртага, сыйлыйк студентны, үзебез дә тамак ялгыйк. Ничек, яраннар, ошадымы сезгә студентның сөйләгәне?

— Ошады, Семен Антоныч. Минә Рокамболь кебек булсаң иде.— дип җавап кайтарды аңа озын муенлы котсыз Дима.

— Бул соң, сиңа кем комачаулый?

— Комачауламый комачаулавын, мин Рокамболь күк түгел, синең кебек тә була алмыйм бит, Семен Антоныч.

— Әйдә ашавың бел, күп сөйләшмә.

Шунда мин:

— Семен Антоныч, Мухага сез, минемчә, юкка җәза бирдегез, рәхимлелек күрсәтеп, гафу итегез аны.— дидем.

— Мухага адвокат булма, студент, минем эшемә тылкышма, кемгә кайчан җәза бирергә, кемне кайчан гафу итәргә икәнне мин кешедән сорамыйм, ашавың бел,— диде кылый авыз, кырт кисеп.

Без ашаганда Муха параша янындагы юешкә кулын куеп, шул кулына башын салып йокыга талган иде.

## 3

Ашап туйгач, кылый авыз тәмәке кабызды да яраннарына:

— Егетләр, безнең күптән камераның старостасын сайлаганыбыз юк, бүген шуны эшләп ташламыйбызмы?— диде.

— Нәрсә, әллә студентны староста итәбезме?— дип сорады аңардан Арик, хәйләкәр елмаеп.

— Старосталыкка бармый студент, бер атка ике камыт киермиләр, аның инде шөгыле бар — безгә романнар сөйләү. Ул без куйган спектакльне карап күңел ачар, көләр. Старосталыкка бер кандидат үзең булырсың, икенче кандидатны фраерлар арасыннан табарбыз. Төш аска, оештыр спектакльне.

Арикның староста сайлавы инде беренче генә тапкыр түгел иде, күрәсең, аска төшеп камерадагы бөтен кешене аякка бастырды.

— Мужиклар, тордык, җитәр йокы симертү, эш бар. Камерабызда староста юк, арабыздан берәүне староста итеп сайларга кирәк. Ул төрмә хуҗалары алдында безнең кирәкләребезне кайгыртыр. Кемгә передача китертергә кирәк, кемгә якыннары, туганнары белән очрашу оештырасы булыр, старостага мөрәҗәгать итәрләр. Ул, камераның без сайлаган тулы хокуклы вәкиле буларак, бөтенебез исеменнән эш йөртер. Кемгә хат яки шикаять язарга кәгазь, каләм, кара кирәк — аларны начальстводан алыр, чирләгән кешеләргә врач китертер, парашаны чыгарырга кизүләр билгеләр, идәнне юдырыр.

— Ник кемнедер сайлап торырга, үзең генә бул староста,— дип тәкъдим итте аңа әшнәсе Филя.

— Голамә нәрсә әйтер бит аңа,— Арик як-ягына каранды.— Әнә пеләш агай синең тәкъдимеңә риза түгел.— Ул тоткыннар арасындагы чигә чәчләре чалланган, маңгае өстендә бер бөртек чәче дә калмаган 45—50 яшьләр тирәсендәге агайга төртеп күрсәтте.

Агай үзенә игътибар ителүгә уңайсызланды.

— Юк, юк, мин каршы түгел, риза, риза,— дип, иңнәрен җыерып, Арикка аркасы белән борылды.

— Риза булсаң, старосталыкка бер кандидат мин, икенчесе син буласың алайса.— Аннары Арик өскә, сәндерәдәге әшнәсенә карады.— Ә син, акыллы баш, төш аннан, ярдәм ит безгә, тәкъдим керттең, аны җиренә җиткереш.

Филя идәнгә төшеп әшнәсе янәшәсенә басты.

— Инде сайлау тәртибен аңлатам. Барыгыз да миңа карагыз, соңыннан хәрәмләдегез диярлек булмасын. Башта ике шырпы алабыз. Шырпыларның берсен менә шулай кыскартып сындырабыз, икенче шырпы бөтен килеш кала. Шуннан соң акыллы баш, яле җиңнәреңне сызганып, кулларыңны терсәктән бөк. Булды. Терсәктән бөгелгән ике беләк арасына әзерләнгән шырпыларны кыстырабыз. Старшиналыкка кандидатлар күзләрен калын чүпрәк яки шарф белән бәйләп иреннәре белән шул шырпыларның озынынмы, кыскасынмы тартып чыгарырга тиешләр. Шырпының нинди — озынынмы, кыскасынмы тартып чыгарган кеше старшина була, мужиклар?

Старшина сайлау камерадагы нишләргә белмәүдән ялыккан кешеләрне гипнозлаган иде бугай, арадан берничә кеше:

— Озын шырпыны, озын шырпыны тартып чыгарган кеше,— диделәр.

— Ягез әле, китерегез безнең теге бердәнбер урындыкны монда. Рәхмәт. Утыр, акыллы баш, урындыкка. Шулай. Беләкләреңне куш, шырпыларны кыстырыйм. Инде берәр чүпрәк белән минем күзләремне яхшылап бәйләгез.

Озак та үтмәде. Арик чумкәйгән иреннәре белән Филяның беләкләре арасына кыстырылган шырпыларны эзләргә кереште. Бераз кармалангач, ул иреннәре белән сынык шырпыны тартып чыгарды.

— Законно, мин старшина түгел,— диде ул, тантана итеп.— Хәзер агай синең күзләреңне бәйлик, инде шырпыларны иреннәрең белән син капша, син дә кыска шырпыны тартып чыгарсаң, старшиналыкка өченче кандидат билгелибез.

Агайның күзләрен бәйләгәч, Арик Филяны урыныннан торгызып, чалбарын төшерде һәм шәрә артын туңкайтып урындыкка тезләнде.

Камерадагы бөтен кеше аптырап тынып калды.

Пеләш агай, иреннәрен шырпы суырырга чумкәйтеп, Арикның шәрә артына якынлаша башлады. Мин, ярсып сәке-сәндерәнең икенче катыннан идәнгә сикереп төшеп, агайны читкә этәрдем.

— Син нәрсә, студент, яшәүдән туйдыңмы?— дип каршыма басты Арик, ачудан тешләрен шыгырдатып.— Парашага башыңны тыктырасың киләме?..

— Бәлки, синең үзеңнең аның тәмен татыйсың киләдер? Мин теләгеңне рәхәтләнеп үтәргә әзер,— дидем.

Өстән кылый авыз:

— Егетләр, әтәчләнмәгез! Акылыгызга килегез, булды, бетте, күтәрелегез монда,— диде.

Арик белән Филя «шаяруларына» комачаулаганым өчен миңа акаеп карадылар.

Шулчак мин үземә бу камерада килешмәс дошманнар булдыруымны аңладым.

## 4

Мин кылый авыз белән аның яраннарына юаныч бирүчегә, аларның күңелләрен табучыга әверелүемне сизми дә калдым. Аларга берөзлексез диярлек «романнар» сөйләдем. Бәйсезлегемне югалтуыма әчем пошты, үз-үземне күрәлмәс булдым. Тора-бара сөйләгән «романнар»ымның күбесе тыңлаучыларымны канәгатьләндермәвен, аларның таләп-татымнарына туры килмәвен тоя башладым. Староста «сайлауга» аяк чалганым өчен кылый авыз һәм аның яраннары алдында дәрәҗәм төште. Моңа әллә ни исем китмәде китүен, шулай да химаячеләремнең мине аларга каршы чыкканым өчен җәзасыз калдырмаячакларын бер генә минутка да исемнән чыгармадым. Миемне, ничек алардан читләшергә, ничек диган уй бораулады. Миңа параша янынннан кайткан Муха аеруча дошманлык күрсәтә башлады. Кылый авыз, җәза бирүенә өч көн үткәч, аны гафу итте. Муха, параша буеннан элекке мохитенә кайткач, шефыннан җәзалануының үчен миннән алырга керешге. Сөйләгәндә миңа төрлечә комачаулады, игътибарымны нәрсәгәдер юнәлтергә тырышты, бүлде. Болар барысы да кылый авыз күрсәтмәсе белән эшләнделәр бугай, ул Муханың «җорланулар»ына битараф калды. Бер көнне йоклаганда Муха минем сул аягымның бармаклары арасына утлы тәмәке төпчеге кыстырды. Мин аяк бармакларым арасы әрнүдән уянып киттем һәм үз-үземне белештермәстән авызын ерып аяк очымда утырган Муханы тибеп очырдым. Ул ах итеп сәке-сәндерәдән идәнгә мәтәлде. Кылый авызның яраннары мине шундук өстемә атланып дөмбәсләргә керештеләр. Мин:

— Семен Антоныч, ятканны тәпәләү каракларның кайсы законында бар? Тый яраннарыңны, аларга мин нинди начарлык эшләдем?— дидем.

— Җитте, егетләр, туктагыз кыйнаудан, ул сез очәүләп тукмарлык нинди гаеп эшләде?

— Ул Мухага типте.

— Муха үзе аның аягын төпчек белән пешерде бит.

Әһә, кылый авыз мине үзенең табан ялаучысыннан күрәләтә мыскыллаткан икән...

Яраннар мине дөмбәсләүдән туктап өстемнән төштеләр. Мин торып утырдым.

— Әйт әле, Семен Антоныч, нәрсәм ярамады сиңа, нигә син мине үз ахириләреңнән кимсетергә юл куясың? Сезнең арагызга мин ялынып килеп кермәдем, син үзең чакырып алдың, бер атнадан артык өзлексез такылдап күңелегезне табуыма рәхмәтегез шушымы?

— Без сиңа бурычлы булып калмадык, такылдаганың өчен ашаттык.

— Мин сезгә тамак хакына эшләдем булды алайса?

— Шулай булды.

— Кеше түгел, адәм актыгы син, хөрмәтле Семен Антоныч. Адәм актыгы, бүтән беркем түгел!..

Кылый авыз күкле-яшелле булды.

— Нәрсә әйттең, кабатла әле тагын бер, студент...

— Син — мразь!..

— Яраннар, чөегез аны сәке-сәндерәдән параша янына, телен тешләсен!..

Мин, тиз генә аякларыма калкып, аркамны стенага терәп бастым. Арик, Дима, Филя, кашларын җимереп, өчесе өч яктан миңа якынлаша башладылар. Мин уң ягымдагы базык гәүдәле Диманы үземә якынрак җибәрдем дә бөтен авырлыгымны салып ияк астына төрттем. Яран аркасы белән «шефы» янына барып сыланды. Арикның җай китереп касыгына типтем, ул да бөгелеп төште. Иптәшләре тынсыз ятуга аптырап «шефына» караган озын муенлы Филяның күкрәк авызына төрткәч, ул да турыга катты.

— Кил, сиңа да өлеш чыгарам, Семен Антоныч, бер ахмак студент телен тешлисе килмичә ямаган иде, дип искә алырсың,— дидем аннары кылый авызга.

— Шәп булды, кирәкләрен алдылар яраннар. Ә миңа янама, рәхмәт, сине болай да онытмам, еш искә алырмын, студент,— диде ул, берни булмагандай.

— Алайса менә нәрсә, чистартыгыз сәке-сәндерәнең бу өлешен, аска төшегез,— дидем.

— Нәрсә?.. Нәрсә?..— дип кесәсеннән пычак чыгарып өстемә килә башлады Арик. Ул инде касыгы авыртудан арынып, аякларына баскан иде.

Мин аны, пычак тоткан кулының беләгеннән эләктереп, аска чөйдем. Пычагы ычкынып, сәке-сәндерә кырыена кадалды. Тиз генә иелеп пычакны эләктереп алдым.

— Йә, эчәкләрегезне агызганчы ычкыныгыз моннан, аксөякләр!..

Кылый авыз яраннарын ияртеп аска төште, алар урынына астан гади тоткыннар үрмәләде. Институтның физкультура-спорт факультеты студентлары белән бокс серләренә өйрәнүем рецидивистлар белән алышканда миңа әнә шулай бик тә ярап куйды.

Ни гаҗәп, каракларның яңадан кемнәрнедер үз кубызларына биетергә омтылулары бүтән сизелмәде. Көн-төн тын гына карта уйнадылар, тавышланмадылар. Кемгәдер килгән передачаның яртысыннан күбрәген талап алудан да туктадылар. Минем исә хәтта барлыгымны да оныттылар кебек, яныма якын да килмәделәр. Берничә көннән мин колониягә озатылдым. Кылый авыз һәм аның яраннары белән безнең юллар шул пересылка камерасында мәңгегә аерылды.

## Ундүртенче бүлек

### I

Кремль буендагы пересылкадан безне инде декабрь аеның икенче яртысы башланган булса да, ачык йөк машинасының шәрә кузовына селкенә дә алмаслык итеп кырык кешене бер-беребезгә елыштырып утырттылар да, Казан урамнары буйлап җилдереп, Вахитов колониясенә китерделәр. Машинадан төшкәч, әйбәтләп тентеп, (мин Арикның пычагын ярый әле пересылка

ишегалдында сукмак читендәге көрткә чөйгән идем, үзем белән алып килсәм, эләгәсе булганмын), сафка тезделәр һәм бизәкләп эшләнгән тимер вахта капкасыннан зонага керттеләр. Вахта бинасы янында һәркайсыбызның «дело»сын җентекләп карап, ашыкмый гына кабул итәргә тотындылар. Көн суык, әмма җил юк иде, ярыйсы ук түздык. Безне кабул итүче өлкән лейтенантның тешне тешкә тидерә алмый калтыранып басып торуыбызга исе китмәде. Тоткынның башта фамилиясен кычкырып, аннары фамилиясе аталган кешенең үзеннән исемен, әтисе исемен, туган елын, нинди статья буенча хөкемгә тартылуын, срогының күпме икәнен әйттереп, әле тикшерелә торган кешенең баш киемен салдырып үзенә, әле аның «дело»сындагы туры карап һәм ян белән төшкән фоторәсемнәренә, әле янадан үзенә кат-кат карый-карый мыштырдады. Һәр тоткынга биш минуттан да ким вакыт сарыф итмәде өлкән лейтенант. Ләкин берни эшли алмадык, бу эчпошыргыч тапшыру — кабул итү процедурасының мөмкин кадәр тизрәк төгәлләнүен түземсезлек белән көттек. Суыктан һәм безне кабул итүче өлкән лейтенантның йокылы-уяулы кеше сыман мыштырдавына үртәлеп басып торганда, кардан чистартылган киң юл буйлап бер кулына балта, икенчесенә колагыннан бармаклары белән чеметеп кеше башы күтәргән, өстендәге бушлатын җилбәгәй җибәреп зона түреннән безгә таба килүче берәү игътибарымны җәлеп итте. Аптырап янымда басып торган иптәшләремә карадым. Алар да вахтага якынлашып килгән балталы бәндәгә гаҗәпләнеп төбәлгәннәр иде. Безне колониягә кабул итү йоласында катнашучы хәрбиләр дә, аны күргәч, сагайдылар.

— Монда якын килмә, тукта урыныңда! — дип боерды аңа өлкән лейтенант, безнең «дело»ларны янындагы солдатка тоттырып.

Бандит туктамады, кулындагы канлы балтасын читкә атып, килүен дәвам итте. Өлкән лейтенант билендәге кобурасыннан пистолетын чыгарды.

— Курыкмагыз, мин сезгә тимим, гражданин начальник. Менә бүләк китерәм, кабул итеп алыгыз, мин аны тере чакта карта уйнаганда оттым, — диде килүче, берни булмагандай кулындагы башны вахта бинасы баскычына ташлагач.

— Кем башы ул? Син үтердеңме аны?

— Каракларга хыянәт иткән Жора Фиксатый башы. Әйе, мин үтердем аны.

— Сохин башымы?

— Шуныкы. Әшнәгез иде бит ул сезнең. Гәүдәсе ашханә янәшәсендәге баракның сушилкасында. Мәетен тапкач, башын эзләп интекмәсеннәр дип монда китердем. Рәхмәт әйтегез. Эшегездән бүлгәнем өчен гафу үтенәм, гражданин начальник. Бүтән сүзем юк, киттем мин.

— Китмәдең, — диде өлкән лейтенант, яньчек борынның юлын бүлеп. — Самарин, Сиропян, кулга алыгыз аны. Син, Алеев, каравыл бүлмәсеннән кул богавы алып чык.

— Нигә мине кулга алырга? Суканы дөмектергәнем өченме? Ул кеше түгел, нәҗес иде бит, начальник, — дип, яньчек борын өлкән лейтенантка текәлде.

— Ачыкларбыз, — диде өлкән лейтенант, пистолетын шинель кесәсенә тыгып. Тирәсендәге солдатларына: — Алып китегез моннан бу адәм актыгын, авызыгызны ачып басып тормагыз! — дип акырды.

— Урынсызга рәнҗетәсең, гражданин начальник, урынсызга... Әйт әле, мин — адәм актыгы, ә син үзең кем? Без менә алар белән, — яньчек борын башы белән безнең якка ымлады, — зеклар, монда көчләп тотылабыз. Без исә, бүтән җирдә эш табалмый, зонада зеклар канын эчәсез, хәсисләр. Адәм актыгы имеш. Җүнле кеше әйтсә икән, җандар әйтә...

Ике солдат яньчек борынны кулларына богау салып вахта янынннан төрткәләп алып киттеләр. Өлкән лейтенант, пистолетын шинель кесәсеннән чыгарып кабурасына салгач, күзләрен акайтып безгә акырды:

— Колакларыгызны шәмрәйтеп ник ул әтрәк-әләмне тыңладыгыз? Ялт тезләнегез!

Әйтерсең, монда без яньчек борынны тыңларга махсус килдек. Вахта янына без чакырып китердекме аны? Син начальник бит, ачтырма идең авызын, тыңламас идек. Тыңларга ярамаслык нәрсә әйтте ул? Хәсисләр диде, дөрес түгелмени?..

Өлкән лейтенантның боерыгын җиренә җиткердек. Тезләргә юка кальсон белән юка чалбар аша суык үтеп шундук үзен сиздерә башлады. Мин пальто итәкләремне тезләрем астына тыкмый булдыра алмадым.

— Һей, син нәрсә анда саз каены шикелле чайкаласың, өстеңә эт җибәргәнне көтәсеңме әллә?— дип ырлады өлкән лейтенант миңа.

Бар икән күрәселәр!.. Монда бандит кеше үтереп, башын колония буйлап күтәреп йөри, аңарда берәүнең бернинди эше юк... Кайда мин, үзебезнең мактаулы социалистик дәүләтебездәме, нинди дер могҗиза белән сакланып калган фашистлар концлагерендамы?.. Илебез мин кулга алынгач шулай танымаслык булып үзгәрдеме, әллә электән үк шундый идеме икән? Әнә иңнәрендә офицер погоннары йөрткән кеше кыяфәтле эт безне бозланып каткан карга тезләндерде. Ул аякларыбызга салкын тидерүебез мөмкинлеген белә бит югыйсә. Җитмәсә тагын өскә эт өстерү белән яный. Шундый вәхшилек, мәрхәмәтсезлек каян килә кешегә? Илебездәге Совет властена утыз өч ел бит инде. Гуманизм, кешелеклелек, демократия, тигезлек турында хөкүмәт җитәкчеләребез күз буяу өчен генә лаф оралар микәнни?..

## 2

Вахитов колониясендә безне башта, зонадагы берәү белән дә аралаштырмыйча, карантинга бикләп тоттылар. Мин анда тормышымда ун айдан артыграк араны эченә алган авырлыклардан соң кешечә ял иттем. Пересылкадан килгән төркемебез эчендә кылый авыз һәм аның акылга сай яраннарыише «аксөякләр»дә, блатнойлар да, тирәләрендәге кешеләрдән үзләрен бер башка өстен куярга яратучы бушкуыклар да, кемгәдер акыл өйрәтмәсә көнен зая уздыы дип саный торган «башлы» бәндәләр дә юк иде. Төркемебез бер үк камырдан әвәләнгән, беребезгә беребез ике тамчы су кебек охшаш кешеләр җыйналган идек. Карантинда мин пересылкадагы романнар тыңларга яраткан «әшнәләрем»нән аерылуыма чын-чыннан сөенеп, кемнеңдер төнлә искәрмәстән һөҗүм ясавыннан курыкмыйча иректәге чагымдагы шикелле тынычлап йоклый алдым. Миңа колония карантинында үткәргән көннәрем кулга алынуымнан соң килгән иң бәхетле көннәрем булды. Көтмәгәндә иркемнән мәхрүм ителгәннән соң кичерелгән алагаем тетрәү, ялгыз камерадагы рухи газаплар, капитан Горшенинның мәсхәрәле сорау алулары, аның берсеннән-берсе тозсыз фикри сөземтәләренә ниндирәк җавап кайтарсам тынычлыкта калдырыр дип баш ватулар, борчылулар, төрмә — инде һәммәсе артта калган, барысы хәл ителгән, хөкем карары чыгарылган дип күпмедер тынычланырга мөмкин иде. Карантинда әле һаман читлектәге кош шикелле ябылуда булсам да, мин үземне чагыштырмача иректә дип хис иттем. Монда инде киләчәк турында уйларга, алдагы көннәргә планнар корырга берни комачауламый иде. Алдагы ун елым билгеле, ул хезмәт белән төзәтү лагерьларында үтәчәк. Мин ул ун елның беренче генә елын тәгәлләп киләм әле. Бу — билгесезлеккә тәүге адымнарны гына атладым, кыенлыклар Эверестына күтәрелү юлының беренче киртләчләрен генә артта калдырдым дигән сүз...

Күпме генә тырышсам да, киләчәгемне берничек тә күзаллый алмадым. Иртәгәм миңа куе томан, шомлы караңгылык эчендә булып күренде. Шуңа күрә киләчәгемә сукмак салырга маташуымнан берни дә чыкмады. Алда үзем кичерәсе тоткын тормышын, ирektән мәхрүм ителгән кешеләрнең хезмәт белән төзәтү лагерьларында нәрсә эшләүләрен, аларның көннәрен ничек үткәрүләрен, уйларын, теләк-омтылышларын белмәвем дә комачаулагандыр бәлки.

Хәзер мин үз теләгем белән берни эшли алмаучы тоткын. Хәлем — котырынып аккан ташу суына эләккән йомычканыкы сыман. Көчле агым

нинди ярга, уңъяк яргамы, сулынамы чөеп калдырыр, билгесез. Минә гомерем ахырында, җиргә син ни өчен килгән идең, ни өчен яшәдең, үзеңнән соң нинди эз калдырдың, дигән сорау куйсалар, ни дип җавап бирермен? Оялмыйча, бернинди эзем дә калмады, диярменме? Кем соң әле минә, нинди генә авырлыклар килгәндә дә үз йөзеңне югалтма, кеше булып кал, диде? Әтием яшендәге карт коммунист Артемий Михайлович әйтте аны. Артемий Михайлович таләбенә турылыклы була алсам, теге сорауга, тормышта мин кеше булып калдым, дип кыска гына җавап бирермен дигән нәтиҗәгә килдем. Шул көннән алып бу минем девизыма, төп максатыма, алдагы маягыма әверелде.

Карантинда берничә көн йокы симерттергәч, безне мунчага алып бардылар. Мин ул көнне үземдә иртәдән үк күптән булмаган рухи күтәренкелек, гаҗәеп ашкыну тоеп, бу сәер халәтемне нәрсәгә юрарга белмәдем. Ни булды, җаным нигә йолкына, тагын нинди ятышсыз хәл көтә мине, дип борчылдым. Шуңа күрә, карантинда дүрт стена арасында ябылып ятудан туйсам да, мунчага теләр-теләмәс кенә, үземне көчләп диярлек бардым. Күңел — күрәзә, йөрәгем юкка ашкынмый, мине тагын имәнгеч күңелсезлек көтә, күрәсең, дип уйладым. Әмма ялгыштым, йөрәгем күңелсезлеккә түгел, сөенечкә ашкынган булып чыкты.

Мунча алдыннан шәп-шәрә калып, чәч, сакал-мыекларыбызны алдырырга, тәнебездә үскән башка йоннардан арынырга чиратка бастык. Анда парикмахер бер генә иде. Әмма ул эшен тиз тота торган елдам бәндә булып чыкты. Миңа аның гәүдә, кул хәрәкәтләре, ара-тирә борынын тартып куюы таныш төсле тоелды. Ул яны белән борылгач, аның балачак дустым Сөләй икәнен шәйләдем. Йөрәгем дулкынланудан ярсып тибә башлады. Дустым миңа ничектер үтә олыгайган, инде дүртенче дистәсен ваклый башлаган агай булып күренде. Йөзенә тирән җыерчыклар уелган, чәчләре инде көмешләнгән иде аның. Башта, Сөләй дә кебек ул, ул да түгел кебек, дип аңа сүз кушарга базмый тордым. Чәчтараш машинка кайчысын чистартырга туктагач, янына барып:

— Исәнме, Тәкәрлек, сине дә күрер көннәр бар икән,— дип иңенә кулымны салдым.

— Ирек?! Син ничек монда?— диде ул, гаҗәпләнүдән күзләрен челт-челт йомып.

— Син ничек, мин дә шулай.

— Урлаштыңмыни? Кем булып эшли идең?

— Урлашмадым, мине күп сөйләүдә гаепләделәр.

— Ничә ел бирделәр?

— Ун.

— Мин синнән баерак икән, парин, минем унике ел.

Без, балачак дуслары, бер-беребез өчен бөтенләй әһәмияте булмаган юк-бар сораулар яудырып, кулларыбызны кысышырга да онытткык.

Бераздан:

— Бәештән күптәнме син? Гайфи белән Кәрим ничек, исәннәрме? Әти-әниләреңнән хатлар аласыңмы?— дидем.

— Бәештән мине өченче ел шушы вакытта алып киттеләр. Бәеш син анда чактагы Бәеш түгел хәзер, бетте,— Сөләй, борынын тартып, тирән көрсенде.— Гайфи райкомда эшли, Кәрим юк, сугышта беткән. Гайфинең түше тулы калай, теге син белгән сельсовет председателе Муллин абый түшеннән аз гына кайтыш. Сугышта батальон командиры булган. Диңгез тубыктан аңа хәзер, күкрәгендәге орден-медальләрен елкылдатып җинел машинада район буйлап җилдерә. Әти-әниләр исән, әле моннан бер атна элек кенә хатлары килде. Әти сугыш инвалиды, бер аягы юк, хатында, тормыш бик авырайды, авылда иӊи үстерер кешеләр бармак белән санарлык кына калып бара, дип язган. Ярый, Ирек, мин эшемә тотыныйм, старшина килеп керсә, тик торуымны күреп бүген үк моннан табан ялтыраттырыр. Эзлә аннан соң монда күңелгә ятышлы җинел һөнәр. Эш беткәч, соңыннан иркенләп сөйләшербез. Син кайда урнаштың? Нинди эштә?

— Карантинда әле. Монда килдем генә.

— Ярый, бер лагерьда булгач, ничек тә күрешербез. Кем идең син иректә чакта?

— Студент.

— Кара әшче, димәк. Вагранка тирәсенә әләгүдән саклан. Балта остасымы, фельдшермы дип алда. Медпунктка әләксәң, миңа начальник булырсың. Анаң фельдшер бит: градусник куя, дарулар өләшә беләсеңдер. Хәйләсез дөнья файдасыз. Монда документлар күрсәтәсе юк, нәрсә әйтсәң, шул дөрес.

Сөләй әшенә тотынды. Чиратым җиткәч, чәч, сакал-мыекларымны алганда ул миңа ләм-мим сүз дәшмәде, чөнки турыдан-туры начальнигы старшина кергән иде. Сөләй, әшен бетергәч, торып юынырга кереп киттем. Колониядә тоткыннар арасында һич уйламаганда балачак дустымны очраткач, тәмам югалып калдым. Кәрим сугышта башын салган, кызганыч. Тавышы әле дә колак төбемдә. Арабызда иң төпле, иң сәләтле иптәшебез ул иде. Хыялы — агроном булу, туган кырларыннан аерылмыйча илгә, кешеләргә файда китерү иде. Жәл. Яшәсен иде Кәрим, аның урынына сугышта мин һәлак булсам, гаделрәк тә, урынлырак та булыр иде. Гайфи молодец, райкомда эшли икән, югалмаган. Малай чактагы үҗәтлеге, үз дигәненә ирешү юлында берниндн киртәләр алдында да югалып калмавы булышкандыр аңа. Офицер булган, түше тулы орден-медальләр, ди. Сөләйнең аннан көнләшүе сизелә. Бөкрене кабер генә төзәтә, дию дөрес, малай чактагы гадәте юкка чыкмаган, сакланган Тәкәрлекнең. Аңа Гайфидән көнләшмәслек тә түгел, ул — колония мунчасында чәчтараш, ә Җирән — райком эшчесе. Аерма — җир белән күк арасы. Мин дә очучы була алмадым. Сөләйнең дә балачак хыяллары тормышка ашмаганга охшый. Минем теләгемә ирешә алмавым табигый, ә аңа нәрсә комачаулады икән? Карантиннан чыгу белән күрешергә, иркенләп сөйләшергә кирәк безгә. Ни очен утырттылар икән Сөләйне? Ул нигә шулай картайды икән? Кызык, минем үткәнем белән бөтенләй кызыксынмады Тәкәрлек. Әти белән әни турында да пик бер сорау бирсен... Көтелмәгән очрашуыбыз аның да кинәт миен түнтәрде, акылын алды, күрәсең...

### 3

Оляның бәйләнчеклегеннән мин тәмам гарык. Колониягә ике көннең берендә килә. Ул килгәч, аның белән күрешергә рохсәт алырга гариза язып начальство алдына барырга кирәк. Бу авыр түгел, әлбәттә. Читенлеге шул: эштән соң кешечә ял итә алмыйм. Төнге сменада уникс сәгать буена обрубкада тешләргә тиен чарлар чыжылдавын, әзлексез җан кыйнап чүкечләр тыкылдавын тыңлаганнан, тончыга-тончыга чуен, ком тузаны сулаганнан соң, ял итәсе урынга, җанаш янына күрешергә чык. Бүтән тоткыннарның хатыннары күк унбиш көнгә, айга бер килсә икән Оля, үч иткән күк көн аралаш килә. Күпме әйтеп карадым, Оля, зинһар, миңа ял итәргә бир, мин ярты тәүлек дәвамында чуен тукмап арам бит, хәлемә кер, атнага яки ун көнгә бер килсәң җитәр, дидем. Юк, үз теләге теләк аның. Синең янына мин дә эштән соң киләм, остәвенә эшем генә түгел, укуым да бар әле, синең белән очрашу миңа бәхет, җан тынычлыгы бирә, сиңа да мин куаныч китерәмдер, дип уйлыйм, ди.

Эшләр шулай: мин, уптугызынчы яшен тутырып килгән булачак педагог, Оляның телимме-теләмимме, тере курчагы — кайгыртучанлык объекты булып киттем...

Очрашкан саен ул мине, эшем буенча югары өешмаларга пик язмыйсың, дип тинтерәтә. Язмадым һәм язмаячакмын да, дим, кирелэнеп. Каядыр нәрсәдер язарга вакыт, уйланырга ара кирәк. Минем кәгазь пычратырга вакытым да, уйланырга арам да юк. Советлар Союзында хөкемгә тартылучы мин берүзем булсам икән! Әнә дөнья күргән тоткыннар хәзер бөтен ил чәнечкеле тимерчыбык киртәләр белән әйләндереп алынып, тоткыннар

белән шыплап тутырылган, зоналар белән чуарланган, диләр. Дөрестер бу. Безнең Вахитов колониясе күпме генә мәйданны били, ә анда биш меңнән артык тоткын асрала. Илебезнең кайсы гына почмакларыннан китерелгән кешеләр юк зонада!.. Украина, Белоруссия, Балтик буе республикаларыннан, Кавказдан, тагын әллә кайлардан. Кырыктан артык милләт вәкилләрен очратырга була монда. Татарстанның үзендә туып үскән кешеләр турында телгә дә аласы юк. Сугыш зилзиләсе үткән урыннарда фашистларга хезмәт иткән полицайлар, старосталар, карательләр белән бергә, төрле рецидивистлар, бандитлар, көчләүчеләр, кеше үтерүчеләр, кесәләренә берничә уч ашлык салып яки култык асларына бер баш көнбагыш кыстырып кайтканда тотылган «караклар», башка төр җәмәгать милкен урлаучылар, рәхәт тормышка ризасызлык күрсәткән «халык дошманнары», «шпионнар», «диверсантлар», «аферистлар» — тагын әллә кемнәр бар монда. Шуларның дүрттән өче үзләрен, минем кебек үк, гаепле санамыйлар. Бөтен илдән барлык тоткыннар үзләрен аклауны, эшләрен яңадан карауны сорап яза башласалар, күпме кәгазь, алар язган исәпсез-хисапсыз шикаятьләрне укырга күпме кеше кирәк. Оля аны уйламый, яз, ди. Аның бар белгәне, син үзең турында уйла, үзең турында кайгырт, еламаган балага имчәк бирмиләр, ела, ишетми калмаслар, дию. Төптән уйласаң, ул хаклыдыр бәлки, әмма миллионлаган тоткыннар арасыннан ничек итеп бер мине араласыннар, мин алланың кашка тәкәсеме?

Өченче көн колониядә бер баптист үзен бәладән аралауның юлын тапты, төрлечә мәсхәрәләп теңкәсенә тигән рецидивистларга түзә алмый кайнар вагранкадагы сыек чуенга башы белән чумды. Эрегән металл юешне сөйми, өстенә бер тамчы су төшсә, салынган савытыннан мизгел эчендә миллионлаган очкыннарга әверелеп әйләнә-тирәсенә сибелә. Кеше организмының дүрттән өч өлеше сыекчалардан торганга, баптист чумган вагранка, бомба күк шартлап, бөтен колонияне аякка бастырды.

Колония начальнигы «корткыч» баптист китергән зыянны карарга цехка килгәч:

— Кешечә үлә дә белми халык дошманнары, аларга җан биргәндә дә дәүләткә зарар китерергә кирәк, кабахәтләргә,— дип сукранган, имеш.

Баптистны өч мең градус чамасы кайнарлыктагы сыек чуенга чуму дәрәҗәсенә җиткергән рецидивист әтрәк-әләмнәрне уена да китермәгәндер дәүләт байлыгы турында «кайгыртучы» начальник ул сүзләрне әйткәндә. Ник китерсен, тегеләр колониядә башка тоткыннарны авызлыклауда аның терәк-таянычлары бит...

Ниһаять, без Сөләй белән очраштык. Мин аны түгел, ул мине эзләп тапты.

— Күренден дә юкка чыктың, мин анда көнне мунчага да килгәнең юк. Әллә инде бу авырды, әллә колониядән китеп барды, дип ни уйларга белмәдем,— диде ул, минем күрешергә сузган кулымны җибәрмичә.— Вакытың булса әйдә, миңа барыйк, бездә аулаграк, иркенләп сөйләшербез, чәем бар, чәй кайнатырбыз. Теге көнге күрешүебез ай күрде, кояш алды кебек кенә булды, эш арасында берни сораша алмадым. Син теге чакта Бәештән киттең дә, яңадан әйләнеп кайтмадың. Иә, тормышта ниләр кырдың, нәрсәләргә ирештең? Әтиең белән әниең ничек, исәннәрме?

Балачак дустым, әйтерсең, түбәмә сугып телем тешләтте. Мин үзем дә инде унөч ел буе җавап эзлим, ләкин җавап таба алмыйм ул биргән сорауга. Иң авырткан җиремә кагылырын белсә, Сөләй очрашуыбызның башында ук эти белән әнигә караган риясыз соравын миңа бирмәс, әңгәмәбезнең ахрына калдырыр иде.

Зонага чыгып, Сөләйнең яшәгән барагына барганда мин балачак дустыма үземнең Бәештән киткәннән соңгы тормышымны артык җәелми генә сөйләп бирдем. Әтием белән әниемнең язмышларын белмәвемне, аларның инде дөньяда барлыкларына ышанмавымны әйттем.

— Әтиеңнең башына Дагалы бүре Габбас җиткәнне беләсеңме син?— диде Сөләй, мин сүздән туктагач.

Мин, аның алдына чыгып, туктап калдым.

— Белмим. Ә син аны каян беләсең?..

— Ул Дагалы бүре белән мин немецларда әсирлектә бергә булдым. Кеше түгел, кеше кыяфәтле убыр, сатлык җан иде ул үләт. Концлагерьда чакта да әллә никадәр кешенең башына җитте. Ул анда капо иде: Фашистларның табаннарын ялаучы, аларга башөсте дип торучы. Ахырда, чамасыз алып узынгач, будылар үзен. Аны буышуда мин дә катнаштым. Тамчы да үкенмим. Авылдашларым алдында намусым пакь калсын, бу адәм актыгы Бәеш һавасын суларга кайтмасын, дидем.

— Әтинең башына аның җиткәнен кем әйтте?

— Дагалы бүре үзе мактанды. Концлагерьда чакта бер кичне үзенең түрәләре яныннан азрак төшереп кайткач, Сабир-фельдфебельне — синең малай чактагы маңкалы әшнәңнең әтисен — авылыбыз күрке саналган мәчет манарасын кисеп Бәешне ямьсезләгәне өчен себер җибәрүче кешенең кем икәнен беләсеңме, диде. Белмим, дидем. Минем кулдан үтте ул, аның Газраиле мин булдым, бездә фатирда торган укытучыгыз Фәсхи абыегызның да. Әллә кемгә куялар иде үзләрен, сабын куыгы күк шартлап юкка чыгуларын сизми да калдылар, дип мактанды. Блокта минем урыным аның белән янәшә иде. Ул мине үзенең хезмәтчесе иткән иде, тик күп җигә алмады, дөмектердек.

Мин тагын, инде ничәнче кат, уйга калдым. Риаңнарны, Габбасларны нәрсә тудыра, каян киләләр алар? Чыганаклары кайда аларның? Бер-ике генә түгел, күбәү бит алар. Сугышка кадәр, сугыш вакытында, сугыштан соң миллионнарның башларына җитте ул мортәтләр. Әмма бетәр исәпләре юк, үлә торалар, икенчеләре туа тора. Тыштан нормаль кешеләр, ә эчләре черек. Күрәсең, үзенә бер төр, беринди дәвага да бирешми торган яман чир белән авырыйлар булыр андый бәндәләр.

— Синең күк миңа да очучы булып булмады, парин,— дип башлады Сөләй үзе турында сүзне.— Җиденчене бетергәч, Кемеровога ФЗӨ мәктәбенә җибәрделәр. Шахтер итмәкчеләр иде. Шахталар янында осләреннән төтен пыскытып яткан конус рәвешле тау токымы — террикон нарын күрү белән җаным бизде шахтерлыктан. ФЗӨдә өч атна чамасы укыгач, койрыкны сыртка салып, ойгә сыздым. Дөресен әйткәндә, шахтерлар хезмәтенә күңелем ятмаудан качмадым Кемероводан, русчаны такы-токы гына белүем качырды. Мастер сөйли, мин ул әйткән биш сүзнең берсен генә аңлыйм. Анысын да әле көчкә-көчкә генә. Авылга кайтып атна да тормадым, тагын озаттылар ФЗӨгә. Бусында Себергә түгел, Донбасска. Крепильщиклыкка укырга. Монысында качмадым. Кырыгынчы елның җәенә кадәр Горловкадагы шахталарның берсендә эшләгәч, Бәешкә сабан туена кайттым да, кабат Донбасска бармадым, колхозда калдым. Көз көне тракторчылар курсына җибәрделәр. Шуннан соң сугышка кадәр МТСта тракторда эшләдем. Аннары — әсирлек, кырык дүртенче елны әсирлектән качкач, поляк партизаннарына кушылдым. Сугышны үзебезнекеләр белән Эльба елгасында тәгәлләдем. Синең ничектер, минем сәламәтлек мактанырлык түгел, парин. Германиядә калдырып кайттым аны. Фашистлар, үзләренә тәлинкә тоткан Дагалы бүрене дөмектерүдә катнашуымда шөбһәләнеп, бик хәтәр кыйнадылар мине. Дагалы итекләре белән типкәләп тешләремне коеп бетерделәр, өч кабыргамны сындырдылар, уң колагымны чукрак иттеләр. Шикләнүләре шуннан булды, алда әйткәнемчә, мин нарада Дагалы бүре белән янәшә йоклый идем. Башым күпне күрде инде, парин, мин күргәннәрне бер эт күрсә, инде күптән аяк сузар иде. Сугыштан кайткач, тук җир дип, заготзернода склад мөдире булып эшләдем. Бәхетсезлегемә каршы, ревизия вакытында складымда җиде центнер ашлыгым җитмәде. Шуңа, караклыкта гаепләп, 12 ел бирделәр. Яртысы да җитәр иде дә, судьялар, күпме бирик, дип бездән сорамыйлар шул. Ну, ничава, әзрәк яшәп калдым ичмаса...

Сөләй белән без, чәй эчә-эчә, озак сөйләшеп утырдык. Ул мине киңәшен тотып үземне фельдшер димәгәнем, обрубкада эшләвем өчен чыпчыплап битәрләде. Аерылышканда мине:

— Үзең турында үзең кайгыртмасаң, сиңа төкерәләр монда. Оорубкада ярты елга да чыдамыйлар, кәкрәяләр, чехотка алалар анда. Тизрәк кач ул җирдән, бүтән эш сора,— дип үгетләде.

Минем үземә дә эшем, җүнә-рәте булмаган көндәлек тормышым ошамый, күптән эчемне пошыра иде, шуңа күрә эшкә салкын караган бер төркем тоткыннарны этап белән каядыр озатырга әзерләүләрен ишеткәч, оператив бүлеккә колониядән китәргә теләвем, этап исемлегенә мине дә теркәүне сорап гариза яздым. Башка колониядә дә шартлар шушындагыча уктыр, монда Оля көн аралаш килеп җәфалый, бүтән җирдә хет борчучы булмас, үземә-үзем хуҗа булырмын дип уйладым.

## Унбишенче бүлек

### 1

Мин хәзер һәркөнне диярлек үзем өчен ачыш ясыйм. Рианга рәхмәт. Ул «булышмаса», күпләрнең төшләренә дә кермәгән Столыпин вагонын белер идемме һәм шул вагонда каты сак астында кая барганымны да белми Себер буйлап өч атна сәяхәт итәр идемме? Юк, әлбәттә. Аны күрү яки эчендә сәяхәт итү түгел, исемен генә ишетү дә тоткыннарның аркаларына салкын йөгертә торган Столыпин вагоны — җидеме, сигезме, инде хәтеремдә юк, тәрәзәсез тимер купеларга бүленгән корыч көпчәкләр өстендәге төрмә ул. Купеларда ут юк, аларның коридорга караган яклары зоопарклардагы зур ерткычлар өчен корылган читлекләрнеке кебек калын тимер рәшәткәле. Купе эчендә өч катлы тоташ сәндерә. Этап белән Казаннан киткәндә шундый «уңайлы» купега без төгәл унбиш кеше сыйдык. Тәҗрибәле кешеләр урта сәндерәгә урнашуны хуп күрделәр. Мин өске сәндерәгә мендем. Урта сәндерәне яулаган бәндәләрнең аякларында зур размерлы резина итекләр иде. Җәйге челләдә җиңел аяк киеме тапсалар, йә, һич булмаса, ялапаяк йөрсәләр нәрсә булыр иде аларга, дип сәерсендем мин. Әмма этапка киткәндә резина итекләр киюнең хикмәте бар икәнен тиз төшендем. Сакчылар Столыпин вагонында юлда барганда туалетка һәр тоткынны иртә-кич тик берничә минутка гына чыгардылар. Бүтән вакыт купе йозакта торды, ничек кенә ялварсаң да аны ачучы булмады. Купеда төрмә камерасындагы кебек параша юк, резина итекләр этапта юлда барганда ияләренә параша хезмәтен үтәү өчен киелә икән.

Вагонда кондезләрен стеналарның һәм түбәнең кул тидермәслек булып кызуыннан, купе эчендәге шашындырырлык бөркүдән, һава җитмәүдән, ташландык бәдрәфтәге кебек күңел кайтаргыч сасыдан мин акылымны югалтыр хәлгә җиттем. Вагондагы сакчыларның бездә гамьнәре юк иде, алар Казаннан кузгалып китү белән шәпләп юл аягын юдылар бугай, җырларга азапланулары, сүгенешүләре, нәрсәгәдер үзара талашулары ишетелеп торды. Аннары алар безне барлауны исләренә төшерделәр.

— Һей, адәм актыклары, яле торыгыз, юкка чыкмадыгыз микән, санагыз бер-берегезне!.. Юк, алай түгел, ятыгыз, аннары өске каттан иң кырыйдагы үләксә бер дип, аның янәшәсендәге ике дип, өченче үләксә өч дип, дүртенчегез дүрт, бишенчегез биш дип күтәрелсен. Урта сәндерәдәгеләр санауны уң кырыйдан алты дип дәвам итә. Аңлашылдымы? Аңлашылса, башлыйбыз.

Безне шундый яңа ысул белән тикшерү сакчыларыбызга килеште, ахрысы, бер купедан икенчесенә күчеп, алар безне шактый озак тикшерделәр. Шул мәсхәрәле барлау вакытында без купеларның берсендә хатын-кыз барын белдек.

— Тешләрең исән, чыраең аз гына адәм карарлык булса янына кереп юл буе иркәләр идем мин сине, җен карчыгы. Итәгең белән чыраеңны капласаң да кызыгырлыгың юк, кызганыч,— дип шаркылдады сакчыларның берсе, вагонның аргы башында.

— Кит рәшәткә буеннан, косык, өстеңә төрмә ширбәте сипкәнче!..— дип җавап кайтарды аңа хатын-кыз тавышы.

— Сибеп кара!..

— Мә, жәл түгел, ал! Иртәгә тагын кил, тагын коендырырмын!..

Сакчы алланы, тәмуг кисәүләрен, кабер такталарын, исенә килгән тагын әллә нәрсәләрне телгә алып бик пычрак сүгенде. Иптәшләренең берсе аңа:

— Сораганыңны алдың, яп авызың, үзең гаепле. Бар юын.— диде.

Мин тоткын хатынның әрсез сакчыны резина итеккә җыйган «хәзинәсе» белән коендырганын аңладым.

Столыпин вагонында барганда без кайнар аш күрмәдек. Көне буена һәр борынга 600 грамм ипи, өчәр тозлы селедка һәм икешәр литр су бирү белән чикләнделәр. Мич эчендәге кебек бөркүдә ашау кайгысы юк иде бездә. Ләкин купеда бөркү, сасы дип ач утырып та булмый, организм нинди генә шартларда да үзенә ризык таләп итә, аңа югалткан калорийларын тулыландырырга кирәк. Юлда безне күбрәк сусау интектерде. Читлегебезгә кертеп бикләгәч тә без, беренче эшебез итеп өстебездәге киемнәребезне салып, трусик яки кальсоннардан гына калдык. Тиребез өсләребезне чишенгәч тә кипмәде. Сусауданмы, әллә купеда бөркү булгангамы, үзебезгә бирелгән суны, яртн сәгать тә үтмәде, комсызланып эчеп бетердек. Ул безгә тәүлек буена бирелгән булган икән, сусаудан иза чигәсебез исебезгә дә килмәде. Кайберәүләр купе-читлектә нишләргә аптыраудан ипи белән балык та ашаганнар иде, аларны сусау аеруча газаплады. Эчәргә су бирүне сорап купеның алгы өлешендәге рәшәткәне ботинка үкчәләре белән тукмавыбыз файда бирмәде, сакчыларыбыз, гүя, мәрткә киттеләр. Кайберәүләрнең эчләре бора башлады, алар туалетка чыгаруны таләп иттеләр, әмма һичкем аларның хәлләренә кермәде. Купедагы резина итекле тоткыннар да нишләргә белми газапланган бәхетсезләргә ярдәм кулы сузмадылар. Һәркем тик үзе турында гына уйлады, һәркайсыбызның үз кайгысы кайгы гына булды. Күмәк тимер табутка охшаш бу имәнгеч вагон-төрмә кешелек сыйфатларыбызның хәтта югын да калдырмый юкка чыгарды. Газабыбызның чиге-ахыры булмас кебек иде. Петр Аркадьевич Столыпин патша сатрапы булган, кансызлыгы өчен аны 1912 елны революционерлар дөмектергәннәр. Бу вагон-төрмәне ул беренче рус революциясеннән соң башланган тәшвишле кара елларда политик тоткыннарны бер урыннан икенче урынга күчергәндә газаплар өчен уйлап чыгарган. Хәзер Совет власте, илгә патша һәм аның мәнсез чиновниклары түгел, халык хуҗа. Дөньяда иң прогрессив саналган беренче социалистик дәүләткә нигә кирәк, ник саклананалар икән революциягә кадәрге инквизиция вагоннары? Аңлашылмый... Сугышта нигә исән калдым мин? Яу кырында һәлак булган коралдаш иптәшләрем, сез бәхетле, чын-чыннан бәхетлеләр, беләсегез килсә. Сез бүгенге миллионлаган тоткыннарны, биек коймалар белән әйләндереп алынган меңләгән колонияләрне, ат урынына үзләре җигелеп җир сөрүче мескен хатын-кызларны, Столыпин вагоннарын, илдәге коточкыч хаерчелекне күрми үлдегез. Көнләшәм сездән, ихлас көнләшәм...

Столыпин вагоныннан төшкәч, Көнчыгыш Себернең әллә ни зур булмаган мәйданын биләгән Китойлагның икенче номерлы колониясенә китереп, карантинга урнаштырдылар. Карантин колония зонасының бер читенә аерып салынган һәм, әйләнәсе биек баганалар утыртылып, өч катлы чәнечкеле тимерчыбык киртәләре белән әйләндереп алынган карсак баракта иде. Колония белән зона арасыннан карак мәче дә үтәрлек түгел: вышкаларда кораллы сакчылар тора, барак тирәсендәге кысан мәйдан да, колония зонасы да көчле прожекторлар белән яктыртыла, әйләнә-тирәдә көндезләрен генә түгел, төннәрен дә җирдә яткан энә дә күренерлек. Карантинда без сиксән өч кеше. Кышкы киемнәребезне һәм булган бөтән аламаларыбызны килү белән каптеркага тапшырттылар. Баракта сәкеләр дә, сәндерәише нәрсәләр дә, урын-җир әйберләре дә юк, аның төзегәндә җәелгәннән бирле юеш чүпрәк күрмәгән пычрак идәнендә ауныйбыз. Иртән йокыдан торганда бөтен тән иңрәп сызлый, баш ярылырдай булып чатный. Карантинда яңа килгән тоткыннарны ялангач идәндә аунату аларның теге яки бу йогышлы авыруларын башкаларга тараттырмауның иң нәтиҗәле ысулы, күрәсең. Ан-

дагы тормышыбызның дүртенче төнендә мин тәнемне кемнеңдер утә әдәпсез капшавына йокымнан уянып күзләремне ачтым һәм өстемә тар маңгайлы, бака кебек ияксез, егерме биш-утыз яшьләрдәге берәүнең кулына һәнҗәр тотып иелгәнен күрдем. Ул, минем уянуымны күргәч, сул кулының бармагын иреннәре өстеннән борынына терәде дә дуңгызныкы кебек кечкенә күзләрен усал ялтыратып: «Тсс!» — дип ысылады. Икенче берәү минем чалбар кесәләремне актара иде. Мин торырга иттем, тар маңгай һәнҗәрен бугазыма терәде.

— Селкенәсе булма, суям!..

Кемнәр болар, алар ничек монда кергәннәр? Чалбар кесәләремне әйләндергән бандит һәнҗәрле иптәшенә:

— Берние юк, күршесенә күчәбез,— диде дә минем янәшәмдә йоклаган тоткынны капшарга кереште. Тар маңгай һәнҗәрен күршемнең бугазына күчерде. Мин башымны калкытмый гына тирә-юнемә күз салдым. Баракка безне тентергә керүчеләр бер тар маңгай белән аның иптәше генә түгел, унлап кеше икән. Берсе включатель янына басып иптәшләренең «эшен» күзәтә, калганнары карантиндагыларның йокыларын бүлми генә өсләрендәге барлы-юклы киемнәрен, кесәләрен капшыйлар. Тирәмдәге иптәшләремнең күбесе уянсалар да, идәннән калкынмый, тын гына яталар. Бандитлар, җәзасыз калачакларына шикләнмичә, бер тоткыннан икенчесенә күчеп нәрсәдер эзлиләр.

Ишек катында йоклаган таза бәдәнле бер тоткын, кинәт җәлт кенә сикереп торып, мизгел эчендә кабызгычны саклаган бандитның касыгына тортте. Аннары:

— Берегез дә йокламый бит, торыгыз! Барыбызны да суя алмаслар, бирик киpәкләрен!— дип кычкырды.

Бу хәлне көтмәгән бандитлар югалып калдылар. Без барыбыз да урыннарыбыздан күтәрелеп аларга ташландык. Мин янәшәмдәге тар маңгайның яңагына ике кулымны бер йодрыкка оештырып бөтен көчем белән тондырдым, ул капчыктай айкалып идәнгә ауды. Шунда күршемдә йоклаган тоткын сикереп торып аның һәнҗәрле кулына басты. Яман чылтырап тәрәзә өлгеләре коелганы ишетелде. Карантинга кергән бандитларның берсе җанын саклап тәрәзәдән шыларга уйлаган икән, аны аякларыннан өстерәп барак эченә тартып төшерделәр. Аяусыз тәпәләш башланды. Чакырылмаган төнге кунаклардан без бөтен тоткынлык үчен алырга тырыштык. Кемнәрдер бандитларны барак эчендәге бердәнбер мичнең кирпечләре белән, кемнәрдер куллары, аяклары белән зонадан солдатлар кереп аралаганчы котырынып дөмбәсләделәр. Бандитларның карантин барагына ничек үтүләре безгә сер булып калды.

## 3

Карантиннан чыккач, мин кырык биш кешедән торган төзүчеләр бригадасына эләктем. Бригадирыбыз Микола Зозулядан калганнарыбыз — барыбыз да «контрик»лар. Арабызда фашистларга хезмәт иткән полицайлар да, старосталар да, хәтта немецлар белән иңгә-ин торып безгә каршы сугышкан хыянәтче власовчылар да бар. Илбасарлар белән берниндн алыш-бирешләре дә булмаганнар бригадабызда тугыз кеше. Иркутск университетыннан бурят егете Иван Олзоев, Донбасстан яшь шахтер Витька Русяев, Кара диңгез хәрби флоты матросы Саша Терещенко, хезмәттәш иптәшләренә Сталинны мыеклы Газраил дигәне өчен ун елга хөкем ителгән Мариуполь егете солдат Юрий Шубин, сабыр холыклы, кайчан карасаң да үз уйлары белән мәшгуль латыш язучысы Ионас Шукис, авыл хуҗалыгы белгече, профессор, бригадирыбыз Зозуляча әйтсәк, ягулыксыз да ярты әйләнештә кабына торган 81 яшьлек морганчы-вавиловчы Яков Борисович Воробьев, үз исәбенчә доньяга 30—35 елга алданрак килгән астроном Михаил Мотяшев, империалистик Япония тар-мар ителгәннән соң Союзга кайткан инженер Арон Маневич һәм мин.

Бригадирыбыз безне бетле интеллигентлар дип атый. Аныңча, без төрмәгә үзебезнең аңгыралыгыбыз, бер телебезгә хуҗа була белмәвебез, иптәшләребез белән аралашканда аларга бәя бирүдә талымсызлык күрсәтүебез аркасында эләккәнбез. Колониядә 58-10 статьясы буенча хөкемгә тартылган тоткыннарны лыгырдыклар дип йөртәләр. Зозуля безне үзе дә кыерсытмый, бригадабыздагы ата фашистлардан да кыерсыттырмый. Иптәшләрем арасында миңа Иван Олзоев якын. Без икебез дә элекке студентлар, еш кына узган тормышыбызны, лекцияләрне, семинарларны, профессорларыбызны, укытучыларыбызны искә төшерәбез. Иван сөйгән кызы Зинаны сагына. Ул Зинасы турында бер сөйләгәнен беркайчан да яңадан кабатламый, сәгатьләр буе сөйли. Мин, ул кызны күргәнем булмаса да, хәзер Оляны ничек күз алдыма бастырсам, шулай ук күзаллыйм. Юрий Шубин — шагыйрь. Ул Есенинны дөньядагы бөтен әдипләрдән өстен саный. Аның шигырьләренең барысын да диярлек яттан белә. Без аңардан сөекле шагыйренең «Әниемә хат», «Качалов этенә», «Эт турында баллада» шигырьләрен, «Фарсы мотивлары»н, «Кара кеше»сен һәм «Анна Снегина» поэмасын җай чыккан саен сөйләтәбез. Юрий карышмый, шатланып риза була һәм дөньядан вакытсыз китәргә мәҗбүр булган тиңдәшсез шагыйрьнең күңелдәге иң нечкә кылларга чиртә торган үлемсез әсәрләрен, бераз сакаулап, дулкынланып сөйли.

Торак урыныбыз — юртада. Юрта дигәч тә ул монголларныкы яки Урта Азиядә яшәүче халыкларныкы кебек киездән корамаланган тирмә түгел, эчләренә пычкы чүбе яки шлак тутырылган калын щитлардан җыелган чын торак. Аның түбәсе сумалаланган берничә катлы толь белән капланган, кышын ягарга миче, өс киемнәрен киптерергә сушилкасы бар. Юртаны шул тирә кешеләре: «Ул кыш өчен бер дигән торак, биленә кадәр карга күмелеп кала да, ачы-зәһәр җилләргә дә, сулышы белән бөтен нәрсәне өшетә торган иләмсез салкыннарга да баш бирми», — дип мактыйлар. Колониядә юрталар күп. Яшәү өчен, чыннан да, уңайлы алар. Эчләрендә ике катлы ятаксәндерәләр бар. Аларның һәрберсендә дүртәр тоткын йоклый. Ятаксәндерәләр арасында ике кешегә бер тумбочка. Әмма юнәткән ашамлыкларыбызны тумбочкага куймыйбыз, астыбызга җәйгән матрац эченә яшерүне кулайрак күрәбез. Анда ышанычлырак. Ял көнебез башлыча юртада үтә. Колония зонасында кечкенә генә клуб кисәге һәм китапханә бар. Клубта айга бер дигәндәй кино күрсәтәләр. Яңа фильмнар күрсәтелми, гел иске фильмнар гына китерелгәч, аларны караучы бик аз. Китапханә дә ярлы. Анда кешеләр уку түгел, тотып та карамый торган политик брошюралар һәм кайбер рус классикларының битләре таланып, югалып беткән кайбер томнары гына бар. Газета-журналлар китапханәгә сирәк-мирәк кенә килә, алар вахтадан зонага керү белән күбесенчә колония начальствосы өстәлләрендә торкарлана. Минем ял көннәрем шахмат этюдлары чишеп үтә. Башкалар ял көннәрендә карта сугалар, домино уйныйлар, йоклыйлар, гәп куерталар. Кешегә буш вакытын нәрсә беләндер тутырырга, борчулы уйларыннан, нииндидер шөгыль табып, арынып торырга, эчпошыргыч бертөрлелектән ничектер арынырга кирәк бит.

Эшебез — йортлар төзү, яңа шәһәр салу. Иртән йокыдан уянгач, юынып, ашык-пошык ашап-эчкәч, түбәсенә ярты метрлы кызыл хәрефләр белән «Хезмәт — намус эше, дан эше, батырлык һәм фидакарьлек ул! — И. Сталин», — дип язылган мәшһүр лозунг беркетелгән вахта капкасы төбенә чабабыз.

Колониябездән эш урыныбызга кадәр ара ярыйсы ук — дүрт-биш километр чамасы. Без һәр карышы таныш ул араны тын гына үтәбез. Сафта барганда сөйләшү тыела. Көн аяз, тыныч чакта конвоирлар борчымый безне. Һәркайсыбыз үз уйларыбызга бирелеп, эш зонасына керү капкасы алдына барып җитүне тоймый да калабыз. Җүнле кеше этен дә өеннән чыгармаслык җил-яңгырлы сыйсыз көннәрдә өс-баш манма су була, күшегәсең, конвой да чыланып күшегә. Ул андый чакта холыксызланып безне ашыктыра, бер-ике адымга арткарак калучыларыбызга акыра, ярсып сүгенә башлый, овчаркалар котырынып өрәләр...

Промышленность мәйданында (эш зонабыз шулай атала) без үзебезгә үзебез хуҗа. Конвоирлар зонага кермиләр, кайтып китәләр. Әмма эшебез зонасында бригадирыбыз безгә кул кушырып тик утырырга ирек бирми, өзлексез эшләтә.

Көннәр яхшы чакта эш уен гына, көннәр бозылса, хәлебез авырлаша. Яңгыр вакытында өс киемнәребез сыгып алырлык була, атналар буе кипми, кигәч лычкылдап тора. Әмма өс-баш чылануга карап үтисе планыбыз җибеми, үзгәрешсез кала. Ул 101 процентка үтәлмәсә, ризыгың дүрт йөз грамм ипи белән бер кружка кайнар судан артмый. План үтәлсә, бер килограмм ике йөз грамм икмәк аласың, көндез һәм кич кайнар аш ашыйсың. Шуңа күрә тоткын эшне эшлисе килеп түгел, ризыгы киселүдән куркып, туйганчы ашаудан мәхрүм калмас өчен башкара. Планны арттырып үтәүнең тоткын өчен тагын бер уңай ягы бар. Ул 150 процентка һәм аннан да артыгракка үтәлсә, хезмәт белән төзәтү колониясендәге бер эш көне өч итеп исәпләнә. Бу — көнлек норма бер ярым тапкырга җиткереп үтәлсә, срок өч көнгә үзеннән-үзе кими дигән сүз. Ирекккә тизрәк чыгасың килсә — ялкауланма, эшлә, алдагы көннәреңә юл үз кулыңда, соңгы көчең куеп тырыш, бәхетеңне кулыңнан ычкындырма, янәсе. Шунысы бар, безнең көнлек норманы алдау-йолдаусыз үтәрлек түгел. Норманы үтәр өчен, тир түгеп эшләүдән бигрәк, прорабны «майларга» кирәк. Аны бригадирыбыз Микола Зозуля башкара, ул аның эше. Безгә ай азагында, план үтәлеп барганда, һәркайсыбызга 100 әр сум эш хакы түләнә. Ул 100 сумның 75 сумын алу белән бригадирыбызга тапшырабыз, 25 сумы үзебезгә кала. Аны, бездән уркалар[1] талап алмаса, тәмәке, чәй-шикәр, башка кирәк-ярак алырга тотабыз. Бригадирыбыз бездән җыеп алган акчаның өчтән ике өлешен киләсе айда да нарядларны тиешенчә ябсын өчен прорабка төртә. Калганын уркалар башлыгына — колониядә иң кодрәтле кеше исәпләнгән Паханга бирә. Шулай бүреләр дә ач калмый, сарыклар да зыян күрми яшәпме яшибез...

Колонияләрдәге тоткыннар арасында, иректәге кебек үк, төрләре дә, әрәмтамаклар да, үзләре ачлы-туклы яшәп түрәләрне симертүче карусыз коллар да бар. Колониядә нарядчиклар, КВЧда (культура-тәрбия бүлегендә) эшләүчеләр, икмәк бүлүчеләр, пешекчеләр югары каста вәкилләре сыйфатында офтанмый гомер кичерәләр. Аларга ачлык та, кимсетелүләр дә, авыр эш тә, тоткыннар тормышындагы исәпсез-хисапсыз бүтән бәла-казалар да кагылмый. Ул каста кешеләре арасында аякларын көчкә атлап йөрүче дистрофиклар да, өсләренә ямау өстенә ямау салынган иске-москыны киючеләр дә юк. Аларның адымнары хуҗаларныкыча нык, сүзләре катгый, чырайлары янып тора, өсләрендә өр-яңа киемнәр. Бригадирлар, санчастьта, бухгалтериядә, мунчада, каптеркада, складта эшләүчеләр, рәссамнар, музыкантлар, тегүчеләр, итекчеләр дә, маңгайларыннан тир түгеп, баш күтәрми эшләмиләр. Ләкин аларны алда телгә алынган «түрәләр» белән бер рәткә куеп булмый. Колонияләрдә тагын нидер эшләргә физик көч куюны үзләре өчен хурлык, иң зур кимсетелү, мәсхәрә санаучы, гомерләре буена кыл да кыймылдатмый гомер сөрүче паханнар, «законниклар», аларга тәлинкә тотучы, аларның теләсә нинди әмерләрен минуты-сәгате белән җиренә җиткерүче шестеркалар бар. Алар — үзләре бер каста. Ул әрәмтамаклар үзләрен колониянең төп хуҗалары итеп саныйлар. Алар тоткыннардан теләсә кемне теләсә кайчан җәберли, җәфалый, суя, үтерә алалар. Араларыннан берәрсе тик ятудан туеп эшли башласа, аны хыянәтче исәплиләр һәм каракларның язылмаган законнары буенча аяусыз җәзалыйлар. Соңгы бу кастага кергән әрәмтамаклар колонияләрдә башларына нинди этлек эшләү уе килсә, шуны тормышка ашырып, үзләренә ничек ошый, шулай көн итәләр. Колония башлыклары әрәмтамаклардан уттан курыккан кук куркып, аларга ярарга тырышалар, куштанланалар. Законникларның көннәре карта сугып, ләчтит сатып, тыгынып, үзләренең «булдыклылыкларын» бер-берләренә мактанып, нинди дер юк-бар планнар корып, әдәбиятны яхшы белүчеләрдән романнар сөйләтеп, малайлар белән гыйшык-мыйшык уйнап, аракы юнәтсәләр аракы

---

[1] Уркалар — караклар (жаргон).

аракы юк чакта чифир эчеп, анаша, гашиш тартып, беләкләренә яки утраксаларына морфи кадатып, наркотик дарулар эчеп кәефләнеп утә. Колонияләрдә иң түбән катлау булып үзләре ачлы-туклы яшәп, зонадагы төрле «түрәләрне» рәхәт чиктерүче XX гасыр коллары — «работягалар» санала. Аларны юктан гына да теләсә кем теләсә ничек кимсетә, мәсхәрәли, түбәнсетә ала. Зонаны саклаучы овчаркалар работягалардан мең тапкыр өстенрәк исәпләнә. Тоткын, кеше булса да, эттән дә түбән. Моны мин кулга алынуымның тәүге минутларыннан ук үзем татый башладым.

## Уналтынчы бүлек

### 1

Көз. Табигать кышка әзерләнә. Колония тирәсендәге тайганың төсе танымаслык булып үзгәрде. Әле берничә көн элек кенә ямь-яшел утырган мәһабәт карагайлар инде сап-сары. Юкә, каен, шомырт, өрәңгеләр алтын яфракларын көзгә кызганмый ясакка түлиләр, кошлар җылы якларга китә. Көндез эш белән мавыккангадырмы, мин күктән торналарның, кыр казларының туып үскән төбәкләре һәм безнең белән язга кадәр үз телләрендә сагышлы саубуллашуларын ишетмим диярлек. Ә кичләрен, кояш батып караңгы төшкәч, аларның серле күк бушлыгында көенечле торкылдаулары, моңлы каңгылдаулары күңелне кузгатып хафалый, хәвефләндерә. Йөрәк ярсып, кышны үткәрергә салкыннар булмый торган һәм азыклар мул җирләргә юл тоткан ирекле риясыз кошларга иярергә, тоткынлыкка мәңге кул селтәргә омтыла. Бу — эшкә ашмас омтылыш. Тоткын кошларга ияреп оча алмый, аның канатлары кисек...

Бүген мин җылы якларга китүче кошларның күктән безгә юллаган саубуллашу авазларын бригададашым Михаил Мотяшев белән бергә тыңладым. Ул аяз көннәрне кичләрен, юртабыздан чыгып, исәпсез-хисапсыз йолдызлар белән чуарланган караңгы күкне күзәтергә ярата. Җәберләнеп кыерсытылган астроном үзенең иске танышлары — күк җисемнәренә карап нәрсә уйлыйдыр, билгесез. Михаил Ильич алар белән үзенең ел ярым элек искәрмәстән өзелгән әңгәмәсен дәвам итәдер бәлки?

Мин төнге күкне күзләрем белән капшап уйланып торганда Мотяшев яныма килеп басты.

— Йолдызларны күзәтәсезме? — диде ул, күзләрен галәм бушлыгына төбәп.

— Җылы якларга китүче торналарны, кыр казларын озатам.

— Мин менә, гадәтемчә, йолдызларымны барларга чыктым. Комачауламамдыр бит?

— Комачауламыйсыз, әлбәттә. Мөмкин булса, иренмәсәгез, бәлки Җидегән турында сөйләрсез миңа? Ул йолдызлык мине бала чактан бирле үзенә тарта, кызыксындыра, әмма әлегә кадәр аның турында берни дә белмим диярлек.

— Җидегән турында сөйләргә дисез? Була, рәхәтләнеп сөйлим. Бер халык аны Арба, икенчеләре — Повозка, өченчеләре — Чүмеч, руслар Олы ана аю дип атыйлар. Русларга бу исем греклардан килеп кергән. Алар Җидегәнне Арктос, ягъни аю диләр. Арктика сүзенең дә тамыры шул арктоска барып тоташа. Арктика — аюлар төбәге дигән сүз. Җидегәннәр, беләсездер, ике — Зур Җидегән һәм Кече Җидегән. Сез кызыксынган Зур Җидегән, бик хаклы рәвештә, күгебезнең соклангыч бизәге санала. Аңардагы җиде йолдызның һәркайсының борынгы гарәп астрономнары кушкан үз исемнәре бар: Бенетнаш, Мицар, Алиот, Мегрец, Фекда, Дубге, Мерак. Ул йолдызлар һәммәсе дә бер үк зурлыкта һәм Җирдән бер үк ераклыкта түгел, төрлесе төрлечә. Безгә иң якыны, әнә чүмеч сабының очындагы — Бенетнаш. Аңа барырга калса, юл бары унбиш яктылык елын гына

тәшкил итәр иде. Бенетнаш янәшәсендәге Мицар куш йолдыз — Мицар А һәм Мицар Б. Авырлык үзәкләре аларның икесенә уртак, бер-берләренә тәмам орынганнар диярлек. Галәм киңлекләрендә куш йолдыз бер Мицар гына түгел, андый икедәш, хәтта өчтәш, дүрттәш йолдызлар бик күп. Галәмне тикшерүче галимнәр парлы һәм оеш йолдызларны гадәти, ә ялгыз йолдызларны төп кагыйдәгә туры килми торган күренеш саныйлар. Мицар А ның пары Б дан тыш тагын иярчене Алькор бар. Алькор, Җир Кояш тирәсендә әйләнгән кебек, Мицар тирәсендә әйләнә. Әмма аның әйләнеш тәүлеге Җирнеке кебек кыска түгел, озак, бик озак. Мицар гарәпчә ат, алькор җайдак дигән сүзне аңлата. Ат һәм җайдак. Шунысы кызык: борынгы гарәпләр, Җидегәндәге Ат өстендәге җайдакны таптырып, сугышчыларының күз үткенлеген сыный-тикшерә торган булганнар. Төнге күктә Мицар янындагы Алькорны күрә алучы сугышчы үткен күзле исәпләнгән. Чүмеч сабындагы өченче йолдыз — Алиот. Ул — Җидегән йолдызлыгындагы Җиргә иң ерак һәм иң зур йолдыз. Безгә аның нурлары алтмыш яктылык елы үткәч кенә килеп ирешә... Йолдызлар иксез-чиксез галәм бушлыгында өзлексез хәрәкәт итәләр, торышларын туктаусыз үзгәртәләр. Мәңгелек белән чагыштырганда кеше гомере тузан бөртегенең миллионнан бер өлеше кадәр дә юк. Йөз мең елдан соң Җир, кешеләр, тормыш нинди булыр? Ул чакта сугышлар да, төрмәләр дә, менә безнеке кебек биек коймалы, өч кат чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган каһәрле колонияләр дә булмас, шөт. Бәлки якындагы еллар эчендә үк «кайнар башлар» газиз бишегебез Җирне шартлатып, планетабызның үзен дә, аңардагы тереклекне дә юк итәрләр...

Кулга алынганга кадәр Пулков обсерваториясендә эшләгән астроном Михаил Ильич Мотяшевның сөйләгәннәрен мин йотылып тыңлап, аның һәр сүзен хәтеремә сеңдереп калырга тырыштым. Җидегәндәге йолдызларның исемнәрен дә ишеткәч, алар миңа тагын да кадерлерәк, тагын да якынрак булып киттеләр. Ул йолдызлык үткәнем, балачагым белән тоташтыручы бердәнбер күпер булганга, мин күк йөзе болытлардан чиста төннәрне аны сәгатьләр буе күзәтәм.

Әлләкси әрчүендә Җидегәндә үз йолдызларыбызны билгеләгән Камали бабай белән бергәләп атлар саклаган көннәргә әйләнеп кайтасы иде хәзер. Әрчү әле дә элеккечә үк матур, төннәрен читләре һаман да әкияттәгечә серле микән? Анда хәзер атларны башка малайлар саклый, учак тирәсендә Камали бабайның тыныч, салмак тавыш белән ашыкмый гына сөйләгән садә һәм хәйләсез хикәятләрен башка малайлар тыңлый булыр. Бәлки шушы минутта күк бушлыгында аларның кайберләре үз йолдызларын билгелиләрдер. Балачак дусларым Гайфи белән Сөләйгә дә Җидегән минем өчен изге булган кебек изге микән? Әнә ул тылсымлы Галәм чүмече! Әнә Гайфи билгеләгән Мерак, әнә Кәрим йолдызы Фекда, әнә Сөләй йолдызы Дубге, әнә минем өлешкә тигән Мегрец. Әнә чүмеч сабында Миләүшә йолдызы — Алиот...

Михаил Ильич Кече Җидегән, Тимер казык йолдызы турында сөйләүгә күчте, минем уйларым таркалды, сүзләре бер колагымнан кереп икенчесеннән чыга торды. Йолдызларның һәрберсенең исемнәрен, алар турындагы җентекле мәгълүматларны ничек хәтерендә саклый, онытмый икән ул? Бу — ул үз эшен, фән дөньясының үзе тикшерү-өйрәнү алып барган тармагын чиксез яраткан, аңа бөтен барлыгын биргән булган дигән сүз. Шуңа күрә Мотяшевның төннәрен, көндезге авыр эштән соң ял итәсе урында, күк гөмбәзенә күз төшерергә, сөекле йолдызлары белән гәп куертырга һавага чыгуы һич тә гаҗәп түгел.

Астроном минем үз уйларыма бирелеп, аны тыңлаудан туктавымны күрепме, әллә чуалган фикерләрен тәртипкә китерер өченме, сөйләүдән туктады.

Арабызда туган уңайсыз тынлыктан котылу өчен мин аңа:

— Михаил Ильич, сез Галәм киңлекләрендәге әнә ул бихисап йолдызларның берәрсендә бездәгедәй тормыш булуга ышанасызмы? — дидем. Соравым, сиздем, балаларча чыкты. Уңайсызландым. Әңгәмәдәшем көттермәде, шундук җавап бирде:

— Ышанам, әлбәттә. Тик бүтән цивилизацияләрдә Җирдәге төсле кыргыйлыклар да, башбаштаклыклар да, мондый колонияләр дә юктыр, алар бездән бик күпкә алга киткәннәрдер дип уйлыйм. Ярар, галәмгә сәяхәтебез бүгенгә җитеп торсын, кереп йоклыйк, иртәгә тагын эшкә барасы. Бу матур, мәгънәле кич өчен рәхмәт сезгә.

— Үзегезгә рәхмәт, Михаил Ильич, минем өчен аны сез матурладыгыз...

## 2

Кыш килде. Салкыннар еш кына 40 градустан да арта башлады. Иртәләрен, җилсез көннәрне, колониябезне тоныкы томан сара торган булды. Җил Ангара ягыннан искәндә (тоткынның өс-башы нәрсә генә аның) үзеңне бөтенләй ялангач итеп тоясың, бөтен тәнне салкын өтә кебек. Эштә, эшкә барганда, эштән кайтканда битләр, юка бүрек астындагы колак яфраклары, жылы бияләйләрдән һәм оекбашлардан мәхрүм кул-аяк бармаклары өшү табигый хәлгә әйләнде. Кыш өчен уңайлылыгы макталган юртада мичкә ягар өчен эштән һәрберебез тик бер пүлән булса да утын алып кайтырга тырышабыз. Йоклаганда ятак-сәндерә тактасына кайбер көннәрне өстәге кием ябышып ката. Әмма салкын 40 градусның өске ягына күтәрелде дип эштән калмыйбыз, тиешле вакытта йокыдан уянып, тиешле вакытта тамак ялгап, тиешле вакытта вахта алдына басабыз. Дөрес, көнебез учаклар тирәсендә уза. Әмма анда иркенләп җылынганыбыз юк. Күшеккән кулларыбызны ут өстендә минут-минут ярым чамасы уабыз да эшебезне дәвам итәбез. Мин латыш язучысы Ионас Щукиска түшәм корамалары ясашам. Беребез корама өчен кирәкле озынлыкта такталар әзерли тора, икенчебез ул такталарны кыскаларын озыннарына аркылы куеп кадаклый. Башта, бригадада эшли башлагач та, мин адәм рәтле итеп чүкеч тә тота, кешечә кадак та кага белми идем. Чүкечем белән кадакка түгел, бармакларыма сугып күпме җәфаланганымны үзем генә беләм. Бригадабызда бөтен кеше миннән көлә иде. Инде өйрәндем, кадакка сугу урынына бармакларымны төюем инде минем белән түгел, бүтән берәү белән булгандыр кебек.

Сабыр холыклы, беркайчан да ашыга, кабалана белми торган олкән яшьтәге Ионас Щукис эштә чакта да, эштән соң да, ял көннәрендә дә кешеләр белән аралашмый диярлек. Мин аны еш кына уч төбе хәе гына кесә дәфтәренә нәрсәдер язып куйганын күрәм. Щукис ул дәфтәрен колониягә алып кайтмый, эш урынында төнгә үзенә генә билгеле җиргә яшереп калдыра. Колониядә безгә бернинди кәгазьләр дә сакларга рөхсәт ителми, үзебез эштә вакытта надзирательләр юртада шмон (тентү) ясап, табылган кәгазь, каләм ише нәрсәләрне юк итәләр, нинди дә язулы кәгазь табылган кешене берничә көнгә карцерга ябалар. Щукис кайчан карасаң да уйчан, йөзе кайчан да саран гына елмаюлы. Мин аның белән берничә тапкыр иркенләп сөйләшергә тырышып карадым, әмма максатыма ирешә алмадым, ул биргән сорауларыма, җәелеп китмичә, әңгәмә куертырга атлыгып тормавын сиздереп, «әйе», «юк» кебек җаваплар бирүдән узмады. Куркытылган карга куактан да шолли дигән кебек, әллә әңгәмә куерткан да артык сүз ычкындырудан курыкты, әллә аның сүзгә һәвәслеге юк, белмәссең.

Ял көнне мин ятак-сәндерәмдә, салкыннан бөрешеп, нишләргә аптыраудан шахмат этюды чишеп утырганда юртабызга сулышы кабынып Әлмәт егете Вәгыйз килеп керде. Ул миңа:

— Әйдә, тиз бул, радиодан татар концерты тапшыралар! — диде.

Юртадан йөгереп тышка чыктык. Зонадагы клуб өстенә эленгән репродуктордан бөтен колониягә, колониягә генә түгел, әйләнә-тирәдәге бөтен тайгага балачактан бирле таныш, якын һәм һәр сүзе күңел кылларына чиртә торган таныш җыр тарала:

...Кәккүк тавышы бигрәк матур тыңларга,
Кәк-күк, күк-күк, күк-күк!
Кәккүкләрне сайратырлык мәхәббәтем бар сиңа.

Тыңла, иркәм, гөл генәм, күккүк тавышын бер генә:
Кәк-күк, күк-кү, күк-кү!
Кәккүкләрне моңлатырлык мәхәббәтем бар сиңа...

Гөлсем апа Сөләйманова тавышы бу. Гүя ул радиодан җырламый, монда үзе килгән. Сулгып йөрәгем кысылды...

Гөлсем апа гүя Вагыйз белән минем өчен махсус җырлый. Юк, юк, ул җырламый, ерактагы Казаннан безгә сәлам юллый. Без Ангара ягыннан искән усал җилнең күз яшьләребезне агызуын да, берни тоймаслык булып туңуыбызны да оныттык...

Аклы ситсы күлмәгемнең
Табалмадым ишләрен,
Әй, гомрем буйларына, Райхан,
Оныталмасам нишләрмен?..

Бусы — Рәшит Ваһапов. Никадәр хис, рух кайнарлыгы, моң! Кайчандыр концерт залларында, патефон тәлинкәсендә кемендә йөзәр кат тыңланган җырлар чит, ят җирләрдә тоткынлыкта тәүге кат ишеткәндәге төсле, күңелнең иң тирән почмакларын актарып, дулкынландыралар. Җырчы аларны гүя махсус сиңа атап җырлый кебек.

Күзләрне яшь томалый, тын кысыла. Бәлки Рәшит абый үзенең иң яратып башкара торган «Фирдәвескәй»ен дә ишеттерер, дип уйларга гына өлгердем, радиодан таныш сүзләр агылырга тотынды:

Кашың кара, буең зифа,
Керфегең бөгеләдер;
Синең өчен, җан кисәгем —
Фирдәвескәй, кара күзкәй —
Үзәгем өзеләдер...

Уйларыбызны әллә кайларга алып киткән концерт кинәт кенә тәмамланды. Вагыйз дә, мин дә аны салкыннан дер калтырап, дөньябызны, тоткындагы коллар икәнебезне онытып, тыңладык. Вагыйзнең ничек булгандыр, әйтә алмыйм, минем күз алдымнан шау-шулы Казан урамнары, киң Идел, Ослан таулары, Маркиз утравы, институт аудиторияләре, анда йөргән бәхетле, гамьсез студент иптәшләрем үтте. Без яңа гына тыңлаган тансык концертны, бәлки, минем кебек үк, элекке сабакташларым да тыңлаганнардыр? Әмма аларга ул безгә ясаган тәэсирне, ышанып әйтәм, ясамагандыр. Кеше сәламәтлеген югалткач кына тазалыгы турында уйлый, кайгырта башлый, аңарчы сәламәтлегенә төкереп карый бит. Теләсә кем белән бәхәскә керә алам, ирекне югалту — сәламәтлекне югалтудан яманрак. Моны мин, үкенечкә каршы, үз җилкәмдә татыйм.

## Унҗиденче бүлек

### I

Зәмһәрир суыкта, ачы җил йотып, концерт тыңлавым кыйммәткә төште — салкын тидердем. Инде менә ике айдан артык шифаханәдә ятам. Үпкәм ялкынсынды. Озак вакытлар температурам төшми азаплады, хәлем инде яхшыра бара. Тик шунысы бар, бөтен тәнемдә — чуан. Аларның берсе тулып тишелергә өлгерми, алмашка шуның янәшәсендә үк икенчесе бәреп чыга. Кырык градуслы салкында радиодан тапшырылган концертны минем белән бергә үк шыкраеп катып тыңлаган Вагыйзгә шайтаным да булмады, бер үк җил авызында, бер үк салкында хозурландык югыйсә. Өс-башы да минеке кебек юка иде: чирләү түгел, аңа хәтта томау да төшмәде. Вагыйзнең организмы минекеннән ныграк, күрәсең. Апың белән мин карантинда

чакта ук таныштым. Бер көнне колония зонасыннан безне бүлеп торган чәнечкеле тимерчыбык киртәсе аша кемдер:

— Һәй, карантиндагылар, арагызда татарлар бармы?— дип сорады.

— Бар. Мин татар,— дидем, башымны тәрәзәдән сузып.

— Кайдан син?

— Казанның үзеннән. Ә син?

— Әлмәттән.

Карантиннан зонага чыккач Вәгыйз белән без чын-чынлап дуслаштык. Ул минем кебек «контрик» түгел, шофер, очраклы рәвештә милиция башлыгының малаен имгәткәне өчен утыра.

— Бала-чага алдын-артын уйламый чаялана бит. Милиция начальнигы малае урамга тимераякта шуарга чыккач, мин йөрткән машинаның тартмасына тимер таягы белән тагып, урам буйлап, җилдән дә җитезрәк җилдерергә уйлаган тишек борын. Мин аның тагылганын күрмәдем, бер урам чатында, йөртләр арасыннан, кинәт каршыма машина килеп чыккач, барган шәпкә тормозга бастым. Машинам кинәт шып туктагач, малай чырае белән кузовка сыланган. Аның иләмсез акыруын ишетеп кабинадан төшсәм, ята бу. Янәшәмә утырттым да алып киттем больницага. Анда аны врачларга тапшыргач юлымда булдым. Ике көн үткәч чакырдылар милициягә. Анда барып керү белән милиция начальнигы:

— Исерек баш, күзләрең тонганчы салып, урамда балалар таптатып йөри алмассың бүтән, мин сине төрмәдә черетәм,— дипябышты миңа.

— Минем берәүне дә таптатканым юк,— дим.

— Беркөн больницага кемне илттең?— ди.

— Машинам кузовына тагылып чыраен җимергән малайны,— дим.

— Боргаланма, аны син тимераякта шуганда бәрдергәнсең,— ди.

Малай, этисе больницага килгәч, үз шуклыгын яшереп, гаепне минем өскә аударган. Начальник өчен малае әйткән дөрес, мин әйткән ялган булды. Бер гаепсездән җиде ел бирделәр, ди Вәгыйз.

Больницада сырхаулар чамадан тыш күп. Без кечкенә генә палатада унике кеше ятабыз. Минем бер як күршем тел бистәсе әрмән Саркис Акопян, икенче як күршем Сызрань «таксисты» Мирон Рыбин. Саркисның өшегән сул аягына инде җиде тапкыр операция ясадылар, ләкин һаман савыгыры икеле. Акопянны бу борчымый, ул аңа хәтта канәгать тә шикелле.

— Рәхмәт аякка, мине суыктан саклый, жәлли,— ди, уены-чыны белән.

Саркис, гомумән, җор сүзле, шаян холыклы кеше, җай чыккан саен нинди дә булса кызык сөйли, үзе дә төшенкелеккә бирелми, тирәсендәге авыруларның да күңелләрен күтәрергә тырыша.

— Мин сиңа әрмән табышмагы әйтәм, шуны чишсәң, тулы акыллы кеше санала аласың,— диде ул миңа кичә.

— Чишмәсәм кем булам?— дидем.

— Чишмәсәң, ничек бар син, шулай каласың.

— Ярар, Саркис, әйтеп кара табышмагыңны, бәлки чишәрмен.

— Чишәсең, әлбәттә, син дә чишмәгәч, тагын кем чишсен аны. Бөтен әйләнә-тирәсе су, уртада — закон. Нәрсә ул, әйт?

Мин табышмакның мәгънәсезлегенә югалып калдым. Бераздан:

— Синең табышмагыңны чишәргә минем башым җитми, Саркис, гафу ит,— дидем, уңайсызланып.

— Һей, шуны да белмәскә инде,— диде күршем, шаркылдап,— җавабы гап-гади ич аның,— прокурор су коена. Минем файдага 0—1.

Мин дә көлдем. Һич чишәрлек түгел бу сәер табышмакны. Нинди җор үзе. Башыңда шарикларың йөздәгән булса да чишә алмыйсың...

— Ярый, менә бусын чишәсең дә чишәсең инде. Ул прокурор турындагы табышмакның сыңары ук. Әйтимме?

— Әйдә, әйтеп кара.

— Бөтен әйләнә-тирәсе крепдешин, уртасында — җен. Чиш, бусы беренчесеннән күпкә җиңел.

Бераз уйлангач:

— Булмый, чишә алмыйм,— дидем, маңгаемны уып.

— Эх, син, баш ватарга теләмисең. Монысының да җавабы гап-гади. Минем хатын крепдешин күлмәген киеп минем духаннан кайтуымны ярсып көтә. Минем файдага 0—2. Өченче табышмакны да чишәсеңме?

— Анысы да әрмән табышмагымы?

— Әлбәттә. Уйла. Бөтен әйләнәсендә җон, уртасы дарулар.

— Әйдә синең файдага — 0—3 булыр, үзең әйт җавабын.

— Һей, кызык түгел сиңа әрмән табышмакларын чиштерү, ми күзәнәкләреңне борчырга куркасың. Башкалар исә үтә дә комарланып, йә теге җавапны, йә бу җавапны әйтәләр. Синең исә җиңелүеңә исең китми, тизрәк бирелергә ашыгасың. Соңгы табышмакның да җавабы җир астында түгел, җир өстендә ярылып ята. Эт саклаган аптека. Уртасы дарулар — аптека, тирәсендә эт чабып йөри, анысы җон. Чишәсеңме тагын безнең әрмән табышмакларын?

— Кирәкми, Саркис, башкаларга калдыр. Минем шарикларымның алар-ны чишәр рәтләре юк, тутыкканнар.

— Шаяртма, тутыкмаганнар. Син башыңны эшләтергә теләмисең, шул гына...

Икенче күршем Мирон Рыбин — сөмсез, мут бәндә. Ул үзен һәрвакыт иплә тоткан Саркиска, син әрмән түгел, яһүд, главврач Ицхак Хаимович белән блатың бар, дип бәйләнә. Саркис көлә, шушы килеш тышта бер биш минут җилләп керсәң, синең дә аның белән блатың булыр, операция арты операция ясарлар, ди.

Алар көн саен үзара тел чарлап алалар. Мирон башлый, Саркис бәхәскә нокта куя. Рыбинның башына өстән кирпеч ташлаганнар, мие селкенгән, башы сызлап изалана.

Бүген ул, Саркисны тынычлыкта калдырып, миңа карап:

— Син үзеңнең ни өчен утырганыңны белмисең бит, агайне,— дип сүз башлады. Бәхәсләшмә, белмисең,— диде шундук, аңа каршы сүз әйтмәсәм дә, 58-10 статьясын зерә бирмиләр дисеңме? Сафсата! Миңа аны берне генә түгел, берьюлы бишне бирерлек. Синең төп бәлаң — дусларыңнан уңмау, ә минем дусларым, ышанып әйтәм, синекеләр шикелле зиһенле тинтәкләр түгел иде. Ни өчен утыруымны сөйлим хәзер, тыңла. Еллар үтеп ирекка чыккач, колониядә чакта шифаханәдә боегу белми, кайгы-сагышларга бирешми торган сызраньле Мирон Рыбин белән бергә дәваланган идек, дип искә алырсың бер. Мин — шофер. Ирекә чакта бу бер тиенгә чукынып яшәгәндер дия күрмә, төрлесе бар шоферларның — бае да, ярлысы да. Мин бай идем. Алтын белән эш иттем ирекә чакта. Валлаһи менә, шаярусыз әйтәм. Чын алтын белән түгел, хәтереңә уй, тонге алтын белән. Ассинизатор машинасында эшләдем. Борының җыерма юкка, ассинизация машинасы теләсә кемгә тәтеми. Тәтесә дә, ул машинада теләсә кем эшли дә алмый. Ис, шакшы, тегесе-бусы... Иң мөһиме — акчаны корәп аласың. Хәтереңә уй, акчасы сасы да, шакшы да түгел, шыгырдап торган нормаль акча. Мин егет кеше бит әле, өйләнмәгән. Буйдаклыгымның сәбәбе — күңелем төшәрдәй кәләш очрамау. Бәхетсезлегемә булгандыр дим, истә-санда юкта эти белән бертуган абыйның улы- Васька бер чибәр белән таныштырды мине. Сөйләшеп киттек, чибәр миңа, мин аңа ошадым. Танышканда ассинизатор икәнемне әйтмәдем, таксида эшлим дидем. Энекәшкә дә кызга мине таксист дияргә куштым. «Төнге алтын» белән эш итүчене кешеләрнең өнәмәүләрен белгәнгә эшләдем моны. Тимерне кызуында сугарга иде исәбем, чибәркәй белән һәр кичне очраша башладык. Эштән соң бик шәплэп юынам да очрашуга чабам, нинди дә булса бүләк алам, буш кул белән бармыйм. Түбәсеннән ташыйк булды миңа кызый, бер дә харап. Очрашканда йөгереп килеп муеныма сарыла, үбә. Кич җитсә, миннән дә бәхетле кеше юк.

Сызрань зур шәһәр түгел, шәһәр димәсәң хәтере калырлык, койты. Анда барлык уңайлыклары булган йортлар бик аз. Бер көнне шулай шәһәр читендәге урамнарның берсендәге йортларның ишегалдында машинам цистернасына «мал» суыртып ятуымны минем чибәркәйнең иптәш кызы күргән. Ул шундук Галям янына барып (чибәркәйнең исеме Галя иде), аңа, яңа гына синең таксистыңны күрдем, ул ассинизатор машинасында килеп, безнең

бәдрәфне чистартып китте, дип фаш иткән. Кичен Галя, мине, гомер булмаганча, иреннәрен турсайтып, кашларын җимереп каршылады. Син таксист түгел, син бук ташучы адәм актыгы, димәсенме!.. Күзләрем дүрт булды, әмма бирешергә исәбем юк, булса соң, мин теләсә кайсы таксисттан баерак, дим моңа күз дә йоммый. «Бүгеннән мин сине белмим, син мине белмә, хуш, ялганчы».— диде дә бу китеп тә барды янымнан. Гарьләнүемнән нишләргә белмәдем, утызга җитеп кияү таба алмаган пумала баш читкә тибәрде ич үземне. Очрашырга, очратып әйбәтләп сөйләшергә тырышып карадым, кая ул! Ай ярымлап узгач, энекәшем Васька Галяның шәһәрнең үзәк урамындагы гастроном директорына кияүгә чыкканын, тагын өч көннән туйлары буласын әйтте. Мин гарьлегемнән үз-үземне кая куярга белмәдем һәм ахырда үч алырга кирәк Галядан, дигән карарга килдем. Туй көнен көчкә көтеп алдым. Галялар өенә бөтен кунаклар җыелып беткәч, машинамның цистернасына шәһәрдәге иң сасы бәдрәфтән «бүләк» суыртып, туйга киттем. Машина шлангасын җәһәт кенә туй барган бүлмәнең тәрәзәсеннән ташлап, цистернаны бушандыру рычагына басарга күп вакыт китмәде... Минем «фидакарьлегем» турында гайбәт шул көнне үк бөтен шәһәргә таралды. «Бүләгем» өчен миңа биш ел бирделәр. Эшләгән эшем өчен үкенәмме? Юк, агайне, шатланам гына. Галя мине гомере буе онытмаячак. Кемнеңдер хәтерендә сакланып калу начар нәрсә түгел, минемчә. Син ничек уйлыйсың?

Миронга минем өчен Саркис җавап бирде:

— Уйлыйсы-нитәсе юк монда, сантый син. Башыңа кирпеч ташлагач аякларыңны сузсаң, бер тинтәк кимегән булыр иде...

## 2

...Вот умру я, умру, и похоронят меня,
И никто не узнает, где могилка моя...

Күңелнең иң түр почмакларына үтеп керә, иң нечкә кылларын тибрәндерә торган бу әчкерсез җырны гомеренең яртысын диярлек төрмә һәм колонияләрдә үткәргән троцкийчы Карл Аврамович Обруцкий суза. Тавышы көчле түгел, әмма үзенчәлекле тембры, тирән сагышы белән иң мөкләнгән күңелне дә кузгатырлык аның. Колония тормышы ирektәге кешеләр өчен сәер, караңгы, чит-ят, үзенә аерым серле бер дөнья. Фаҗигале дөнья. Кеше анда үткәненә битараф кала, киләчәгенә үтеп керергә, аңа күз ташларга тырыша. Тоткын күзаллаулар, гоман кылулар, өмет һәм хыяллар дөньясында яши. Ә хыял канат җәйгән җирдә иҗат киң колач ала. Иҗатка беркайда да киртәләр юк. Тоткыннарның ирektәге кешеләрнекеннән аерымлыклы үз иҗатлары — бай фольклорлары бар. Бер хәзинәгә җыелса, туплана иде ул авыз иҗаты! Еллар үткәч, күпме кабатланмас, гүзәл әсәрләрнең эзсез юкка чыгулары мөмкин. Тоткыннарның күбесе түзә алмаслык колония шартларында да кешелекләрен югалтмыйлар, сагышлану, сыкрау, сыктау белән бергә ачы итеп көлә дә, кирәге чыкса шаярта, күңел ача да беләләр. Мин тормышка килдем, яшим дип яшәгән кешегә берни дә комачау-киртә булырга тиеш түгел. Кешене кеше иткән нәрсә — омтылыш, өмет, хыял һәм тырышлык. Үз-үзен хөрмәт иткән адәм башкаларны да хөрмәт итә, бүгенендә үк иртәгәсе белән дә яши, берсекөненең дә якты булып туасына ышанып, тенлекләрдә дә өметен өзми.

Карл Аврамович беркем белән дә бәхәскә керми, җиңел аралаша торган кеше. Палатада аның йә бер авыру, йә икенче авыру белән сөйләшеп утырганын күрәсең. Ул, ара-тирә сүзләреннән һәм көйләреннән сагыш-хәсрәт ташып торган җырлар җырласа да, борынын салындырып ах-вах килеп бәргәләнүчеләрдән түгел. Обруцкий вагоннан төзелеш материаллары бушатканда аягына бүрәнә төшеп имгәнгән, култык таякларына таянып көчкә йөри. Кичә минем яныма килеп, сөйләшеп утырды.

— Үткәннәр беркайчан да кабатланмый. Иртәгәге көн бүгенгедән матуррак булып туа. Аккан суга рәттән ике кат керелми, беренче кергән су ин-

де агып киткән була. Берни дә мәңгелек түгел,— дип башлады ул сүзен.— Рәсәй хәзер иң авыр, иң шыксыз еллар кичерә. Бу хәл инде байтактан дәвам итә, һәр нәрсәнең чиге булган кебек, безнең караңгы чорның да ахыры килергә инде күп калмагандыр дим мин. Революцияне күпләр, борылыш башы, яңалык чыганагы, диләр. Минем өчен революция — тегермән. Аны ясаган, аңа табынган кешеләр орлыклар. Әмма кысыр орлыклар. Алар, җиргә чәчелеп шытым бирәсе урынга, революция тегермәненең ташына эләгеп юкка чыгалар. Революция үзен ясаучыларны аямый, юк итә...

Сөйкемсез саташу бугай бу. Әмма Карл Аврамовичның акылы әле зәгыйфьләнә башлаганга ошамый.

## 3

Олядан хат алдым. Ул бу хатында да, алдагы хатларындагы кебек үк, СССР Верховный Судына үземнең гаепсезгә утыруым турында тагын да язарга кушкан. Эһ, нахакка утыручы бер мин генә булсам икән... Яздым, берничә тапкыр яздым ич инде, ләкин ни файда чыкты ул язулардан? Янәдән язсам да, нәтиҗә шул ук булачак. Бу — көн кебек ачык. Минем әле шикаять язып ирек яулаган кешене моңарчы күргәнем юк колониядә.

Хатында Оля, институтта синең турыда сүз иярә сүз чыкса, күпләр сөйләшүне шундук өзәләр, дәвам итмиләр, дигән. Бу гаҗәп түгел. Үз иминлекләрен кайгыртучылар өчен мин йогышлы чирдән дә яманрак бит. Ә илебезне, хөкүмәтебезне, идеологиябезне күрәлмавымны, совет халкы өчен изге саналган барлык нәрсәләргә дошманлыгымны, хөкем карарында әйтелгәнчә, контрлыгымны ник үзем тоймыйм икән мин? Кулга алынганчы ничек булсам, үзгәрмәдем: һаман да шул ук, төрмә дә, хезмәт белән төзәтү колонияләре дә икенче кешегә әверелдермәделәр. Студент иптәшләремнең минем турыда сүз чыкканда аны куәтләмәүләре, шундук кисүләре күңелләрендә миңа нәфрәт саклаудан түгел, үзләренең дә таш капчыкка эләгүләреннән куркудан гына ул. Әйе, без нәкъ өркәк куяннар күк куркаклар. Теләгән нәрсәбезне сөйләргә, өстенә кинәт кенә кара күләгә төшкән кеше белән аралашырга, тыелган нәрсәне, аның нигә тыелганын белер өчен табып укырга, чит ил радиотапшыруларын тыңларга, фикерләребезне үзара уртаклашырга, хәтта Сталин рәсеме басылган газетаны да бөгәрләргә шүрлибез. Курку, дәвалауга үтә авыр бирешә торган эпидемия күк, безнең бөтен тормышыбызны биләгән. Бер-берләренә иң якын кешеләр дә теге яки бу нәрсә турында фикер алышканда уйлаганнарын ачыктан-ачык әйтергә базмыйлар. Без бөек рус язучысы Чеховның Беликовы сыман, адымыбыз саен як-ягыбызга каранабыз. Кешеләрдә бер-берләренә генә түгел, әйтергә оят, хәтта үз-үзләренә дә ышаныч юк. Ул гына да түгел, адым саен үзебезне үзебез алдыйбыз. Безнең бөтен тормышыбыз алдауга корылган. Сугышка кадәр, безнең самолетларыбыз иң тиз, иң биектә, иң еракка очалар, илебез егерме еллык икмәк запасы белән тәэмин ителгән, танкларыбызның броньлары бернинди снарядлар да тишә алмаслык калын, туган җиребезнең бер генә карышына да ятларны бастырмабыз, дошманны үз җирендә тукмарбыз, дип шапырынуларны мин бала чактан ук күп ишеттем. Ә асылда нәрсә килеп чыкты? Сугыш башында ук мактаулы самолетларыбызның күбесе җирдә килеш үк юк ителделәр, күккә күтәрелергә өлгергәннәре фашист самолетларыннан күпкә кайтыш булып чыктылар. «Егерме еллык икмәк запасыбыз» ике-өч айга да җитмәде, бетте, «куәтле» танкларыбыз сугыш кырында, кече калибрлы снаряд тисә дә, шырпы тартмалары кебек дөрләп янды. Дошман җиребезгә бер карыш кына түгел, тирән тылдагы Сталинградка кадәр үтте. Сугышка без бөтенләй әзерлексез керешкән булып чыктык. Әмма безне, дошман илебезгә искәрмәстән һөҗүм итте, уңышсызлыкларыбыз вакытлы хәл, фашист илбасарларның тиздән муеннарын сындырырбыз, дип юаттылар. Илне тәмам бөлдергән, күпме кешеләрнең гомерләрен кискән, күпме кешеләрне гарипләндергән, күпме хатыннарны тол иткән, күпме балаларны ятим калдырган сугыш исә тиз генә

бетмәде, дүрт ел дәвам итте. Әле дә ул һәр тармакта үзен сиздерә. Тик сугыш безне акылга утыртмады, хәзер дә элеккечә үк уйдырмалар артыннан уйдырмалар туа тора, аларны чынбарлыкка юравыбыз күпмегә барыр — алла белсен...

Ирektә калган үткәнем белән мине хәзер тик уйларым һәм Оля гына бәйли. Танышларым барысы да күптән йөз бордылар, алар өчен мин инде юк. Бу — табигый. Халык дошманы исәпләнәм бит. Үзен хөрмәт иткән кем шундый хәтәр бәндә белән алыш-бирешен дәвам итсен икән... Оляга да мин, арабызда элемтәнең өзелергә тиешлеген әйтеп, һәр хатымда яза торам. Ун ел срок азмы? Күп ул, бик күп. Тоткынлыктагы бер көн дә ел шикелле озын. Ирektәге кешенең тормышы чагыштырмача бәйсез: ул ни уйласа, шуны эшли, теләгән җиренә бара, теләгән кешесе белән очраша. Мине ун ел утырып чыкканнан соң да алда кимсетелүләр, төрле мәхрүмлекләр көтә. Кемнең дә үз язмышын минем язмышым белән бәйләп ялгышачагы көн кебек. Оля: «Син минем өчен баш авырттырма, минем үз акылым үземдә, сине шушы авыр вакытта ташласам, үземнән үзем җирәнәчәкмен. Синең турыңда уйлау, синең хәлеңне, тормышыңны җиңеләйтергә тырышу минем намус эшем, кешелек бурычым». — дип язды. Киләчәгемнең күләгәле булачагын, аның куаныч китермәячәген Оля ишетергә дә теләми. Ул, сине ирекkә чыгаруны үземә максат итеп куйдым, аңа ирешү өчен бернинди каршылыклар алдында да тукталып калмаячакмын, дип тәкрарлавын дәвам итә. Мин аңа, моңа сине тормышны белмәвең, дуамал үҗәтлегең котырта, син тормышыңның бу елларын миңа багышлап зая үткәргәнеңә соңыннан үкенәчәксең, дим. Юк, тыңламый.

## Унсигезенче бүлек

### 1

Көннәр тоткынлыкта да тукталып тормыйлар, үтәләр. Инде 1953 елга аяк бастык. Җәй көне эсседән, яз һәм көз айларында яңгырлардан, юештән, пычрактан, кыш кергәч салкыннардан зарланабыз. Эссегә түзеп була, яңгырларга, юешкә, пычракка күнегелә, ә менә үзәккә үтә торган Себер салкыннарына тәкать җитми. Башыбыздагы юка бүрекнең исеме генә бүрек, аның аша төнлә йолдызлар санарлык, өстебездәге сырмабыз исимме-исмимме дип икеләнеп торган иренчәк җилне дә тәнгә үткәрә, автомобиль покрышкасыннан әтмәләнгән «унталарыбыз» филгә ярарлык зурлар, аларның һәркайсына бер аяк урынына өч аяк сыярлык. Өстәвенә алар таш шикелле каты, юешләнгәндә кайнар мичтә атналар буе ятсалар да кибәрлек түгел. Куллардагы бияләйләрнең дә исемнәре генә, алар беренче киган көнне үк тетелеп аламаланалар. Кыскасы, кышкы салкыннар — Себер колонияләрендәге тоткыннар өчен авыр газап та, котылгысыз каза да, җәза да. Дөрес, зәмһәрир салкыннардан безне эш вакытында учаклар саклый. Аларны промплощадкага бару белән берничә урында тергезәбез дә шыкырайган саен килеп шунда җылынабыз. Утынга аптырарлык түгел, ачык вагоннарда көн саен бер дигән төзү материаллары килеп тора, калын идән такталары, шыңгырдап торган ишек, тәрәзә борыслары, авыр имән ишекләр, ырмауланган такталар кайчан теләсәң, шул чакта учактагы утка азык булалар, беркем бер сүз әйтми. Файдаланылган опалубка (кыса) такталары да ягам дисәң, кул астында гына, тик ул такталар яңа төзү материаллары кебек коры түгел, бетон дымы сеңгәнгә, учакка салу белән дөрләп кабынмыйлар, шуңа аларны ягып азапланмыйбыз. Безгә һәр минут кадерле. Учак җылысыннан ике-өч адым гына китәсең, салкын үзен шундук сиздерә, аяк астындагы кар ачулы сукрангандай шыгырдый башлый, суык яңа гына җылыга рәхәтләнгән бит-кулларны кабат өтә, авыз-борыннан мул булып бу бөркелә. Як-ягыңа карансаң, әйләнә-тирәнең күксел томанга өретелгәнен күрәсең. Без сала торган яңа

шәһәр тирәсендәге урман кыш көне, гүя, акка төренә, сихерләнә, ул тирән йокыга тала сыман, аннан берниндн тавыш-тын ишетелми. Эшкә баргач, атлаган саен кар шыгырдавы күңелгә шом сала. Бригадабыз, салкын дип, кул кушырып утырмый, булачак театр нигезенә бетон коя. Кышын салган бетонның рәте булмастыр шикелле. Әмма прорабыбыз — ул иректә чакта тәзүче инженер булган,— кем белән сөйләшкәндә дә «слушай»сыз сүз катмаучы әрмән Халаф Балаян: «Слушай, суыкка игътибар итмәгез, электродлар бетонны җылытып туңарга бирмиләр, кайгырмагыз».— ди. Салынган бетонга шундук электродлар кадалып, алюмин чыбыклар белән бер-берләренә тоташтырылалар да аларга ток җибәрелә. Аннары бетонның өсте 25—30 сантиметр калынлыгындагы тун-пычкы чүбе белән каплана.

Кич суыкта шакыраеп эштән кайткач, бригадабыз вахта капкасыннан керергә генә өлгерде, нарядчик Змей бригадирыбызга: «Зэк Кадыйровны опер котә, аны хәзер үк оператив бүлеккә җибәр»,— диде.

Бригададаш иптәшләрем миңа кызганулы караш ташладылар, оперга тикмәгә чакырмыйлар. Анда дәшелгән кешене йә берәрсе нахакка чаккан була, йә юртаны тентегәндә аның сакларга ярамаган нинди дер нәрсәсе табыла, шуның өчен җәза бирергә дәшәләр, йә опер катына чакыртылган бәндә иптәшләрен чагучы стукач була. Мин, тумбочкамда яки матрацымнан нәрсә таптылар икән, дип борчылдым. Бригадирыбыз:

— Кадыйров, сине кум сагынган, тиз йөгер янына,— диде.

Тоткыннар оперуполномоченныйны яратмыйлар, аны мыскыллап мәрхәмәтсезлекләре, кансызлыклары, үчлеклелекләре, зэкларны бөтенләй кешегә санамаулары белән аерылып торалар. Оперуполномоченный тоткынны теләсә кайчан кимсетә, уена нинди гаеп килсә, тоткынга шуны яга ала. Шуңа күрә зэклар оперуполномоченныйның күзенә мөмкин кадәр азрак чалынырга тырышалар. Моңарчы кумга чакырылганым булмаганга, мин аның кабинетының кайда икәнен дә белми идем. Шуны сорап вахта янындагы бер солдатка мөрәҗәгать иттем.

— Оператив бүлекнең кайда икәнен белмисең? Вәт тинтәк,— диде ул.— Күрәсеңме әнә теге карсак бинаны? Шуның аргы башыннан кергәч, сул яктагы икенче ишек — оперныкы.

Солдат күрсәткән бинадагы үземә кирәкле ишекне шакып, бүлмәгә үттем. Өстәл артында газета укып утырган яшь кенә өлкән лейтенант, мин кергәч газетасыннан аерылып, башын күтәрде.

— Сез миңамы?

— Белмим, мине оперуполномоченный чакырды, диделәр.

— Димәк, мин чакырткан булам. Фамилиягез?

— Кадыйров.

— Кулга алынганчы студент идегез, шулаймы?

— Әйе.

Өлкән лейтенант, дусларча елмаеп, миңа текәлде. Башымнан, каян белә ул минем студент икәнемне, дигән ахмак уй узды. Ник елмая, нәрсә кирәк аңа миннән? Нигә чакыруын әйтсен дә эшен бетерсен тизрәк. Елмая, димәк, йомшак җәеп катыга утыртудыр нияте. Болай үзе кансыз кешегә бөтенләй охшамый да кебек...

Өлкән лейтенант урыныннан торып, өстәле алдына чыкты.

— Танышыйк, Кадыйров, мин дә студент. Фамилиям — Поляков. Исемем һәм әтиемнең исеме — Гогольнеке кебек, Николай Васильевич, бер ишетүдә истә кала, онытылмый. Иркутск университетында читтән торып укыйм, инде икенче курста. Аралашканда мине просто Коля дип атагыз. Оперлык эшемне, дөресен әйтәм, җенем сөйми. Никтер куркалар миннән. Менә сез дә кергәннән бирле каршымда калтыранып торасыз.

— Мин сездән куркып калтыранмыйм, эштә оясыз эт шикелле туңдым...

— Әнә мичкә аркагызны терәп утырыгыз, хәзер чәй әзерлим, чәй эчәрбез, җылынырсыз.

— Рәхмәт, мин чәйләп утырмам монда, нигә чакыртуыгызны әйтегез дә китәрмен. Өс-башымны киптерәсем бар, иртәгә тагын эшкә барасы, көне буе бетон коеп нык ук арылды, ял итәргә кирәк.

Опер иреннәрен чалыштырып көлеп куйды.

— Әгәр иртәгә сезне эшкә җибәрмәсәм нәрсә диярсез? Иртәгә дә, бер секөнгә дә, бер атнага да, күбрәккә дә, ә? Ышанмыйсызмы?

Мин иңнәремне җыердым.

— Эшкә җибәрмәслек нинди гаебем бар, бәлки әйтерсез, гражданин өлкән лейтенант?

Оперга официаль мөрәҗәгатем ошамады ахры, йөзен чытты.

— Бер гаебегез дә юк, тышта суык, сез туңасыз, просто хәлегезгә кермәкче булам.

Әңгәмәбез мондый юнәлеш алгач, мин ни уйларга белмәдем.

— Рәхмәт сезгә. Ләкин миңа тышта салкын дип эшләми ятырга ярамый. Бердән, эшләмәсәм зачетлардан мәхрүм калам, икенчедән, кесәмдә бер тиен дә акчам булмый.

— Эшләми дә зачетларыгыз барса, өстәвенә акча да түләнсә, нәрсә әйтерсез?

— Миңа эшләми килгән зачетлар да, тир түкми алынган акча да кирәкми, гражданин өлкән лейтенант.

— Гражданин өлкән лейтенант, гражданин өлкән лейтенант,— дип үчекләде опер мине,— әйттем ич сезгә, мине просто Коля дип атагыз.

— Мин сезгә әдәпсезлек күрсәтә алмыйм, гражданин өлкән лейтенант, сез колониядә барлык минем кебек зэкларның турыдан-туры начальнигы, мин — халык дошманы, тоткын.

— Халык дошманы! Америка ачтыгыз, харап!.. Беләм мин сезнең нинди халык дошманнары икәнегезне. Күбегез нахакка утыра. Заманы шундый, кендектән югары сикерә алмыйсың. Сүзне бу турыда артык дәвам итмик. Мин сезне монда ни өчен чакырттым дисезме? Уңайсыз булса да әйтим, контроль эшләрем шактый бөялде минем, шуларның кайберләрен эшләргә булышмассызмы диган идем...

Мин җавап бирергә ашыкмадым, утенечен кире каксам, үземне нәрсә көткәнен яхшы белә идем. Какмасам, ул контроль эшләрне кайда, кайчан эшләргә икәне башыма килмәде.

— Нинди факультетта укыйсыз соң сез?

— Сезнең кебек үк тарих-филология факультетында. Шуңа сезгә мөрәҗәгать итәм дә.

— Контроль эшләрегезнең темалары нинди, бирегез карыйм әле?

— Монда түгел алар, өйдә. Риза булсагыз, бөтен кирәкле материалларны иртәгә алып килермен. Сез эшкә бармассыз иртәгә, монда сәгать көндезге унберләрдән соң керерсез, килештекме шулай?

— Миңа сезнең тирәдә чуалу зэклардан уңайсыз, гражданин өлкән лейтенант. Контроль эшләрегезне үтәргә каршы түгел мин, тик аларны кайда эшләрмен, белмим.

— Ярар, алайса, минем тирәдә буталмассыз, КВЧда[1] утырырсыз.

— Булды гына, иртәгә мин сәгать 11 дә шунда керермен. Бүген миңа китәргә рөхсәт итегез?..

— Минем белән чәй эчмисезме?

— Юк, рәхмәт. Хушыгыз, тыныч йокы сезгә.

## Унтугызынчы бүлек

### 1

Иртән промплощадкага бардык кына, янибызга ирекән кереп эшләүче электрик Василий Тузов килде. Утыз биш-кырык яшьләрдәге сүз тыңлаучан бу ыхтымат кеше, булган акчабызга, сорасак—папирос, тәмәке, чәй, шырпы,

[1] КВЧ — Культура-тәрбия бүлеге.

кәгазь, конверт, карандаш кебек нәрсәләр алып керә, язган хатларыбызны өенә кайтканда юл уңаенда почта тартмасына төшерә иде.

— Сезгә күңелсез яңалык әйтергә килдем, егетләр, бәлки үзегез дә ишеткәнсез инде, радиодан бүген бөек юлбашчыбыз Иосиф Виссарионович Сталинның кинәт авырганын хәбәр иттеләр,— диде ул, беребезгә дә карамыйча.

Бу хәбәр күбебезгә ток суккандай тәэсир итте. Тузовны шундук сырып алдык:

— Нинди авыру икәнен әйттеләрме?

— Кайчан авырый башлады диделәр?

— Сорауларыгызга анык җавап бирә алмыйм, егетләр, ул күңелсез хәбәрне мин үтә дулкынланып, йокылы-уяулы кеше кебек тыңладым. Шуныны ачык әйтәм, аңына килми, температурасы башта югары иде, инде стабильләшүгә якынайды, диделәр.

— Ул үлсә, илне кем җитәкләр, аны алыштырырдай кеше юк бит, — диде бригадирыбыз, үзалдына сөйләнгәндәй.

— Чирнең нәрсә икәнен, аллага шөкер, үзенә дә татыр вакыт җиткән канәчкечкә,— диде астма авыруыннан җәфаланучы белорус Стась Коляда.

— Авыргач, дөмексен иде инде ул тизрәк, бәлки безнең тормышта да уңай якка үзгәреш булыр иде,— диде әзәрбәйҗанлы Аббас Гусейнов.

— Юк, тиз генә дөмекмәсен, җан бирә алмый җәфалансын иде ул агач даһи. Без дүрт ел буена фашистларда әсирлектә интектек, монда кайткач менә ул интектерә. Бездә әсир төшүчеләр юк, хыянәтчеләр генә бар, имеш,— диде пермяк Валерий Мухин, ачу белән.

Сталинны мин үзебез кебек гади кеше итеп түгел, ниндидер гадәттән тыш зат итеп күзалларга күнеккәнгә күрә аның авырып аяктан егылуына, аңын югалтуына ышанасым килмәде. Сталин һәм авыру. Бу — акылга сыймас нәрсә! Сталин — даһи, ул ниндидер чиргә бирешергә тиеш түгел, электрик Тузовның төшенә генә кергәндер аның чирләве. Алай дисәң, Ленин да даһи бит, әмма үлгән. Дөрес, аңа эсерка Фанни Каплан агулы пулялар белән аткан, ул шуннан мантый алмаган. Сталин үлмәс, авыруыннан савыгыр, хәзер Ленин заманындагы хорти медицина түгел, гигант адымнар белән алга киткән, күрелмәгән могҗизалар тудырырга сәләтле медицина. Авыруы куркыныч булса да, иптәш Сталинның тереләчәге бәхәссез.

Әмма минем фаразым акланмады. Ике көн үткәч, Сталин дөньядан китте, дип хәбәр иттеләр. Бу тетрәткеч яңалыкны колониядә төрле кеше төрлечә кабул итте. Күпләр Сталинны югалтуга чын-чыннан кайгырып кайнар яшь түктеләр, аның үлүенә чиксез шатланучылар да, бөтенләй битараф калучылар да аз булмады.

— Үлгәч. Мыекның бер яхшылыгы тиде — ял иттерә,— дип көлде диңгезче Терещенко.

— Егетләр, үлгән кешене хурлау яхшы түгел, ул бит әле хәтта җирләнмәгән дә. Ә сез аны пычракка аунатасыз, акылыгызга килегез,— дип тыйды бригадирыбыз халыклар атасына сүз тидерүчеләрне.

— Үлгән кешегә тел тидермиләр, дөрес. Әйтегез әле, бугор, ә Сталин кеше идеме соң?..

— Сталин — шәхес. Акыл сатмыйк, аңа хөкем чыгару безнең эш түгел.

## 2

Сталин үлгәч, Терещенконың гына түгел, колониядәге башка тоткыннарның да амнистия көтүләре акланды. Югары эшелондагы җитәкчеләр аны бөек даһи илне «ятим калдыргач» ук эшләмәделәр, шактый вакытка кичектерделәр. Әмма зәкләр дүрт күз белән көткән ул амнистия политик тоткыннарга кагылмады, аларны читләтеп үтте.

Амнистия колонияләрне шактый бушатты. Ул, алда әйткәнемчә, безгә — политик тоткыннарга гына бернәрсә дә бирмәде. Без Сталин исән вакытта да халык дошманнары санала идек, ул үлгәч тә кимсетелү һәм хур-

лыклы кушаматтан арынмадык. Терещенко амнистиянең үзенә кагылмавына бик нык пошынды. Мин үзем Сталинның үлеме илгә нинидер үзгәреш китерәсен баштан ук көтмәгән идем, шуңа күрә хөкүмәтнең безгә битараф калуына пошынмадым.

Көннәр бер-бер артлы үтә торды. Илебезнең төрле почмакларыннан колониягә килгән хатларда амнистия буенча иреккә чыккан «егетләрнең», элекке һөнәрләрен яңартып, киң колач белән эш итүләрен — талаулар, көчләүләр, үтерүләр белән халыкны зар елатуларын яза тордылар. Амнистиягә кадәр чәнечкеле тимерчыбык киртәләр артындагы колонияләрдә ярамас шөгыльләреннән тыелып яшәгән бозык затлар дүрт яклары кыйблага әверелгәч, «заяга» үткән көннәренең үчен бише белән генә түгел, уны белән кайтарырга керешәләр. Моны мин үз күзләрем белән күрмәдем, ишеткәнемне язам. Ә менә безнең колония начальнигы подполковник Мятлов һәм аның гаиләсе белән булган хәлне, үзем күрмәсәм дә, ул чыннан да шулай булды дип кистереп әйтә алам. Ул хәлне бөтен Китойлаг чирканып сөйләде. Мятлов үчлекле, дорфа һәм чикләнгән кеше иде. Аның кәефе юк чакта зонада күзенә ташлансаң, ул, гаепләме син, түгелме, җәза бирми калмый иде. Кышын йә кар көрәргә куша, йә зона эчен берничә тапкыр йөгертеп әйләндерә, йә карга яткырып үрмәләтә, яисә метрлы авыр утын агачларын бер урыннан икенче урынга ташырга куша. Колониядәге зэклар гына түгел, безне саклаучы солдатлар да өнәмиләр иде Мятловны. Ул зэкларны үзе җәзаламый, солдатлардан җәзалата, солдатлар ул әйткәнне җиренә җиткереп үтәмәсәләр, аларны гауптвахтага озаттыра иде.

Амнистиягә эләгеп иреккә чыккан дүрт рецидивист бер көнне колония начальнигы Мятловның өенә төшке ашка кайтканын көтеп торалар да, аның янына «саубуллашырга» керәләр. Алар кергәндә подполковник өендә үзе генә түгел, хатыны һәм унҗиде яшьлек кызы белән була. «Саубуллашырга керүчеләр» Мятловның күз алдында аның хатыны белән кызын чиратлашып көчлиләр. Аннары подполковникның үзен идәнгә сузып салып авызына шакмак кыстыралар һәм аны унитаз итеп файдаланалар...

Зэкларны җене сөймәгән колония башлыгы, бу вәхшилекне күтәрә алмады, ашыгыч рәвештә эшеннән чыгып, хатыны белән кызын ияртеп каядыр китеп барды, диделәр. Мятловны майор Ступнов дигән кеше алмашты. Яңа начальник өчен колониядә зэклар әллә бар, әллә юк иде. Эшкә йөриләрме алар? Йөриләр. Алар ничек яшиләр, ничек тукланалар, нәрсә белән кызыксыналар — майорның анда гаме юк иде.

## Егерменче бүлек

### 1

Олядан хат килде. Ул миңа ирек юллап Мәскәүгә, Никита Сергеевич Хрущев янына баруын язган. Эшенне яңабаштан караячаклар, көтәм, тиздән Казанга кайтачаксың, дигән. Эчкерсез сантыйлык! Дәүләт башлыгының мазасы мин генә анда. Буш вакытында нишләргә белмичә, кичәге көнгә кабат юл ярырга маташкан тинтәк төсле, минем хакка әллә кемнәрне бимазалый Оля. Тынычлан, синең алдыңа куйган максатың чебеннең бүлмәдән тәрәзә өлгесен ватып тышка чыгарга маташуы белән бер бит, дип аңа хатым саен тукыйм. Тыңламый, үзенекен итә. Мәскәүгә барган, эшемне яңабаштан караячаклар, имеш. Илебездәге бихисап тоткыннардан һәммәсенең якыннары Мәскәүгә барып, Хрущевның алтын вакытын ала башласалар, нәрсә булыр. Башында аз гына акылы бар кеше шәхси үтенече белән дәүләт җитәкчесен борчыймы? Хрущев Җир шарының алтыдан бер өлешен биләгән илебез Советлар Союзы белән идарә итә, аның исәпсез-хисапсыз лагерь-колонияләрдә җәфаланучы аерым кешеләрнең язмышларын тегеяки бу якка хәл итәргә вакыты бармы? Моның өчен Никита Сергеевичка миллионга, бер генә мил-

лионга түгел, әллә ничә миллионга ярылырга кирәк булыр иде. Оля аны ничек күрә һәм ничек сөйләшә алды икән? Бәлки, бу аның мине юату өчен юрамал уйлап чыгарган уйдырмасыдыр? Алай дисәң, Никита Сергеевич белән сөйләшкәннән соң мин сине инде иреккә чыкканга санап тизрәк янына барырга омтылдым, тик Мәскәүдән соң ерак Себерне дә урап кайтырга акчам юклыгы гына тоткарлады, дигән. Дуамал, чамадан тыш дуамал кыз Оля! Алдын-артын исәпләми, башына нинди уй килсә, аны тизрәк эшкә ашырырга ашыга. Үзенең ташып торган энергиясен күбрәк тиктомалга сарыф итүен ялгышып кына булса да уйлаганы бармы икән аның? Шагыйрь Некрасов әйтмешли: «В беде — не сробеет, спасет, коня на скаку остановит, в горящую избу войдет». Минем өчен серле табышмак ул. Инде менә дүрт ел язышабыз, тик әле һаман тиешенчә аңлый алмыйм үзен. Минем, Оля көч куймаса да, срогым инде ике елдан аз гына артык. Алда, зачетлар бетерелмәсә, тоткынлыктагы тормышым, күп дигәндә, җиде-сигез ай кала дигән сүз бу. Шул җиде-сигез айлык җәфалanулардан тизрәк арыну, алардан иртәрәк котылу өчен югарыдагы таш маңгайлы түрәләргә мөрәҗәгать итеп, мин гаепсез, зинһар, мине иреккә чыгарыгыз, дип түбәнсенергә, мескенләнергәме? Әшең, хәлең, ил, партия, халык алдында тузан бөртеге кадәр дә гаебең юклыгы турында аларга сөйләү күктә йөзгән ак болытка: «Зинһар, мине тоткынлыктан арала»,— дип инәлү белән бер бит. Кайдадыр гади затларның буйлары гына түгел, уйлары да ирешмәс югарыда безне кешегә санаучылар бармы икән? Оляны, ашарга утырган берәүнең тирәсендә очып, эшен пошырган чебенне иренеп кенә селтәнеп куган шикелле, интәшегезнең эше яңабаштан каралыр, дип шатландырганнар. Аның шуңа башы күккә тигән. Ул мине дә шул коры вәгъдә белән сөендерергә тырыша. Ач чыпчыкка ашарга бөртекләр сибәсе урында, мул итеп әрбә аударып, шул туклыксыз кибәк белән сыйланырга кыстау кебек ич бу, бүтән түгел.

Олядан хат алуымның өченче көнендә мине эшкә җибәрмәделәр, зонада калдырдылар. Колониядәге бригадалар вахтадан чыгып беткәч, нарядчик:

— Хәзер юртагызга кайтып урын-җир әйберләреңне каптеркага тапшыр да, сәгать сигез тулуга шәхси дирбияларың белән бирегә кил,— диде.

Мине каядыр күчерергә җыеналар ахры, дип уйлап, яшәгән юртабызга кайттым. Тормышымда булачак үзгәрешкә битараф идем, борчылмадым да, шатланмадым да. Бәлки, Казанга озатачаклардыр, Оля хатында, эшең яңабаштан каралачак, дип язган бит. Казанга кайтасы булса, юл озын, хаҗәте чыгар, артык булмаслар.

Әйтелгән вакытка Оляның хатлары, йөзләгән шахмат этюдлары, чүп-чар кәгазьләр саклангән чемоданыма бер пар резина итекләр салып вахта янына килдем. Мин килгәндә анда беркем дә юк иде, иртәрәк килдем ахры, дип читкәрәк китеп чемоданыма утырдым. Бераздан вахтаның үтәли йөреnмәле коридоры ишегеннән кулына юка гына папка тотып оперуполномоченный Николай Васильевич Поляков чыкты. Мин аягүрә бастым.

— Сәлам,— диде ул миңа, дустанә елмаеп.— Шатлан, туган. Казаныңа озатабыз сине. СССР Верховный Суды хөкем карарыңны юкка чыгарган. Казанлылар эшеңне яңабаштан тикшерергә сине анда ашыгыч кайтаруны таләп итәләр.

— Беләсездер, Козьма Прутков, акрынлап ашык, дигән. Ашыгу шайтан фигыле бит, Николай Васильевич.

— Килешәм, дөрес әйтәсең. Контроль эшләр өчен сиңа зур рәхмәт, Кадыйров. Алар өчен мин бишлеләр алдым, шәп булыштың, молодец! Хезмәтең өчен үзеңне бәхилләтә алмадым, үпкәләмә. Эшем тавык та чүпләп бетермәслек күп, өлгерә алмадым. Иреккә чыга калсаң, хат яз, котәрмен. Сине хәзер станциягә озатып куярлар. Берәр үтенечең булса, әйт, үтәрмен.

— Бернинди үтенечем дә юк, рәхмәт. Мошиан китәсемне нигә кичә үк әйтмәдегез, бүгенгә калдырдыгыз, Николай Васильевич?

— Моннан китәсегезне кичә яки бүген белүегезнең ни әһәмияте бар, барыбер түгелмени?

— Түгел, хөрмәтле өлкән лейтенант. Мин менә бригададашларым белән саубуллашмый китәм. Бу бик мөһим. Әйтерсең, мондагы семьяма хыянәт итәм.

— Бер төн булса да тынычлап йокласын, йолкынмасын, дидем мин сине. Семьям дисең, бригададаш иптәшләрең белән нинди уртаклыгың бар иде, аларның үз кыйблалары, синең үз кыйблаң бит.

— Кыйблаларыбыз төрле, әмма кояшыбыз уртак иде, Николай Васильевич. Мин бригададашларым белән өч ел буе иңгә-иң торып эшләдем, бер түбә астында бер үк бозык, тынчу һаваны суладым, алар төсле үк зэк исәпләндем.

— Гафу ит, хаталык эшләгәнмен, гаебемне таныйм. Үтенәм, эшегезнең ни белән бетүен хәбәр итегез миңа. Килештекме?

— Күз күрер.

Без кул кысышып аерылыштык.

## 2

Мине станциягә алып килгән йөк машинасы ерак тупикта торган ялгыз вагон янында туктады. Вагон эченнән шундук өч солдат чыкты. Алар мине колониядән алып килгән конвоирдан башта документларымны, аннары үземне кабул итеп алдылар. Әйләнә-тирәмә күз салырга да өлгермәдем, ашыктырып вагонга керттеләр. Күңелне юкка күрәзә димиләр, резина итекләрне бик урынлы алганмын, тамбурны узгач, Столыпин вагонына эләгүемне абайладым. Вагон коридорына кергәч, миңа тагылып диярлек атлаган табак битле, кысык күзле казах тибындагы солдат:

— Чемоданыңны шунда керт,— диде җиңемнән сул якка тартып.

Анда ишеге яртылаш ачык купе икән, кердем, солдат та миңа иярде.

— Кесәләреңдә нәрсәләрең бар, чыгар.

— Бернием дә юк.

Табак бит әйткәнемә ышанмады, барлык кесәләремне кулын тыгып тикшерде, өстемдәге киемнәремне капшап чыкты.

— Ботинкаларыңны сал.

Салдым. Ботинкаларымны тикшерде.

— Чемоданыңны ач.

Ачтым. Солдат андагы хатларны, кәгазьләрне өстән-өстән генә тикшергәч, чемоданны ябарга кушты. Мин ботинкаларымны салып, аякларыма резина итекләр киеп алдым. Казах аяк киемнәремне алыштыруыма сүз әйтмәде, ул котсыз итекләрне нигә кигәнеңне беләм дигән төсле саран гына елмайды. Аннары мине яңадан коридорга алып чыгып, вагонның аргы башына алып китте. Анда барганда мин ал яклары калын тимер рәшәткә белән ныгытылган купе-читлекләрдә берәүне дә күрмәдем. Башыма бөтен вагонга мин берүзем микәнни дигән күңелсез уй килде. Юк, мин үзем генә түгел, иң аргы купе-читлектә бер кеше бар булып чыкты. Эт башы кадәр йозакны ачып, солдат мине купе-читлеккә кертеп бикләде. Андагы бәндә миңа керү белән:

— Танышыйк. Сергей Александрович Жирнаков. Рәссам. Соль-Илецкидан,— дип кулын сузды.

Таныштык.

— Алланың рәхмәте, бик үк бәхетсез түгел икәнмен әле, менә сез кердегез, икәү булдык. Юкса инде тәүлек буена ялгызым үземне тар кабердә, тимер табут эчендә итеп күзаллый башлаган идем,— дип куанды купедашым.— Күрәсез, шаккаткыч уңайлыклар белән Казахстанга сөргенгә кайтаралар мине. Сез дә минем кебек үк сөргенгә юл тотасызмы?

— Юк, минем эшем яңабаштан каралачак, шуңа кайтаралар.

— Алай. Статьягыз нинди?

— Элек 58-10 ның икенче матдәсе иде.

— Күпме утырган идегез инде?

— Дүрт ел ярым.

— Мин унны утырдым. Минем дә статьям 58-10, тик аның беренче матдәсе. Дәүләт иминлеге министрлыгы вәкилләре теле белән әйтсәк, башымдагы шөрепләремне тутык басканы өчен утырдым. Тикшерү вакытында да, судта да, син дошман тегермәненә су коеп, үзең белән аралашкан кешеләрнең миләрен чүпләгәнсең, диделәр.

Без купе-читлегебезнең урта сәндерәсенә урнаштык. Читлектәшем сүзчән кеше икән, тынлыйммы аны, тынламыйммы, сөйләвен белде.

— Сез минем ни өчен утыруымны әйткәч, өнәп бетермәдегез кебек,— дип башлады ул сүзен.— Минем фикерләвемне дингә, аллага ышанмаучы кешегә аңлавы да, кабул итүе дә читен. Дин, кешенең җаны бар, дип өйрәтә. Кешенең җисеме үлгәндә аның җаны үлми, исән кала. Җан — изге, ул, мәңгелек. Үлгән кешенең җаны күк бушлыгындагы фәрештәләр арасында кая барырга белми каңгырап йөрми, яңа җирлеккә — ана карынынннан дөньяга килгән балага кайта. Бу чын дөрес хәл. Сугыштан соң бер фәнни-популяр журналда Селезиядәге кечкенә генә немец шәһәрендә бер рус солдатының шул шәһәрдәге башкаларыннан һич аермасы булмаган гади генә бер йорт алдында сихерләнгәндәй туктап калуын яздылар. Солдат тылсым көченә буйсынгандай як-ягына карана, алдындагы йорттан, магнит белән тартылгандай, йә арткарак чигенә, йә аңа якынрак килә. Үзе, минем монда булганым бар бит, бар, дип кабатлый. Тик бу йортның фасадында элек күргәндә ике генә багана иде, хәзер дүрт, киң баскычның ике ягында нәрсәләрдер җитми, тик нәрсәләр җитмәүне хәтерли генә алмыйм, дип үз алдына сөйләнә-сөйләнә йорт эченә үтә. Анда кергәч йорт хуҗасын эзләп табып, фасадагыздагы колонналарны сез кайчан арттырдыгыз, баскычыгызның як-якларыннан да нәрсәләрнедер алгансыз, йортыгыз алдында алар юк, ди. Йортыбыз фасадындагы таш баганалар, бабам заманында, мин туганчы ук өстәлгәннәр, дип җавап бирә солдатка хуҗа. Баскыч читендәге арсланнарны, фасадта баганалар арткач, йортның гомуми күренешен бозып торганы, урамның тулы ансамбленә ярашмаганы өчен башка җиргә күчергәннәр. Аннары ул солдаттан, сез минем йортымның иске фотосын кайда күргән идегез, дип сорый. Мин фотода түгел, натурада күргәнем бар йортыгызны, дип җавап кайтара немецка солдат. Сиңа ничә яшь, ди хуҗа. Егерме өч, ди солдат. Минем бабам үлгәнгә инде утыз елдан артык, бу йортны синең элек күрүең мөмкин түгел, ди немец. Әфәндем, мин йортыгызның эчке бүлмәләрен дә беләм. Әнә коридорыгызның сул ягындагы өченче ишек дүрт биек тәрәзәле, бизәкле эшләнгән борынгы каминлы бүлмәгә кертә, дип шаккатыра хуҗаны солдат.

— Немец белән рус солдаты нинди телдә сөйләшкәннәр?— дип бүлдем мин юлдашымны.

— Журналда ул турыда язылмаган иде, әйтә алмыйм. Бәлки солдат немецча белгәндер, ә немец русча аңлагандыр...

— Сез аны анык белмисез, димәк, бу бик мөһим бит.

— Аларның нинди телдә аңлаша алулары турындагы уй исемә дә килмәде минем.

— Ярар, алар нindидер уртак тел тапсыннар да ди. Мәсьәлә анда гына түгел. Сез башта ук, дингә, аллага ышанмаган кешегә минем фикерләүләремне кабул итүе кыен, дип кисәттегез. Әйе, яшермим, аңлавы авыр сезне. Концепциягезнең, мин сезнең фикерләүләрем диюегезне шулай үземчә атыйм, ничектер очлары очка ялганып ук бетми шикелле. Миңа сез гөнаһлыларны теге дөньяда тәмуг, гөнаһсызларны җәннәт көткәнен аңлатмасагыз да була. Тик менә тәмугта гөнаһлының нәрсәсе дәһшәтле утта янып, коточкыч җәфалар кичерә дә, җәннәткә эләккән гөнаһсызның анда нәрсәсе рәхәт чигә, хозурлыклар кичерә — төшендерегез шуны. Үлгән кешенең җисеме туфракка әверелә, анысы бәрәүгә дә сер түгел, сез җанны мәңгелек, ул ана карынынннан дөньяга яңа килгән сабыйга күчә, дидегез. Монда да концепциягезнең очы-очка ялганмый бугай бит, ә?..

Юлдашым миңа үзе инанган нәрсәләрне яклап та, шик астына алып та тормады, турыдан-туры:

— Фикерләүләремнең сез шикләнгән өлешләрен мием тегермәнендә яңабаштан тартып он итәсен, аннары ул оннан туклыклы ипи пешерергә кирәклеген сез үзегез дә сизми гади генә итеп аңлаттыгыз миңа, рәхмәт,— диде, елмаеп.— Фикерләүләремне дәвам итимме?

— Ихтыярыгыз.

— Хәзер мин, кем әйткәндәй, пластинкамны алмашып, концепциямнең икенче өлешен бәян итәм. Атом төшенең электроннарга һәм протоннарга таркалу хасияте инде берәүгә дә сер түгел, аны елтырык борынлы балалар да белә булыр. Мин кеше организмы да триллионлаган атомнардан гыйбарәт дигән карашта торам. Табигый буларак, кеше организмындагы атомнар да электроннарга һәм протоннарга таркалалар. Алар безнең тәнебездә бик үзенчәлекле функцияләрне башкаралар. Әйтик, менә сез һәм мин. Без таныштык. Безнең танышуыбыз эзсез генә үтмәде, сезнең протоннарыгызның күпмеседер миңа, минем протоннарымның шул кадәресе үк сезгә күчте. Алар безнең геннарыбызның хәтер күзәнәкләренә урынлашты. Шулар аркасында алда сез мине исегездә саклarsыз, мин — сезне. Бу безнең күченгән протоннарыбызның үзебездә калган электроннары белән яңадан кушылырга омтылуларыннан килә. Шул нигездә кешеләр үзләренең кайдагыдыр якыннарына бәхетсезлек килүен, яки үзләренә шатлык йә борчылу киләсен алдан сизәләр. Кеше кинәт кенә тынычлыгын югалта, борчыла, үз-үзенә урын табалмый. Аннары берничә көннән хәбәр ала, ул тынычсызланып чыгырыннан чыкканда аның туганымы, үтә якын кешесеме дөньядан киткән була. Бу инде яшәүдән туктаган кешенең синдә саклана торган протоннары үзләренең электроннары һәлакәткә юлыкканга чамадан тыш ярсынуларыннан килә. Шуларның ярсынулары синдә борчылу тудыра. Сөйләгәнем сезгә аңлашыларак төшсен өчен тагын кабатлыйм, менә без сезнең белән таныштык һәм бер-беребез белән протоннарыбызны алмаштык. Алмашкан протоннарыбыз безгә, һич югында, бер тапкыр, бер-беребезне аз гына мизгелгә булса да искә төшерергә, хәтерләргә булышачаклар.

— Фикерләвегезнең бу өлешенең ниндидер дәрәҗәдә нигезе бар кебек,— дип сүз кыстырдым мин юлдашымның сөйләвенә.— әмма тынычсызлану һәм үз-үзенә урын тапмауларны электроннарга һәм протоннарга бәйләү бик примитив. Ә төш күрүне сез ничек аңлатасыз?

— Төш күрү тәндәге электроннар һәм протоннарның кеше йоклаганда да уяу калулары, аларның бал кортларының умартада калган күчтән аерылгандагы шикелле халәт кичерүләре турында сөйли. Шуңа күрә кешегә әллә нинди куркыныч төшләр керә...

Очраклы юлдашым Сергей Александрович Жирнаков үзенең фикерләүсаташуларын шулай Ангарскидан башлап Омскига кайтып җиткәнче сөйлисөйли саруымны кайнатты. Омскида безне аердылар. Купеда ялгызым гына калгач, Казанга кадәр араны үз-үземне кая куярга белмичә борчылып кайттым. «Хөкем карарыгыз СССР Верховный Суды тарафыннан юкка чыгарылган, сезне Казан эшегезне яңабаштан тикшерү өчен үзенә ашыгычлык белән кайтаруны таләп итә»,— диде колониядә кум мине зонадан станциягә озатканда. Сигез ай буена сузып тикшергәннәр иде бит инде. Тикшерүчем үзе уйлап чыгарган уйдырма «җинаятьләрем»нән кала, бүтән гаебем табылмаган иде. Минем эшемне кырык кат тикшерсәң дә бер үк нәтиҗә булачагын Мәскәүдә аңламадылар микәнни? Күпчелек беркетмәләргә кулым куелмаган, тагын ни җитми икән инде? Оляга шогыле юктан шогыль табып кычытмаган җирләрен кашу нигә кирәк иде, моның белән ул минем эшемне четрекләндереп, азатлыкка чыгу көнемне күпмегәдер артка чигермәсме? Эшемне яңабаштан тикшергәндә, миңа өелгән гаепләр барысы да уйдырма, аларның һәммәсе дә чынлыктан ерак дипоемә ышанучы булырмы? Һәй, эшем тикшерелде ни дә, тикшерелмәде ни, ирекка чыктым ни дә, чыкмадым ни, алда барыбер җүнле-башлы яшәү көтми мине. Маңгаема сугылган «халык дошманы» мөһере мәңгелек, ул беркайчан да юылмаячак. Гомерем фронтта киселгән булса, исән калган коралдаш иптәшләрем хәтерендә урын алыр идем ичмасам...

Ниһаять, Казанга кайтып җиттем. Кайтуымны монда көткәннәр ахры, поезд туктагач, ярты сәгать тә үтмәде, купе читлегемнең йозагын ачып, мине коридорга чыгардылар.
— Эчтә берниеңне дә онытмадыңмы?
— Юк, һәммә нәрсәмне алдым.
— Ә резина итекләрең кая?
— Артык кирәкләре юк аларның миңа, калсыннар, бәлки кемгәдер ярап куярлар.
Вагоннан чыкканда кулыма чемоданымны тоттырдылар. Тышта, вагон ишеге төбендә, мине бер сержант белән муенына автомат аскан солдат көткәннәр икән. Чемоданымны ачып, аякларыма ботинкаларымны кидем. Сержант, кулындагы дело-формулярны ачып, дикъкать белән карады да:
— Фамилияң, исемең, әтиең исеме, туган елың?—диде.
Әйттем.
— Әйдә, кулларыңны артка куеп як-ягыңа карамый миңа ияр.
Мин утырып кайткан вагонны станция читендәге почта складлары алдында калдырганнар иде, без иң кырыйдагы рельслар буеннан тимер юлны аркылыга кисеп үткән шоссега юнәлдек. Солдат, муенына аскан автоматын атарга әзер тотып, дүрт-биш адымга артка калып, безгә иярде.
Көн кичкә авышып килә, әйләнә-тирәдә беркем күренми, вокзал ягыннан маневр паровозының ара-тирә ялкау гына пошкырганы ишетелә.
Сагынылган Казан туфрагыннан әллә бераз үз аякларымда атлатырлармы дигән идем, булмады. Шоссега җиткәч, «кара козгын»ның ябык кузовына мендереп, караңгы тар шкафка бикләделәр. Күрепекле фикер иярәреннән кемдер, елгадагы бер үк суда ике тапкыр коенып булмый, дигән. Килешәм. Елгада ул ирешелмәслек эш. Ә менә «кара козгын» кузовындагы тар шкафларга ике генә түгел, бихисап тапкырлар кереп чыгу мөмкинлеген чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган лагерь-колонияләр зонасындагы һаваны сулаган тоткыннар үз тәҗрибәләрендә беләләр. Гадәләт «яратучы», чамадан тыш «тугры» һәм «илгәзәк» хокук органнары ул мөмкинлектән һәркемне файдаландырырга әзер торалар. Без, совет кешеләре, дөньяда чикләнмәгән хокуклар белән тәэмин ителгән иң бәхетле бәндәләр исәпләнәбез. Башка илләрдә безгә иш беркем юк. Хәреф таный башлау белән һәр адымыбызда бик тә гакыллы лозунглар, хикмәтле өндәүләр укый башлыйбыз. Алар чынлыкка туры киләләрме, әллә коры хыял җимешләре генәме, ул турыда уйлап баш катырмыйбыз. Безнең очен партия һәм аның зирәк юлбашчылары уйлый.
Тимер юл станциясеннән Дзержинский урамындагы Дәүләт иминлеге комитеты урнашкан бинаның ишегалдына кадәр араны «кара козгын» тиз үтте. Әрҗәдән төшереп, эчке тормәдәге ялгыз камераларның берсенә мине документ-фәлән күрсәтүемне, фамилияң, исемең, әтиең исеме кебек сорауларга җавап бирүемне таләп итми генә керттеләр. Бу мине гаҗәпләндермәде, киткән йортыма яңадан әйләнеп кайттым бит. Күңелдә һәр карыйны онытылмаслык эз уйган бу интегү урынында күзләремә сизелерлек үзгәрешләр ташланмады. Аның эченә уздыра торган топ ишегендәге «Чит кешеләргә керү тыела» дигән катгый язуның үзгәрешсез сакланганын күргәч, мондагы надзирательләр дә алмашынмаганнар, шулар уктыр, дип уйладым һәм ялгышмадым. Төрмә коридорында мин кайчандыр песнәккә охшаткан иң үчлекле, тоткыннарны җене сөйми торган явыз надзиратель хатын кизү иде. Аның белән мин баш кагып исәнләштем. Ул, чыраен җирәнүле чытып, ирешәрен борештереп, читкә борылды. Шунда, сез, апай, үзегезне һаман да түрә итеп саныйсыз икән әле, мин дә сезгә үземнең төшеп калганнардан түгеллегемне күрсәтермен, дип күңелемә беркеттем. Камерага керү белән асты-өскә әйләндерелгән табутны хәтерләткән, йозләгән кешеләргә ятак хезмәтен үтәп шомарып беткән топчанга аудым. Надзиратель хатын шундук ишектәге кормушка капкачын ачып:
— Ятарга ярамый, тор, йоре!—дип әмер бирде.
— Сезнең урыныгызда ятмыйм, борчылмагыз, үз урыным, тормыйм,—дидем.

— Торырсың, безнең монда теләсә кем теләсә ничек аунарга санаторий да, курорт та түгел.

— Карагыз әле, ябыгыз кормушканы, йокым килә, комачауламагыз.

— Мин хәзер үк төрмә начальнигын чакырып, аңа синең бездәге тәртипләргә буйсынмавыңны әйтәм, ул нишләтергә белер...

— Хет комитет председателенең үзен чакырыгыз, ул да могезле түгелдер, курыкмыйм. Сару кайнатмагыз, ябыгыз кормушканы.

— Соңгы кат кисәтәм, тор, киреләнүеңнең ахыры яхшыга булмас!..

— Шулаймы? Котымны алдыгыз тәки, үләм.— Капылт кына торып утырдым.— Кешечә әйткәнне аңлыйсызмы, китәсезме ишектән? Тәмам сагыз булдыгыз, туйдым сездән.— Үрелеп стенага беркетелгән өстәлчектән кружка алдым.— Кормушканы япмасагыз, шушы кружка белән чыраегызга бәрәм. Йә, өчкә кадәр саныйм: бер... ике... өч!

— Бандит!..— Кормушка капкачы шап итеп ябылды.

## Егерме беренче бүлек

### I

Язмышым мине тикшерүчем Горшенин белән тагын очраштырды. Бу юлы аның иңнәрендәге бер сызыклы тар капитан погоннары урынына ике сызыклы подполковник погоннары иде, уң түшендә — Кызыл Йолдыз ордены. Башыма ирексездән, әһә, болай тиз үскәч, аңа инде генерал булырга да күп калмаган икән дигән мыскыллы уй килде.

Мине Горшенин, элекке таныш булгангамы, киң елмаеп, ачык йөз белән каршылады, ишек катында Дәүләт иминлеге комитеты иләге аша үтүче кешеләр өчен идәнгә кузгатмаслык итеп беркетелгән махсус табуреткага түгел, өстәле каршындагы өч урындыкның берсенә утыртты. Әйтерсең, ул элек даими рәвештә кемнәргәдер ошарга, кемнәрнедер кабатларга тырышучы мин белгән кыланчык түгел, бөтенләй башка кешегә әверелгән иде. Гәүдәсендә салмаклык, олысымаклык. Хәрәкәтләрендә үзенә чамадан тыш ышанганлык кычкырып тора. Тышкы кабыгы алмашкан, ә хакыйкатькә мөнәсәбәте элеккечә калдымы, аллә анысы да үзгәрдеме икән?

— Йә, кәефләр ничек, Кадыйров? Казан сагындырдымы?

— Сезне иң кызыксындырган нәрсә шулар гынамы, Семен Андреевич?— дип, сорауга каршы сорау бирдем мин.

Подполковникның сипкелле чыраендагы кунакчыл елмаю һич булмагандай юкка чыкты.

— Очрашканда әйтелә торган дежур сүзләр алар, сүзне нәрсәдәндер башларга кирәк бит...

— Аңлашылды, рәхмәт. Мин, җүләр, аны чын-чынлап сорадыгыз дип уйладым тагын. Кәефемә килсәк, зарланмыйм, кәефем шәп. Казанны түгел, сезне сагындым мин, Семен Андреевич. Колониядә чакта анда дүрт күз белән гел сезне китерүләрен көттем. Ник дисезме? Урыныгыз монда түгел, күптән җинаятьчеләр арасында бит сезнең.

Тикшерүчем, олысымаклыгын онытып, миңа теге вакыттагы кебек сагаюлы текәлде.

— Күрәм, сез шактый остарып кайткансыз.

— Булыр, академия үттем бит, чынбарлык академиясен... — Әйтегез әле, ни өчен мин җинаятьчеләр арасында булырга тиеш?

— Шуны белмисезме? Әйтәм: фальсификацияләр әмәлләгәнегез өчен. Бернинди җинаять тә эшләмәгән һәм аны эшләргә дә уйламаган мине, шулай ук минем иште нахакка монда әләккән кешеләрнең гаепләрен фил кадәр итеп күрсәтеп, халык дошманнары ясаганыгыз өчен. Дәүләтебез алдындагы шундый «мөхтәрәм» хезмәтләрегез сезне инде әнә подполковник дәрәҗәсенә күтәргән һәм хәрби орденга лаек иткән. Ләкин куанмагыз моңа,

ул ялгышлык иртәме-соңмы төзәтелер, төзәтелми калмас. Әнә стенагыздагы әле кайчан гына эленеп торган иконагыз Берия портретын үзегез үк чыгарып чөйгәнсез инде. Ул сезнең шикелле сабын куыгы күк өреп кабартылынган түрә иде. Очты адәм актыгы, аңына килергә дә бирмәделәр. Иконагыз артыннан сез дә озак тукранмассыз, очарсыз дим мин.

— Беттеме сүзегез?— диде тикшерүчем, калтыранган бармаклары белән өстәлендә яткан портсигарыннан папирос алып.

— Бетмәде. Бу бүлмәгә соңгы кат аяк басканнан соң үткән дүрт елда сезгә җиткерәсе сүзләрем байтак җыйналды минем, әмма хәзергә әйтелгәне җитеп торсын. Нигә чакырттыгыз? Кәефем белән генә кызыксыну өчен түгелдер, шәт?

— Сезнең хөкем карарыгыз юкка чыгарылган, миңа эшегезне яңабаштан тикшерү йөкләнде.

— Аны башкарырга сездән дә ахмаграк кеше юкмыни бүтән?

— Сезгә мин үземне мәсхәрәләргә киңәш итмәс идем.

— Мин сезне мәсхәрәләмим, ничек булсагыз, шуны гына әйтәм. Эшемдә объектив булырыгызга ышанмыйм. Сез миңа таккан гаепләр буенча суд хөкем карары чыгарып ун ел биргән иде ич инде, элек тикшергәнегезгә нәрсә өсти, нәрсәне аныклый алырсыз? Эшемне сезнең тиешенчә ерып чыгарыгызга ышанмыйм, шуңа күрә бүтән кул тыкмагыз аңа.

— Эшегезне мин башладым, ахырына да мин үк җиткерергә тиеш. Аны яңабаштан тикшерүне башка кешегә бирү мөмкин түгел.

— Алай булгач эшебез карусельне хәтерләтәчәк икән.

— Нинди карусельне?

— Ярминкә каруселен. Карусельдә агач атка атланып әллә никадәр юл үткән кебек буласың. Баксаң, беркая да китмәгәнеңә, гел бер урында әйләнгәнеңә төшенәсең.

— Алай уйламагыз, сез монда булган 1950 елдан соң безнең системада да күп кенә нәрсәләр үзгәрде, Кадыйров.

— Ә төрмәгез, андагы мөхит, тәртипләр шул ук калган.

— Мәсәлән?

— Тоткынга элеккечә үк ятып торырга да, озак утырырга да рөхсәт юк. Ул тимер читлектәге ерткыч җанвар шикелле берөзлексез йөрергә тиеш. Хатын-кыз надзирательләр, сине туалетка алып баргач, табигый ихтыяжларыңны ничек үтәвеңне бөтен ваклыкларына кадәр күзәтеп торалар. Алар өчен бу — театрда кызыклы спектакль карау белән бер, күрәсең.

— Мин сүз бирәм, камерагызда сезгә карата чикләүләр булмас, мөнәсәбәт үзгәрер.

Тикшерүчем сүзендә торды, надзирательләр мине тулы тынычлыкта калдырдылар. Камерама икенче көнне үк яңа китаплар һәм журналлар да керде. Сорау алулардан бушап торган сәгатьләремне укып үткәрә башладым.

Баштагы көннәрдә тикшерүчем мине үз кабинетына еш чакыртты. Аның эшне тизрәк ахырына җиткерәсе, тәгаллисе килә иде шикелле. Беркетмәгә сорауларына ничек җавап бирсәм, үзгәртми терки барды, үзеннән бер ни дә өстәмәде. Ахырга таба да ул бу принцибына хыянәт итмәде. Эш арасында сорау алуда катнашучы прокурор кызыксынып миннән ике-өч тапкыр колониядәге тормыш, андагы контенгент, конкрет хәлләр турында сорашты. Соңгысында:

— Хезмәт белән төзәтү лагерьларында рецидивистларның хакимлек итүләрен ишеткәнем бар, ул дөресме?— диде.

— Элек хакимлек итәләр иде, соңгы амнистиядән соң әллә ни озына алмыйлар, таянычлары азайды, политик тоткыннар койрыкларына бастылар,— дип җавап бирдем.

— Җәмгыятебезнең түбәнгә тәгәрәгән кешеләренә сезнең бәягез нинди?

— Рецидивистларгамы?

— Әйе.

— Җәмгыятебез тәненә ябышкан паразитлар алар. Эш сөймиләр. Эштән берничә көнгә генә булса да арынып тору өчен әгъзаларын гарипләүне,

тәннәрен бозуны гадәти нәрсә санайлар. Хәтта пычак белән корсакларын яралар. Тирән кисмиләр, чамалап кына, әллә ни сызланмаслык итеп сызалар. Берәүләре, эшкә чыгуларын таләп итеп үз яннарына кергән начальствоны аяк өсте басып каршыламас өчен, умалларын (йомырка капчыкларын) зур кадак белән сәке тактасына кадаклыйлар, начальстволарны күрмәс өчен, аскы күз кабакларын өскесенә ябыштырып нечкә тимерчыбык белән шәплән тегеп куялар. Кайберләре, үзләрен теләсә нинди авыртуларга исләре китмәүне күрсәтер өчен, шәрә тәннәренә ике капламлы пальтодагы шикелле итеп нечкә тимерчыбык белән иңнәреннән билләренә кадәр ике рәт төймә тагып «шаккатыралар».

— Ә политикларга лагерь ничек?—диде подполковник.

— Аны сөйләп тормыйм, Семен Андреевич, анысын анда үзегез баргач күрерсез дип ышанам,—дидем.

Прокурор минем җавабымнан рәхәтләнеп көлде. Уйлап эш итә торган төпле кеше бугай ул, миңа эшемне тикшерү барышында бер тапкыр да чеперекле, буталчык сорау бирмәде, хәлемә кергәндәй тын гына утырды.

— Нигә шул тикле күрәлмисез сез мине, Кадыйров?

— Нигә күрәлмисез, имеш! Сез минем язмышымны харап иттегез. Шуны белмәгән кеше кебек сорап торасыз тагын...

Риан да Казанга кайткан. Горшенин мине аның белән прокурор алдында кара-каршы очраштырды. «Дустым»ның инсафлылыгы элек тә чамалы иде, сак астына эләккәч, ул аеруча оятсызланганга охшады. Аңа тоткынлыкның аз гына да файдасы тимәве күренде. Хәер, бөкредән нәрсә көтеп була, аны тик кабер генә турайта бит. Риан үзен, электәгечә үк, һичнигә исем китми дигән сыман һавалы тота. Ул да әле ирекккә чыкмаган бугай, өстендә минеке кебек үк зэк киемнәре. Аны минем эшемне яңабаштан тикшерү уңае белән безне кара-каршы очраштырырга кайтарганнар, күрәсең.

Тикшерүче аңа:

— Ничек, Саттаров, сез Кадыйров хакында элек күрсәткәннәрегездән ваз кичмәдегезме?—дигән сорау биргәч, ул кабаланып:

— Андый нәрсәнең, гражданин полковник (хәйләкәр, подполковникны бер баскычка үстерде, кемгә ничек мөрәҗәгать итәргә белә), минем уема да кергәне юк, һәм, ышанып әйтәм, килмәс тә,—дип кырт кисте.

— Ә сез нәрсә әйтерсез моңа, Кадыйров?—дип миңа карады тикшерүчем.

— Минем дә җавабым электәгечә, үзгәрешсез, Саттаровның миңа яккан гаепләре барысы да нахак уйдырма.

— Ирек, нигәборгаланасың, мондагы зур кешеләрнең башларын катырырга тырышуың көлке бит. Сиңа мин төрмә бераз акыл керткәндер, файдага киткәндер дип уйлаган идем инде.

— Мин төрмәнең сиңа да берни дә бирмәгәнен күрәм. Син теләсә кемгә койрык болгарга, өстерсәләр, атаң-анаңны да өзгәләп атарга әзер алабай идең, инде мәетләр белән тукланучы шакалга охшый башлагансың, бер урында гына тормыйсың, үсәсең. Белсәм дә сорыйм әле, синең үз гомереңдә берәр кешегә яхшылык эшләгәнең бармы?

— Ник булмасын, менә сиңа яхшылык эшләдем.

Мин мондый оятсыз җавап көтмәгән идем, югалып калдым.

— Миңа?.. Син нинди яхшылык эшләдең миңа? Өстемнән нахак ошак язып башымны таш капчыкка тыгуыңны яхшылык эшләүгә санайсыңмы?

— Әлбәттә, шуны. Аңарчы син яхшы белән яманны аера белми идең, тоткынлыкта үткән елларыңда тормышның кадерен белергә өйрәнгәнсең дип уйлыйм.

— Чыннан да, мәет белән тукланучы, башкаларның хәсрәт чигүләреннән тәм табучы кабахәт шакал икәнсең син!..

— Әйе, синең кук яңгырсыз болыт түгел...

Подполковник безгә артык чәкәләшергә бирмәде, бүлде.

— Бетерегез үзара талашуыгызны, җитте! Кадыйров, Саттаровка сезнең дәгъвагыз бармы? Аны сез нәрсәдә хаксыз санайсыз һәм моны нәрсә белән дәлилли аласыз?

— Соравыгыз урынлы, рәхмәт. Саттаров, минемчә, сәламәт акыллы нормаль кеше түгел, аны сары йортка җибәреп тикшертергә кирәк. Аннары нәрсәгә хаҗәте булды бу кара-каршы очраштыру кәмитен. Мин элек тә Саттаров белән очрашу беркетмәсенә кулымны куймаган идем, хәзер дә куймыйм. Үтенәм, эшемне тизрәк бетереп суд хөкеменә озатыгыз да, мине төрмә кандалаларын симертүдән азат итегез.

## 2

Инде йокыга китеп бара идем, камерам ишеге йозагында ачкыч борылганны ишетеп сискәнеп киттем. Тикшерүчем йокымны бүлеп төнлә чакырмаса, аңа көн кыска, күрәсең, дип уйладым үртәлеп. Берни эшләп булмый, мин үз иркемдәге кеше түгел, Семен Андреевич сагынган икән, күренеп төшми ярамас.

Ишекне киң ачып, камерама авызы колагына җиткән төрмә башлыгы килеп керде. Әллә сәрхүш инде сантый, нигә куанычы ташып чыккан моның?

— Кәефләр ничек, Кадыйров? Күңелең урыныңдамы, берни сизмиме?..

Торып аякларыма бастым.

— Кәефем зарланырлык түгел, гражданин начальник, рәхмәт. Күңелем дә урынында, берни сизми, тыныч.

— Мине гражданин начальник димәгез бүтән, иптәш Пронин диегез. Иптәш Кадыйров, җыеныгыз, мин сезне ирекка чыгарырга кердем.

— Нәрсә?.. Минеме?

— Әйе, дүрт ягыгыз кыйбла хәзер сезнең, ирекка чыгасыз!..

Төрмә начальнигы, күзләремә дусларча карап, иңемнән какты.

Минем бу көтелмәгән хәбәрдән колакларым шаулый башлады, йөрәгем тибүдән туктагандай булды.

— Ник шатланмыйсыз, мин чынлап әйтәм. Җыегыз әйберләрегезне. Сезгә комачауламас өчен мин коридорга чыгып көтәм.

Ирекка чыгам!.. Өнме бу, әллә төшме? Бәлки, саташам гынадыр? Юк, саташмыйм бугай. Төрмә начальнигы үзен гражданин димәскә, иптәш Пронин диярга куша, гаҗәп...

Тоткынның җыярдай ние бар, тиз-тиз өстемә киенгәч, юрганымны, җәймәләремне, мендәремне, сөлгемне матрацым эченә төреп, коридорга чыктым.

— Мин әзер, гражданин начальник.

— Мин хәзер сезнең өчен гражданин түгел инде, Кадыйров, ә иптәш булам. Гражданин сүзен ирекка чыккач та тәкрарлый күрмәгез, монда калдырыгыз.

— Нәрсә, иректә инде гражданиннар юкмыни, иптәш Пронин?

— Бар, ник булмасын. Тик иректә гражданин сүзе мондагы мәгънәсендә йөрми. Ирекнең үз законнары, төрмәнең үз тәртипләре. Биредәге аршын иректәге аршын белән бер түгел, үзгә. Шул гына...

— Совет власте ирек өчен дә, төрмә өчен дә бер үктер бит?

— Бер үк, әлбәттә.

— Ә нигә соң иректә законнар, төрмәдә тәртипләр дисез?

— Законнар белән тәртипләр арасында, миңа калса, үзгәлек юк. Әйдәгез, иптәш Кадыйров, фәлсәфә куертып маташмыйк.

— Сез хаклы түгел, иптәш Пронин, давыл кубарга тиеш. Әмма ул стакандагы суда башланып, киң җәелергә, бөтен гаделсезлекләргә, башбаштаклыкларга, законсызлыкларга чик куярга тиеш.

Төрмә начальнигы, безне берәрсе тыңламыймы икән дигән кебек, як-ягына сагаюлы күз ташлады.

— Мин сезнең белән тулысынча килешәм, эш шуңа бара шикелле...

Ирекка чыгам... Эт булып эт тә түзә алмаслык кыерсытылулардан соң, ниһаять, бу көн дә килде! Төрмәдән азат ителәчәгемне, ирекка чыгарылачагымны нигә миңа көндез үк прокурор яки тикшерүчем әйтмәде, нигә аны

алар төрмә начальнигыннан әйттерделәр? Бу бәлки үзләренчә кәмит уйнауларыдыр аларның? Теләсә нинди түбәнлеккә барырга сәләтле бит ул таш маңгайлар...

— Шәһәрдә танышларыгыз, кунар урыныгыз бармы, иптәш Кадыйров?

Дүрт ел да сигез айдан соң үземә атап әйтелгән иптәш сүзен төрмә начальнигы авызыннан ишетү ничектер сәер дә, ят та. Кара, зәктан мин дә кешегә әверелә барам лабаса!.. Нәрсә, нәрсә?.. Танышлар, кунар урын... Ул нигә сорый аны?..

— Шәһәрдә кереп баш төртерлек якын танышларым юк минем. Кулга алынганчы тулай торакта яшәдем. Кунар урын табармын, шәт. Шәһәр бакчаларындагы теләсә кайсы куак төбе фатирым була ала минем...

— Бәлки, иртәгә кадәр бездә генә калырсыз, төрмәдә генә йокларсыз?

— Рәхмәт, иптәш Пронин, каламмы соң!..

— Шулай да, кайда баш төртергә аптырасагыз, бирегә кайтыгыз, кертербез.

Төрмә һавасын бер генә сәгать сулау да үз-үзеңә җирәнү тудырганын белми микәнни бу «киң күңелле» чиновник? Ул эчке төрмәне кунак йорты, үзен шул тәрәзәләре рәшәткәле «җәннәт»нең шәфкатьле хуҗасы дип исәпли микән әллә? Ирекәә чыгарулары, чыннан да, хак, димәк. Тик нигә көндез чыгармадылар, төнгә калдырдылар? Бу ләгънәтләнгән йорт капкыныннан кемнедер азат итүне кешеләргә күрсәтергә ярамый, бирәдә интеккән тоткын ирекәә көн яктысында чыкса, «серле» учреждениенең абруена хилафлык кылу мөмкинлеге бар, күрәсең... Шәп, төнлә кулга алалар, төнлә чыгаралар.

Пронин мине тышкы ишеккә кадәр озатты да:

— Төрмәдән азат ителүегез турындагы документ әле әзер түгел, аны алырга иртәгә сәгать ун тулгач керегез. Тыныч төн сезгә,— диде.

— Рәхмәт!— дип тизрәк тышка атладым.

### 3

Иртәгәсен сәгать унда Татарстан дәүләт иминлеге комитетының пропусклар бүлегенә бардым. Мин анда урамнан керү белән шундагы ишекләрнең берсеннән төрмә начальнигы Пронин чыгып:

— Керегез монда, Кадыйров,— диде.

Йөрәгем жу итте, ул миңа бүген кичәге кебек иптәш димәде, язмышым тагын шикләнды, күрәсең, дип коелып төшеп төрмә начальнигы чакырган кечкенә генә бүлмәгә үттем.

— Исәнмесез.

— Исәнмесез.— Пронин бүлмәнең бердәнбер җиһазы-бәләкәй өстәлдә яткан зәңгәр тостәге юка гына папкадан ярты дәфтәр битe зурлыгындагы ниндидер кәгазь алды. Аның җитди йөзендә мин кичәге шат елмаюының эзен дә күрмәдем.— Менә бу кәгазьгә басылган текстны дикъкать белән укып чыгып, «имзам» дигән җиренә кулыгызны куегыз.

Мин үземә сузылган кәгазьне алып аннан түбәндәгеләрне укыдым:

*Сер саклау турында ышаныч кәгазе*

*Мин, Кадыйров Ирек Сабирович, Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы Дәүләт иминлеге комитетының эчке төрмәсеннән чыкканда анда үзем кичергән һәм үзем хәбәрдар булган фактларны берәүгә дә фаш итмәскә сүз бирәм.*

*Сүземдә тормасам, РСФСР Уголовный кодексы нигезендә, җавапка тартылачагым аңлатылды.*

*Имзам.*

Шул мизгелдә үк йөрәгем юкка жу иткән дип шатланып, җиңел сулап куйдым, һәм, өстәлдә яткан ручканы алып, кәгазьгә кулымны куйдым.

— Паспортыгызны элек үзегез пропискада торган милиция бүлегеннән, хәрби билетыгызны да шул ук районның хәрби комиссариатыннан алырсыз.

Мена чемоданыгыз.— Төрмә башлыгы чемоданымны өстәл артыннан яныма чыгарды.— Яңадан илебезнең тулы хокуклы гражданины булуыгыз белән котлыйм сезне, иптәш Кадыйров. Алдагы тормышыгызда уңышлар телим сезгә.

Ул каты итеп кулымны кысты. Аның йөзендә кичәге дустанә елмаю бөтен тулылыгы белән кабат балкыды.

— Рәхмәт,— дидем.— Сез миңа ирекка чыгарылуым турында бернинди документ та бирмисезмени?

— Бирәм, иптәш Кадыйров, бирәм, нигә бирмәскә.— Төрмә начальнигы өстәлдәге зәңгәр папкадан мин әле генә кул куйган кәгазь зурлыгындагы ук икенче бер кәгазьне чыгарып миңа тоттырды.

Ул кәгазьдәге «Белешмә» дигән сүзгә күз салдым да, аны укып тормадым, дүрткә бөкләп түш кесәмә тыктым.

— Миңа инде чыгарга мөмкинме?

— Мөмкин, бик мөмкин, иптәш Кадыйров. Изге юл сезгә.

— Рәхмәт яхшы теләгегез өчен. Хушыгыз.

— Сау булыгыз.

Кулга алынгач кертелгән ишектән үк иреккә чыктым. Авыр имән ишек аркама аткан төсле шартлап ябылып калды. Гүя, Дәүләт иминлеге комитеты бинасы мине, чәйнәп-чәйнәп тә йота алмавына җенләнеп, ачу белән тышка төкерде.

Карыйм, нинди документ бирде икән миңа төрмә башлыгы, анда нәрсәләр язылган икән? Чемоданымны тротуарга утыртып, дүрткә бөкләп түш кесәмә тыккан кәгазьне чыгардым. Оһо, аның өске өлешенә «Яшәр өчен документ була алмый, югалтылса кабат бирелми» дип язылган. Кызык нәрсә генә була ала икән соң ул?.. Ары укыйм әле.

Белешмә

*Бу белешмә 1925 елда Үргәнч шәһәрендә туган, милләте татар, СССР гражданины Кадыйров Ирек Сабировичка 1950 елның 23 гыйнвареннан 1954 елның 22 сентябренә кадәр Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы Дәүләт иминлеге комитетының эчке төрмәсендә сак астында тотылуы, аны гаепләү эшенең туктатылуы һәм Кадыйровның, азат ителеп, яшәү урынына җибәрелүе хакында бирелде.*

*ТАССР МС каршындагы ДИК эчке төрмәсе*
*Начальнигы вазифаларын үтәүче — Пронин.*
*Эчке төрмәнең секретаре — Власова.*

Бу белешмәдән күренгәнчә, илле алты ай гомеремне тик эчке төрмәдә генә үткәргән булып чыгам түгелме? Нигә анда ун елга хөкем ителүем, дүрт елга якын Себер колониясендә булуым күрсәтелмәде икән? Яшәр өчен документ була алмагач, нәрсәгә генә ярар икән бу кәҗә билеты? Кулымда шушы хәсрәт кәгазьдән бүтән документларым, кесәмдә бер тиен акчам булмагач, кая бара алам мин? Яшәү урынына җибәрелә, имеш. Минем соңгы яшәү урыным Казан иде, димәк, тору урыныма инде кайткан булам, шуңа миңа ике-өч көнгә генә булса да бернична тәңкә акча бирүне артык санаганнар булып чыга. Ярар, илдә чыпчык үлми, ул да ничек тә яшәр әле, дигәннәрдер... ДИК бинасы алдында зәк киемнәреннән карачкы кебек басып торудан файда юк, каядыр барырга кирәк. Ләкин кая барырга? Казанда бер ике көнгә генә дә сыенырлык урыным юк, мин, монда бөтен кешегә ят бит. Оля ерак районда. Мин хәзер әле яңа гына дөньяга килгән ярдәмгә мохтаҗ сабый күк. Аерма шунда гына: сабыйны әти-әниләре күтәп ала, минем исә бераүгә дә хаҗәтем юк...

Чемоданымны алып, Черек күл бакчасының Дзержинский урамы ягындагы тар гына капкасыннан балалар паркына үттем. Анда каршы яктагы тын аллеяда бала арбасы тәгәрәтүче бер яшь хатыннан бүтән кеше күренмәде. Мин парк ягына таба үтеп, ял итәргә уңайлы эскәмияләрнең берсенә утыр-

дым. Шул мизгелдә үк кинәт башым әйләнеп, күз алларым караңгыланып китте, бик нык арыганымны, җеп өзәрлек тә хәлем калмаганын сиздем. Кичәдән бирле авызыма бер бөртек ризык кергәне юк, төрмәдә җан асрарлык кына тукландырып яшәттеләр, ачлык галәмәтедер бу, дидем үз-үземә. Аз гына икмәк кабасы, аны чәйнәмичә суырып кына утырасы иде хәзер...

Нәрсәдер эшләргә, каядыр барырга кирәк миңа, болай утырудан файда юк. Монда, янәшәдәге Карл Маркс урамында, милиция бүлеге бар иде бит, чемоданымны шунда кертеп калдырыйм да Матбугат йортына төшим. «Кызыл Татарстан» һәм «Яшь сталинчы» газеталары редакцияләрендә мине белүче иптәшләр бар иде, бәлки берәрсе очрар? Бу бакча — төрмәдән иреккә чыккан кеше урыны түгел...

Их, ирек, ирек! Күпме газаплар, түбәнсетелүләр, җәфа-мәсхәрәләр кичереп ирешелгән ирек, нигә син мине шатландырмыйсың? Бәлки, ирекле тормышның кыйммәтен, тәмен-ләззәтен оныткандыр мин? Бәлки, аңардан ятсынамдыр, кем белә? Төрмә кемгә әверелдерде мине? Хуҗасыз этнең берәүгә дә кирәге булмаган кебек, минем дә кемгә кирәгем бар?..

*1969 ел.*

*Икенче кисәк тәмам*

---

*Котлыйбыз!*

## Альберт Яхинга 60 яшь

Язучы һәм әдәбият галиме Альберт Гатуф улы Яхин 1931 елның ноябрендә Татарстанның Арча поселогында хезмәткәр гаиләсендә туган. Урта мәктәптән соң Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Аннары Азнакай районы Тымытык урта мәктәбендә эшли. 1956—59 елларда Казан дәүләт университеты аспирантурасында укый, 1964 елда «Шамил Усманов иҗаты» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

1959—75 елларда Альберт Яхин «Чаян» редакциясендә эшли. Баштагы тугыз елда ул җаваплы секретарь, ә аннан соңгы җиде елда баш редактор вазифаларын үти. 1975 елның сентябреннән 1981 елның февраленә кадәр Казан дәүләт университетында татар әдәбияты кафедрасын җитәкли. 1981 елдан бирле — шул ук кафедрада өлкән укытучы.

А. Яхин әдәбиятка фән һәм журналистика аша килә. Ул — күренекле язучы, гражданнар сугышы каһарманы Шамил Усмановның тормыш һәм иҗат юлы турында ике китап авторы. Аның Аяз Гыйләҗев белән берлектә язган «Шамил Усманов» дигән тарихи драмасы да бар. Ә алтмышынчы еллардан башлап ул юмор-сатира өлкәсендә актив эшли. Илебезнең һәм республиканың сатирик журналларында, төрле җыентыкларда аның хикәя һәм фельетоннары еш дөнья күрә. 1975 елда бу әсәрләр «Әйттем исә кайттым» исемле китап булып та басыла. 1978 елда исә алар рус телендә «Полный порядок» исеме белән дөнья күрә.

А. Яхин галим буларак үзенең тикшеренү эшләрен дә халык иҗатына, юмор-сатирага бәйләп алып бара.

Альберт Яхин — 1977 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Татарстан Язучылар берлеге һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлыйлар, аңа иҗат уңышлары, сәламәтлек телиләр.

## ГАСЫР БАШЫ ШИГЪРИЯТЕННӘН

# Бәдретдин Киләчи

Бу имза белән басылган шигырьләр «Идел» газетасы һәм «Аң» журналы битләрендә очрый. Әстерхан якларыннан булса кирәк. Шәхси тормышы, эшгамәленә нисбәтле мәгълүматлар табылганы юк.

### Диңгез

Уйный диңгез. Ач арысланнар кебек дулкыннары!
Котрына бер туктамый айлар вә көннәр-төннәре.
Әйдә, котрын! Коточарлык кайнасын тулкыннарың!
Тау вә ташларны йотарлык уйнасын упкыннарың!

Әй, киң диңгез! Әгәр мин син булсам иде!
Күккә карап күкрәк киреп торсам иде!
Таулар төсле тулкыннарым алга таба
Арыслан тик омтылганын күрсәм иде!

Мин шул хәлдә янсам шушы яну берлән,
Ай күзләрдән алмас яшьләр таму берлән,
Күптән инде җир-күкләрен, ялынса да,
Упкан булыр идем тотып барын бердән.

*«Аң», 1914 ел, 5 сан*

# Кәшфи Кәрибов

1892—1918

Уфа губернасының Бөре өязе Байталлы авылыннан чыккан шагыйрь. 1915 елларда «Госмания» мәдрәсәсе (Уфа) мөгаллиме. «Тормыш» газетасы редакциясендә дә эшләгән. Чехлар һөҗүме вакытында үтерелгән.

К. Кәрибовның шигырьләре күбрәк «Нур», «Тормыш» газеталарында басылган. 1914 елда Уфада «Мәхәббәт шигырьләре» дигән китабы да чыга. Аның керешендә мондый сүзләр бар: «Бу шигырьләрдә рус, төрек, татар шагыйрьләреннән берсенә дә тәкълид итәсем килмәде. Милләт, тәрәккъый сүзләрен дә язмадым. Монда күбрәк сөю-сөешү шигырьләре язылган. Шуңа күрә «Мәхәббәт шигырьләре» дип атадым».

## Ялындыра

Әй туташым, юк өчен
Мине дивана әйләмә:
Чын мәхәббәттән инде
Башкаем да әйләнә.

Дөрләгән утка янучы
Чын гашыйкны бәйләмә:
Күрсәт инде йөзкәеңне,
Мине моңлы әйләмә.

Бер ялынгач, мең ялынып
Зар елаучы әйләмә;
Җанкаем, ходай хакына,
«Ташланучы» әйләмә.

Әй гафифә[1], әй матур, син
Мине мәхрүм әйләмә;
Ай йөзеңне күрми күзем,
Мине мәхзүн[2] әйләмә.

*1914*

## Яшьләр түгелсен

Юк ла!
Мин өмид өзмим:
Ул, бәлки, бер көләр,
Бәлки... энҗедән сафрак тешен
Күрсәтеп...
Сөекле авызлары белән
Берәр сүз сөйләр.
Бәлки, сөйләр, бәлки, көләр,
Мине ошатыр:
«Сөямен» дияр...

*1914*

# Бәхтияр Мирзанов

1892—1941

Тумышы белән Башкортстанның Эстәрлетамак районы Йөрәктау авылыннан. «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый. Берара «Сөембикә» журналы редакциясендә эшли. Шигырьләре 1914—1917 еллар дәвамында «Шура», «Аң», «Сөембикә» журналларында, «Вакыт», «Кояш», «Тормыш» газеталарында дөнья күргән. Поэмалары, тәрҗемә әсәрләре бар.

## Гашыйк

Йолдызлар тынды,
Диңгез тулкынды,
Урман һаман да
Шаулыйдыр тынмый.

Таулар җилкенде,
Җирләр селкенде,
Тынган йолдызлар —
Юк булды, сүнде.

Томан агарып,
Йөзә кабарып,
Бар җан аллага
Шул вакыт торды
Куркып, ялварып.

[1] Гафифә — саф, намуслы.
[2] Мәхзүн — моңлы.

Салкын җил өрә,
Күктә ай сүнә,
Шул вакыт кемдер
Еглый да көлә.

Кемдер ул үзе?
Моңайган күзе!
Ирне калтырый,
Саргайган йөзе.

Шунда ай сүнде,
«Ул» да бер көлде,
Көлде ул, чөнки
Тынды дәрт, сүнде!

Шаулады диңгез
Кичә вә көндез,
Әмма гашыйктан
Калмады бер эз!

*«Сөембикә», 1915 ел, 24 сан*

## Әйдә, сызлан...

*С. Р.-КӘ БАГЫШЛАНДЫ*[1]

*Сызла, сызла, сызла, күңлем! Сызла бер туктамыйча;*
*Сызла айлар, сызла еллар, сызла төн йокламыйча!*

Әйдә, сызлан әрни-әрни ялкыныңда, әйдә, ян;
Әл дә тәңрең нечкә хис биргән — шуңа шатлан, куан.

Һәр караңгы төнгә каршы якты көн биргән ходай;
Ялтырарсың илдә, бәлки, ай кеби син дә шулай.

Нур түгә ай, җил өрә, тик золмына күнмәсме дип;
Тукта, золмәт капласын бу җирне, ул сүнмәсме дип.

Бел: кара көннәргә йөз чытмый әгәр торсаң түзеп,
Бер күләрсең алда якты йөз белән йолдыз кебек.

Юк рәхәт инсанга, юк күкрәк канын түкми азат!
Тапмады хәтта Муса да Нил суын үтми нәҗат[2]!

Белмимен, никтер шулай һәр тәмленең бер агуы бар,
Һәр теләк, һәр изге эшкә каршы бер фиргауны бар.

Син кирәк ул! — бу халык әйтмәс, бу мескин үлде дип,
Үлде, дәртен, хисләрен яшьли, вакытсыз күмде дип.

Билгеле: ямь юк сиңа тормак аларча — тән белән;
Әйдә, иркендә канат ач, уйна, көл, ямьлән гелән!

Бер көләр бәхтең ае, золмәт китәр, ул ялтырар;
Бул чыдау да, яктырыр бер көн күңлең ак таң белән!

Бу сүземнең растлыгын син бер заман аңлап-белеп,
Үч алырсың шунда иркең тоткыны — көннән көлеп.

Бозмасын кәйфең гавамнан пакь исемең тапталу,
Ниңди файда сандугачка бер ишәктән мактату?

---

1 С. Р. — татар шагыйре Сагыйть Рәмиев. Эпиграф аның «Сызла, күңлем» шигыреннән.
2 Нәҗат — котылу.

Үтте... сәнгать мәйданында энҗе дип чүп-чар казып,
Без күңелгә тапмадык һичбер нәфасәт, тәм, азык.

Инде гөлләр бакчасында бер матур гөл сайла син!
Күп ялыктык каргалардан, сандугач бул, сайра син?

Сайра, без дә моңнарың ишетик әле, бер ямьләник,
Бәхтемезнең бакчасында нәрсә бар — бер әйләник!

Без көтәбез нур күңелгә, көлче син бер таң белән!
Балкысын нурсыз күңелләр — ялтырап Чулпан белән!

*«Аң», 1916 ел, 8 сан.*

# Кәшшаф Патии

Бу шагыйрьнең әсәрләре «Шура» журналы һәм «Идел» газетасы сәхифәләрендә аеруча еш күренгән. «Кәшшаф Патии шигырьләре» һәм «Әшгарь» (шигырьләр) дигән зур булмаган ике китабы 1910 һәм 1915 елларда басылып чыга. Элекке Сембер губернасы Зимничә авылында туып үскән бу авторның шәхесен һәм тормыш юлын ачыкларлык башка төр мәгълүматлар хәзергә табылмады.

## ...гә

Сөйләсәң сүз матбугатта, сөйлә чын, кирәклене —
Ул яратмыйдыр синең кебек сирәк иләклене.

*«Шура», 1914 ел, 14 сан.*

## Гармун

Тарткан саен гармун дәртләндерә,
Каршысына моңлап җырласаң,
Узган гомер белән күмелеп калган
    Изге, пакь эшләрне уйласаң.

Өзелә соң гармун, өзә эчне,
«Зиләйлүк» көйләрен уйнасаң;
Таша йөрәк-бәгърең, егълыйсың да,
    Гармун ни әйткәнен аңласаң.

Уйный ла соң гармун, уйный ла соң,
Моңсу «бас»ларына еш бассаң;
Онытасың кайгы-хәсрәтләрең,
    Шул саф тавыш белән сызлатсаң.

Сүнми хиссиятең, үлми рухың,
Гармуныңны кулдан куймасаң;
Без дә бар бит дисең, яшим дисең,
    Милли көйләр тартсаң, уйнасаң.

*1915 елгы җыентыгыннан*

## Яз башы

Яз башы житте хәзер, күктән төшә су тамчысы,
Җир яшәртте, шартлатып суккач, Хозырның камчысы.

Керде рух, килде шагыйрьләргә шигырь илһамчысы,
Тугъды җир — житте халык ярдәмчесе-ихсанчысы.

Май ае — айлар көмеш балдагының ак энҗесе,
Тойгылы-хәссас күңелләрнең рухы, җан серчесе.

Уйный гармуның, туташ, кыжмырдый кош-корт — барчасы,
Бакчаларда чут та чут җырлый табигать җырчысы.

Кыр, сулар елмайдылар, көннәр — күңел сихерчесе,
Күк эчендә балкый нур тауларының тылсымчысы.

*1915 елгы җыентыгыннан*

# Габдерәшит Рамазанов

Шигырьләре 1910—1918 еллар эчендә «Идел», «Бәянелхак», «Кояш», «Йолдыз», «Шура» кебек газета-журнал сәхифәләрендә еш чыгып торган. Шул ук заманнарда Казан мәтбагалары аның «Г. Рамазанов шигырьләре», «Уку чәчәге», «Уку гөле» исеме белән шигырь китапларын да басып чыгарганнар. Тәрҗемәләре, хикәяләре дә бар. Тәрҗемәи хәленә кагылышлы мәгълүматлар аз сакланган. Чиләбе газетасы 1923 елда аның вафатына дүрт ел тулуга багышлап кичә үткәрелү турында хәбәр итә.

## Минем фәһмем[1]

Кайвакыт каплый болыт; золмәт — бара торган юлым;
Яктылык калмый, күренми ал вә артым, уң-сулым.

Нишли дә алмыйм, баралмыйм, алга мин юл күрмимен,
Шул караңгылык сәден[2] читкә этәлмим, йөрмимен.

Калмый шул чак дәрманым, — хәлдән таям, — һич калмыйдыр,
Белмим шул чак үзем: уңмы бу ягым, алмыдыр?

Шул халәттә мин гаять мохтаҗ улам шул дәмдә[3] мин
Якты юлны күрсәтүчегә, бөек ярдәмгә мин.

Бервакыт әллә каян миңа рушан[4] кояш туа,
Нур чәчә, золмәт-болытның үзенә нурлар тула.

---

[1] Фәһмем — акылым.
[2] Сәд — киртә.
[3] Дәмдә — вакытта.
[4] Рушан — яктыртучы.

Күрсәтә нурлар чәчеп миңа барырга якты юл,
Шул караңгылык сәдең калдырмыйдыр һич таплы ул.

Шул вакыт гайрәт кирә, алга китәм йөрәк белән!
Булмый һич манигъ[1] миңа! Барын этәм күкрәк белән.

Һәр эшем мәйданга тезелешеп килә башлый шулай,
Шул кояшым ярдәме берлән киләләр бит болай!

Һәм аның берлән килә мәйданга бу нәзмым[2] минем;
Ул кояшымны беләсең килсә, ул — ф ә һ м е м минем.

*1910 елгы җыентыгыннан*

## Күр

Мин дә бит яздым шигырь! — дип күккә ашмакчы булам —
Дәгъваланма, әй Рәшит син! Ач та язганыңны күр.

«Тасвирым!» — дип тә киереп түшне димәк булам —
Дикъкать ит! Юк-бар хыял берлән саташканыңны күр.

Эшләреӊ эшлә! Фәкать син итмә һичбер ифтихар[3];
Ашма ходаңнан, һаман һәрдәмдә вөҗданың күр.

Чын кеше булмак теләр исәң, менә мә, шул сиңа:
Йомма күзең, ач та дикъкать ит вә ноксаныңны[4] күр!

*1910 елгы җыентыгыннан*

# Әбрар Сәгыйди

1895—1939

Татар шигъриятенә Апас районының Кече Кошман авылыннан килгән әдип. Ул Казанда «Мәрҗания» мәдрәсәсендә, Учительская семинариядә белем ала, аннары мөгаллим була. Шигырьләре һәм поэмалары «Шура», «Сөембикә», «Ак юл» журналларында, «Йолдыз», «Кояш», «Тормыш» газеталарында басыла, «Сугыштан абыем хатлары» (1915) һәм «Ирек азаны» (1917) исемле китапларында чыга.

Октябрьдән соң ул журналистика, мәгариф эшендә булды, шигырьләр, пьесалар, күпсанлы мәкаләләр язды.

## Бәхтемә

Син генә, бәхтем, гомернең бар яме,
Син шулай гомрем буена нурлы бул;
Баш имә һич таш күңелле дөньяга:
Алдамасын ул, сгылсаң — бирми кул.

*«Шура», 1915 ел, 1 сан*

---

1 Манигъ — киртә, каршылык.
2 Нәзмым — шигырем.
3 Итмә ифтихар — мактанма, горурланма.
4 Ноксан — кимчелек, җитешсезлек.

## Кара көчләр

Безне алда, мең шөкер, ак, яхшы тормышлар көтә,
Әкрен-әкрен инде бар мәлгунь кара көчләр бетә.

Күп изелдек... күп газапландык алардан без борын,
Күрсәтер пәрвәрдикяр[1] инде тыныч тормыш юлын.

Без яшәрбез мәңге шатлыкта кара көчләр бетеп,
Аһ! Кара заман... яшәгән һәр хатын-кыз ут йотып.

Инде ул кара заманнар юк, шөкер, үткән алар,
Һәм дә беткән ул замандагы рәхимсез җанлылар.

Инде акмас дип беләм мискен хатын-кызлар яше,
Бер алар һәм йөкләмәс таудай авыр күп кайгылар.

Тик кара көчләрне без бетерик, кырыйк җан-тән белән —
Ул ничек ямьсез, караңгы төн бетә ак таң белән.

Аһ, заман!.. Зинһар: кара көчләрне без бетерик, җиңик!
Һәрбер илгә ак, көмеш төсле матур уйлар сибик!

Бергәләп эшлик, ике төркем уйлыйк бар алдагын,
Ни авыр күрү йөрәкләрдән кара кан тамганын!

*«Сөембикә», 1915 ел, 2 сан*

# Җамалетдин Юмаев

**1892—1937?**

Курган өлкәсенең Әлмән авылыннан. Ятимлектә үскән. Троицк шәһәрендәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте. Берара рус-татар мәктәбендә укыган.

Шигърият мәйданына 1910—1911 елларда килеп керә. Әсәрләре «Шура»да һәм «Идел»дә аеруча еш тәкъдим ителгән. Пушкин, Лермонтов, Мәгарридән тәрҗемәләре бар. 1914 елда «Җамалетдин Юмаев шигырьләре», 1915 елда «Әдәби шигырьләр» дигән китапларын бастыра. 20 еллар башында туган авылына мулла итеп куйганнар. Аннары Урта Азиядә яши. Шәхес культы корбаны булган дигән хәбәрләр бар.

## Вөҗдан

Бу дөнья диңгезендә һәрбер әшья[2] —
Карарсыз — туктамый дулкынламакта.
Йөри иркен бөтен нәфсани[3] эшләр,
Мәгәр вөҗдан уянмый йокламакта.

*«Шура», 1912 ел, 22 сан*

---

1 Пәрвәрдикяр — алла, тудыручы.
2 Әшья — әйберләр, нәрсәләр.
3 Нәфсани — бозык.

## Тугърылык

Күңелле: тугърылыкны иркәлиләр,
Кадерлиләр вә хөрмәтләп торалар;
Вәләкин тугърылыкны әйтсә бер мән[1],
Яратмыйлар аны, хәтта оралар.

*1915 елгы җыентыгыннан*

## Гомер вә эш

Үтәр көннәр, тотар аңларның урнын башка бер көннәр,
Шуныңчөн берсе-берсеннән бөтенләй башкадыр көннәр.

Булыр бер көн: явыз тормыш сине ямьсез изәр, таптар,
Сәгадәт яктысын шактый кара көннәр белән каплар.

Янар күкрәкләрең, кайнар йөрәкләр моң вә дәрт берлән,
Җыларсың — битләреңдә эз салырсың канлы яшь берлән.

Булыр бер көн: күз алдыңда күрсәң шактый юл-эзләр,
Йөрерләр әйләнәңдә зур өмидләр — якты йолдызлар;

Тәмам шатлык белән син шатланырсың алдагын уйлап,
Күңелне борчымассың тормышыңның калганын уйлап.

Үтәр көннәр шулай бер кайгы, бер шатлык белән алмаш,
Мәгәр бу үзгәрешләр тиз заманда онтылыр — калмас.

Вәләкин бар гомергә онтылудан читтә торган эш —
Үзең һәм дустларыңның каршысында эшли торган эш.

*«Йолдыз», 1913 ел, 22 декабрь*

Сәхифәне **Зофәр РӘМИЕВ** әзерләде.

[1] Бер мән — берәү, бер зат.

## ПУБЛИЦИСТИКА

# Тәлгать Галиуллин

# ЗАМАНА БАЛАЛАРЫ

### Хакыйкать — авыр нәрсә...

Минем куптәннән Алабуга педагогия институты, шул төбәк белән бәйле олы, әмма ерактан бик кечтеки күренгән вакыйгалар, анда яшәгән, эшләгән, «керәп чыккалаган» кешеләр, республиканың шул чордагы җитәкчеләре турында язасым килеп йөри иде. Әмма өстәп артына утырырга, Тукай әйтмешли, лампада бик тиз май кими, күңел сүрелә, кәеф кырыла. Нәрсәдән башларга бу истәлекләрне? Үткәннең кайсы баскычлары, күргән-белгән, кичергәннәрнең нинди үрләре, чоңгыллары кызык булыр икән укучыга да, кайсылары бүгенге катлаулы, әрмәле көннәрнең рухына ятышыр, кешеләргә үзләрен һәм тирәлекне аңларга ярдәм итәр икән? Ул бит Әмирхан Еники белән Мостай Кәримгә генә ата-бабаларының, әби-килеләренең, кыскасы, нәсел-нәсәпләренең кайсы буынын искә төшерсәләр дә, нәрсә турында илһамланып язсалар да килешә. Алар — тере классиклар, каләмнәреннән кәгазьгә иңгәнне бастырып чыгармыйча кара да, укымыйча кал. Үзенең хәбәрдарлыгын күрсәтергә яраткан берәр зыялысы кеше алдында: «Еникинең «Соңгы китабы» ошадымы?» — дип сорап куйса, аңа барып җитә алмадым әле, дип акланып тора алмассың бит.

Тагын бер нәрсә туачак язмалардан биздерә килде. Ил корабын җилнең кая алып барганын аңлавы кыен. Һәр адәми зат нәрсәдер яза, зарлана, сукрана, ачулана, распый, кычкыра. Үткәнне каһәрли, элеккеге түрәләрне кояш яктысына тартып чыгара. Юл уңаенда үзен күтәребрәк куярга да онытмый. Әйтерсең лә ул хәзер үзе «сүткән» җәмгыятькә, аның олыларына заманында мәдхия яудырмаган, элеккенең бер шөребе булмаган. Яшәгән чорыңнан өстен калып, үзеңнән югары сикереп булмый икән. Кайберәүләр, башкалар ялгыша, мин хаклы, дип уйлый. Аның турында «башкалар»ның шулай ук хөкем йөрткәнен исенә дә кертеп карамый. Кыскасы, демократия чорында, яңартып кору җилләре үтәдән-үтә искәндә, дөреслекнең кайда ятканын аңлавы җиңел түгел икән. Бер шәхси күренгән вакыйга әлеге истәлекләргә, хәзерге тарихыбыз һәм хәләте рухиябез турында уйлануларга кискен этәргеч бирде.

1990 елның җәйге ямьле айлары... Мөхәммәт Мәһдиевнең Тукай бүләген рәсми алып йөргән көннәре. Колыма тоткыны, үзенчәлекле язучы Ибраһим Сәләхов файдасына матбугат аша премиядән баш тартып та, олы бүләкнең язган ризык төсле, тешләрен «сындырып» кергән бәхетле мизгелләрендә иптәшне шифаханәгә салдылар. «Үз гомеремдә больницада ятканым юк», — дип, малай-шалайны ирештерергә яраткан язучыбыз тормышының ниндидер бер яңа чорына килеп керде.

5 нче шәһәр больницасына салганнар икән үзен. Көч-хәл белән эзләп таптык бу шыксыз, ямьсез, ташландык хәлгә килгән бинаны. Аның җимерек коймаларын, чалшаеп беткән утыргычларын, таш, ком, тимер-томыр белән тулы ишегалдын күрсәң, һич кенә дә чирлисең килмәс! Эчендә ремонт эшләре бара икән. Әдибебез — дүрт кешелек бүлмәдә. Ике карт фани дөнья белән бөтенләй саубуллашып ята, яннарына туганнары утырган, ә яшь-җилкенчәкнең аларда эше юк. Хәлен белергә килгән иптәшләре белән шаркылдап-көлешеп сөйләшәләр. Берәү үлми, икенче көн күрми, диләрме әле?! Әдүртенче тимер караватта — чал чәчле, кырынмаган, әмма рухын төшермәгән горур Мәһдиев... Бер чит ил кунагы безнең шифаханәләрне багып йөргәч: «Мондый медицина бары тик бушлай гына була ала», — дигән нәтиҗәгә килгән, имеш. Ул хаклыдыр, шәять.

Янәшәдә басып торган университет деканы, бу хәлдән исе, акылы китеп:

— Безнең җәмгыятькә кеше кирәк түгел шул. Башка илдә Мәһди кебек шәхесне күтәреп йөртерләр, иң яхшы, иң затлы шифаханәгә салырлар иде,— дип әйтә куйды. Икенче юлдашыбыз әлеге фикерне үзгә яктанрак ачып салды:

— Бу җәмгыятькә олы шәхесең дә, бәләкәй кешең дә барыбер. Аны тик юлына каршы төшкәннәр генә кызыксындыра, алар гына борчый...

Мәһдиевне башка шифаханәгә күчерүгә ирешә Язучылар берлеге идарәсе берничә көннән соң. Иншалла, ул хәзер исән-сау. Ләкин ул яткан больница, бүлмә, иптәшләр әйткән сүзләр һаман да күңелдә, колакта. Ничек без шундый хәлгә төштек соң әле? 1913 елда Тукай үлгән Клячкин шифаханәсе дә аның премиясенә лаек булган варисы яткан җирдән затлырак түгелме? Без бит дистә еллар буена нәрсәләрдер төзедек, көрәштек, кан койдык, хыялландык бугай? Бөтен кыенлыкларны палач Сталинга, башбаштак Хрущевка, барин Брежневка гына сылтап котылырга уйлыйбызмы?! Ә Татарстанны кем менә шул хәлгә китерде?..

Бикле җәмгыять шартларында без Татарстанның ни дәрәҗәдә бичара, мескен яшәвеннән хәбәрдар түгел идек. Дөрес, күрше Чуваш, Мари якларына чыгарга туры килгәндә, яхшы таш юлларны, челтерәп агып яткан чишмәләрне, төзек авылларны, кибетләрендәге муллыкларны, Уфаның төзеклеген, чисталыгын күреп, күңел әрнеп, җан елап кайта торган иде. Хәзер һәртөрле мәгълүматлар берьюлы башка килеп төшкәч, чәчләр үрә тора. Күп өлкәдә җан башына җитештерү буенча ил күләмендә беренче сафларда торсак та, уртача эш хакы ягыннан 50—60 нчы рәтне, шифаханәдәге урыннар буенча 61 нче, югары белем дәрәҗәсе җәһәтеннән 60 нчы урыннарны билибез икән без.

Кырык ел вакыт арасында Татарстан куеныннан суырылган җилекнең бәясе 250 млрд. доллар тора. Әмма республикага нефть биргән акчаның йөздән фәлән өлеше дә эләкмәгән икән!?

Татарстан бүген үз промышленносте биргән байлыкның нибары 1,5 проценты белән генә файдалана, бер генә колониаль, басып алынган илнең мондый аяныч хәлдә калганына мисал юк тарихта.

Милли аң уяну илнең сәяси, икътисади мәсьәләләренең дөрес хәл ителүенә бәйле. Чишелешен көтеп яткан хәлләрнең күбесен хәерчелек һәм ирек, азатлык, мөстәкыйльлек булмау китереп чыгара.

Бәйсезлек — XX гасыр архитектоникасының нигез ташы. Чөнки азат кеше генә эшхәрәкәтен үзе сайлап ала, омтылыш-ниятен үзе билгели. Азатлык шулай ук авыр һәм хәтәр сынау да ул. Яңартып коруның казанышы — кешегә үзенең мәхәббәтен, нәфрәтен, сәяси кумирларга, үз тарихына, бүгенге халәтенә мөнәсәбәтен ачыктан-ачык ярып салырга, омтылыш-ниятләрен яшермәскә мөмкинлек бирүдә.

Теләсә кайсы халыкны нәрсә күтәрә? Ул — нәселне, кавемне, телне саклау инстинкты, эчке сиземе; тормыш басымына, фаҗигагә каршы бергәләп көрәшү, бергәләп дәррәү уяну көче.

1990 елның 30 августы татар халкына ничә гасырлар буенча көткән куанычлы, шатлыклы мөстәкыйльлекнең беренче карлыгачын алып килде. Киләчәге турында уйлаудан да курыккан, балаларының туган телләрен, тарихи үткәннәрен онытуы, рухи, иҗади байлыклары юкка чыгу белән, язмыштан узмыш юк дип килешкән, шул бичаралыгына риза булу хәленә җиткерелгән халыкның биле тураеп төште, йөзенә — нур, иреннәренә елмаю иңде. Өметсез кеше — канатсыз кош. Су буе сөйләп, төне генә түгел, көне дә йоклап узган вакыт үтеп бара кебек. Әмма изге теләк, максат олылыгы, рухи күтәрелеш үзеннән-үзе уңышка алып килми әле. Көрәшнең иң авыр, кайнар күз яшьләре агыласы көннәр әле алда.

Татарстан азатлык юлына Балтыйк буе халыклары һәм башка зыялы милләтләр үрнәгендә, парламентаризм, демократик сайлау аша чыкты. Татар халкының чыдам, сабыр, тыңлаучан холкы авыр, үкенечле юлында беренче тапкыр диярлек изгелек булып кайтты. Халыкның ихтыяр көче, азатлыкка омтылышы, милли аңы ахыргача сындырылмаган икән әле. Ул көтмәгәндә, уйламаганда ачылып китеп, үзенең хокукын таләп итә башлады. Аның азатлыкка омтылышы, рухи дәрте, көче идарәгә яңа килгән җитәкчелеккә дә тәэсир ясады, аны үз артыннан ияртте.

1990 елның 30 августы — дөньяда иң бәхетсез язмышка дучар ителгән, мәңгаенда башка милләтләр тамгасын йөртергә мәҗбүр булган халык өчен тарихи көн. Ул кибәнгә ныклап урнаштырылмаган салам кебек таралып беткән, сибелеп яткан, өзелгән чәчәк хәлендәге татар милләтен бергәрәк тупларга мөмкинлек бирер, дигән ышаныч та яңа күңелдә. Милләттәшләребез кайда гына гомер кичерсә дә, аның төп җире, туган йорты — Идел-Татарстан. Үзбәкстанда, Ашхабадта, Алма-Атада, Сахалинда, Норильскида, Донбасста яшәүче татар фикерләү рәвеше, уйлану үзенчәлеге, үз-үзен бәяләве ягыннан бөтенләй башка кавем, «телен «йоткан», мәдәниятен онытуга, ата-анасы исемен үзгәртеп, алыштырып, бозып әйтүгә разый, буйсынган, сындырылган, тамак ялына хезмәт итүче кол шәхес. Чөнки ул анда — килмешәк. Шуны яхшы аңлаган кырым татарлары, палестина халкы безгә үрнәк була алмыймы?

30 август үзбилгеләнүенә ышанмаган шикләнүчеләр әлеге Декларацияне «курчак уены» диләр. Хуш, Кеше тормышы курчак уеныннан башлана, димәк, татар халкы яңадан балачак чорын кичерә. Бәлки, киләчәктә буыннары ныгып, чын-чынлап аякка ба-

сып, ул да гайрәтле ир-егет булып җитешер, яшьлек романтизмы Болгар дәүләте, Казан ханлыгы дәверләреннән, олы тарихтан килгән акыл белән кушылып китәр.

Әүвәл үзәктә бу казанышны күрмәмешкә, белмәмешкә салышып, чын-чынлап гадәти бер җыен уенына кайтарып калдыру рухи өстенлек итте. Балтыйк буе республикаларының берсе дә җир, халык саны, җитештерелгән милли байлык күләме ягыннан Татарстаннан артык түгел. Күп яктан кайтыш илләр. Ә ул халык белән ничек санлашалар, җитәкчеләре үзләрен тәртипле, олылыклы, бәйсез, хәтта тәкәббер тотып, ил хуҗалары белән тигез, үзләре теләгәнчә диалог алып баралар.

Хәзер икенче чор — Татарстан суверенитетына каршы ачыктан-ачык көрәш башланды. Сәясәт кырыс нәрсә, ул хыялыйлык белән санашмый, балавыз сыгуны исәпкә кертми. Өченче милли дәүләтебез булырмы? Әллә янәдән гадәти бер өлкә дәрәҗәсендә калырбызмы? Бу сорауда — халык язмышы.

«Без» шигырендә үз халкының дәүләтләре, иреге югала баруны күздә тотып: «Гомерләр кучеп кәрван вә кәрван. Килеп кичте җиһаннан канча илләр», — дип язган иде Дәрдемәнд гасыр башында. «Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!», «Җиһан тормыш туен иткән чагында, Синең урының үлекләр аймагында» кебек төшенке, өметсез, пессимистик юллары да хәтергә килә матбугатта Солженицын, Хасбулатов, Травкин, Жан Миндубаев кебек милли мәсьәләдә чын неосталинчылар чыгышларын тыңлагач, мәкаләләрен укыгач.

Кешене су төбенә китте яисә яхшы чума икән дип мактаганчы, аның кире чыкканын көтәсе була. Илнең зыялылары элек-электән килгән йола буенча һаман да татарларга «игътибарлы». Ул сан буенча РСФСРда икенче халык булса да, аның вәкилләрен хөкүмәт биналарына да, депутатлар арасына да кертергә ашыкмыйлар. Юкса, Рәсәйдәге 100 түрәнең, 100 профессорның һәр өчесе татар милләтеннән булырга тиеш иде дә, бу коэффициент урам себерүчеләргә, кибетчеләргә, вокзал йөкчеләренә, шахтерларга нисбәтән генә үтәлә. Шулай да кемнедер бу мәсьәлә туктаусыз борчый, бимазалый. Мәсәлән, Марина Лебедева «И сколько в аппарате всех ЦК, например, татар?» — дигән сорауны куярга ашыга («Огонек», 1990, № 27).

Менә шул хәлләр, өермәле вакыйгалар хәзерге тарихыбызны аңларга омтылыш юлына алып чыкты да инде. Биредә сүз яшьләре, җәмгыятьтә тоткан урыннары, дөньяга карашлары, рухи һәм әхлакый кыйммәтләрне аңлау дәрәҗәләре төрле-төрле булган кешеләр, бер-берсенә тышкы яктан охшамаган хәлләр турында барачак. Заманыбыз казанышы плюрализм, фикер төрлелегенә, бәя үзгәлегенә, субъектив, шәхси үйлануларга юл ачты. Бу истәлекләр — шуның бер җимеше.

Чор тарихы өчен артык әһәмияте булмаган исем-фамилияләр, бер ише вакыйгалар азмы-күпме, әмма үзләре һәм якыннары танырлык, аңларлык дәрәҗәдә үзгәртелде. Демократия шуңа да мөмкинлек бирә. Аларның әле күбесе исән-сау, кешеләр арасында яшисе, эшлисе бар. Икенчедән, биредә фактларга гына ияреп бару, булган хәлләрне тәп-төгәл кабатлау алымыннан баш тартып, мәгълүм күләмдә, гомумиләштерүгә дә омтылыш ясалды.

## Үзәккә — табыш, халыкка — язмыш

Алтмышынчы-сиксәненче елларда Татарстан белән икесе дә типсә тимер өзәрлек, басса бакыр изәрлек таза ирләр — Фикрәт Табеев һәм Гомәр Усманов җитәкчелек итте. Дөрес, арада Рәшит Мусин ялтырап алды, әмма аның «ак йорттагы» гомере чикерткәнеке төсле генә булды: ай күрде, кояш алды үзен...

Без, «череп таркалган» Көнбатыш илләрдән аермалы буларак, җитәкчеләрнең тормыш юлы, эше, дөньяга карашы турында бөтенләй диярлек белмибез. Трибунадан укылган докладларда беркайчан да шәхес күренми һәм ул үзе язмаган чыгышта «яшь» дә алмый. Чынлап караганда, халык һәм республика язмышын хәл итү кулларына тапшырылган кешеләр биографиясе, аларның үткәне — шәхси «байлыклары» гына түгел. Ул — безнең хәзерге тарихыбыз.

Тарих бит ул монгол яуларының Бөек Болгар дәүләтен җимерүенә, шул ук фаҗиганең Казан ханлыгы язмышында да кабатлануына, изге патшага табынып яшәгән бабаларыбызның Разин, Пугач хәрәкәтләрендә катнашуына гына кайтып калмый. Татар халкы янә бер талпынып, физик җегәрен һәм рухи көчен ачып, күрсәтеп алган егерменче гасыр башы да, нәкъ менә шул казанышларга балта чапкан, кан, күз яше агызган унҗиденче елдан соңгы чор да, болай да кысылган Татарстанның җирен актарып ташлаган, кара туфрак өстенә төтен чыгарып утырган олы-олы заводлар, күп очракта татар агаена тәтемәгән катлы-катлы йортлар утыртылган, урманнарын, елга-күлләрен киптергән 60—80 нче еллар да — безнең аяныч тарихыбыз.

Яңартып кору чоры кешесенең республиканы бу хәлгә китереп теләүгә үзләреннән хәлиткеч өлеш керткән җитәкчеләрнең шәгыйле, язмышы, дөньясы турында күбрәк беләсе килү шулай ук табигый. Әнә «Огонек» журналы үткәннең «бөекләре»нә, социализм пәйгамбәрләренә, замана балаларына урынны бер дә кызганмый.

Юрганны башыннан ук бөркәнеп яту белән генә үткәнеңнән качып булмаган шикелле, җитәкчеләрне күңелдән сызып ташлавы кыен, маңкортлык бередә бигрәк тә килешле түгел. Табеев белән Усманов Мәскәүдәге югары эшләреннән китеп, үзләре Татарстаннан еракта яшәсәләр дә, фикерләү, күзаллау аларны тиз генә иҗтимагый мохиттән, аңнан чыгарып ыргыта алмый. Аннан соң һәр кеше үзе исән чакта бәясен алырга, арттан килгән буыннарның үзе турында фикерен ишетергә, белеп торырга тиеш дип уйлыйм. Башкача яшәештә күчемлелек дигән төшенчәнең мәгънәсе югалачак. Икенчедән, әле хәзер дә Татарстан дилбегәсе Табеев-Усмановларда тәрбия алган, торгынлык чоры кешеләре кулында. Бәҗрәга читтән кеше кертелми, кысып чыгарыла. «Онытылмас еллар сабагы» исемле мәкаләдә («Социалистик Татарстан», 14 сентябрь, 1990 ел) Сталин һәм Брежнев чорларында илдә бик күп кечкенә культикларның туүы һәм апарның күбесенә хәзер дә җип-яңгыр тимәү турында акыллы фикер әйтелә. «Күбесенең кешеләргә яхшылык эшләргә хәлләреннән дә килә югыйсә, мөмкинлекләре дә бар. Әмма эшләмиләр. Эшли дә белмиләр, изгелек дигән төшенчәне аңламыйлар да».

Татар матбугатында җитәкчеләр турында ачыктан-ачык язу гадәте юк диярлек. Әйтик, Батулланың «Колакчын Тафи» әкиятендәге төсле ниндидер кинаяә, төрттерү (өлкомның сөекле уллары бу әкияти сурәттә Табеевның нурлы йөзен танып алалар) булырга мөмкин. Шуннан ары үткәнебез юк. Нигездә куркаклык, юашлык, табыну, ышанудан бигрәк, хәбәрдарлык булмау ята торгандыр бу дәшмәүчелекнең төбендә. Әйтик, чит илләрдә дәүләт, хөкүмәт хуҗасы турында шәхси тормышына чаклы энәсеннән-җебенә чаклы беләләр, туктаусыз язып торалар. Бу төр әсәрләр халыкның тарихи аңы үсүгә ярдәм итә, тарих кешегә якыная.

## Үз кулында иде бәхет тезгене...

Кызыл фикер. Мин сине, әфәндем, элекке хуҗабыз, хәзер мактаулы пенсионер Фикрәт Табеев турында фикер алышуга чакырам. Мин аны биек тауга тиңлим. Ник дисәң, ул, беренче секретарь булып эшләү дәверендә, дөньяда зурлыгы буенча көндәше булмаган КамАЗ, ап-ак ташлы Чаллы, эшләп чыгарган малын 36 илгә озатучы Түбән Кама шәһәрен төзетеп, мәмләкәтебезне алдынгы үзәкләр дәрәҗәсенә күтәрде.

Кара фикер. Хак әйттең. Уңдырышлы, илгә ягып ашарлык, кап-кара туфраклы җир өстенә татар халкына бәхет тә, сөенеч тә алып килмәгән, урман-суларны корытып, агулы төтенен сулар һавага ташлап утыручы, тапканын читкә озатучы заводларны, төссез, милли чырайсыз шәһәрләрне коруга син мөкиббән киткән Табеев таудай өлеш кертте. Күзгегә үпкәләп булмый, анда без үзебез чагылабыз.

Кызыл фикер. Кара алтын табу буенча Татарстанны илдә беренче урынга чыгаруын нигә оныттабыз! Шул чорда йолдызстанга мендек, безнең нефтьне саткан валютага кибетләрне чит ил товарлары белән дыңгычлап тутырдык, аракыны да талонсыз, теләсә күпме эчтек. Борынгыдан килгән кара, көнче хисеңә юл куйма!

Кара фикер. Рәхмәт инде дустыңа. Черчиль бер әңгәмәдә: «Бай Рәсәйне хәерче ил ясау өчен әллә ни акыл кирәкми»,— дигән. Татарстан илен каһәрле төбәккә әйләндерде, чылтырап аккан, бала күз яшедәй саф сулы чишмәләр, инешләр, балыклы күлләр тозга, мазутка батты, республика, ахырзаманын көтеп, асты куыш упкын өстендә асылынып тора. Аның мәрхәмәте илә тишек чүмәнда утырабыз.

Кызыл фикер. Син Табеев эшчәнлеген берьяклы бәялисең. Казанга менә дигән аэропорт салдырды, татар театры аның заманында төзелә башлады, мәдәният институты ачты... Саный китсәң...

Кара фикер. Татар театрын сазлыкка, тыштан үзе дә бакага охшаган бинага куып кертүгә нигез салды анысы. Казанны галәмдә иң ямьсез, төссез, юлсыз калага әйләндерде шәһәр башына утырткан ярдәмчеләре белән. Дошманнары күпме генә лаф орсалар да, шул ук Кунаев, Алиев, Усубалиев, Шакировлар үз мәмләкәтләренең мәркәзләрен мәрмәргә киендереп, менә дигән урамнар, рәсми йортлар, кунакханәләр, шифаханәләр корып, хапыкларны күңелендә сөбханга паек бүлдылар. Табеев та, аңа алмаш түрәләр дә Татарстан байлыгын үзәккә, читкә озату ягын карадылар. Күпме байлыкның кая киткәнен берәү дә белмәде. Шундый җәмгыять төзедек шул 73 ел дәвамында.

Кызыл фикер. Табеевның яхшы якларын юри күрмәмешкә салынасың. Чаллы, Түбән Камалар белән мавыгып, Казанга игътибары җитмәде анысы. Ә шулай да... Өлкә комитеты өчен нинди затлы бина корды, Ленин мемориалын да ул салдыра башлады. Чехов базары артындагы йортларның матурлыгына игътибар ит.

Кара фикер. Шунда киткән кыйммәтле ташларны, Әрмәнстаннан ташыган туфларны Кабан күленә, Болак елгасына тотса, шәһәрдә һава яхшырыр, бер ял урыны булыр иде. Адәм хуры ич. Балтыйк буе илләрендә кала үзәгендә шундый ямьле күп торса, күптәннән илаһи бер күңел ачу, чит ил кунакларын кабул итү, эстетик тәрбия үзәге булып китәр иде.

Кызыл фикер. Үзе татар мәдәниятен тирәнтен белмәсә дә, һәрдаим әдәбият үсешенә ярдәм итәргә тырышты. Аның заманында Дәрдемәнд, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй,

утызынчы елларда репрессиягә эләккән язучылар әсәрләре халыкка кайтты. Әнә Усманов, үзе укымаган, белмәгән Гаяз Исхакый шәүләсе белән сугышып, барлы-юклы абруен гына төшерде.

Кара фикер. Шаяртма, дустым, кая барсын ди ул. Әнә руслар шул чорда 1917 елгы большевиклар инкыйлабын шайтан уены, каһәрле көннәр дип язып чыккан, Г. Исхакый төсле үк читтә үлгән И. Бунинnарны күтәрделәр дисәң дә күтәрделәр ичмасам! Ә Усманов, Г. Исхакыйны бастырып чыгаруга каршы көрәшендә, бөтен чамаларын онытты. Ә нәтиҗәсе сиңа мәгълүм.

Кызыл фикер. Фикрәт аганың мәсләге — кеше бәхете иде, минемчә. Республиканың бәйсезлеген, мөстәкыйльлеген ныгыту, милли кадрларны үстерү өчен армыйталмый көрәште.

Кара фикер. Татар мәктәпләрен корытуны мәгърифәткә өлеш кертү дип санасаң, син хаклы. Аннан килеп, хәбәрдарлык дигән татлы ризыкны кабып та караганың юк бугай синең. Газета укуны да вакытны заяга уздыру дип саныйсың бугай. «Татарстан яшьләре»ндә 1990 елда гына басылган «Халык, аның сыйфаты һәм корбан такәләре» исемле мәкаләсендә профессор М. Госманов Табеевның 1977 елда СССР Югары Советында, безгә автономия биргән өчен, рәхмәтләр әйтә-әйтә чыгыш ясавы хакында бик вакытлы искә төшерә.

Аннан килеп, язучылар, галимнәр арасында да Табеев белән Усманов иптәшләр турында мөкиббән китеп мактаган сүзләрне ишеткәнем юк. Аларга чакпы эшләгән Семен Игнатьев менә гел уңай яктан телгә алына. Сүзне әүвәл Г. Бәшировка бирик. Соңгысына ул мондый бәя бирә: «Әдәбият-сәнгать өлкәсендә милли кадрларның кадерен белә, аларга төрлечә ярдәм итәргә тырыша иде». («Социалистик Татарстан», 1991, 18 январь).

М. Мәһдиев дәвам иттерә: «Укымышлы халыкның теленда бер генә шәхес булды: обком секретаре. Әйе, Семен Денисович Игнатьев — әнә шул рус кешесе ул елларда өлкә комитетының башында тора иде. Имеш, шул әйткән: ачыгыз шундый йорт, дигән, анда милли ашлар пешерегез, әмма хәмер кертмәгез, дигән. Карагыз ул алфавитыгызны, рәтләгез, дигән... Ул шәхес, безнең кайсы милләт кешеләре икәнлегебезне аңлата язып, бераздан Мәскәүгә эшкә китте. Элек-электән килә инде ул: юньле җитәкче дә, юньсезе дә Казанда озак тора алмый». («Казан утлары», 1991, 1. 114 б.).

Кызыл фикер. Бу сүзләргә беркадәр тәнкыйть белән карарга кирәкмиме икән? Бу — өлкән туган вәкиле алдында ясалган реверанс кына түгелме? «Иелгән башны кылыч кисмәс» кебек мәкаль башка халыкларда юк диярлек. Билне бөгеп, тезне чүгеп яшәргә өйрәнгәнбез. Ә үз милләтебездән үсеп чыккан шәхесләрне бәяләп җиткермибез түгелме?

Кара фикер. Минемчә, Г. Бәширов һәм М. Мәһдиевнең кемгәдер ярарга, куштанланырга тырышыр вакытлары үткән. Икесе дә — үткен, туры сүзле әдипләр. Мин аларга ышанам.

Кызыл фикер. Кызык адәм син! Авызын ачса, үпкәсе күренеп торган татар язучысын җәлләп, республиканың беренче кешесе ачлы-туклы утырмас бит инде. Син Табеев эшчәнлеген, аның шәхесен дөрес бәяләү дәрәҗәсенә күтәрелә алмагансың. Соңгы соравымны бирәм дә, чираттагы корылтайга, тамаша карарга китәм. Татарстан башында хәзер дә Табеев яисә Усманов утырган булса, 30 августта мөстәкыйльлек игълан ителер идеме? Бу декларация дигәнегез комнан бау ишү белән бер түгелме?

Кара фикер. Үз фикеремне көчләп такмыйча, шагыйрь Роберт Миңнуллинның Татарстанга бәйсезлек алып биргән тарихи сессиядә ясаган чыгышыннан бер өзек китерәм. Җавапны шуннан табарсың, шәт. «...кайбер иптәшләр суверенитет идеясен дискредитацияләргә тырышалар, янәсе ул өстән төшерелгән. Шулай булган булса икән! Безнең алга бу проблеманы тарих үзе куйды. Әгәр аны берәр лидер күтәреп чыкса, ул 1985 елның апрелендә үк куелган булыр иде. Ә шушы арада һәр милләт, һәр республика, иртәме-соңмы, аны хәл итәргә алыначак».

Гафур Коләхмәтовның «Ике фикер» пьесасы геройлары безнең көннәрдә яшәсәләр, менә шулайрак сөйләшерләр иде дип уйлыйм.

Чыннан да, Табеев исеме, соңгы елларда гына — яңартып кору җилләре исеп, демократия теләсә нәрсә сөйләргә, язарга, кычкырырга мөмкинлек биргәч кенә — теләрдән төшеп килә. Ә шулай да ул шәхесне дөрес бәяләргә омтылу плюрализм заманында файдалы булыр дип уйлыйм.

Табеев — Хрущев чоры «җепшеге»ндә кинәт күтәрелгән, тышкы яктан ифрат бәхетле кешеләрнең берсе. Ул административ баскычларны «тизләтелгән юл» белән үтеп (университет укытучысы, өлкә комитеты бүлеге мөдире, идеология буенча секретарь), Татарстан җирендә мөмкин булган иң югары дәрәҗәгә яшьли һәм җиңел ирешә. Тоталитар режимның сайлап алу машинасы ялгыш җибәрми диярлек. Беренче секретарьга үз телен, мәдәниятен белү мәҗбүри түгел. Ул үзен үстергән кешеләргә, дөресрәге, системага хезмәт итәргә, өстән иңгән һәр фәрманны, орчык шикелле бөтерелеп, сүзсез җиренә җиткерергә тиеш.

Милләтнең таза, мөстәкыйль көчләре, зыялылары, затлы шәхесләре юкка чыгарылгач, алар урынына үз ана телен, халкының фәлсәфәсен, гореф-гадәтен начар белгән,

кубрәк башка мохиттә тәрбияләнгән буын кинде. Табеев — шул чорда нигыган, аның яхшы һәм яман якларын сеңдергән шәхесләрнең берсе.

Татарстан мәмләкәте аны теләп, яратып кабул итте. Ирекле, азат тормыш күрмәгән, Көнбатыш демократиясенең исен дә иснәмәгән татар халкы, әйтергә кирәк, руслар кебек үк, изге патшага, революциядән соң яхшы җитәкчегә табынып, аңа ышанып яшәде. Янәсе, ул гына халыкка бәхет алып килә, йортлар төзи, киемгә, ипигә туйдыра ала. 1917 елдан соң, аңлашылса кирәк, совет властен да, динне дә партия җитәкчесе алыштырды. Ә халык үзе әлегә чаклы бервакытта да партия башына куелган кешеләрне сайлауда катнашмады, ул үзенә китереп сылаган теләсә кемне яратырга, аңа ышанырга, табынырга тиеш иде.

Сүз дә юк, Табеев көчле кеше, холкы белән романтик булса да нык ихтыярлы һәм кырыс шәхес булып чыкты. Ә андый зат башкалар өстеннән хакимлек итәргә ярата, үзүзенә бик ышанучан була. Ә ышанычны инде бөтен тормышны, яшәешне, әхлакны, ихтыярны үзенә буйсындырган партия диктатурасы тәэмин итә.

Әйе, йолдызы Татарстан күгендә кинәт кабынды, дан тиз һәм җиңел килде. Аны иркенлеккә, дан-шөһрәткә ике канат алып чыкты: нефть һәм КамАЗ. Табеев заманында татар нефте елга булып акты. Без, табигатьнең беркатлы балалары, шуңа шатландык, горурландык, янәсе, «Дуслык» үткәргече буйлап безнең кара алтын ага, бөтен социалистик дөньяны без җылытабыз. Чынлыкта исә, нефть татар халкына бәхет тә, шатлыклы тормыш та алып килмәде, башка халыкларга бай, тук яшәеш биргән бу байлык татар халкына экологик фаҗига гына калдырды. Киләчәктә нәрсә буласын әйтүе дә кыен.

Аннан КамАЗ килде. Яңа төзелеш халыкта шулай ук дәрт, рух күтәренкелеге уятты. Татар халкы аңа нииндидер өметләр баглады.

Табеевның күп тапкырлар, бу төзелеш өчен көрәш-тартыш көчле булды, ул чынлыкта Башкортстанда салынырга тиеш иде, ләкин без Политбюроны, иптәш Брежневны, шушы урын һәр яктан да иң кулае, дип ышандыра алдык, дип олы трибуналардан чыгып мактанганы әле дә хәтердә.

Чаллыдагы төзелеш уяткан күтәренкелек, өметләр озакка бармады. Борынгы җиребездә, Чулман буенда шәһәр күтәрелде. Тирә-як татар авыллары юкка чыкты.

Гигант төзелешләр — иң көчле ассимиляторлар. Яңа, зур шәһәрләрдә халык йолалары, әдәп, әхлак бозыла, аларны гомуми тормыш, ялган, ясалма җыеннар, олы-олы тулай тораклар алыштыра. КамАЗ төзеп, Чаллы белән рухланып йөргәндә, бу төзелешләрнең татар халкының үз җирендә азчылык милләт булып калу ихтималын сизенсәк тә, әйтергә базмадык. Ә хәзер инде соң.

Табеев үз халкына каршы аңлы геноцид алып бармаса да, аның «гигантомания чире», янсә кеп-кечкенә Татарстан җиренә туктаусыз завод-фабрикалар утырту, шәһәрләр кору белән мавыгуы татар милләтен кысуга, аның үз туган җирендә азаюына, урыслашуына алып килде.

Табеевның зиһене һәм сүз әзләп кесәгә керми торган осталыгы турында халык яратып сөйли иде. Ул эшли башлаган елларында һәр олы колхоз-совхозның хуҗасын хәтердә тоткан, туган елын, биографиясен белгән, гаиләләрен дә өйрәнергә тырышкан диләр. Аның турында гыйлемле, фикерле, колачлы шәхес, дигән бәя киң таралды. Чыгышларыннан үзем дә биһуш булган заманнар бар иде. Башка милләттән булса, үзен күтәргән Хрущев тәхетендә озаграк утыра калса, аның Политбюрога эләгерлек куәте бар иде. Әмма теләсә кайсы эшлекле, бер урында озак утырса, аның көчле яклары ачылып бета дә, матур төсен җуя башлый. Яңа лидерның чыгышын: «Кара син аны ниндн акыл иясе! Әйтсә дә әйтер икән! Адәм баласына ходай бирсә дә бирер икән!» — дип тыңлаган кешеләр, җиде-сигез елдан соң, «бер үк балык башын күпме чәйнәп була», «туйдырып бетерде» дип, туктаса ярый па ул «демагог», «кызылавыз», дип сөйләнә башладылар. Тормышның кырыс закончалыгы 60—70 нче елларда танылган политологлар Табеев белән Беляевларны да кызганмады. Халык алардан да туйды. Сталин шуңа күрә дә аудитория каршына бик сирәк чыга торган булган, диләр.

Кешене, бигрәк тә олы җитәкчене бер очрашудан, берничә тыңлаудан гына тануы кыен. Йомырка салмас борын, чебешләрне санап булмый, диләр. Вакыт үзу белән кылган эшләрнең нәтиҗәсе ачыла. Иң әүвәл аның үз янына ипигә май сөртеп торучы куштан кешеләрне җыеп алуы күренде. Өлкомның сөякле уллары барлыкка килде.

Табеевның җитәкче кадрлар сайлап алуда үз алымнары, үз «селекциясе» бар иде. Ул хакимлек иткән дәвердә (егерме елга якын) төрле дәрәҗәдәге идарәләргә өстән аска карап сөйләшә торган, озын буйлы, таза, кырыс, имансыз ир-егетләр килде. Гомуми кагыйдәдән чыгармалар булса да, күбесе комсомол мәктәбен узган иде. Комсомол дип аталган сугышчан оешмада кеше үз халкына, аның теленә, мәдәниятенә мәхәббәттән башка һәр тарафтан тәрбия алды, аерым бер «җитәкче булу» мәктәбен үтте. Комсомол, аннан партия баскычы буйлап рәхәт тормышка үрмәләргә бирелгән мөмкинлек апарга якты маяк, өмет, таяныч иде. Күбесе — милләтен югалткан татарлар.

Гомумхалык мәдәниятен үзләштереп, мәҗлес күтәрә, теле-телгә йокмый торган әрсез, елгыр, үз өстенә берни алмаучы, ертлач кешеләрдән торды бу төркем. Аларны шул чорда үк эш өчен камыттан чыгардай булып көчәнмәүләреннән, кигән киемнәреннән, Мәскәү каршында кулга эләккән куян кебек калтырап торуларыннан танып була иде.

Кубесе әле хәзер дә — татар «державасы» башында, яңартып кору өчен көрәштә.

Апар мөкиббән киткән әйбер дә арзанлы булыр иде. Әйтик, Табеев үзенә тиредән кепка тектерсә, көт тә тор, бер айдан өлком, комсомол җитәкчеләре, районнарның беренче секретарьлары, райисполком һәм райпо рәисләре шундый ук фуражкалардан йөрергә тотына иде.

Табеевның оста сунарчы булуы да халыкка мәгълүм. Ул, мәсәлән, Алабуга урманнарыннан болан, кабан, бүре, куркак куян кебек җәнлекләрне генә түгел, юл уңаенда кадрларны да чүпләп үз янына алып китә торды. Һәр мисалда — язмыш уены. Үзем төгаен белгән, шаһиты булган хәл-әхвәлләргә генә тукталам.

Табеевның бер килүендә Алабугада комсомол секретаре, аннан шәһәр комитетында идеология хуҗасы булып эшләгән Н. И. Демидов Түбән Кама башкарма комитеты рәисе итеп күчерелде. Аннан — өлкомда бүлек мөдире, эчке эшләр министры. Һәм шул ук юнәлештә Мәскәүдә шактый югары урын били. Эре сөякле, олы гәүдәле, салмак хәрәкәтле, киң, түгәрәк битле Николай Иванович бер күрүдә үк хуҗага охшый, аның мәхәббәтенә, игътибарына лаек була. Хәер, ул үзен тота белә, аның адәм баласына хас ярарга тырышуы ялагайлыкка күчми, үзенең һөнәрләрен кечләп такмый, Есенин шигырьләренең ниндиен кайсы вакытта укырга кирәклеген төгаен сиземли. Кыскасы, тирән психолог булуы башка җитешсезлекләрен каплабрак тота. Өлкә комитетында утырганда аның эш өстәле пыяласы астында машинкада басылган рус халык мәкальләре, әйтемнәре, фразеологик гыйбарәләре ятуын бүлек егетләре гаҗәпләнү катыш мактап, хәтта горурлык белән сөйлиләр иде. Бер кәгазь ятланып бетүгә, аны икенчесе алыштыра. Ә бит иң кирәкле җирдә, вакытында кыстырып куелган тапкыр җөмлә, канатлы сүз озын-озын нотыгыңны егып салырга мөмкин. Шуннан соң бүлек мөдире үз эше белән шөгыльләнми дип әйтергә кемнең теле күтәрелер?!

Николай Иванович үзе турында гына кайгырта торган тар күңелле кеше булмады, ул үзе артыннан энекәшләрен дә тартты, җаваплы урыннарга урнаштырып калдырды. Патшалар да якыннарына, үзләренә охшаган кешеләргә шундый җиңеллек белән урыннар тарата алмаганнардыр, шәт. Кадрлар сайлауда сәләт, әхлак, әдәп, намус кебек төшенчәләрнең сукыр бер тиенгә тормаганлыгын күзаллау кыен булмастыр бу мисалдан.

Татарстанда эшләвенең соңгы елларында мәмләкәтебез башлыгы күп вакытын Чаллы, Алабуга тирәсендә уздыруы нәтиҗәсендәме, әллә башка берәр сәбәбе булдымы, хәзер кистереп әйтүе кыен, әмма Шишкин урманнары арасында армый-талмый халыкка хезмәт итеп яткан җитәкчеләрне бер генә мизгелдә дә тынычта калдырмады. Бер-бер артлы диярлек Алабуга фирка оешмасының беренчесен, идеология сәркәтибен, юллар төзү оешмасы җитәкчесен үзе янына, Казанга алып китте.

Б. Г. Масленников Алабуга шәһкомына әле күптән түгел генә культура-агарту училищесыннан күчеп килгән иде. Ленинград мәдәният институтын тәмамлаганнан соң, ул шунда укытучы итеп җибәрелә, директор урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелгәч, районга баш идеолог итеп билгеләнә. Язу-сызуга маһирлыгы бар, әмма пропаганда эшенә, милли мәсьәләләргә тирәнтен кереп торуны бер дә өнәми. Хыялы — үзе эшләп килгән уку йортына җитәкче булып кайту һәм балык тотып, гөмбә җыеп, вакытында ашап, кипкән җиләк белән чәй эчеп, ватылмыйча, иплән кенә яшәү. Ләкин бер яхшы сыйфаты аның «башына җитте», гади, кешелекле хыялларын чәлпәрәмә китерде. Җиренә җиткереп шигырь укый белә иде ул. Тавышы Демидовныкы шикелле үк көчле булмаса да, тәэсирлелек, эчке аһәң, моң белән алдыра. Табеевның нарат урманына чираттагы сәфәрендә Алабуганың беренчесе үзе белән идеологын да нәртә. Күңел ачу, өлком хуҗасының кәефе йөрәген рухи тукландыру сәгате суккач, сүз Борис Григорьевичка бирелә.

Ни хикмәттер, бүген Есенинның «Персидские мотивы» бәйләме дә, «Собаке Качалова» шигыре дә дулкынландырмый олы кунакны. Битараф ай төслә утыра бирә чиклавек төше ашап. Шуннан тигез йомры нарат бүрәнәләр, буялмаган сап-сары идән түшәмнәр, мул өстәл, тәрәзәдән өйгә ыргылган куе томан бунтарь ир Стенька Разинны җәзага алып баруның шаһитлары булып китәләр. Е. Евтушенконың «Братская ГЭС» поэмасыннан өзек укыла. Олы хуҗа дулкынланып, әсәрләнеп, урыныннан сикереп торып, ишекле-түрле йөренә башлый, әйтерсең лә ниндидер казакны түгел, ә аның әтисен, шундый ук дуамал көрәшчене соңгы юлга алып китәләр. Ә шигырьче бу мәсләкне күреп, тимерне кыздыра бара, кыздыра бара. Хисси уртаклык мәҗлестә утыручы барлык кешене берһаштерә, якынайта.

Табеев чәркәсен кулына алып: «Рәхмәт! Молодчина! Иртәгә минем белән Казанга китәсең! Башка сорау бирмәгез!» — ди.

Шул сәяхәтеннән соң Борис Масленников Алабугага фәкать ганиәсен Казанга, менә дигән квартирага алып китү нияте белән генә кереп чыкты. Сез инде Табеев аны культура бүлегенә яисә мәдәният институтына алып киткәндер дип фараз кыласыздыр. Юк шул, андый олы кешеләрнең хыялы артыннан очар кош та өлгерә алмас, бөркет тә канаты талып, тыны бетеп, арып калыр. Алабуга һәвәскәрен ул республика дәүләт куркынычсызлык комитетының иң мөһим бүлегенә мөдир итеп куя. Гомерендә бу төр эш белән тамчы да шөгыльләнмәгән кеше КГБга килеп утыра.

1989 елның җәендә, Идел буенда, элеге оешма кешеләренең җиләк-җимеш бакчаларында булырга туры килде. Авырлык белән таныдым Борис дусны. Башында — соры,

җиңел эшләнә, өстендә — гади тукымадан тегелгән пижама тибындагы кием, кулында — резина кәлүшә. Бакчасына су сиптерә. Кочаклашып күрештек.

— Менә шулай көтмәгәндә килеп эләктем әлеге өешмага. Иң олы хуҗа тәкъдим иткәч, кандидатурама каршы килүче булмады. Аннан соң Магаданда хезмәт иттем, шунда исәнлегемне югалтып, инвалид булып кайттым. Еракка чыгып китүемнең сәбәбе? Мин, үзең беләсең, «Табеев кадры» идем. Өлкомга башка җитәкче килгәч, минем өчен һавалар үзгәрде... Алабугамда гына рәхәтләнеп утырсам, гомерем озынрак булыр иде. Нишлисең инде, язмыштыр,— диде ул көрсенеп.

Һәр очракта да Табеев кадрларны эзләп, табып алып, үстереп кенә яшәде, дип уйлау дөрес булмас. Мисал кирәк дисәгез, рәхим итегез.

Татнефть берләшмәсенең элеккеге генераль директоры, хәзер СССР нефть промышленносте министрының экономика буенча урынбасары Әкълим Мөхәммәтҗановны кара алтын табылган якларда белмәгән, танымаган кеше юктыр. Туры мәгънәсендә буразнадан күтәрелгән шәхес: педучилище тәмамлый, мәктәп һавасын сулый, республикада нефть табылгач, бораулаучы ярдәмчесеннән башлап, Мәскәүгә чаклы барып җитә. Әтисе сугышта үлеп, кулында әнисе белән ике энесе калу, аның холкын чыныктыра, яшәү өчен көрәшергә өйрәтә.

Милли мәсьәләләр турында сөйләшергә, суверенитет өчен көрәшергә бик яратмаса да, ул халык мәнфәгатьләрен җиргә салмады. Эшләгән бер җирендә кыйммәтле җиһазлар белән бизәлгән сәламәтлек биналары, ял йортлары, мәдәният сарайлары төзеп калдырды.

Хәер, туганнарын да, балаларын да рәхәттә яшәтә белде, Америкада, Гыйракта эшләп кайтырга телисеңме — рәхим ит, Казан һавасы туйдырса, сине Мәскәүдә җайлы эш, әзер фатир көтә.

Кыскасы, татар халкына элек-электән хас эш йөртүгә маһирлык, төрле милләт кешеләре белән уртак тел таба белү, изгелеккә яхшылык белән җавап бирер, үз хасиятләрен дә юнәтергә онытмыйча, булганлык кебек инде пыскып сүнеп барган сыйфатларын уята, яңарта алды Әкълим әфәнде.

Шул ук вакытта аяз күк астындагы җылы урыны өчен аңа да һәрдаим көрәшергә туры килә иде. Партаппарат аны чак кына, ияреннән сөйрәп төшереп, туплпарсыз калдырмады. Мөхәммәтҗановка мөнәсәбәтендә Табеевның кадрларны тәрбияләү, сайлап алу, «үстерү» юнәлешендәге стиле, «милли үзенчәлеге» ярылып ята.

Әкълим Касыймович Алабуга нефть табу идарәсе башында утыра. Эше гөрләп бара, күчмә кызыл байракларны, мактау кәгазьләрен, премияләрне алып кына өлгер. Әмма шуңа да карамастан, үзенең шәхси теләге белән бөтенләй санашмыйча, тоттылар да аны күз уңыннан ераграк җиргә, Бөгелмәгә, «Дуслык» нефть үткәргечене күчереп куйдылар. Бер дә китәсе килмәде дускайның Алабугадан! Сәбәбен әйтүче булмады: мөстәкыйльрәк кыланып ташлаганмы, кунак-кунак уйнаган өчен акча түләгәндә чыраен сытканмы — өздереп әйтүе кыен.

Мөхәммәтҗанов Әкълим туганда ук күлмәкчән булгандыр, мөгаен. Бер ел үтәрүтмәс, Табеевны Әфганстанга илче итеп җибәргәч, Татарстанга хуҗа булып Рәшит Мусин билгеләнде. Кыска гына вакыт аралыгында да ул, Юрий Андропов шикеллерәк, үзе турында халыкта уңай тәэсир калдырып, изге эшләр башкарып өлгерде, аерым алганда, «Татнефть» берләшмәсенә яңа «генеральный» билгеләп өлгерде. Ул — куылган, җәберсетелгән Әкълим Мөхәммәтҗанов иде.

Халык җитәкченең һәр адымын, һәр хәрәкәтен күзәтеп, әйткән бер сүзен игътибар үзәгендә тота. Юк кына яхшылыгы изге бер эш сыман күңелләргә кереп калса, икенче яктан, аның кечтеки генә ялгышы да, зур итеп, күпертеп күрсәтелә. Хаталана башлавының бер күрсәткече булып аның турында мәзәкләр туа башлый. Хрущев, Брежнев турындагы фольклор — күпмилләтле совет халкының «уртак байлыгы». Аларның бит әле һәр төбәктә ихтыярларын гамәлгә ашыручы пәйгамбәрләре, бәләкәй аллачыклары була. Ә инде үз республикасында беренче секретарь — тулы хуҗа, теләсә нәрсә эшли, теләсә ничек кылана.

Табеевның чикләнмәгән иректән, тулы хакимлектән килгән сәерлекләре, кыланышлары турында сөйләкләр киң тарала, яраннары үзенә җиткерә бардылармы, әллә куркып, мәдхия җырлап кына йөрделәрме — ул хәтлесен әйтә алмыйм.

Татарстанда яшәүче күпләрнең язмышы ахыр чиктә Табеев кулында иде. Сүзе бер — әйтте, бетте, бәхәс тә, шик астына алу да мөмкин түгел. Бер үк вакытта кешелекле дә, аждаһадай явыз да була белгән Табеевка охшап калсаң, наз-нигъмәт эчендә йөзәрсең, ә инде аның, социализм теориясе төсле, сикәлтәле холкына җайлаша алмасаң, үзеңә үпкәлә. Пленумда да, олы тантаналарда да күрмәсләр. Бигайбә, үзең гаепле.

Шундый хәл булгандырмы, юктырмы, гөнаһысын тулысынча өстемә ала алмыйм, әмма Алабуга якларында җае чыккан саен, гыйбрәтле бер вакыйганы бәян итәргә бик тә ярата иде агай-эне.

Табеев Сармангамы, Актанышкамы (әһәмияте юк), томшыгының сарысы да кипмәгән яшь кешене беренче секретарь итеп билгели. «Ике айдан үзем килеп, эшеңне карап китәрмен»,— ди. Яңа хуҗа, вакытның тиз агышына зарлана-зарлана, Табеевны каршы алырга әзерләнә: чүпләрне утата, юлларны рәтли, кунарга түшәкле урыннар әзерли. Иң кайгыртканы — төшке аш. Табеевның сәерлекләреннән хәбәрдар булмаган түрә

нечкә билле бәллүр рюмкалар тездерә, күрше районнан алтын-көмеш кашыклар, пычаклар, чәнечкеләр юнәтә. Өстәлдә муллык, шешәләрдә кояш нурлары уйный — искитмәле матур, гаҗәеп нпле итеп тезелгән барысы да. Яшь хуҗа һәр кашыкны үзе сөртеп йөри.

Табеев машинадан төшеп, өстәлдәге биниһая байлыкка күз салгач: «Урып-җыю вакыты хәзер. Без ресторанда да, ялда да түгел. Барысын да гади стаканнарга, гади кашыкларга алыштырыгыз!» — дип боера.

Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, һәммә нәрсә бар, ә стаканнар юк. Чабыш, йөгереш, пышылдашу, халат кесәләрен актару, машина бардачокларын тикшерү, катыклы чиләк янындагы ун тиенлек стаканны сабын белән юулар башлана...

Табеев, тәмәкесен пыш-пыш китереп, урман аланындагы табын тирәсендә йөренә башлый. Ачуы чыкканы борын тишекләренең киңәюеннән, битендәге тимгелләрнең төсе үзгәрүеннән күренеп тора. Этләшә торгач, берничә стакан табыла. Тирләп-пешеп беткән сәркәтип аз-азлап, калтырана-калтырана аракы коя. Аны да, ярдәмчесе чеметкәч кенә, тутырып сала.

Табеев стаканын кулына алып, басып торган төбәккә уңдырыш теле дә, сүзне озынга сузмыйча эчеп тә куя. Озатып йөрүчеләр аңа кушылалар. Яшь секретарьның бер дә күрәзәчелек сәләте булмагандыр: иренен тидерә дә кире куя: янәсе, олы хуҗа алдында салып утыру килешмәс, аннан соң әле көн озын, эшләр дә күп. Юыртып барган тулпарның абынып егылуы бер дә юктан була икән шул!

Табеев салатларга, кыздырылган үрдәк, тутырылган тавык итләренә, тастымал белән ябып куелган бәлешләргә кагылмыйча, кечкенә кыярның яртысын уртлый да, янындагы гвардиясенә:

— Бирегә анонимщик утыра. Киттек,— ди.

Ашау-эчүгә исе китмәүнең сәбәбе аңлашылса булыр, күрше районның чигендә үк икенче бәләкәй хуҗа нарат агачы төбендә кайнар бәлеш күтәреп басып торыр...

Ике атнадан «шикаятьче»нең урып-җыюның барышы турындагы хисабы бюрода карала, әлбәттә, эш начар дип табыла. Егет, сират күперен чыга алмыйча, югары эшелоннан бөтенләйгә төшеп кала. Уеннан уймак чыгара да куя Табеев. Элеккеге беренче хәзер бер колхозда агроном булып кына эшләсә дә, Табеевны көткәндә район хуҗалары киңәш-табышка аңа килә торган булганнар, имеш.

— Карале, хуҗаның иртәгә безгә керәсе. Син аны кабул иткән кеше. Нәрсә ашаттың, ни эчерттең?

— Юкка борчылмагыз. Аның бар ашау-эчүе бер стакан аракы да ярты кыяр,— ди икән теге, күз кысып.

Табеевка охшый белгән агай-эне ак мыек рәхәттә, халык әйтмешли, балда-майда йөзеп калды. Әйтик, ул елларда «Табеев дачасы» дигән серле бер гыйбарә яши иде. Үз исеме белән йөртелгән кайбер дачалар аның төшенә дә, бәлки, Әфганстанда үлем арасында йөргәндә генә кергәндер. Шул сыптау белән байтак район хуҗалары үзләре өчен кеше күзеннән яшерелгән, табигать кочагында менә дигән ял итү урыннары ясатып калдылар. Татарстанның кайсы ягына гына барып чыкма, урындагы түрәләр белән бераз аралашып, күңелләрне җепшетеп алгач, сиңа Табеев йортын, Табеев куышын, Табеев умарталыгын, күпен күрсәтә башлыйлар. Ул өй йә тау итәгеннән бәреп чыккан чишмә буенда, йә серле инеш ярында, йә матур аланда, юкә, нарат урманы эчендә урнашкан булыр.

«Табеев йортын» кормаган райком секретарен кешегә санамыйлар иде ул чорда. Вилласы булмаса, аның белән теләр-теләмәс кенә исәнләшәләр, республика андый мәгънәсез районга ашламаны, машинаны, тактаны азрак бирел, икмәк, йомырка, йон, ит тапшыру йөкләмәләрен өсти тора. «Дача» республиканы кулында тота, әллә нинди хыялларны үзгәртә, өметләрне чәлпәрәмә китерә.

Районнарда шундыйрак алым киң таралган иде. Райком башлыгы, «Табеев килә», «иртәгә безгә хуҗа керә», дип, бик мул өстәлләр әзерләтә. Табеев ул вакытта республикадан бөтенләй читтә булырга да мөмкин. Якыннары белән үзе мунча чабына, шашлыгын, тутырган тавыгын, чөгендерле катыгын авыз итә... Иртән моны көтеп торучы райком аппаратына хәбәр итәләр: хуҗа сезгә сәлам әйтергә кушты, ашыга иде, сәгать ярым гына булды, безнең чәчүнең барышы белән бер дә канәгать түгел, нык әрләде, хәзер дә кызарып утырам (ә кызарып утыруның сере башкада икәнлекне үзләре генә белә)...

Романтиклыгы сабыйлыкка барып тоташа иде Фикрәт аганың. Алабуга, Чаллы якларында очрашуларны санамаганда, аның эш бүлмәсендә өч тапкыр булырга туры килде миңа. Бәлки, «насыйп булды» дип язаргадыр, аның тарих дәресләр. Зур авырлык белән планга кергән пединститут тулай торагын төзү туктатылгач, кердем бер мәртәбә. Шалтыратты, ярдәм итте. Ә икесендә үз теләгемнән башка, фән һәм югары уку бүлеге егетләре, «хуҗага күрсәтергә, добросын алырга», дип алып керделәр. Берсе — проректор, икенчесе ректор булып расланганда. Әйтергә кирәк, Табеевның Алабуга педагогия институтына мөнәсәбәте хәерхак, мәрхәмәтле, дәресрәге, игътибарлы булды. Ректор итеп үзе белән бер чорда, бер группада укыган, күрәсең, ышанган кешеләрдән — гел тарихчыларны җибәрү ягын карады. Бәлки, яраргa тырышып, ярдәмчеләре, урынбасарлары шулай эшләгәндер.

Ике керүемдә дә, өстәл артыннан каршыга чыгып, зурлап исәнләште. Сүзләр бер үк:

— Авыр йөкне җилкәңә салырга ризамы?

— Ышанып тапшырсагыз, риза.

— Алабуга институты өчен бөтен Казан вузларын бирергә риза мин үзем. Авыл өчен иң кирәк кешеләр әзерли. Казаннан җибәреп кара провинциягә берәрсен! Шиша два. Әллә нинди сәбәпләр юллый, Казаннан чыгып китми. Нәрсә табалар инде сасы калада? Синең белгечлегең нинди әле?

— Татар әдәбияты. Күбрәк тәнкыйть өлкәсендә эшлим.

— Сез, телчеләр, кызык халык. Өч наратмы, каенмы арасында тик адашып йөрисез. Берегез «эшләпә», дип язу дөрес, ди, ә икенчегез сүзне болай ук бозарга ярамый, «шләпә», дип әйтергә кирәк, ди. Өченчегез «шляпа», дип урысча калдырырга тәкъдим итә.

Үз монологыннан арып, миңа карап куйды да нәтиҗә ясады хуҗа:

— Менә син шул мәсьәләдә разберись, внеси ясность и миңа доложи. Пока!

Менә шундый проблемаларны куярга да җитешә торган иде Әхмәтҗан агайның булган егете, хәзерге Мәскәү пенсионеры.

## Бәйрәм мәңгелек булмый...

Тирән чокырны икегә бүлеп сикергән кешене күргәнегез булмагандыр әле. Аның үрнәген ниндидер күренекле спорт иясе түгел, ә Татарстанның элеккеге беренче секретаре Гомәр Исмәгыйль улы Усманов күрсәтте. XIX партконференциянең соңгы көннәре... Опысы-кечесе, акыллысы-тилесе дигәндәй зәңгәр экран аша аның эшендә катнашып, тын да алмый утыра, ник дисәң, ил киләчәге, партия язмышы хәл итела. Фирка форумының трибунасына йөгерә-атлый республиканың зур хуҗасы чыга.

Килешле, хәрәкәтчән гәүдә, аз-маз кырау төшә башласа да шактый сакланган бөдрә чәч, саргылт түгәрәк бит, татар сакалы сорап торган тар ияк. Тик күзләре генә тынгысыз, хәвефле, характерының әле Татарстан турында сөйләгәндә ачылып җитмәгән якларына ишарә ясый кебек. Республиканы борчыган хокук, азатлык, мәдәният, экология мәсьәләләрен сикереп үтеп, кинәт күчеш ясап, Усманов Б. Н. Ельцинны әрли, үгетли, тәрбияли башлый. Чабатасын түргә эләә.

Үз эше белән шөгыльләнмәгәнен, кеше сүзен тыңлап, тайгак юлга чыкканын сизенде булса кирәк, заманында түләүле лектор булып эшләвенә дә карамастан, ул табигыйлеген саклый алмый, каушый, зиһене эзлеклелекне җуя. Хаклыгыңа эчке ышаныч, рухи таяныч булмаудан, үз йолдызыңны югалтудан килә бу нәрсә.

Партконференция баскычыннан төшкәндә, ул берәүләр өчен канаты янган күбәләк, ренегат, ялагай, сатлык җан, куштан бер шәхес булса (чокырның яртысы), икенчеләргә үз кеше, булган егет, «безнең малай»га әйләнә (икенче өлеш).

Бу «тарихи» нотыгыннан соң ул шәхес буларак күпне югалтты, үзенә-үзе ышанмыйча каударланып, борчылып эшли башлады. Нәкъ шул чорда кашын-күзен җимереп, XX гасырда татар халкы тудырган иң олы шәхесләрнең берсе, күренекле әдибебез Гаяз Исхакыйга ташланды. Әсәрләрен укымыйча, сәяси карашлары, ачы язмышы белән танышмыйча, ялагай киңәшчеләре сүзенә һәм арзан публикацияләргә таянып, берничә тапкыр әдип адресына яман сүзләр әйтте. Кояшны күл белән каплау кебегрәк бу нәрсә татар җәмәгатьчелеген үзенә каршы куюга алып килде.

Җирле җитәкченең үзәккә яравын, «файдалы эш» башкаруын соңрак нинди урындыкка утыруыннан белеп була диләр. Гомәр Исмәгыйлевичның Үзәк Комитетка секретарь итеп алынуы шуның моңсу дәлиле.

Гомер дигәнең агымсу. Сигез-тугыз айлык Мәскәү тормышы үтеп тә китте. Без аның урамнарны ялтырып, үзен дистәләгән машиналар белән озаттырып (аңысы, бәлки, җирле түрәләр ялагайлыгыдыр), Казанга махсус очкычта килеп китүе турында белеп-ишетеп кала идек.

Бу күтәрелү аңа бәхет өстәдеме, юкмы — әйтүе кыен. Әмма, яше җиткәнче үк пенсиягә озатылу барысы турында да ап-ачык сөйли.

Бер караганда, бу шәхси катаклизм очраклы күренсә дә (әйтик, Ельцинның сайлауларда җиңеп чыгуы), аның төбендә тирән мәгънә, тормыш һәм тарих логикасы, кешенең үзенә яшәеш, җан-кан биргән халкына мөнәсәбәте, үз чоры белән аңлаша алу-алмавы — кыскасы, тирән фәлсәфә ята.

Тормышның рәхәт, татлы мизгелләренә алданып, карьера куып, кемнәргәдер ярарга тырышып, ул бөтен гомере буена үз фаҗигасен үзе әзерләде. «Ике фикер» драмасының финалын үзе язды. «Җаныңныңваклыгын сылтама заманга...» — дип язган иде бер татар шагыйре.

Тыштан караганда, Исмәгыйль агай улы — авызына көмеш кашык кабып, күлмәкчән туган, тоталитар җәмгыять өчен көнләшерлек язмышлы кеше. Төрле хезмәтләрдә чирканчык алып, бик яшьли Чаллыда авыл хуҗалыгы җитәкчесе, Буа райкомы беренчесе

булып эшли, 34 яшендә Татарстан Министрлар Советы рәисе (1966—1982 еллар). Үр артыннан — үр, үтәсе чокырлар күренми диярлек, партиянең мәрхәмәтле канаты астында кеше үсә, яңара, үзгәрә, татар тарихын әйдәп барырдай шәхес дәрәҗәсенә күтәрелә.

Тормыш арбасы шулай көйле генә үткән гомерләрне санап барганда, көтмәгәндә, уйламаганда, һәрхәлдә, безгә «аста», түбәндә шулайрак тоелды, Татарстан хуҗасы — Табеевны ерак Әфганстанга илче итеп җибәрделәр. Иңе белән эшләгән, буе белән күтәрсен дигәндәй, иркә яшәешкә өйрәнеп кенә беткәч, кешене майсыз кызган табага ташладылар.

Татар кешесенә 1917 елдан соң мондый ышаныч сирәк тәтү сәбәпле, әлеге сугышның чын эчтәлегеннән, коточкыч якларыннан хәбәрдар булмау аркасында (Әфган халкы һәм хөкүмәте үтенечен искә алып, тәртип саклау нияте белән кечтеки генә контингент керттек), дәүләтнең бу карарын горурлык белән дип әйтерлек кабул иттек: татарыңны аңлый, ышана башладылар, янәсе. Соңрак әлеге адымның төбендә яткан усал мәкер өскә калыкты, Бохара әмирлегенә, Урта Азия басмачыларына каршы татбригаданы ташлаган шикелле үк, татар халкының абруена каршы юнәлтелгән бер чөй икәнлеге ачылды. Әйтик, Әфганстанга илче итеп шул якның логатен, гадәтен яхшырак белгән коньяк республикаларыннан кеше табып булмас идемени? Булыр иде кебек.

Иншалла, Табеев иптәшебез анда да сынатмады, исән-сау әйләнеп кайтты, илчелек вазифаларын тырышып үтәгән, мөһаҗирләрне Кабулга үткәрмәгән өчен үзенә РСФСР хөкүмәтендә җаваплы эш тапшырдылар. Хәзер элеккеге фирка башыбыз лаеклы ялда, берәүне дә читләтеп үтми торган «хезмәттә» — пенсиядә.

Ә Гомәр Усманов Министрлар Советындагы кабинетында, йолдызлар җитә һәркемгә, дип, тыныч кына утыра бирде. Күрәсең, ул партия хуҗаларының эшенә таяк тыкмаган, үзенә кушылган йөкләмәләрне тырышып үтәгәндер. Хәер, Үзәк Комитет секретаре итеп Мәскәүгә күчерелгәч, аның бу чор эшенә дә югары бәя бирүчеләр табылды. Ничек кенә сәер тоелмасын, Усмановны хәзер генә күргән кеше төсле, Табеев күтәреп куйды.

«Социалистик Татарстан» газетасының 1989 ел, 13 декабрь санында Табеевның Т. Дронова белән әңгәмәсе урнаштырылды. «Бөтен ил белән күтәрдек» дип аталган чыгышта төп максат — КамАЗ, Чаллы шәһәрен төзүнең Татарстан өчен ифрат файдалы, кирәкле булуына ышандырырга тырышу. Ул шул төзелештән күкрәкләренә Алтын Йолдыз тагып киткән Л. Васильевны, төрле елларда төзелеш начальниклары булып эшләгән В. Иванцов, Е. Батенчук, В. Фоменколарны мактап телгә ала. Татарстан җирендә ясалган унар миллион сумны Мәскәү киностудиясенә озату җаен эзләгән, берләшмәне ваклап сату шөгыленә керешкән Житомир кешесе, КамАЗның хәзерге генераль директоры Н. Бехка югары бәя бирә: «...иң кыю эзләнүләр һәм тәҗрибәләр үткәрергә сәләтле белгеч». Күңеле киң аның, үзе үстергән Р. Беляев, Р. Гыйлаҗевлар турында да җылы сүз әйтер, дип көтәсең. Аларны газета битләрендә пычраткан, кайсыдыр түрә яратмаган өчен генә бөтенләй күрмәмешкә салышып, атлап үтү хакыйкать юлы түгел бит. Кешелекле җәмгыять, игелекле шәхес алай эшләмәс иде. Мәкалә дәвам итә: «КамАЗ төзелгәндә сөт һәм сөт продуктлары, бәрәңге һәм яшелчәгә беркинди кытлык булмады. Ни өчен? Чөнки бик кыска вакытта 30 гектарлы теплица сафка бастырылды, Чаллы янындагы 34 сөтчелек фермасы яңартылды. Бу эштә, ул чакта, Татарстан АССР Министрлар Советы председателе булып эшләгән Г. И. Усманов зур ярдәм күрсәтте».

Бездә менә шулай, Мәскәүдә югары дәрәҗә биләмәсә, Усмановның «зур ярдәмен» берәү дә, шул исәптән Табеев та күрмәмешкә салышыр иде. Дистәләрчә еллар кешене хезмәте буенча бәяләүдән биздереп, биләгән урынга баш ию рухында тәрбияләде система безне. Бер төрле уйлап та, икенче төрле сөйләү нәкъ менә шуннан килә.

Хәзер инде тәгаен билгеле булганча, Табеев үзе урынына, Татарстан партия оешмасы түренә Усмановны тәкъдим итми, Әлмәттән килеп, өлкомда аз-маз секретарь булып чирканчык алган Фәйзулла Гайнуллинны «төртә». Без, шул чорда «патша» алышыну шаһитлары, әлеге хәбәрнең дөреслегенә инандык, чөнки беренче итеп бөтенләй башка кешене куйдылар. Безнең илдә бер кая да язылмаган, әмма мәҗбүри рәвештә үтәлә торган эчке канун яши. Эшеннән китүче җитәкчедән, үз урыныгызга кемне тәкъдим итәсез, дөресрәге, кемнәрне әзерләдегез, үстердегез? дип сорыйлар. Ул тәкъдим иткән кешене беркайчан да куймыйлар куюын. Бушаган урынга, гадәттә, киткән түрәнең иң яратмаган, җене сөймәгән адәмне утырталар. Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре итеп, озак еллар дәвамында Казан шәһәр комитетын җитәкләгән Рәшит Мусинны билгеләделәр.

Ат аягын дагалаганда, бака ботын кыстыра, димәсәгез, бу законча лыкның түбәнрәк дәрәҗәләрдә дә яхшы мотор кебек эшләвен раслау өчен, фикеремне бер мисал белән дәлилли алыр идем. Алабугадан, пединститут ректорлыгыннан киткәндә, миннән дә: «Кемне тәкъдим итәсез, кемне әзерләдегез?» — дип сорадылар, әлбәттә. Кешеләр алышынып торса да, йола күчә икән. Мин фәннәр булегенә, соңрак өлком секретаре Раис Беляевка: «Пединститутта көнендә үк эшләп китә ала торган бер генә кеше бар — ул уку һәм укыту эшләре буенча проректор Наил Лаисов»,— дидем.

Минем: «Лаисов Актаныш ягында туып-үскән, педучилище тәмамлаган, шул ук институт дипломын алып, Казан университетында аспирантура үтеп, озак еллар дәвамында шунда ук декан ярдәмчесе, иң зур факультетның деканы булып эшләгән, фән белән

шөгыльләнә, тыйнак, эшчән»,— кебек дәлилләремне бүлдермичә тыңлап утырдылар да... Үзләренчә хәл иттеләр, югары уку йортында аз эшләгән, Казан педагогия институты доценты Җәмил Нигъмәтовны, урамнан тотып алып диярлек, китереп утырттылар.

Хәер, аңа озак эшләргә ирек бирмәделәр, институтта казык та кактыра алмый калды бугай. Алабугада ныклап урнашу борчымагач, балалары, дуслары, бакчасы шунда булгач, аңа һәр ялда, һәр бәйрәмдә Казанга чабарга туры килде. Эшкә кереп китә алмыйча коллективны да интектерде, үзе дә борчылды. Мактау грамотасы урынына институт тулай торакларындагы башбаштаклыклар, әхлакый бозыклыклар турында «Чаян»да (1989, № 1) басылган фельетонны күтәреп, өч елны да тутырмыйча, Казанга кире кайту бик үк күңелле булмагандыр дип уйлыйм.

Демократия җилләре исеп, партия аппараты кадрлар мәсьәләсендә югары уку йортлары эшенә тупас тыкшынмый башлагач, коллектив ректор итеп шул ук Наил Лаисовны альтернатив җирлектә сайлап куйды. Китерелгән зыян, кадрлар сайлаудагы ялгышлар өчен берәү дә җавап бирмәде, җәмгыятебез шундый.

Татарстан зыялылары, Рәшит Мусинга шактый өмет баглап, эшен ул чыннан да яхшы гына башлап җибәрсә дә, шул ук аппарат кешеләре, яраннары үзен Чистайга алып барып, мактый-мактый кунак итеп, туры мәгънәсендә яндырдылар.

«Ак йорт» шактый вакыт хуҗасыз яшәде. Беренче секретарь алышыну — милли республикалар өчен инкыйлабка тиң бер нәрсә. Чөнки аларның үз табигый үсешләре ниндидер олы революцион үзгәрешкә китерә алмый, буйсынган милләтләр язмышын тирәлек хәл итә, тарихын башка халык яза. Әйтик, татар халкына 1917 елгы Октябрь революциясе бөтенләй кирәк түгел иде, ул аның мәдәниятен юкка чыгару дәрәҗәсенә җиткерде (әлифбалар үзгәртү, газета-журналлар, милли мәктәпләр ябылу, зыялыларга каршы геноцид һ. б.), таралып утырган халыкны кеп-кечкенә территория эчендә калдырды (аннысын да башка милләт кешеләре белән дыңгычлап тутырды), зыялыларын кырып бетерде. Уянуга, аякка басуга бөтен өмет акыллы, кыю, халык хыялы белән партия ихтыярын, аппарат көчен үз милләте ихтыяҗларына юнәлтә белгән җитәкчедә кала. Ә андый кешеләр, татар тарихы күрсәтүенчә, бик тә сирәк.

Усманов кандидатурасы тирәсендә бәхәсләр байтак булды. Омтылыш һәм чыдамлылык үрнәге күрсәтеп, ул үз теләгенә иреште. Ничек итсә итте, барыбер Мәкәрҗәгә китте, дияр иде татар агаең.

Табеев белән Мусиннан соң, Усмановка алар калдырган өстәлне биләве җиңел булмагандыр. Кемнеңдер кул астында әйткәнне, кушканны җиренә җиткереп яшәү — бер хәл, ә хәзер Мәскәү белән мөнәсәбәттән алып, Казан халкына чөгендер, кишер ашату, шифалы су эчертү турында да үзеңә уйларга кирәк иде. Табеев ни әйтсәң дә, фәннәр кандидаты, теоретик яктан көчлерәк шәхес иде. Авыл хуҗалыгы институтын читтән торып кына тәмамлаган Гомәр Исмәгыйлевич теоретик яисә марксист-галим буйуга дәгъва итмәде кебек.

Усмановның беренче булып сайлануын авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре аягүрә басып алкышлады (үз кеше), совет һәм партия аппараты кешеләре генә түгел, хәтта зыялылар да ниндидер өмет белән каршы алдылар бу хәбәрне. Менә ни өчен дип уйлыйм. Бердән, «экс» беренчеләр Моратов, Табеев, Мусиннар, ни әйтсәң дә, Татарстаннан читтә туып үскән адәмнәр, «килмешәкләр» иде. Гомәр Исмәгыйлевичка килгәндә, ул «мишәрстан» башкаласы Чистайда туып-үскән, хезмәт юлын шунда башлаган. Икенчедән, күп еллар дәвамында Министрлар Советында утыру сәбәпле, халыкны борчыган мәсьәләләрне аңлый, белә. Өметсез шайтан, ди, бәлки, татар тарихына, мәдәниятенә, милли кадрларга игътибарлырак булыр, дигән хыял да яшәде изге күңелләрдә. Әмма бу өметләрнең берсе дә акланмады.

Гигантомания чире Табеевның «милли» үзенчәлеге иде кебегрәк фикер яши халык арасында. Чыннан да, КамАЗ, Түбән Кама, Менделеевскида, Казанда яңа гигантларны ул башлады. Бу «сырхау»ның асылында татар халкы турында кайгырту ятмаганы көн кебек ачык. Шул төзелешләр «ярдәмендә» татар милләте бабалары җирендә азчылык булып бара. Кызганычка каршы, Татарстанда дыңгычлап олы-олы берләшмәләр (завод-фабрика мазар гына түгел) булдыруга шәхси амбиция һәм карьера куу (югарырак урынга күтәрелү, үзәктән мактау сүзе ишетү, герой булу, түшкә орден кадау һ. б.) алып килде.

Авыл хуҗалыгы белгече Усмановта бу сырхау сизелмәгән иде шикелле. Бу мәсьәләгә «Татарстан яшьләре»нә биргән интервьюсында Р. Беляев ачыклык кертә. «Трактор заводы Башкортстанда төзелергә тиеш иде. Башкорт җитәкчеләре акыллырак булды, төзелешне башламый тордылар. Минемчә, юри суздылар. Усманов, чирле Черненко янына кереп, Татарстанга сорап алды ул төзелешне» (1990, 15 ноябрь). Шул чорда «ак йортта» утырган Р. Беляев сүзләрен шик астына алырга нигез юк.

Аннан килеп, картлык көннәрендә элеккеге беренчеләребезнең икесе дә Казанга кайтып егылмадылар (әйтик, Кунаев, Шакиров, Алиев һ. б. кебек), Мәскәү «патшаларына» барып сыландылар. Бу — үзе бер күрсәткеч.

Кадрлар «инфляция»се Усманов заманында тагын да көчәйде. Кешене бәяләүдә аның табигатьтән, белем дәрәҗәсеннән, үз халкына мөнәсәбәтеннән килгән рухи омтылышларын исәпкә алу бетте, аның реаль бәясен аппаратта утыручыларның карашы алыштырды. Тәкъдим итәрлек, «арттан төртеп» барырлык кешең булса — син шәхес, ан-

дый аркаң юк икән, тычкан төсле посып кына үз почмагыңда утыра бир, яңа түрә килгәнне көтеп.

Беренче секретарьның файдалы эшләрен инкяр итү турында сүз бармый бирелә. Эшчән, таләпчән кеше буларак, ул авыл хуҗалыгы үсешенә мәгълүм өлеш кертте, шәһәрләрне азык-төлек белән тәэмин итүдә дә билгеле бер уңышка иреште кебек.

Шуннан килеп, аның һәр районда дачалар салдырмавы, гомерен Табеев үрнәгендә, Алабуга якларында уздырмавы, күпләргә ошады. Димәк, тыйнак кеше.

Әмма тиз арада аның үз милләтенә, мәдәниятенә карашында куркаклыкка барып чыккан бик сак, урта кул функционер булуы ачыкланды.

Вакыт тик тормый, бер-берсенә рухи якын затларны калыплый тора. Табеев белән Усманов арасындагы ниндидер аңлашылмаучылык, тышкы форсатка кайтып калып, эчке якынлык, салкын диңгездәге кайнар су агымы кебек, өскә бәреп чыкты.

Теләсә нинди дәрәҗәдәге партия, дәүләт эшлеклесе төп ике күрсәткечтә танылa дилəр. Беренчесе — үзе җитәкчелек иткән төбәктә яшәүче халыкның тормышын яхшырту юнәлешендә башкарган гамәли эшләре.

Икенчесе — җитәкченең шул республикага исем биргән халыкка мөнәсәбәте. Мәскәүгә күчкәч, «Правда» газетасында басылган беренче әңгәмәсендә, мин совет халкына хезмәт итәчәкмен, әмма «урынчылыкка» каршымын, дигән фикере күңелгә таш булып утырды. Үз халкына яхшылык эшли алмаган кеше башка милләт вәкилләрен дә сөендерә алмый. Усмановның иң курыккан нәрсәсе милләтчелектә гаепләнү иде. Урыска охшарга тырышуы да артык күзгә бәрелеп тора, шуңарда аның ниндидер идеалларга тугрылыклы булып калуы турындагы сүзләре дә ихлас кабул ителми. Икейөзлелек ышанмаучылык тудыра. Кеше үз халкына мөнәсәбәттән башка яши алмый.

Аннан соң, олы урын биләгән зат чын мәгънәсендә зыялы булганда гына, урынны бизәү белән канәгатьләнми, үз вазифаларын җиренә җиткереп үти, гомуми үсешкә туган халкына хезмәте аша өлеш кертә. Ә бу нәрсәнең нигез өлгесе — Балтыйк буе республикалары үрнәге күрсәткәнчә, кадрлар сәясәте.

Усманов өлком башында утырганда үз кешеләрен үстереп өлгерә алмады, дөресен әйткәндә, аңа омтылмады да. Аның теләсә нинди дәрәҗәгә һәрдаим әзер «комсомол элитасы» юк иде. Әйтергә кирәк, яңа сәркәтип Табеев «дружинасы»ның күренекле вәкилләрен шактый селкетеп алды. Республиканың элемтә хуҗасы, комсомолның элеккеге беренче секретаре Илгиз Рахманкуловка «әхлакый тотнаксызлыгы» өчен каты шелтә бирүдән башлады иске хуҗадан үч алуны (сүз урамдагы автоматларның үзәктә дә эшләмәүләре, гомумән, республикада элемтәнең, удмурт, мари, мордвалар белән чагыштырганда да, начаррак булуы турында барса, бер хәл иде).

Икенче «корбан» итеп, табигый буларак, Табеев дәвере комсомол лидеры, Чаллы горкомы беренчесе, заманында ТАССР Министрлар советы рәисен кешегә дә санамаган Р. Беляев сайлана. Усманов аны өлкомның идеология секретаре итеп үз янына күчереп, аңа көч биреп торган җирлектән, бердәм оешмадан аерып ала. Рәис Кыямович, үз теләге белән, йодрык астына килеп керә. Мәдәният үзәкләреннән ерак, караңгы бер мишәр авылында, күп балалы гаиләдә туып-үсеп, университетта, юридик факультетта укыганда ук, өлгер активист булып китә Кыям ага малае. Комсомолдан партия эшенә алына, КамАЗ күтәрелгәч, Чаллы партия оешмасының җитәкчесе итеп күчерелә. Ташып торган җегәре, төрле дәрәҗәдәге кешеләр белән уртак тел таба белү сәләте, халык алдында кагазьсез, алдан әзерлексез сәгатьләр буена сөйли белү осталыгы аңа шөһрәт алып килә. Зиһене бик күп информация тота, кешеләр турында һәртөрле белешмәләрне хәтерли, бу нәрсә аңа бик еш авыр хәлләрдән чыгарга мөмкинлек бирә. Чокчынып, утырып эшли торган, язу-сызу белән бәйле гамәлләрне бик өнәп бетерми, ул төзелештә, заводта, колхозда булуны, халык белән аралашуны, барабанлы, байраклы җыеннарны ярата төшә.

Чаллыда иркен яшәргә, теләгәнен кыланырга өйрәнгән кешегә идеология артык «вак» эш күренә. Хрущевка тартымрак характерын артистлар, язучылар, көйчеләр, биючеләр, чичәннәр белән очрашулар, шаярулар аны тиз туйдыра. Беляевның министрларны, ректорларны, директорларны сәгатьләр буе кабул итү бүлмәсендә утыртуы, мәдәни, милли мәсьәләләргә җиңел каравы, хәл итмәве, аңардан күбрәкне көткән җәмәгатьчелектә ризасызлык уята. Торгынлык елларында, аргта көчле терәк барында, Чаллыда үткәрелгән алымнар монда ярап бетми. Шулай да бездә партҗитәкчене эшләмәгән өчен генә урыныннан алу гадәте юк, аны ниндидер сәбәп табып, пычратырга кирәк. Нияз сәбәпне үзе таба. Мәскәүдә Тукай, Җәлил юбилейларын уздырганда, өлком секретаре шау-шулы, эчемлекле мәҗлесләрдә катнаша, районнарга чыкканда, кешеләргә рыясыз ышанып, үзеннән өстә утырган абзыйлар турында күңелендә йөрткән фикерләрен әйткәли. Шуларны сәбәп итеп «очырдылар» Р. Беляевны өлкомнан.

Мин, Беляевны яхшы ук белгән кеше буларак, шуны өсти алам: аның күңел түрендә, тирәндә үз милләтенә ярдәм итү теләге, изге нияте бар. Чаллыда эшләгәндә ул милли кадрларны җыю, үстерү хасиятен беркайчан да онытмады, күз уңында тотты. Ул аннан киткәч, бигрәк тә Усманов Татарстанда чакта, КамАЗ шәһәрендә татар кешеләрен җитәкче эшләрдән читләштерү башланды.

Беляев белән уздырылган уңышлы «операция» (дөрес, ул карарлар, Усманов Үзәктән китү белән, Реском пленумы тарафыннан юкка чыгарылдылар) «ак йорт»

хуҗасына ышаныч, дәрт бирә. Элек Чулман-Кама буенда урнашкан шәһәрләрдә партия, совет оешмаларында эшләгән Табеев ярарнарыннан берничә иптәшнең язмышын үзгәртүгә, төрле җәзалар бирүгә ирешә. Хәер, бюрократик система мөмкинлекләрен яхшы үзләштергән әлеге иптәшләр югалып калмадылар, элеккеге шикелле үк булмаса да, шактый җайлы урыннарга кереп оялад ылар.

Усманов райком секретарьларын шактый алыштырса да, кадрлар үсешенә нинди дер яңалык өсти алмады. Хәер, бу катлаулы, четерекле, дәгъвалы өлкәгә ул катнашмады диярлек. Ул сәүдә, хисап, ит, балык тирәсенә генә Чистай якларыннан таза, куштан, шома, ялагай эшкуарларны туплап калдыра алды.

Мәгълүм булганча, өлком аппараты белән, нигездә икенче секретарь идарә итә. Рус милләтеннән билгеләнгән «икенче» кадрлар белән эшләү, аларны урыннарга утырту буенча, юридик яктан, өлкә партия комитеты хуҗасы белән бер дәрәҗәдә тора. Беренче мәркәздән читкә чыгып киткәндә, республикада бөтен хакимият аның кулына күчә.

Усманов үзенә таяныч, димәк ки, Татарстанның икенче кешесе итеп Аркадий Родыгинны сайлады. Тормыш тәҗрибәсе сокланырлык бай. Биографиясен Әгерҗе тимер юлында гади эшчедән башлап, тиз арада Алабуга шәһәр комитеты секретаре дәрәҗәсенә күтәрелә. Көннәр буена кабинетында бикләнеп шахмат уйнап утыргань өчен (дөрес эшләгән, партия оешмаларының белер-белмәс катнашуы аркасында, күпме халык интекте!), аны Мәскәүгә иҗтимагый фәннәр Академиясенә аспирантурага җибәрәләр. Аннан ул икътисади фәннәр кандидаты дигән таныклыкны алып (бу оешмага эләккән кешегә көчләп булса да диплом бирү тәртибе яши), кесәсенә салып, кая кайтып төште дисезме? Кая булсын инде, әлбәттә, Алабуга педагогия институтына, анда да читтән торып уку буенча проректор булып. Иң җылы, рәхәт, тыныч, җавапсыз урыннарның берсе ул Советләр мәмләкәтендә. Уку сессиясе — елына ике тапкыр, калган ун ай вакытны ничек уздыру синең хыялыңнан, мәвыгуларыңның күпмелегеннән тора. Хәер, ярты еллап кына яшәп кала алды Аркадий Андреевич бу «оҗмахта». Аны КамАЗ парткомы секретаре итеп алдылар. Шунда инде биләгән урынның аңа хезмәт итү чоры башланды. Өлкомда аз-маз булек мөдирләре булып эшләп алгач, тыштан бик тыныч характеры, чыгышлар яза белүе аны югары эшелонга күтәрде.

Рус һәм башка «олугъ» милләт вәкилләренә безнең республикаларда үсүе җиңел иде. Номенклатура кешеләренең, хуҗалык директорларының, ТССР депутатларының биографияләренә юри генә күз салыгыз, күбесе чит өлкәләрдән (Воронеж, Могилев, Брянск, Житомир, Тула һ. б.) килеп, карьераны Казанда, Чаллыда ясаган, туган ягына кайтып китәргә ашыкмаган кешеләр булыр. Әле шуның өстенә республикада да әллә ни майтара алмаган кешеләрне Мәскәүгә чүпләп алып торалар (артта калган халык арасында күпме яшәтеп була?! дип, кызганыпмы шунда).

Родыгин ашыкмыйча, иплән, сыйпап кына республиканы үз кулына алып бетерде. Оста психолог бупарак, ул, Усмановның татарлыкта гаепләүләреннән куркып, теләсә нинди урынга башка милләт вәкилләрен куюга риза икәнен аңлады (әлбәттә, кулында берниндн көче, акчасы булмаган хәерче министрлыкларны санамаганда). Җирле халык вәкилләре хәлиткеч урыннардан көзге яфрак кебек коелып бетте.

Хәер, мин үзем рус, яһүд, чуваш һәм башка милләт вәкилләренең болгар-татарның шифалы, мәрхәмәтле һәм миһербанлы җирендә үсүенә бик шатмын. Аркадий Андреевичны нинди дер «изм»нарда гаепләүдән дә ерак торам. Берәү дә ата-анасын, милләтен сайлап алмый. Һәр намуслы кеше үзен дөньяга яраткан халкына турылыклы хезмәт итәргә тиеш.

Ә татар кешесе табигый җегәрен кайда сынап карый, генофондын ничек, ни рәвешле яңарта ала соң? 800 меңләп татар яшәсә дә, Югары Советында бер генә депутаты, милли мәктәбе, газетасы булмаган Үзбәкстандамы? Яисә Донбасс, Донецк шахталары төбендә ятып, яисә түшенә бирка тагып, арба этеп йөреп Мәскәүнең Казан вокзалында татарның канын яңарта аламы?

Менә шул яссылыктан килеп, Усмановның кадрлар сәясәтенә күз салыйк. Безнең заманда тормыш бер урында тора алмый. Ул, телиме-теләмиме, кемнәрнедер үзенә тәрәк итеп алырга тиеш. Күрәсең, партаппаратта ялагайлыкка һәм мәкерлеккә өйрәнеп беткән шома кешеләрдән шикләнеп, өлком хуҗасы берниндн сәяси, тормыш тәҗрибәсе булмаган «университет егетләрен»ә йөз тотты, ак колонналы фән йортында берни белән дә аерылып тормаган фәннәр кандидатлары идеология, фән һәм уку йортлары, административ бүлек мөдирләре булып расланып, йомшак креслога, «03» саны белән башланган машиналарга күчеп утырдылар. Берсе дә татар дип аталган милләт вәкиле түгел иде. Аларның бер-икесен Гомәр Исмәгыйлевич үзе белән Мәскәүгә үк алып китте.

Казан райкомнарының беренче секретарьлары гына түгел, хәтта мәгариф бүлекләрендә дә паспортында «татар» дип язылган кешеләрнең бик аз булуына игътибар итте җәмәгатьчелек. Халык белән җитәкчелек итүне аның аерым вәкилләрен эзәрлекләү, әрләү, җәберләү диебрәк аңлады бугай беренче. Мәсьәләгә икенче яктан килеп карыйк.

«Бераз милли кадрлар турында кайгыртыйк, кешене урынга куеп, сынап карамыйча, аның эчке җегәрен ачып, белеп булмый, ничә гасырлар дәвамында кырыла килгән нәселләкнең кайлардадыр сакланып калган орлыкларын үстерәсе, коплык халәтеннән арынырга мөмкинлек бирәсе иде!» — дип Усмановка әйтүче булмадымы икән? Гомере

буенча диярлек янәшә кабинетта утырган, Галимҗан Ибраһимов иҗаты буенча төп белгеч, профессор Мансур Хәсәнов та бу хакта хуҗасына берни әйтмәдеме икән? Иптәшләрнең беришесе, юктыр, әйтмәгәндер, күрмәмешкә, белмәмешкә салышып утыргандыр. Әгәр яңа зыялылар үсеше өчен, татар мәктәпләре өчен терсәген канатып йөрсә, мондый җаваплы, илле, җылы урында озак утыра алмас иде, диләр. Бәлки, хаклы сүзләрдер.

Кешеләрне «үстерү» юлында Усманов сәерлекләренең иге-чиге юк сыман тоела башлады бермәлне. Татарстан профсоюзларының хуҗасы итеп Чаллы эшчесе, ул вакытта югары белеме дә булмаган Г. Баштанюкны алып кайтып куюы аек акылга сыя торган нәрсә булмады. Өлкә профсоюзлар Советы рәисе булып гомер-гомергә татар кешесе эшләде. Бу — табигый. Чөнки әлеге оешма күбрәк авыл кешеләренә, өлкән буыннарга шәфкатьле кулын, ярдәмен сузарга тиеш. Бер украин кешесе Казан шәһәр советы рәисе булып күп еллар буена утырып (монысы Табеев «сәерлеге» булгандыр), шәһәребезне адәм мәсхәрәсенә калдырды. Усмановка да үз Бондаренкосы, ягъни Баштанюгы, кирәк булды, күрәсең. Менә шул очракта да аңа каршы әйтүче димим, анысы тиле-миле хыял булыр иде, киңәш бирүче табылмады микәнни?

«Тел яшерү», халыкны томана санап, алдап-елдап гомереңне озайту егетлек була алмый. Әйтик, Усманов СССР Югары Советына депутат, соңгы партия съездына делегат булып Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә кебек үзәкләрдән читтә, ерак, халык күп нәрсәне белми, алданучан, ышанучан «караңгы» авыл районнарында, альтернативасыз диярлек үтте. Алла түгел икәнен аңлаган, сиземләү бар. Матбугат бу очрашулар турында язмаса да, Усмановның Чүпрәледә халыкка чүпрә, башка җирдә галош, сабын, чүпрәк-чапрак саттырып, сайлау көнне Зеленодольск ягына баручы кыска юллы поездлар санын (каршы тавышлылар Казаннан бармасыннар, дип) киметүе хакында имеш-мимешләр бихисап булды.

Мәскәүләр ягына сәфәр тотар алдыннан Гомәр ага Казанның иҗат зыялылары белән очрашу үткәрде. Электән килгән йола, дөресрәге, Лев Толстойның яланаяк сука сукалавы кебек бер уен иде бу. Торгынлык елларындагы шикелле үк, бюро әгъзаларын, ярдәмчеләрен, министрларын иярте килгән, һәркайсы түрдәге өстәлгә кунаклап алдылар, алларына каләм-кагазьләр куеп, ифрат эшлекле кыяфәткә кердeләр. Тамашаны Усманов үзе ачып җибәреп, кереш сүзен озын-озак туктапышлар белән бер сәгатьтән артыкка сузды. Максаты ачык: халыкны ялыктыру, бәхәскә, икеләнүгә урын-вакыт калдырмау; сүз XIX партконференция йомгаклары, авылны борчыган мәсьәләләр, яңа яшелчә кибете ачылу уңаеннан чираттагы кешеләр белән әңгәмәләр турында барды. Тавык итенә талоннар бетерелү турындагы куңелле хәбәр дә колакка шунда иңде.

Халыкның арый башлаганлыгы урындыклар шыгырдаудан, үзара сөйләшүләрдән сизелде. Сорауларга җаваплар башлангач, язучы халкы, ничек инде Әмирхан Еники белән Гомәр Бәшировтан узып күп кутәрәсең дип, бер-берсенә карашып утырган арада, әрсез кино операторлары, театр тирәсендә кул җылытучылар сикереп чыгып, вакытны алдылар. Очрашу булды, әмма эш фикер алышуга, сөйләшүгә барып җитмәде. Безнең күңелдәгене Усманов үзе әйтеп салды: «Мин бүгенге очрашудан канәгать түгел». Кызганычка каршы, безнең илдә иҗат кешесе тулысы белән партия һәм совет оешмаларында утыручыларга бәйле. Шул нәрсә аның ихтыярын сындыра, коллык психологиясе тәрбияли һәм хыял чишмәләрен саектыра.

Татарстаннан аны вакытында күчерделәр кебек. Өлкә комитетын һаман да ул җитәкләгән булса, 30 август булыр идеме икән соравын күпләр куя. Дөрес, тарихи зарурятны аерым шәхес кенә туктата алмый. Әмма Усманов, халык ихтыяры басымы астында да, нык кичектереп, башкорт, якут, удмурт, марилардан соңарып, хокукы буенча, хәзергедәң дә кисеңгән хәлендә кабул иттерер иде әлеге Декларацияне.

* * *

Бу язмаларны 1990 елның август-сентябрь айларында тәмамлаган идем. Шактый кешегә укыттым. Бераүләре хуплады, Гомәр Усмановка катырак бәрелгәнсең, бик учле кеше, гафу итмәс, югары дәрәҗәдән китсә дә, Татарстан — аның тәрбиясен үткән кешеләр кулында, диючеләр дә табылды. Мәскәүдә чыга торган «Независимая газета»га биргән интервьюсы мине үземнең хаклыкка, язылганнарның дөреслегенә инандырды. Чөнки аның нигезендә Татарстан җөмһүрияте Россиянең «Татария» атлы бер өлкәсе итеп калдыру хыялы ята. Адәм баласы хакимияттән читләтелгәч тә, буш амбицияләрдән арына алмыйча, үзен һаман да кирәкле кишер яфрагы санап йөреп, халкы алдында гаебен тану дәрәҗәсенә күтәрелә алмаса, аңардан инде өмет, мәрхәмәт көтмә. Тук яшәү өчен халкыңны кат-кат сату кирәкме икән диган сорау борчый күңелне. Шаһ Галидән соң болай мәсхәрә ителгән, арзанлы комедиант дәрәҗәсенә төшерелгән кешене татар тарихы белми иде кебек.

Усмановның бу әңгәмәсенә «Шәһри Казан»да Р. Низамиев, М. Галиев, Р. Зәйдулла кебек язучылар, укучылар тулы җавап бирде. Алар фикере белән килешүемне генә белдерәсем килә.

# МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ ЭЗЛӘРЕННӘН

## ӘДИПНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Яшьлек елларында тормыш мине Оренбург өлкәсенең Орск шәһәренә юллады. Соңыннан «Хрущев тудырган хөрлек заманы» дип билгеләнгән бер чор иде бу. Күпләребезне ятим иткән канлы сугыш, аннан соңгы авыр һәм ачлы-туклы дәвер артта кала, онытыла барган чак. Авыл, шәһәрләрдә тормыш рәтләнә башлаган, күңелләр күрәя төшкән заман. Һәр авылда, шәһәрдә диярлек үзешчән артистлар барлыкка килде, драма түгәрәкләре оешты. Аларда М. Әмирнең «Тормыш жыры», «Миңлекамал»лары, Г. Насрыйның уенчак-шаян драмалары һәм комедияләре белән беррәттән, сугыш алды елларындагы кебек, Мирхәйдәр Фәйзинең атаклы «Галиябану» әсәре дә кат-кат уйнала иде. Дөресрәге, байтак кына авыл «артист»лары үз осталыкларын шушы драманың Галиябану, Хәлил, Исмәгыйль, Бәдри образларын гәүдәләндерүдән башлыйлар иде. Башка төбәкләрдә дә шулай булгандырмы, әмма ул дәвердә мин белгән Оренбург өлкәсе татар авылларында «Галиябану» пьесасының бик популяр чагы иде.

Бәлки менә шул сәбәпләр белгеч дипломы алгач Орск каласын сайлавыма бер этәргеч булгандыр. Ул шәһәрдә атаклы драматург, «Галиябану» әсәрен язган Мирхәйдәр Фәйзинең яшәгәнлеген мин яшьтән үк белә идем. Өстәвенә анда Дәрдемәнд дигән шагыйрь дә яшәгән бит әле. Дөрес, аның ижатын мәктәптә өйрәнмиләр, күрше авылның бер укытучысы әйткәндәй, «буржуаз тормыш жырчысы» булган ул. (Ә ул укытучы үзе Такташка гашыйк, ул «Такташча мәхәббәт жырчысы» булучыларны гына хуп күрә.) Ә Дәрдемәнд шигъриятенә кагылышлы әз-мәз хәбәр безгә, әлбәттә, Орск шәһәренең татар мәктәбендә укыту бүлеге мөдире булган авылдашыбыз Мәрхәбә апа аша ирешкәндер.

Әйе, мин Орск каласына килеп эшли башладым. Халкының күпчелеге милләттәшләребез булган Иске калада ул елларда гөрләтеп татар клубы эшләп тора. Мулланур Вахитов исемендәге милли китапханәдә татарча, башкортча, хәтта казакъча да китаплар, газета-журналлар күпләп алдырыла иде. Алтмышынчы елларда болар икесе дә әкренләп бетерелде диярлек. Беренче май клубы бинасы да — ә аңа нигез ташларын гасырыбызның унынчы елларында танылган олы артисткабыз Галия апа Нигъмәтуллинаның бабасы салган — тиздән Орск педагогия институтына бүләк ителде.

Беренче май клубында һәвәскәр жырчы һәм биючеләрдән тыш көчле генә драма түгәрәге дә эшли, һәр ай саен диярлек анда тупланган яшьләр шәһәр халкына берәр әсәрне сәхнәләштереп күрсәтәләр. Һәм бу түгәрәк үз клубы сәхнәсе белән генә чикләнмичә, якынтирә авыл һәм бистә клубларына да даими рәвештә йөреп тора иде. Орск каласының зур-зур завод-комбинатларына эшкә килгән күпсанлы милләттәшләребезне тулай торакларга барып та табалар, тулай торак кызыл почмаклары да ике-өч атнага бер «татар клубы»на әверелә. Шул драма түгәрәгенең тынгысыз житәкчесе бүгенге атаклы шахматчы Гата Камскийның бабасы булганлыгын әйтеп китү кирәк.

Берничә ел татар дөньясыннан читтә йөргән һәм рухи бер сусау чоры кичергән кеше буларак тиздән мин дә бу клубның һәм татар китапханәсенең якынына әвереләдем. Шул елларда Мирхәйдәр Фәйзи тормышына кагылышлы хәлләр, истәлекләр белән кызыксынуым артты. Аннары туган-үскән жирендә — тиз агышлы Гөберлә буендагы Күкшел утары урынында һәм Мирхәйдәрнең яшьлек елларына бәйле Җүнәү авылында да булырга — ул күреп, рухланып үскән табигать хозурлыгын да татырга туры килде. Ә инде берничә еллардан соң Мирхәйдәр Фәйзи эзеннән барып Юлык авылын күрергә дә, әдипнең кабере сакланган Баймак шәһәрендә дә булырга да туры килде. Шунлыктан мин бу язмамда аңа кагылышлы кайбер истәлекләрне искә алып китмәкчемен.

Мирхәйдәр Фәйзи гомеренең иң кызыклы һәм мәгънәле өлеше Орск шәһәрендә узган дисәк, һич тә ялган булмас. Бу шәһәргә ул унбер яшендә, мәдрәсәдә укырга дип килә. Димәк, 1902 елның көзеннән шушы калада яши башлый. Атасы Мостафа карт озакламыйча Иске шәһәрнең үзәк урамына янәшә булган Тау урамында үз йортын төзергә керешә. Ишле гаиләгә исәпләнгән бу йортның аскы каты кирпечтән, өскесе бүрәнәдән салына. Иркен ишегалдында ат араны, арба сарае, утын келәтләре була. Урамга биш зур тәрәзәсе карап торган ул таш йорт әле дә исән-сау, драматург тууга 80 ел тулган көннәрдә анда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе үтенечenә нигезләнеп истәлек тактасы беркетелде. Ә Мирхәйдәрнең үз эш бүлмәсе

дә булган икенче кат исә байтак еллар элек янган һәм кабат торгызылмаган. Мирхәйдәрнең ата-анасы шушы йортка 1907 елда Күкшел утарыннан күчеп килгәннән соң, Фәйзуллиннар тәгаен шәһәр кешесенә әвереләләр. Бу вакытта Орск шәһәре Оренбург губернасының иң зур һәм иң бай өязенең үзәге була. Шушы урында Мирхәйдәр Фәйзи көндәлегеннән бер өзек китереп китү гыйбрәтле.

«Башка җирләр белән чагыштырганда Орск өязе Курскиның бөтен губернасы кадәр, чит мәмләкәтләрдән Даниянең бөтен җире Орск өязеннән кечерәк икәнен белдем», дип сокланып яза ул 1917 ел февралендә.

Егерменче гасыр башында Орскида татарлар шәһәр халкының өчтән берен диярлек тәшкил иткән. Калада биш мәхәллә, биш мәчет була. Ә Урал-суның аргы ягында, Европа өлешендә, хәзерге Яңа шәһәрнең бер читендәрәк мөселман казакълары авылы — Ильяс утары була. Шәһәрнең үзендәге дүрт-биш мәдрәсәдән кала, өяз халкы арасында Ильяс утары мәдрәсәсе дә начар исәптә йөрми.

Мирхәйдәрне исә Сәлимгәрәй агасы 1902 ел көзендә Габдулла хәзрәт Мәгази җитәкләгән Орск мәдрәсәсенә тапшырып китә. Моннан тыш ул чорда Орскида танылган язучы Гаяз Исхакыйның өченче буын кардәше Әхмәтхан Исхаков җитәкләгән «Дамелла» мәдрәсәсе, Әхмәтҗан хәзрәт Рәхмәтуллин мәдрәсәсе, аның хатыны Маһруй Борнаева-Рәхмәтуллина оештырган кызлар мәктәбе һ. б. була. Шәһәр байлары һәм зыялылары күмәкләшеп 1907 елда белем җәмгыяте оештыралар, зур китап кибете ачалар. Аның уку бүлмәсенә килеп, һәркемгә газета-журналлар белән танышып китү мөмкинлеге тудырыла. Ә 1911 елда бер иркен бина шушы белем җәмгыяте акчасына алына һәм анда зур гына китапханә булдырыла. Аның беренче китапханәчесе «Бәкре Гариф» дигән укымышлы кеше була. (Ул китапханәгә 1919 елда Мулланур Вахитов исеме бирелә.) Мирхәйдәр Фәйзинең соңыннан китапханәче булып китүенә шушы Гариф белән яшьли үк якыннан аралашуы да тәэсир иткәндер, мөгаен. Һәрхәлдә, аның әдип булып китүенә, әүвәл шигырьләр, соңра хикәя һәм драмалар язарга керешүенә әлеге «Шәрык китапханәсе» дигән китап сәүдәсе йортының да, аның каршында ачылган «Халык китапханәсе»нең дә йогынтысы зур була.

«Шәрык китапханәсе»н оештыручыларның берсе әлеге Чистай төбәгеннән чыккан мулла Әхмәтхан Исхаков була. Аның инициативасы белән бу китап йорты күпмедер вакыт нәшрият вазифаларын да башкара, Казан, Оренбург типографияләренә заказ биреп, берничә китап та бастырып чыгара.

Мирхәйдәр Фәйзи әсәрләренең байтагы шушы шәһәрдә яшәү чорында язылганнар. Шул исәптән «Галиябану» драмасы да 1916 елның көзендә һәм кыш башында монда, Орскиның хәзерге Пугачев урамындагы алтмышынчы йортның икенче катындагы урам як бүлмәсендә языла. Ә моңарчы шушы бүлмәдә һәм Мортаза агасының мануфактура кибетенең касса «кетәге»ндә беренче драмасы «Ике Хәсән» (1909), «Чәчәкләр арасында» (1911), «Яшьләр алдатмыйлар» (1911), «Бизәнү» (1911), «Кызганыч» (1913), «Тәкъдирнең шаяруы» (1913), «Авыл бәйрәме» (1913) пьесалары, шигырьләре, тәрҗемә әсәрләре иҗат ителәләр. Шушында ук Оренбург, Казан, Уфа шәһәрләрендә чыккан төрле газета һәм журналлар өчен мәкалә, информацияләр дә языла.

1911 елда Мирхәйдәр Фәйзи, теләктәш иптәшләр туплап, Орск шәһәрендә беренче драма түгәрәге оештырып җибәрә. Бу вакытта инде шәһәрдә үзешчән артистлар һәм бер урыннан икенчесенә күчеп йөрүче ярым һәвәскәр труппалар тарафыннан русча спектакльләр уйнала торган була. Әйтик, нәкъ шушы елларда булачак күренекле язучы Лидия Сәйфуллина (аның атасы, ятим калып, рус гаиләсендә тәрбияләнә һәм яшүсмер чагында чукындырыла) беренче мәртәбә Орск сәхнәсендә артистка сыйфатында күтәрелә, аннары күчмә театр белән ил гизеп йөри.

Мирхәйдәрнең искә алуынча, 1909 ел кышында ул беренче мәртәбә русча спектакль карый. Шул тамашадан соң, шигырь язуыннан тукталып, сәхнә әсәрләре иҗат итәргә керешә, Орскидан читтә татарча әсәрләр куючы театрларның да яшәгәнлеген газеталардан укып бара һәм шулар тәэсирендә үзе дә «театр тамашасы» оештыру хыялы белән яши башлый.

Әдипнең чордашы Мәгъсум бабай Шәмсетдинов сөйләвенә караганда, бу хыялына ул тиз генә ирешә алмый: берәүләр моңа көч һәм сәләт җитмәс дип шикләнсәләр, яшьләрнең бер ишесе олылар һәм муллалар алдында хур булудан, оятка калудан курка. Ләкин тора-бара Мирхәйдәрнең үгетләүләре бу шикләрне җиңә. Яшьләр, берәрсенең ата-анасы өйдә булмаган кичне сагалап, чаршау артларына кача-поса беренче репетицияләренә керешәләр. Шушы беренчеләр арасында Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗановның абыйсы Мөхәммәтҗан, Мәгъсум Шәмсетдинов һәм тагын берничә егет була. Дөнья күргәнрәк сәүдәгәр балалары һәм приказчиклар — болар. Берничә күнегүдән соң, зурдан кубып халык алдына чыгарга җөрьәт итмичә, бер бай өендә уздырылган яшьләр кичәсендә татарча беренче театр уйныйлар. Кичәдә катнашучылар аларның уенын хуплап кабул итәләр, күңелләрен күтәреп җибәрәләр. Ләкин ул арада җәй җитә. «Артистлар» сәүдә эшләре белән төрлесе төрле якка таралышалар.

Ә шул җәй урталарында монда «Сәйяр» труппасы килеп чыга да, тагын яшьләр күңеленә ут сала. Мирхәйдәр җитәкчелегендә репетицияләрне яңартып җибәрәләр һәм тиздән унөч кеше катнашында беренче ачык спектакль уйнала.

Орскида Мирхәйдәр күңеленә беренче мәхәббәт нурлары да бөркелә. 1916 елның җәй башларында ул шәһәрнең иң бай сәүдәгәрләреннән исәпләнгән Борнаевларның Гөлсирә исемле уналты яшьлек сылу кызларын очрата. Тиздән алар кабат очрашалар, сөйләшәләр, аңла-

шалар. Танышу хөрмәтенә дип Гөлсирә бу «олы егет»кә үз фоторәсемен бүләк итә. Сөйләүләренә караганда, Гөлсирә «эчтән гүзәл, тыштан бик чибәр» бер кыз була. Мирхәйдәр кыз бүләк иткән фоторәсем артына:

*Гомерем барда исемең телләремдә*
*Гөлләр белән тиңләп тирбәлер,*

— дип язып куя.

1916 елның җәй айларын Мирхәйдәр Фәйзи Орскидан утыз чакрымнар көнбатыштарак, Гөберлә суы буендагы кечерәк бер авылда, «ямьле бер табигать кочагында» уздыра — өлкән абыйларына печән чабуда, урак уруда булыша. Аннары ерак Казан якларына, Шода авылында киявдә булган апасы янына кунакка бара. Анда авыл яшьләре белән аралашып, кичке уеннарда катнаша. Ә көзен, Орскидагы кечерәк үз бүлмәсенә кайткач, Гөлсирә белән танышу һәм Казан арты яшьләре белән очрашу хатирәләрен яңартып, «Галиябану» пьесасын язарга утыра. Пьеса 1917 ел башында язылып бетә, Оренбургтагы бер артист-режиссерга җибәрелә, хуплана. Тиздән аны Оренбургта һәм башка театрларда куялар. Әдип монда сөенә, әлбәттә.

Ә инде Орск урамнарында янсә сирәк-мирәк булгалап алган кичәләрдә Гөлсирә тугашны очратса, аның белән бер-ике кәлимә сүз сөйләшү бәхетенә ирешсә, ул тагын да сөенәрәк төшә. Унбиш-уналты яшеннән үзендә йөрәк өянәге сизеп яшәвенә карамастан, бу көннәрдә ул үзен чиксез бәхетле санап, зәгыйфь йөрәк тибешен дә тоймыйча, күкнең җиденче катын гизгәндәй яши.

Ләкин!.. Ләкин сөйгән кызы белән ярәшү, кавышу көннәре якынлашып килгән бер мәлдә, 1918 елның көз айлары кергәндә, Гөлсирәне ил буйлап таралган йогышлы авыру бернichә көн эчендә гүр иясе итә. Бу хәлдән кызның ата-анасы һәм вәгъдә куешкан Мирхәйдәр генә түгел, бөтен шәһәр халкы диярлек әче хәсрәт кичерә. Мирхәйдәр кайгыдан авыруга ук сабыша. Ә бераз тернәкләнгәч аның, бу кадерле шәһәрне ташлап, каядыр китү теләге уяна. Өязнең мәгариф бүлегендә аңа каладан ике йөз чакрымдагы ерак бер авылда китапханәче хезмәтен тәкъдим итәләр.

Ул заманнарда авылларда китапханәләр булганмы соң? — диярләр. Кайберләрендә булган, әлбәттә. Әйтик, егермеләп алтын приискасы тоткан Рәмиевләрнең байтак кына прииска бистәләрендә «уку өйләре» булган. Ә инде төп утарлары саналган Юлык авылында мәчет, мәдрәсә тотуга да, һәркем өчен оештырылган бай китапханәне булдыруга да алар чыгымны кысмаганнар. Әйтик, китапханә өчен урынны да барлык китап, журнал һәм газеталарны да алар сатып алган, һәр көнне китапханәне эшләтү шарты белән китапханәчегә хезмәт хакын да алар түләгәннәр. Әмма 1918 елда, гражданнар сугышы барышында, бу китапханәнең эше туктала, аның байлыгы төрле кулларга тарала башлый. Моны булдырмас өчен 1919 ел башында Мирхәйдәр Фәйзи шушы авылга китапханәче итеп җибәрелә. Мирхәйдәр килеп монда эшли башлауга, 1919 елның март аенда, Башкортстан республикасы оеша. Юлык, Баймак тирәләре шушы яңа республикага керә. Драматург һәм шагыйрь Мирхәйдәр Фәйзинең калган язмышы (бер кыш Казанда балалар китапханәсендә эшләвен санамаганда) шушы Юлык, Баймак, Темәс авыллары белән бәйле.

1928 елның июль башында бу олы әдип һәм кызыклы шәхес Баймакта туберкулез авыруыннан вафат була. Ул гражданнар сугышы каһарманнары каберлегендә тантаналы шартларда җир куенына иңдерелә.

Хәзер матур бер шәһәргә әверелгән Баймак уртасындагы ул каберлек әле дә бар, исән. Ә Мирхәйдәр Фәйзи каберенең һәйкәле соңгы елларда яңартылган — яңа таш куелган. Кабер ташына: «Видный советский драматург Мирхайдар Файзи. 1891—1928», — дип язылган.

Мирхәйдәр Фәйзи заманыннан бирле чыгып килүче «Октябрь байрагы» газетасы яңа бинага күчкән. Менә шул җыйнак бина каршында Мирхәйдәрнең мөлаем бюсты редакциягә килеп-китүчеләрне каршылап һәм озатып утыра. Димәк, Баймаклар әдипне онытмыйлар, олылыйлар.

Орск һәм Баймактан кала әдип биографиясендә үзенчәлекле урын биләгән, аның күңелендә тирән эз калдырган җир — Юлык дидек. Биредә дә олы яшьтәге апалар аны яхшы хәтерлиләр әле. Юлык урта мәктәбенең әдәбият классында әдипнең фоторәсеме һәм аңа багышланган стенд бар. Бу стендны шушы авыл укытучысы, һәвәскәр артист һәм үзешчән фотограф Фидаи Әбүбәкеров оештырган. Ул стендта Юлык укытучылары әүвәлге елларда куйган «Галиябану» спектакленнән күренешләр һәм Мирхәйдәр Фәйзигә өченче буын кардәш булган композитор Җәүдәт Фәйзинең истәлек хатлары урын алган.

Ләкин бу мәктәптә башка бер генә татар язучысының да рәсеме юк. Мәктәптә башкорт теле һәм әдәбияты укытыла, шунлыктан башкортча язучы әдипләр генә анда «урын» алганнар. Хәтта бабалары шушы авылдан булган Нәкый ага Исәнбәт тә монда «чит кеше» булып чыккан.

Юлык яшьләренең эчкерсезлеге, үзара мөнәсәбәттә самимилеге шагыйрь күңелен йомшарта, яшәртә, дәртләндерә. Ә инде Мәгърүфкамал исемле бик сада күңелле, нурлы йөзле кыз аны тәмам үзенә гашыйк итә. Шушы Мәгърүфкамал Әдһәмовага багышлап шагыйрь бернichә эпиграмма һәм шигырь яза, фоторәсемнәрен бүләк итә, аңа хатлар юллый. Менә ул кызга багышланган шигъри юллар:

*Былбыл кунган куркэгенә*
*Кеше түгел, гөлдер, дип.*
*Телләреңнән гөлләр тама,*
*Уйлыйм күңелең гөлдер, дип.*

Шушы юллар астына әдип: «Сине яратучы Хәйдәр Фәйзи. 1921 ел, 1 май, Юлык»,— дип өстәп куйган.

Табигый инде, бу кызга карата туган саф хисләрен әдип, үз хәлен алдан сиземләп, тыярга мәжбүр була. Ул Юлыктан китә. Ә Мәгъруфкамал тиздән кияүгә чыга. Әмма күңел түрендә Мирхәйдәр абыйсына булган хис-хөрмәтне мәңге саклый. Әдип бүләк иткән фотоларны, үзенә багышланган шигъри юлларны һәм хатларны да һич ташламый, сандык төбендә кадерләп кенә тота. Ире элегрәк бу хәлгә ризасызлык белгерткәләсә дә, ул кадерле хатирәләргә кагылырга җөрьәт итми. Мәгъруфкамал апа вафатыннан соң гына ул истәлекләр төрле тарафка тарала башлыйлар. Юлык кешеләре әйтүенчә, аларның бер ишесе Мирхәйдәр Фәйзи мирасы белән кызыксынучылар кулына да эләккән булырга тиеш.

Мирхәйдәр Фәйзи мирасы белән кызыксынучы һәм аны барлаучылар, белүемчә, бик ишле түгел. Илленче, алтмышынчы елларда Орск, Җүнәй якларында үзен Баймак шагыйре һәм журналисты дип таныткан Батыр Вәлидов булгалап китә. Эзләнүләре уңышлы буламы, юкмы — әйтә алмыйм. Казан матбугатында аның хезмәтләрен очратканым булмады.



Рәсемдә: *Мирхәйдәр Фәйзи туганнары арасында. Баймак, 1927 ел.*

Соңрак Мирхәйдәр Фәйзи эзләре буенча Орск, Баймак якларында яшь аспирант Муса Мөлеков та берничә мәртәбә була. (Хәзер ул Уфада яши, байтак еллар «Кызыл таң» газетасы редакторы булды). Житмешенче елларда ул шушы темага кагылышлы күпсанлы мәкаләләр бастырды. Ләкин, минем карашымча, ул хезмәтләрдә бер тенденциоз фикер сиземләнә: Муса иптәш Башкортстан җәмәгатьчелеген әдипнең әсәрләре башлыча Баймак төбәге вакыйгаларына нигезләнеп язылган, шул исәптән Галиябану образының прототибы да шул җирлектә яшәгән, дип ышандырмакчы була. Шул җәһәттән Җүнәй авылы исемен дә башкорт орфографиясенә якынайтып «Юнәй» дип бирә. Аспирантына ияреп булса кирәк, 5 нче класслар өчен чыгарылган «Татар әдәбияты» дәреслегенә дә бу татар-мишәр авылы исеме «Юнәй» дип кергән.

Галиябану образына һәм аның прототиплары мәсьәләсенә килсәк исә, Мирхәйдәр Фәйзинең 1919 ел февраленә хәтле Баймак төбәгендә булмавы хак. «Галиябану» пьесасын язу

дәверендә ул башлыча Орск яшьләре һәм Җүнәй авылы яшьләре белән генә аралаша. Язу өстәле артына утырыр алдыннан гына Казан ягындагы Шода авылында булып кайту да аның күңелен кузгаткан, билгеле.

Җитмешенче еллар башында Мирхәйдәр Фәйзи иҗатын һәм тормыш юлын «Орский рабочий» газетасы редакторы Михаил Григорьевич Секрет та өйрәнә. Аның бу эзләнүләренә башлангыч этәргечне Татарстан язучылары берлеге идарәсе бирде дисәм дөрес булыр. Әдипнең тууына 80 ел тулу алдыннан идарә Орскиның җәмәгать оешмаларына берничә хат юллаган иде. Ул хатларда Мирхәйдәр Фәйзинең татар һәм совет әдәбиятында тоткан урыны, әсәрләренең халык арасында киң таралганлыгы, пьесаларының Татарстан белән Башкортстан театрларында күп еллар дәвамында уңыш белән барганлыгы, ләкин әдип яшәгән һәм иҗат иткән «үз» шәһәрендә генә аның шәхесенә карата игътибар җитмәгәнлеге әйтелгән иде. Менә шушы хатлардан соң Орск шәһәре музеенда (ә калада хәзер өч йөз меңләп кеше яши) юбилей стенды оештырылды, халыктан Мирхәйдәргә бәйле истәлекләр, кулъязмалар, афишалар керә башлады. Ул яшәгән һәм иҗат иткән өйдә, шул фактны раслаучы белешмәләр тупланганнан соң, 1972 ел кышында истәлек тактасы беркетелде.

Шушы эшләрнең барышын күзәтү шәһәрнең партия комитеты тарафыннан бюро вәкиле М. Г. Секретка йөкләнгән иде. Бу эш белән ул бик теләп шөгыльләнде. Соңыннан аның үзе өчен дә байтак кына материал тупланганлыгы, Мирхәйдәр Фәйзигә багышлап документаль әсәр язарга керешкәнлеге мәгълүм булды. Ул әсәрдән өзекләр Оренбург өлкә газетасы «Южный Урал» белән «Орский рабочий» битләрендә басылып чыкты. Шулай итеп Мирхәйдәр Фәйзи эшчәнлеге белән бу өлкәдә яшәүче халыклар таныша алдылар.

Белүемчә, М. Г. Секрет ул хезмәтен элегрәк документ копияләре һәм әдипнең бүгенгәчә киң җәмәгатьчелеккә таныш булмаган фотолар белән бергә Татарстан китап нәшриятына да юллаган иде. Ләкин аңа «хезмәтнең әдәби эшләнеше йомшак» дип җавап бирелде, кулъязма кире кайтарылды шикелле. Юлыкта әйтүләренчә, Михаил Секрет Мәгъруфкамал апа сандыгына да юлны беренчеләрдән булып таба, Мирхәйдәр Фәйзи истәлекләрен саклаучы башка байтак кына кешеләрнең архив-сандыкларына да башлап юл 順ручыларның берсе була. Михаил Секрет Орск шәһәрендә әдип тууының 90 еллыгына атап тантаналы утырыш уздырышуда, шул көннәргә багышлап махсус буклет бастырып таратуда актив катнашты.

Мирхәйдәр Фәйзи иҗатын барлауга шактый өлеш керткән икенче шәхес — Орск шәһәре музее җитәкчесе Татьяна Григорьевна Черкас булды. Бүгенге көндә ул музейда Муса Җәлилгә багышланган ике стенд һәм Дәрдемәнд, Мирхәйдәр Фәйзи, Рәфгать Фәйзи (РСФСРның һәм Башкортстанның халык артисты, Мирхәйдәрнең агасы Шакирҗан улы) һ. б. милли «йолдызлар»га багышланган бер даими бүлек оештырылды. Шунда без Мирхәйдәр Фәйзинең кем булуын белдергән кыскача белешмә һәм әдипнең балачакта киеп йөргән укалы бәрхет кәләпүшен дә күрәбез. Киләчәктә, музей заллары киңәйтелгәч, әлегә «караңгы бүлмә»дә саклаган афишаларны, Мирхәйдәр Фәйзинең кайбер кулъязмаларын һәм фотоларын да «дөньяга» чыгару күздә тотыла икән. Бирсен ходай, дип кенә телисе кала...

Тагын шуны да әйтәсе килә. Байтак еллар дәвамында Орск шәһәр советының мәдәният бүлеге мөдире булып эшләгән Абдулла Ильясов, күренекле әдип иҗатын пропагандалау ниятеннән чыгып, аның берәр пьесасын Орск драма театрында сәхнәләштерергә теләгән иде. Ләкин әдип әсәрләренең русчага чын әдәби тәрҗемәләре булмау, очраклы кешеләр тарафыннан гына рус сәхнәсе теленә күчерергә азапланулары уңышка илтмәде.

Ә үз телебездә сәхнәләштерелгән «Галиябану», «Асылъяр»ларны без озак еллар буена соклана-соклана карарбыз әле!

Лирон ХӘМИДУЛЛИН

# КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

## «Галәкъ» («Оешкан кан») сүрәсе

ТУКСАН АЛТЫНЧЫ СҮРӘ. УНТУГЫЗ АЯТЬ

بسم الله الرحمن الرحيم
اقرأ باسم ربك الذي خلق ۝ خلق الإنسان
من علق ۝ اقرأ وربك الأكرم ۝ الذي علم
بالقلم ۝ علم الإنسان ما لم يعلم ۝ كلا إن
الإنسان ليطغى ۝ أن رآه استغنى ۝ إن إلى
ربك الرجعى ۝ أرأيت الذي ينهى ۝ عبدا
إذا صلى ۝ أرأيت إن كان على الهدى ۝
أو أمر بالتقوى ۝ أرأيت إن كذب وتولى ۝
ألم يعلم بأن الله يرى ۝ كلا لئن لم ينته
لنسفعا بالناصية ۝ ناصية كاذبة خاطئة ۝
فليدع ناديه ۝ سندع الزبانية ۝ كلا
لا تطعه واسجد واقترب ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).*

*Икъраэ бисми раббикәл-ләзи халәкъ (2). Халәкаль-инсанә мин галәкъ (3). Икъраэ вә раббүкәл-әкрам (4). Әлләзи галләмә бил-каләми (5). Галләмәл-инсанә мә ләм йәгъләм (6). Кәллә иннәл-инсанә лә-йатга (7). Әр-разәһүс-тәгъна (8). Иннә илә раббикәр-руҗга (9). Ә разәйтүл-ләзи йәнһа (10). Габдән иза салла (11). Ә разәйтә ин кәнә галәл-һуда (12). Әү әмәрә бит-тәкъва (13). Ә разәйтә ин кәззәбә вә тәвәллә (14). Ә ләм йәгъләм би-әннәл-лаһә йәра (15). Кәллә ләэил-ләм йәнтәһи лә-нәсфәгам-бин-насыйәти (16). Насыйәтин кәзибәтин хатыйэәтин (17). Фәльйәдгу надийәһ (18). Сәнәдгуз-зәбанийәтә (19). Кәллә ла түтыйгуһү вәсҗүд вәкътәриб (20).*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әй, Мөхәммәд! Укы син Коръәнне, барлыкка китерүче Раббеңнең исеме белән (2), һәрбер нәрсәне һәм адәмнәрне кан кисәгеннән яраткан Раббеңнең исеме белән ярдәм өстәп (3). Әй, Мөхәммәд! Коръәнне халыкка өйрәтү өчен укы син! Иң хөрмәтле булган Раббең шундый Заттыр (4). Ул каләм белән язуны өйрәтте (5). Һәм дә адәмне бер нәрсә белмәгән заманда, аңа тугры юлның һәм башка һөнәрләрне өйрәтте (6). Болай булып та, адәмнең азгынлыкта булуы яраклы булмас (7). Дөреслектә, адәм озын маллы булып, ярдәмсез булганы өчен тугрылыктан язар (Монда Әбү Җәһил күздә тотыла) (8). Әй, яман адәм! Дөреслектә, үлгәннән соң кайтачак җир Раббең тарафынадыр. Гафил булма, малыңа алданма, ахыр көндә газапка эләгерсең (9)! Әй, Мөхәммәд! Күрәсеңме, (10) намаз укучы колны намаздан тыюны теләгән кешене (11)? Әгәр дә ул тыелган кеше тугрылыкта булса (12), яки тәкъвалык белән боерса (13), һәм дә тыючы кеше хакны ялганга чыгарып иман китерүдән йөз чөйсә (14), белмәсме ул кеше Аллаһы Тәгалә аның бу эшен белеп торганын?

---

Дәвамы. Башы 9, 10 саннарда.

Ягъни Әбү Җәһил хак якта булып, рәсүл ялган якта булса, Аллаһы Тәгалә аларның хак яктысына ярдәм биреп, рәсүлне сакламыйча Әбү Җәһилне өстен кылыр иде дип уйламыймы? дигән сүздер. Тыелучы — рәсүл, тыючы — Әбү Җәһил (15). Намаздан тыючының бу эше яман эштер. Әгәр дә ул намаздан тыючы кеше бу бозыклыгыннан тыелмаса (16), ялганчы һәм дә азгын булучы маңгай чәченнән тотарбыз, ягъни ахирәт көнендә (17). Ул шул вакытта үзенең мәҗлестәшләрен өндәсен дә Безнең газабыбыздан котылсын! (18). Без дә үзебезнең дошманнарны газап кылу өчен булган зәбаниләребезне чакырырбыз. Шул чакта ул тыючының хәле яман булыр (19). Әй, Мөхәммәд! Син аның сүзен тотма, Раббеңә сәҗдә кыл, һәм дә Аңа якынлык хасил кыл! Бер дә андый тыючы дошманнардан курыкма!

## «Кадер» («Көч-кодрәт») сүрәсе

### ТУКСАН ЖИДЕНЧЕ СҮРӘ, БИШ АЯТЬ.

بسم الله الرحمن الرحيم
إنا أنزلناه في ليلة القدر ۝ وما أدراك ما
ليلة القدر ۝ ليلة القدر خير من ألف شهر ۝
تنزل الملائكة والروح فيها بإذن ربهم من
كل أمر ۝ سلام هي حتى مطلع الفجر ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Иннә әнзәлнәһү фи ләйләтил-кадри (2). Вә мә әдракә мә ләйләтул-кадри (3). Ләйләтул-кадри хайрум-мин әлфи шәһрин (4). Тәнәззәлул-мәләәикәтү вәрруху фиһа би-изни раббиһим-мин күлли әмрин (5). Сәләм, һийә хәттә мәтлагыйль фәҗр (6).*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Дөреслектә Без Коръәнне кадер кичендә иңдердек (2). Һәм син кадер киче нинди булуы турында нәрсә беләсең? Ул — олуг булган кадер кичедер. Аны Аллаһыдан башка зат белә алмаган (3). Кадер киче — мең елдан да изгерәктер (4). Ул кичтә фәрештәләр һәм дә Җәбраил Раббеләренең рөхсәте белән, тәкъдир ителгән һәрбер эш сәбәпле иңәләр (5). Ул кич таң туута кадәр һәрбер мөэмин-мөселманга сәламәтлектер[1]

## «Бәййинәт» («Ачык билге») сүрәсе

### ТУКСАН СИГЕЗЕНЧЕ СҮРӘ, СИГЕЗ АЯТЬ.

بسم الله الرحمن الرحيم
لم يكن الذين كفروا من أهل الكتب
والمشركين منفكين حتى تأتيهم البينة ۝

رسول من الله يتلوا صحفا مطهرة ۝ فيها
كتب قيمة ۝ وما تفرق الذين أوتوا الكتب
إلا من بعد ما جاءتهم البينة ۝ وما أمروا

---

[1] Кадер киче — Рамазан Шәрифнең егерме жиденче кичәсендә Кадер киче буладыр. Бу кич мөселманнарның диннәренең асылы булган Коръән Шәриф иңгән кичтер. Бу кичтә Аллаһы Тәгалә тарафыннан фәрештәләр җиргә иңеп, мөэмин-мөселманнар өчен ярлыкауны сорарлар. Кояш баюдан таң аткангача кадер киче булыр. Бу кичтә һәркем дә тәүбә-истигъфарда булырга тиешле. Бу кичтә кылынган гамәлләр мең ай тоташ кылынган гамәлләрдән артык буладыр (Ш. Хәмиди искәрмәсе.)

إِلَّا لِيَعْبُدُوا اللَّهَ مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ حُنَفَاءَ
وَيُقِيمُوا الصَّلَوٰةَ وَيُؤْتُوا الزَّكَوٰةَ وَذَٰلِكَ دِينُ
الْقَيِّمَةِ ۝ إِنَّ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْ أَهْلِ الْكِتَٰبِ
وَالْمُشْرِكِينَ فِي نَارِ جَهَنَّمَ خَٰلِدِينَ فِيهَا ۚ أُولَٰئِكَ
هُمْ شَرُّ الْبَرِيَّةِ ۝ إِنَّ الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا

الصَّٰلِحَٰتِ أُولَٰئِكَ هُمْ خَيْرُ الْبَرِيَّةِ ۝ جَزَاؤُهُمْ
عِنْدَ رَبِّهِمْ جَنَّٰتُ عَدْنٍ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا
الْأَنْهَٰرُ خَٰلِدِينَ فِيهَا أَبَدًا ۖ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ
وَرَضُوا عَنْهُ ۚ ذَٰلِكَ لِمَنْ خَشِيَ رَبَّهُ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Ләм йәкүнил-ләзинә кәфәру мин әһлил-китаби вәл-мушрикинә мунфәккинә хәтта тәэтийәһумул-бәййинәтү (2). Расулумминәл-лаһи йәтлу сухуфәм-мутаһһаратән (3). Фиһа күтүбүн каййимәһ (4). Вә мә тәфәрракаль-ләзинә үтул-китабә иллә мим-бәгъди мә җаәт-һуммул-бәййинә (5). Вә мә умиру иллә лийәгъбудул-лаһә мухлисыйнә ләһуд-динә хунафәэә вә йукыймус-салатә вә йуэтуззәкәтә вә залике динул-каййимәһ (6). Иннәл-ләзинә кәфәру мин әһлил-китаби вәл-мушрикинә фи нари җәһәннәмә халидинә фиһа, үләэикә һум шәррул-бәриййәһ (7). Иннәл-ләзинә амәну вә гамилүс-салихати үләэикә һум хайрул-бәриййәһ (8). Җәзаэүһум гыйндә раббиһим җәннәту гаднин тәҗри мин тәхтиһаль-әнһару халидинә фиһа әбәда, радыйал-лаһу ганһум вә раду ганһ, залика ли-мән хашийә раббәһ.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әһле китаптан, ягъни дини китапларның берсенә (Тәүрат, Инҗил, Коръәнгә) ияреп дин тотучылардан һәм дә мөшрикләрдән, ягъни мәҗүсиләрдән булган кяферләр, хаклык билгесе булган (2), хаклыкны беркетү иясе язуларны эченә алган пакь сәхифәләрне укып торган (3) Аллаһының рәсүле, ягъни илчесе килгәнче таралышучы һәм дә аерылышучы булмады, ягъни рәсүлулла — пәйгамбәр булганыннан соң гына таралыштылар (4). Китап бирелгән кешеләр рәсүлулла килгәнче таралышмаганнар иде, рәсүл килгәч, алар аерылыштылар. Ягъни рәсүлулла килгәнче яһүд һәм христиан Тәүрат һәм Инҗилдә сыйфатлануына күрә Мөхәммәдкә (Аңа Аллаһының сәламе булсын!) иман китерәчәк булып торалар иде. Рәсүлулла пәйгамбәр булгач, көнләшеп, рәсүлуллага иман китерүдән баш тарттылар (5). Ул кяферләр үзләренең китапларында боерылмадылар, бары бер булган Аллаһыга, Аның диненә ихлас баглап иман китерү белән генә боерылдылар һәм дә бозык иануларыннан хак иманга ашыгып боерылдылар. Намаз укуга, зәкят бирүгә боерылганнар иде. Бу эшләр белән боерган дин — хак һәм нык булган дин (6). Дөреслектә әһле китаптан һәм мөшрикләрдән булган кяферләр көферләре өчен җәһәннәм утында мәңге булырлар. Бу кешеләр — мәхлукларның, ягъни җан ияләренең иң явызлары (7). Дөреслектә, иман китереп изге гамәл кылган кешеләр — болар, мәхлукларның изгеләредер (8). Болар өчен Раббеләре каршында асларында елгалар ага торган Гаден җәннәтләре булучыдыр. Алар шул җәннәтләрдә мәңге булырлар. Алардан Аллаһы Тәгалә, Аллаһы Тәгаләдән алар разый булырлар. Бу дәрәҗәләр Раббеләреннән куркып, дөньяда вакытта изге гамәлләр кылган кешеләр өчендер.

## «Зилзәлә» («Җир тетрәү») сүрәсе

ТУКСАН ТУГЫЗЫНЧЫ СҮРӘ, СИГЕЗ АЯТЬ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
إِذَا زُلْزِلَتِ الْأَرْضُ زِلْزَالَهَا ۝ وَأَخْرَجَتِ
الْأَرْضُ أَثْقَالَهَا ۝ وَقَالَ الْإِنْسَٰنُ مَا لَهَا ۝

يَوْمَئِذٍ تُحَدِّثُ أَخْبَارَهَا ۝ بِأَنَّ رَبَّكَ أَوْحَىٰ
لَهَا ۝ يَوْمَئِذٍ يَصْدُرُ النَّاسُ أَشْتَاتًا لِيُرَوْا
أَعْمَٰلَهُمْ ۝ فَمَنْ يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ ۝
وَمَنْ يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Иза зүл-зиләтил-арду зилзаләһа (2). Вә ахраҗәтил-арду әскаләһа (3). Вә калəл-инсану мә ләһа (7). Йаумәизин тухәддису әхбараһа (5). Би-әннә раббәкә әуха ләһа (6). Йаумәэзий-йасдурун-насу әштатəл-ли-йурау әгъмаләһум (7). Фә-мәй-йәгъмәл мискалә зәррәтин хайрай-йәраh (8). Вә мәй-йәгъмәл мискалә зәррәтин шәррай-йәраh.*


СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаh хакына (1).

Кайчан җир үзенең тетрәү вакытында тетрәтелмеш булса (2), Җир үзенең авыр йөкләрен чыгарса (3), шул вакытта адәм әйтер: «Ни булды бу җиргә?» — дип (4). Шул көндә ул халыкка үзенең тетрәвен һәм дә йөкләрен чыгарып ташлавын бәян итәр (5). Моны бәян итүгә җирнең Раббесе — Аллаһы Тәгалә аңа вәхи белән белдергән булыр. Шул вәхи сәбәпле бәян итәдер (6). Ул көндә адәмнәр таралышып, хисап мәйданына төшәләр, үзләренең гамәлләренең җәзаларын күрсәтмәкләре өчен (7). Инде берәү дөньяда вакытында тузан кадәр изгелек эшләсә, шуны да күрер (8). Һәм тузан кадәр явыз гамәл кылган булса, аны да күрер, ягъни тузан кадәр генә изгелекләре булмаган кешеләр дә шул гамәлләренең җәзаларын күрерләр.

## «Гадийат» («Сугыш атлары») сүрәсе

### ЙӨЗЕНЧЕ СҮРӘ, УНБЕР АЯТЬ


بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
وَالْعَادِيَاتِ ضَبْحًا ۝ فَالْمُورِيَاتِ قَدْحًا ۝ فَالْمُغِيرَاتِ
صُبْحًا ۝ فَأَثَرْنَ بِهِ نَقْعًا ۝ فَوَسَطْنَ بِهِ جَمْعًا ۝
إِنَّ الْإِنسَانَ لِرَبِّهِ لَكَنُودٌ ۝ وَإِنَّهُ عَلَىٰ ذَٰلِكَ
لَشَهِيدٌ ۝ وَإِنَّهُ لِحُبِّ الْخَيْرِ لَشَدِيدٌ ۝ أَفَلَا
يَعْلَمُ إِذَا بُعْثِرَ مَا فِي الْقُبُورِ ۝ وَحُصِّلَ مَا
فِي الصُّدُورِ ۝ إِنَّ رَبَّهُم بِهِمْ يَوْمَئِذٍ لَّخَبِيرٌ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәл-гадийати дабхан (2). Фәл-мурийати кадхан (3). Фәл-мугыйрати субхан (4). Фә-әсәрнә биһи нәкъган (5). Фә-васатнә биһи җәмган (6). Иннәл-инсанә ли-раббиһи лә-кәнуд (7). Вә иннәһу галә заликә лә-шәһид (8). Вә иннәһу ли-хуббил-хайри лә-шәдид (9). Ә фә-лә йәгъләму иза бугъсирә мә фил-кубури (10). Вә хуссыйлә мә фис-судури (11). Иннә раббәһум биһим йаумәэизил-лә-хәбир.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ


Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаh хакына (1).

Сугыш атлары белән ант итәмен, кайчан ул атлар каты чабулары сәбәпле сулуларын тавышлап алсалар (2), һәм дә кичләрдә ташлык җирдә чабып, тоякларыннан ут чыгарган атлар белән ант итәмен (3). Атланган кешеләрен таң вакытында дошманнары өстенә китереп җиткезүче атлар белән ант итәмен (4). Ул атлар таң вакытында (5) тузаннар туздырып дошманнар арасына килеп җиттеләр[1] (6). Дөреслектә адәм үзенең Раббесенә карышучылар (7) һәм дә үзенең бу карышулыгына үзе дә шаһид, ягъни үзендә дә каршылыгын белдерә торган билгеләр бар (8). Һәм дә ул адәм малны бик каты сөючедер, ягъни малы булса да, Аллаһы Тәгалә юлына бирүдән саранланыр (9). Адәм белмәсме, кайчан каберләрдә булган нәрсәләр кубарылса (10), һәм дә күңелләрдә булган нәрсәләрне гамәл дәфтәрләрендә язылган булса, шул вакытта яманнар үзләренең һәлак булуларын уйламыйлармы (11)? Дөреслектә аларның Раббеләре шул кыямәт көнендә, бер дә шиксез, аларның күңелләрендә булган нәрсәләрне белүчедер.

[1] Бу аятьләрнең иңүе турында болай диләр: «Бер вакытта рәсүлебез бер тарафка атлы гаскәр җибәргән икән, бер ай үткән, һич тә болардан хәбәр беленмәгән», бу аять шул вакытта иңгән. (Ш. Хәмиди искәрмәсе.)

## «Әл-Каригаһ» («Кыямәт көне») сүрәсе

### ЙӨЗ ДӘ БЕРЕНЧЕ СҮРӘ. УНБЕР АЯТЬ


بسم الله الرحمن الرحيم
القارعة ○ ما القارعة ○ وما أدراك ما
القارعة ○ يوم يكون الناس كالفراش
المبثوث ○ وتكون الجبال كالعهن المنفوش ○
فأما من ثقلت موازينه ○ فهو في عيشة
راضية ○ وأما من خفت موازينه ○ فأمه
هاوية ○ وما أدراك ما هيه ○ نار حامية ○

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Әл-каригату (2). Мәл-каригату (3). Вә мә әдракә мәл-карига (4). Йаумә йәкунун-насу кәл-фәрашил-мәбсуси (5). Вә тәкунул-җибалу кәл-гыйһнил-мәнфуш (6). Фә-әммә мән сәкуләт мәвазинуһу (7). Фә-һувә фи гыйшәтир-радыйәһ (8). Вә әммә мән хаффәт мәвазинуһу (9). Фә-үммуһу һавийәһ (10). Вә мә әдракә мә һийә (11). Нарун хамийәһ.*


СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Кыямәт көне (2). Нәрсә ул Кыямәт көне (3)? Һәм син Кыямәт көне нинди булуы турында нәрсә беләсең (4)? Кыямәт көне — һәр нәрсәне куркытучы һәм һәр нәрсәне урыныннан кубаручы, куркынычлы көн. Ул Кыямәт көнендә адәмнәр — таралган чикерткәләр (5), таулар — тетелгән йоннар кебек булырлар (6). Инде ул көнне берәүнең гамәл үлчәүләре авыр булса (7), ул кеше үзенең күңеленә ошаган кәеф-сафада булыр (8). Әммә берәүнең гамәл үлчәве җиңел булса (9), ул кешенең урыны — һавийәһ булыр (10) һәм син һавийәһнең нинди булуы турында нәрсә беләсең (11)? Ул — кызулыкта чиктән чыгып, янып торучы ут.

## «Тәкәсүр» («Байлык белән мактану») сүрәсе

### ЙӨЗ ДӘ ИКЕНЧЕ СҮРӘ. СИГЕЗ АЯТЬ


بسم الله الرحمن الرحيم
ألهاكم التكاثر ○ حتى زرتم المقابر ○ كلا سوف
تعلمون ○ ثم كلا سوف تعلمون ○ كلا
لو تعلمون علم اليقين ○ لترون الجحيم ○
ثم لترونها عين اليقين ○ ثم لتسألن
يومئذ عن النعيم ○

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Әл-һакумут-тәкәсуру (2). Хәттә зуртумул-мәкабир (3). Кәллә сәүфә тәгъләмун (4). Суммә кәллә сәүфә тәгъләмун (5). Кәллә ләү тәгъләмунә гыйльмәл-йакыйн (6). Лә-тәравуннәһа гайнәл-йакыйн (8). Суммә лә-тәравуннәһа гайнәл-йакыйн (8). Суммә лә-тусьәлуннә йаумәэизин ганиннәгыйм.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ


Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Байлык белән мактану — сезне Аллаһыдан аера (2). Каберләргә барып күмелгәнче сезне байлык белән мактану шөгыльләндерде (3). Каберлеккә күмелүне онытып байлык белән мактанышу — яраклы эш түгел, андый эшнең яраксызлыгын киләчәктә белерсез, ягъни үлгәннән һәм дә үлеп кубарылганда белерсез дә үкенерсез (4)! Әгәр сез киләчәк куркынычлы кыямәтне үзегез күреп белгән кебек белсәгез

иде (*5*), маллар белән мактанышуны сөймәс идегез (6). Әмма эш сез уйлаганча түгел, ант итәмен, кыяматтә җәхим, ягъни җәһәннәм тәмугысын алдыгызда күрерсез (7). Шул вакытта Аллаһы Тәгалә тарафыннан үзегезгә бирелгән нигъмәтләреннән соралырсыз, ягъни «мактанышкан малыгызны кая куйдыгыз, фәкыйрьләргә бирдегезме?» дип соралырсыз да, җәһәннәм тәмугысына кертелерсез (8)! Шулай булгач, каберлеккә барганчы алдыгызны һәм артыгызны карагыз!

## «Гасыр» («Заман») сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ ӨЧЕНЧЕ СҮРӘ, ӨЧ АЯТЬ




ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәл-гасри (2). Иннәл-инсанә ләфи хусрин (3). Илләл-ләзинә амәну вә гамилүс-салихати вә тәвасау бил-хаккый вә тәвасау бис-сабр.*


СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Заман белән ант итәмен (2), дөреслектә адәм һаман хәсрәттә (3), мәгәр иман китереп, изге гамәл кылып, хаклык белән һәм дә сабырлык белән васыять итешкән кешеләр генә хәсрәттә түгелләр. Ягъни, дөнья-ахирәт сәгадәтле булачак кешеләр — шундый кешеләрдер, алар Аллаһыга һәм башка ышануы тиешле булган нәрсәләргә иман китерерләр, өсләренә тиешле булган изге гамәлләрнең кулларыннан килгәннәрен кылырлар. Шуннан соң бер-берсенә хак юлда булып, яманлыктан тыелу белән үгет бирешерләр.

## «Һүмәзәһ» («Хурлаучы») сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ ДҮРТЕНЧЕ СҮРӘ, ТУГЫЗ АЯТЬ




ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәйлул-ли-күлли һүмәзәтил-лүмәзәтин (2). Әлләзи җәмәга мәләвәгаддәдәһү (3). Йахсәбү әннә мәләһү әхъләдәһ (4). Кәллә ләйумбәзәннә фил-хутамәти (5). Вә мә әдракә мәл-хутамәһ (6). Нарул-лаһил-мукадәтү (7). Әлләти тәттәлигу галәл-әфъэидә (8). Иннәһа галәйһимум-мүэүсадәтүн (9). Фи гамәдим-мүмәддәдәһ.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Һәрбер мөэмин-мөселманны хурлаучыга, аларны яманлаучыга олуг газап. Вәлид бине Могаййирә кебекләр рәсүлулланы һәм дә мөэминнәрне хурлыйлар иде, шулар хакында иңде (2). Ул хурлаучы күп мал җыеп, аны санап гомерен үткәзә дә

(3), шул малы аны дөньяда мәңге калдырыр дип уйлый (4). Малны саҗап тору ахирәт көнендә файда бирми (5)! Әлбәттә, җирнең урталарына кадәр җитә торган (6), янып торучы һәм һәрбер нәрсәне яндырып, ашап торучы (7) утка ташланган булыр ул кяфер (8). Ул ут — зур, биек биналар эчендә багланган хәлдә (9), шул биналар эчендә газапланыр ул кяфер.

## «Фил» сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ БИШЕНЧЕ СҮРӘ, БИШ АЯТЬ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
أَلَمْ تَرَ كَيْفَ فَعَلَ رَبُّكَ بِأَصْحَابِ الْفِيلِ ۝
أَلَمْ يَجْعَلْ كَيْدَهُمْ فِي تَضْلِيلٍ ۝ وَأَرْسَلَ
عَلَيْهِمْ طَيْرًا أَبَابِيلَ ۝ تَرْمِيهِم بِحِجَارَةٍ مِّن
سِجِّيلٍ ۝ فَجَعَلَهُمْ كَعَصْفٍ مَّأْكُولٍ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).*
*Ә ләм тәра кайфә фәгалә раббукә би-әсхабил-фил (2). Ә ләм йәҗгал кәйдәһум фи тадлилив (3). Вә әрсәлә галәйһим тайран әбабилә (4). Тәрмиһим би-хиҗаратим-мин сиҗҗил (5). Фәҗәгаләһум кәгасфим-мәэкул.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Әй, Мөхәммәд! Күрдеңме, синең Раббең фил иясләрен ни рәвешле һәлак итте (2). Ул фил иялəре син туачак елда хәйләләр кылып, Мәккә халкын үзләренә иярту өчен Кәгъбәне фил белән ваттыру өчен килгәннәр иде. Әмма бу хәйләләре бушка чыкты. Филләре, Кәгъбәне ватарга боерылгач, сүзләрен тотмады (3). Шул вакытта Раббең аларга вак кына кошлар җибәрде (4). Ул кошлардан вак ташлар белән аттырып (5), фил иялəрен корт ашаган агач яфраклары кеби кылдырды.

## «Курәйш» сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ АЛТЫНЧЫ СҮРӘ, ДҮРТ АЯТЬ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
لِإِيلَافِ قُرَيْشٍ ۝ إِيلَافِهِمْ رِحْلَةَ الشِّتَاءِ
وَالصَّيْفِ ۝ فَلْيَعْبُدُوا رَبَّ هَٰذَا الْبَيْتِ ۝
الَّذِي أَطْعَمَهُم مِّن جُوعٍ وَآمَنَهُم مِّنْ خَوْفٍ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).*
*Лиэиләфи Курәйшин (2). Иләфиһим рихләтәш-шитаэи вәс-сайф (3). Фәлйәгъбуду раббә һазәл-бәйти (4). Әлләзи атгамәһумум-мин җугыйв-вә амәнәһум-мин хауф.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Аллаһы Тәгаләнең фил иялəрен һәлак итүе Курәйш гарәпләре кышкы һәм җәйге сәүдәләрендә электән ничек берегешеп кәрван белән сәүдәгә баралар иде. Һәркайчан шул рәвештә бердәмлектә булу өчен аларны фил иялəре кулына төшерүдән саклады (2). Гарәпләр кыш көне барысы бергә җыелып, сәүдә белән Йәмәнгә, җәй көне Шамга, ягъни Сүриягә баралар иде (3). Инде шулай булгач, курәйш гарәпләре бу өйнең хуҗасы булган (4), аларны ачлыктан туйдырган, хәвеф-хәтәрдән саклаган Раббеләренә гыйбадәт кылсыннар.

## «Магун» («Изгелек кылу») сүрәсе[1]

ЙӨЗ ДӘ ЖИДЕНЧЕ СҮРӘ, ЖИДЕ АЯТЬ

بسم الله الرحمن الرحيم

أرأيت الذي يكذب بالدين ۝ فذلك
الذي يدع اليتيم ۝ ولا يحض على
طعام المسكين ۝ فويل للمصلين ۝ الذين
هم عن صلاتهم ساهون ۝ الذين هم
يراءون ۝ ويمنعون الماعون ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Ә раәәйтәл-ләзи йукәззибу бид-дин (2). Фә-заликәл-ләзи йәдуггуль-йәтимә (3). Вә лә йәхудду галә тагамил-мискин (4). Фә-вәйлул-лил мусаллыйн (5). Әлләзинә һум ган салатиһим саһун (6). Әлләзинә һум йураәун (7). Вә йәмнәгунәл-магун.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әй, Мөхәммәд! Кыямәт көнен ялганга чыгаручы кешене таныдыңмы (2)? Танымасаң, сиңа бәян итәмен: ул (Әбү Җәһил) ятимне каты күңел белән кире кайтарып җибәрә (3). Һәм дә мескенне ризыкландырырга кызыкмый (4). Намазларын гафиллек сәбәпле, ягъни белми калып укымаганнарга (5), һәм дә икейөзлеләнү белән укучыларга (6), һәм дә өй арасында йөртелә торган йомышларны тыючыларга, ягъни балта, табак, иләк кебек нәрсәләрне бирмәүчеләргә (7) олуг газап бар.

## «Кәүсәр» («Мул») сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ СИГЕЗЕНЧЕ СҮРӘ, ӨЧ АЯТЬ

بسم الله الرحمن الرحيم

إنا أعطيناك الكوثر ۝ فصل لربك
وانحر ۝ إن شانئك هو الأبتر ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Иннә әгътайнәкәл-кәүсәр (2). Фәсалли ли-раббикә вәнхар (3). Иннә шанизәкә һувәл-әбтәр.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әй, Мөхәммәд! Без сиңа очы-кырые булмаган нигъмәтне (пәйгамбәрлекне) бирдек (2). Инде син намазны ихлас белән укып, тәвәләрне суй һәм итен ятимнәргә тарат (3). Дөреслектә синең дошманың исеме онытылачак, изгелекләрдән мәхрүм булачак.

---

[1] Бу сүрә — кайбер Коръәндә башланып китүче иң беренче сүз исеме белән аталып, «Әраәйтә» сүрәсе дип тә күрсәтелә (Ә. Х.).

## «Кәфирун» («Кяферләр — Алласызлар») сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ ТУГЫЗЫНЧЫ СҮРӘ. АЛТЫ АЯТЬ.

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

قُلۡ يَٰٓأَيُّهَا ٱلۡكَٰفِرُونَ ۝ لَآ أَعۡبُدُ مَا تَعۡبُدُونَ ۝
وَلَآ أَنتُمۡ عَٰبِدُونَ مَآ أَعۡبُدُ ۝ وَلَآ أَنَا۠ عَابِدٞ مَّا
عَبَدتُّمۡ ۝ وَلَآ أَنتُمۡ عَٰبِدُونَ مَآ أَعۡبُدُ ۝
لَكُمۡ دِينُكُمۡ وَلِيَ دِينِ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).*

*Куль йа әййүһәл-кәфирунә (2). Лә әгъбүдү мә тәгъбүдүнә (3). Вә лә әнтүм габидүнә мә әгъбүд (4). Вә лә әна габидүм-мә габәдтүмм (5). Вә лә әнтүм габидүнә мә әгъбүд (6). Ләкүм динүкүм вә лийә дин.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әй, Мөхәммәд! Әйт син кяферләргә: «Әй, кяферләр (2)! Мин сез коллык кылган Затка коллык итәчәк түгелмен (3) һәм дә сез дә мин гыйбадәт кылган Затка гыйбадәт кылачак түгелсез (4), һәм дә мин сезнең гыйбадәт кылган Затыгызга гыйбадәт кылмам (5). Сез дә минем гыйбадәт кылган Затыма гыйбадәт кылмассыз (6). Сез дә үз динегездә торырсыз, мин дә үз динемдә торырмын», — дип.

## «Наср» («Ярдәм») сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ УНЫНЧЫ СҮРӘ. ӨЧ АЯТЬ.

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

إِذَا جَآءَ نَصۡرُ ٱللَّهِ وَٱلۡفَتۡحُ ۝ وَرَأَيۡتَ ٱلنَّاسَ
يَدۡخُلُونَ فِي دِينِ ٱللَّهِ أَفۡوَاجٗا ۝ فَسَبِّحۡ بِحَمۡدِ
رَبِّكَ وَٱسۡتَغۡفِرۡهُۚ إِنَّهُۥ كَانَ تَوَّابَۢا ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).*

*Иза җаәә насрул-лаһи вәл-фәтхү (2). Вә рәәйтән-насә йәдхулүнә фи динил-лаһи әфвәҗән (3). Фә-сәббих бихәмди раббикә вәстәгъфирһү, иннәһү кәнә тәүүаба.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әй, Мөхәммәд! Кайчан Аллаһы Тәгаләнең ярдәме ирешсә, һәм дә Мәккә шәһәрен алу вакыты җитсә (2), һәм дә адәмнәрнең Аллаһының диненә груһ-груһ булып керүен күрсәң (3), шул вакытта Раббеңә шөкер итеп тәсбих әйт, һәм дә тәүбәләрне кабул кылучы Раббеңә ялварып, гонаһларны ярлыкавын үтен!

## «Ләһәб» («Ялкын») сүрәсе[1]

ЙӨЗ ДӘ УНБЕРЕНЧЕ СҮРӘ. БИШ АЯТЬ.

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

تَبَّتۡ يَدَآ أَبِي لَهَبٖ وَتَبَّ ۝ مَآ أَغۡنَىٰ عَنۡهُ
مَالُهُۥ وَمَا كَسَبَ ۝ سَيَصۡلَىٰ نَارٗا ذَاتَ لَهَبٖ
وَٱمۡرَأَتُهُۥ حَمَّالَةَ ٱلۡحَطَبِ ۝ فِي جِيدِهَا
حَبۡلٞ مِّن مَّسَدِۭ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Тәббәт йәда Әби Ләһәбив-вә тәбб (2). Мә әгънә ганһу мә кәсәб (3). Сәйәслә нарән зәтә ләһәб (4). Вәмраәтуһу, хаммәләтәл-хатаби (5). Фи җидиһә хабләум-мим-мәсәд.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әбү Ләһәбнең заты һәлак булсын иде, һәм ул чыннан да һәлак булды (2). Аны һәлак булуыннан малы да, кәсеп кылып тапкан нәрсәсе дә коткармады (3). Тиз көндә Әбү Ләһәб үзе (4) һәм дә хатыны, утын күтәреп (5), һәм дә муенында хөрмә мунчаласыннан җеп булган хәлдә утка керерләр[2].

## «Ихлас» сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ УНИКЕНЧЕ СҮРӘ, ДҮРТ АЯТЬ

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

قُلْ هُوَ اللّٰهُ أَحَدٌ ۝ اَللّٰهُ الصَّمَدُ ۝ لَمْ يَلِدْ ۝
وَلَمْ يُولَدْ ۝ وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Куль һүвәл-лаһу әхад (2). Аллаһус-самәд (3). Ләм йәлид вә ләм йүләд (4). Вә ләм йәкул-ләһу куфүүән әхад.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Бер заманда мөшрикләр, ягъни мәҗүсиләр Аллаһының илчесе Мөхәммәд пәйгамбәрдән сорадылар: «Синең Раббең алтынныммы, көмештәнме, тимердәнме?» — дип. Шуларга җавап өчен бу сүрә иңде. Мәгънәсе (1): Әй, Мөхәммәд! Әйт син кяферләргә: «Минем Аллаһым бер (2), Ул һичнәрсәгә мохтаҗ түгел (3), Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады (4), һәм дә Аңа һичбер зат тиң булмады», — дип.

## «Фәләкъ» («Таң») сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ УНӨЧЕНЧЕ СҮРӘ, БИШ АЯТЬ

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ ۝ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ ۝
وَمِنْ شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ ۝ وَمِنْ شَرِّ النَّفّٰثّٰتِ
فِي الْعُقَدِ ۝ وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Куль әгузу би-раббил-фәләкый (2). Мин шәрри мә халәка (3). Вә мин шәрри гасикыйн иза вәкаб (4). Вә мин шәррин-нәффасати фил-гукади (5). Вә мин шәрри хасидин иза хәсәд.*

---


[1] Бу сүрә «Мәсәд» («Хөрмә мунчаласы») дип тә атала. Кайбер Коръәндә «Ләһәб» дип, ә кайберсендә «Мәсәд» дип күрсәтелә. (Ә. Х.)

[2] Бу сүрәнең иңүенә сәбәп: рәсүлебезгә «Үзеңнең якын туганнарыңны хаклыкка өндә!» дигән аять иңгәч, рәсүлулла туганнарын җыйды да хаклыкка өндәде. Шунда Әбү Ләһәб: «Син безне шуның өчен чакырдыңмы?» дип таш белән рәсүлуллага атмак булды. Шуннан соң бу сүрә иңде. Әмма хатыны рәсүлулланың йөри торган юлына агачлар ташлый иде, рәсүлулланы җәфаламак өчен. (Ш. Хәмиди искәрмәсе.)

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Әй, Мөхәммәд! Әйт син: «Аның яраткан, ягъни барлыкка китергән нәрсәләренең зарарыннан таңны тудыручы Раббемә (2), сыенам (3). Һәм дә, караңгылыгы һәрнәрсәне каплаучы караңгы кичтән сыенам (4) һәм дә төеннәргә сихер теләп өрүче хатыннарның зарарларыннан (5), шулай ук көнчеләрнең көнләшүләреннән Раббемә сыенам.

## «Ән-нас» («Кешеләр») сүрәсе

ЙӨЗ ДӘ УНДҮРТЕНЧЕ СҮРӘ, АЛТЫ АЯТЬ




ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Куль әгузү би-раббин-наси (2). Мәликин-наси (3). Иләһин-наси (4). Мин шәррил-вәсвасил-ханнас (5). Әлләзи йүвәсвисү фи судурин-наси (6). Минәлҗиннәти вән-нас.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Әй, Мөхәммәд! Әйт син: «Мин адәмнәрнең Раббесе (2), Адәмнәрнең Alласы булган Раббемә сыенам (3). Вәсвәсә кылып, ягъни күңел аздырып изге гамәлләрне кичектерүче заттан, ягъни шайтаннан (4), җеннәрдән һәм адәмнәрдән дә булып (5), адәмнәрнең күңелләрендә вәсвәсә кылучы заттан сакланам (6).

Коръән сүрәләрен, аларның транскрипциясен һәм тәфсирен басмага Әнвәр ХӘЙРИ әзерләде.

**Китап күзәтү**

# БАБИЧ ҺӘМ АНЫҢ КИТАБЫ

Шәехзадә Бабичның 1990 елда басылып чыккан «Зәңгәр җырлар» исемле әсәрләр җыентыгы мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тормышында гаять зур вакыйга. Озак, бик озак көтте укучыларыбыз бу җыентыкны. Буталышлар дәвереңең әрнеткеч, дәһшәтле фаҗигасе канлы пәрдә белән каплап, яшереп яткырды ул җыентыкны. 70 еллар каплап торды. Ниһаять, менә бу көнне дә күрү насыйп булды. Җыентык куллрыбызга керде. Күңелләребезнең юраганнары юш килде: Бабич — яңа әдәбиятыбызның Тукай, Такташ, Туфаннар масштабындагы, шул шагыйрьләр тибындагы, шул исемлектән һәм әдәбиятыбыз, шигъриятебез яшәешеннән аерып булмый торган бер күренеш. Шигъриятебез Бабичсыз тулы һәм төгәл була алмый. Ансыз ул кимчелекле, зәгыйфь булачак. Тукай традицияләре совет чоры татар поэзиясенә, Такташларга, Туфаннарга бары тик Бабич аша гына килә. Бабич — шигъриятебезнең әдәбияттан читләштерү мөмкин булмаган зарури бер өлеше. Ләкин аның бу олылыгы, бу әһәмияте бүгенгәчә игътибардан читтә торды. Әйтик, бу җыентык шикелле сайланмасы үз вакытында, 20 нче еллар башында мәйданга чыккан булса, бу иҗат күптән фән күзенә ташланыр иде. Әлбәттә, шагыйрьне игътибардан читләштереп торган, тискәре юнәлештә эшләгән башка сәбәпләр дә бар.

Бабич — безнең әдәбиятта бик тә үзенчәлекле язмышка ия шагыйрь. Чынлыкта, Бабич дигән традицион мәгънәдәге шагыйрь ул чакны әдәбиятта күренми дә кала. Әдәби хәрәкәттә, дөресен әйткәндә, ул катнашмый. Ул — шигырьләр дә сызгалаучы бер шәкерт кенә. Ул шәкертләр хәрәкәте атаманы. Ул — яшьләр уеннарының башлыгы, сәхнә кызыкчысы. Бабич — әдәби хәрәкәт шагыйре түгел, тормыш җырчысы. Г. Ибраһимовка шәкерт төшү дә аны әдәби хәрәкәт атмосферасына алып кереп китә алмый. Киресенчә, тормышында ул, Ибраһимов, Гафури һ. б.лардан читләшеп революцион сугышлар юлына таба китә. Икенчедән, Бабич үзенең язган шигырьләре кайларда чәчелеп калганлыгын үзе дә белмәгән булуы мөмкин. Табигать аңа тиңсез муп талант биргән. Яшьлек «җилбәзәклеге»нә әртелеп, аның каләменнән шул чор поэзиябезнең асыл җәүһәрләре, яшен атылгандай, әдәбиятка чәчрәгән дә торган. Аларны танып, бер җыентык — әдәбият объекты итеп мәйданга куюю теләге бер әүнең дә күңеленә килмәгән. 1922 һәм 1925 ел җыентыклары да социализм шаукымы көч ала барган шартларда инде бу бурычны үти алмаганнар. Өченчедән, шагыйрь бик тә, бик тә яшьли дөньядан китә. Кичә генә шәкертлектән чыккан 24 яшьлек бу шук егет — татар шигърияте кебек могтәбәр, үтә дә җитди феноменның терәк баганаларыннан берсе булыр дигән уй кем күңеленә генә килә алсын соң?..

Юк, «терәк багана» сүзләрендә аз гына да арттыру юк. Яңа җыентык Бабичның Тукайлар, Такташлар кебек үк шигъриятебездә яңа баскыч булганын күрсәтә.

Җыентыкта Тукай традициясенә тоташкан шигырьләр күплеге игътибарны җәлеп итә. Әйе, яшь шагыйрь Бабич — Тукай иҗаты үсентесе, Тукай шәкерте. Әмма бу, Тукай традициясендәге шигырьләрне игътибар белән укысак, аларда нәкъ менә Бабичлык, үзенчәлек — оригинальлек, кемгәдер ияреп ясалганлык түгел, чын сәнгатьчәнлек, ихлас (конкрет) эстетик-эмоциональ накал барлыгын сизәмлибез. Юк, бу шигырьләрендә Бабич һич кенә дә остаз чабуына ябышкан шәкерт түгел, үз кыйбласы — үз ориентиры булмаган «иярчен», эпигон түгел. Бабичның Тукай традициясендәге шигырьләре остазы иҗатыннан шактый аерылып та тора. Ул аерымлану әсәрнең мәгънә тирәнлегенә яшерелгән. Аны аңлауга шигъриятебездә Бабичтан башлап үсә барган яңа бер юнәлеш аша чыгып була. Халык иҗаты, җырлар традициясенә таянып, Бабич иң җитди темаларда да «шигъри шаярулар», шукланулар («теш ырҗайтулар»), Такташтагы «Нәни шаярулар» татар поэзиясе өчен үзенчәлекле булмаган парадокслар белән «уйнаулар» традициясен активлаштырып җибәрә. Әйткәнебезчә, хәтта аның иҗат биографисе дә шук шәкертләрнең шигырь белән шаяру төсен ала. Мондый шигырьләрнең югары классика, поэтик казанышларыбыз дәрәҗәсенә күтәрелүе аларның «шуклык», «уен» гына булмаганын, аларның дөньяга яңа бер мөнәсәбәт, дөньяга яңача караш — яңа фәлсәфә тантанасы авазы булганын искәртәләр, («Гөнаһ — җәза», «Аптыраш», «Әй, адәм балапары» һ. б.), шул характердагы күп шигырьләре. Соңыннан Такташ үстереп алып киткән, әмма Бабичта формалашкан икенче бер тармак «героик индивидуализм» ши-

гырьләре дә нәкъ шул характерда. «Тукай традициясендәге» шигырьләргә дә менә шул ноктадан күз салсак, аларның да үзенчәлеге, аерымлыгы нәкъ шул яңа мөнәсәбәткә — яңача дөньяга карашка барып тоташуын ачыкларбыз. Алар да, халык инде үз иткән традиция калыбына салынып шул ук яңа мөнәсәбәт, яңача дөньяга карашны халык аңына, халык фикеренә һәм яшәеш-көнкүрешне сеңдерү бурычын үти.

Бабичның матбугатта чыгуларына игътибар итик. «Зәңгәр җырлар» җыентыгыннан күренгәнчә, Бабичның «Шура»да Оренбург — 24, «Кармак»та — 20 шигыре һәм шул журналның тагын алты санында «Китабеннас» басма күрә. «Кармак»та ук әдибнең 14 проза әсәре чыга. Уфадагы «Тормыш» газитәсендә — 5, «Иректә» — 3, «Безнең юл» һәм «Солдат теләге» газитәсендә берәр, үзе яшәгән Уфа шәһәре матбугатында барлыгы — 10 шигыре басылган. Троицк шәһәрендәге «Акмулла» журналында 4 шигыре һәм 4 проза әсәрен, «Хөр милләт» газитәсендә 3 шигыре, барлыгы — 11 әсәре дөнья күрә. Казандагы «Аң» журналында — 6 шигыре, Мәскәүдәге «Сүз» газитәсендә бер шигыре басыла. Болар — Бабичның көндәлек әдәби һәм иҗтимагый хәрәкәттә катнашы. Бу статистикадан шундый нәтиҗәгә килеп була: беренчедән, Бабич, Акмулла кебек, илнең Көнчыгыш төбәкләренә йөз тоткан шагыйрь. Икенчедән, искитәрлек хәл: Бабич — «Шура» шагыйре икән ләбаса! Бу фәнни диярлек журналда тагын безнең кайсы зур шагыйребез шулкадәр шигырь бастырды икән? Димәк, беренче адымнарыннан ук, Бабич «Шура»да — аңлау, теләктәшлек, яклау таба. Бик игътибар итәрлек факт ич бу! «Шура» редакторы Риза Фәхретдинев — шигъри классикабызны иң актив пропагандалаган, аны формалаштыруда җиң сызганып катнашкан шәхес. Тиңсез лирик Шәмсетдин Зәкине ул әдәбиятыбызга башлап тәкъдим итә, киләчәк буыннарга шагыйрь мирасыннан бай үрнәкләр аның тырышлыгы белән генә сакланып кала. Гасыр тузаны астыннан күтәреп, әдәбиятыбыз тарихына Әбелмәних Каргалыйны ул кертеп калдыра. Мөхәммәтсадыйк әфәнденең «Фәрьяд», «Фәган» (1901, 1903) китаплары... Беренче адымнарыннан ук Тукайны танып, «Вакыт» битләрендә аның иҗатын пропагандалауны да башлап җибәрә. Бактың исә, Бабич та аның фатыйхасы белән канатланган икән ләбаса! Әйе, Риза хәзрәт игътибары ул вакыт өчен аз нәрсә түгел бу!

Бабич иҗатының (һәм тормыш фаҗигасенең дә) мәгънәсенә әнә шул «Көнчыгыш кыйбласы» аша чыгып була. Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар фәннилегеннән, Г. Исхакый, Ф. Кәримиләр утлы публицистикасыннан соң, әдәбият, көтмәгәндә, Бабич прозасында гүя кабат Тукай полемикасына әйләнеп кайта. Оренбург басмалары «Шура», «Кармак», (авторы Бабич), прозасында, тематик яктан Тукай эзлекләренә һәм кискенлегенә белән, «сүнгәнме, әллә йокпаганмы» гынамы Уфаны «яңа культура үзәге» ролендә күрер өчен ярсу көрәш алып бара. Әгәр максат — культура өлкәсендә Уфаны замана югарылыгына китерү генә булса, нигә соң әле ул яңа татар мәдәнияте үзәге булып формалашкан Казанга таянасы итми? Киресенчә, һәр уңай очрактан файдаланып, Казанның бу максатка яраксызлыгын аэсызыклап үтәргә тырыша кебек. Күрәсең, Бабич иҗатында «замана югарылыгы» турында гына түгел, ә яңа, бөтенләй әр-яңа мәдәният, яңа мөнәсәбәт — дөньяга яңа карашка нигезләнгән мәдәният турында сүз кузгатыла, Уфаны аның шул мәдәният үзәге итеп күрәсе килә...

Ул көн тормышында, иҗтимагый һәм мәдәни тирәлектә, Бабичның бу олы идеалына туры килерлек җирлек тә, аңа хезмәткә сәләтле кешеләр дә күренми. Әмма болар аның идеалын буш хыялга, аның ярсуларын буш куык шартлатуга әйләндерми. Чөнки инде тарих моңарчы күрмәгән 1905 ел революциясенең тәҗрибәсе бар, аннан да бигрәк, Бабич иҗатын мәйданга китергән 1917 елның якынлашкан гөрелтеләре бар. Шуңа Бабич ярсулары — кодрәтле, сөйләме һәм сәнгате — тормышчан, конкрет, хөкемнәре — логикалы, дәлилле-ышандыргыч һәм эзлекле. Бабич яклаган идеал шагыйрь иҗатында гәүдәләнгән, ул — яшәештәге яраксыз тискәре күренешләр белән килешә алмау, аларны инкяр итү, олы якты идеалны ярсып теләү, аңа тормышта урын даулап, эзлекле көрәш. Шуңа күрә шигырьләрендә Бабич бу көрәшнең Дон-Кихоты булып түгел, бәлки, чагыштыру кирәк икән, сихри Грааль капасына үтеп керү серен тапкан, тылсым чәшкесен кулга төшергән рыцарь Персеваль буларак мәйдан тота. Көнкүреш белән элемтәсе бик тә катлауландырылган олы идеалны әсәрләрендә шагыйрь үзенә урын һәм игътибар даулаган тормыш фактына әйләндерә, шул рәвешчә, халык фикеренең киләчәк (идеал) белән контактына юл сала. Шагыйрьнең бу казанышы әдәбиятыбызда тотрыклы күренешкә әйләнә. Февраль революциясеннән соңгы болганчык елларда Бурнаш үзенең поэмалары белән, Октябрь һәм Гражданнар сугышыннан соңгы тотрыксыз елларда,- Такташ гыйсьянчылык шигырьләре белән бу юнәлештә шуңа охшаш, шундый ук зур, матур казанышларга ирешәләр. Шул рәвешчә, Бабич — үтә катлаулы чорда бай тарихлы әдәбиятыбызда яңа бер юнәлеш башлап җибәргән шагыйрь булды.

Бу калын китап — дөньяда 24 ел гына яши алган егетнең барлык язганы түгел. Яшьлегеннән үк шагыйрь гүя халкының фикер органына, язу аппаратына әйләнгән. 1922 елгы җыентыгына сүз башында Г. Ибраһимов Гыйльми үзәккә Бабичның табылган кадәр язмаларыннан меңләгән бит мирас килеп кергәнен, киләчәктә аларны, әзерләп, аерым китаплар рәвешендә тулысынча чыгарыласын хәбәр итә. Ләкин дәһшәтле еллар бу язмаларның күлен күкка очыра. Алар әдәбиятыбызга керә алмый калалар: 1922 нче ел җыентыгына керми кал-

ган барлык язмалары юкка чыга. Инде табыпуларын да өмет итеп булмый диярлек. Бу зур китап, «Зәңгәр җырлар» җыентыгы — гүя шагыйрь иҗатының, артык олы булуы сәбәпле, яныл бетә алмастан, мифик феникс кошы кебек, яңгыннан яңарып, яшәреп, җанланып чыгуы сыман бер күренеш. Ул — мәдәниятебез мәйданына кайтып керде. Аның әдәбиятыбыз тарихында да үз урынын һәм үз бәясен апасына ышанасы килә. Бер уңайдан, бу җыентыкны, берәмтекләп барлап, җыеп, әзерләп, бай аңлатмалар белән чыгаруга зур көч һәм хезмәт куйган, шагыйрьнең авылдашы Галимҗан иптәш Гыйлманов тырышлыгын да тәкъдирләп узу кирәк.

Китапка бай фәнни хәзинә — искәрмәләр әзерләнгән. Әсәрләр, алардагы аерым хәлләргә ишарәләр, күп санлы шәхесләр турында гаять әһәмиятле, ышанычлы мәгълүматлар китерелә. Бу хезмәт үзе генә дә җитди фәнни казанышыбыз дигән бәягә лаек. Әмма биредә, уңышка мәдхия җырлау урынына, анда күренгән кайбер чатаклыкларны күрсәтү дә максатка муафыйк булыр дип уйлыйбыз. Аерым шәхесләрнең яшәү вакыты турында белешмәләрдә ашыгу нәтиҗәсе булган төгәлсезлекләр бар. 473, 512 нче битләрдә Г. Исхакыйның туган елы 1871 ел дип, ә менә 486 биттә, дөрес итеп — 1878 ел дип күрсәтелгән. 474 биттә — М. Иманколыйның үлгән елы 1938 ел дип күрсәтелгән. 486 биттә Шакир Мөхәммәдьяровның (Г. Ибраһимов замандашы) туган елы да 1873 ел дип, ялгыш күрсәтелә. 492 биттә Габдерәшит Ибраһимовның үлгән елы — 1922 дип, ә 516 биттә дөресе — 1944 ел дип күрсәтелә. 507 биттә Н. Думави үлгән елы — 1938, дөресе — 1933. 508 биттә Ж. Вәлиди үлгән елы — 1938, әдәбият тарихының 4 нче томында 1932. 522 биттә «Тәрҗеман»ның чыга башлавы — 1903, дөресе 1883.

Тагын түбәндәге тип чатаклыклар очраштыргалый. Г. Исхакый «Мөселман иттифакы» партиясе әгъзасы итеп күрсәтелә, ә ул — эсер (473 б.) Сембер (Ульяновск) шәһәре хәзерге Куйбышев дип күрсәтелә. (482 б.) Хөсәен Әмирхан исеме Хәсән дип бирелә (484 б.) һ. б.

Болар — вак кимчелекләр, әмма алар киләсе басмаларда кабатланмаска тиешләр.

Текстны редакцияләү өлкәсендә дә уйланасы очраклар бар. Бер өтерне кая куюдан гына да мәгънә төптән үзгәрә ала. («Аклагра ярамый, җәзаларга», «Аклагра, ярамый җәзаларга» очрагын искә төшерик). Мәсәлән, «Мунча роэясе» шигыре буенча (109 бит) күп белгечләр җыелып, бәхәсләшү аша, бер концепциягә килү зыян итмәс иде.

Шигырь үлчәме таләбе һәм «сыгылмалы иҗек» системасын файдалану (сүзгә иҗек өстәү, яки иҗек кыскарту), буенча тәзүче байтак эш башкарган, әмма ахыргача эзлеклелек күрсәтә алмаган. Бабич шигыре шундый, ноктасын ноктасына китереп, төгәл эшләнгән сәнгать ки, аның нәфислеге — шул үлчәмлегендә, ул һичнинди үлчәмнән чыгуларны күтәрә алмый. Шигырь — бу сүзләрнең шулай әйтелешенә чамалап язылган. Шагыйрьнең рифмалары да шундый: үзенә генә хас бер төгәллек, нәфислек тәшкил итәләр. Орфография дип, һич кенә дә аларның ул тәңгәллеген бозарга ярамый. Ритмик буыннар үлчәмлегә бозылу сизелгән урыннар да беренче басмаларда яки ашыгыч күчерү вакытында ялгыш үрын алыштырулар аркасында килеп чыккан нәрсә дип бәяләнергә тиеш. Әйтик, 131 биттә «Дип ачыккан кандалам салды кадәм» юлын, рифмада Бабич яңгырашына китерер өчен: «Дип, салды кадәм ашыккан кандалам («кан алам» дигән сүзгә), безнеңчә, урынлы да, тиешле дә төзәтмә була ала. 165 биттә дә:

*Юлыңның артын ял — торлесен,*
*Алдын ач — ак көннәр күренсен,*

— юллары аңлашылмый. Тексттан аның:

*Юлыңның артын ял, нурласын —*
*Алдын ач: ак көннәр күренсен,*

— рәвешендә булганы аңлашыла. Хәсән ага Туфаннан мин: «Җибәрсәләр җибәрсеннәр, Себер үзебезнеке» (216 бит) юлын: «Сөрсә сөрсеннәр Себергә: Себер — үзебезнеке» рәвешендә, ул аппетерацияләрнең мәгънәсен шәрехләү белән ишеткән идем. Ул моны һәм аның мәгънәсен Бабичның үзеннән ишеткән булуы да ихтимал. Җәмәгатьчелек арасына да ул шул рәвештә кереп киткән һәм халык авыз иҗаты материалына әйләнгән. Аны шул рәвештә бирү дә, безнеңчә, Бабичны бозу һәм төзәтү түгел, аны үз рәвешенә кайтару гына булыр иде. Ә бу вариантлар да югалмасын өчен, аларны тиешле аңлатмалар белән искәрмәләрдә бирергә кирәк булгандыр. «Байбикә кем! Тәнең шәп вә саудыр бит» юлында да (195 бит) үлчәм бозылу да бар, мәгънә чатаклыгы да сизелә. Ул да, күрәсең: «Байбикә кем, тәнең исән вә саудыр бит?» кебек, төгәллеккә китерелергә тиеш.

Бу безнең фикерләр генә түгел. Үз вакытында, Бабичның элекке басмаларында гадәттән тыш күп хаталарга юл бирелгәнлегенә җитди борчылып, Бабичны яхшы белгән Хәсән ага Туфан белән Сәйфи ага Кудаш, бер очрашуларында, шул хакта, киләчәк текстологларга хәтта махсус мөрәҗәгать язып калдыруны кирәк табалар. Галимҗан иптәш Гыйлманов, бер уңайдан, ул кимчелекләрнең дә байтагын чистәштергән. Калганнарын күру, киләсе басмаларда аларны берәмтекләп чистәштерү — алдагы мөһим бурыч булып кала.

Мәсгут ГАЙНЕТДИНОВ

## ДЕПУТАТЛАР БӘХӘСЛӘШӘ

15 октябрьдә Казанда Татарстан ССРның уникенче чакырылыш Югары Советының җиденче сессиясе ачылган иде. Сессия унбиштән артык мәсьәләне карауны көн тәртибенә кертте. Алар арасында «ТССРдагы милек турында», «ТССР дәүләт милкен үзгәртеп кору турында», «ТССРда референдум турында»гы закон проектлары, «ТССР Дәүләт гербы һәм ТССР Дәүләт флагы турында»гы мәсьәләләр дә бар иде.

«Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында»гы мәсьәләне көн тәртибенә кертү өчен депутатлар арасында кызу бәхәсләр булды. Бу исә сессия барган көннәрдә Ирек мәйданына җыелган халыкта зур ризасызлык тудырды. Нәтиҗәдә 15—16 октябрь көннәрендә халык һәм хокук саклау органнары арасында бәрелешләр булып алды.

Көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне тикшерү, кабул итү вакытында да депутатлар уртак фикергә килә алмый озак бәхәсләштеләр. Тора-бара бу хал депутатларны Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәшүчеләр белән «бердәм һәм бүленмәс Россия»не яклаучы төркемнәргә бүленүгә китерде.

Шуңа да карамастан, ТССР Югары Советы сессиясендә халкыбыз һәм җөмһүриятебез өчен мөһим карарлар кабул ителде.

ТССРның Дәүләт гербы һәм ТССРның Дәүләт флагы эскизлары проектларын тикшерүдә шулай ук байтак депутатлар катнашты. Дәүләт символларыбызны камилләштерү юнәлешендә төрле фикерләр, тәкъдимнәр әйтелде. Шуларны истә тотып, эшне дәвам итәргә кушылды.

Сессиядә Татарстан Республикасының Дәүләт бәйсезлеге акты турында карар проекты буенча республика Президенты М. Ш. Шәймиев чыгыш ясады.

Татарстан ССР Югары Советы ТССРның Дәүләт бәйсезлеге турындагы акт хакында карар кабул итте.

Сессиядә шулай ук «Татарстан ССР Конституциясенә (Төп Законга) үзгәрешләр кертү турында»гы мәсьәлә дә тикшерелде. Бу мәсьәлә буенча документларның проектларын әзерләү өчен халык депутатларыннан эшче группа төзелде.

## КАРДӘШЛӘР ЯКЛЫЙ

Татарстан Республикасының уникенче чакырылыш Югары Советы сессиясе барган көннәрдә сессиягә адресланган бик күп хатлар, телеграммалар алынды. Арада мондый эчтәлектәгесе дә бар иде:

«Без, суверен Үзбәкстан Язучылар берлегенең унынчы съездында катнашучылар, Татарстанның мөстәкыйльлеген яклыйбыз һәм милли бәйсезлек өчен көрәштә тугандаш татар халкына теләктәшлегебезне белдерәбез. Без теләсә кайсы халыкның дәүләт суверенитетын чикләүгә каршы. Кайчандыр үзенең куәтле дәүләте — Казан ханлыгы булган татар халкының мөстәкыйль җөмһүрият төзеп яшәргә тулы хакы бар».

Әлеге телеграммага Т. Мирзә, Ә. Синугыл, М. Көнҗабек, М. Али, З. Әгъләм, А. Шер, А. Вәлиев, Ч. Эргаш һ. б. әдипләр кул куйган.

## НИЗАМИ — ШАГЫЙРЬЛӘР ШАҺЫ

Низами Ганҗәви — бөтендөньяга билгеле шәхес. Аның иҗаты Көнчыгыш халыклары әдәбиятларына, ә соңрак «Хәмсә» исеме белән бөтендөнья әдәбиятына керә. Низаминың сюжетларына ияреп яңадан-яңа «Хәмсә»ләр туган, дөнья әдәбияты классиклары Сәгъди, Хафиз, Җами, Нәваи, Физули, Шекспир, Гете һәм башкалар шул сюжетка күпләгән шигырьләр, поэмалар иҗат иткәннәр.

Низаминың шигъри юллары милләттәшләре — азәрбайҗан халкы күңелендә яши, буыннардан буыннарга күчә килә. Аның исеме белән урамнар атала, мәйданнар Низами исемен йөртә.

Гомумтөрки генә түгел, гомумкешелек хәзинәсенә әйләнгән шигъри энҗеләр калдырып киткән Низами Ганҗәвинең тууына быел 850 ел тулды. Бу вакыйга уңае белән төрле чаралар үткәрелде. Низами әсәрләре тупланган китаплар басылып чыкты. Әлеге вакыйганы җөмһүриятебез дә билгеләп үтәргә тырышты. Матбугат битләрендә аңа багышланган язмалар басылып чыкты. Аның әсәрләре татарчага тәрҗемә ителде. 18 октябрьдә исә Татарстан Язучылар берлегендә Низаминың якташы, бөек шагыйрьнең исемен бөтен илгә таратырга җәяүләп чыккан замандашыбыз, яшь шагыйрь Алишер Әхмәтзадә белән очрашу булды. Әлеге очрашу вакытында бөек шагыйрь Низами Ганҗәвинең шигъри сүз җәгәрен үстерүгә, яшь әдипләр тәрбияләүгә бүген дә зур өлеш кертүе, аның шагыйрьләр шаһы булуы билгеләп үтелде.

## «АРГАМАК» ЮЛГА ЧЫКТЫ

Оештыручылары халык депутатларының Чаллы шәһәр Советы башкарма комитеты, «КамАЗ» акционерлык җәмгыяте һәм Чаллы язучылар оешмасы булган өр-яңа журнал нәшер ителә башлады. Журналның баш мөхәррире Айдар Халим: «Аргамак» татар матбугатында беренче, тулысы белән диярлек публицистик, ягъни җәмагатьчелекне бор-

чыган, көн кадагына суккан язмалар, үткен материаллар басмасы булачак»,— дип вәгъдә итә.

«Аргамак» журналының октябрь аенда укучылар кулына барып ирешкән беренче саны бу фикерләрне тулысынча раслый. Р. Хисматуллин, В. Байсар, Г. Малихов, С. Кудаш, Я. Игәнәй һәм башкаларның публицистик язмалары шул хакта сөйли. Журналда В. Имамов, Т. Таһиров һ. б. повесть, романнан өзекләре дә урын алган. Шигъри әсәрләргә дә киң урын бирелгән.

### ХӨРМӘТЛӘҮ

Рөстәм Яхин — халкыбызның яраткан композиторы, ТССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты. Бу елның август аенда аңа 70 яшь тулган иде. Шушы уңай белән 22 октябрьдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында зур тантана булды. Татарстан җәмәгатьчелеге, илнең төрле төбәкләреннән килгән күп санлы кунаклар, сәнгатькәрләр, язучылар, артистлар катнашкан мәҗлес иде ул. Аны ТССР Премьер-министрның беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты һәм чыгыш ясады.

Сәхнәдән Р. Яхин иҗат иткән күп кенә җырлар, романслар яңгырады. Танылган җырчыларыбыз И. Шакиров, Х. Бигичев, Р. Ибраһимова, З. Сәнгатуллина, Р. Ибраһимов һәм башкалар башкарган җырлар Рөстәм Яхинга бәйрәм чәчәкләре булып барып ирешге.

# ТССР һәм РСФСР Язучылар берлекләренең УРТАК БЕЛДЕРҮЕ

РСФСРның бәйсез Язучылар берлеге һәм Татарстанның бәйсез Язучылар берлеге, Россия һәм Татарстан халыкларының тулы мөстәкыйльлеккә хокукларын танып, түбәндәге белдерүне ясарга кирәк тапты:

1. Россия һәм Татарстан Язучылар берлекләре, тарихи һәм мәдәни хезмәттәшлек итүдә милли традицияләребезгә тугрылык саклау йөзеннән, Татарстан белән Россия халыкларының мәнфәгатен күздә тотып, киләчәктә дә әдәби, мәдәни элемтәләрне ныгыту, үзара ярдәмләшеп иҗат итү юлыннан атлаячакларын белдерәләр.

2. Һәр ике як, СССР Язучылар берлегендәге хәлне тикшергәч, мондый нәтиҗәгә килде: СССР Язучылар берлегенең, милекнең, финанс байлыгының һәм СССР Әдәби фондының язмышын кичекмәстән үткәрелергә тиешле һәм язучылар тарафыннан закон нигезендә сайланган IX съезд хәл итәргә тиеш.

3. 1991 елның 23 августында СССР Язучылар берлегенең Уставына каршы килеп оештырылган СССР Язучылар берлеге секретариаты тарафыннан кабул кылынган барлык карарларны законсыз һәм һичнинди көчкә дә ия түгел, дип табарга.

4. Һәр ике як, язучыларның барлык Берлекләренә мөрәҗәгать итә: язучыларның мәдәни һәм икътисади хезмәттәшлеген үстерү өчен СССР Әдәби фонды урынына язучыларның суверен берлекләре Әдәби фондының республикаара Советын оештырырга.

5. Татарстан республикасы Язучылар берлеге белән РСФСР Язучылар берлегенең үзара хезмәттәшлеге турындагы Килешүне әзерләргә һәм аңа кул куярга.

РСФСР Язучылар берлегеннән

С. ЛЫКОШИН,
РСФСР Язучылар берлеге сәркатибе.

В. РОГОВ,
РСФСР Язучылар берлеге сәркатибе.

ТССР Язучылар берлегеннән

Р. МӨХӘММӘДИЕВ,
Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсе рәисе.

З. МАНСУРОВ,
Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе.

10 октябрь, 1991. Казан.

# РСФСР Язучылар берлеге белән ТССР Язучылар берлеге арасында төзелгән хезмәттәшлек

# КИЛЕШҮЕ

Бу Килешүгә кул куйганда РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, тигез хокуклылык шартларында, түбәндәге юнәлешләрдә һәрьяклап хезмәттәшлек итәргә килешенделәр:

1. Милли мөнәсәбәтләрне, халыклар мәдәниятен үзара үстерә баруга юнәлдерелгән тарихи эздән дәвам итәргә, ныгытырга.

2. Россия һәм Татарстан язучыларының экономик бәйләнешләрен һәм үзара мөнәсәбәтләрен камилләштерергә, ныгытырга.

3. Россия һәм Татарстан Язучыларының берлекләре арасында масса-күләм информация чараларын таратырга, даими төстә мәгълүматлар алмашып торырга.

4. Нәшриятләрнең үзара элемтәләрен үстерергә; Россиядә һәм Татарстанда татар һәм Россия язучыларының китапларын төрле телләрдә чыгаруда ярдәмләшергә.

5. Язучыларның үзара иҗади элемтәләрен үстерергә; иҗади берлекләрнең эшчәнлегенә һәм башка тормышчан мәсьәләләргә багышланган уртак киңәшмәләр, конференцияләр уздырырга. Иҗади берлекләрнең уртак мәнфәгатен истә тотып, конференцияләр һәм киңәшмәләр вакытында делегацияләр, вәкилләр алмашырга.

6. Республикаларда Татарстан һәм Россия язучыларының иҗат эшенә, ялына кирәкле уңай шартлар булдырырга.

7. Демократик җәмгыять шартларында иҗат кешесенең һәм шәхеснең үз карашларын, инанганлыгын белдерү иреген якларга. РСФСР һәм Татарстан язучыларына карата халыкара авторлык хокукларының тулысынча саклануын тәэмин итәргә.

Килешүнең көче, имзалар салынганнан соң, биш елга исәпләнгән.

РСФСР Язучылар берлегеннән

С. ЛЫКОШИН,
РСФСР Язучылар берлеге сәркатибе.

В. РОГОВ,
РСФСР Язучылар берлеге сәркатибе.

ТССР Язучылар берлегеннән

Р. МӨХӘММӘДИЕВ,
Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсе рәисе.

З. МАНСУРОВ,
Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе.

*Уртак белдерү һәм хезмәттәшлек килешүе Татарстан Язучылар берлеге һәм Татарстан Әдәби фонды идарәләренең киңәйтелгән утырышында кабул ителде.*

# ТИМЕР БИЗӘКЛӘР

Казандагы тимердән чүкеп яки коеп ясау сәнгатенең язмышы бик кызыклы һәм, әйтергә кирәк, бик аянычлы. Бу һөнәр төре Палех, Кубачи, Хохлома, Касли шәһәрләрендәге кебек үк яңгырарга өлгермәсә дә, үзенең иң югары камилләшү ноктасына житеп килгәндә генә, безнең гасырның афәтле утызынчы елларында яшәеш юклыгына дучар ителде.

Казанда яшәүчеләр башкалабыз урамнарындагы тимердән чүкеп, бизәкләп ясалган бик матур рәшәткәләр, капкалар, болдырларның күплегенә инде күптән күнегеп беткәннәр. Ләкин мондый сәнгатькә бай шәһәрләрнең санаулы гына булуын шактый кеше белмидер әле, мөгаен. Дөрес, Мәскәү һәм Ленинград кебек зур калаларда бу өлкәдә заманында Рәсәйнең иң яхшы архитекторлары, рәссамнары, тимерчеләре, коючылары эшләү сәбәпле, андагы манзара җәмәгатьчелеккә электән мәгълүм. Әмма Казанда тимердән чүкеп ясалган әйберләрнең сыйфаты андагыларныкыннан бер дә ким түгел. Бирәдә ул Шәрык һәм Европа бизәү традицияләренең аралашып-үрелеп, үзенчәлекле бер композиция хасил итүе белән аерылып тора.

Казанда тимердән чүкеп ясау сәнгатенең кайчан барлыкка килүе әлегә төгәл генә мәгълүм түгел. Әмма Европада беренче булып Болгар дәүләтендә чуен коюю, аннан соң бу традиция Казан ханлыгына күчеп, алга таба дәвам иттерелүе тарихта яхшы билгеле. Тимерчеләр элек тә бихисап булган, әлбәттә. Башта алар вак-тояк хуҗалык кирәк-яракларын, ә соңрак тимер караватлар, сиртмәләр, чардуганнар да җитештерә башлыйлар. Тора-бара осталар тимердән чүкеп бизәкле архитектура әйберләре эшләү серләренә дә төшенә башлыйлар. Бу төр сәнгать мәктәпләренә нигез XVII—XVIII йөзләрдә салына башлый. Ләкин ул Казан декоратив архитектурасында бары тик XVIII гасыр азаклары — XIX гасыр башларында гына киң таралыш ала.

XIX йөз азагы — XX йөз башларында күп санлы бина түбәләрендә тимердән бизәкләп эшләнгән флюгерләр, манаралар, каланчалар, өйләрдә болдырлар, айваннар ешрак күренә башлый. Һәр җирдә диярлек сырлап эшләнгән ишек тоткалары, тәрәзә кысалары, челтәрле капкалар, култыксалар, әләм кыстыргычлар күпләп куела.

Шул чорларда тимерчелек яңалыклары белән таныштырып бару максатыннан вак һөнәрчеләр өчен махсус альбомнар, вакытлы матбугат чыгарыла. Анда Рәсәй һәм чит мәмләкәтләрдә тимердән чүкеп ясау сәнгате турында мәгълүматлар бирелә, казанныш өлгеләренең сурәтләре дә бастырыла.

Казанның татарлар яшәгән өлешендәге тимер рәшәткәләр, башка әйберләр аеруча үзенчәлекле һәм дикъкатькә лаек. Бирәдә челтәрләп эшләнгән рәсемнәр еш кына милли бизәлеш үрнәкләре булган лалә чәчәге, кояш, ярымай, йөзем тәлгәшләренең сурәтләре белән баетылган. Шулай ук төрле максатларда файдаланыла торган биналарның ишекләре, андагы тоткалар гаҗәеп зәвык белән бизәлгән.

Әйтелгәнчә, совет чорында тимердән чүкеп ясау сәнгатенең традицияләре бөтенләй диярлек онытылды, юкка чыкты. Гәрчә хәзерге заман технологиясе белән тимерне эретеп ябыштыру авыр кул хезмәтен шактый нык җиңеләйштерә алса да, бу һөнәр безнең көннәргә кадәр үстерелеш ала алмады. Шуңа күрә дә башкалабызда һәм республикабызның башка урыннарында әле булган кадәр сакланып калган бу кыйммәтле ядкәрләрне киләчәк буыннар өчен саклап калу безнең иң изге бурычларыбызның берсе булырга тиеш. Шулай ук электән килгән матур һәм кирәкле бу һөнәрне янә аякка бастыру турында да уйланырга бик вакыт, югыйсә.

**Нияз ХАЛИТОВ,**
архитектура фәннәре кандидаты.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы һәм галим Миркасыйм Госманов.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.


# КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

Татарстан китап нәшрияты 1991 елда түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

**Абдулла Алиш.** Койрыклар. 20 бит, рәсемнәр белән. Б. 15 т.
**Фәүзия Бәйрәмова.** Моң. *Повестьлар.* 192 бит. Б. 60 т.
**Марсель Галиев.** Шүрәле һәм жил. 28 бит, рәсемнәр белән. Б. 20 т.
**Рафис Гыйззәтуллин.** Көтелмәгән сорау. *Балалар өчен хикәяләр.* 72 бит, рәсемнәр белән. Б. 15 т.
**Наис Гамбәрев.** Баш очында кояш. *Шигырьләр.* «Шагыйрьнең беренче китабы» сериясеннән. 72 бит. Б. 75 т.
**Миркасыйм Госманов.** Үткәннән киләчәккә. *Очерклар.* 472 бит. Б. 1 с. 25 т.
**Рәдиф Гаташ.** Кар астында гөлләр. *Шигырьләр.* 272 бит, портрет белән. Б. 2 с. 50 т.
**Әмирхан Еники.** Сайланма әсәрләр. Өч томлык. 1 том. *Повестьлар.* («Уяну», «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә»). 464 бит, портрет белән. Б. 3 с. 60 т.
**Фарсель Зыятдинов.** Тагын килде язлар. *Шигырьләр. Поэма.* 96 бит. Б. 10 т.
**Фирая Зыятдинова.** Ташкын. *Шигырьләр, җырлар.* 144 бит. Б. 1 с. 10 т.
**Илсөяр Иксанова.** Ышанасы килә. *Шигырьләр.* «Шагыйрәнең беренче китабы» сериясеннән. 110 бит. Б. 35 т.
**Рәисә Ишморатова.** Тормыш дәвам итә. *Повесть.* 224 бит. Б. 40 т.
**Хатыйп Касыймов.** Акчишмә. *Шигырьләр.* 96 бит. Б. 10 т.
**Кави Латыйпов.** Иркен сулыш. *Шигырьләр.* 112 бит. Б. 90 т.
Мажаралар дөньясында. 1 китап. *Повестьлар.* 256 бит. Б. 55 т.
**Газинур Моратов.** Оча жырлар. *Шигырьләр.* 142 бит. Б. 40 т.
**Вакыйф Нуриев.** Бүре кадәр бүрек. *Көлке хикәяләр.* 72 бит. Б. 15 т.
**Вакыйф Нуруллин.** Сайланма әсәрләр. Ике томлык. 1 том. *Повестьлар.* 496 бит. Б. 2 с. 30 т. 2 том. *Повестьлар.* 432 бит. Б. 2 с. 10 т.
**Басыйр Рафиков.** Вакыт жиле. *Шигырьләр.* 88 бит. Б. 30 т.
**Гәрәй Рәхим.** Татлы сагышларым. *Повестьлар, хикәяләр, публицистика.* 368 бит. Б. 3 с. 50 т.
Сагыналар сине якын дуслар. *Сара Садыйкова турында истәлекләр.* 200 бит, рәсемнәр белән. Б. 65 т.
**Фоат Садриев.** Тозлы бал. *Сәхнә әсәрләре.* 352 бит, рәсемнәр белән. Б. 1 с. 80 т.
Сак-Сок. *Татар халык әкияте.* 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 30 т.
**Хәсән Сарьян.** Нокталы өтер. *Повестьлар.* 416 бит, рәсемнәр белән. Б. 1. 60 т.
Таң ата да кич була. *Такмаклар.* 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.
**Адлер Тимергалин.** Кабул булсын теләгең. *Повестьлар һәм хикәяләр.* 480 бит. Б. 1 с. 20 т.
**Габдулла Тукай.** Кәжә белән сарык әкияте. 40 бит. Б. 1 с. 20 т.
**Радик Фәизов.** Адымнарым. *Повестьлар, хикәяләр.* 320 бит, портрет белән. Б. 1 с. 10 т.
**Мәрзия Фәйзуллина.** Чиккән яулык. *Поэма.* 192 бит. Б. 20 т.
**Нурихан Фәттах.** Шәҗәрә. *Тарихи-лингвистик эзләнүләр.* 325 бит. Б. 1 с. 40 т.
**Зөфәр Фәтхетдинов.** Үлем әлмәге. *Мажаралы роман һәм повесть.* 352 бит. Б. 4 с.
**Ренат Харис.** Көзге мәхәббәт. *Поэмалар, шигырьләр.* 208 бит, рәсемнәр белән. Б. 1 с. 50 т.
**Хәкимҗан Халиков.** Яшел докторлар. 18 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.
**Гали Хуҗиев.** Таныш күзләр, таныш карашлар. *Шигырьләр һәм поэмалар.* 208 бит, портрет белән. Б. 80 т.
**Мөсәгыйт Хәбибуллин.** Илчегә үлем юк. *Тарихи роман.* 384 бит. Б. 1 с.
**Хәйдәр.** Су кызы. *Повестьлар.* 176 бит, Б. 60 т.
**Данис Хәйруллин.** Йөрәк тибеше. *Шигырьләр.* 96 бит. Б. 30 т.
**Лирон Хәмидуллин.** Офыктагы рәшәләр. *Повесть, хикәяләр, очерклар.* 224 бит. Б. 60 т.
**Габдулла Шәрәфетдинов.** Күрше малае. *Балалар өчен повесть һәм хикәяләр.* 128 бит, рәсемнәр белән. Б. 60 т.

*Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин. Адреслар: 420057, Казан шәһәре, Октябрьская урамы, 18. «Китап-почта» кибете. 420084, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. 1 китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.*

Бәясе 1 сум 50 тиен. Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог